# Казан утлары

8.1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

8

1986

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ


## Бу санда


М. ХӘСӘНОВ. **Язгы аҗаган.** *Роман* . . . . 3
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. **Күпер уртасы.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 62
Ф. ЯРУЛЛИН. **Кыйгак, кыйгак каз кычкыра.** *Повесть* . . . . . . . . . . . . . 66
Р. ХАРИС. **Тузга язганнардан.** *Шигырьләр* . . . 118
М. ШАБАЕВ. **Ул — август йолдызларыннан** 124
Ф. Г. ЛОРКА. **Үлем биюе.** *Поэма* . . . . . 125
С. ГӘРӘЕВА. **Урал җиле.** *Шигырьләр* . . . 127
М. ХУҖИН. **Төп нигез.** *Хикәя* . . . . . . 130
М. КАЮМОВ. **Канатлар.** *Шигырьләр* . . . 138

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

М. ЗАРИПОВ. **Мәңге яшел агач җимеше** . . 141
Л. УМАНСКАЯ. **Җиңүчегә — чәчәк бәйләме** 149

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Ф. С. СИБАГАТУЛЛИН. **Үргә күтәрелгәндә** *(Мамадыш районы)* . . . . . . . . 151

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ЮНЫС. **Исәннәрнең кадерен бел** . . . . 155
**Тәрҗемә турында сөйләшәбез** . . . . . . 160

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Шагыйрьлекнең ике канаты** . . . . . . . . . . . . . 164

КОНКУРСКА

Ә. СӘХӘПОВ. **Кемнәр алар — «һәм башкалар»?** . . . . . . . . . . . . 168

ФОЛЬКЛОР

**Себер татарлары әкиятләре** . . . . . . . 172

СӘНГАТЬ

Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Бергә гомергә . . . . 177

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

С. ЧЕРВОННАЯ. Җәүһәрләргә тузан кунмасын . . . . . . . . . . . . . . 181
Ф. ИБРАҺИМОВА. Мәгърифәт йорты . . . 186

Кызыклы хәлләр . . . . . . . . . . 188
Культура тормышы көндәлеге . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИННУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Роман М. ХАСАНОВА «Весенняя зарница» (окончание). Повесть Ф. ЯРУЛЛИНА «Крик гуся». Рассказ М. ХУЗИНА «Родительский дом». Стихи РОБЕРТА АХМЕТЗЯНОВА, Р. ХАРИСА, С. ГАРАЕВОЙ и М. КАЮМОВА. Публикация М. ШАБАЕВА о творчестве Ф. Г. Лорки. Сказки сибирских татар.

«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» — очерк М. ЗАРИПОВА «Вечно зеленое дерево» (о проблемах Нижнекамского нефтехимического комплекса). Статья Л. УМАНСКОЙ «Гвоздики — победителям»(новые формы в организации социалистического соревнования).

В рубрике «Татарстан — родной мой край» — статья первого секретаря Мамадышского райкома КПСС Ф. С. СИБАГАТУЛЛИНА.

В рубрике «Литературная критика» — литературный портрет поэта Ш. Галеева. В журнале продолжается дискуссия о проблемах перевода.

В номере рецензируются книги Р. Файзуллина и Л. Ихсановой.

Статья С. ЧЕРВОННОЙ о новых материалах художественного творчества народа. Публикация Ф. ИБРАГИМОВОЙ о первой публичной татарской библиотеке.

Занимательные истории из жизни знаменитых личностей татарской культуры.

Дневник культурной жизни.

На наших обложках — творчество художника Е. Зуева.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Г. Салихҗанова*, *Ч. Фәтхуллина*.

Производствога бирелде 21.05.1986 ел. Басарга кул куелды 28.07.1986 ел. ПФ 01108. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 62449. Заказ В-202. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

## Мәхмүт Хәсәнов

# ЯЗГЫ АҖАГАН

РОМАН

### Алтынчы көн

I

Башкарылган эшебезгә йомгак ясау көне иде бу. Барыбыз да халык депутатларының Чаллы районы башкарма комитеты утырышлар залына җыелдык. Шактый ук күңелсез, бик гомуми сөйләшү булыр дип уйлаган идем, әмма ялгышканмын. Чынлыкта исә командировкамның иң кызыклы, иң эшлекле көне шушы алтынчы көн булды.

Ул җыелышта безне, Кама буе нефте турында сөйләшүдән тыш, тагын бер нәрсә көткән икән. Хәер, нинди олы вакыйга буласын райбашкармага барып кергәч тә төшенергә мөмкин иде. Анда газета-журнал, радио-телевидение хәбәрчеләрен дә очраттым.

Билгеләнгән вакытта — төп-төгәл сәгать унда көткән кеше килеп тә житте. Бу — илебезнең иң эре төзү оешмаларыннан саналган, меңләгән төзүчеләрне туплаган берләшмәнең житәкчесе иде.

Менә ул трибуна артында. БАМ, Атоммаш кебек бөек төзелешләрне телгә алганнан соң, сүзне безнең Чулман төбәгенә күчерде. Илебез автомобиль төзелешенең алгы сафына басарга тиешле КамАЗны да, тиздән калкып чыгачак егерме-егерме бишәр катлы мәһабәт Аккаланы да, Европада иң зурлардан саналачак Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсен дә, ГЭСын да, шушы тирәдә калкып чыгачак Татарстан атом электр станциясен дә, трактор заводын да телгә алды.

— Илебездәге иң олы төзелешләрне күргән-белгән кеше мин,— диде ул.— Әмма мәшһүр Чулман буенда калкачак корылмалар барыбер хыял житмәслек шикелле тоелалар. Моны аңлау өчен бүгенге Чаллының тиздән миллион кешеле шәһәргә әвереләчәген генә әйтү дә бик житәдер. КамАЗ үзе генә дә бөтендөнья төзелешенә әвереләчәк. Бүгеннән үк инде Көнбатыш илләренең йөздән артык атаклы фирмасы бу гигант төзелештә катнашырга теләкләрен белдерде. Елына йөз илле мең зур йөк автомашинасы эшләп чыгаруга исәпләнгән Кама автомобиль берләшмәсе, фән һәм техниканың иң яңа казанышларын, СССР халыклары дуслыгын, аларның хезмәт батырлыгын гәүдәләндерәчәк. Бер үк вакытта

---

Ахыры. Башы 5, 6, 7 саннарда.

ул күпләр өчен чыныгу, җитлегү, хезмәтне фәнни оештыру мәктәбенә әвереләчәк... Коммунистик төзелешнең алгы сызыгы саналган бу эшләрдә дә комсомоллар башлап йөриячәк. Бүген үк инде меңнәрчә һәм меңнәрчә яшьләр, комсомол юлламасы белән, Чулман буена килергә теләкләрен белдерделәр. Бу төзелешләрнең һәркайсы яшь замандашларыбыз дәрт-дәрманына һәйкәл булачак. Аларның «Эшебез гасырларга калырлык булсын!» дип тырышачагына ышанам...

Бу көтелмәгән очрашудан мин, канатлар куелгандай, дәртле бер хис белән чыктым. Һәм миңа ничәнче тапкыр инде күңелем түрендә: Эх-х, теләсә кемне дулкынландырырлык итеп халкыбызның бөеклеген, заманыбызның олы вакыйгаларын, кайнар сулышын лаеклы гәүдәләндерә алсаң иде икән дигән фикер туып тойдым.

* * *

Гази ни кылырга да, җанын кая куярга да белмичә, һаман ята да ята. Билгесезлектә могҗиза көтеп яшәү өзгәли лә икән үзәкләрне. Якты көне күптән инде төнгә әверелде, әйләнә-тирәсе караңгы җәһәннәмгә охшап калды. Үч иткән кебек, уйлары да нәкъ картларныкыча, әллә кайларда йөриләр-йөриләр дә, ниндидер эчке авазга буйсынып, ихтыярсыздан үткәннәргә, яшьлегенә кабат әйләнеп кайталар.

Менә хәзер дә ул, чит-ят җирне шактый таптаганнан соң, туган якларына кайтып төшкән чакларын күз алдына китерде. Шактый еллар үтүгә дә карамастан, пароходтан төшеп, беренче тапкыр туган туфрагына аяк баскан чагын, соңгы сулышы чыгып, күзләре йомылганда да онытасы юк.

Соңгы пароходларның берсе белән кайтып төште ул. Көз иде. Һәркайда шыксыз ачы җил хакимлек итә. Иртә-кич аяк асларын шатырдатып туңдыра. Ләкин Газига бу яклар гаять тә ягымлы, гаять тә матур булып күренде. Күңел күзе шулай итеп күрергә теләгәндер инде...

Район үзәге Чаллыда әле яңа гына шаулап Октябрь бәйрәме үткән. Шул тантана уңаеннан эленгән кызыл әләмнәр, лозунглар һәм транспарантлар да алынмаган иде.

Гази үзе белән күп җирләрне гизгән иске чемоданын кулына, биштәрен аркасына аскан көе пароходтан төште. Яр өстенә күтәрелде. Әйберләрен бер читкә куеп, җиргә тез чүкте... Исәнмесез, үскән җирем, эчкән суым, йөргән сукмакларым! Саумы, гөлгә тиң яшьлегемә сөенеп туймый яшәгән туган ягым! Саумы, рухымны җылытып, йөрәгемне ымсындырып, күңелемне җилкендереп торган газиз туфрагым! Ашыгып-ашкынып кайттым... ерак чит-ят җирләрне гизеп. Кабул ит, нахак җәберләнгән үксез balaңны...

Бер яктан: «бу көннәрне дә күрәсе бар икән!» — дигән уй туса, икенче яктан: «инде кая барырга?» — дигән сорау да башын калкытып куя иде. Билгеле, хәзергә әле Газиның омтылышы бер: ул да булса — туган авылына кайтып егылу. Әмма туган авылына якынлашып килгән саен: «Ә кем янына?» дигән сорау туып, күңелне бимазалап куя иде. Билгеле, бер-ике көнгә кем янына да сыеп булыр, куып чыгармаслар. Шулай уйлана торгач, тагын да ачырак хакыйкать ачылгандай булды Гази өчен. Кара инде, ә! Бер генә туган-тумачалары да юк икән ләбаса! Менә бит, ә!.. Әтисенең яшьтәш-көрәштәшләре дә кайсы Бөек Ватан сугышында, ә кайсы соңрак үлеп-нитеп беткәннәрдер инде.

Уйлый калсаң, хәйран калырлык. Һаман да шул, әлеге дә баягы, изге җанлы бер Җәүһәрия утырып калган. Аның да хәзер кардәш-туганлыгы ташка үлчим... Бер турылыклы, шәфкатьле күңеле генә бар. Тажиның, Җәүһәрияне ташлап, кайдадыр нефть районнарының берсендә башлыкузле булып, шактый зур түрәгә әверелеп яшәве турында ишетеп белә иде инде Гази. Кече энесе Һади да кайдадыр шул якларда адашып калса кирәк...

Газига сайланып, баш ватып торырлык чама калмаган иде инде. Ул туган авылына кайтып, иң элек әтисе белән әнисенең каберенә баш иргә булды. Берьюлы шунда Җәүһәрия килен янына кереп, иң авыр вакытларда ярдәм кулы сузып, җан саклап калырга булышканы өчен рәхмәт әйтеп чыгар...

Гази җәһәт кенә күтәренде дә район үзәгенең югары очына таба юл тотты. Алар авылына шуннан чыгып китәләр. Салаязныкылар машиналарны һәм олауларны, гадәттә, шул башта көтәләр.

Озакламый, доңгырдап, зур ябык әрҗәле машина килеп чыкты. Кабинасында кеше барлыгын күрсә дә, Гази механик рәвештә кулын күтәрде. Машина, тирә-юньгә тузан бөркеп, аның янына ук килеп туктады.

— Кая?..— дип сорады яшь кенә егет.

— Салаязга иде...

Егет дәшми-тынмый гына кабинасыннан сикереп төште дә машинасының арткы ягындагы ишеген ачты.

— Менегез! Без үзебез Салаязга түгел. Шулай да аңар орынып ук узачакбыз.

— Ярар, ярар!..— диде Гази.

Ул утырган машина механика мастерское булып чыкты. Бер якта эскәнҗә беркетелгән верстак сузылган. Гази, шул верстак буена килеп басты да, тимер рәшәткәле бәләкәй генә тәрәзәдән карап бара башлады.

Рәшәткәле тәрәзә... Күпме юллар үтелмәде, ниләр күрмәде бу газиз башкайлар!

Күктә авыр болытлар йөзә. Көя күбәләкләренә охшап, тузгып-тузгып төссез кар бөртекләре очкалый. Шулай тәрәзәдән күзләрен алмыйча уй-хыялларына бирелеп, туган авылы җирләренә кайтып җиткәнен сизми дә калды Гази. Менә «Тау өсте басуы» дип атала торган киңлек. Әле дә хәтерендә, малай чагында алар монда яшел кузак ашарга менәләр иде. Ә инде көз көне, борчагы җыеп алынгач, коелып калган бөртекләрне чүпләрләр иде... Берәмләп кенә җыйсалар да, «шти» пешерерлек борчак кайта торган иде. Нишләмәк кирәк, тормышларының бер генә вакытта да тулы-житенке булганын хәтерләми Гази.

Машина кинәт туктап калды. Аны уйларыннан арындырып, яман чайкалдырып туктады. Әле дә ярый ике куллап верстакка тотынып калды. Югыйсә түрдә яткан төрле тимер-томыр өстенә барып капланасы икән. Көч-җегәр, хәл беткән шул дип уйланып куйды Гази.

Шофер егет тышкы яктан ишекне ачты.

— Килеп җиттек, абзый кеше... Хәзер без Чакмалыга борылабыз.

— Рәхмәт сезгә...— диде Гази.

Егет аңар әйберләрен чыгарышырга һәм текә баскычтан төшәргә ярдәм итте. Гази, нык җиргә төшеп басу белән, егетне бәхилләтергә теләп кесәсенә тыгылды. Әмма шофер: «Сез нәрсә!..» — дип, бимазалаган чебен-черкидән котылырга теләгәндәй итеп, кулын гына селтәде. Аннары кабинасына сикереп менеп,үзе артыннан ишекне шапылдатып япты да, тирә-якка зәңгәрсу төтен-сөрем бөркеп, китеп тә барды.

Гази төшеп калган урыннан авылның арт урам дип атала торган өлеше генә күренә. Төп өлешен зират каплап тора. Озак хозурланып тормады Гази, яңадан күтәренде дә, зираттан чак кына читтәрәк, авыл башындагы калкулыкта торган ялгыз кабер — әтисе кабере янына юнәлде. Менә ул... Олы гына таш куелып, рәшәткә белән уратып алынган. Рәшәткәсе муртаеп, череп беткән. Эчке якта, утыртылган таш төбендә, уңып төсләрен җуйган кәгазь чәчәкләр ята...

Гази чардуган буена әйберләрен урнаштырды да кабер алдына чыгып басты. Баш киемен салды. Яссы ташка чокып язылган сүзләрне укыды: «Авылның беренче коммунисты, ячейка секретаре Хаҗи Зәкиев. 1922 елның язында кулаклар тарафыннан вәхшиләрчә үтерелде».

Бераз басып торганнан соң, кабат каберне әйләнеп чыкты. Шул ва-

кыт кабер ташының каралган бер өлешенә акбур белән: «Дан сезгә, дан, Хажи абый!..» — дип язып куелган сүзләр чагылды. Йомры хәрефләренә караганда, бу инде, һичшиксез, Хажи абыйлары кебек үк курку белмәс батыр булырга хыялланучы малайлар эше иде.

Ыргып-ярсып искән көзге ачы җил үзенекен итте: Газины чынлап торып дерелдәтеп, калтыратып алды. Якасын күтәреп куйды, кепкасын батырыбрак киде. Аннары инде: «Ярар, әти... Мин тагын килермен әле»,— дип, әйберләрен эләктереп, зиратка таба юнәлде.

Зиратның киртәләре тәмам мыртаеп, череп беткән, урыны-урыны белән хәтта бөтенләй коелып төшкән. Әле дә ярый, зират кырыйларын буйдан-буйга куе булып котырып үскән канәфер, карга миләше куаклары каплап тора.

Гази череп җимерелеп төшкән киртә аша атлап, зиратның «Иске рәт» дип атала торган башына керде. Моңсу күренеш каршы алды аны. Йөзәр яшьлек карт тупыллар, кәкре-бөкре булып үскән моңсу каеннар, күптән инде шәрәләнгәннәр. Ваграк агач-куаклар да яфракларын койган. Зират киңәеп ачылып калган. Бәлки шуңа күрәдер, каберләр дә, ничектер, кинәт кенә кубәеп киткән кебек күренделәр. Аларның күбесе иңгән, инде җир белән тигезләнеп, көзге яфраклар астында бөтенләй югалып калган, кабер икәнлеген дә белер хәл юк. Ә бит анда кемнәрнеңдер якыннары, кайчандыр сөйгән-сөелгән кешеләр ята. Кешеләр!.. Һай-й, бу дөнья дигәнең!

Гази әйберләрен яшен сукканга охшап чәрдәкләнеп, сынып төшкән бер агач төбенә куйды. Як-ягына күз салды... Тирә-юньдә эре-эре яссы сөякләрне хәтерләтеп саргаеп, вакыт үз тамгасын салудан кара-күчкылланып калган ташлар гына ята. Аларга ай сурәте төшерелеп, гарәп хәрефләре белән ниндидер сүзләр язылган. Кайберләренең язулары тәмам эштән чыккан, укырлыклары калмаган. Шунда ук, сирәк-мирәк кенә булса да, буралап эшләнгән чардуган калдыклары күренгәли. Ләкин алар да инде күптән черек өемнәренә әверелгәннәр. Бары тик бер чардуган сакланган, ул да булса, заманында Мәккәләрдә булып кайткан Садыйк хәзрәт чардуганы иде. Шактый урынны биләп торган бу чардуган, яссы таштан өелеп, ниндидер сыекча белән катырып салынган.

Гази түргәрәк узды. Кайдадыр, зиратның авыл ягы өлешендә, аның әнисенең дә кабере булырга тиеш. Бу турыда Гази бары тик хат аша гына белә. Әнисе белән соңгы тапкыр саубуллашуын гына хәтерли ул. Әнисе, мәрхүмә, газиз баласы белән соңгы тапкыр күрешүен сизенде ахрысы, тыела алмыйча, сулыгып-сулыгып елап калган иде. Шулчак Газига, кабер түмгәкләрен хәрәкәтләндереп, җир сулыш ала сыман булып тоелды...

«Әнинең каберен Җәүһәриядән сорарга кирәк булыр. Шәт ул белә торгандыр»,— дигән уйлар белән ул яңадан әйберләре янына килде. Шунда беренче авыл советы рәисе Бәһрам карт кабере тап булды.

Урам буйлап үткәндә аңар әллә ни дикъкать итмәделәр. Хәер, олы юл өсте шул, үтеп-сүтеп йөрүчеләргә халык күнегеп беткән. Менә нәрсә гурыңдадыр бик зәһәр бәхәсләшеп бер көтү малай-шалай узып китте. Әнә чишмә буеннан менеп килүче бер төркем житкән кызлар һәм киленчәкләр күренде. Әле генә каз өмәләре башланган ахрысы, су буеннан менүчеләрнең дә көянтәләренә чиләк урынына өчәр-дүртәр каз түшкәсе эленгән.

Гази, шул төркемдә Җәүһәрия киленнәре дә юкмы икән дип, кызжилкенчәкләр ягына күз салды. Хәер, булса да Гази аны хәзер барыбер танымас иде. Ул киткәндә, Җәүһәрия әле җиләк кебек житлегеп килә торган япь-яшь кыз, Тажи белән дә йөрешеп кенә маташкан чаклары иде. Аннан соң бит инде күпме гомер үтте, күпме сулар акты...

Гази кайчандыр үзләре яшәгән, төп йортлары торган урынга килеп житте. Әтисе салган нигезгә. Хәзер монда жиде ятлар яши. Алты почмаклы, калай түбәле, бик житенке йорт тора...

Туган нигезнең ташлануына да бик күп еллар үткән шул инде. Үзләренең йорты тузып, яшәрлеге калмагач, әниләре Җәүһәрия килеңнәренә күченә. Бу турыда да Гази хатлар аша гына белде.

Гази уйлавынча, Җәүһәрия дә шушы урамда, шушы тирәдә генә яшәргә тиеш иде. Ул адымнарын әкренәйтеп, як-ягына каранып алды. Берәрсеннән сорап белешү нияте белән, бер өйнең җил капкасы турысында туктап калды. Юк, аңар өйгә кереп, сорашып-нитеп йөрергә туры килмәде, бая су буеннан менеп килүче төркемнән аерылган бер кыз аңар таба якынлаша иде инде. Гази авыр йөк күтәргән яшүсмер кызны күтеп алды. Башта исәнләште, аннары йомышын әйтте.

— Менә ике йорт аша безнең күршедә генә тора ул Җәүһәрия апа,— диде кыз, юлыннан бүленеп. Көянтәсенең як-ягына дүртәр, буш кулына яңадан ике каз түшкәсе аскан. Шулай да Гази яныннан китеп барырга ашыкмады, туктады. Ап-уланган йөзен кабат Газига таба борып, тартынып кына:

— Сез әллә Гази абый буласызмы?..— дип сорап куйды.

Бу көтелмәгән сорау каушатып җибәрде Газины.

— Әйе, мин бу —... диде ул, кызның каз тәпиләре кебек кып-кызыл кулларына күз төшереп.

— Җәүһәрия апаны сорагач, шулайдыр дип уйлаган идем аны. Алайса, кайтуыгыз котлы булсын, Гази абый!..

— Рәхмәт!..

— Безгә дә кереп утырыгыз, Гази абый. Әтиләрнең дә хәзер эшләре кимеде...

— Рәхмәт, үскәнем! Ә үзең кем кызы соң син?

— Күршегез Муса кызы мин.

Гази ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

— Кит инде! Гайсә Мусасыныкымы?

— Шуныкы инде...

Туган җиргә аяк басмас борын, үзеннән шактый яшьрәк кешенең үсеп буйга җиткән кызларын күрү, шуның өстенә әле якты йөз белән чакырып торулары әллә нишләтеп җибәрде Газины. Боек күңеле күтәрелеп киткәндәй булды.

Кыз юлын дәвам итте. Ә Гази әле генә ул күрсәткән капкага таба юл тотты...

Җәүһәрия өйдә иде. Ниндидер папкалар, кәгазьләр белән мәш килеп утыра. Газины күрү белән үк таныды, кәгазьләрен читкә ташлап, урыныннан сикереп үк торды.

— И-и, Гази абый кайткан лабаса! Шаклар катам... Менә бит, ә!..— дип хәтта чак кына балавыз да сыгып алды.— Исән-сау булгач, бер күрешәсең икән аны... Кара инде, ә!.. Гази абыйны да күрер көннәр бар икән! Менә бит, ә! Шаккатам!

Кырык эшен кырык якка ташлап, шундук табын әзерләде, чәен-мәен дә чыгарып куйды. Тиресеннән чыгардай булып бөтерелде Җәүһәрия. Көндезге эшенә дә бармады. Баскыч төбенә чыгып: «Бик кадерле кунагым бар... Барып йөри алмам. Үзегез генә карарсыз анда...» — дип кемгәдер кычкырып керде.

Үзе сөйләнде, үзе ут уйнатып бертуктаусыз хәрәкәтләнде. Иң элек, каз баш-аяклары һәм бүтәкәләре тутырып, тегермән ташы кадәрле бәлеш ясап тыкты. Ул да булмады: «Мунчага ут төртеп килим әле»,— дип, өстенә дә киеп тормыйча, янә өермә кебек чыгып йөгерде.

Көннең ничек үткәнен сизми дә калды Гази. Ә инде кичен, утлар алгач, ул кемгә дә булса ир-атлы күршеләргә кереп куну турында сүз кузгатты. Җәүһәрия аңар авыз да ачырмады. Хәтта бераз үпкәсен дә белдергәндәй итте.

— Нинди сүз ди ул тагын. Юк, юк! Булмаган нәрсә белән башыңны катырма әле. Шаклар катам! Беркая да бармыйсыз. Менә сезгә өй,

менә сезгә йомшак урын-җир. Ә үзем мин төнен-төн буе фермада булам. Дежур торам. Һәр төнне берничәшәр сыер бозаулый хәзер...

Җәүһәрия китеп, биш-алты минут үттеме икән, капка келәсе янадан шалтырады. Юк, өй хуҗасының кире борылуы түгел иде бу. Нәкъ шул вакытта кемнеңдер баскыч төбендә, аннан өйалдында әкрен-салмак кыймылдап, ишек янына якынлашканы ишетелде. Бусагада, таягына таянган, бик бетәшкән бер карчык пәйда булды. Шактый ук соңгарып килеп кергән карчыкны күргәч, Газиның бәгырен өтәләп, ниндидер бик таныш бер сискәнү дулкыны үтте.

Ул арада карчык артыш таягын ишек яңагына сөяп куйды да күксел тамырлардан гына торган, корышып каткан кулларын алга таба сузып, Газига таба якынлаша башлады.

— Газиулла балам!.. Синме соң бу?!. Ярабби, төш кенә түгелдер ич... И-и, дөньялар! Исән-имин генә кайттым дисең инде алайса...

Гази башта, күгелҗем иреннәре тоташтан дерелдәп торган карчыкны танымыйчарак торды. Әмма тәмам якынлашкач, аның җилсенгән күз төпләрен, арык йөзен күргәч, төсмерләде, әнисенең якын ахирәте, гомерлек дусты, Салиха карчык иде бу. Бермәлгә Гази, үзен ничегрәк тотарга белмәгән кеше сыман, аптырабрак калды. Әмма озакка түгел, шундук карчыкка таба атлап, куш кулын сузды.

— Исәнме, Салиха түти!..

— Газиулла кайткан дигәч, дөньялардан китәм икән дип торам. И-и, ходайның рәхмәтләре! Газиз башкайларың исән булгач, бер әйләнеп кайтасың икән аны. Бу шатлыклы, бу куанычлы көннәрне, бичаракай, әниең генә күрә алмады. Язмаган икән. И-и, көткән дә иде, бәгырькәем. Авыр туфраклары җиңел була күрсен, ахирәттә оҗмах нурлары белән нурлансын, берүк...— Салиха карчык, шәленең очы белән йөзен каплап, елапсыктап алды.— Әлегедәй күз алдымда, бәгырькәем, капка төбенә чыгып утырыр иде дә, күзләрен Чулман ягы юлларыннан алмас иде. Иллә-мәгәр көткән дә иде үзеңне, мәрхүмә...

Гази, түрдән урын күрсәтеп, әбине утырырга чакырды.

— Хәзер, хәзер, Газиулла балам... Чак кына хәл алам да... Кайтуың турында ишетү белән, соң дип тормадым, тыным кабып килеп тә җиттем менә...

— Килеп чыгып бик һәйбәт иткәнсең,Салиха түти, үзем дә кереп, хәлеңне белеп чыгармын дип тора идем әле.

Карчык утырды. Шәлен чишеп, бишмәтенең төймәләрен ычкындырып җибәрде. Нәкъ менә әбинең шушы хәрәкәтләрендә Гази әнисенең чалымнарын күргәндәй булды.

— И-и, заманалар! Шул газиз балакаемны бер күрсәм, сәламәтләнеп үк китәр идем, карап күзләрем талмас, сөйләп сүзләрем бетмәс иде, дигән сүзләре әле дә булса хәтер төбемдә. Шул инде! Бала өчен ана йөрәге әрнемичә кемнеке әрнесен ди. Ана күңеле бала өчен нәние биләүдә чакта гына түгел, балигъ булгач та сызлый. Баланы тикмәгә генә бәгырь җимеше димәгәннәрдер шул..

Әби кеше, иркен сулыш алган сыман, бер генә мизгел дәшми торды да Газиның хәлләре белән кызыксына башлады. Әмма Гази үзе турында җәелеп китеп сөйләргә ашыкмады, ничектер, тартына калды. Моны сизенгән Салиха карчык сүзне үзе дәвам итте.

— Әй-йе, Газиулла балакай, тормыш дигән нәрсә җитәрлек каккан алайса үзеңне... Язмыштан узмыш юк ди шул. Сугышта булуларың бер хәл иде. Сугыштан соңгы хәбәрләр бик ватты мескенкәйне... Шул инде, хыял-максат тау артында, бәла-каза ишек алдында димәсләр иде аны. Әлеге яман хәбәрләр ишетелгәч, гомер буе кан саркытып җәфалый торган мәңге төзәлмәс җәрәхәт алган сыман булды мәрхүмә. И-и, тотынды, ялгыз башы моңаерга, гомер бакый онытасым юк ул көннәрне. Ә үзе, эчендә янган утта көеп, сулып калса да, сер бирмәскә, түбәнсенмәскә тырышты...

Гази сүзгә икенче төрлерәк юнәлеш бирергә теләгәндәй, әнисенең озак авыру-авырмавы белән кызыксынгандай итте.

— Бик газапланмадымы соң?

— Җук, Газиулла балакай, урын хастасы булып озак ятмады. Ә инде тәрбиягә килгәндә, киленегез Җәүһәриягә мең рәхмәт. Улы ташлады дип тормады, үз өендә, үз әнисен тәрбияләгәндәй карады. Аллаһе тәгалә озын гомер, бәхет, тәүфикъ бирсен үзенә. Аяк-куллары сызлаусыз булсын. Тагын шул: хәерхаһ кешеләр күп иде. Мөхтәрәм картлар да күп җыелды. Бераз соңгарып булса да, энеләрең дә кайтты... Ходайның биргәненә шөкер, үзем күзләрен йомдырдым, үзем кәфенләдем, мәрхүмәне...

Ул арада Гази, җәһәт кенә иелеп, караваттастына тыгылган чемоданыннан бер төргәк чыгарды.

— Менә, Салиха түти, шушыны җылы кулларың белән кабул итеп ал әле. Әниемә дип әзерләгән бүләгем иде. Үлгәнлеге турында ишеткәч: газиз анамның күзләрен йомдыручыга булыр дип, күңелемә беркетеп куйган идем...

— И-и, Газиулла балам!.. Бердән, ходайга, икенчедән, сиңа мең-мең рәхмәтләр укырмын. Миндәй ятимә карчыкның шулай күңелен күрүләрең өчен аллаһе тәгалә үзеңә бәхет, озын гомер бирсен...— Салиха карчык иелә төшеп, тагын тавыш-тынсыз гына елап алды.— И-и, аллам, Газиулла балам! Сине күргәч үземнең Сәлимҗаным белән Галимҗанымны күргәндәй булдым...

— Алар да кайтмадылар, алайса?..

— Җук. Җиде-ят җирләрдә, яу кырларында шәһит киттеләр... Сугыш дигән нәрсә аяуны белми икән шул ул! Мең-мең нәләт аңа. Күпме михнәтләр кичердек шуның аркасында. Ялгызлыкта үләрмен, дип башыма да китермәгән идем кана... Ялгыз картлык — вакыт җитми үлүгә тиң икән ул, Газиулла балам. Шул газиз балакайларымның вафат хәбәрләрен алганнан бирле, баш әйләнү өянәгенә тарыдым. Син дә мин корт-каның моң-зарыннан туйгансыңдыр инде. Үзең, үзең турында әйт, нинди уй-максатлар белән яшисең? Син әле, ходайга шөкер, яшь, үз көчең, үз җегәреңдәге кеше. Сиңа тагын бер сөаль: ни ... ни дип торам, үзең яшәгән җирләрдә башлы-күзле булмагансыңдыр бит?..

Гази елмаймыйча булдыра алмады.

— Каян килеп, Салиха түти!

— Алай димә син, Газиулла балам, юл озын, гомер кыска дигәндәй, гелән йөрәк өзгеч зар белән яши алмассың. Әй-йе!..— Карчыкның тагын нәрсәдер әйтергә җыенуын, нәрсәдер житкерергә бик теләгәнлеге йөзенә чыккан иде.— Ни, Газиулла балам... Җәүһәрияне әйтәм әле, өенә кадәр ямьле шуның, хуш исле, муллык җитенкелек исе. Иллә-мәгәр уңган да инде, берүк күзләр генә тия күрмәсен үзенә. Әнә фермаләрдә дә: шул уңган Җәүһәрия белән янәшә эшләгәндә, гадәти көн дә бәйрәм булып тоела, дип әйтеп әйтәләр ди...

Икенче көнне Газины чәйгә дип тә, ашка дип тә чакырдылар. Гайсә Мусаларында да булды. Ул алдынгы механизатор булудан тыш, колхозның партоешма секретаре да икән әле. Табын мул иде. Сүз дә җитәрлек булды. Билгеле инде, Газиның кай тирәдәрәк төпләнергә уйлавы турында да сүз чыкты. Гази яшермәде: әгәр дә мөмкинлек чыкса, больница тирәсенә, үзенең төп эшенә урнашырга теләге барлыгы турында ачыктан-ачык әйтте.

Кунакчыл авылда ике-өч көн рәттән аштан-ашка йөргәннән соң, тынгысызлана башлады Гази, тормышына тизрәк ачыклык кертү теләге туды. Энесе Һади янына, Таулыга юл тотканга кадәр, иң әүвәл, яшьлегенең бер балкышы булган, җанына бик тә газиз Чулман буйларын бер әйләнеп кайтырга ниятләде. Яшьлек эзләре буенча хыялларга бирелеп бер йөрсә, күңелләре тулыланып, җаны бөтенәеп, мәңге төзәлмәс йөрәк яралары чак кына язылып китәр сыман иде.

2

Гази, дөньяларын онытып, Рәхимҗанның хикмәтле, гыйбрәтле маҗаралар тулы хикәяләрен тыңлап утырган авылдашларын күздән кичерде. Халык кичәгегә караганда да күбрәк җыелган. Түшәктә яткан хасталарга кадәр аякланганнар иде ул кичне.

Рәхимҗан абые каршында, эленмәле җиделе лампаның икенче ягында, хуҗабикә утыра. Шушы арада гына, авылда иң беренчеләрдән булып иренең үлгән хәбәрен алган Сабира атлы яшь сылу хатын. Ире Зариф бөтен Чаллы районында атаклы механизатор иде. Шунлыктан өйләре дә авылда бер шул аларның. Әнә хуҗабикә, күзләрен бер ноктага төбәгән килеш, нәрсәдер уйланып утыра. Берсеннән-берсе бәләкәй өч бала белән нихәлләр итәрмен, дип уйлыйдыр ул мөгаен. Шундый хафалы уйлардан авыраеп калган башкаен әледән-әле күтәреп-күтәреп куйгалый ул. Дөрес, аңа кара печәтле кәгазь килмәде. Әмма бер-бер артлы ике хат алды ул. Баштагысын, русча язылганын, Зарифның фронтташ иптәше җибәргән. Аларның икесен дә авыр туп сөйрәп йөри торган тракторга билгеләгән булганнар. Юлда бик яман бомбага тотылганнар. Зариф шунда һәлак булган. Ниндидер Кунцево станциясе янындагы туганнар каберлегенә үз куллары белән җирләве турында язган иде. Үз-үзен аңлый алмас бер халәттә саташып йөргәндә, икенче хат китереп тоттыралар Сабирага. Монысын инде Зариф үз кулы белән язган була. «Әнисе, бүген иртәгә фронтка озатырлар дип торабыз. Анда ни көтәдер, хәзергә әйтүе кыен. Уйларымда да, төнлә төшләремдә дә гел сез. Сине, әнисе, бәләкәйләремне сагынуга чыдар чамалар юк...» Ул хатларның әнә икесе дә матча ярыгына кыстырып куелган...

Рәхимҗан башларыннан кичкәнне ашыкмыйча гына сөйли. Аны сулыш та алмыйча тыңлыйлар. Шактый ук йомык, аз сүзле күршесенең гәп сатарга шул кадәр үк сәләте бардыр дип Газиның башына да килгәне юк иде. Әнә ни турында гына сөйләмәсен, күз алдына китерә дә бастыра бит, имансыз.

— Иргали абыйны бәхетле йолдыз астында тумаган дип кара инде син! Шунда, җәһәннәм читендә, кара тайга уртасында, танышы очрап торуын күр әле син аның. Танышы дип әйтү бик үк дөрес тә булып бетмәс. Башта Кайзер Германиясенә, соңрак акларга, чит ил интервентларына каршы бер частьтә сугышканнар, бер окопта ятып, солдат тормышының барлык ачысын-төчесен бергә татыган булганнар. Бар бит әле дөньяда ике күреп бер сөйләшкәнне туганыдай якын итә торган олы җанлы, киң күңелле бәндәләр. Роман да нәкъ шундый урыс иде.

Очрашулары да бик мәзәк булды. Берсе: «Миргалиев, братан, син түгелме соң бу! Син ич! Менә дөньяны кысан димә инде син моннан соң...» дип, икенчесе шаккатып: «Роман!..» дип, бер-берсенә ташланып, иң якын туганнар кебек, кочаклашып күрештеләр. Китте исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашу. Китте гәп, китте сүз, түз генә.

— Я, братан, сөйләп җибәр, нинди җилләр, нинди ачы язмышлар китереп ташлады сине бу якларга?

— Син әйтмешли, ачы язмыш хикмәте, Роман...

— Булмас ла!

— Чыны шул.

— Бездә: адәм ышанмаслык сүзне атаң сөйләсә дә ышанма диләр. Син бит акгвардиячеләргә, Антантага каршы көрәшкән батыр кызылармеец. Ут, су һәм бакыр торбалар аша үткән ир-егет! Командирлар сине башкаларга үрнәк итеп куялар иде. Хәтерлисеңме Перекопны, «кара барон» Врангельне?.. Һични аңламыйм, братан, дөресен генә әйт әле, нәрсә булды? Ничек килеп чыкты мондый хәлләр?..

— Була икән ул, Роман. Кешегә авырлык салып та яшәмәгән идем. Була икән... Юк белән, бөтенләй пүчтәк белән шушы көнгә калдым.

— Әй-йе, братан, биек нәрсә янына җил шаукымы чүп-чарны күбрәк җыючан була шул...

— Иң яманы, Роман, туган илдән, туган туфрактан аерылу.

— Аңлыйм. Туган як — кеше гомеренең таяну ноктасы гына түгел ул...

Озата килүчеләр китеп баргач, без тулысынча әлеге Роман карамагында калдык.

Бик хикмәтле кеше булып чыкты ул. Авызы һәрчак ерык. Шул ерык авызы сүздән бушамас үзенең.Сүзе дә гелән уңай якка, гел без дигәнчә тагын. Роман диганебез ике көнлек ял игълан итте, барыбызны да фатирларга таратты, һәркайда мунча ягарга, олау башына бирәр мич ипи салырга фәрман бирде. Ә безне үзенә алды. Шунда ихлас олылап, бик тә үз күреп, яратып, риясыз кунак итте. Шунда гомеремдә беренче тапкыр буларак аю итеннән, аюның бавыр-бөерен туң майда катырып әзерләнгән сэбярин диган ризыкны авыз иттем. Телләремне йотам дип торам. Сый-хөрмәттән табыннар сыгылырлык иде. Хуҗа кеше, бераз төшергәч, Иргали абыйны кабат кочагына алды. «Юк, Миргалиев, теләсәң нәрсә диген, әмма синең, революция солдатының, батыр кызылармеецның җинаятьче булуына үтерсәләр дә ышанмыйм. Монда нидер караңгы!..» — ди бу.

Билгеләнгән көнне таң белән острогка җыелдык. Хәер, аның инде хәзер төрмә диярлек җире калмаган. Кайчандыр тоткыннар яшәгән баракларны пушнина, ягъни җәнлек тиресе кабул итү пунктына әверелдергәннәр. Лапасларны келәт иткәннәр. Ныгытманың бер өлешен агач эшкәртү, такта яру цехына әверелдергәннәр.

Атлар җигелгән, олаулар бәйләнгән, кыр казлары сыман итеп капкага каратып тезеп куелган. Иртәнге һаваны яңадан Роман тавышы ярды. Килгән чаклы ук булмаса да, алда озын сәфәр, яхшырак әзерләнегез, янәсе. Җитмәсә тагын юл, күп дигәндә, бер-ике генә авыл аша узачак. Төннәрне дә йолдызлар астында гына үткәрергә туры киләчәк икән.

Киң күңелле Роман бәйләм-бәйләм көрәкләр, чалгылар, балта, пычкы ише нәрсәләр чыгарып өйде. Кызып китеп бер зур гына лапасның ишеген ачып җибәрде. Анда җәнлек тиреләре, башка төрле товарлар өстенә каплый торган бөркәвечләр, капчык-торыпшалар. Роман көлә, шаяра. Алыгыз, янәсе, әмма яхшылыгымны хәтерегездән чыгармагыз. Сезнең хәлегез, имештер, чегәннәрнекеннән дә яманрак. Аларның, ичмаса, җил-яңгырдан ышыклану өчен кибиткалары була. Ә сезнең баш очыгызда ачык һава, тирә-юнегездә кара тайга гына булачак. Ширпы, тоз, сабын, керосин кебек әйберләрне дә күбрәк алырга кушты, яшереп-нитеп маташмады, барып урнашачак җирегездә каккан казык та юк, диде ул.

Ә инде безне Роман дәдәйнең озата барачагын ишеткәч, сөенеп бетә алмадык, әчләргә җылы кереп, күңелләр күтәрелеп китте. Ниһаять, йөкләребезгә тагын торыпша, көрәк, бүтән кирәк-яракларны өстәдек тә юлга чыктык. Юлларның юл диярлеге юк иде ул тирәләрдә. Кая карама, күлдәвек, сазлык-баткаклык.

Роман дәдәй дөрес әйткән, чыннан да беренче төнне тайгада кундык. Кая таба күз салма, көмеш томан бөркелгән урман киңлекләре, шомлы һәм серле карурман ешкынлыгы. Өлкә үзәгеннән чыкканнан бирле, бу безнең беренче тапкыр төнне ачык күк астында уздыруыбыз иде. Арбаларны агачлар арасынарак кертеп, урта бер җирдә мәйдан сыман нәрсә ясадык. Атларны, аю-фәләннән саклау өчен, эчке якка алдык. Уртада берьюлы ике-өч урында зур-зур учаклар яктык. Тайга эченнән әледәнәле шомлы авазлар ишетелә. Атлар тынгысызлана. Күзләре аларган. Романның Иргали абыйга бүләк итәр өчен ияртеп лайкасы, бүре алуыннан курыккандай, карангылыкка карап, елый-елый өрә. Иң теңкәгә тигәне, әлбәттә, чебен-черки иде. Аларның өтәләвеннән, талавыннан муенбитләр, куллар күптән инде тоташ җәрәхәттә. Черки, озынборын тавы-

шыннан бөтен тайга чыңлап тора сыман. Балаларның әлеге тамашага чыдый алмыйча елашуыннан йөрәкләргә кан сава. Бераздан атлар кая керергә тишек тапмый башлады, безнең янга төтен эченә ыргылалар, кешниләр.

Бөтен мәйдан эчен төтен белән ыслап, ничек кирәк шулай төнне уздырдык. Хәер, төн диярлеге дә юк иде аның. Бер яктан, тоташ күе томанга төрелеп, караңгы инсә, икенче яктан, һәрнәрсәне манма чыкка манчып, таң атты. Анда таң да бездәгечә атмый. Ничектер күңелләргә шом салып, бөтен дөньяны иңләп тайга янып килгән сыман, кояш чыгасы як кан кебек кызыллыкка манчыла. Иртүк торып, утларны бик һәйбәтләп сүндереп, зуррак кисәүләрне күмеп, янә юлга чыктык.

Өйлә вакытлары авышкач, зур гына бер авыл аша узарга туры килде. Кешеләр әллә ни күзгә чалынмады, бары тик этләр генә һау да һау килеп озатып калды.

— Игътибар беләнрәк карап үтегез бу авылга,— диде Роман.— Хәтерегездә тотыгыз, сезгә иң якын авыл шушы булачак. Авыл Советы да шушында.

Авыл артта калды. Аны чыгып,бер-ике сәгать үттекме икән, урман чак кына сирәгәйгән сыман булды. Юллар да күзгә күренеп үзгәрде. Изрәп-ялтырап яткан болганчык сулы күлдәвек тә, арба көпчәкләре җимергән сазлык-баткаклыклар да бетте.

Без барган бу ачыклыктан бик күптәннән бирле атлылар үтмәгәнлегенә төшенү өчен әллә ни зур зирәклек кирәкми иде. Арба эзләрен куе үлән, вак куаклык басып киткән. Бака яфрагы түшәлгән аучылар сукмагы да аермачык булып ярылып ята.

Тагын күпмедер юл үткәч, иләмсез зур ачыклыкка килеп чыктык. Роман дәдәй «перевал» игълан итте. Әлеге ачыклыкны күздән кичерәм. Ул шыксызның да шыксызы, ялкыны сүнгән тәмугны хәтерләтеп торган, янгын кичергән бер урын иде. Аланның түрге өлешендә, күзгә ял биреп, оя-оя яшь усаклар гына агарынып утыралар. Урта бер җирдә, анда-санда тырпаеп торган агачлар арасында, аучылар телендә кышлау дип атала торган сыңар тәрәзәле генә ялгыз бер бүрәнә йорт тора. Өйне дә күздән кичереп чыктым. Түрдә, ярган сайгаклардан ятак ясалган. Агартмаган мич буенда ике-өч ягарлык коры утын белән каен тузлары ята. Кашагасына ярты кап шырпы куелган. Тәрәзә каршындагы өстәл өстендә ике калай савыт: берсендә тоз, икенчесендә ниндидер ярма. Тайганың язылмаган законы буенча аучылар шулай бер-берсе турында кайгыртышалар икән.

Мин ул өйдән чыкканда бик күпләр атларын туарып утлауга җибәргәннәр, хатын-кызлар учаклар ягып мәш килә иде инде. Күрәм, ир-атлар каяндыр яр астыннан чиләк белән су алып менеп атларын эчертәләр, казан-чәйнекләрне тутыралар. Шунда юнәлдем. Һәм текә яр астында, күз тиюдән курыккандай куе агачлар артына яшеренеп кенә агып яткан мул сулы, көчле агымлы елганы күреп, хәйран калдым. Юк, алай мин уйлаганча ук шыксыз урын түгел икән ләбаса!

Мондый уй тикмәгә генә күңелем төбендә тумаган, күрәсең. Көтмәгәндә-искәрмәгәндә килеп чыккан бер кечкенә генә вакыйга безне бөтенләйгә шул урында төпләнеп калырга мәҗбүр итте. Әлеге дә баягы шул Сиражи атлы кешебез китереп чыгарды ул могҗизаны. Чиләк алып, аучылар сукмагыннан суга төшеп барган җиреннән гөрселдәп җиргә ауды да: «Туганнар!.. Күрегезче... соң бу бит безнең йорт, нигез тараканы!..» дип, кешеләрнең өнен алып, еламсыраган тавыш белән разбой салды. Аның мүкәләп диярлек бер җирдә бөтерелүен күргәч: елан-фәлән чактымы әллә үзен, дип баштарак пошаманга төштек. Ду кубып йөгерешеп янына килдек. Ә ул, учына алган нәрсәне югалтудан курыккандай, бер үк сүзләрне тәкрарлапмы тәкрарлый: «Күрегезче, туганнар!.. Күрегез!.. Йорт тараканы ич бу... Кешеләр белән мәңге бер нигездә яшәүче җан иясе... Я, раббым! Безгә дә шушы урынны нигезебез итәргә, шушын-

да төпләнеп, газиз туфракны үбеп, антлар итеп, тамыр җәяргә, нәселебезне дәвам итәргә язды микәнни?!. Нәкъ үзе бит... Күрегез, йорт тараканы бит...»

Бу көтелмәгән хәлдән кайберәүләр тәмам аптырап хәйран-вәйранга калдылар, икенчеләре, мәзәк табып, теш агартырга кереште.

Беренче карашка, Сираҗиның сукмак өстеннән өй тараканы табып алуында алай бер дә ис китәрлек нәрсә юк та иде кебек. Кем белә, бәлки җил-җил килеп су ташыганда берәрсенең кием-салымыннан төшеп калгандыр. Мондый хәлнең булуы бик ихтимал иде. Чөнки кайларда гына туктамадык, нинди генә урыннарда төн уздырырга туры килмәде, анда гап-гади өй тараканы гына түгел, әллә нинди хәшәрәтләр дә ияртергә мөмкин иде.

Сираҗиның үз тугызы тугыз, бернигә дә игътибар итмичә сөйләнүен белде. Имештер, аның бабасының бабалары да, көчләп чукындырудан качып, нәкъ безнең кебек өерләре белән күз күрмәгән, колак ишетмәгән якка чыгып китәләр. Алар да, нәкъ безнең кебек, нининдидер бер кыргый урында йорт тараканына тап булалар. Шунда, газиз туфракны үбеп, нәсел-ыругны үрчетергә, буынны дәвам итәргә антлар эчеп, нигез коралар.

— Без дә җәмәгать, туктыйк шушында... Үкенмәссез, туганнар! Өй тараканын, нигез тараканын очратуны борын-борынгыдан яхшыга юраганнар, изге фалга санаганнар. Ә инде кешенең гомерлек өйдәше авылдан качса, ул авылдан игелек тә, бәрәкәт тә кача, имештер. Андый авылны кичекмәстән ташларга кушканнар, чөнки аны иртәме-соңмы, барыбер яман афәт көтәчәк, дип өсти торган булганнар ил картлары...

Ул арада бөтен ир-ат һаман да әле җирдә утырган Сираҗи янына җыелып өлгергәннәр иде инде. Иргали абый белән Роман дәдәй дә шунда. Аңа мәзәк, Сираҗи әйткән сүзләр белән кызыксына. Иргали абый аңлаткан-төшендергән саен тегенең ансыз да ерык авызы тагын да ерыла бара. Соңыннан ул да, Иргали абыйны якын күреп, үз фикерен әйтте. «Әгәр дә урын чыннан да ошый икән, пожалуйста, мин каршы түгел,— диде ул.— Бергәләп киңәш-табыш итегез дә, конкрет карарга килегез. Ә урыны чыннан да шәп!Елгасы үзе генә дә ни тора. Мөлдер сулы чишмәләре дә әнә кул сузымында гына...»

Иргали абый шунда катгый бер карарга килеп, җыелган ир-атка утырышырга кушты һәм: «Нишлибез, җәмәгать?..» — дип, беренче җыенкиңәшмәне ачып җибәрде. Сүз алып сөйләү кадәресе юк, аның каравы сорауларны яудырыпмы яудыралар. Шуңлыктан иң әүвәл сүзне Роман дәдәйгә бирделәр. Иргали абый янына, түгәрәк эченә, кереп урнашкан Роман дәдәй, бу хәлне алдан ук көтеп алгандай, түш кесәсеннән карта чыгарып, тезләре өстенә җәеп салды. Нечкә генә чыбык алып, хәзерге минутта безнең кай тирәдәрәк булуыбызны аңлата башлады. Әмма аның һәрбер сүзен диярлек, шунда ук берьюлы ике-өч сорау белән бүлә тордылар.

— Бу нинди елга?.. Кая таба ага?..

Икенче берәве, сүзнең бүленүенә үзенең ризасызлыгын белдереп, әйтә сала:

— Нинди булсын, Инәсәй елгасының берәр тармагыдыр...

Юк икән шул. Ярына Себернең борынгы башкаласы урнашкан Үб елгасы кушылдыгы булып чыкты ул. Исеме дә безнеңчә, саф татарча икән.

Бу хәбәр күңелдә берничә төрле хис уятты. Моннан ике-өч кенә көн элек Инәсәй елгасы буенда идек, кай арада шул кадәр ара үттек соң әле? — дип, башта йөрәк жу-у итсә, елганың нәкъ үзебезчә аталуы күңелне юатып җибәргәндәй булды. Андый чакта адәм баласына күп кирәкмени соң!

Роман дәдәй, чыбыгы белән карта өстенә төрткәләп, хәзер алар туктаган аланлыкны аучылар «Кешеле эрбет» дип йөртүен әйтте.

— Ә ни өчен алай дип атаганнар?..

— Чыннан да, ни өчен «Кешеле»?..

— Кем белә инде аны, белсәләр аучылар беләдер,— дип җаваплады Роман дәдәй.— Менә монда, елганың өске өлешендә, бая без узган Ильня дигән зур гына авыл. Ерак түгел, күп дигәндә, унбиш чакрымнар чамасы гына. Рус авылы. Таза яшиләр. —Роман дәдәй, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, чак кына уйланып торды да дәвам итте.— Шул ук авылда бөтен Себердә атаклы Михай-Баянай дигән аучы яши. «Сыңар яңак» дигән кушаматы да бар...

— Ә ни өчен алай дип атаганнар?..

— Бер яңагын «Тайга хуҗасы», ягъни аю, «сыйпаган»...— Роман дәдәйнең кысынкы күзләрендә елмаю, әллә шаяра, әллә чыны шул, аңламассың анықын.

— Йомышыгыз төшсә, аңа мөрәҗәгать итү ягын карарсыз. Алтын кеше. Хатыны эвенк. Аның өчен милләт аермасы юк. Әгәр дә хак булса, аның янына аю ауларга дип Тобольск, Енисейск татарлары да килгәлиләр, ди...

Кемгә ничектер, әмма Михай-Баянайның исеме үк минем күңелемә хуш килде. «Михай» дигәненнән бигрәк, үзебезчәрәк яңгыраган «Баянай» дигән өлеше ошады, күңелгә сары май булып ятты. Нindидер изгелек, тел белән әйтеп аңлатып булмый торган миһербанлылык бар иде сыман бу исемдә. Ә инде Михай дәдәйнең үзен күргәч, якыннан танышкач, җан дуслар булып киткәч, ялгышмавыма тәмам төшендем. Соңрак «Баянай» дигән сүзнең мәгънәсен дә белдем. Эвенкча: сунарчылык алласы дигән сүз икән.

Роман дәдәй, тезләре өстенә җәеп салган картадан күрсәткәләп:

— Менә монда, агымның өске өлешендә, тагын бер авыл бар. Моннан егерме-егерме биш чакрымнар чамасында. Староверлар, баптист-сектантлар яши. Җәй көннәрендә яннарына барырмын димә, кеше-фәлән үтеп керә алмаслык сазлык-баткаклыклар эченә яшеренеп утырганнар. Башка дин кешеләрен бер дә өнәп бетермиләр. Кыскасы, кыргый халык. Совет власте һаман да үтеп керә алганы юк. Законнары үз кулларында. Җинаять ясаган кешеләренә хөкемне дә үзләре ясый, җәзаны да үзләре билгели. Законнары каты, җәзалары яман — гаепләне җәен дә, кышын да, анадан-тума чишендереп, агачка бәйләп куялар. Өч-дүрт сәгать тә үтми, кеше әзер: кышын — бозга әверелә, җәен — черки, озынборыннар талап үтерә...

Авызларын ачып, хәйран калып тыңлап утыручылардан кайсыдыр сорап куйды:

— Безгә зыян-җәберләре тимәсме соң?..

Роман дәдәй гадәттәгечә елмайды да, бернинди шик-шөбһәгә, хафалануга урын калдырмаслык итеп әйтте:

— Юк, фанатик булсалар да, үзегез зыян-җәбер салмасагыз, бар да һәйбәт булыр.

Шуннан соң Сиражи сүз алды. Ул туктаган урынны мактады, төрле яктан килгәнлеген әйтте, җәннәт белән генә чагыштырмады инде.

Өлкән кеше дип, Шаһиулла картның да сүзен ишетергә теләделәр. Кыстатып тормады карт, тамагын кырып алды да, сакалын сыйпаштырып, әзер тәгъбирләр белән сиптерә дә башлады...

— Минем уй-фаразымны беләсегез килсә шул: без күңел ачарга чыккан сәйяхлар түгел... Тагын ни диим? Инде төпләнәсе урынга килсәң, күреп торасыз: алла каргаган кара урман уртасы. Дүрт тарафны да адәм баласы үткесез тайга биләгән... Иге-чиге бардырмы аның, белгән юк. Әййе! Сайланыр форсатыбыз юк, язмыш тәкъдиренә буйсынырга туры килер. Югыйсә, алла сакласын, тагын әллә ниткән бәлаләргә таруыбыз бар. Башлыгыбыз Иргали зирәк бәндә күренә, аның ихтыярына беребез дә киртә булмабыз. Нәчәлнигебез дә без, мөселманнарга карата бик миһербанлы күренә. Ул әйткәнгә дә күник, ходайга тапшырып, шуны муафыйк күрик. Киләчәктә насыйп булса...

Иргали абыйның йомгаклау сүзеннән соң җыен таралды. Тирә-юньдә ниндидер башка төрлерәк җанлылык башланды. Чөнки һәркем әйләнә-тирәгә башкача карый башлаган иде инде. Тайганың янгыннан калган, кара көйгән өлеше дә баштагыча ук җан кайтаргыч булып күренми, гайрәтне чигерми иде. Чөнки һәркем бу тирәләрне хәзер үзенең тормышына, киләчәгенә бәйләп карый. Аның күз явын алырдай булып матураюы тулысынча үзләренә, бары тик үзләренә генә бәйле булачагын үйлый иде. Кешеләр зур эшкә алынырга җыенгандай, бер-берсе белән киңәш итәләр, вакытлыча гына булса да ниндирәк куыш әмәлләү турында баш ваталар. Кемдер баз казып керү хәерлерәк булыр• ди. Икенче берәве: тереләтә караңгы каберга керер хәлем юк дип, тирмә-чатыр юнәтү ягында.

Без исә икенче төрлерәк карар кабул иттек: ике арбаны янәшә куйдык та, астын төнгелеккә ятак, ә өстен якты «бүлмә» ясарга булдык. Менә кайчан кирәк булдылар Роман дәдәй биргән капчык-торыпшалар!

Ул арада Роман дәдәй безне озатыша килгән сакчыларын үзе янына чакырып алды да ниндидер йомыш кушты. Тегеләр сикерешеп торып, мылтыкларын кабат күздән кичергәннән соң, яннарында мәш килгән Лайканы ияртеп, елга буе сукмагы белән ешлыкка кереп югалдылар.

Күп тә үтмәде, тайга эченнән, җиз кыңгырау чыңлаганны хәтерләтеп, Лайканың өргәне ишетелде. Ул да булмады, барчабызны сискәндереп, бер-бер артлы мылтыктан атулар һаваны ярды...

Бераздан сакчыларның берсе, туарып җибәргән атларын тотып, янә урман эченә кереп юк булды. Күп тә үтмәде, сука калагына охшаган мөгезләре белән җирне сөрдереп, тау кадәрле ике пошины сөйрәтеп ачыклыкка чыгардылар. Сугымчылары да бик тиз табылды.

Көн кичке якка авышу белән, Роман дәдәйләр китәргә җыена башлады. Беренче эш итеп, нәрсәгәдер чиксез куангандай, алсу телен чыгарып сикеренгән Лайканы безнең арбага бәйләп куйды. Тайганың үз законнары, этсез булмый, янәсе. Монда нәселле яхшы эт — күз дә, колак та.

— Я, братан Миргалиев! — диде Роман дәдәй яңадан Иргали абыйны кочагына алып. — Әйдә, саубуллашыйк... Тик озакка түгел. Атна-ун көннән ничек тә килеп чыгу ягын карармын. Бер дә булмаса, башка берәү аша азык-төлек, бүтән кирәк-яраклар җибәртү чарасын күрермен. Ә хәзер, әйләнечрәк булса да, авыл аша китәбез. Михай-Баянайга сезнең турыда хәбәр салып чыгарга кирәк булыр. Иртәгәдән дә калмыйча янына үзең бар. Тагын шул: хуҗа булып син каласың, барысы өчен дә җавап синнән соралыр. Хәзергә авылыгыз булмаса да, авыл советы председателе вазифасы сиңа йөкләнә. Картага да «Кешеле Кедрач аланы» дигән урынга «авыл» дип тамга сугылды. Мин дә кайту белән отчет ясыйм... Кабатлап әйтәм, иртәгә ук «Сыңар Яңак» янына барасың. Тайганың үз законнары — кеше бер-беренә аеруча мәрхәмәтле, миһербанлы монда, һәрхәлдә, ташлап бетермәсләр...

Шулай итеп, тайга уртасында өелдек тә калдык. Кич житте. Халык сагайды. Сизәм, һәммәсен, ниндидер шомлы киеренкелек иза чиктерә. Ир-ат кына түгел, хатын-кызлар да, каядыр билгесез бер якка йөгерә башларга җыенгандай, балаларын кулларыннан төшермиләр.

Күрәм, барчасының күзе Иргали абыйда. Юк, күзләп кенә калмадылар, киңәш-табыш итәргә җыенгандай, безнең арбалар тирәсенә елыша ук башладылар. Белмим, әгәр дә шулчак Иргали абый да ихтыяр көчен бер генә мизгелгә югалта-нитә калса, нишләгән булыр идек икән без. Ләкин ул һәркем үз язмышын, үз киләчәген аңа ышанып тапшырганны күңеленең кай өлеше беләндер тоя, мондый хәлдә авыз йомып калырга тиеш түгеллеген дә сизенә, андый сүзнең бу минутта кеше күңеленә өмет чаткысы булып ятачагын, яшәргә ышаныч тудырачагын, дәртдәрманны көчәйтеп җибәрәчәген тоя иде булса кирәк. Табигать сирәк очрый торган акыл, зирәклек биргән бер зат ул.

Сүзне бик гади нәрсәләрдән башлады Иргали абый. Атларны тышауламаска, арканламаска кушты, буталып-егылып аяклана алмыйча харап булулары бар диде. Яшь балалы хатын-кызлар төнне аучы алачыгында уздырыр диде. Анда ышык, черки-чебеннән котылуы да җиңелрәк булыр. Ачык һавада калучыларга да эш табылды: төнлә кизү тору өчен нәүбәт билгеләде. Берничә урында зур итеп учаклар ягарга, сизгер-сак булырга, төрле көтелмәгән хәлләргә әзер торырга, йокы белән мавыгып, бөтенләй онытылып китмәскә кушты. Янныбызда кораллы сакчылар юк, икеләтә-өчләтә уяулык таләп ителәчәк дип өстәргә дә онытмады.

— Язмыштан узмыш юк, кардәшләр...— диде ул.— Җылап-шыңшып, ялынып-ялварып, язмышның шәфкатьсезлегеннән зарланып кына хәзер бернәрсә дә үзгәртеп булмаячак. Тәкъдир шаяруларын чын ир-егетләрчә кабул итә белергә кирәк. Чөнки безгә сайлар өчен бүтән төрле тормыш та, язмыш та юк. Арада, бәлки, ул-бу коткармасмы, бераз сабыр итик диючеләр дә табылыр. Ләкин алдан ук шуны әйтәсем, кисәтеп куясым килә: һәрбер өмет тормышка ашып бетми... Өмет кенә морадка җиткерсә, һәркем кул кушырып утырыр иде, тик утыру — үзмаксатка әверелер иде. Безнең юл ул түгел. Күреп торасыз, кардәшләр, тормышыбызны буш урынга, тигез җиргә казык кагудан башларга туры киләчәк. Әйтергә теләгәнем шул: дөнья көтү, тормыш итү тулысынча үз карамагыбызга тапшырылды. Бер нәрсәгә анык төшеник, кардәшләр, киләчәгебез, иртәгәге көнебез тулысынча үз кулыбызда. Баш очыбызда түбә, абзар-кураларыбызда мал-туар, келәтләребездә икмәк булсын дибез икән — монда вәгазь, үгет-нәсихәт артык — яшәвебезнең рәвеше дә, мәгънәсе дә безнең хезмәтебезгә бәйле. Көч сарыф итми, кара тир түкми булмас. Җиң сызганып, булсын дип бергәләп алынсак, иншалла, тамакка интекмәбез. Мир белән этәргәч, тау күчкән ди. Хөкүмәтебезгә килсәк, ул үзе безгә ярдәм кулы сузарга тора. Ссуда биреләчәк, өлкә үзәгендә үк белештем.

Иргали абый фикеренчә, кешенең бөтен олылыгы да, бөеклеге дә, дәрәҗәсе дә — хезмәттә, бары тик хезмәттә. Эш белгәнгә — уңыш юлдаш ди бит. Үзегез беләсез, эш дигәндә Иргали абый җан атып тора. Хезмәт белән юана да, куана да торган кеше ул. Нинди генә эшкә алынмасын, ул башкарган һәркемгә үрнәк иде. Тере ялкау булудан мәет булуың артык дип кенә җибәрә иде ул.

— Киләчәккә йөз тотып, көр күңел белән яшик, кардәшләр. Дөрес, морадыбызга ирешер өчен байтак вакыт кирәк булыр. Түзәргә туры киләр, илдәшләр, сынаулардан сыгылмыйк.— Бу сүзләрдән соң тыңлап торучыларның күзләрендә өмет чаткылары кабынгандай булды, йөзләре ачылып китте.— Монда без яхшысын да, яманын да күргән кешеләр. Һәркемнең иңендә үз язмышы йөге. Ул яктан ходайга шөкер... Һәркайсыбызның үз үткәне, анда теләсә кемнең тыкшынырга хакы юк. Кирәге дә юк. Үткән беткән. Һәркем кулы белән кылганны җилкәсе белән күтәрә. Дөрес, арада нахакка гаепләнгәннәр дә бардыр. Кайчандыр өстебезгә ябырылып килгән бәла-казалар, михнәт-газаплар, кара кайгы, ачы хәсрәтләрне юлда килгәндә арбадан төшеп калдыга саныйк, илдәшләр! Яңа тормыш башлыйк. Коргаксыган күңелләр язылсын. Хәзер бөтен көч-дәрманыбызны туплап шул яңа тормышыбызны төзүгә юнәлтик. Гаилә иминлеге дә, үзара татулык та, ахыр чиктә, җан тынычлыгы да — хезмәттә, кардәшләр. Мәгълүм хакыйкать бар: бәхетне аны эзләп түгел, эшләп табалар. Ә без — белгәнегезчә, бәхет эзләүчеләр. Ә бәхет эзләүче бәхетледән дә бәхетлерәк дигән бер акыллы баш.

Халык арасында чын күңелдән көлешеп алдылар.

— И-и, рәхмәтнең иң зурысы сиңа, Иргали туган!..

— Авызыңа бал да май.

— Акыллыдан акыллы сүз шул...

— Тагын бер үтенечем бар, кардәшләр! Зур үтенеч!..— дип кабатлады Иргали абый.— Халкыбызның йөз суын түкмик, хилаф эш кыл-

мыйк. Без монда яңа кешеләр. Бик җентекләп күзәтерләр, сынарлар, һәркайда ихтирамлы татар халкы дигән могтәбәр исемгә тап төшермик. Болар татарлар дип һәркайда, һәрчакта исемебезне хөрмәт белән телгә алсыннар...

Кеше сүзе кешегә шулкадәр тәэсир итә дип әйтсәләр, баштарак ышанмас идем. Иргали абый сүзләре дә кешеләрнең йөзләренә нур иңдерде, күңелләренә канат куйды, үз көчләренә ниндидер инану тудырды. Кешеләр таралды, төрле җирдә гөлт итеп учак ялкыннары кабынды. Алар да җанлырак яна төсле. Казаннарда пошн ите кайный. Һәркайсы, көндәлек гадәти эше белән шөгыльләнгәндәй, шактый ук иркен хәрәкәтләнә. Тыз-быз килеп учак янында кайнаша яки, төн үткәрү өчен, куыш әзерләү белән мәшгуль иде.

Кичке ашны бик тиз түгәрәкләдек. Шуннан файдаланып мин дә, чебен-черкидән сакланыр өчен йөземне, муен-кулларымны дегеткә буядым да, черем итеп алырга ниятләнеп, башымны арба астына тыктым. Ничек яткан булсам,шул көе «мәрткә» дә киткәнмен...

Кемнәрнеңдер иләмсез каты итеп тарткалап-төрткәләвеннән, нәкъ ямьсез төш күргәндәге кебек, уянып киттем. Нәрсәләрдер дөпе-дөпе килүеннән, кемнәрнеңдер ачыргаланып кычкыруыннан йөрәгем ярыла икән дип торам. Көч-хәл белән аңыма килсәм, тирә-юньдә — мәхшәр. Халык шашкан диярсең... Атлар арбалар арасына, мәйдан эченә бәреп кергәннәр. Шашкан сыман бер-берсе өстенә меңәләр, әйлән-бәйлән уйнагандай, бер урында зыр-зыр килеп әйләнәләр-тулганалар. Тояклары астында җир тетри, шатыр-шотыр килеп коры агачлар сына. Атлар пошкыруына, суйгандагы сыман кешнәвенә кемнәрнеңдер акырганы-бакырганы кушыла. Кемнәрдер җан-фәрманга буш казаннарны, савыт-саба нше нәрсәләрне кага. Утлы кисәүләр белән коралланган кешеләр акыра-бакыра әрле-бирле йөгеренәләр. Лайка өзгәләнә. Бер сүз белән әйтсәң,хәйран-тамаша, мәйдан эчен ут алган диярсең.

Бу көтелмәгән хәлдән зиһенем чуалып китсә дә, җәһәт кенә сикереп торып, халык мәш килгән якка ташландым. Шунда мәгълүм булды: әле яңарак кына бирегә тайга хуҗасы — аю килгән булган. Ул куптарган икән әлеге ыгы-зыгыны.

Ул төнне бүтән ятарга туры килмәде. Ут янына җыелып алган ир-атлар өзми дә куймый да, «төнге кунак» турында гәп саттылар. Сүзнең төрлесе бар. Кайсыдыр: туктаган урыныбыз алла каргаган тоташ тайга гына түгел, аю төбәге дә икән әле. Беренче кем күргән? Атларны ничегрәк итеп куркыткан? Ничегрәк үкергән? Ничекләр итеп качып киткән?..

Таң беленү белән, Иргали абый, ат җигеп, Н. авылына барырга җыена башлады. Үзе белән-бары тик Сиражины гына аласы итте. Миңа тирә-юньгә күз-колак булуны тапшырды.

Ул арада яныбызга Шаһиулла карт белән каенесе килеп басты. Сүзне Шаһбаз башлады, мине дә үзегез белән алыгыз диде. Шулчак, уртак сергә үзебез генә ия булыйк дигән кыяфәт белән як-ягына каранды да: «Менә ни өчен мине алырга кирәк»,— дигәндәй, пәлтә чабуын ачып, һәйбәтләп иңенә аскан мылтыгын күрсәтте. Көпшәсе киселгән чын винтовка иде бу. Йөрәгем жу-у итеп китте. Ничекләр итеп шушы тиклем җирләргә кадәр саклап алып килә алган диген син аны!

Шундук икенче уй туды башта. Бүген төнлә савыт-сабалар, буш казаннар кагып, «чакырылмаган кунак»ны өркеткәндә ни өчен коралын кулланмады икән бу эт? Тегене кабат күздән кичерәм. «Минем белән чамалабрак эш итүегез сорала»,— дигән кыяфәттә горур басып, салпы мыегын тагын да аскарак тарткалап тик тора бу. Аның караве күз карашлары йөрәккә сугарлык, бөтереп-бөрештереп китерерлек.

Әмма обрезны күрсә дә, Иргали абый әллә ни сер бирмәде.

— Тыныч яшим дисәң, беренче булып кулыңа корал алма, башкаларга янама,— диде ул, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Шундук: — Хәтереңә бик нык сеңдереп куй бу сүзләрне,— дип өстәп тә куйды.

Сүзгә карт кушылды.

— Алай димә әле, кем, мелла. Таныш булмаган авылга таяк тотып кер, этләре булуы мөмкин дигән борынгылар да. Әй-йе!..

Иргали абый бу сүзне дә колак яныннан гына уздырып җибәрде. Моны абайлап алган Шаһбаз да, ачы елмаеп, соңгы сүзен әйтте.

— Мәйлең! Һы-ы!.. Безнең якта тагы: иртәгә мәет булганчы, бүген кораллы булуың хәерле дигән мәкаль дә бар...

Иргали абыйлар якты көздә әйләнеп кайтып та җиттеләр. Артларында тагын бер җигүле ат. Арбада өч ир-ат. Шунда беренче тапкыр Сыңар яңак Михай-Баянай дәдәйне күрдек. Ярсаң ике, томырсаң өч бүлырлык өрлектәй таза бәдәнле кеше. Киңчә йөзле, чалара башлаган сакал-мыеклы. Тузгып торган чәченә дә бәс кунган. Әмма якынрак килеп йөзенә багу белән әллә нишләп китәсең: урыс халкына килешеп торган җитенке сакал яңагының бер ягында гына. Сул яңагы исә чигәсеннән иягенә кадәр шәп-шәрә, төерләнеп торган күгелҗем яра белән капланган. Ләкин Михай дәдәй әлеге кимчелеген яшерү әмәлен тапкан, әлеге сырланып зәңгәрсу тамырлар тибеп торган төерле ярасын, җитенке чәче белән әледән-әле каплап-яшереп куйгалый.

Михай дәдәй арбасыннан төшкәч үк ут янына җыелган халык белән берьюлы исәнләште. Ә инде юан бүрәнә өстенә килеп утыргач, тайга турында, без килеп урнашкан аланлык турында сүз башлады.

— Тайга — безнең газиз өебез ул: җылыта да, ашата да, киендерә дә, кирәк чагында бәла-казадан да саклый,— диде.

Без килеп урнашкан аланлыкның авыл өчен уңайлы, җайлы булачагы турында да сүз куертып алды. Искәрмәстән генә татарлар турында гәп сатарга кереште. Олы җанлы, тугрылыклы, хезмәт сөючән батыр халык дип атады. Тел төбенә караганда, Инәсәй, Тубыл татарлары арасында якын танышлары да бар икән. Көзгә таба, тайгада чебен-черки бераз басылу белән, Алтай тауларына күченеп киткән мараллар — эре Себер боланнары кайткач, татарлар ауга киләләр, имештер.

Чебен-черки турында сүз чыккач, ул хәшәрәтләрнең елына ике ай чамасы вакыт эчендә, җитмәсә, җәйнең иң матур чорында, тормышның бөтен ямен алуыннан, кешеләргә генә түгел, мал-туарга, җәнлек-киеккә дә ак-кара күрсәтмәвеннән, талап-өтәләп җелекләренә үтүләреннән зарланып алды.

Шундук ул үзенә ияреп килгән яшьрәк иптәшләренә нәрсәдер әйтте. Тегеләрнең берсе арбалары янына барып, авызын чүпрәк белән бәйләгән кечерәк кенә чүлмәк алып килде.

— Чыдар чамагыз калмаганда, балаларыгызга менә шушы даруны сөртерсез,— диде ул, әлеге хикмәтле савытны Иргали абыйга тоттырып.

Елга буен тоташ стена сыман каплаган куелыкка күрсәтеп, җил керсен өчен аны бераз сирәгәйтергә кушты. Бөтенләй шәрәләндереп тә бетермәгез, җәй артыннан кыш киләсе барын да онытмагыз дип, кисәтеп тә куйды.

Михай дәдәй тормышны гелән ал да гөл итеп кенә сурәтләмәде. Тайганың бик кырыс, ифрат яман яклары да күп. Шуларның иң яманы — җир бирмичә интектерүе, иза чиктерүе икән.

— Бездә бу турыда: атасы агач төпли, улы җир эшкәртә, оныгы иген игә дигән әйтем дә бар. Хак сүз бу.

Сүз уңаенда, агачларны екканда төбе-тамыры белән егу ягын карагыз, алай иткәндә җирне тамырлардан арындыру җиңеләя дип киңәш итәргә дә онытмады.

Иргали абый, җаен китереп, бу төбәкнең ни өчен «Кешеле эрбет аланы» дип аталуы турында да сорап куйды.

— Бу тирәгә ауга йөргән бабайларыбыздан калган сүз ул,— диде Михай дәдәй.

Шушы аланлыктагы кедрларның берсе эченә кеше кереп яшеренгән. Әле дә булса шунда ята, имештер.

Аның бу сүзләреннән соң җыелып торган кешеләрнең кайберләре суга төшә торган сукмак буендагы мең яшәгән, хәзер инде тәмам корып, ботакларын коя башлаган чамадан тыш юан эрбет агачы ягына күз салып алдылар. Бу хәл атаклы сунарчы игътибарыннан да читтә калмады. Әмма ул башка нәрсә турында сүз кузгатты, каралты-тораклар төзи башлаганчы, ботак-фәләне төшеп бирәрегезне имгәткәләгәнче, әлеге эрбет агачын мөмкин кадәр тизрәк аударырга кушты.

Шулай әңгәмә корып әллә ни күп вакыт та үтмәде кебек, ә күз тәмам ияләште бит Михай дәдәйгә. Елмаюларына кадәр күңелдә ниндидер төпле ышаныч, якты өмет уята иде аның. Соңыннан бик күп хикмәтле нәрсәләр ишетеп белдек үзе турында. «Баянай» дигән сүзнең нәрсә аңлатканын да төшендерделәр. Җирле халык аны тикмәгә генә: «Сунарчылык алласы» дип атамаган икән.

Күпмедер вакыт утыргач, Михай дәдәй урыныннан кубып, тирәюньне күздән кичерде. Күрде бу: кемдер землянка казый, кайберәүләр чатыр ише нәрсә корып маташа. Елан ише хәшәраттән курыкканнары арбалары өстенә чеган көймәсе сыман нәрсә әтмәлләгән. Безнең куыш эченә дә күз салды бу. Ризасызлык белдерү белән генә чикләнмәде, үзенә ияртеп килгән ике иптәшен янына чакырып алды да ниндидер эш кушты боларга. Сүзләре арасында безгә аңлашылмаганнары да очраштыргалый. Тегеләр әһ дигәнче эшкә дә керештеләр.

Ә үзе һаман кинәшләр бирә, өйрәтә, тәҗрибә уртаклаша. Тизрәк төзү-кору эшенә керешергә куша. Таш-фәлән кирәксә, каян алу юлларын күрсәтә. Янәшәбездә генә бер күл дә бар икән, шунын тирәсендә таралып яткан таш үзе бер кала салырга җитәрлек ди.

Михай дәдәйгә ияреп, елга буйларын әйләнеп килдек. Шаулап-ыргып аккан су өстенә аркылы-торкылы агачлар ауган. Бәлки шуңадыр, елга күбекләнеп, әллә нинди шарламалар ясап, чоңгылланып ага. Яр буйларында балыклар уйный. Безнең гаҗәпләнүебезне күргән Михай дәдәй иртәгә үк бер көймә белән бер-ике ау җибәрергә вәгъдә итте. Яр буйларын бераз чистартырсыз да, шунда салырсыз. Аш үзгәртергә ярап куя ул балык, диде.

Безнең учак янына кире борылып килгәндә, озын колгалар ярдәмендә янәшәдә генә чум сыман нәрсә корып куйганнар иде инде. Кичә туналган пошилар тиресе дә ярап куйган. Карасак, аның очлаеп килгән өске өлешендә төнлек тә калдырылган. Михай дәдәй чумның өстенлеге, уңай яклары турында сөйләнеп алды.

Аучылык алласы Баянай дәдәй: эшебез шушының белән тәмам дип, кайтып китәргә ашыкмады. Кичекмәстән, шул сәгатьтә үк, аучы өе тирәсен чүп-чардан, ботак-сатаклардан арындырып, бәрәңге белән яшелчә чәчү өчен урын әзерләргә кушты.

— Иртәгә үк берәр олау җибәр, орлык бәрәңгесе җыеп бирербез, — диде.

Рәхимҗанның һәрбер сүзен йотлыгып тыңлап утыручыларның берсе түзмәде: «Бирделәрме?..» — дип сорап куйды.

— Бирмиләрме соң! Алга китеп булса да әйтим, ул җәйне күршеләрнең кирпеч сугучылары, тимерчеләре бары тик безнең өчен генә эшләделәр. Хәтта, көндезләрен ашханә, кичләрен җыен йорты вазифасын үтәгән беренче зур йортны да алар күтәреште. Алар эшләгән изгелекләрне әйтеп тә, санап та бетерә торган гына булмады. Хәтта партизан заманнарыннан калган әртил казанына кадәр бүләк иттеләр.

Икенче көнне нәкъ Михай дәдәй әйткәнчә, иң элек эшне аучы йорты торган аланлыктан башладык. Башта сирәк-мирәк кенә утырган агачларны төпләп ектык. Кәүсәсен-кәүсәгә, төбен-төпкә аерып, атлар белән сөйрәтеп, юл кырыйларына ташыдык. Ботакларын җыеп алан кырыена өеп шундук ут төрттек. Төтеннән файдаланып, көрәкләр белән коралланган ир-атлар, хатын-кызлар кыр казлары кебек тезелешеп, җир казу эшенә керештеләр. Селкенә алган карт-корыга, бала-чагага да эш табылды:

алар кирәк, балталар ярдәмендә актарылып чыгарылган тамырларны, агач черекләрен җыеп-чүпләп, янган учакка ташып тордылар.

Бераздан Иргали абый тазарак өч-дүрт ир-атны җир эшеннән бүлеп алды да кичә Михай дәдәй күрсәткән, картаюның аръягына чыккан эрбет агачын аударырга кушты. Әлеге артельгә мин дә эләктем.

Агач янына җыелдык. Корыган ябалдашы белән, сирәк-мирәк кенә узып киткәләгән ак болытларны тарап калган өске өлешенә күз салу белән, өнең алынырлык. Өч-дүрт кешенең колачы җитмәслек юанлыгы турында әйткән дә юк. Йөрибез шулай тегенең әйләнә-тирәсендә. Ничек аударырга дип баш ватабыз. Пычкы буйларлык кына да түгел бит, хәерсез. Җитмәсә тагын күңелдә: теге «Кешеле эрбет» шушы түгелме икән дигән уй да тынгылык бирми...

Кайсы яктанрак керешергә соң дигәндәй таптанабыз агач янында. Балта түтәләре белән суккалап карыйбыз. Тонык кына дөкелди бу — димәк, эчтән череп куышка әверелгән. Кабат әйләнеп чыгабыз эрбет агачын. Бу юлы кеше-фәлән сыярлык урын юкмы, шуны чамаларга ният. Юк, өн ише нәрсә күренми. Шулай да, кеше буе чамасы биеклектә, тегермән ташы зурлыгында бүлтәнмә сыман нәрсә бар барын. Кем белә, бәлки кеше кереп-чыгып йөргән ярык сагыз белән шулай «җөйләнергә» өлгергәндер?..

Озак баш ватарга урын юк, тизрәк эшкә керешергә кирәк иде. Һәркайсы үзе бер агач юанлыгы ботагы-ние төшә күрмәсен дип, янибыздан артык кешеләрне куды та, бисмилланы әйтеп кулга озынрак йөзле пычкы алдык.

Алмаш-тилмәш як-яктан кисәбез моны. Пычкы чүбеннән үк чамалап була — корыгач та бик күп еллар буе торган инде бу бичара. Туктап, кай яккарак аударабыз, дип кабат киңәшеп алдык. Яр буеннан сузылган сукмак буйлап җибәрергә кирәк дигән карарга килдек. Чүп-чарын, череген җыеп яндырырга җайлы булыр, янәсе.

Тырыша торгач, йөзләрчә ел буе тайга-ана җырын тыңлаган, бик күп вакыйгалар шаһиты булган эрбет, үзен борчып-бимазалаган өчен ризасызлыгын белдергәндәй, уфылдап-шатырдап хәбәр салды. Без дә: «Сак булыгыз!» — дип кычкырынырга тотындык...

Шундый ауды — җирләр селкенде. Карт эрбетнең һәркайсы үзе аерым агач сыман юан ботаклары гына түгел, кәүсәсенә кадәр ике-өч урыннан шартлап сынып чыкты.

Без башкарган эшебезне бәяләргә дә өлгерә алмыйча калдык. Кинәт кабер, тынчу ләхет исе килеп кигкән сыман булды. Киселгән агачның төбендә, оя сыман уентыкланып торган җирендә, тешләрен ыржайтып, буш күз чокырларын безгә төбәп яткан адәм башы сөяген күреп, өнсез каттык та калдык. Аның шулай кем тарафыннандыр өеп куйганга охшап, таркалмавының сәбәбен бары тик җентекләп карагач кына төшендек. Мәрхүмнең кул-аяк сөякләре күптән инде тутыгып-күгәреп, черегән агач төсенә кергән богаулар богжрасы эченә алынганнар иде.

Эш бүленде. Әлеге җан тетрәткеч тамашаны күрергә дип агач төпләүчеләр дә, җир эше белән мәшгульләр дә килеп житте. Тел шартлатырга да җөрьәт итүче юк. Бу хәл барыбызга да баштанаяк бозлы су белән коендыргандай тәэсир итте. Кем ул? Нинди язмыш бу тирәләргә китереп ташлаган? Богауланган килеш шушы кара тайгада озак йөргәнме? Бәлки ирек өмет итеп, үзен эзәрлекләүче дошманнардан качып, бүрәнәгә ябышып елга буйлап йөзеп төшкәндер? Нинди көч агач куышына куып керткән аны? Бәлки ерткыч-җанвардан яшереним дип, шунда актык сыену урынын — каберен тапкандыр? Ничек кенә, кем генә булмасын, шаулы-даулы көннәр, җил-давыллы кара тарих тирәнлегеннән безгә хәбәр китерүче иде бу. Үзебезчә шулай бәяләдек без моны. Соңыннан әлеге адәм баласының актык сыену урыны булган агачның тагаракка охшап ярылган өлешен алдык та, шуны табут итеп, сөякләрен җыеп, янына богавын салдык та җирләдек. Шулай итеп, авылга нигез салын-

ганчы ук, аланның тайгага барып тоташкан түрге ягында зират хасил булды...

Юк, Себер кадәр Себердән кайткан Рәхимҗан абые янына башка сүз ишетергә диебрәк килгән иде Гази. Кем турында булсын, әлбәттә Гөлүсәсе турында. Я-а, хода! Онытылмаса да онытылмас икән яшьлекнең изге хисләре! Гөлүсә!.. Аңарга бәйле булган мизгелләрдән дә яктырагын, татлырагын белми Гази.



Ә Рәхимҗан абые, әнә, Баянай дәдәй ясаткан чумның уңай яклары турында гәп сата. Урта бер җирдә ут якканлыктанмы, ниһаять, чебен-черки бимазалаудан чак кына котылган сыман булалар. Урын-җирләре, ятаклары җирдә — як-ягын кәз белән әйләндереп алынган учак тирәсендә.

— Килеп урнашуыбызга атна чамасы уздымы икән,— дип дәвамлады Рәхимҗан өзелеп калган фикерен тапкан сыман итеп.— Чумның Роман биргән торыпшадан ясаган итәк-ишеген күтәреп куеп, иртәнге чәй янында утырабыз. Шулай уйламаганда-көтмәгәндә, олы гәүдәсе белән бөтен яктылыкны томалап: «Әссәламегаләйкем!» — дип, әлеге дә баягы Шаһи карт килеп басмасынмы.

— Әйдүк, Шаһиулла абзый, түрдән уз,— дип каршылады аны Иргали абый. — Мактап йөрисең икән, әйдүк, аш-сыебыз уртада...

Карт кыстатып тормады: «Лә хәүлә вә лә куәтә...» — дип ишек катында тирән куныччлы кәвешен салып калдырды да бөтен куышны тутырып эчкә узды һәм, ах-вах килеп, бүселеп, аякларын бөкләп, күрсәтелгән урынга килеп утырды. Башта кулларын күтәреп: «Хуш-ш, йортка бер дога! Ходай-тәгалә чир, зәхмәт, бәла-казалардан сакласын»,— дип бөтен йоласын китереп, озаклап амин тотты.

— Ярабби, бу йортка иминлек бирсен, авыру-сырхау, бәла-каза, зыян-зәвер китермәсен. Нигез хуҗаларына, нигъмәт ияләренә сәламәтлек бир, ходаем! Моннан ары хәвеф-хәтәр күрергә язмасын берүк. Әй-йе!.. Бусагага йөз сөрүне, ягъни, хуҗа өенә сәҗдә итүне мөкатдәс эшкә санаган китап.

— Исән-имин генә йөрешме, Шаһиулла абзый?

— Сезнең хәер-догада, кем, мелла!

Карт төлкенең тикмәгә генә сырпаланып йөрмәвен үзе килеп күренү белән үк сизенгән идек инде. Башта сер бирмәде. Дөнья хәлләре турында сүз кузгатып бераз гәп саткандай итте. Аннары зур кабаклы, нәкъ гөберле баканыкы сыман ояларыннан чыгып торган акай күзләрен елтыр-елтыр тәгәрәтеп, барыбызны да барлап чыкты. Ул да түгел, карашын әле яңа гына алдына чәй ясап куйган Гөлүсәдә туктатты бу. «Рәхмәтләр яусын, кызым, аяк-кулларың сызлаусыз булсын берүк. Намуслы, игелекле вә итагатьле бала күренәсең, кем, балам. Хәләл сөт имгән бәндәләр насыйп итеп, җаннарыңа-тәннәреңә сәламәтлек биреп, аклык көннәре язсын үзеңә, балам. Кем... Кем дип торам, атыңны белеп бетермим, кем, кызым...

— Гөлүсә аның исеме,— диде Иргали абый әллә ни исе китмәгән кыяфәт белән.

— Бик хуп, бик күркәм, бик мәслихәт, кем... Исеме дә җисеменә ятышлы икән, рәхмәт төшкересе. Әй-йе! Әгәр дә мөмкин булса, кем, кызым, чак кына тирмәдән чыгып торуыңны теләр идем. Әтиең белән әниеңә җиткерәсе сүзем бар иде. Һай-й, рәхмәтләр төшкересе лә! Менә шулай!..

Гөлүсә чыгып китү белән, үзенең тикмәгә генә йөрмәвен һәм сүзнең шактый җитди буласын сиздерергә теләгәндәй, авыр гәүдәсен турайтып тагы да кукырая төште бу.

— Хуш-ш, кем, мелла! Үтенеч, йомыш дип әйтимме инде, ифрат зур эш белән килүем иде. Хәер, ничек кенә атасам да, хак тәгалә шаһит, изге йомыш белән савaплы юлда йөримен. Әй-йе! Борынгылар: җиткән кыз ул — әманәт ди торган булганнар. Шундук: ару суны читкә түкмиләр дип өстәргә дә онытмаганнар. Әй-йе! Заманачарак итеп әйтсәк: җиткән кыз-

лы йортның капкасын җиде яктан җил кагар ди. Менәтерә, уйлаштыкkиңәштек тә килергә ниятләдем. Килеп күрену, ризалык сорау ата-бабалардан калган йола түгелмени, мин әйтәм...

Сүзнең нәрсә турында барганлыгын тәгаен төшенеп өлгергән Гөлниса апа тәмам каушап-югалып калды. Бу искәрмәстән килеп туган хәл аны бөтенләйгә телдән үк яздырды.

Диндар картның үз тугызы тугыз.

— Һәрхәлдә, мин әйтәм, үтенечебезне аяк астына салмаслар. Бер язмыш бәндәләре, мин әйтәм... Һич югында, балаларыбызга күмәк бәхетсезлегебезнең күләгәсе төшмәсен, мин әйтәм. Иле бар кеше генә кеше ди бит...— Картның тавышы калтырап, чатнап куйды.

Әмма Иргали абый салкын канлылыгын саклый алды.

— И-и, Шаһиулла абзый!..— диде ул шактый ук күтәренке, көр тавыш белән.— Шулай яучылар җибәрешеп, кызлар ярәшеп йөри торган чакмыни соң?!. Юк белән баш катырмыйк әле, вакыты ул түгел. Йорт дисәк баш очыбызда түбә юк, җир дисәк, анысы алла кулында...

Шаһи карт өй хуҗасының сүзләрен колагына да элмәде. Күкләргә чөеп үзенең каенесен, ягъни булачак кияүне мактарга кереште.

— Ходайның биргәненә шөкер, азып-тузып йөргән бала түгел. Шулай ук атсыз-йортсыз, җирсез-сусыз бераү түгел. Янә нәсел-нәсәпсез адәм дә түгел. Даны дисәң даны, малы дисәң малы дигәндәй, бөтен нәсел-ыруглары белән зыялы, әхәбире көлмиян-укымышлы, зур абруйлы кешеләр. Ил-көн итүләре дә теләсә кем кызыгырлык. Бәлки әле ишетеп тә беләсездер, атаклы Акмаловлар нәселеннән алар. Ата-бабасы гомергомергә мәҗлес түрен тоткан түрәләр. Тирә-юньне дер селкетеп яшәгән асыл затлар... Әйтсәм әйтим инде алайса, Шаһбаз балакай — минем туганнан-туган энемнең бердәнбер улы. Әтисе указлы имам гаиләсендә туган. Үзе әдәпле, үзе игелекле, заманына күрә укымышлы да. Өстәп тагы шуны да әйтим, Акмаловларның нәсел-нәсәбе бик тирәнгә китә, шәҗәрәләренең очы Казан ханнарына барып тоташа. Әй-йе!..

Шушы урынга җиткәч, Иргали абый тегенең сүзен кырт кисте.

— Ни бит, Шаһиулла абзый, без үзебез — бик гади халык. Әллә ни югарыга үрелер хәлебез юк...

Тегесе дә шундый ук җәһәтлек белән каршы төште:

— Алай димә, кем, мелла, авызыңны да ачма берүк. Тиң күрмәсәк, үз итмәсәк, ике аягымның берен атламаган булыр идем. Әйтсәм әйтим инде алайса, каенемнең күзенә әүлия булып күренгән кызың.— Шаһи карт, кан тибеп чыгардай калын-итләч иреннәрен ерып, хәтта елмаеп куйды.— Ходай кушса, заманалар гелән болай тормас, үзгәрер, үзгәрми булмас. Очар кошлардай булып туган якларыбызга да әйләнеп кайтып төшәрбез, боерган булса. Хәзергә исә, тешләребезне кысып булса да чыдарга, сабыр итәргә кала. Бүгенге көнебезне алла тарафыннан сынар өчен җибәрелгән җәза дип кенә кабул итәргә кирәк. Тиздән, бик тиздән азат булырбыз, ходай кушса. Алладан бары тик шуны ялварыйк, кардәшләр. Совет дигән зәхмәт бетә ул, Советның кәфене муенында аның...

Шаһи карт шулай җае чыккан саен дөньяларның иске эзгә төшәсе турында гәп сатарга, искечә яшәүне мактап сөйләргә ярата иде.

Шулчак Иргали абый да аваз салды.

— Тукта әле, Шаһиулла абзый,— диде ул шактый кырыс, кискен тавыш белән.— Мөмкин булса, минем сүзгә дә колак сал әле син...

Барыбыз да бер кешедәй аның ягына борылдык. Тавышының шулай үзгәрүенә караганда, сүз җитди һәм катгый төс алыр шикелле иде. Хәзер сикереп торыр да: сару кайнатып, юк белән җанымны талап йөрмә әле монда, эзеңне себер, дип картны куып чыгарыр төсле иде. Әмма Иргали абый ачу белән нәфрәтнең кешегә акыл өстәмәвен яхшы белә иде шул.

— Сүз дә юк,— дип дәвам итте хуҗа кеше,— Шаһбаз утны-суны кичкән, булган егет. Кулыннан да, кодрәтеннән дә күп нәрсә килгәнгә охшаган. Ләкин бит, Шаһиулла абзый, сез тәкъдим иткән бу нәрсә алай

капылт кына башкарыла торган эш түгел. Кем әйтмешли, киңәшик, уйлашыйк, үлчик дигәндәй... Кызның да кылларын тартып карарга кирәктер.

Картның җавабы әзер.

— Тәүфикълы, әдәпле кыз бала ата-анасы сүзеннән чыкмас.

Иргали абый тагын бер бик җитди сәбәп барлыгын кисәтергә теләгәндәй, янә сүз кыстырып куйды.

— Ни бит, Шаһиулла абзый... Бер кыз баланы ике тапкыр ярәштермиләрдер ич?..

Карт җәһәт кенә өй хуҗасы ягына борылып: «Ничек?» — дип таркау гына сорап куйды.

— Дөньялар болайга китәр дип кем уйлаган? Гөлүсәнең ярәшкән-вәгъдәләшкән, бергә булабыз дип антлар итешкән егете бар...

Картның чырае ук бозылды.

— Кайда?.. Кайчанрак булды ул хәл?

— Кайда дип... Туган илдә инде. Егете хәзергә шунда калды.

Шаһи картның тук чырае янә үзгәрде, бу юлы мыскыллы елмаю хасил булды.

— Һы-ы, шулаймыни! Вәгъдәләшкән-ярәшкән, антлар бирешкән дисең инде алайса. Һай-й, ходаем ла! Андый вәгъдә-антлар хәзер, нәкъ кабул ителмәгән дога кебек, җир белән күк арасында асылынып калдылар. Һәй, кем, мелла! Рәчәйдә ярәшкән сөйгән ярлар гына түгел, икешәр катлы, патша сараедай таш пулатлар да, кешенең төшләренә дә кермәслек утарлар да калды...— Шулай диде дә, Иргали абыйның йөзенә карап үзе өчен бик әһәмиятле нәрсә күрергә теләгәндәй, бермәлгә чекрәеп карап торды. Аннары, тавышына салкынлык өстәп, дәвам итте.— Карап-карап торам да, кем, мелла, кашларыңны җыергалап, минем тәкъдимемә каршы килергә җыенган сыман итенәсең. Нәрсә бу? Безне тиңсенмәү түгелдер ич? Алай артык һаваланмыйча, сатулашмыйча гына бер сөйләшик әле. Безнең беребез дә ошбу дөньяга күктән төшмәгән, синең дә кем икәнлегеңне беләбез... Статьяларыбыз бер чамада булуы беркем өчен дә сер түгел. Әй-йе!.. Күреп торасың, мин дә ходай язмаган, ил күрмәгән эш белән йөрмим. Риза-бәхиллегеңне бир дә, тәвәккәллик. Шәригатькә дә сыя торган хәл. Ант-шарт итешик тә, аллага тапшырып, никахларын укып, кавыштырып куйыйк балаларны. Әллә ни зурдан купмыйча гына туй-тамаша ише нәрсә дә ясагандай итәрбез. Ичмаса алар, газиз балаларыбыз, безнең тәмугка тиң тормышыбызның күләгәле якларын күрмәсеннәр. Пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп тик яшәп ятсыннар. Әй-йе!..

Картның сүздән туктавына тәмам өметен өзгән Иргали абый, җаен туры китереп, кыстырып куйды:

— Ярый ла, Шаһиулла абзый, араларында син әйткән мәхәббәт дигән нәрсә булса?..

— Мәхәббәт никахтан соң килә диярләр иде борынгылар. Тәнгәтән, җанга-җан якынайгач, бар да үз урынында булыр, аллаһе тәгалә боерса. Ходай әмере белән тәкъдирләренә язылып, чәчләре чәчкә бәйләнсә, барысы да һәйбәт булыр, кем, мелла.

— Безнең җавабыбыз, Шаһиулла абзый, бая әйткәнчәрәк булыр,— диде Иргали абый.— Уйлашыйк, киңәш итик. Бая әйткәнемчә, уптымилаһи гына башкарыла торган эш түгел бу. Гөлүсәнең үзе белән дә сөйләшик...

Мондый җавап картның сырт йонын кабарту өчен җитә калды.

— Мин дә: менә хәзер үк никах укыйм,— дип тәһарәтемне яңартырга тормыйм ич,— диде ул.— Һәрхәлдә, иң соң дигәндә, берсекөннәргә тәгәл җавапны ала алырбыз дип уйлыйм. «Башланган эш — беткән эш»,— ди мәкаль. Әй-йе!.. Алайса, шулай хәл иттек, кем, мелла... Сүзебезне аяк астына салмассыз дип уйлыйбыз. Кызыгызны бик ошаттык... Ике яшь җанга хәер-фатиха биреп, исәнлек-саулык, бәхет-сәгадәт телик тә... Иргаләргә үк куанычлы хәбәр көтәчәкбез...

Шаһи карт китте. Чум эченә сәер тынлык инде. Бу истә-оста юкта килеп чыккан хәлдән һушы китеп утырган Гөлниса апа да, ниһаять, үз фикерен әйтер хәлгә килде.

— Ю-юк!..— диде ул, тирән көрсенгән сыман итеп.— Минем теләсә кемгә бирергә дип үстергән кызым юк. Күрәләтә горып терелятә утларга салыр хәлләрем юк газиз балакаемны. Гомере буе җәфа чиктереп, канлы күз яшьләрен түктереп, үкенү зарында йөздерер иде бугай. Ю-юк, кая ул!..

Нәни Азатҗанны тезенә алып утырган Миңсылу да тел тибрәтеп берике авыз сүз әйтүне кирәк тапты.

— Аб-бау-у, китегезче зинһар! Ерткыч затыннандыр ул. Күз карашларында ук иман юк аның.

Чум ишегендә Гөлүсә пәйда булды. Әле бая гына табын түрендә нурлар чәчеп утырган Гөлүсәнең танырлыгы калмаган иде. Күзләренә бөялеп торган яшьләрен тәгәрәтеп ул бары тик бер кәлимә сүз катты: Әгәр дә мәгәр ризалаша-нитә калсагыз, белегез... әнә, кара тайга, чыгам да китәм... Вәгъдәләшкән кешем барлыгын беләсез. Утка да, суга да керермен, әмма вәгъдәмдә торырмын. Ул эт йөзгә... үтерсәгез дә риза булмаячакмын.

Ләкин бу кадәресе бәланең башы гына булган икән. Хикмәтләрнең олысы икенче көн иртән башланды. Эшкә чыгарга дип җыенып кына торганда, Шаһи карт бәреп керде. Хәл-әхвәл сорашып тору юк. Күзләр тасрайган. Пешкән чөгендер төсле кызгылт-көрәнләнеп торган тукмак борынының тишекләре, гөбе авызымыни, киңәйгәннәр. Артыннан куганнар диярсең инде менә. Сулышы капкан. Үзе башак ашаган сыер сыман мыш-мыш килә. Кыяфәте өненңне алырлык. Ниндидер гадәттән тыш хәл булганлыгы бөтен кыяфәте-килбәтенә чыккан моның. Кичә борчагы пешмәгәч, эченә зәһәрлек җыеп килгән. Һәрхәлдә, изгелек белән бусага аша атламаганлыгы көн кебек ачык иде.

Иргали абыйның сәламен дә алырга онытты бу. Бәреп тә керде, ярсып сүзгә дә керешге.

— Я-а, тәңрем! Бар икән күрәселәр... Шул кирәк мин карт диванага. Картайган көнемдә беркатлыланып, сине Мөхәммәт өммәтеннән олуг һәм дәрәҗәле кешегә санап, тәкъдимнәр ясап йөргән булам. Син исә мәкерле, хәйләкәр вә оятсыз адәми зат икәнсең. Юк, кем, мелла, андый эшне йомып калып та, йолып калып та булмый, хаклык кайчан да бер өскә калкып чыга ул...

Берни дә аңлар хәл юк. Ахыр чиктә Иргали абый авызыннан ут чәчкән картны туктатырга, сүзен бүлергә мәҗбүр булды.

— Зинһар дип сорыйм, Шаһиулла абзый, аңлатыбрак сөйләче. Ни булды? Нәрсә бар?..

— Ни булганын, әнә, пакь-даман кызыңнан сора!.. Яа-а, тәңрем!.. Бар икән күрәчәкләр...— Бу отыры ярсый, төкерек чәчә, түз генә.— Гыйффәтсез кыз паригә тансык ди. Сез нәрсә белмәмешкә салынып маташкан буласыз? Кемгә санныйсыз безне? Нәрсә, үзегезгә күрә мыскыл итүегезме? Кайнеш әйтмешли, ничу монда!..

Иргали абый да аптырашта.

— Берни дә аңламыйм. Аныграк итеп әйтсәгезче, Шаһиулла абзый...

— Моннан да аныгы инде! Соң, алла колы, өрфиягә төргән кызың, Рәчәйдә үк яшерен никахта булып, гыш-гыйшрәт кылып, ягъни, зөфаф кичәләрен үткәреп килгән ләбаса!..

Бу сүз һәммәбезгә дә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте, телдән яздык. Беренче булып ис-акылын җыеп өлгергән Иргали абый телгә килде: — Син, абзый кеше, андый сүзләр белән авызыңны чамалабрак ач, яме! — диде ул, ахыр чиктә тотырыгын җуя башлап.

Кинәт төсләре киткән ана кешенең үзәк өзгеч итеп, илереп-тәкатьсезләнеп әйткән сүзләре яңгырады.

— Тыйнаклык, пакьлек үрнәге булган кыз балага шулай дип әйтер-

гә, мәсхәрәләргә ничек телләрен бара? Оятсызлыгың җир күтәрмәслек бит. Ул сиңа ниндидер шаталак яки аумакай кыз бала түгел. Һай-ла, тәмам җүнсез, денсез кеше икәнсез! Оятсыз, битсез икәнсез... Гөнаһларын кая куярмын ди торгансыздыр!.. Ничекләр итеп юар-йолырсыз бу кара гайбәтегезне!..

— Үз гөнаһым үземә, минем кабергә башка берәү кереп ятмас. Әй-йе! Әнә, пакь-даман кызыгыз каршыгызда тора, сорагыз үзеннән, ишетерсез, барысын да белерсез...

— Булмас! Затыбызда юкны... Акылыңнан язгансыңдыр син, картлач... Телең ни сөйләгәнне колагың ишетми торгандыр. Адәм баласы күтәрә алмаслык коточкыч яла ягу ич бу. Нишләвең бу, шәфкатьсез җан! Һич югында язгыннан куркыгыз... Эчеңдә — агу, мәкер икән. И-и, башың беткере! Йөзеңә төкермичә яныңнан да узмаслар бит. Аллаһе тәгаләнең ачы каһәрләре төшүдән курыкмасаң, адәмнән оялыр идең, ичмаса... Тәмам җир бит икәнсең!.. — Ана кеше җәһәт кенә Гөлүсә ягына борылды да, ачынып-әрнеп кычкырына ук башлады. — Нәрсә күреп тәре баганасы кебек катып калдың?.. Телләреңне йоттыңмы әллә? Әйт, үзәкләренә үтәрлек итеп әйт, карт денсезнең... Илгә-көнгә начар исемеңне чыгарырга ниятләнә бит... Ничекләр итеп яшәрсең?!. Яа-а, тәңрем!..

Әмма Гөлүсәнең Шаһи карт сүзләрен инкарь итмичә: «Әйе... шулай...» дигән ике сүзе янә барыбызны да катып калырга мәҗбүр итте.

Шулчак Гөлниса апа белән әллә нәрсә булды. Бу көтелмәгән хәбәрнең тау-таш булып өстенә ишелеп төшүеннән сакланган сыман, иң элек ике кулы белән чал башына ябышты, аннары ыңгырашып: «Я-а, сабырлык бир, раббым!..— дип, бер кырыйга авып төште.

Вакыйганың шундыйрак борылыш алуын күреп тәмам тетрәнгән Гөлүсә әнисе янына ташланды. Шулчак гомергә күрелмәгән вакыйганың шаһиты булырга туры килде: Гөлниса апа Гөлүсәгә кул күтәрде... Коелыплар инде бичара кыз, үкси-үкси буылып еларга кереште. Сыгылыплар төшеп елады, мескенкәем. Эх-х, юатасы иде дә бит үзен, кая ул!

Гөлниса апа берни белән дә исәпләшеп тормады, китте тиргәү, китте каргыш-рәнҗүләр, түз генә.

— Шул кирәк син җирбиткә... Шул кирәк!.. Уф-ф, нихәлләр итим?!. Ил-күз алларында рисвайлар итү өчен үстердеммени соң мин сине! Оят, вөҗдан дигән нәрсә бар. Нихәлләр итеп яшәрсең?.. Яа-а, тәңрем!..

Аптырау белән йөдәүнең аръягына чыга башлаган Иргали абыйның да кискен-яман тавышы һаваны ярды. Бар да тынды.

— Җиттеме сезгә, юкмы!..— дип үкерде ул.— Житкәндер, ниһаять... Син дә тәресен югалткан марҗа кебек улаудан тукта. Баштарак карыйлар аны. Барысына да үзең гаепле. Үзең генә!.. Өзелеп төшмәс, борын аслары кипмәс борын: «Бер-берсе өчен яратылганнар болар...» — дип үзең үк ярәштереп куйган идең. Хәтереңдәме?.. Менә җый хәзер җимешләрен. Ярар, житкәндер. Аның өчен хәзер егылып үлеп булмый. Яшьли табышканнар иде, димәк, кавышканнар... Ул гына әүлиядән булмагандыр. Тормышы шулайга әйләнгәч, нишләмәк кирәк. Язмыш кешене бер үчекли башласа, үчекли ул. Җиткәндер, ниһаять! Бер таптан кояш сүнмәс...

Шаһи карт та, Иргали абыйның соңгы сүзен генә көтеп торган диярсең, кинәт үзгәрде дә куйды.

— Хак сүз әйттең, кем, мелла, чын ир-егет сүзе әйттең,— дигән булды, йөзенә ясалма елмаю чыгарып, тавышына йомшаклык өстәп.— Әйдә, калганын алла ярлыкасын. Адәм баласы хатадан хали түгел ди. Коеласы укасы коелган. Үткән эшкә салават, диик тә... Хак тәгаләнең тиешле җәзасы дип кабул итик. Әй-йе!..

Сүзне янадан Шаһи карт алды. Тезде дә тезде. Тел төбеннән шул аңлашылды: каенсе, кызның урагы яшелли урылганга, тормышта булып кайтуына да карамастан, өйләнергә риза икән.

— Юк инде, Шаһиулла абзый,— диде Иргали катгый рәвештә. Шун-

дый итеп әйтте, чабып үзде диярсең инде мена.— Болайга киткәч булмастыр. Бигайбә! Ша!.. Бу турыда бүтән сүзнең булуы да мөмкин түгел. Тешегезне дә агартмагыз хәтта!

— Һы-ы, алай икән! Нәрсә, моны кире кагу дип фараз кылыйкмы?

— Әй-йе! Шулай дип фараз кылыгыз.

— Мең кәррә гафу, кем, мелла! Аллаһе тәгалә шаһит, теләк-ниятләребез изге иде. Үзебезнең мөселман кеше, аңлашырбыз дип уйлаган идем.— Кинәт үзгәргән, карлыккан тавыш белән дәвам итте.— Әллә кабат уйлап карыйсыңмы? Бәлки, тәкъдир шулай язгандыр дип килешергә, буйсынырга кирәктер?..

— Булмый, Шаһиулла абзый.

— Булмый дисең, алайса?

— Әйе. Булмый дим.

— Һы-ы, алай икән! — Иргали абыйның каты торуын күргәч, тәмам сөмсере коелды картның. Шундук рәнҗү катыш ризасызлыгын да белдерде.— Бу фани дөньяда без кунак кына, кем, мелла.

— Син хаклы, Шаһиулла абзый. Сүз дә юк, бик аз яшибез. Әмма көн дә яшибез. Һич югында шуңа шөкерана кылырга кирәк...

Чыраен төн караңгылыгы басты тегенең. Күз карашлары күңелгә пошаман салырлык булып тоныкланды. Кабарынкы күз кабаклары тагы да салына төште. Хәтта, шешенке бит тиреләренә кадәр шәлперәйде сыман. Тавышына кадәр тыңкышланды.

— Кабатлап әйтәм, кем, мелла, без — бер язмыш кешеләре. Шулаймы? Шулай. Ике авыз сүз белән әйтсәң, барыбыз да бер чыбыктан куылганнар без монда. Әй-йе! Бака, җылан бер күлдә, барысы да бер телдә дигәндәй, әллә уртак тел табарбызмы дигән идем. Бергә-бергә оешып, киңәшеп,туганлашып яшәүгә ни җитә! — Шаһи картның кыяфәте төкселәнеп, кырысланып кына калмады, турыдан-туры яный, куркыта ук башлады.— Аң бул, кем, мелла, заман көчленеке. Әй-йе! Ил ошатса, соңгы атыңны суй дигән борынгылар. Мөһәҗирләр дөнья чите санаган, мәңге ләгънәтләнгән, мәңге каргалган Себер бу, күзеңне ач!.. Аннары үкенерлек булмасын дип кисәтүем. Минем каенеш, урыс әйтмешли, ай-һай ла отчаянной галава. Башын салса салыр, әмма үз дигәнен итми калмас...— Картның танырлыгы юк. Ачуыннан тагы да кара көя төште. Азау тешләренең ныклыгын сынагандай, яңак сөякләрен хәрәкәтләндереп алды да Иргали абыйга, бәрәңге алмасы төсле сыек яшькелт бәбәкләренең агы белән генә карап, соңгы сүзен әйтте.— Вөҗданың сукыр икән, кем, мелла. Болайга киткәч, ашыкма, ачарлар күзеңне. Әй-йе! Малай йөгәнсез, холыксыз. Теле үткен, җор, кулы каты... Кара аны!

Чыдамы калмаган Иргали абый да күңелен кырысландырырга өлгергән иде инде. Анын да җавабы бил алышуга тартым: «Үгезенә күрә камчысы»,— дип кенә җибәрде.

Тегесенең тел төбе үтә мәкерле.

— Югыйсә, әнә, кайнеш нәрсә ди: закон — тайга, аю — прокурор ди...

— Әйтсә әйтә инде, һәрбер ахмак сүз әйткән кешенең авызын томалап булмый.

Шаһи карт китте. Анын: «Никах дигәнең җеназага әверелмәсен... Иманыңа килерсең... әмма соң булыр»,— дигән янау сүзләрен аермачык ишетеп калдык. Шулай итеп, башы беткере җан, ансыз да көйсез-ямьсез тормышыбызның тәмам тынычлыгын алды, күңелебезгә шом, йөрәгебезгә җәрәхәт салды. Ул төнне күзләребезгә йокы кермәде. Иргали абый бөтенләй ятмады бугай. Ярсуын тиз генә баса алмыйча: ат белән сыерны карап керим әле дип тышка чыгып шактый вакытлар шунда булып керде.

Шуннан башланды хикмәтләр. Китте сүз, китте гайбәт. Хурлыгыннан кая керер тишек тапмады Гөлүсә. Гарьлегеннән тыела алмыйча үксепүксеп җылар иде, бичара. Ике-өч көн эчендә таный алмаслык булып үзгәрде, йөзенә сары булып сагыш иңде. Күзгә күренеп ябыкты, сулды, төс ташлады.

Кодалашып йөрүләрнең шулай сәер төгәлләнүенең сәбәбе соңрак ачыкланды. Беренче көн бездә булып чыкканнан соң, Шаһи карт кайта да Иргалинең ык-мык итеп икеләнеп торуын, үзеп җавап бирмәвен Шаһбазга житкерә. Теге ерткычка житә кала. Шул ук көнне, сагалап торып, Гөлүсәнең юлына аркылы төшә бу: кәнфитләнеп маташкан булма, барыбер минеке булачаксың дип кымтырата ук башлый. Менә шунда Гөлүсә аңа үзенең ярәшкән кыз гына булмыйча, яшерен никах белән кушылган ир хатыны булуы турында әйтә: ягъни, үз-үзенә яла яга, нахак бәла күтәрә. Бәлки теге эт өйләнергә дигән уеннан кайтыр, дип уйлый ул. Кая инде! Барыбер минеке булачаксың ди тегесе. Шунда аптырау белән йөдәүнең ахыр читенә житкерелгән Гөлүсә: үлсәм үләрмен, әмма синеке булмаячакмын ди. Теге кире беткән жан җүри үчегә башлый. Гөлүсәгә өйдән чыгып йөрү чамасы бетә. Берсеннән-берсе яманрак сүзләр ишетерәләр: Аң булыгыз, янәсе, баш очыгызда козгыннар әйләнә... «Әгәр дә шул сылуны ефәк чәчләре белән тирмәмнең җир иденнәрен себертмәсәм, башларымны кисмәгә бирәм. Шулай, чишмә корыганчы эчеп кала торганнардан мин»,— дип әйтеп әйткән ди, имеш. Хәбәр китерүчеләрнең сүз сөрешенә караганда, бу сүзләр бик үк нигезсез дә булырга тиеш түгел иде. Андый алла каргаган явызлардан теләсә нәрсә көтеп була: этлеккә тәһарәт кирәк түгел аңа. Шаһбаз кебекләр, үз морадларына ирешү өчен, берни белән дә исәпләшеп тормыйлар.

Күпмедер вакыт үткәч чак кына тындылар кебек. Хәтта: «Саварга кәҗәсе булмаса да, хатын табыла ла ул»,— дигән сүз дә ишеттерделәр. Гөлүсәне эзәрлекләүдән дә чак кына тыелдылар кебек.

Менә шунда Гөлүсә, әнисенең куенына атылып, борчуга салганы өчен жылый-жылый гафу үтенде, чын хакыйкатьне ачып салды. Әти белән әнисенең ризалык биреп куюларыннан курыккан ул. «Язмышымны күзаллап, жаным теләмәгән никахтан котылу әмәлен эзләүдән шундый адымга бардым. Әнием, жанием, күз нурым, ышан газиз балаңа, күңелем саф, намусым чиста, тәнем пакь», була Гөлүсәнең соңгы сүзләре. Ә анага нәрсә: бер кулы сукса, икенчесе сыйпар ди бит...

Рәхимжан абыеның шушы сүзләрен кайчаннан бирле көтеп утырды бит Гази. Ни өчен хикәясен шушы сүзләрдән башламады соң ул? Югыйсә әнә, Гөлүсә турында сүз чыккач та, барлык авылдашларының да күзләре аңарда булды. Арада терсәкләрен уйнатып, аның ягына бик мәгънәле итеп ым кагып куючылар да табылды. Җүнсез дигәннәрдер, игелексез дигәннәрдер, кыз баланы нинди бәхетсезлекләргә дучар иткән бит дигәннәрдер. Әй-йе, гайбәтен сатарлыгы, чынлап торып гаепләрлекләре дә бар шул. Ә бит, бик теләгән тәкъдирдә, Гази үзенең сабый чактан сөйгән беренче һәм соңгы мәхәббәтен әлеге коточкыч бәла-казалардан йолып та кала ала иде. Әй-йе, ала иде. Ала иде!..

Газиның горур тотарга күнеккән газиз башкае иелде дә төште. Күптәнге, инде чак кына җөйләнә башлаган йөрәк җәрәхәте кабаттан ачылдымыни! Бәгыренең меңгә телгәләнүенә чыдар чамалары юк, өзгәләнепме өзгәләнә. Күрче зинһар, үзенең дөньяда тиңдәшсез, жаныннан газиз Гөлүсәсен нинди бәхетсезлекләргә дучар иткән бит ул. Ничек, ничек түзмәк кирәк бу хәлләргә?!. А-а, мондый гаепләре, рәхимсезлекләре өчен ул иң каты җәзаларга лаек. Ничек җир күтәреп тора диген син аны!

Юк, ялгышу гына түгел иде бу. Ялгышуны кичерергә мөмкин, әмма хыянәтне — юк! Йөрәгенең бөтен булган көче белән яраткан кешесенә хыянәт итте бит ул. Андый хыянәтне суд та, дус та ярлыкамый. Бәхете әллә кая, кошлар да очып житмәс чит-ят җирләргә китеп юк булгач кына төшенде ул үзенең нинди коточкыч адым ясавына. Ай-һай ла авыр кичерде Гази ул хәлләрне. Төннәр буе йокы күрми яткан чаклары бик күп булды. Вакытны иң яхшы табип диләр. Юк икән. Күпмедер вакыт үткәч, бәлки, сагыш-әрнүләр, иза чигүләр бераз басыла төшер дип уйлаган иде ул. Юк, алай булмады. Вакыт узган саен тойгыларының тирәнәя, ялгызу

турындагы уй-фикерләренең житдиләнә баруын гына тойды Гази. Тора-бара аның уфтанулары, үкенү-кичерешләре гүр газапларына әверелде.

Хәзер дә ул Гөлүсә турындагы уйларга бирелеп, Рәхимжан абыеның хикәясен элекле рәвештә тыңлый алу сәләтен югалткан иде. Колагына бары тик өзек-өзек сүзләр генә кергәли. Иргали абыйсының эшне оештырырга, кешеләрне хезмәткә өндәүгә ифрат та оста, ифрат та сәләтле булуы турында гәп сата иде Рәхимжан.

— Читән казыксыз тормый дигәндәй, һәркайда терәк, башлап йөрүче кирәк шул,— дип дәвам итте ул сүзен...

Гази һаман да әле һушына килә алмаган кеше сыман утыра бирде. Күңел түрендәге иң газиз, иң кадерле кешесенә карата ясалган гаделсез адымының сәбәбенә төшенергә маташты ул. Чыннан да, каян килде икән соң ул чакларда Газига шул хәтле шәфкатьсезлек? Ничек бара алды ул шундый гаделсезлекләргә? Көчсезне түбәләү, рәнжетү — үз намусыңны аяк астына салып таптауга тиң түбәнлек. Кеше мәрхәмәтсез булса да булыр икән. Хәер, кеше генә түгел, кайчакта вакыт та мәрхәмәтсез була белә икән шул. Уйлый калсаң, хәйраннар булырлык. Ә бит ул үләрдәй гашыйк иде. Ә гашыйк йөрәк, гадәттә, юмарт, шәфкатьле, гадел, тугрылыклы булырга тиеш иде кана...

Тагын Рәхимжан абыйсының сүзләре.

— Күпчелек эшкә, нәкъ Иргали абый кебек, жене кузгалып тотынды. Ә эшнең бетәсе юк. Аланның түрге өлешендә гөрес тә гөрес агачлар ава. Төтен, ялкын, тач яу кыры диярсең инде менә. Шунда ук шау-гөр килеп ат белән бүрәнә тарттыручылар. Елга буендарак, өйләр салынасы урында, бернича такта яру станы. Анда көне-төне эш тынмый. Шунда ук, тирә-юньгә татлы сагыз исе аңкытып такта ышкылаучылар эшлиләр. Бернича урында бишәр-алтышар ниргәдән торган буралар тезелешеп киткән. Карт-корыга, хатын-кызларга да, хәтта, бала-чагага да эш табылды. Алар балта тотучы, балта чабучылар яныннан йомычкаларны жыеп, яндырып торалар. Төтен эчендә чебен-черки ул кадәр бимазаламый...

Ә инде тән яздырып алыйм дисең икән, рәхим ит, яр астында гына ягып томаланган мунча! Ул әледән-әле яңартылып торыла.

Иң беренче салынган йорт аеруча шәп чыкты. Аскы өлеше таштан, өске ягы шәмдәй эрбет, нарат агачларыннан иде. Аскы өлеше амбар вазифасын үтәде. Анда он, ярма, ит кебек азык-төлек сакланды. Өске өлешендә көненә ике-өч тапкыр аш-су әзерлиләр, көн дә ипи салалар, берүк вакытта ашханә урынына да файдаланалар. Кичләрен жыеннар да шунда үтте. Иргали абыйның эш бүлмәсе дә шунда иде.

Иргали абый ашау-эчүдән, йокыдан калды, күзгә күренеп суырылды. Эштән үзе дә бушамый, башкаларга да кул кушырып утырырга юл куймый. Чак кына буш вакыт табу белән, ат жигәр иде дә, я күрше авылга, я район үзәгенә китеп барыр иде. Киракнең исәбе-хисабы юк.

Тик Шаһи карт белән Шаһбаз гына аяклы каза булдылар. Аптыраш та йөдәш иде ул каһәр иңгерләре белән. Булсынга яшәмәделәр этләр, аркылыны буйга алып салмадылар. Бер кешене бишкә бүләрдәй чакларда, эшкә чакырып, бер-ике тапкыр тирмәләренә барырга туры килде. Мыскыл сүзеннән башканы ишетмәдем. Шаһбазы исә: «Мин чирле кеше...» — диган булып күләгәдә, черки-чебен кермәслек итеп бөркәлгән чыбылдык астында йокы симертүдән бушамады. Ышанычлы терәгең, тугрылыклы юлдашың, ил агасы булырмын дип мең төрле изгелекләр вәгъдә биргән Шаһи карт та, тора-бара жан көегенә, кара эчле, мәкерле бер корткычка әверелде. Карт диярлеге дә юк иде бит ичмаса, төп кебек тап-таза ир уртасы кеше. Этләшсә этләште, әмма эшкә чыкмады, сәбәбен таба торды. «Юк, юк, кем, мелла, бүген жомга. Гыйбадәт көне, фани дөнья эшләре белән мәшгуль буласым юк, килешеп бетмәс...» дияр иде. Яисә, күе-йонлач кашларын жимереп, ачыктан-ачык эштән баш тарта: «Фани дөнья эшеннән сырт сынган инде монда».— дип кенә жибәрә.

Үзләре эшләмәве бер хәл, башкаларның канына тоз салып, җан кыйнап йөрүләрен әйт әле син аларның. Беркөн ут йотардай булып, кая барып бәрелергә белмәгән бер мәлдә, Иргали абыйның эш бүлмәсенә Шаһбаз килеп керде. Аңа бүтәннәргә яраган, ягъни, әртил казанында пешерелә торган ризык ярамый башлаган, җыен кош-корт, поши-болан ише нәмәстәкәйләр эченә тия, янәсе.

Иргали абый да төшеп калганнардан түгел, нинди ният-максат белән йөрүен шунда ук төшенеп алды моның.

— Куй ите белән җылкы казылыгын хәзер генә каян алыйм соң сиңа? — дигән булды ул, туры җаваптан качкан сыман итеп.

Тегесенең дә әйтер сүзе әзер: син хуҗа кеше, теләсәң каян табарга тиешсең, янәсе.

— Рас баш итеп сайлап куйганбыз икән инде, будь добр, тап, анда безнең эшебез юк,— дигән булды, салкын бер гамьсезлек белән. Җитмәсә тагын авызын кыйшайта биреп, мыскыллы елмаеп маташа.

Иргали абыйның баш булуы кемнәрнеңдер мазасына тиюе безнең өчен күптән сер түгел иде инде.

Иргали абый, җаен туры китереп, эш турында сүз кузгатты. Әллә ни авыр булмаган эш тә тәкъдим итте. Шаһбаз күзен дә йоммады: эшләп кем баеган, бәхетне аны эшләп түгел, эзләп табалар дип, мыскыллы елмаеп җавап кайтарды.

— Нәрсә ул эштән курыктың? Өстеңә атланып йөрмиләр ич анда да. Шулай ук кул итең дә ашалмас иде.— Аннары теге эт ягына кулын селтәде.— Хәер, ялкаулансаң — кашык та авыр ди.

Иргали абый иплән кенә һәркемгә бер ук дәрәҗәдә кагыла торган бурычларны, закон-кагыйдәләрне телгә алды. Риясыз буйсына да белергә кирәк, янәсе. Тегесе шундук чәчрәп каршы төшеп, Иргали абыйның сүзен бүлде.

— Закон ул көчлеләрдән саклану өчен, җыен беткән, мескен җаннар тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсә, аның безнең ишеләргә дәхеле юк,— дип фәлсәфә сатты.

Иргали абый, көрсенгәндәй итеп:

— Эх-х, сез! — дип куйды.— Сау-сәламәт башыгыз белән эшләмичә ятасыз, оялыр идегез бераз. Берәүләр аяктан калып чаба, ә сез?..

Йөзе кара көйгән җүнсез җан, бу юлы да җавапсыз калмады:

— Акыл сатма, яме! Мин сиңа киңәшкә түгел, ярдәм сорарга килдем,— дип кенә җибәрде.

Юк, җайга-ипкә килә торганнардан булмады алар. Һич тә көтмәгәндә, уйламаганда, ходай безне менә шундый бәндәләргә юлыктырды да куйды. Хәер, ул зобаныйлар белән яшәп булмасын мин башта ук сизенгән идем инде.

Гази Рәхимҗан абыеның нәкъ картларча: «Ходай, каһәр иңгере, зобаный» кебегрәк сүзләр кыстырып сөйләвенә игътибар итмичә булдыра алмады: үзгәрсә дә үзгәрә икән кеше дигәнең.

Ул арада Рәхимҗан абые теге «аяклы казаларның» халык арасында, бигрәк тә картлар аша итәк астыннан ут йөртүләре, җыен тузга язмаган коткы, төрле уйдырмалар таратып, ризасызлык тудырып йөрүләре турында сөйли иде инде.

— Көннәрнең берендә Шаһи карт,— дип дәвам итте ул,— йорт-җир, ихата-кура буласы урыннарны чистартып, агач каезлап йөргән берничә картны җыеп, «Балаларыгызның исемлеген төзеп, урыс авыл Советында яздырып кайткан, чукындыра башламасыннар тагын...» — дип, халык күңеленә тәшвиш салып, тегеләрне тәмам үз ягына аударып, котыртып, Иргали абыйның эш бүлмәсенә җыеп алып килде. Әллә нинди ифрат та зур эш майтарырга теләгәндәй килеп керделәр болар. Минем дә ниндидер йомыш белән Иргали абый янында утырган чагым иде.

Моңарчы ярсып һәм үчләнеп, кара көеп йөргән Шаһи картның танырлыгы юк, кай арада әүлия, изге зат кыяфәтенә кереп өлгергән ди-

ген әле син аны. Сүзне дә ул башлады. Иргали абыйның минутны кырыкка бүләргә әзер хәлдә кыбырсынып утыруын күрептер инде, ике сүз белән аңлатып бирерлек нәрсәне юри сузып, кирәксә-кирәкмәсә дә борынгы сүзләр кыстырып, иплән кенә гәп сата башлады бу. Тел төбеннән аңлашылды: аз да түгел, күп тә түгел, мәчет салып бирүне таләп итә икән.

— Тукта әле, кем, мелла... синең белән минә мәслихәт кылып аласы эшебез бар иде. Әй-йе!..— Тасма телле юха җыланның кулында ниндидер кәгазь кисәге дә бар икән.— Кем, мелла... безне дүртәү-бишәү генә килгәннәр икән дип уйлап гөнаһлы була күрмә. Менә монда, унҗиде имза куелган гариза да бар. Безне монда бик изге йомыш китерде. Әй-йе! Ошбу көндә иң кирәге — мәсҗет. Озын сүзнең кыскасы шул, ил картлары, мөэмин мөселманнар безнең бүгенгедәй шартларга разый түгелләр. Әй-йе! Безгә кичекмәстән гыйбадәтханә, ягъни, мәсҗет кирәк. Ходай тәгалә тарафыннан шундый сынауларга дучар ителгәнбез икән инде, һич югында соңгы көннәребезне шәригатьчә яшәү турында уйларга кирәктер. Шәригать кануннары — алла ихтыярының җирдәге гәүдәләнеше ул. Адәм баласында сабырлык-тыйнаклык, рәхим-шәфкать дигән изге нәрсәләр төкәнде. Мәсҗет — дин терәге, ә дин — халык терәге ди китап. Белгәнеңчә, адәм баласы бер күренеш, хәлнең асылына төшенә алмады исә: «Ал-ла!»—ди, тәңребезгә мөрәҗәгать итә. Шунлыктан без дә бертавыштан: «Мәсҗет».— дип тәүсия кыламыз. Рәсүлемез Мөхәммәт галәйһе әссәлам биш вакыт намазны безгә фарыз итеп калдырган икән, шәригать кушканга буйсынмый булмас. Бу сүзләрне илләреннән аерылганнарның, ачы язмышка дучар ителгәннәрнең иңрәү авазы итеп кабул ит. Мөэмин-мөселманнарга үз кыйблаларын югалтырга ирек бирмә. Шул изгелегеңне кызганма, кем, мелла... Бу — безнең олуг үтенечебез. Шулаймы, картлар?..

Моңарчы таякларына таянган килеш, каршыга да, уңайга да ләммим сүз катмый торган картлар, бу фикергә кушылуларын белдереп, үзара мөгердәшеп алдылар.

Шаһи картка шул гына кирәк. Ул:

— Яраб-би газим! Фәрештәләрнең «Амин!» дигән вакытына туры килсенче, шулай булсынчы! — дип кычкырып ук җибәрде. Әмма, Иргали абыйның дәшмичә утыруын күргәч, тавышын йомшата төшеп, төзәтенгән сыман янә сүз башлады.— Мәсҗет дигәч тә, өнең алынмасын, кем, мелла. Кая инде ул безгә бөтен шартларын туры китереп, һәйбәтләп, вәгазь әйтү өчен мөнбәрле, манарасына алтын йөгертелгән ай куелган мәсҗет салулар! Безгә дәрвиш хөҗрәсе хәтле генә берәр йорт салып бирсәң дә, бик разый булыр идек. Дөрес, мәсҗет манарасыннан аермачык булып кыйбла офыгы күренүе шарт диелгән китапта. Әй-йе!.. Күрәсең, кем, нәпсебез зурдан түгел. Калган гомеребезне, картайган көннәребезне дингә багышлап, тәсбих төймәсе тартып уздырырга язсын иде. Амин!..

Картлар бердәм дога кылып битләрен сыпыргач, киерелеп утырган Шаһи абзыйның әллә сүзе беттеме икән дип уйлаган идем. Тик кая ул!

— Әгәр дә мөселман кардәшләремезне намаз-ниязсыз, гыйбадәтсез калдырсак, ансыз да бәхетсезлеккә төшкән газизләребезне аллаһе тәгалә, тагын да зуррак афәтләрен җибәреп, тагын да яманрак сынауларга, бәхетсезлекләргә дучар итәр, михнәт-газапларның да иң ачысын җибәрер. Әй-йе!..

Шаһиулла картның гелән шулай юк-бар белән кешеләрнең йөрәген алуы, җыен тузга язмаганны сөйләп күңелләргә шом салуы безнең өчен яңа түгел иде инде. Аның сүзе бетәсе юклыгын күреп, Иргали абыйга үз йомышымны әйттем. Әмма тегеː «Илнең могтәбәр картлары, хак мөселманнары җыелган урында, дөнья сүзләрен калдырып тор әле, кем...» дип авызымны бик тиз томалады.

— Изге китапта янә мондый сүзләр бар: ир-атка мәсҗет мөнбәренә сәҗдә кылып намаз уку егерме өлеш саваплырак, имеш. Әгәр дә адәм баласы аның шул тикле саваплы икәнлеген белсә, түше белән шуышып

барыр иде диелә шул ук изге китапта. Шуңа күрә дә мәсҗет турында тизрәк кайгыртасы, хәстәренә керәсе иде дип әйтүебез. Югыйсә, бу ләгънәтләнгән, каргалган Себер җирләрендә болай да ярты каферга әверелеп барабыз бугай инде. Тәүбә-әстәгъфирулла! Әйттем исә кайттым...

Шактый вакыт дәшми утырган Иргали абыйның искәрмәстән генә үтә дә җитди, катгый-кырыс тавыш белән:

— Беттеме сүзең?..— дип сорап куюына, барыбыз да сагая калдык.

— Әйтәсе сүз әйтеллде бугай...— диган булды Шаһи карт, үзенең иярченнәре ягына күз салып.

— Алайса ярый. Мине дә тыңлап карагыз, булмаса. Артны кашырга вакыт тапмаган, хәлебез хәттин-ашкан бер чакта, җыен тузга язмаган вак, пүчтәк дәгъвалар белән кеше башын катырып йөрүдән кайчан туктыйсың син, ә? Үзегез аркылыны буйга алып салмау гына җитмәгән, хәзер инде башкаларны да эштән аерасызмы? Ниткән хәл бу? Хәзер үк җавап бирегез!

Сорауны шулай кабыргасы белән куяр дип көтмәгәнме, бүлмәдә тынлык урнашты.

— Изге юлда йөрибез ич, кем, мелла...— диган булды Шаһи карт, туры җаваптан качып.

— Нинди юлда йөргәнеңне бик яхшы беләм мин. Җиткәндер, ниһаять! Мин тагын синең турыда: акыллы ил карты дип уйлаган идем. Айһай ла, нык ялгышканмын! Син исә халык арасында коткы таратып, кешеләрне юлдан яздыруны максат итеп куйган бер зат икән.— Чыдары беткән Иргали абый тезде дә тезде.—...Себердә теләсә нинди башбаштаклык, төрле корткычлыклар эшләп ятарга ярар дип уйлыйсыңдыр. Ялгышкансың! Монда да Совет власте. Мәчет диган буласың, ике сүзнең берендә: Алла! диган буласың. Икейөзлеләнмә! Бернинди дә изге нәрсә юк сезнең өчен. Аллага ышан, үзең кымшан дигәндәй, алла бирмәгәнне, мулла бирмәсен бик яхшы беләсең син. Юкка суфыйланып, гайрәт орып йөргән буласың. Безнең арада сездән дә динсез, сездән дә иблис кешеләр юк...

Шаһи картның танырлыгы калмады. Итләч борыны, табак бите күзгә күренеп кызарды, чалшайды, чигәсендәге кан тамырлары бүртеп чыкты. Ачуыннан ярсып-зәһәрләнеп сикереп торды да, баскан урынында биибии, йодрыкларын айкап, буылып кычкырына, ачыктан-ачык яный ук башлады.

— Ах-х, башың беткере! Ах-х, вөҗданыңнан ваз кичкән нәрсә. Иблис ләгыйн! Дәһри җан! Андый сүзләр әйтергә ничек телең әйләнә синең?!. Тәүбә, диген, исәр, алла сугар. Мордар китәсең ич, зобаный. Бетәсең ич!.. Аны кара, бәддога укымасыннар үзенә. Шулай, мөселманнар йөзенә кара ягарга беркем дә хокук бирмәгән сиңа. Матри аны, иблис токымыннан туган нәмәстә!.. Иленнән куылган өендә булмас ди. Без болай да кара тайгада җәфа чикмәктә. Алайга китсә, без башкача да эш йөртә белербез. Әй-йе!.. Синең эше динсезләргә каршы көрәш аллаһе тәгалә алдында да хилафлыкка саналмый. Алла илчесе Мөхәммәт пәйгамбәр дә муафыйк күргән андый адымны... Дәҗҗал кавеменнән саналган синдәй бәндәләрне, тәңре әмере белән үтереп китү дә фараз ди. Ату без...

Иргали абый, сине тыңлап торырга бүтән вакытым юк дигәндәй, Шаһи карт ягына кулын селтәде дә аның иярченнәре ягына борылды һәм кырт кистереп сорау биреп куйды.

— Нәрсә, абзый кешеләр, сез дә кырык эшне кырык якка ташлап, беренче чиратта, мәчет салу эшенә керешү ягындамы?.. Ә алда эш-шөгылының чиге-чамасы юк чак. Күреп торасыз, мәшәкатьләр бихисап. Бик күпләр йокысыз-ялсыз эшлиләр. Башкача мөмкин түгел. Эшсез килсә, эш калдырыр ди. Сезгә дә, абзый кешеләр, җил кай якка иссә, шул тарафларга авышып йөрмәскә иде. Болай шәләй-вәләй йөреп, бүтәннәрне рәнҗетәсез. Андый аумакай булырга ярамый. Кемгә иярдегез

сез, ә? Әллә оныкларыгыз өчен шулай борчылып йөри дип уйлыйсызмы аны? Йөрер, бар! Безнең бердәм алынып, тормышыбызны җайга сала башлавыбыз эчләрен яндыра аларның. Сез мине дөрес аңлагыз, картлар. Мин сезнең биш намазыгызга каршы түгел. Бик телисез икән, намаз уку урыны җунәтү ягын да карарбыз. Хикмәт андамыни. Беренче чиратта әнә бернчә бүлмәдән торган барак сыман йорт салабыз. Мәктәп бинасы. Анда балаларыбыз аң-белем, тәрбия алачак. Надан кеше бу дөньяда сукыр белән бәрабәр. Укулар башланганчы әлеге баракта сабый балалы гаиләләр яшәп торыр. Ул арада бураларны күтәреп, түбә астына да керә башларбыз. Башкача мөмкин түгел, агайлар. Районда да, авыл Советында да шулай диделәр. Хәтта әнә дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары өчен акча да бирделәр. Ә инде балаларыбызга белем бирүгә килсәк, саф туган телебездә, дөньяви китаплардан дөньяви белем алачаклар. Дошманнар котырына нярмәгез, абзыйлар. Исемлек тә бары тик шул максаттан, Казан тикле Казаннан кайсы сыйныфка нинди һәм күпме дәреслекләр алдырту өчен төзелде. Бәхетебезгә каршы, арабызда мич чыгаручылар, тир- иләүчеләр генә түгел, мөгаллимә белән доктор да бар икән. Тиз арада Казаннан газит-журналлар да, китап ише нәрсәләр дә кайта башлаячак... Үземә калганда, картлар, мин барлык эшләрне дә сезнең белән киңәшеп башкарырга тырышам. Шулай да бер нәрсәне үз белдегем белән эшләдем, аның өчен генә гафу итәрсез дип уйлыйм. Булачак авылыбызга Чулман буйларындагы исемне куштырдым. Нишлим соң, туганнар, туып-үскән як манзаралары һаман да йөрәктә, һаман да күңел түрендә. Безнең авыл гүзәл Чулман буенда иде. Идел — илнең ишеге, Чулман — җирнең бишеге дигән сүзне шәт сезнең дә ишеткәнегез булгандыр... Ифрат та хозур, матур табигатьле шул туган якларыбыз...

- Күрәм: картлар тураеп кына калмадылар, әкренләп Иргали абый өстәле янына елыша башладылар. Һәм аның һәрбер сүзен диярлек хуплап, ияк кагып җөпләп тордылар. Тәмам тынычланып өлгергән Иргали абый, киләчәк турында, халыкны йортлы-җирле итеп кенә калдырмыйча, һәр гаиләне мал-туарлы итү өчен дәүләттән ярдәм соравы турында да, якын киләчәктә Себердәге авылыбызның кыйммәтле җәнлекләр үрчетә торган махсус хуҗалыкка әвереләчәге турында да сөйләп китте.

— Күрдегезме, туганнар, безгә яшәгән урыныбызны гына түгел, гомер буена килгән, ата-бабалардан калган һөнәребезне дә алыштырырга туры киләчәк икән әле. Дөрес, бу хәл вакытлыча, тайганы чигендергәнче генә шулай булачак. Игенчелек — ул безнең мәңгелек һөнәребез. Борынгы бабайларыбыз тикмәгә генә: иген иккел, рәхмәт өмит итәр булсаң, димәгәннәрдер.

Иргали абый тагын тегүчеләр, күн иләүчеләр, итек басучылар өчен артил ачу турында, коелар казыту, авылда кибет ачу, доктор өчен бүлмә булдыру турында сөйләп китте. Боларның барысы өчен хезмәт хакын авыл Советы түләячәге турында өстәргә дә онытмады.

Шушы сүзләре белән Иргали абый суйды да салды барсын берьюлы. Картлар: Иргали туган, син без диваналарны кичерә күр инде диеп, гафу үтенеп, таралыштылар. Аның каравы теге җүнсезләр ачыктан-ачык корткычлык, җинаять юлына басты. Әлеге сөйләшүдән соң ике-өч көн дә үтмәгәндер, бавын кисеп көймәне агызып җибәрделәр. Михай-Баянай, ризык төрләндерерсез дип ике ау-ятьмә белән бер көймә китерткән иде. Шул көймә ярдәмендә яр буен ауган агачлардан арындырып, нәкъ Михай дәдәй күрсәткәнчә, ау салган идек. Иртәгесен шаклар каттык: ярты көймә балык кергән. Үзләре эредер, һәркайсы биш кадактан ун кадакка тартым булыр. Үзебез дә кинәндек балыкка...

Шулчак тыңлап утыручыларның кайсыдыр, соклануын яшерә алмыйча: димәк балык ише нәрсә күп? — дип сүз кыстырып куйды. Рәхимҗан исә, тагын да җанлана төшеп, дәвам итте:

— Күп кенәме соң! Адәм әйтеп адәм ышана торган түгел. Аю-бүре-

нең бетәсе булмаган кебек, башка төрле киек-җәнлекнең, кош-кортның исәбе-хисабы юк. Иртә-кичләрен балык уйнавыннан елга-күл өсләре кайнап тора. Баштарак көртлек-суер ише эре-эре кошларны малай-шалайлар таяк белән генә бәреп алалар иде. Балык турында әйтеп торасы да юк. Соңрак без аны сайлап — нельма, сирак, муксун, керкә ишеләрен генә ашый торган идек. Күлдән тотыла торган керкә балыгын Себердә, тимгел-тимгел булгангадыр инде, ала балык дип йөртәләр. Андый да тәмле балык дөньяда юктыр. Патша табынына куела торган ризык дип сөйлиләр иде аның турында.

Балык дигәннән, аңа бәйләнгән мәзәк хәлләр дә булгалады. Яз көне дәрья булып ташыган Кәт әкренләп ярларына кайтты. Хатыннарның берсе, ташу вакытында торбаларына тикле күренмәс булып су астында калган мунча янына төшеп, ягарга әзерли башлый. Әмма, ләм баскан өйалды ишеген күпме генә тырышса да ача алмый бу. Җилкәсе белән эткәли-төрткәли торгач, ишекне урыныннан кузгата хатын. Әмма шулчак эчтән кемдер шундый итеп ишеккә бәрә, мескен хатынның өне алына. Мунчада җен бар дип бөтен халыкны аякка бастыра.

Себердә тышкы ишекләрне эчкә таба ачыла торган итеп эшлиләр. Беренчедән, кар бик ишле була. Ат йөздермәле. Бураннардан соң, еш кына, йорт-куралар бөтенләе белән көрт астында калгалый. Кемнеңдер килеп казып алуын көтеп ятып булмый, һәркем үз җаен үзе карый. Икенчедән, тайга хуҗасы — аюдан саклану өчен дә ишекләрне эчкә таба ачыла торган итәләр. Чөнки ул этү-төртүне өнәми, бар белгәне үзенә таба тарту, йолку, умыру...

Соң шул, жыелышып, мунча янына төштек. Ишеккә кагылуыбыз булды, шулчак кемнеңдер эчтә лайны чупылдатып хәрәкәтләнүен абайлап алдык. Карасак, җен дигәнебез өч-дүрт пот чамасындагы, иләмсез бер җаен балыгы булып чыкты. Ташу вакытында кереп калган!

Күрше авыл староверлары белән исә көтмәгәндә-уйламаганда күзгә-күз очрашырга туры килде. Юк, дуслык юлында түгел, яманлык аралаштырды безне. Көтелмәгән низагның килеп чыгуына әлеге дә баягы Шаһбаз сәбәпче булды. Кем тарафыннандыр, «Вобла» дигән кушамат тагылган, заманында башы өтерманнән чыкмаган Зариф атлы бер бәндәне ияртеп, тегеләрнең тайга аланлыгына чыгарган көтүләреннән берьюлы ике башмак тана урлыйлар. Бу хәлне сизенгән көтүчеләр ат менеп куа чыгалар. Шаһбаз да хәйләле: тана житәкләгән Зарифны алга җибәрә дә, атыннан төшеп, агач артына яшеренеп, тегеләрне ут ачып каршылый. Көтүчеләрнең берсе яралангач, башкалары туктап кала.

Икенче көнне иртән бер төркем ат менгән староверлар авыл башына килеп туктадылар. Әле яңарак кына балта-пычкы астыннан чыккан буралар арасында, дистәләгән чум, чатыр-куыш күргәч, безне чегәннәр дип уйлаганнар булса кирәк. Араларыннан берәү: «Вожагыгыз кайда?!» — дип аваз салды. Билгеле инде, алар каршысына Иргали абый барып басты. Тегеләрнең сүзләре кыска. «Тана урлап, авылдашларын яралаган кешеләрне тотып бирмәсәгез, бүген үк, менә хәзер үк кан коелачак, авылыгыз кара күмергә әвереләчәк...»

Кыяфәтләренә караганда, сүзләре бер дә эштән аерылырга охшамаган: сакал-мыек баскан шөкәтсез йөзләренә баксаң, өннәрең алынырлык. Йонлач кашлары астында, нәфрәт чаткылары чәчеп, котсыз күзләре генә яна.

Ин курыккан кеше — Шаһи карт булды. Иргали абыйның бер алдына, бер артына төшеп: «Алла хакы өчен дип сорыйм, ярдәм-шәфкатеңнән ташлама. Зинһарлап үтенәм, низагка кермәүнең берәр чарасын таба күр; һич югында тана урынына сыер вәгъдә ит»,— ди бу.

Бәхетебезгә каршы, нәкъ шул вакыт авылыбызга, ике тимер-хут арбага төялешеп, НКВД белән милиция вәкилләре килеп төште. Шунда ук, конторага кереп, тикшерүләрне башлап та җибәрделәр. Араларында доктор да бар икән. Җәрәхәтнең пуля ярасы икәнлеге билгеле булган.

Иргали абый үзенең шиген әйтте. Иң элек Шаһбазны алып килделәр. Күзен дә йоммый, алдаша, җир бит: сырхау булу сәбәпле, куышымнан да чыкканым юк, шулай ук минем берничнди мылтык та күргәнем юк ди бу. Вакытлыча дип, келәт вазифасын үтәгән өй астына ябып куйдылар моны. Тана урларга килүчеләрнең икәү булганлыгы ачылгач, ач яңак Зарифны да алып килделәр. Анысы бик тиз «тишелде», барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Тананы да кай тирәдәрәк бәйләп калдырулары турында әйтте.

Тананы алырга баручыларга мин дә ярдем. Авылдан шактый еракта, куе чыршылыкка кертеп бәйләп куйган булганнар. Күз күне булуга да карамастан, дымсу, тынчу. Әмма безне тана үзе түгел, ә мөгезләреннән нык сүс арканга бәйләнгән, канлы башы гына каршылады. Тайга хуҗасы — аю аны үзенә табыш иткән. Чак кына читтә, ботак ише чупчар белән күмелгән, яртылаш ашалган түшкәсен дә таптык. Аю табышын шулай исләндеребрәк ашарга ярата.

Бары тик шуннан соң гына «Вобла» Зарифын идән астына ябылган Шаһбаз белән күзгә-күз очраштырдылар. Иптәшенең «тишелгәнлеген» белгәч, тегесенең йөзендә иман затлары калмады. «Ах-х, тинтәк!.. Иң элек синең муеныңны борып ташлыйсы калган икән!..» — дип зәһәрләнде.

Шаһбаз: «Обрезны тайгада ташлап калдырдым»,— дигәч, аны да ике милиция арасына бастырып, алып чыгып киттеләр. Мылтыкны тапмадылар, әлбәттә, нибары ике буш гильза алып кайттылар. Тагын кирәгер, дип, каядыр җыеп куйган булган иблис токымы.

Каенесе фаш ителгәч, чалмалы шайтан да икенче төрлерәк сайрый башлады. «Тамак — иблис, тәмугка кертә,—ди.— Тана ите кирәксенә иде шул... Бәндә хатадан хали түгел ди, кем, мелла... Зинһар ярдәмеңнән ташлама! Синең бер сүзең житә хәзер... Корал саклауда гаепләнә, имеш! Бу коргыры заманда коралсыз була димени...— Ә инде Шаһбазның кеше яралауда гаепләнүен белгәч, алыштырып куйдылар диярсең үзен, ыргылып, Иргали абыйга ябырылды.— Мәчет дидем, төрле бозыклар башланыр, дидем. Бер түгел, гелән әйтә килдем. Җыландай телләремне чыгарып әйттем, тыңламадың. Менә, сүзләремнең рас килүен күрдеңме инде! Әййе, кем, мелла, барысына да син генә гаепле. Балаларыбыз азынды, шайтан коткысына бирелде. Китап әйтә: дин тотучылар азайган саен, шайтан коткысына бирелүчеләр күбәя барыр ди. Берни дә түгел, шайтаннар гына котырткан безнең балаларыбызны да...»

Ике көнгә сузылган тикшерүләрдән соң, тегеләрне алып китәргә әзерли башладылар. Шаһбазның танырлыгы калмаган, йөзендә вәхши кырыслык, зәһәр катылык. Кан баскан күзләрендә рәхим-шәфкатьнең әсәре дә юк. Иргали абыйдан үч алу хисе белән ярсыган мөртәт агуын чәчте дә чәчте.

— Ну-у, кара аны! Болай калдырыр димә... Җиде бабаңа житеп, тәүбәгә китермәсәм, исемем Шаһбаз булмасын! Миннән җир астына качып та котыла алмассың, сүзем сүз, җир йөзендә барыбер яшәтмәм... Яшь урынына кан түктереп, җәлладың булып иманыңны суырмасаммы...

Шартлар дәрәҗәгә җиткән, каенесе белән китәргә җыенган Шаһи карт та, ашатып торуыбызга, баш очларында түбә булдыруыбызга каршы, ниһаять, үзенең «рәхмәтен» әйтте. «Башларыгыз бетсен, шушы кара тайгада тамырларыгыз корысын. Илсез-догасыз зобаныйлар, ачы каргышым төшсен сезгә!..» — дип бәддога укыды.

Ниһаять, алып киттеләр үзләрен. Бераздан, кылган җинаятьләренә карап, һәркайсына төрле җәза бирелүе турында да ишеттек. Инде адәм исеме күтәреп йөргән имгәкләрдән котылдык дип тә уйлаган идек. Торабара янаулар, ләгънәт сүзләре дә онытыла төште. Халык та иркен сулыш алды.

Әмма куанырга, инде котылдык дип шатланышырга иртәрәк булган икән. Фаҗигенең иң зурысына, яшәү ямьнәреннән мәхрүм иткәненә шул ук елның кышында тарыдык...

Рәхимҗан, фикерен тупларга җыенгандай, кашларын җыера төшеп, бермәлгә тынып калы. Әмма озакка түгел. Күкрәген тутырып тын алды да, күңелен бимазалап торган ачы истәлектән котылырга теләгәндәй, сабыр-тыйнак кына хикәяли башлады.

— Минем, атлар җигеп, Инәсәй елгасы буендагы район үзәгенә киткән чагым иде. Өйләребез, нәкъ мондагыча, кара-каршы, бер ихата эчендә. Абзар-куралар да бергә.

Ул көнне Иргали абый эштән бик соң кайта. Ихата тирәсендә бераз чуалганнан соң, өйгә керергә ниятләнеп, фонарь янып торган баскыч болдырына күтәрелә. Шулчак аран белән ике арадагы әрдәнәнең өске өлеше ишелеп төшкәнне ишетә. (Анда без, Себер халкыннан күрмәкче, өй-кура тирәсен койма белән түгел, утын әрдәнәләре белән уратып ала идек). Иргали абый, ике-өч кочак утын ишелеп төшкән якка борылып: «Әй-й, кем бар анда?..» дип аваз сала. Шунда теге вәхши Шаһбазның җан ачуы белән әйткән сүзләрен ишетә. «Нәрсә, оныттың дамыни?.. Очрашырбыз дип кисәтеп киткән идем бит, хәтерең бик төпсез икән, халуй җан! Миңа көн күрсәтмәдең... Икебезнең беребез артык бу дөньяда. Менә исән чакта алыш-бирешне, исәп-хисапны өзәргә дип кайттым. Без алай бурычлы кала торганнардан түгел. Иманыңны китер, сатлык җан!..» — ди бу. Шул мизгелдә үк мылтыктан аткан тавыш һаваны яра. Әмма Иргали абый ут яктысыннан читкә тайпылырга өлгереп кала.

Дары төтене таралганда гына кайдандыр Миңсылу атылып чыга. Эт йөзнең яңадан мылтык корганын ишетеп: «Тагын ата ич!..» — дип болдырга очып менә... Шулай итеп, Иргали абыйга дип төзәп атылган пуля Миңсылуның күкрәген тишеп үтә...

Шау-шу куба. Кичләрен клуб итеп файдаланыла торган мәктәптән кайтып килүче яшьләр, мылтыктан аткан тавышны ишетеп, капкадан йөгереп керәләр. Эшне аңлап алгач, ау мылтыклары белән коралланып, яссы чаңгыларына басалар да куа чыгалар. Кайдан килгәндер албастыга көч-егәр, ат йөздерерлек карны ерып, кай арада бакчалар артындагы кисентегә барып җитәргә өлгергән диген син аны. Эзәрлекләүчеләрне, якынайган этләрне ут ачып каршылый бу.

Төн урталары авышкач, аяк-кулларын бәйләп, чаңгыга сузып салып, сөйрәп кайталар моны. Иртәгәсен килеп җиткән милиция, кулларына богау салып, яңадан алып китә.

Мин кайтып җиткәндә,бар да беткән, хәл эчендә яткан Миңсылуның кешене аерыр, кешене таныр чамасы да калмаган иде. Йөзенә мәет сарылары йөгергән, нечкә сызык кына булып кан саркып торган иреннәре дерелди. Менә ул, саубуллашырга теләптер инде, ятагы тирәсенә җыелып торучыларны соңгы тапкыр күздән кичерде. Мин дип уйлаптыр инде, бәгырь, үрелеп Иргали абыйның кулын үзенекенә алды. Бу дөньяны ташлап китүдән курыккандай, Иргали абыйның кулын җибәрмичә торды, өзек-өзек зәгыйфь тавыш белән: «Малайны тәрбияләүне... үз кулыңа ал. Кеше ит...» диде. Аннан соң инде әллә ни озак тормады...

Эх-х, нигәләргә генә аягым тартмаган шул сәфәрләргә чыктым дип, ул чактагы үкенү-уфтануларымны үзем генә беләм! Үч иткән кебек, ят кешеләрне генә түгел, күрше-күләннәрнең тавыгын да ишегалды тирәсенә якын җибәрми торган Айканы да үземә иярткән идем шул.

Авызларын ачып, дөньяларын онытып тыңлап утыручылардан берәве, бик тә көрсенеп:

— Чит-ят җирләрдә гүр иясе булган икән, мескенкәем,— дип куйды.

— Кемнең кайда тигез җирне түмгәк итәсен кем белгән! — диде икенче бер тавыш.

— Миңсылусыз да калгач, тормышымның яме, тәме, мәгънәсе бетте,— дип дәвамлады Рәхимҗан таркау гына.— Шуның өстенә, менә сәламәтлегем... Кая карама — сагышка батыра, кай тарафларга күз салма — җанны кыса. Иле ямьсез, суы тәмсез булып тоела башлады Себернең. Рәтле язы, юньле җәе юк. Ул да түгел, кырыкка тәрләнеп, җан ия-

ләренең теңкәсен корыткан зәмһәрир салкыннары, көз ачкысыз буран-нары белән кыш житә. Баштарак, Миңсылу исән чакта, алтын көзләре искитмәле дә матур булып тоела торган иде. Чебен-черки бетә, көннәр чат аязлана. Җиләк-җимешнең, эрбет чикләвегенең исәбе-хисабы юк. Һәрьякта муллык. Кәт елгасы буенда, нәкъ безнең яклардагы кебек, шомырт, миләш, тал, зирек, зелпе кебек агачлар үсә. Көзләр життеме, нәкъ безнең яклардагы кебек саргаялар... Күңелдә билгесез моң кузгату өчен шул бик житә иде. Соңрак ул якларга карый алмас булдым. Су буйларына күз салдыммы — сары сагыш, тайга ягына баксам — кара кайгы... Шунда мин тәкатьсезләр булып туган якларыбызны жирсенә башладым. Чыдар чамалар калмады.

Хәер, бер мин генә түгел, авырлыкларны зар-сыкраусыз күтәрә белә торган Иргали абый да иягәшә алмыйча иза чикте, сагыну-юксынуга бирелгәләде, сарыга сабышты. Икәүдән-икәү генә калган чакларда еш кына: Эх-х, берәр могжиза, нинлидер тәкъдир көче белән туган якларыма кайта алсам, ничек яшәргә икәнлекне белер идем, каһәрләнсәм дә түзәр идем дигәли иде. Күңелебез шулай һаман үткәннәрдә, туган якларда булды. Әмма Иргали абый ул кадәр үк бетәшмәде, үзеннән бигрәк башкалар өчен ут йотып, һәр эштә башлап йөреп, авыррак эшләрнең юан башын үзе күтәреп яши бирде. Шулай итеп көн артыннан узды көн, узды ай, узды ел...

Әле бая гына дәртләнеп-ялкынланып утырган Рәхимжанны кинәт алыштырып куйдыла́рмыни, тәмам шиңде, башы да күкрәгенә иелеп төште. Бүлмәне дә авыр тынлык басты. Шунда кайсыдыр аны күңелсез уйларыннан, фажигале истәлекләреннән арындырырга теләгән сыман итеп, сүзне Иргалигә күчереп, аның нахакка гаепләнүе хакындагы хәбәрне алгачыннан нишләве турында сорап куйды. Бу мәсьәләнең барысын да бер үк дәрәжәдә кызыксындырганы сизелеп тора иде.

Рәхимжан башын калкытты: «Бик соң бугай бит инде...» — дип, як-ягына каранып алды. Әмма: «Сөйлә әле, кышкы төннең иге-чиге юк аның»,— дип аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Кунакка башка чара калмады, буйсынды.

— Бу хәл өченче кышка кергәч булды,— дип башлады ул сүзен.— Көннәрнең берендә, район үзәге Пировкадан НКВДга чакырып кәгазь килеп төште. «Ашыгыч» дигән сүзе дә булгач, өйдәгеләрнең күңеленә кара шом тулды. Ул тирәгә чакыруның җүнлегә түгеллеген без инде белә идек. Миңсылу белән булган фажигадан соң, Иргали абыйны НКВДга чакырып алып, шактый талкыдылар: «Шундый корткычларда обрез барлыгын белә торып, ник башта ук тиешле урынга жәвит итмәдегез?» — дип байтак тинтерәттеләр. Бәлки хужалыкка кагылышлы мәсьәлә беләндер дип, үз-үзебезне тынычландыргандай иттек.

Иргали абый: андый-мондый хәл була-нитә калса, һич югында, син хәбәрдар булырсың дип миңа да жыенырга кушты. Мичәүләп пар ат жиктек тә юлга чыктык. Илле чакрым ара юлмыни ул, барып та життек.

...Көтәм. Юк та юк бу. Атларга да солылы торыпшалар кидереп куйдым. Ә Иргали абый күренми генә бит. Кем әйтмешли, эчтә утлар дөрли, күңелне шул тикле сызландыра, чыдар чама юк.

Ниһаять, чыкты бу. Йөзе киндердәй ап-ак. Минем дә аяк астындагы жир убылып, чайкалып куйган сыман булды. Дәште юк. Тел аркылы тешләнгән. Харап, мин әйтәм...

Иргали абый чана янына килде дә, басып торырга хәле калмаган кеше сыман, түшәлгән печәндә яткан толыбы өстенә утырды. Ике куллап башын тотты да бу хәрәкәтсез калды. Ишетәм, үзалдына гына сөйләнә: «Кемнәргә кирәк булды соң бу хәллар?!. Нәрсәгә кирәк булды?..»

Шулчак әлеге тимер капкадан Иргали абыйның сугышчан дусты Роман атылып чыкты. Йөгереп тә килде, Иргали абыйны жилтерәтеп аягына да бастырды. Үзенең авыз ерык, күзләр ут, асылкош тоткан диярсең инде менә. Эткәли, Иргали абыйны, төрткәли. Нәрсә өчендер

тәбрикли, молодец! ди. Мондый да олы куанычны юмыйча ярамас, әйдә, хәзер үк безгә киттек ди. Кымтыратыпмы кымтырата Иргали абыйны. Үзе һаман сөйләнә: «Синең кебек революция солдаты җинаятьче була алмый. Сиңа документлар әзерли калдылар... Бөтен юл чыгымнарыгызны хөкүмәт күтәрәчәк. Ә кайткач мал-туарларыңны, йорт-җирләреңне дә үзеңә кайтарып бирәчәкләр...»

Иргали абый: өйгә кайтыйм әле, Роман туган, чакыруың өчен рәхмәт дип, аларга барудан баш тартты. Тегесе дә аңлады ахрысы, бүтән кыстамады.

Юлда Иргали абыйның теле чишелде. Чын үтерүченең табылуы, Иргали абыйның нахакка гаепләнүе турында хәбәр килгән икән. Аңа: «Син, иптәш Миргалиев, очар коштай иректә! Рәхим ит, дүрт ягың кыйбла»,— дигәннәр.

«Артыннан кем йөрде икән?..» — дип тә баш ваттык. Ахыр чиктә Иргали абый: казанлыларның кулы уйнагандыр дигән нәтиҗәгә килде. Ничек кенә булмасын, без хәзер, чыннан да, очар кошлар кебек иректә идек. Эх-х, бу көннәрне, бу куанычларны Миңсылу гына күрә алмыйча китеп барды дип уфтандык.

Иргали абыйның аклану хәбәре бездән алда кайтып җитеп, сәгате-минуты белән таралып өлгергән иде инде. Бөтен авыл халкы аякланган. Гомердә булмаган хәл, өйгә үк басып керделәр. Сиражи кебекләр артык кыстатып-нитеп тормыйча түргә уздылар. Җитмәсә тагын үзе генә дә түгел, һәрчак йөзенә сары сагыш сарылган, олы күзле хатынын да, ике улын да ияртkән. Утырырга урын җитмәгәннәр аяк өсте тора. Бактың исә, барысы да үзебезнекеләр, сагыш-михнәтләрне дә, кайгы-хәсрәтләрне дә бергә кичергән кешеләр. Өстәлгә күз салсаң, хәйран-тамаша: түтәрәме белән салкын ит, кыргый умарта балы дисеңме — һәммәсе дә бар.

Иргали абыйны, Гөлниса апа белән Гөлүсәне, берьюлы безне дә зур куанычлы хәбәр белән тәбрикләгәннән соң, сүзне Сиражи алды. Карусыз, кыю ир, якын дустыбыз, сердәшебез. Күпләргә үрнәк кеше. Кеш асрауда Иргали абыйның уң кулы, беренче ярдәмчесе. Ат җене кагылган бу кеше «йомшак алтын» дип аталган мехлы әлеге җәнлекләргә ат итеннән ризык әзерләү серләрен ачты. Шуның нәтиҗәсендә безнең нәселле җәйлек бригадасы тирә-юнь хуҗалыкларына үрнәк итеп куела торган иде.

Соң шул. Сүзне Сиражи алды:

— И-их, Иргали абыкай!.. Шулай итеп аерылышабыз дамыни инде?.. Син барында, нинди генә эшкә алынсак та, тәм табып тырышатырмаша идек. Рәхим-шәфкатьле инеңне даим тоеп яшәдек. Башлы идең, Иргали абыкай. Ә башлы кеше ташны аш итә дия торган булганнар өлкәннәр. Синсез нишләгән булыр идек икән без, күз алдыма да китерә алмыйм. И-их, Иргали абыкай. Менә шул безнең кебекләрне инде «канатсыз кошлар» дия торган булганнардыр...

Шунда ул хатыныннанмы, әнисе янында торган улыннанмы, җыйнак кына җиз телле тальян гармун алды. Алды да: «И-их-х, едрит-кудрит!» дип, гармунын җан-фәрманга каерып торып уйнап та җибәрде. Җиренә җиткереп, үткәзеп уйнады, бу моң хыялны үзенә ияртеп туган якларга алып китте:

Без түгел кошлар моңая,
Кайтырга иләренә...

«Туган ил» көе — Сиражиның йөрәк түреннән чыккан җыруы барыбызны да әллә нишләтеп җибәрде. Җанның иң нечкә кылларына моң сарылды... Никадәрле аһәң, никадәрле илаһи көч, кодрәт, сихри дәрт бар иде бу көйдә. Бөтен дөнья тынсыз-өнсез калды. Урамдагы җилләр дә, тайга шавы да тынып калды кебек. Бу моң ата-бабаларыбызның күңеленнән, үзебезнең туган туфрагыбыздан шытып чыккан, гасырлар буена

халкыбыз тарафыннан кадерләп сакланган, назлап үстерелгән рухның бер аһәңе иде. Бу монда туган илне, газиз җирне өзелеп сөю дә, өзгәләнеп сагыну-юксыну да бар иде. Гармун ашкынып-талпынып моң түгә, җанга үтеп, бәгырьләрне парә-парә телгәли. Шунда бер нәрсәне ачык төшендем: сагынудан, җирсүдән дә көчлерәк ачыттырган хис юк икән күңелне. Җирсү дигән нәрсә тора-бара җан газабына әверелә.

Сиражи уйный... Көй тылсымы җанга сарыла, җанны сулкылдата, тәкатьсез итә... Бишектән үк таныш, соңгы сулышыбызгача күңелне җылытып, иркәләп, назлап, туган халкыбызның бөтен рухын чагылдыра торган могҗизалы моң йөрәк-бәгырьләрне урыннан кубарды, авырттырды, әрнетте... Ул да түгел, күзләрне әчеттереп, бугазны ниндидер төер томалады. Күз алларына туган туфрактан аерылулар: «Хушыгыз! Күрешергә язмаган булса, бәхил булыгыз!..» дип, туган нигез бусагаларына башларны салып җылаган чаклар килде. Ә моң агыла. Юк, моң гына түгел... Әйтерсең лә, туган якларыбыз, авылларыбыз, нигезләребез үзләре безне эзләп килеп җиткән иде...

Кычкыра торган каккукне
Очырмас идем күрсәм дә;
Туып-үскән илне бер күрсәм,
Үкенмәс идем үлсәм дә...

Шулчак җыр урта бер җирдә өзелде. Дөньялардан китеп гармунын сыздырган Сиражига әллә нәрсә булды, иелеп төшеп, сулкылдап җылый башлады. Яман тынлык урнашты. Еракларда адашып калган изге туфрак, туган як өннәре үзенекен итте, аңа хатыннар да кушылып сыктап җылый башладылар.

— Иргали абыкаем ла! — диде Сиражи.— Туганым-җаным ла!.. Шулай итеп безне ташлап китәрсең микәнни?!. Нишләрбез без, нишләрбез?!. Синсез калгач, үзебезне шушы кара тайга урталарында адашкандай хис итәчәкбез бит. Уйлыйсыңмы шуны, күз алларыңа китерәсеңме безнең хәлләрне?..

Чын кешеләрне бәхетсезлек якынайта, яманнарны тагын да читләштерә диләр. Хак сүз икән.

Ул арада Сиражиның хатыны да телгә килде. Аның үзәк өзгеч тавыш белән: «Иргали абый!.. Ташлама безне!..» — дигән сүзләре барчабызны тетрәндереп җибәрде. Хатын сүзен башкалар көчәйттеләр. «Бүгенгесе көндә абруебыз, бәһабез бар, йөзебез ак икән, бу фәкать синең аркаңда гына, Иргали туган!..»

Китте тагын зар җылашу, китте аһ ору. Мәхшәр көне диярсең инде менә.

Мин дә күзләремне яшь элпәсеннән арындырып, түрдә утырган Иргали абый ягына борылдым. Аның да, салкында озак булганнанмы, йөзе кызарган. Күз төпләре ялкынсынып киткән...

Ул кичне Иргали абый тел тибрәтеп уңай якка да, тискәре якка да ләм-мим сүз әйтмәде, бары тик бер үк сүзләрне кабатлады: уйлашырбыз, дусларым, киңәшербез...

Бары тик соңыннан, икәүдән-икәү генә калгач, әйтте бу: «Беләм, кайда да тамагыбыз тук, өстебез бөтен булыр иде. Хикмәт андамыни!.. Яшәү мәгънәсе, халык ышанычын аклау дигән нәрсә бар бит әле. Зур нәрсә ул...»

Мине болдырга кадәр озата чыккач, Иргали абый тагын бер авыз сүз әйтте: «Эх-х, Рәхимҗан! — диде ул,— әле иңәргә дә өлгермәгән Миңсылу кабере белән ничек хушлашып китмәк кирәк...» Якын күрә иде шул ул балдызкаен.

Шулай итеп, Иргали абый халык үтенечен җиргә салмады. Үз ихтыярыннан да зуррак бер көч аны Себердә калырга мәҗбүр итте. Урынына кеше тапкалаганчы, халык баш-күз алгалаганчы, дип берәр елга калып торырга булды. Вакыт үтә торды. Бераз ияләшенде дә. Кем әйт-

мешли, кеше тәмугка да иядәшә ди бит. Ул арада «йомшак алтын» дип йөртелә торган кеш, чәшке, төрле төстәге төлке ише җәнлекләр үрчетү кебек ифрат та җаваплы эш тапшырдылар үзенә. «Дөньялар тыныч түгел, валюта кирәк» — диделәр аңа. «Валюта» — саф алтын, яки доллар дигән сүз икән. Иргали абый бу очракта да берьюлы ике-өч камыт киеп эшкә алынды. Әллә ни күп үтмәде, бөтен төбәкне хәйранга калдырды. Исеме макталып телдән, сурәтләре гәҗит битләреннән төшмәде. Аннан соң икеме-өчме ел үттеме икән, район советы депутаты итеп сайладылар үзен...

Вакыт бик соң иде инде. Рәхимҗан да: калган кадәресен иртәгә дәвам итәрбез дип әңгәмәне өзәргә булды. Төн урталары якынлашкангамы, аны бүтән кыстамадылар. Кич утыручылар дәррәү кузгалып, берберсенә тыныч йокылар теләп, таралыша башладылар.

## Җиденче көн

### I

Ниһаять, соңгы көн дә килеп җитте. Барысының да кәефе бер төрлерәк — тәртәләрне тизрәк кайту ягына бору. Юллары ераграклар билет хәстәрен дә күрергә өлгерделәр инде. Әмма, барысы да белә: әүвәл Мәскәүдән килгән комиссия җитәкчесе Анатолий Степанович Кремнев белән саубуллашып чыгасылары бар.

Анатолий Степанович, сәламәтлеге күзгә күренеп диярлек яхшырса да, врачлар кушуынча, бер-ике көнгә калып торачак. Аның өчен Казаннан махсус санитар вертолеты киләчәге безнең өчен дә сер түгел иде инде.

Иртәнге тугызларда без инде больницада идек. Күрер күзгә җыйнак кына булып күренгән автобустан шактый ук зур төркем халык төшүен күреп, шифаханә хезмәткәрләре янә сагая-аптырый калды. Изге ният белән йөрүебезне белгәч, бик тиз тынычландылар тагын.

Безне кояштай балкып: «Рәхим итегез!» — дип баш врач Хәзбулат Хәнипович каршы алды.

Анатолий Степановичны аерым палатага урнаштырганнар. Бүлмә иркен, якты, һавасы саф. Ак салфетка белән япкан тумбочка өстендә дә, тәрәзә төбендә дә, җыйнак кына банкаларда, әле яңа гына өзелгәнгә охшап, умырзая чәчәкләре утыра иде.

Кремнев, бик әһәмиятле нәрсәләр турында әйтергә җыенып та, хәтере алдалавыннан курку аркасында гына әйтә алмый калырга мәҗбүр булган кеше сыман, чыраен сытты.

— Беләсезме, нәрсә?..— диде ул ахыр чиктә, чамадан тыш зур серен ачкандай итеп.— Миңа операция ясаган хирургны... мин инде кайдадыр, кайчандыр бер тапкыр күргәнмендер кебек. Тик үтерсәгез дә хәтергә төшерә алмыйм. Кайчан? Кайда?.. Менә ничәмә-ничә төннәр инде шуны уйлап ятам. Ләкин башны ваткан бәйләнчек фикердән һич кенә дә котыла алмыйм.

Кремнев, һаман да аңлатырга теләп тә аңлата алмавына гаҗиз булган кеше кебек, кабат чыраен сытты.

— Бу очракта ялгышмыймдыр кебек. Танырдым мин аны. Иң кызыгы шунда: беренче тапкыр күргәндә дә ул марля маскада иде сыман. Хәзергедәй күз алдымда... Аны башкалар белән бутап булмый, ул тамгалы... маңгаендагы мөһереннән, кашын урталай ярган җәрәхәтеннән таныдым. Тик менә кайда, кайчан очрашуыбызны гына хәтеремә төшерә алмыйм. Үзен күрәсе иде...

Сүзгә Дисә Зиннәтовна кушылды.

— Хирург хәзерге минутта гына больницада түгел иде шул...

— Чибәрем, бәлки беләсездер, фронтовикмы ул? Хирург турында соравым...

— Әйе, фронтовик. Башыннан адәм әйтеп адәм ышанмаслык могҗизалар кичергән ул. Әсирлеккә төшеп, концлагерьларда бернична тапкырлар үлем белән күзгә-күз килгән кеше...

Шулчак Анатолий Степанович, күпме вакыт баш ватып та, хәтеренә китерәсе нәрсәне бары тик шунда гына исенә төшерүенең билгесе итеп: «Аһ, бу картлык!» — дигәндәй, уч төбе белән чәпелдәтеп маңгаена бәреп алды.

— Соң, әлбәттә!..— диде ул кинәт кычкырып.— Әйттем ич!.. Ялгышмыйм дидем бит мин сезгә. Әлбәттә шул!..— Тавышы көр, күтәренке иде аның.— Андый кешене онытырга мөмкинме соң?!. Әгәр дә хәтерем ялгышмаса, аның әле концлагерьда «Фәрештә» дигән кушаматы булуы турында да ишеттергәннәр иде.

«Фәрештә» сүзен ишетү, Дисәне сагайтып кына калмады, тәмам тетрәндерде, һәм ул, үз-үзен белешмәгән кеше сыман, авыруга якынайды.

— Сез... Сез, Анатолий Степанович, ялгышмагансыз. Аның чыннан да шундый хикмәтле кушаматы булган.

Бу хәбәр әллә нишләтеп җибәрде авыруны. Ул утырган җиреннән сикереп торырга җыенгандай, талпынып куйды һәм палатадагыларга таба кулларын сузды.

— Әйтәм ич!..— диде ул тәмам канатланып.— Ялгышаммы соң!.. Менә бит, ә!.. Ничәмә-ничә еллар үткәч... язмыш кабат очраштырыр дип кем уйлаган?!. Һай, бу картлык! Искә төшерә алмыйча газаплануымны күр инде, ә!.. Соң бит шул, герой!.. Без бит инде аны күптән җирләгән идек... Карательләр тарафыннан юк ителүе турында бик төпле мәгълүмат та алган идек.

Дисә, соравын алдан ук әзерләп куйганмыни, шактый ук каушаган тавыш белән:

— Сез, әллә... «Батя»мы?..— дип сорап куйды.

Анатолий Степанович: «Сезгә әле вакыйганың шул кадәресе дә билгелемени?» дигән бер кыяфәттә күзләрен кысып, бөтен йөзе белән елмайды да әйтте:

— Юк, кадерлем, мин «Батя» түгел. Мин аның көрәштәше, әгәр дә шулай дип әйтергә мөмкин булса, аның уң кулы идем. «Батя» Берлин өчен барган сугышларда һәлак булды. Беләсезме нәрсә; кадерлем, чакырсагыз иде сез аны минем янга. Күрер идем... Лагерьда да ул үзен чын геройларча тоткан дип сөйләделәр. Хәтта элемтәче дә булган диделәр... Зинһар дип үтенеп сорыйм сездән...

Газиның герой булуы, моңа кадәр исә бөтенләйгә гаепсезгә әзәрлекләнүе турындагы хәбәр, минуты белән бөтен больницаны айкап чыкты. Иң сөенгән, иң каударланган кеше, әлбәттә, Гайния түти булгандыр.

— Һай, аллам! Менәтерәк, вәт!.. Үзен белгән кешеләрне эзләп кайларга гына язмаган иде бит ул! Гаепсезлеген исбат итәргә теләп әнә уннарча ел гомере изага узып та киткән... Менә ичмаса сөенеч!.. Сөенеч дисәң дә сөенеч... Каягыз, төшеп сөендерик әле үзен! Алып төшәргә әзерләп куйган ризыкларым да бар. Әйдәгез!.. Дисә! Дисә, кызым... Тик берүк бу хәбәрне кинәт кенә әйтүдән исәрләнеп китә күрмәсен. Белмәссең дөнья хәлләрен. Ансыз да кырыкка телгәләнгән йөрәк...— Дисәнең аны тыңлап торырлыгы калмаган иде инде. Ул җәһәт кенә килеп, чөйгә эленгән җиңел пальтосын йолкып алды да, ишекне орып-бәреп, чыгып та йөгерде. Мин дә: «Менә, балачак дустым белән очрашырга сәбәп тә булды»,— дип, Дисәгә иярдем.

## 2

Уйлар, уйлар...

Бик еракларга алып китәләр алар, кыска гына вакыт эчендә, гомер

дигән нәрсәне артка чигереп, кеше үзенең бөтен тормышын күз алдыннан уздыра ала.

Гази да үзенең яшьлек елларында адашып йөри. Ул, фронтка китәр алдыннан туган авылына кайтып, әнисе белән саубуллашкан чакларын күзаллап ята. Авылда аны гаять тә зур яңалык көткән: Себер кадәр Себердән — аның Гөлүсәсе яныннан — Рәхимҗан абые кайтып төшкән иде.

...Ниһаять, Рәхимҗанны кунакка алу чираты Газиларга да җитте. Анасы Зәйтүнә, югын бар итеп, зурдан кубып, заманына күрә бик һәйбәт аш-су әзерләде. Чорма бәбкәсеннән каклаган каз да очып төште. Кулы кулга йокмады Зәйтүнәнең ул көнне, аш-су әзерләвенә сөенеп-куанып йөрде. Ишегалды, өй, чолан арасында балалтәкләре генә җилфердәп калды. Үзе ике сүзнең берендә: «Күрше хакы — тәңре хакы, игелекләрен бик күп күрдек, үлгәндә дә онытасыларым юк»,— дип сөйләнүен белде.

Гази үзе барып алды Рәхимҗан абыен. Анысы бик һәйбәт булды. Югыйсә, кешеләр алдында, бигрәк тә Газиның әнисе барында, ычкындырырга ярамаган сүзләре дә булган икән.

— Мин кичә халык алдында барысын да тәфсилләп әйтеп бетерергә теләмәдем,— дип башлады Рәхимҗан абые.— Гөлниса апа тикмәгә генә шулай күтәрелеп бәрелмәде... Гөлүсәгә дә тикмәгә генә кул күтәрмәде. Шулай ук сиңа да эләкте... «Ходайның ачы каһәрләре төшсен, кыз баланың намусын, безнең ышанычыбызны аяк астына салып таптаган өчен, кул-аяклары корышып, муеннары аска килеп, кәкрәепләр катсын иде»,— дип каргады үзенне. Каргау сүзләре бәгырьләреннән кайнап чыккан иде аның. Хикмәт менә нәрсәдә иде. Әнисенең: «Кайчан? Кайда булды ул хәлләр?» — дигән соравына, Гөлүсә, ят кеше бар дип тормады, күзләрен дә йоммыйча: «Чулман буенда, печән өмәсендә»,— дип әйтте дә салды. Авылда яшәгән чакта, сез печән өмәсеннән кайткачыннан ук, кемнәрдер килеп: «Гөлүсә белән Гази көймә белән каядыр китеп, икәүдәникәү генә төн уздырдылар»,— дип җиткергәннәр иде инде...

Ул арада, Рәхимҗан абые киенеп бетеп, мамык шарф белән авызборынын томалады. Алар ике өй арасын йөгерә-чаба бик тиз уздылар. Кунакны ай-кояштай балкып, күгәрчендәй гөрләп, Зәйтүнә каршылады.

— И-и, жаныемдыр ла! Әйдүк, әйдүк, Рәхимҗан, күршекәй! Менәтерәк, күрдеңме инде... Исән-саулар булгач, бәндә баласы туган җиренә кайчан да булса бер әйләнеп кайта икән ул. Һай-й, туганкаем ла! Сезләрне уйлый-уйлый хыялларга сабыша язган идем инде. Бигрәкләр дә кешелекле, бигрәкләр дә олы җанлылар идегез шул...

Гази кунакка чишенергә ярдәм итте. Сүз ияре сүз китеп, туган җирләрдән, туган туфрактан аерылуларның михнәте турында гәп сатып алдылар.

— Читтә каңгыраеп йөрүләрне әйтмә дә инде, Зәйтүнә апакаем, моны башыннан кичергән кешеләр генә белә торганнардыр. Каңгырау туган якның кадерен ныграк сиздерә икән. Туган яклар — дөньяның оҗмахы дип әйттерә икән ул. Юксыну, туган туфракны җирсенү турында әйтеп аңлатыр сүзләр юк, Зәйтүнә апакаем...

— И-и, кем, Рәхимҗан туганкаем! Болар аңламыйлардыр дип уйлый күрмә берүк, бик аңлыйбыз. Борынгылар: сагыш җәрәхәтеннән бәндә баласы савыга алмый икән дия торган булганнар. Нишләмәк кирәк, тәкъдирегезгә шулай язылган булгандыр, күрәмсең. Ә язмыш дигән нәрсә, айһай ла, айкады-чайкады халыкны...

— Башта юллары... Ә бит безгә исәпсез-хисапсыз юллар үтәргә туры килде. Юл газапларын әйтеп тә тормыйм...

— Әй-йе, Рәхимҗан бәгърем, моннан соң да һәлакәт-каза күрергә язмасын диген.

— Шунда бер нәрсәне ачык төшендем: чит-ят җирнең суы муллыгы да, ризыкка тулылыгы да күзгә күренми икән. Нинди генә булмасын, туган илне алыштыра алмый икән. Чит җир — чат үги ана дип белмичә әйт-

мәсләр иде аны, якты йөз күрсәткәндәй итсә дә, күңелен ачып, йөрәк жылысын биреп бетерми икән...

— Шулайдыр, шулайдыр, кем, Рәхимжан бәгърем!..— Зәйтүнә үзе сөйләнә, үзе чәч үргеченә таккан талир тәңкәләрен чыңлатып һаман жил-жил килеп йөренә, һаман эш белән мәшгуль. Менә ул сәке йөзлеге янына ук күчереп куелган өстәлгә кызгылт төстәге шакмаклы бизәкләр төшереп сугылган киндер ашъяулык жәйде. Эреле-ваклы савыт-саба, кашык-чүмеч ише нәрсәләр китереп куйды. Бары тик шуннан соң гына кунакны табын янына кыстый башлады.

Рәхимжан исә, берни дә булмагандай, Себер турындагы әңгәмәсен дәвам итте.

— Анда бит, Зәйтүнә апакаем, бөтен нәрсә үзгә. Шәфәкъның ансыз да күңелгә шом салу хасияте бар дигәндәй, ул якларда кояш баеп, кояш чыгуларына кадәр икенче. Таңнар атканда яман афәт, иләмсез янгын якынлашкан сыман, бөтен күк йөзен тоташ кызыллык баса. Кичке шәфәкъләрдә, тәрәзә пыялалары кан ягып куйганга охшап калалар, бер иләшкәнче күңелне гелән шом биләп ала торган иде.

— Менә, хәерлегә булсын, туган якларыңа кайтып төштең. Ә туыпүскән якның һава-сулары да житмеш төрле чиргә дәва дия торган иде Хажи абыең. Шул ук Мәгыйшә карчык әйтмешли, тән-буыннарыңа әбелхәят сулары бөркелгәндәй булыр, ходай кушса, көч-сихәт жыярсың,— диде Зәйтүнә.

— Белмим инде. Булган яралар жөйсез, эзсез генә төзәлмәсләр... Үткәннәр тиз генә онытылмас. Шуның өстенә юксыну-сагыш газаплары күкрәкне кыса...

Ул арада Зәйтүнә бер чите калайланган зур агач табак белән аш алып чыкты. Үзе һаман кунагына юату сүзләре тезде.

— Зарар юк, Рәхимжан жанашым, бар да һәйбәт булыр. Зәңгәр томан артында өметең булсын дия торган иде мәрхүм Хажи абыең. Үсеп яткан улың бар. Рәтләнми калмас тормышың. Тик менә Миңсылуның гына чит-ят жирләрдә үлеп калулары... Авыр туфраклары жиңел була күрсен, мәрхүмкәйнең. Иллә-мәгәр уңган да иде инде! Кулларыннан төймә кояр иде. Ул аш-су әзерләүләре турында әйткән дә юк. Әлеге яман хәбәрләрне ишеткәч, башкайларым түнеп, зиһенемә сыйдыра алмыйча газапландым. Яле, бары белән ашаплар гына утырыгыз әле.

Түгәрәк табын янында, бер жайга гына гәп сатып, хәтсез утырдылар. Сөйләр сүзләр бихисап. Искәрмәстән генә Иргалинең дә исеме телгә керде. Дөресрәге, Рәхимжан кузгатты. Иргали абыеның кырык тирен сыгып чыгарырга теләгәндәй эшкә алынуы турында сөйләп китте.

— Әйе, эштән-хезмәттән өзлегә торганнардан түгел иде шул ул. Тикмәгә генә: затлары белән эшмәкәрләр дип йөртмиләр иде үзләрен. Шуңа күрә дә дөньяның майлы йөрәгенә басып яшәде ул.— Бу сүзләрне хужабикә әйтте. Бер үк вакытта табындашларын кыстарга да өлгерә иде ул.— Яле, житешегез, кадерле кунакларым! Шулай дими, кем диим?! Гази да кунак кына хәзер өйдә.

Гази да, үз чиратында, әнисенә күтәрелеп карады. Карады да, йөрәге сызып, әрнеп куйды. Бетәшкән, картайган. Шактый йөз куярга өлгергән. Бу каһәр суккан сугыш аның юка иңнәренә дә шактый үк мәшәкатьләр салды шул. Гәүдәгә дә ничектер жыйнакланыбрак, ябыгып-тартылып калган сыман. Күзләрендәге чак кына сирпелеп торган моңсулык та арткан шикелле тоелды. Шул күз карашыннан һичбер ялгышусыз ана күңелендә нинди хикмәтләр барын, нинди уйлар белән яшәвен, берни ди ялгышусыз әйтеп бирергә мөмкин иде. Менә хәзер ул ерак илләр гизеп кайткан кунагының йөзенә күз төшереп, вакыты белән хәтта чак кына текәлебрәк тә карап алгалый. «И-и, жанякаем ла! Тәмам эштән чыккансың ич, бичара! Үзеңне туган туфрагың гына тартып кайтарган лабаса!..»

Әнисенең сөйләшүен тыңлаганда гына түгел, онытылганда бер язган хатларын укыганда да Гази күз алдына әнисе килә дә баса, ә колак тө-

бендә ягымлы, нәфис тавышы яңгыраган сыман була. Сүзләренә киракса-кирәкмәсә дә «-лар», «-ләр» кушып, күплектә сөйләргә ярата ул. Хатларында да: «...ачларга тилмерепләр йөрмисеңме икән дип, кайгырыплар ятам», «Өзелепләр сагындым үзеңне», «Кайтасы юлларыңа караплар торам»,— дип язар иде. Ә инде кайтып күзенә күренгәч: «Калтыраныплар торасың, улым, әллә керепләр ятып торасыңмы?» — дип борчылыпмы борчылыр иде.

Ул кичне Гази, кем әйтмешли, «күңелләре» соңгы тапкыр күрүен сизенгәндәй, газиз әнисеннән күзләрен ала алмыйча озаклап карап утырды. Заманында аның турында: «Иорәкле, гайрәтле хатын»,— дия торганнар иде. Ә хәзер әнә бетәшкән, картайган, гәүдәгә дә җыйнаклана төшкән...

Бик күп еллар үтәр. Газига газиз әнкәсе нәкъ менә шушы табын янында утырганча күз алдына килә торган булып калыр. Башына ак яулык чөйгән, биленә күкрәкчәле ак алъяпкыч япкан... Ә йөзеннән өзлексез рәвештә җылы яктылык бөркелеп тора. Юк, яктылык кына түгел, ә аязып китүгә тартым елмаю чалымнары иде алар. Тагын бер нәрсәгә игътибар итте Гази: әнисенең йөзендәге елмаюы озак саклана. Чын күңелдән елмайганга шулайдыр дип уйлый иде ул.

Менә хәзер дә хуҗабикә бөтен халәте белән кунак ягына тартылып, бик әһәмиятле сорау бирергә җыенгандай итенеп утыра, үзе өчен бик-бик кадерле сүз ишетергә теләве көн кебек ачык иде. «Күршекәе» дә моны, әлбәттә, сизенә иде. Һәм ул улы Азатҗан турында сүз башлады. Хуҗабикәне хафаланмаска чакыргандай: «Ул ташбаш өчен борчылмаска да мөмкин»,— рәвешендәрәк сөйләде. Иргали абыйны «дәүәти» дип, Гөлниса апаны «дәүәни» дип, ә инде Гөлүсәне, аеруча якын итеп, үз күреп: «тәти апаем» — дип йөртә икән. Хәер, Миңсылу исән чакта да малай олы яктан, ягъни, Гөлниса апаларыннан чыкмаган, бөтенләй үз кеше булып беткән.

Ул арада тутырган тавык та килеп кунаклады табынга. Кабат җанланып алдылар. Кунакка да «байлар» төсе керде— йөзенә чак кына алсулык кунгандай булды.

Самавыр да озак көттермәде. Гази һаман әнисен күзәтте. Күңеле белән сизенде ул, әни кеше кунакның моңарчы сөйләгән сүзләре белән бик үк канәгать түгел, тагын бик хаҗәт нәрсә турында сорарга атлыгып торганлыгы йөзенә чыккан. Гази аның нәрсә турында сорарга җыенуын да төшенә: чак кына, улының «акылсызлыгы, беркатлылыгы» аркасында гына килене була алмыйча калган Гөлүсәнең язмышы кызыксындыра иде ана кешене. Әмма бу юлы да үзен кызыксындырган сорауга җавап ала алмыйчарак калды, шулчак кемнендер өйалды ишеген ачып кергәне һәм, итеген итеккә бәреп, кардан арынуы ишетелде.

Ул да булмады, өй ишеге ачылып китте. Бәреп кергән ап-ак болыт дулкыны эченнән югары оч Гыймран картның:

— Исән-имин генә яшәп ятышлармы? — дигән карлыккан тавышы ишетелде.

— Әйдүк, әйдүк, Гыймран абзый, мактаплар гына йөрисең икән әле. Әнә, самавыр да сүрелмәгән, җыруын сузып утыра бирә.

— Җук-җук, Зәйтүнә килен, берүк хафалана күрмә. Әнә, кунакларыңны кара. Мин бушандылармы икән инде диебрәк кергән идем. Менәтерәк, шул! Иртәрәк кергәнмен икән... Урам тулы халык анда. Әрсезләндереп мине керткәннәр ие.

— Бик һәйбәт булган, бик вакытында кердең, Гыймран абзыкаем. Әйдүк, түргә уз!..

Ул арада инде Рәхимҗан да: «Сый-хөрмәтләреӊ өчен, Зәйтүнә апакаем, рәхмәтләр яусын. Иллә-мәгәр һәйбәт тә булды соң!» — дип түгәрәкләнә башлаган иде.

Шуны гына көтеп торганнар диярсең, исәнлек-саулык сорашып, үзләре белән мул итеп салкын ияртеп, халык керә башлады. Минут та үт-

мәгәндер, өй эче кешеләрнең үзара медер-медер сөйләшүләре белән тулды.

Житез-өлгер хуҗабикә дә: «Бер кинәнеп кич утырыгыз әле...» — дип, кунаклар хөрмәтенә берьюлы ике лампа кабызды: сукыры мич кучкарына куелды, куыклысы — табын турында матчага эленде.

Вакытны әрәм итүдән курыккандай, Рәхимҗанны сораулар белән күмеп, киречкмәстән сүзгә керешергә мәҗбүр иттеләр. Кайсыдыр: «Үзебезнең борынгы ыругларыбыз — Себер татарлары белән очрашырга туры киләгәләдеме соң?» — дип сорап куйды. Рәхимҗан исә нәкъ шул сорауны гына көтеп торган кеше сыман элеп алып та китте.

— Себер татарлары, гомумән, ул як халкы ифрат кунакчыл. Танышмы син, юкмы, барып керә-нитә калсаң, хөрмәтләп түргә уздыралар, табынга утырталар, хәленчә сыйлыйлар, хәерле юллар теләп озатып калалар. Ә инде Себер татарларына килсәк, күрер күзгә ярыйсы ук чибәрләр. Чак кына кинчә йөзлеләр. Сабыр-басынкы холыклы, тыйнак табигатьлеләр. Телләре генә әллә ничегрәк, игътибар белән тыңласаң сәер-мәзәгрәк ишетелә. Аңлашыла үзе. Көндезне «көнтес», көтүлекне «паскут» дип, егет белән кыз диясен «екет пелән кыс» диләр. Ә эрбет чикләвеген «косык» дип кенә җибәрәләр... Күп төрле чирләрне, шул исәптән зәңгеләне дә, ылыс төнәтмәсе белән дәвалыйлар. Һәр чирнең үзенә үзгә ылыс агачы.

Беренче тапкыр танышуыбыз көтмәгәнчә-уйламаганчарак килеп чыкты. Көннәрнең берендә авылыбызга өермә кебек биш-алты җайдак бәреп керде. Башта: «Тагын берәр афәт чыктымы икән әллә?» — дип аптырабрак калдык. Житмәсә тагы һәркайсы коралланган. Жилкәләрендәге мылтыкларыннан тыш, билләрендә пычаклар. Кемнәр булыр болар? Эш белән йөриләр дисәң, киемнәре бик затлы. Иярләре ефәк каймадан да чуктан, йөгәннәре көмеш тәңкә белән чуарланган. Йөк асылган атлар да ияркәннәр. Атларның берсе сыртына Себер боланы — марал аркылы салынган.

Шулчак араларыннан берсе алгарак чыкты да, атын биетеп, тояклары белән җир уйдырып, нәкъ безнеңчә: «Сау-сәламәт кенә яшисезме, мөселман кардәшләр!..» — дип аваз салды.

Иргали абый алга чыкты. Сәламнәрен кабул итте. Тегеләр дә, атларыннан сикерешеп төшеп, көлеп-елмаеп, үзебезчә куш куллап күрешергә керештеләр. «Исән-сау гына яшәп ятасызмы, ыругдашларыбыз!.. Милләттәшләребез!..»

Жир астыннан калыккандай, Михай-Баянай дәдәй килеп чыккач кына, бар да ачыкланды. Авызын ерып уртага кереп тә алды бу. «Менә, кадерле күршеләр, ачуланмасагыз, кунаклар алып килдем үзегезгә.— Себер татарлары ягына ым кагып өстәп тә куйды.— Болар барысы да минем кадерле дусларым. Сахрага күңел ачарга чыкканнар. Күршебездә генә Казан татарлары яши дигән сүз авызымнан чыгуы булды, кунакларымны җил тузгыттымыни, син күр дә мин күр, сезнең янга чыктылар да чаптылар. Шулай итеп килеп чыгыш менә...»

Китте танышу, китте дуслашу хөрмәтенә кул кысышулар. Ул арада, елгага төшә торган сукмак буенда, аланлыкта берьюлы ике-өч учак кабыздылар, казаннар астылар. Кай арада тунап өлгергәннәрдер, икенче тапкыр алан ягына күз салганда, ат сыртына аркылы салынган болан бөтен килеш күмер тавы өстендә әйләнә иде инде.

Бер төркеме башта безнең ишегалдына, аннан өйгә үттеләр. Өй эче бик кәттә, бик затлы-зиннәтле кунаклар белән тулды. Әзмәвердәй буйсынлысы Ягъсүм атлы иде. Танышка торгач, бар да ачыкланды. Кунакларның иң олылары — аталы-уллы Юлтыевлар, Ягъсүмнең туганнан туганнары икән. Ата кешенең исеме — Илбай, улы — Лачын атлы. Менә шунда күрде дә инде Лачын нуры түгелеп торган сылуыбыз Гөлүсәне. Күрде дә таң калды, телдән язды.

Ул вакытта инде Гөлүсә Инәсәй каласында техникумда ветврачлыкка укый иде. Инәсәй — Себернең иң борынгы калаларыннан санала икән. Узган гасырларда, мәсәлән, Рәчәйнең барлык алтыны шул Инәсәй губернасында табыла торган булган. Өйдәгеләр дә: тормышыбызның төп кәсебе, хуҗалыгыбызның төп эшенә бәйле дип Гөлүсәнең читтә укуына әллә ни сүз әйтмәделәр. Баштарак, барып урнашкан елларда, бер мөгаллимә апасына балалар укытырга ярдәм итүе турында сөйләгән идем бугай инде. Башлангыч сыйныфларда ана теле дәресләре бирде. Бер тапкыр ул укыткан балаларның күмәкләшеп шигырь ятлаулары әле дә булса колак төбемдә яңгырап тора:

Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем...

Кунакларыбыз бик тә үзенчәлекле, хәтта сәеррәк булып чыктылар. Өстәл янына утырудан баш тарттылар. Үзебезнең табын әзер дип, барчабызны җыеп, су буе аланлыгына чакырдылар. Андагы ындыр табагы хәтле итеп әзерләнгән табынны күрдек тә шаклар каттык. Алар күңел ачарга дип зурдан кубып, бик нык әзерлек белән чыкканнар икән. Нинди генә ризыклар юк иде ул зур келәм җәйгән табында. Шундук тау кадәрле итеп, сэрярин турап куелган. Аю бавырыннан казылык сыман итеп хәзерләнгән ашамлык ул. Аның тәмлелеге искә төшкәндә генә дә авыздан сулар килә...

Бераздан табынга туралган болан ите китерелде. Төрле үлән төнәтмәләре, серкә янә башка төрле тәмләткечләр сибеп күмер өстендә кыздырылган андый да татлы, андый да сусыл итне бүтән ашарга туры килмәде. Авызларда гына тотып торырлык тәмле иде шул!

Табындагыларга күз төшерәм. Түрдә Иргали абый белән Гөлниса апа утыра. Иргали абыйның бер ягында Имбай белән Ягъсүм урнашкан. Икенче бер якта Михай дәдәй. Ул безне таныштыруына чиксез шат. Бу аның йөзенә үк чыккан. Аңардан бигрәк без шат. Баксаң, без ялгыз түгелбез икән ләбаса! Янәшәбездә генә безгә җаннарын ярып бирерҕә әзер торучылар бар икән ләбаса. Моннан да зуррак бәхетнең булуы мөмкинме соң!

Михай-Баянайның уң ягында — Лачын. Сизелеп тора, карт сунарчы белән азамат йөрәкле аучы егет — чын дуслар. Хикмәт Лачынның оста мәргән булуында гына да түгелдер. Чыннан да, кунак егет карап-сокланып туймаслык иде. Калку күкрәк, киң җилкә, зифа буй-сын. Төскәбиткә килгәндә дә, карап кына тормалы. Балаларныкы кебек самими ачык йөз. Үзе яшь. Гөлүсәгә караганда да яшьрәк булмадымы икән әле. Киң маңгаенда акыл нуры чагыла, күзләрендә җанлы фикер очкыннары, тавышында ягымлылык яңгырый, һәрбер сүзендә ипләлек, һәр хәрәкәтендә итагатьлек ярылып ята. Үзе ифрат та тыйнак, басынкы, акыллы.

Искәрмәгәндә-көтмәгәндә җыйналган мәҗлес кызганнан-кыза барды. Бераздан ул бәйрәм төсен алды. Бу хәйран-тамашага бөтен авыл халкы чыкты. Алар да мәҗлестәш булып киттеләр. Тальян гармунын кыстырып, Сираҗи да табын янына килеп кунаклады. Себер татарлары телгә генә чичәннәр түгел, җыр-моңга да бик маһир, бик хирес халык икән. Ә җырлары, мин сиңа әйтим, жанны кинәндерә, ләззәт бирә, яшәешкә ямь өсти торганнар. Менә бер заман Ягъсүм дигәннәре сузып җибәрде:

Җырла дисәң мән җырлаем,
Җырны сатып алмыйм акчага;
Сезнең ләй кебек дус-ишләрне,
Сезнең ләй кебек дус-ишләрне,
Чәчеп үстереп булмый да бакчада.

Аларның «Хан кызы», «Кара да гына жылан» кебек җырларын

күмәкләп башкарулары безне тәмам әсир итте, кушылып җырлый башлавыбызны сизмичә дә калганбыз.

Ул арада авыл яшьләре чәерле чыршы, нарат төпләре янган ут тирәсендә әйлән-бәйлән уеннары оештырып җибәрделәр. Билгеле инде, кунак егет Лачынны көчләп диярлек үз яннарына алдылар. Гөлүсә дә түгәрәктә. Шунда икесен янәшә күрдек тә авызларыбызны ачып каттык та калдык. Үтә дә пар килгәннәр иде алар, бер төптә өлгергәннәр диярсең инде менә. Бигрәк тә Лачын шәп иде. Коеп куйган буй-сынына кием-салымы да килешеп тора. Башында — томак. Кыйммәтле җәнлек тиресе белән бизәп тегелгән баш киеме. Билендәге көмеш аеллы кәмәренә кыйммәтле ташлар белән бизәлгән кынлы ау пычагы тагылган. Аягында — пошн тиресеннән читек сыман итеп чигеп-бизәп тегелгән җиңел итек. Кыскасы шул, Лачын белән Гөлүсәне янәшә күргәннән соң: «хәерлегә була күрсен»,— дип һәркем үзенчә юрады.

Елга аръягындагы чыршы-нaратларның киртләч башларын беренче кояш нурлары яктыртканда, кунаклар китәргә җыена башлады. Тик Лачын гына бик ашкынмады. Хәер, егетнең ул минутта ниләр кичергәнен этисе Имбай да, туганы Ягъсум дә бик яхшы сизенәләр иде булса кирәк. Лачынның этисе, тел төбенә тирән мәгънә салырга тырышып: «Себердә танышып дуслашалар да, вакыт җиткәч, туганлашалар. Без дә шул тәләктә калыйк. Хәзер инде таныштык, белештек, эзебезне суытып бетермәбез»,— дигән булды. Шундук Инәсәй елгасы буенда, район үзәгендә яшәгән туганы Ягъсумгә: «Син янәшәдә генә яшисең, яңа дуслар белән гелән элемтәдә бул»,— дип әмер сыман нәрсә дә бирде. Тегесе: «Бар да син дигәнчә булыр, туганым»,— дип баш иде. Шунда Лачынның этисе Имбай, танышу һәм дуслашу бүләге булсын дип, Иргали абыйга, карап сокланып туймаслык өч баш ат биреп калдырды.

Кунакларны озаткач атна үттеме икән, дөньяны яулап алырдай булып, өермәдәй тузгып, ат менгән Лачын килеп чыкты. Әмма безне күрү белән егет каушады, югалып калды, бар әйткән сүзе «сагындым!..» булды. Башына күтәрә алмаслык хәсрәт төшкән кеше сыман, кая барып бәрелергә урын тапмады. Ул гашыйк иде. Ут белән мәхәббәтне, бар, яшереп кара!

Гәп саткандай итәбез. Ничек кайтып җитүләре белән кызыксындык. Этисе Инәсәйгә үк киткән, ә ул калган. Хәзергә район үзәгендә, туганы Ягъсум абыйларында торып тора икән. Хәйлә-мазарны белмәгән сабый балалар сыман беркатлы Лачын, телдән язган кебек бераз утырды да китәргә җыенды. Шулай да, тартынып-оялып булса да, бердәнбер үтенечен белдерде: «Рөхсәт итсәгез, тагын килер идем»,— диде. Шулай диде дә, атына чөңгереп, төнгә каршы дөм караңгы тайга эченә кереп күздән дә югалды. Менә бит гыйшык дәрте нишләтә кешене!

Лачынны беренче күрүдә үк барыбыз да ошаткан идек. Гөлниса апа да: керсез, саф күңелле, бик тәүфыйклы бала дип, аның өчен җан атып торды. Егет үтә дә ягымлы, сүзе белән дә кешенең күңеленә ятышлы иде.

Тагын өч-дүрт тапкырлар килде бу. Аннары атларын мичәүләп җиргеп, туганы Ягъсум килеп төште. Нинди ният белән килгәнлеген яшерепнитеп маташмады, ике авыз сүз белән аңлатты да бирде. Энесе күзгә күренеп боега, эчтән сыза. Сагыш-хәсрәттән саргая башлаган. Аның сызлану-ямансулавын күреп, ата-анасы да, барча туган-тумачалары да пошаманга төшкәннәр. Исәр кеше сыман, дус-ишләре белән аралашудан тәмам туктаган, өйдән бизгән, башы тайгадан чыкмый ди. Ул-бу чыга күрмәсен дип, ут йоталар икән. Сәбәбе бер: энесе — гашыйк. Димәк, ходай аларны бер-берсе өчен яраткан. Димәк, балаларны кавыштырып туганлашудан бүтән юл калмаган. Әмма егетнең бу турыда авыз ачып сүз катар әмәле юк — артык юаш, оялчан, кыз балалар сыман тыйнак. «Шуңа күрә мине менә гозерләп сезнең якларга юлладылар. Туганым: «Зинһар барып белешеп, кыз ягындагыларның кылларын тарткалап кай-

та күр».— дип хәбәр салды. Олуг өметләр баглап, ышанып килдем...»

Өйдәгеләр ячы сүзләреннән тәэсирләнеп тынып калдылар. Аларның җавап бирергә атлыгып тормауларын кунак Ягъсүм үзенчә юрады булса кирәк. Имбайларның бөтен нәсел-нәсәбе турында да сүз куертып алуны кирәк тапты. Туганнарының бик ипле, бик төпле кешеләр булуын мактап кына калмады, җиде буыннарына житте, гомер-гомергә муллыкта яшәгән мал-мөлкәтле, затлы нәселдән булуларын җеген җеккә китереп тезде дә тезде. Борын заманнардан бирле бөтен Тубыл, Түмән, Тум төбәкләрендә дөнья һәм шәригать хөкемнәрен хәл итүдә катнашканнар, сәүдә-кәрван йөрткәннәр икән алар.

Көнбатыш Себер Рус дәүләтенә кушылганнан соң да, аларның нәсел-ыругы дәүләт тәрәге булудан туктамаган. Шәҗәрә башы Колмәмәт, мәсәлән, озак еллар буе Тубыл татарлары солтаны булып торган. Патша галиҗәнапләренә тугрылыклы хезмәт иткәне өчен берничә тапкыр затлы киемнәр, исеме язылган кораллар, җир-су һәм урман белән бүләкләнгән. Ә инде «Әби-патша» указы белән алар нәселенә дворян дәрәҗәсе бирелгән. Юка ефәккә алтын белән язылган Указ әле дә булса сандык төбендә саклана икән. «Атасы болан атмаганның баласы калан атмас,— диде.— Күргәнегезчә, балабыз бик итагатьле, әдәпле, заманына күрә укымышы да житәрлек. Ата-анасы өчен бердәнбер бала. Әгәр дә безнең бу тәкъдимне муафыйк дип күрәсез икән, мин кайткач ук кан-кардәшләрем белән элемтәгә керер идем...»

Әмма Иргали абый белән Гөлниса апаның «ризык эшен белеп булмый» диюдән узмавын күргән Ягъсүм, төзәтенгән сыман итеп әйтте: «Әгәренки инде чак кына сабыр итик, уйлашыйк-киңәшик дисез икән, рәхим итегез, җавапны хәзер үк бирмәсәгез дә ярый». Шулай диде дә, безгә озын гомерләр теләп, иелә-бөгелә саубуллашып, китеп тә барды.

«Бәлки туган якларыбызга кайтырбыз» дигән уй-хыяллар белән яшәгән Гөлүсә тормышка чыгып Себердә калуны ишетергә дә теләмәде. Алай гына да түгел: «Мине җир читендә ташлап калдырмакчы буласызмы?» — дип рәнҗеп, үкси-үкси җыларга ук кереште.

Ә Лачын һаман килде. Ахырчиктә ул да, нинди хыяллар белән яшәвен, ялтыравыклы сүзләр белән бизәмичә, кызга ачты. «Тиздән без китәбез...» дигән җавапны алгач, егетебез өнсез калды. Аннары Гөлүсәнең кире кагуы белән һич кенә дә килешә алмавы, андый хәл булганитә калса, дөньяда яшәмәячәге турында әйтте.

Шундый шомлы сүзләр белән саубуллашкан Лачыныбыз бер заман суга баткандай юк булды. Егетебез үзенең язмышына буйсынды ахрысы дигән уй да туа башлаган иде инде бездә. Әмма юллар төшкәнне генә көткән икән, бахыр.

Көннәрнең берендә тайга эченнән бөркәүле чаналарга парлап җигелгән атлылар килеп чыкты. Кыңгырау-шөлдер авазларына караганда, килде-китте генә мөсафирлар йөрмәвен чамалавы кыен түгел иде. Ни күрик, безнең капкага таба борылдылар болар. Йөгерешеп каршы алырга чыктык. Чыннан да, ялгышмаган икәнбез, кунакларның бик кәттәләре килгән иде.

Иң әлек Лачынның атасы Имбайны танып алдык. «Тагын без әле...» — дип, Иргали абый белән кочаклашып күреште бу. Ягъсүме дә шунда. Авызлар ерык, күзләр ут яна. Ни әйтсәң дә, күптәнге танышлар бит.

Әмма кунакның иң олысын — чанадан төшереп кенә маташалар иде. Ике кеше ике яктан зур саклык белән генә житәкләп төшерделәр тегене. Шундук таныштырдылар да. Бу — Лачынның әнкәсе Җомабикә иде. Базык гәүдәле. Өстендә аю тиресеннән тегелгән тун. Башында дингез кошы гагара мамыгы кушып бәйләнгән йонлач шәл. Аякларында болан тиресе белән тышланган каюлы унтылар. Килеш-килбәте горур, үз дәрәҗәсен белгәнлеген әйтеп бетерә торган да түгел. Барысы да биеп кенә торалар моның каршында. Һәрнәрсәнең ул дигәнчә генә булырга тиешлегенә

күнеккән, күрәмсең. Бөтенесен дә үз кулында йомарлап тотканлыгы, чикләнмәгән хокукка ия хуҗабикә булуы әллә кайдан сизелеп тора.

Тагын бер нәрсәне күңел бик ачык тойды: кире кагылган саен газиз баласының тәүге мәхәббәте сүрелү генә түгел, киресенчә, Казан ягы кызына ныграк тартыла баруын сизенгән ана, ниһаять, әлеге хикмәтләрне күрергә, әтрафлы бәяне бирергә үзе килгән һәм барысын үзе теләгәнчә хәл итәргә җыенганлыгы кыяфәтенә чыккан. Безнең сәламебезне коры гына кабул итте. Кыяфәт житди. Йөзе чытыккамы, чем кара кашлары бергә кушылган. Менә тегене житәкләп диярлек өйгә алып керделәр. Шунда Җомабикә бердәнбер газиз улын «кешелектән чыгарган», туган йорт-нигезеннән биздергән Татарстан кызы Гөлүсәне күрде. Күрүгә болыттай караңгы йөзе ачылып киткән сыман булды, кашлары да чак кына язылды. Соклануын яшереп тормады. «Бәрәкалла!..» — дип Гөлүсә янына килде һәм кочакларга теләгән сыман итеп, ике кулы белән булачак килененең иңенә кагылып куйды. Бары тик шуннан соң гына: «Саумы, кызым!..» — дип кәләшне хуп күргәнлеген белдерде.

Шул чак Җомабикә, як-ягына борылып карамыйча гына, бармак шартлаткан сыман хәрәкәт ясады. Аны сүзсез дә аңларга гадәтләнгән кешеләре күз ачып йомганчы ике зур гына төргәк алып кереп, идән уртасына куйдылар. Шунда Җомабикә Гөлүсә белән Гөлниса апаның җилкәләренә өф-ф! дип өрсәң һавага күтәрелергә торган җиңел, йомшак, күз яуларын алырдай затлы кеш туннары салды.

Бу хәлне күзәтеп торучылар, бер кеше сыман, җиңел сулыш алдылар. Әмма иркен суларга иртәрәк иде әле. Шулчак бөтенләй көтелмәгән, барыбызны да тораташтай катып калырга мәҗбүр иткән хәл булды. Гөлүсә: «Рәхмәт, миңа сездән берни дә кирәкми»,— дип, җилкәсендәге тунны салып Җомабикәгә тоттырды да ишек катында эленеп торган үз киемнәрен йолкып алып, чыгып ук йөгерде. Гөлниса апаның: «Җүләрләнмә, Гөлүсә! Нишләвең бу?..» — дигән сүзләре дә ярдәм итмәде.

Уңайсызланудан кая керергә тишек тапмаган ата белән ана:

— Күңелегезгә авырга алмасагыз иде. Чак кына сабыр итешик. Белмәссең яшьләрнекен... Бар да һәйбәт булыр. Күнәр! Ата белән ана сүзенә дә күнмәсә! — диештеләр.

Ләкин хикмәтләр моның белән генә чикләнмәде. Кәләшне күреп кенә түгел, ишетеп тә сайлыйлар ди бит. Соң шул! Кайсыдыр җүнсезе Шаһбазлар белән булган вакыйганы тәки тишкән бит, башы беткере. Җитмәсә тагын коточкыч итеп ишеттергәннәр. Имештер, ул кыз аркасында кемдер үтерелгән, кемнәрнеңдер башы өтермәндә чери... Ни эшләсә дә, кодрәтеннән килә, көче җитә, һәрнәрсә дә бары тик ул дигәнчә генә булырга тиеш дип уйлаган илтотмыш Җомабикәгә шул җитә калды, ире Имбайның кан туганы Ягъсүмнең сүзләрен колагына да элмичә, атларны җиктереп кайтыр юлга чыгарга катгый әмер бирде. Шулай итеп шул заманында бөтен Себерне тоткан кунакларыбыз ары талпынып, бире түнеп дигәндәй, ахыр чиктә бернинди дә игә килә алмыйча төксәешеп, кунарга да калмыйча, төнгә карап китеп бардылар. Хак булса, Җомабикә: һәркем кәләшне сөрелгәннәр, каторжаннар арасыннан эзләр иде аны дип әйткән имештер. Тәгаен әйткәндерме, һәрхәлдә шулай дип ишеттерделәр. Кеше авызын томалап куеп була димени!

Бу вакыйгалар узган елның кышында булган иде. Ә аннан соң дөньяның асты өскә килде — җәен сугыш башланды. Ул вакытта инде тайгадагы авылыбызда алтмыш-җитмеш хуҗалык бар иде. Халыкның берише хатлар язышып, ачлык-хәерчелектән качып, тормышның муллыгына кызыгып килде. Чыннан да, муллыкта яшәдек. Сугыш башлануның икенче көнендә, авылдан ирләр китә башладылар. Һәркайсы Иргали абый янына килде. Һәркайсының сүзе бар: «Иргали абый, гаилә синең карамакка кала, зинһар ташлап бетермә, таянычлары, ярдәмчеләре була күр!..»

Лачын да беразга югалып торды. Афәт килгән җәйнең көзендә көтмәгәндә-искәрмәгәндә район үзәгендә очраштык моның белән. Күрдем дә исләрем-акылларым китте, егетебезнең күләгәсе генә калган. Каршымда дөньядан ваз кичкән кеше тора диярсең инде менә. Йөзендә — тирән хәсрәт. Ирексездән әнисе Җомабикәнең: «Казан кызы гына харап итте балакаемны. Ул гына сихерләде, ул гына бозды»,— дип ишеттергән нахак сүзләре хәтеремә килде. Кабат күздән кичерәм тегене. Кайда ул элеккеге чәчрәп-яшьнәп торган егет! Күзләрендә эңгер-меңгер. Андый халәт, гадәттә, өмете өзелгән, яшәү ямен югалткан кешеләрдә була. Әйе дип уйлап куйдым мин, олы ярату хәсрәтсез булмый торгандыр шул. Аннары тагын Лачын яшендәгеләр кирәгеннән артык хискә бирелүчән булалар...

Егет, гадәттәгечә, сокланып карап туймаслык атка атланган. Безгә юл тотышы икән бахырның. Бәхетенә, Гөлүсәнең укуларын тәмамлап кайткан чагы иде. Бер-ике көнгә генә соңласа да, Гөлүсә практика үтәргә күрше авылга китәсе иде. Лачынның атын тәртә башына бәйләдек тә, үзе минем янга арбага күчеп утырды. Серләребез уртак иде безнең. Нинди хисләр, нинди газаплар кичерүен миннән яшерми торган иде. Еш кына: миңа яшәү өчен сирәк-мирәк кенә булса да Гөлүсәне күрү, сезне күрү кирәк дия торган иде бахыр.

Бу юлы да сүзе булган: «Саубуллашырга барам...» — диде ул. Шундый итеп әйтте, йөрәгем жу итеп китте. «Ник алай?..» — дигән булдым сер бирмәскә тырышып. «Сугышка китәм»,— диде бу. «Кайчан?» «Обоз иртәгә кузгала». «Нәрсә, повестка бармы, әллә үзең теләпме?» «Үзем теләп...» — булды җавабы.

Кайта торгач «Аучылар түбәсе», «Аюлар төбәге» дип атала торган урынга да җиттек. Шушы тирәдә инде аюлар берьюлы өч аучыны өзгәләгән булган. Юл кырыенда һәйкәл сыман нәрсә дә куелган. Бу тирәләрне мин, гадәттә, җил уйнатып кына уза торган идем. Янымда Лачын утыргач, кая ул шүрләү, уйлап та бирде юк.

Соң шул, кайтып барабыз Лачын белән. Көзге юл шәп, тимерхут арба келтери генә. Инде «Аюлар төбәге»н дә узып китеп бара идек, шулчак атларга әллә нәрсә булды, бер-берсен кысрыклап, яман өркеп, кушаяклап юл читенә сикерделәр. «Аю!..» диде Лачын, тау түбәсенең куе кура белән капланган өлешенә ым кагып. Шулай диде дә, арбадан сикереп тә төште. «Син кая?..» — мин әйтәм. Күзен дә йоммады егетең: «Аюны алам... Гөлүсәгә соңгы бүләгем булыр».— ди. Әйтүе булды, яшь чыршыларга, дәү-дәү ташларга посып, юлбарыс тизлеге белән өскә таба менеп тә китте. Вакыты белән күздән дә югалып торгалый бу. Мин исә өннәре алынып тәмам ярсыган атларны башларыннан боргычлап тоттым да: ни белән бетәр бу хикмәтле тамаша дип,күзәтә бирәм. Мәхәббәтеннән исәрләнеп, Гөлүсә дип саташып, хараплар гына булмаса ярар иде дип, җаннарымны учымда кысып торам.

Күрәм, куе куралык каплаган өстәге мәйданчыкка күтәрелде бу. Әлеге ачыклыкта ара-тирә генә, юан-юан йөзьяшәр эрбетләр дә бар. Лачын, ауга чыккан җанвар тизлеге белән, шундый агачларның берсе янына барып басты. «Инде нишләр?» дип тын да алмый көтәм. Шулчак Лачын, кура агачларын шатыр-шотыр китереп изеп-таптап йөргән ерткыч ягына карап, нәрсәдер кычкырды. Башта, әллә миңа дәшә микән дип торам. Юк, аю белән сөйләшә икән. Лачынның аваз салуын гына көтеп торган диярсең, шунда, нәкъ тау кадәрле булып, аягүрә баскан аю калыкты. Зурлыгын күреп өннәрең алынырлык иде инде менә. Тайга хуҗасы үз чиратында, бимазалап йөрүләренә ризасызлыгын белдергән сыман итеп, үкереп җавап кайтарды. Ул да булмады, юлында нәрсә очраса шуны изеп-тузгытып ташларга җыенган үгез сыман яман үкереп, Лачын өстенә килә дә башлады. Инде изә, инде бетерә, харап итә егетне дип күзләремне чытырдатып йомар чиккә җиттем. Ажгырып килгән аю тәмам якынлашып, аягүрә басып,Лачын өстенә ташланырга гына торган-

да, кетелмәгән хәл булып алды. Егет, күз иярмәслек кискен хәрәкәт ясап, башындагы томагын салып аюга сузды. Тегесе чебен аулаган мәче житез-леге белән, баш киемен элэктереп тә алды...

Шушы хәрәкәте харап итте ахры аюны. Кинәт янә әллә нәрсә булды, тайга хуҗасы, бер генә мизгелгә таш сын кебек катты да калды... Лачынның уң кулындагы сунар пычагы белән ерткычның йөрәген айкап чыгарган чагы булган икән.

Шуннан соң башланды хәлләр. Әҗәл ярасы алган тайга хуҗасы, дөньяның астын-өскә китерергә теләгәндәй, котны алырлык яман авазлар чыгарып, Лачын өстенә ыргылды. Ә тегесе, нәкъ яшен ташы сыман, эр-бет артына сикерде. Үз каны исенә исергән ерткыч, агач артына поскан һәм әле бер якка, әле икенче якка уйнаклап торган сунарчыны эләк-терә алмавына тәмам ярсып, ахыр чиктә, ике кеше колачы житмәслек агачны төбе-тамыры белән йолкып атарга теләгәндәй, эрбетне кочагына алды... Күрәм, шыксыз тырнаклары астыннан тирә-юньгә эреле-ваклы агач кайрылары гына оча...

Ахыр чиктә җанвар, агач башына менәргә җыенгандай, сикеренгә-ләп алды. Шунда ул тагын да яманрак тавыш белән үкерергә кереште. Яман иде бу аваз. Гадәттә, күзенә ак-кара күренмәгән, ярсыган яшь үгез-ләр, аяклары белән җирне тырный-тырный шундыерак авазлар чыгару-чан була. Кем белә, бәлки үзенең туган тайгасы белән шулай саубуллаш-кандыр...

Шулай үксүгә охшаган авазлар чыгарганнан соң, җиргә чүкте бу, күренмәс булды. Әлеге үксүгә охшаган авазлар әкренләп шыңшуга, аннан әрнеп ыңгырашуга күчте. Бераздан бар да тынды. Шунда Лачын-ның: «Рәхимҗан абый, чак кына сабыр ит инде...» — дигән тавышы ишетелде. Аюны тунарга чамалый торгандыр инде дип уйладым мин.

Чыннан да, ярты сәгать чамасы уздымы икән, юл кырыенда җилкә-сенә тау кадәрле итеп аю тиресе күтәргән Лачын күренде. Ерткычның чак кына өтәләнгәнгә охшаган җирән-көрән тиресен күргән атларны көч-хәл белән тыйдым, өннәре алынудан кая керергә тишек тапмыйлар мал-кайлар, таптыйлар дип торам үземне.

Тирене арбага салгач, күрдем, Лачын да терсәктән кара канда. Аю канydыр дип уйлаган идем, карасам, аның да бер беләге буйдан-буйга ярылган, аерылып төшкән сыңар җиңе чак-чак кына эләгеп тора. Яшь наратның чәерле каерысы белән яраны каплап бәйләгәндәй иттек тә кай-тырга чыктык.

Лачынның саубуллашырга дип килүе турында ишетү өйдәгеләрне әллә нишләтеп җибәрде. Акыллы, гадел, тормышның ачысын-төчесен хәт-сез татыган Гөлниса апа, кызына гына ишетелерлек итеп болай диде: «Бала яуга китә, дөньяныкын белеп булмый, кызым, берүк кешечә озата күр үзен, өметләрен кисәсе булма... Ризалыгым юк».

Гөлүсә дә ана сүзеннән чыкмады, егеткә моңарчы булмаган игъти-бар, якты йөз күрсәтте. Иң әүвәл һәйбәтләп ярасын юды, бәйләде, канга баткан киемнәрен юып элде, соңрак ямады. Ә инде кояш баегач, Лачын белән икесе яр өстенә, гадәттә, яшьләр җыела торган җиргә чыгып утыр-дылар. Чебен-черки булмаса да, учак кабызып җибәрделәр. Берсенә берсе күтәрелеп карарга кыймаган сыман утырдылар рәхмәт төшкер-ләре. Моны күреп, мин дә ярты чиләк чамасы эрбет күркәсе алып чыгып, учакка илтеп салдым. Шулай итеп сагыз-чәерен яндырмыйча торып, яңа уныш күркәсе эчендәге чикләвеген алырмын димә...

Соң шул. Гөлүсә белән Лачын, учак янында чикләвек чиертеп, шак-тый озак утырдылар. Кайтуларын күзәтеп тордым: егет, беренче талкыр буларак, Гөлүсәнең кул очларыннан гына житәкләгән. Шуның өчен Гө-лүсәгә эчемнән генә рәхмәтләр укыдым.

Лачын өйдәгеләр белән саубуллаша башлады. Аты инде ял иткән, ашатылган-эчертелгән. Шунда Гөлниса апа, туган улын озаткан кебек итеп, егетне күкрәгенә алып кысты да: «Исән-сау кайт, балам!» — дип

изге теләкләр теләде. Юлына дип кирәк-ярак, азык-төлек ише нәрсәләр дә хәстәрләп куйган иде, Лачын Ягъсүм абыйлар аша китәм дип. алмады.

Атын ияртеп урамга чыкты. Гөлүсә дә капка артына кадәр озатты үзен. Шунда, төсем итеп сакларсың дип, егеткә кулъяулык бүләк итте. Әнисе әйткән теләкләрне ул да кабатлады: «Исән-сау әйләнеп кайт, Лачын, җиңеп кайт! Көтәрбез...»

Бәхетеннән исергән кеше сыман итенде бичара. Атына очып кына менеп атланды да, аткан уктай, кара тайга эченә кереп юк та булды. Без инде курку белмәс азамат егетнең шулай төнгә карап хәтәр юлга чыгып китүләренә тәмам күнеккән идек.

Лачынны соңгы тапкыр күрүебез иде бу. Шул китүеннән кайтмады бахыр. Мин туган якларыма сәфәр чыгар алдыннан гына, сыңар хат-хәбәре килде. Язган кадәресе әле дә булса хәтер түремдә. «...Мәскәү урамнарыннан үттек,— дигән иде Лачын ул хатында.— Көнбатыштан аермачык булып туптан аткан тавышлар ишетелә. Алда фронт. Дошман артиллериясе шулай ата. Һавада, ак болыт кисәкләренә охшап, аэростатлар асылынып тора. Төнне метро станциясендә уздырдык. Әнә «сафка!..» дигән әмер яңгырады, язуымны бүлеп торам...» Чыннан да, хатын бары тик ике-өч көн узгач, алгы сызыкка барып җиткәч кенә төгәлләгән иде. «Әле яңарак кына митинг булды,— дип дәвам иткән иде Лачын.— Политрук Клочков чыгыш ясады. «Бөтен Германия өстебезгә ябырылса да, алны бирде юк. Чигенергә бүтән урын калмады, артыбызда — Мәскәү!..» диде ул. Яныбыздан гына Волоколамск юлы үтә. Хәзер без 251 нче биеклекне саклыйбыз. Мин генерал Панфилов кул астындагы укчы дивизиядә икәнмен. Күпчелек халык Себердән. Монда инде безгә кадәр бик каты бәрелешләр булган. Юлның як-ягында җимерек-ватык машиналарның, танкларның исәбе-хисабы юк...» Аннары инде Лачын мәхәббәт, сагынуюксыну сүзләре тезгән. «Саубуллашкач, бернәрсәгә бик ачык төшендем: тайга анам да, туган Инәсәем дә син икәнсең, Гөлүсә!..» дигән иде.

Әлеге хаттан соң икеме-өчме көн узгач, һәркайсыбызга яшен суккандай тәэсир иткән хәбәр алдык. Аны Ягъсүм китерде. Лачыныбыз Мәскәүне дошманнан саклап калу өчен барган дәһшәтле сугышларның берсендә батырларча һәлак булган. Өйдәгеләр иңрәп калдылар. Гөлниса апа, бала килеш утлы мәхшәргә барып кереп башын салган бит дип, балавыз да сыгып алды.

...Шул ук кичне Гази Рәхимҗан абые авызыннан, колагын торгызырлык кына түгел, тәмам тетрәндерерлек хәбәр ишетте. Гөлүсә, курсларын тәмамлап кулына документ алу белән, үзе дә фронтка китәр төслерәк итеп әйткән, имештер. Дөрес, ул моны сер итеп Рәхимҗан абыеның үзенә генә тишкән. Шул җитә калды. Гази кунакның бүтән сүзләрен ишетмәде. Беренче мизгелдә аны: бәлки әле очрашу урыныбыз да сүтелгән йомгак кебек чәбәләнеп беткән фронт юлларының берәрсендәдер дигән уй яулап алды. Бу уй аның бик күп елларга сузылган хыялый юлдашына әверелде. Очрашуның мең төрлесен күз алдыннан уздырды. Нинди генә шартларда, кайларда гына очрашып кавышмадылар алар! Менә Гази каты яраланган, имештер. Аңына килеп күзен ачса, ни күрсен: өстенә иелеп, аның хәленә кереп, Гөлүсәсе басып тора... Шунда Гази телгә килә «Гөлүсәм, беренче һәм соңгы мәхәббәтем, барысы өчен дә кичерә алса идең икән» дип гафу үтенә, имештер. Икесенең дә күзләрендә мөлдерәмә яшь... «Ничек кичермим ди инде, Гази! Мин дә син дип кенә яшим ич...»

...Газиның соңгы тапкыр күрүе иде Рәхимҗан абыен. Иртәгәсен таң белән Казанга чыгып китте. Фронтка чыгар алдыннан исә бер авылдашын очратты. Иң әүвәл әнисе турында сорашты. Сүз иярә сүз китеп, телгә Рәхимҗан абые да килеп керде. «Һаман да чиратлап кунакка йөрүен, авызына каратып Себер вакыйгалары сөйләвен дәвам итә»,—

иде авылдашы. Кеннәрнең берендә артыграк «сыйлап» ташлаганнар Рәхимҗанны, җырлый ук башлаган бу. Җыры да Себер турында ди.

Омски да безнеке,
Табулы да безнеке;
Себер белән куркытмагыз,
Себер үзебезнеке...

3

Моңа кадәр Гази түзә алмаслык авыр минутларында яшьлек хыялы Гөлүсәне күз алдына китерә иде дә тормыш зилзиләләренә каршы торырлык көч тапкандай була иде. Әмма соңгы көннәрдә татлы сагыну хисләренә бирелү, Гөлүсә турында уйлау да йөрәген газаптан, сагыштан, йончулы уйлардан арындыра алмый, бәгырь иңрәве дә, җан сыкравы да басылмый иде.

Гази тәрәзә ягына күз салмаска тырыша. Әчкелтем исле чия агачының шәрә ботаклары аша, күңелләргә шом салып, өзлексез рәвештә ажаган балкышлары килеп җитә. Шулчак аның хәтеренә җырмы, кайчандыр бер ишеткән шигъри юллармы килде:

Ажаган ялтырап китә, күңелләрне
шомландырып,
Әллә кемнәр искә төшә, сискәндереп,
уйландырып...

Әлеге балкышның ажаган түгеллеген дә белә Гази, әмма ялкын катыш шом биләп алган күңеленә күп кирәкмени соң! Әнә, ян тәрәзәдә уйнаклап торган яктылык кораб төзәтү мастерскойларыннан килә: сваркачылар эшли. Чия ботаклары аша күренгәне дә билгеле: Чулман буендагы нефть скважиналары янында факеллар яна, шулар һавадагы болытларны ялмап ала...

Газиның иң курыкканы — ялгызлыкта үлү. Бу уй туганда гына да аның җаны өши, ихтыяры туңа, рухы өтәләнә. Өйдә ялгызы бикләнеп калмас өчен, ул кече капканы да, өйалды һәм өй ишеген дә шар ачык калдырды. Теләсә кем керсен, күрсен, тиешле урынга хәбәр итсен...

Яшь, сау-сәламәт кеше генә киләчәк белән яши, Гази кебек тормышына нокта куярга җыенганнар үткән белән яши торгандыр шул. Менә ничәнче кабат инде Гази бөтен тормыш юлын күз алдыннан уздырмакчы була. Дөрес, узган хәлләрне, башыннан кичергән барлык могҗизаларны болай бер сулыштан күзаллавы мөмкин түгел. Шулай да бер нәрсә бәхәссез: тормышын гадел кичерде, нинди генә очракларда да елан кебек боргаланмады. Гомере буе беркемгә дә үпкә сакламады. Һәрхәлдә, ул үзен беткән, кешелеген җуйган вак җанга санамады. Шулай булмыйни! Әҗәленне чәбәләнмичә көтә белү, каршы алу — үзе генә дә ир-егетлек ләбаса!

Әмма Газиның тормышка ашмый калган үкенечләре бар. Шулар уфтандыра. Беренчесе — институтны тәмамлый алмавы иде. Эшкә урнашкан чакларда: «Дипломыгыз бармы?» — дигән сорауны ишетмәс өчен ул әлләниләр бирергә әзер иде. Элеккерәк елларда төшләрендә дә Казан каласы, институт белән саташып чыгар иде. Имештер, аңа имтиханнарын бирергә рөхсәт иткәннәр... Менә ул Казан шәһәрендә. Йөгерә-чаба хәлдән тая, җаны чыгар дәрәҗәгә җитә, әмма институтны таба алмый... Тора-бара, яше олыгайган саен, институтны тәмамлый алмавы белән килешергә туры килде. Нишләмәк кирәк, аңа, башка бәхетләләр кебек, югары уку йортларының баскычларын санарга язмагандыр инде, күрәсең.

Икенче үкенече — иң яманы һәм үзен атлаган саен сиздереп торганы — шушы көнгә кадәр Ватанының тугрылыклы улы икәнлекне исбат итә алмавы. Кара тап белән кара гүргә керер микәнни? Тора-бара Гази бу уена да, хәерче өстендәге сәләмәгә ияләшкән кебек, акренләп күнегә төште: кеше теләсә ни уйласын, әмма минем Туган илем алдында намусым саф, вөҗданым пакь, дип үз-үзен тынычландыргандай итә иде.

Әмма үкенеч-уфтануның иң олысы, берни белән дә чагыштыргысызы — үзенең беренче һәм соңгы мәхәббәте Гөлүсәне күрмичә, аның алдында гафу үтенмичә дөньядан китеп бару иде. Димәк, язмаган...

Шулчак, Газиның уйларын челпәрәмә китереп, өстенә сап-сары өрәңге яфрагы килеп төште. Уйнаклап аның йөрәк турысына кунган яфрак, эзлекле фикерен чуалтып кына калмады, ачык тәрәзәдән скелет кулы сузылгандай тәэсир итте. Бу көтелмәгән хәлдән сикереп тора язды Гази. Бары тик башын кыйшайтып, өскә таба күз салгач кына төшенде: көз көне, матурлыгына кызыгып алтын-сары яфраклы өрәңге ботагын сындырып алып, түрге почмакның бүрәнә ярыгына кыстырып куйган иде. Тәрәзәдән кергән җил кагып төшергән булса кирәк әлеге яфракны.

Гази, җыен юк-бар хорафатларга ышанмаса да, яхшыга юрамады бу хәлне, ниндидер яман хәбәр алыргадыр дип кабул итте.

«Шом хәбәрчесен» кулына алды Гази. Йомшак кына сыйпаштырып тигезләде яфракны, язды. Тырпайган бармакларындагы кан тамырларын хәтерләтеп, яфракның сабагы төбеннән як-якка нечкә җепселләр йөгергән. Күренеп тора, яфрак тәмам өлгергән, җитлеккән. Сабагының калынаеп килгән икенче башында, өзелеп төшкән урынында, бөре оясына охшашлы уенты да бар. Әйе, бөре оясы иде бу. Димәк, яфрак киләсе ел бөресенә урын биргән, юл куйган. Тормышта да шулай: бирәүләр китәләр, икенчеләре аларга алмашка килә. Нишләмәк кирәк, бу дөньяда берәү дә мәңгелек түгел...

Әрнү-сызлану эчендә иңрәп яткан Гази: үз аңымда вакытта, тел тибрәтергә хәлем барында хәзер үк, минутка да кичекмәстән, Һади энемә шалтыратырга кирәк дигән карарга килде. Булган бар егәрен җыеп, ян тәрәзә төбендә, кул сузымда гына торган телефонга үрелде... Аның искәрмәстән генә яман чыңлап шалтырый башлавыннан коелып төште: «Уф-ф!..» — дип куйды ул, чигәсе турысында тамыры тибә башлавын тоеп.

— Әй-йе! Тыңлыйм...

Гайния түти икән. Башта хәл-әхвәл сорашты, кәефе белән кызыксынды. Ашар-эчәренә бармы? Берәр җаның теләгән нәрсә кирәкмиме? Тартынып торма, әйт, янәсе.

— Менә монда, Газиулла, синең белән тагын бер кеше сөйләшергә тели. Хәзер трубканы аңар бирәм...

Чыбыкның теге башында, серләшкән кебек итеп, пышылдашып алдылар. Һәм шулчак аермачык булып чак кына таныш сыман тавыш ишетелде:

— Исәнмесез... Исәнме, Гази!..

— Саумысез!

Башта Гази Гайния түти хәбәренә әллә ни игътибар итмәде. Аның хәлен белешеп шалтыратулар еш була. Кайчандыр ул операция ясаган яки дәвалаган авырулар шулай кызыксынгалап, үзләренең рәхмәтләрен белдереп торалар.

Ахыр чиктә кем шалтыратуын анык белергә булды.

— Кем сез?

— Бу мин... Гөлүсә...

Газига әллә нәрсә булды. Кинәт кенә зиһене томаланды. Ул да түгел, йөрәгә шартлар дәрәҗәгә җитеп ярсынып тибә башлады. Еллар томаны аша ишетелгән сыман яңгыраган бу тавышны таныды ул. Бу тавыш аңа колак төбендә генә чаң суккандай тәэсир итте. Күз алдында яшелле-күкле таңкәләр биешәте. Әмма акылы бу хәлнең чын булуына ышанырга теләмәде. Авыру кеше ниләр генә кичермәс, мондый халәтләр бер түгел.

күп тапкырлар булгалады бит инде. Хәзер чак кына дәрман туплар да айныр, бу галәмәтләр шундук юкка чыгар дип уйлады Гази. Үзе ирексездән: «Нинди Гөлүсә?..» — дип, урынлы-урынсыз сорау бирүен сизмичә дә калды.

Теге якта да капылт кына җавап кайтарырга ашыкмадылар. Ниһаять, чак кына калтыранган тавыш янә ишетелде.

— Гөлүсә мин, Гази... Синең бала чактагы дустың... Яшьлегең юлдашы... Оныттың да мыни инде?!.

Газиның телефон трубкасын тоткан хәлсез кулы күкрәгенә төште. Әмма аны тетрәндергән, тәмам кешелектән чыгарган тавыш Газины һаман сөйләшергә чакыра, аның җавап бирүен таләп итә иде.

— Ал-ло! Гази дим... Ал-ло! Ишетәсеңме мине? Бу мин, Гөлүсә. Әллә кинәт кенә хәлең авырайдымы? Бер генә сүз әйтче... Ник дәшмисең? Бер генә сүз әйтче, Гази!

Бу юлы да Гөлүсәнең тавышы ниндидер йомшак, калын пәрдә аша гына ишетелгән сыман тоелды. Тел тибрәтерлек хәле калмаса да, Гази, актык ихтыяр көчен туплап, телефон трубкасын колагына китерде.

— Тыңлыйм сине... Гөлүсә!

— Бик һәйбәт, Гази!.. Менә хәзер яхшы ишетелә. Рәхмәт сиңа! Тагын ни булса да әйтче...

Гази бу могҗизага һаман да ышанып бетә алмый иде әле. Чыннан да Гөлүсә ич! Аның Гөлүсәсе шалтырата лабаса! Димәк, ул Чаллыда. Бәлки әле очрашырлар да? Әлбәттә, очрашачаклар. Ярабби! Төш кенә түгелме соң бу? Юктыр, әлбәттә! Бу уй аның җәрәхәтле йөрәген җылы дулкын булып тибрәндереп узды. Шушы минутларны көтеп аның ярты гомере үтте түгелме соң? Шулай ич! Бу — якты хыял, Гази өчен һичкайчан да ирешеп булмый торган өмет кенә иде. Шушы мизгелдә аның сулышлары киңәеп, җаны яктырып киткән сыман булды.

Гази йөрәгенең ярсуын, берүк вакытта сызып-талпынып кагуын басарга теләп, күкрәген тутырып сулыш алды да бер тын белән тагын сорау бирде:

— Гөлүсә... Бу якларга ничек килеп чыгасы иттең?..

— Йомыш белән, Гази. Кызымны укырга кертергә дип алып килдем... Медицина институтына.

Михнәт-газапларны күп күргән, күп кичергән йөрәге янә кузгалган сыман булды. Гази хәтта ыңгырашып куйды ахры. Нәрсә диде? «Кызымны укырга кертергә алып килдем» — дидеме? Әй-йе, шулай диде. Димәк, Гөлүсә тормышка чыккан... Кызы бар. Аның Гөлүсәсе күптән инде әни кеше икән... Бик яраган! Әле дә ярый, Гөлүсә, син ул бәхеттән мәхрүм булмагансың...

Телефонда Гөлүсә тавышы. Ул, әйтәсе сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккандай, тезде дә тезде:

— Гази, ишетәсеңме?.. Хәзер яныңа барам. Каршы килмәссең бит? Шушы кадәр җиргә килеп, сине күрмичә китә алмам бит инде. Көт, Гази, синең янга йөгердем. Көт, яме!..

Гази янә үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә килде. Чыннан да килерме икән? Чыннан да, күрер микәнни ул үзенең Гөлүсәсен? Менә кем аңа монарчы яшәү көче, менә кем аңа вакытның дәһшәтле агышына каршы торырга егәр бирде. Менә кем тормышка ашмас хыяллар белән өзгәләнгән, меңгә телгәләнгән җанын аз-маз җылыта, боек күңелен беркадәр юата, алҗыган тәненә чак кына ял бирә торган иде. Чыннан да, күрер микәнни үзенең тәүге мәхәббәтен, үзенең Гөлүсәсен?.. Йөрәге артык ярсып, тибүдән туктамаса гына ярар иде. Өзгәләнмә, йөрәккәй, ул тиклем, ярсыма, түз, йөрәк, сабыр бул, чыда!.. Һай-й, ачы язмыш, нинди генә хәлләргә төшермисең син газиз адәм балаларын!..

Гаҗәп хәл! Ниндидер гадәттән тыш вакыйга буласын, өметенең чынга, тормышка ашасын гомер буе көтеп яшәде ич ул. Бу өмет, бу ышаныч менә ни заман тынгылык бирмәде аңа. Гази белә: могҗизалар сирәк

була. Шулай да ул ышанды, көтте әлеге хикмәтне. Нишләмәк кирәк, кешене өмет дигән нәрсә яшәтә.

Тик менә сөйләшүе генә әллә ничегрәк, килешсезрәк чыкты кебек. Сон шунда, телефонда Гөлүсә икәнлеген белгәч тә: «Саумы, Гөлүсә! Саумы минем сөеп туймаган беренче һәм соңгы мәхәббәтем!» — дигән булса, теле корыр идемени. Гөлүсәнең: «Онытмадың да мыни?..» — дип үпкә катыш әйткән сүзләренә дә тиешле җавап кайтара алмады. Шунда: «Онытаммы соң!..» — дисә, ни булыр иде инде.

Гази менә ничәнче кат инде, язмышының иң ачы сынавына әзерләнгән сыман, үз-үзен кулга алырга, җыен тузга язмаган нәрсәләр турында уйламаска тырышып карады. Тик кая ул!.. Ялкынсынган ми икеләтә-өчләтә көч белән эшли, яңадан-яңа уй катламнарын актара, яңадан-яңа хәтирәләрне ачып кына тора.

Иң гаҗәпләндергәне шул: бер генә тапкыр да шатлыклы кыяфәттә күзаллый алганы юк Гөлүсәне. Беренче күренеш — Иргали абыйлары Себергә сөреләсе көннәр. Ярәшелгән ике гашыйк чишмә тыкрыгында, бер-берсен көтеп-сагынып торган кебек, кара-каршы килделәр дә бастылар. Гөлүсәнең җилкәсендә көянтә-чиләк. Ул күренешне гомере буена да онытасы юк Газиның. Алар хәтта күрешмәделәр дә. Сүзләренең дә рәтебашы булмады. Егетнең хәле аеруча мөшкел иде, кызның йөзенә күтәрелеп карарга кыюлыгы җитмәде. Әмма Гөлүсәнең әрнеп-сызланып: «Шулай итеп аерылышырбыз да микәнни?..» — дигән сүзләре аны аңына китерде һәм ул кызның йөзенә күтәрелеп карарга мәҗбүр булды. Карамаса, мең тапкыр яхшырак буласы икән. Кыз баланың яшь әлпәсе аша балаларча гөнаһсыз карашы гомере буена мәңге җуелмас эз булып күңел түренә уелды да калды.

Аннары Бөгелмәдә саубуллашулар... Гөлүсәнең шунда: «Га-зи-и, онытма мине-е!..» дип ачыргаланып кычкырулары... Шул тавыш, шул аһәң аны гомере буе эзәрлекләде, тормыш юлы буенча озатып йөрде, төшләренә кереп, шабыр тиргә батырып уяткан чаклары еш булды. Фронтта вакытта, әсирлек афәтләрен кичергән чакта, берәр хатын-кыз тавышын ишетә-нитә калса, Гөлүсәсе ярдәмгә чакырып кычкырадыр дип, җаннары өши, тамырларындагы каны туңа торган иде.

Аны иң изгәне, өзгәләгәне, үзенең тораташтай битараф калуы иде. Ир-егетләрчә саубуллаша да белмәде бит ул үзенең бердәнбере белән. Шунда: «Гөлүсәм! Минем сине соңгы сулышымда да онытасым юк... Галәм читенә китсәң дә, янына барырмын, җир асларыннан юллар салып булса да, эзләп табармын!» — дип кенә кычкырасы иде кана. Юк бит, юк!.. Ихтыяры богауланган кеше сыман, шул адымны да эшли алмады бит ул. Ничек итеп уфтанмыйсың да, ничек үкенмисең ди!.. Ә бит аларның мәхәббәте якты иде, саф иде, изге иде, мәңге онытылмас җырга тиң иде.

Тиздән, тагын берничә минуттан, ул Гөлүсәсе белән очрашыр... Тик бер генә тапкыр күрәсе иде дип күпме гомер хыяллануын, акылдан шашу дәрәҗәсенә житүен Гази үзе генә белә. Нинди хикмәттер, кавышу минутлары якынайгач кына, әлеге тәкатьсез теләге, кинәт кенә каядыр икенче планга күчеп, икенче бер хис белән алышынган сыман булды. Ул каушый калды. Гүя аңа беренче мәхәббәте белән түгел, ә вөҗданы белән күзгә-күз очрашасы бар кебек тоела башлады. Әлеге уй туу белән Газиның йөрәге яңадан урыныннан купты, шундый какты, күкрәгенә сыймый башлады. Яңадан: «Аңымны гына җуймасам, һушымнан гына язмасам ярар иде»,— дигән уй биләп алды аны.

Шулчак ниндидер көч урыныннан күтәрде Газины. Аякларын караваттан төшерде. Башы әйләнүгә, күз аллары караңгылануга түзәр чама юк. Шулай да ул, үз-үзен көчләп диярлек, караватт башына тотынды да аягүрә басты. Башта стенага, аннан өстәл кырыена тотынып, көзге каршысына килде. Әмма үз-үзен танымады. Аңа сакал-мыек баскан, күзләре эчкә баткан ят кеше карап тора иде. «Әй-йе, чыкмаган бер жа-

ның гына калган... Бу кыяфәттә Гөлүсәң күзенә ничек күренерсең?..» — дигән уй чагылып китте аның башында.

Гази, исерек кеше кебек, анда-монда тотынгалап, мич аралыгына керде. Ут кабызды. Юынгыч янында кабат көзгегә күз төшерде. Җитенке сакал-мыекны электр бритвасы белән генә алырлык түгел иде. Бит-ягагын мул итеп сабынлады да киштәдә торган иске бритвасы белән кырына башлады.

Юынып-сөртенгәннән соң, мөмкин кадәр турырак атларга тырышып, яңадан караваты янына килде. Бераз хәл җыеп утырганнан соң, тумбочкасыннан ак күлмәген алып киде. Урын-җирен, мендәр тышын алыштырды, бары тик шуннан соң гына, тәмам хәлдән таеп, караватына авып төште. «Уф-ф!.. Булгандыр инде...— дип уйлады ул.— Әле дә ниндидер изге юлга әзерләнгәндәй җыендым...»

Гази күзләрен йомды. Шул вакыт кайдадыр урам ягында аяк тавышлары ишетелгән сыман булды. Башта, йөрәгем шулай дөпелдидер дип уйлаган иде ул. Әмма юк, чыннан да, кемдер килә иде. Үзен күрмәсә дә, таныды Гази. Әүвәлгечә җиңел-житез атлавыннан таныды: бу Гөлүсә иде. Аяк тавышлары якынайды, ишегалдына түшәлгән яссы ташлар өстеннән җитез-өлгер атлап үттеләр. Менә өйалды идәннәренә җан керде. Һәм, ниһаять, ачык ишектә Гөлүсә үзе пәйда булды.

Бу мизгелдә Гази ниндидер аңлы-миңле бер халәттә иде. Гөлүсәне дә ул, бик ерактан күргән сыман, танудан бигрәк төсмерләде генә кебек. Анда да әле үз күзләренә үзе ышанмыйча торды. Әмма бу хакыйкать иде. Гүзәллек һәм яшьлекнең гәүдәләнеше булып, чынбарлыкка әйләнгән Гөлүсәсе басып тора иде аның каршында.

— Исәнме, Гази!..

Я-а, аллам, изге җан, синме соң бу?!. Төш кенә түгелме? Бары тик шунда, Гөлүсәнең тавышын ишеткәч кенә, яшьлеге белән кабат күзгә-күз очрашкандай булды.

— Саумы, Гөлүсә... Исән-имин генә йөрешме?..

Сүзләре беткән кешеләр сыман, икесе дә бермәлгә тынып калдылар. Кая китте Газиның, очраша-нитә калсалар дип, йөрәгенең иң түренә, иң тирән урынына туплап-әзерләп куйган иң кадерле, иң мөкатдәс сүзләре?!. Кайда алар?..

Хәер, хисләр тулышканда сүзләр нигә? Менә Гөлүсәсе аның каршысында гына ич. Кул сузымында гына.

Гөлүсә! Менә ул... Йөзендә шул ук ягымлы ояльчанлык, әдәплелек, нәфислек. Хәрәкәтләрендә күркәм тыйнаклык. Күзләре дә, нәкъ элеккеге төсле, аяз көн йөзедәй күксел-зәңгәрләр. Тик хәзер алар чак кына уңганнар сыман... Моңсулык, сагыш та өстәлгән. Матур итеп өскә күтәртеп куелган чәчләренә дә дөрләп янып артта калган елларның көле сибелгән икән... Әмма бу кыяфәт аңа бик тә килешә иде. Тигез булып кояшта янган чыраена чак кына уйчанлык-моңсулык өстәлсә дә, төс ташламаган. Иң хикмәтлесе — Гөлүсә йөзендәге һәр чагылышның, һәр үзгәрешнең иң нечкә төсмерләренә кадәр табигый булуы иде. Өстендә йөзенә иш килә торган, эре күзәнәкләп бәйләнгән сыек зәңгәрсу төстәге йон күлмәк. Тәненә сыланып торган бу күлмәк хатынның бөтен гәүдәсен җыйнак, ыспай күрсәтә иде. Бернинди дә бизәнү-ясану әйберләре такмаган. Гәүдәсе чак кына, сизелер-сизелмәс кенә түгәрәкләнеп киткән, әмма бу аның буй-сынына җитлеккән ямь, нәфислек кенә өстәгән иде.

— Утыр, Гөлүсә...

— Рәхмәт, Гази!..

Гөлүсә тагын да якыная төшкәч, янә бер нәрсәгә игътибар итте Гази: кунагының күзләрендә мәңге эремәс боз булып тирәнгә киткән бер яшерен сагыш чагыла. Менә ул еллар моңсулаткан күзләре белән Газиның йөзенә томырылып карап торды да:

— Я-а, ходаем! Бу көннәрне дә күрәсем бар икән!..— дип куйды. Гөлүсәнең йомшак-мөлаем тавышы йөрәкләрне айкап алды.

Гази тамак төбенә нииндидер әлпә килеп бөялүен тойды. Әмма үзен бик тиз кулга алды, күңелендә кайнаган хис-фикерләрен бер җепкә тезәргә көч тапты.

— Минем дә, Гөлүсә... бер күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем дигән чакларым күп булды. Бөтен ихтыярымны туплап: «Юк-к, Гөлүсәне күрмичә үләргә хакым юк!» — дип, гел тәкрарлап тордым...

Гөлүсәнең йөзендә яңадан зәгыйфь елмаю хасил булды:

— Юк сүз сөйләмә, Гази... Нинди үлү ди ул! Яшибез әле...

— Үз хәлемне яхшы беләм мин, Гөлүсә...— Бу сүзләрне әйткәндә Газиның чыраенда тән сызлануының гына түгел, җан иңрәвенең дә чалымнары бар иде кебек.

Гөлүсә тагын елмайгандай итте, тагын Газины тынычландырды. Әмма күпме генә тырышса да, булдыра алмады: күзләре көлсә дә, күңеле елый иде аның.

Менә аның бер генә мизгелгә иреннәре тетрәнеп куйды. Йөзендә авыр кичереш, аптырап калу галәмәтләре... Күз яшьләрен күпме генә тыярга тырышса да, күңеле мөлдерәмә тулган иде ахры, дымлана башлап авырайган керфекләрен чыт-чыт йомгалап алды да кисәк кенә читкә борылды... Һәм, йөзен куллары белән каплап, сулкылдап үксергә үк кереште.

— Зинһар, Гази... Гафу итә күр мине...

Бу минутта Гази да, тел тибрәтергә хәле калмаган кеше сыман, тынып калды. Тыны кысылды, тамак төбенә килеп бөялгән төерен йотарга тырышып карады. Аның җаны гына түгел, тәненең барлык күзәнәкләре дә елый иде. Күз тирәләрен пешереп, күзләрен яшь пәрдәсе саруын тойды.

— Хәзер инде үкенмим...— диде ул ахыр чиктә.— Гомеремнең иң татлы хыялы тормышка ашты: сине күрү бәхетенә ирештем...

Алар янә тынып калдылар. Ул арада Гөлүсә дә, ташыган хисләрен яшь белән мул итеп сугаргач, тынычлана, күңеле дә чак кына иркенәя төшкән сыман булды. Күзләрендә дә кабат нур уянып алды кебек. Газиның да әрнегән җаны чак кына язылып киткәндәй булды.

— Һаман да ышанып бетә алмыйм... Синме бу, Гөлүсә?..— диде ул йөрәк түреннән чыккан бер җылылык,ягымлылык белән.— Бу сүзләремә гаҗәпләнмә, Гөлүсә!.. Менә чирек гасыр инде уем, сагышым, сөенечем, көенечем, өметем, шигем бер син идең. Бу хис шундый кодрәткә ия иде, хәзер инде уйлавы да хәтәр... Әгәр дә шушы көнгәчә бу дөньяда яшәгәнмен икән, бел: бары син булганга, күңелемдә сине бер күрергә ашкыну булганга гына яшәдем. Мәхәббәтем исәбенә яшәдем...

— Сөю хәсрәтсез булмый торгандыр инде...— диде Гөлүсә кинәт ачылып. Әмма шундук яңадан уйчанланды, әле яңарак кына бәхет нурлары чәчкән күзләрендә үпкә һәм шелтә чаткылары кабынган сыман булды.— Юксыну, ачы сагыш минем дә гомерлек юлдашыма әверелде... Үзең уйлап кара, Гази, мин көткән яклардан ник бер хат, ник бер сәлам, ник сыңар сүз генә килсенче!.. Нишләп соң әле без яшьлегебезне, мәхәббәтебезне саклый алмадык? Нәрсә булды безгә?..

— Синең тарафлардан да хәбәр-хәтер булмады бит, Гөлүсә. Ым гына как идең, сәгате-минуты белән сине эзләп сәфәр чыккан булыр идем. Эх, белмисең Гөлүсә, сез киткән якларга җәяүләп чыгып китәрдәй чакларым күп булды минем. Тик нишләмәк кирәк... Үләр дәрәҗәгә җитеп сагынганда да, тилерер, акылым зәгыйфьләнер дәрәҗәгә җитеп юксынганда да түзәргә тырыштым...

Бер-берсенә карашып янә тынып калдылар, өнсез-сүзсез тордылар. Никадәр мәхәббәт, үз итү иде ул карашларда! Бу мизгелдә алар, мөгаен, икесе дә әллә кайда, бик еракта калган үкенечле яшьлекләрен күз алдына китергәннәрдер.

— Әй-йе!..— дип куйды Гази, тирән көрсенеп.— Сындырып сыный икән дөнья. Эх-х, Гөлүсә, белсәң иде хәлләремне! Үземне гаепле санау

тәмам кешелектән чыгарды мине... Җәзамны да алдым кебек. Әй-йе, алдым! Барысы да шуның нәтиҗәсе... Бәхет дигән нәрсә читләтеп узды. Гомумән, тормышымның рәте-чираты булмады.

— Нишләмәк кирәк,— диде Гөлүсә, Газины авыр уйларыннан арындырырга теләгән сыман.— Заманасы шундый иде бит аның. Бигрәк тә четерекле, бигрәк тә михнәтле заманнарга туры килде шул яшьлегебез. Әти әйтмешли, сыйнфый көрәш чоры, ата улны, ана кызны белмәгән бер дәвер иде.

И-и, Гази! Яман ла икән чит-ят җирләрдә яшәүләре! Үзебез китсәк тә, ярты җаныбыз, йөрәк парәләребез туган илдә аерылып калды... Сагыну, юксыну хисе көнелне шундый телә, талый, вакыты белән тәгәрәп-тәгәрәп елыйсы килгән чаклар була...— Гөлүсәнең күксел-зәңгәр күзләрендә янә моң-сагыш чагылып үтте.— Кайда гына булсам да, нинди генә йолдызлар астында яшәсәм дә, кемнәр белән генә аралашсам да, күңелне һәрчак бер кайнар хис, бер тынгысыз тойгы — туган туфракны сагыну хисе, туган авылымны, сине күрәсем килү тойгысы алгысытып торды. Туган якларыбыз минем күңелем түрендә мәңге дә ямьле, мәңге дә тынычлык, бары тик мәхәббәт кенә хакимлек иткән сихри бер ил булып гәүдәләнә иде. Аның кояшы да күз камаштырырлык яктыдыр сыман тоела иде. Туган якның чирәм катыш каз үләне үскән тар тыкрыгына кадәр җаннан газиз гүзәл күренеш булып күз алдына килә иде. Их-х, очып кына кайтып, читтән генә булса да бер күрәсе иде дигән минутлар аз булмады. Кайтып бер күреп килмичә, барыбер тынычлана алмам дидем дә кайттым менә. Әни дә: «Кошлар да очып җитә алмаслык ерак-ларда калган, җәннәтләргә тиң туган якларны күреп кайт, кызым. Моңлы бер җыр булган икән ул безнең туган якларыбыз... Минем өчен дә күреп кайт, кызым, йөрәгеңә сеңдереп кайт»,— диде.

...Бигрәк тә яз-көзләрен, киек казларның өер-өер булып—юлыбыз ерак, юлыбыз кыен, юлыбыз хәтәр дигән сыман моң-зар тулы тавышларын ишетү яман иде. Ай-һай ла, авыр иде ул авазларны ишетү, бөтен җанны төбе-тамыры белән кузгатыр, күңелләрдә сүнеп бетмәгән өметләрне яңартыр иде. Безнең авылдан якында гына, карагач-эрбет агачлары каплаган таулар арасында бер могҗизалы күл бар. Аккош күле дип йөртәләр үзен. Шунда ялга төшәләр иде киек казлар. Аларның өннәре авылга кадәр ишетелеп торыр иде. Көннәрнең берендә, күк йөзе кара болытлар белән тартылган бер дәвердә, әлеге күл буенда ялгыз бер киек казга тап булдым. Күлнең яр буйлары чыраган. Салкын җил исә. Төшкән кар эремичә яткан бер вакыт иде. Адашыпмы, яраланыпмы өереннән аерылып калган киек каз, күл өстендә шактый вакыт әйләнде. Канат каккан саен шундый да әрнеп, йөрәкләрне меңгә телгәләрлек итеп кычкыра бу... Кычкырмый, ә зар елый сыман... Аның йөрәк төпләрен айкап-актарып ташларлык үзәк өзгеч тавышыннан, бөтен күк гөмбәзе иңрәп торды кебек ул көнне. Минем заяга узган яшьлегем турында елаган сыман тәэсир итте...— Гөлүсә бераз тынып торгач, күңелсез генә өстәп куйды: — Гафу ит, Гази! Истәлекләр шулай һәрвакыт чак кына моңсу буладыр инде ул. Узган гомер үз тамгасын саладыр, күрәсең...

«Истәлекләр»дән арынуга сөенгән кебек, Гази да тизрәк сорау бирергә ашыкты.

— Гөлүсә... ә ирең ниндирәк кеше соң?

Кунакның йөзе яктырып киткән сыман булды. Кабат елмайды. Тынычландырырга теләгәндәй, сузылып Газиның кул сыртын чәбәкләп алды, аннары бөтенләй ачылып китеп, бары тик бер сүз әйтте.

— И-и, Гази!

Ул бу сүзне шундый итеп әйтте ки, Гази көтмәгәндә-уйламаганда искиткеч кыйммәтле бүләк алгандай тойды үзен. Гөлүсәнең шул бер сүзе әрәмгә узган чирек гасырны гүя сызды да атты. Кунак үзе дә бу мизгелдә июнь ае чәчәгенә охшап калды. Әчтән ниндидер нур, илһам белән өре-

телгән сыман күренә башлады. Хисләнүдән, бер үк вакытта сокланудан гаҗиз иде Гази бу минутта.

Гөлүсә сүзен дәвамлады.

— Кияүгә чыгу бәхетенә ирешеп булмады шул, Гази...

Бу юлы инде Газиның кашлары югары чөелде.

— Ничек?.. Бая кызымны укырга кертергә алып килдем диген түгелме соң?..

— Әйе. Шулай дидем.

— Соң?..

Шунда Гөлүсә Газины чынлап торып хәйран иткән вакыйга турында сөйләде. Себергә барып урнашкан елларда, Гөлүсә хат аша Газиның врачлыкка укырга китүе турында ишетә. Шушы хәбәр аның да тормышын үзгәртә: ул да шәһәргә барып башта фельдшерлыкка укырга керә. Ил өстенә кара афәт килгән елны тәмамлап, кулына таныклык ала. Практикага Инәсәй елгасы буенда утырган бер авылга җибәрәләр. Көннәрнең берендә, эштән кайтышлый, сафларга тезелеп балалар килүен абайлап ала Гөлүсә. Аларның сугыш барган яклардан китерелүе турында ул инде элгәрәк ишеткән була.

— Шунда мине тәмам тетрәндергән, тотрыксыз иткән бер вакыйга булды. Иске шәлгә төренеп, кулларын кара-каршы китереп, иске бишмәт җиңнәренә тыккан бер нәни генә кызчык, миңа күтәрелеп карады да, кинәт сөртенгән сыман туктап калды. Күзләре, йөзе әсәрләнеп китте моның. Ул да булмады, минем янга ташланды... Ике куллап тезләремне чытырдатып кочаклап алды да, бөтен дөньяга хәбәр салгандай, үксеп елый-елый бер үксүзләрне кабатларга керешә: «Мама... Мамочка!.. Мамите моя!» Ә үзе өзми дә, куймый да, сорау артыннан сорау бирә: «Ник болай озак килмәдең?.. Мин сине бик көттем бит... Озак көттем... Мамите моя!..»

— Ул елый, мин елыйм. Тирә-юнебезгә җыелган хатын-кызлар елый. Ул арада янибызга балаларны тезеп каядыр алып баручы тәрбияче йөгереп килеп җитте. Кызчыкны миннән аерып ала башлады. Кая ул! Тагын да ныграк ябышты бу миңа. Үзе үкси, үзе сөйләнә: «Бирмим... Минем әнием!.. Беркемгә дә бирмим, минем мамите!..» Ярсый башлаган бала, нишләгәнен дә абайламыйча, тәрбиячесенең кулын тешләп алды хәтта. Ахырда тәрбияче хатын-кыз, тешләнгән кулын угалап: «Соңрак, бераз тынычлангач, үзем килеп алырмын»,— дип минем адресны сорады, кайда эшләвем белән кызыксынды. Бала шулай итеп миндә калды. Фатир хуҗасы нәни кунакка миннән дә артыграк куанды...

Шунда Гөлүсә, сабыры төкәнгән кеше сыман, искәрмәстән генә сорау биреп куйды.

— Гази... ә үзең өйләнмәдеңме соң?

— Юк, Гөлүсә, өйләнмәдем.

— Ник алай?

— Кемне дә булса бәхетсез итәсем килмәде...

— Алайса... тәрбияләп аякка бастырам да Себер тарафларына алып китәм үзеңне. Тайга һавасыннан шифалырак нәрсә юктыр ул. Балыкка, ауга йөрерсең... Ерак барасы түгел, суер, көртлек, бөҗыр, теллетәвеч кебек кош-кортлар бакча артында гына. Малай-шалайлар таяк белән дә бәргәләп алгалыйлар.

— И-и, хыялый җан! — диде Гази, соңгы көч-егәрен, ихтыярын туплап.— Кая инде ул миңа... син әйткән юллар?.. Мине Гөлүсә... бүтән сәфәр көтә...

Гази әлеге сүзләре белән Гөлүсәгә карата артык рәхим-шәфкатьсезлек күрсәтүен шундук чамалап алды. Әмма юату сүзләре эзләп торырга соң иде инде. Сүзне икенчегә бору нияте белән, Иргали абые, Гөлниса апасы турында сораштырды.

— Рәхмәт, Гази. Әти дә, әни дә исәннәр, тик бик нык картайдылар. Беләсеңме, бер тапкыр әти чак-чак кына туган авылыбызга килеп

чыкмый кала. Моннан берничә ел элек, СССР Халык хуҗалыгы күргәзмәсенең «Җәнлекчелек» павильонында безнең борын-борыннан атаклы Баргуза кеш тиреләре Алтын медаль белән бүләкләнгәннән соң була ул хәл. Казанга житәрәк, поезддан төшеп калу нияте белән, әйберләрен дә жыя ул. Ниһаять, поезд гөрелдәп Идел аша салынган күпергә килеп керә. Дәрья буйлап аккош кебек пароходлар үтеп барганын күреп кала. Әмма Казан станциясендә төшәргә җыенгач кына, орденнарының үзе белән түгеллеген абайлап ала. Әти, сугыш елларындагы фидакарь хезмәте өчен, Ленин ордены, соңрак Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Шуларның тагылмаган булуы аның юлына киртә була да кала. «Эх-х, бер күрүе — бер гомер», дип Вятка Аланы станциясендә тагын бер тапкыр талпынып карый. Әмма анда да әлеге уеннан кире кайтырга мәҗбүр була. Дус бар, дошман бар, дигәндәй; «Мине сөреп нәрсә оттыгыз соң?» — дип йөзе аклыгын расларга теләгән булгандыр инде...

Гөлүсә бер генә мизгелгә сүздән туктады да, Газиның сулып калган ап-ак йөзенә кызгану катыш сөю белән карап торды.

Шунда сырхау телгә килде:

— Алай итеп карама миңа, Гөлүсә... югыйсә елап җибәрүем бар...— диде ул ялварулы бер тавыш белән.

Гөлүсә, җинаять өстендә тотылган кеше сыман, каушап-югалып калды. Әмма озакка түгел. Шундый тетрәткеч минутта да елмаерга көч табып, Газины яман да хәтәр уйларыннан арындырырга теләгәндәй, сөйләвендә булды:

— Күп тә үтмәде... безнең нәселле җәнлекләр совхозының даны илебезгә генә түгел, бөтен дөньяга таралды. Әти эшне зурдан йөртә белде. Совхоз директоры да, бер үк вакытта баш зоотехнигы да иде. РСФСРның атказанган зоотехнигы» дигән мактаулы исем дә бирделәр үзенә. Унунбиш ел рәттән инде район Советында депутат булып тора...— Бу сүзләрне Гөлүсә бары тик сүз булсынга, тик Гази кирәкмәгән ямьсез уй-хисләргә, өметсезлеккә бирелмәсен өчен генә сөйләде. Шулай итеп, сырхауның уй-фикерен читкә юнәлтеп, дөрес эшлидер сыман иде.— Совхозыбыз мех житештерү белән шөгыльләнә. Һәр елны җиде-сигез миллион саф табыш алабыз. Мин үзем дә әти белән бергә эшлим. Баш ветврач мин хәзер. Диссертация якладым, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты...

— Гөлүсә!.. Кулыңны бир...— диде Гази тыныч, бер үк вакытта шомлы тавыш белән.— Тиз бул!..

— Нәрсә, Гази?..— Гөлүсәнең тавышы каушап, калтырап чыкты.

— Миңа... аерылышабыз да...

— Юк, юк, Гази!.. Юкны сөйләмә...— диде Гөлүсә, Газиның өмет чаткылары сүнгән күзләренә карап.— Ярты гомерем буена көтеп алган беренче кавышуыбыз бит бу! Ю-ук!.. Булуы мөмкин түгел...

Ул арада Гази күз аллары караңгылана башлавын тойды. Кинәт кенә киң офыклы дәрья ачылгандай булды. Шул манзарада алар икәү, имештер. Яшь чаклары, янәсе... Шулчак яшен балкышы сыман гына булып миен: «Миңа әҗәлем дә килеп житте»,— дигән уй өтәләп алды. Ә бит әле аның күңелендә дулаган хисләр дә, Гөлүсәгә әйтәсе сүзләр дә байтак иде. Эх-х, үкенечле дөнья!..

— Гөлүсә...— диде Гази ниндидер хәлсез бер пышылдау белән.— Хуш!.. Бәхил бул... Мин китәм... Андый чакта күңел алдаламый. Күзләремне йомдыргач... әгәр дә шикләнмәсәң... Үтенечемне үтәрсең, яме?.. Дәшәрсең миңа. Син янымда булсаң, үлгәч тә яшәвемне... дәвам итәрмен. Ишеткәнемне... ничек булса да... керфегемне кагып бүлсә да... белдерермен...

— Ю-ук, Гази-и!..— диде Гөлүсә әчке бер тетрәнү белән.— Юу-ук, үлмисең...

Ул тәкате бетеп сикереп торды да сырхау өстенә иелде. Газины шушындый да битараф, шушындый да гаҗиз кыяфәттә күрермен дип ул

башына да китермәгән булгандыр, күрәсең. Кинәт кенә дөньяның асты өскә килгән сыман булып тоелды аңа. Һәм ул, кабат Гази өстенә иелгәндә, чәчрәп чыккан кайнар яше аша, Газиның тутырып, томырылып караган хәрәкәтсез күз караларын гына абайлап алды...

Автобуска кереп урнашсак та, кузгалып китә алмыйча торабыз: «Хәзер, өстемә генә элэм дә чыгам...»— дип калган Гайния түтине көтәбез. Автобустагыларны күздән кичерәм. Больница шоферы Өлфәт, сыңар кулын уңга-сулга хәрәкәтләндереп, Газиның кай тирәдәрәк торганлыгын аңлата булса кирәк.

Күзләремне читкә алам. Әле яңа гына яфрак яра башлаган, куерырга өлгермәгән карт тирәкләр аллеясы аша җәйрәп яткан гүзәл Чулман күренә. Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: иртә якта гына елганың аръягында оеп торган каракучкыл авыр болытларга әллә ни булган — бар да хәрәкәттә... Күзе-башы тонган болытлар әүмәкләшеп, айкалып-ургылып берсе өстенә икенчесе ябырылалар. Аларның шулай өзлексез хәрәкәтләнүеннән күк гөмбәзе кайнап торган сыман. Гүя анда, иксез-чиксез киңлектә, нинди дәһшәтле көчләр арасында мәрхәмәтсез көрәш бара...

Ниһаять, больницаның күп тапталудан ашалып-уентыкланып беткән киң таш баскычында кулына сөтле шешә, тагын нииндидер банкалар тоткан Гайния түти күренде.

Ул, аһ-вах килеп, автобуска кергәч үк, кузгалып та киттек. Беравык тын бардык. Һәркем үз уена бирелгән. Яңарак кына ишеткән хәбәр һәркемгә үзенчә тәэсир иткән. Мин дә инде күңелем белән гөнаһсыз сабый чакларда бергә әүмәкләшеп үскән балачак дустым Гази янында. Бу уй тәнемә нииндидер рәхәт бер җиңеллек иңдерде, ә күңелемдә дуамал хисләр өермәсе уятты. Ничегрәк итеп очрашырбыз икән? Әлбәттә, өенә бәреп керү белән: «Гази!.. Яшьлегемнең тугрылыклы дусты, саумы!» — диярмен. Кочагыма алырмын. Шулай озак күрешә алмавыбыз өчен гафу үтенермен. «Тыңдашсез куанычлы хәбәр алып килдек үзеңә»,— диярмен...

Алдагы креслоларның берсенә урнашкан Гайния түти дә өзми дә куймый, бер үк сүзләрне кабатлый.

— Менәтерәк, әйттем бит!.. Гелән әйтә килдем мин сезгә... Юк идем, Газиулла андый җинаятькә бара торган кешегә охшамаган... Андый түгел ул, тиккә генә мазалыйлар адәм баласын идем...

Ниһаять, безнең автобус җиләк-җимеш бакчаларына күмелеп утырган өйләр янына — үзәнлеккә төшә башлады. Нинди тыныч, нинди аулак урын! дип сокланырга да өлгерә алмый калдым, машинабыз уенчык кебек кечкенә бер йортның ачык капкасы турысына килеп тә туктады. Без җәһәт кенә автобустан төшеп, ишегалдына үттек. Араларыннан яшел үлән эзләре төртеп торган яссы ташлар өстеннән, җилҗил атлап үттек тә болдырга күтәрелдек.

Өй ишеге дә ачык иде. Әмма без эчкә үтә алмадык, ишек катында тораташтай каттык та калдык... Караватта куллары күкрәгә өстенә куелган Гази ята. Ачык тәрәзәдән кергән җил, аның чал чәчләренә җан өргәндәй, селкеткәләп куя. Ак йөзендә, күптәнге теләгенә ирешкән кешенекедәй, гаҗәеп бер тынычлык иде.

Газиның гәүдәсе янында исә буйга-сынга бик тә килешле, йөзгә-биткә дә сөйкемле бер ханым басып тора һәм, акылына зәгыйфьлек килгән кеше сыман, йомшак тавыш белән:

— Гази!.. Гази дим... Ишетәсеңме, бу мин... Синең Гөлүсәң! Ишетәсеңме?..— дип һаман бер үк сүзләрне тәкрарлый иде.

*Азнакай — Малеевка — Зеленый Дол*
*1967—1984*

# Роберт Әхмәтҗанов

## Күпер уртасы

*Шагыйрь Әнвәр Давыдов истәлегенә*

Юкәләр шау чәчәк иде, июнь иде;
балкып тора Болакның бар тарафлары...
Суда йөзә ак болытлар, суда кыяк-камыш,
бәйрәм итә иде энә каракларыі!

Шушы мизгел мәңгелеккә калыр диеп,
кем уйлаган? Күз чагыла якты көн каршында!
Кемне көтә? Ак күлмәктән балкып, шагыйрь
туктап тора күпер уртасында...

Шул күпердән узды күпме язлар, көзләр,
яшел дөнья күтәрелде шаулап кояш яктысына...
Ә ул шунда ничә еллар ак күлмәктән басып тора,
килеп җитеп гомере яртысына.

Бер тылсым да кузгаталмый аны шуннан,
чыкмый хәтта шул урыннан таныш җыр каршына...

Калды шагыйрь күңелләрдә һәйкәл булып,
ярлары юк күпер уртасында...
Тора һаман
гомере уртасында!

## Белдерүләр тактасында

Үткән-сүткән укып китә,
бер язу бар,
кадакланган белдерүләр тактасына:
«Бүленешәбез. Кирәк безгә
аерым-аерым ике бүлмә
ике җирдән,
аерым булса, үзем риза барысына...»

Безнең оя — насыйп булыр икән кемгә:
бер бүлмәсе — ундүрт адым (буш бүлмәдә

---

РОБЕРТ ӘХМӨТҖАНОВ (1935) — *шагыйрь, «Егерменче яз», «Идел-йорт», «Олы юлның җилләре» һ. б. татар һәм рус телләрендә унбиштән артык шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

читлектәге җәнлек кебек көн дә
арлы-бирле йөреп үлчәдем мин ялгыз),
зур балконлы (анда соңгы сары гөлләр),
уты — яна, суы — ага (сусаганны
басмый, җылытмый җанны,
һич югында хатирәләр утын кабыз!)
ап-ак стенада — экрандагы сыман,
гел үткән көннәр,
көне кыска, төне озын — һич атмый таңы
йөреп тора ике чыгыр ике якта
(яшьлек вагоннары тавышы колакта);
бөтен шарты килгән: унитазы, хаҗәтханә,
утын ягасы юк кышка,
чүпләрен дә түгәсе юк еракка...
(тик юк-барны чыгарасы түгел иде безгә тышка!)

Элек нинди серле идек!
Яшерә идек,
горур идек җиде ят каршында.
Дустым,
шундый көнгә калдык:
безнең уртак бәхет
эленеп тора инде
белдерүләр тактасында!
Яңгырларда, карда
бер галәм каршында
җилферди! Елый! Чакыра!
Хәзер инде безнең тик бер максат:
икебезгә ике җирдән
аерым-аерым ике бүлмә.
Ике бүлмә!
Ике йөрәк,
бер-беренә сыенып,
баралмады кыш каршына бергә.
Ике җирдән
аерым-аерым ике бүлмә —
гомер бакый —
икебез
барып кергәнгә чаклы
аерым-аерым
ике гүргә!

Инангандай
безнең уртак көннәрнең
мәңгелеккә инде кайтмасына,
кадаклап куйдылар безне
белдерүләр тактасына!

Чат башына...

## Төштә күрдем сине...

Үткән төндә төштә күрдем сине:
мин каршыңа, имеш, чабамын.
Кыска гына төшемә нигә кердең?

Бик күрәсем килә дәвамын...
Бик күрәсем,
бик күрәсем килә дәвамын.

Болын буйлап каршы килә идең,
кулым сузып, сиңа үрелдем.
Арабызга төште ташкын сулар,—
син тауларга китеп күмелдең.
Син тауларга,
син тауларга китеп күмелдең.

Тау артыннан килә синең җырың,—
ерагая бара, үткәнгә.
Мин кузгалмый шунда басып торам,—
сабырлыклар бирсен көткәнгә!
Сабырлыклар,
сабырлыклар бирсен көткәнгә!

Үткән төндә сине төштә күрдем:
мин каршыңа, имеш, чабамын...
Кыска гына төшемә нигә кердең?
Бер күрермен микән дәвамын?
Бер күрермен,
бер күрермен микән дәвамын?..

Узып киткән очкычларның
тавышлары соңга кала...
Тавыш тизлекләрен узып,
безнең гомер бара алга.

Гомерләрнең авазлары
артта кала, артта кала...
Фида җаннарның гомере
юл күрсәтеп дөрләп бара.

Яна гөлтләп! Яктылыкның
тизлекләре артта кала.
Йөрәкләре метеор кук
сызылып оча —
яна-яна!..

## Көзге тургай

Күкләр биегәеп, көн яктырды —
һаваларда
әллә ничә кояш диярсең!
әллә кабат җәй башланды диеп,
тургайларның бөтен гаиләсе
күтәрелде дәррәү көн каршына,
табылды дип, язгы җыр башы!
Сайрап карадылар. Чыкмады көй...
Ишетелде бары чыр да чу!..

Бүз тургаем көн дә җыр каршына
оча-оча күңелен көйрәткән.
Онытылган вакыт! Үткән җәйләр
алып киткән моңны йөрәктән!

Ә язларын ничек сайрый иде!
«Ут чыгара» иде күкләрдән!..
Тиңсез моңнарның да чиге була.
Сабак булыр бу да күпләргә...

Онытылганмын мин дә яз куенында,
рәхәт калгып, җәйләр үткәнен
сизмәгәнмен. Китеп күмелгән бит
көн артына — минем көткәнем...

Көтеп тормас бит ул кырыс вакыт.
Ул искәртеп тора әле дә;
Мәхәббәт! дип җырламакчы идем,
калдым... көзге тургай хәленә!..

# Җилдерә ат...

I

Солы кыры борчак белән катыш,
тургайлары сайрап армаган!..
Бу — Балачак иле! Яшел кырга
сикереп төшеп калдым арбадан.

Ат юыртып китте. Күрше агай
үрдә көтте атын туктатып...
Муенымнан йөрим солы ерып...
(төшкә керә шулай күп вакыт!)

Башын кыңгыр салган, җырлый агай...
«...чыккан чакта туган иллэрдән...»
...Ат пошкыра әле дә...
Борчак катыш
солы исе килә җиллэрдән!

II

...Җилдерә ат, җырлый агай,—
күрше үрдә авазы...
Мин бер малай әле, миңа
чабасы да чабасы!..

Үрне төшкәч җитәрмен күк
(сабый дип карамасын!),
каршыма чаба, кул изәп,
күрше үр карамасы!

Кала зират каеннары,
күрше авыл ызаны...
Ат пошкыра, офыкларда
олы юлның тузаны!

Җилдерә ат, сизелми дә
күпме вакыт узганы...
Җилләр белән ишетелә
агайның җыр сузганы:
«Олы юлның тузанын...»

Җилдерә ат, мин дә чабам,
житеп булмый һаман да...
Җилдерә ат: тәгәрмәчләр
әйләнделәр табанга...
Җилдерә ат! Җырлый агай
инде карлы яланда!

Җилдерә ат! Җилә вакыт,
Җырлый агай, мин чабам:
үргә менәм, сулар кичәм,—
көн югалтып юл табам!
Ат пошкыра,
җил сызгыра,
агай җырлый,
мин — чабам:
җитмәсәм җитмәм,
җилдерсен,
әйдәсен иде һаман
яңа үрләргә табан!
Чакрым баганаларыдай
алышынып тора заман,
атылып кала елларым
олы юллар чатында.

...Җилдерә ат
чорлар аша
яңа үрләр артына!

## Фәнис Яруллин

# КЫЙГАК, КЫЙГАК КАЗ КЫЧКЫРА

ПОВЕСТЬ

### 1



Урамнар трактор эзе белән яргаланган. Бары тик капка төпләрендәге эскәмия асларында гына яшел-лек күренә. Әнә шул тигезсез урам буйлап бер каз бара. Ул, нәрсәгәдер хәвефләнгәндәй, озын муенын алга сузган. Аяк астындагы юлга карамый, шуңа-дыр күрәсең: әле түмгәккә абына, әле трактор эзенә төшеп китә. «Кыйгак, кыйгак!» — дип кычкырып куя үзе. Ләкин башка казларның аңарда гаме юк. Чөнки аларның кырыйларында, пип-пип килеп, сөйкемле бәбкәләре кайнаша.

— Кыйгак, кыйгак!

Бәбкә чыгара алмаган бичара казның тавышы кешеләрнең биек коймаларына бәрелеп хәлсезләнә, юкка чыга. Ишегал-дында һәм тыкрыкларда бәбкә саклап ятучы балалар, бу каз монда килеп кушыла күрмәсен тагын, я бәбкәләрне чукыр дип, каз якынлаша башласа, мунчаладан ясалган пумалаларын болгый башлыйлар.

— Кыйгак, кыйгак!

Урам коесына суга дип чыккан хатыннар каз күздән югалганчы карап калалар.

— Кем казы икән?

— Карт казга охшый. Муеннарында, түшләрендә мамыгы коелып беткән.

Аннары сүз башка нәрсәләргә күчә.

— Малик малае өйләнгән ди.

— Кит аннан? Кемне алды икән?

— Шәһәрдән алып кайткан ди.

— Алайса Малик малайсыз калган икән. Алып китәчәк, менә мин әйтте диярсез.

— Колхозда эшлим дип әйтә ди бит. Председатель теге яңа салдыр-ган өйне бирәм дип әйткән ди үзләренә.

— Бирер, бирер. Шәһәрдән кайтканнарга бирә ул. Гомер буе колхоз йөген җигелеп тартканнарга гына бирми юк.

Кемдер хатынның бу сүзе белән килешә, кемдер килешми. Бәхәс

---

*ФӘНИС ЯРУЛЛИН (1938) — шагыйрь, прозаик, драматург. Дистәдән артык китап авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

кузгалып куя. Сулы көянтә-чиләкләр иңнәрне баса, ләкин, авыл хәбәрләре сөйләнеп бетми торып, беркемнең кузгалып китәсе килми. Ком арасыннан ялтыравык кабырчык эзләгән балалар сыман, һәркайсы үзенең хәтер катламын актара. Әгәр инде башкалар ишетмәгән хәбәр табып алса, комнан кабырчык тапкан баладан ким сөенми.

Инде таралырга дип торганда, арадан берсе иң кызыклы хәбәрне тапты ахрысы, көянтәсен икенче иңенә күчереп:

— Сез ишеттегезме әле, Сәхи кайткан бит,— диде. Бусы инде Малик малаеның өйләнүе генә түгел иде. Күзләрдә кызыксыну очкыннары кабынды.

— Исән микәнни әле ул?

— Шайтан таягына ни булсын...

Авыл хатыннары иңнәренә көянтә-чиләкләрен аскан килеш озак сөйләнделәр. Кое янына килүче һәр хатынга әлеге хәбәр житкерә торылды. Берничә сәгатьтән инде Сәхинең кайтканлыгы турында авылның барлык өлкән кешеләре белә иде. Яшьрәкләр генә:

— Кем соң ул Сәхи? — дип сорау бирәләр. Мондый сорау бирүчегә өлкәннәр шундый гажәпләнгән күз белән карый ки, әйтерсең сүз бөтен дөньяга билгеле булган космонавт яки атаклы галим турында бара, әйтерсең Сәхинең кем икәнен белмәү — зур гаеп. «Сәхи кем?» — дип сораучы яшьләр мондый караштан соң оялып, кыенсынып тын калалар. Төпченергә батырчылыклары житми. Кемнең инде үзенең белмәгәнлеген кешегә күрсәтәсе килсен?

Ә Сәхи үзе турында бөтен авыл сөйләгәнне гүя ишетми. Озын күн пальтосын иңенә салып капка төбенә чыгып утыра, зиратларны әйләнеп кайта. Күңел төбендә нинди дер уе барлыгы әллә каян күренеп тора. Хәер, уйсыз кем бар соң? Чит жирләрдә, ят якларда озак йөреп, үз нигезенә кайткан кеше күңелендә нинди уйлар кузгалмас? Ә Сәхигә шактый йөрергә туры килде.

Чынлап та кем соң ул Сәхи?

Бу сорау чит кешеләр күңелен генә түгел, Сәхинең үз җанын да борчып тора. Кем мин? Ничек яшәдем?

Сәхи, дөресрәге, Сәхия, шушы авылда туып үсте. Әниләре сугышка кадәр үк бик яшьли үлеп китте. Сәхия белән Сәкинә әтиләре кулында калдылар. Әтиләре Локман колхозда арбадыр, чанадыр ныгыта, сынган тәртәләрне алыштыра, кыскасы, балта эшендә эшли иде. Сәхия, әтисенә ияреп, бригадага барырга ярата. Анда ул иң элек ат абзарына кереп чыга, бигрәк тә нәсел айгыры Күзен яндыра аның. Сәхиянең шул айгырга атланып, авылны урыйсы, болыннарны иңлисе килә. Ләкин әтисе кызының теләген ишетергә дә теләми.

— Чү, чү, кызым, чү! — ди ул, атлар тирәсендә кайнашкан кызын күреп.— Тибеп җибәрсәләр, гомерлеккә имгәтерләр үзеңне. Алла сакласын!

Әмма Сәхия әтисенең сүзенә колак салмый. Аранга кереп, атлар койрыгыннан кыл йолкый, кылларын йолыккан саен, атларның чәбәләнеп куюлары аңа кызык кына. Ул үзе йолыккан кылдан камчы ишә, аннары шуны көннәр буе шарт-шорт шартлатып йөри. Әтисе аңа:

— Сиңа малай булып туасы калган, ялгышкансың,— ди.

— Ялгыштым шул,— ди Сәхия әтисенә чын-чынлап үпкәләп.— Малай булсам, син мине кара айгырга атландырыр идең.

— Әй алла, исең китте инде шул кара айгырга! Күреп торасың бит, усал ул. Өстенә атланган егетләрне дә чөеп кенә ыргыта. Беркөнне әнә Нуриман малаен мәчет тыкрыгындыгы баганага бәреп калдырган. Ярты сәгать исәңгереп яткан мескен. Әле һаман күз төпләре күгәреп йөри. Ә син кара айгыр дисең...

Сәхия кара айгырның усал икәнлеген белмимени? Нәкъ менә усал булганы өчен кызыга ул аңа. Һич югы койрыгыннан кыл йолкып аласы иде бер. Әмма кара айгыр әкәмәт сизгер: янына бара башласаң, колак-

ларын тырпайтып куя, күзләре фонарь кебек яна башлый, танау тишекләре киңәя. Йотарга җыенган аждаһа диярсең. Мондый чакларда Сәхия түгел, өлкән агайлар да аңардан ераграк йөрергә тырышалар. Тик Сәхиянең үз көчсезлеге белән килешәсе килми. Җитмәсә аны малайлар гел котыртып торалар.

— Һи, минем әти бригатта эшләсәме? Кара айгырны биетеп күрсәтер идем.

— Син белмисеңмени? — дип бүлә икенче малай.— Кара айгыр бит яулыклы кешеләрне яратмый.

Малай үзенең тапкырлыгыннан үзе көлә башлый. Аңа башкалар иярә. Үзләренең малайлыклары белән Сәхия алдында мактанып алырга җай чыгуына һәркем шат.

Сәхия малайларның бу сүзләренә бик үртәлә. Кайвакыт эшләр сугышуга кадәр барып җитә. Әмма киребеткән малайларны Сәхиянең кечкенә йодрыклары гына куркытамы соң? Үртәлгәнеңне күргән саен, ныграк үрти алар.

— Әти,— ди Сәхия беркөнне,— миңа кепка ал әле.

— Бусы нәрсә тагын? — ди ата кеше гаҗәпләнеп.— Кыз балага ниемә ул кепка? — Сәхия ык-мык килеп баскан урынында таптанып тора. Серен әтисенә чишәсе килми. Кара айгыр яулыклы кешеләрне якын җибәрми икән дисәң, әтисе мәңге кепка алып бирмәячәк. Болай да, атлар тирәсенә бара башласаң, коты чыга. Хәйләнең ышандырырлыгын уйлап табарга кирәк.

— Ни бит, әти,— ди ул,— кепканың бит козырегы бар. Әминем кояшта күз чагыла. Беркөннәрне кояшка каршы барганда, күз чагылмасын дип, күзләрне кысып бара идем, бригат капкасына килеп бәрелгәнмен. Күздән утлар очты.

Атасы кызына сынаучан караш ташлый: «Берәр хәйлә кормыймы бу кызыкай?» Шулай да Сәхиягә кепка алып бирә. Сәхия, башына кепка киеп алгач, батыраеп киткәндәй була. Кара айгыр янына курыкмыйчарак килә башлый. Ләкин никадәр батыраймасын, айгырның елкылдап торган сыртыннан сыйпау бәхете эләкми. Айгыр аңа: «Мине бик яратсаң да, читтәрәк йөр, юкса тояк астына кереп, көлчә булуың бар»,— дигән шикелле утлы күзләре белән карап куя.

Бүтән кеше бәлки әллә кайчан бу ниятеннән ваз кичәр, башка уен белән мавыгыр иде. Сәхиянең исә үҗәтлеге арта гына барды. Болай гына эшләр пешмәячәген аңлагач, хәйлә белән алдырмакчы булды.

Кара айгырның улагы абзарның нәкъ өрлек астында иде. Сәхия әнә шул өрлек өстенә менеп ятты да, айгыр улакка иелгәч кенә сузылып, тегенең койрыгыннан берничә кыл йолкып алды. Айгыр капкан башагын чәйнәүдән туктап як-ягына каранды. Аның бөтен карашы: «Бу нинди оятсызлык? Кайсыгыз минем тынычлыгымны бозарга җөрьәт итте?» — ди кебек иде. Сәхия пырхылдап җибәрүдән чак тыелып, эченнән болай дип уйлады: «Мин сине үзем белән санлашырга өйрәтәм әле. Иха-хай диясе урында, Сәхиякәй ди башларсың». Һәм айгыр тынычланып ашый башлауга, тагын тегенең койрыгыннан берничә кыл йолкыды. Кара айгыр бу юлы кушаяклап тибенеп җибәрде. Әгәр ул әз генә акыллырак булып, артын чөясе урында, киресенчә, арт тәпиләренә басып, муенын югарырак сузса, үзен җәберләүчене үткен тешләре белән каптырып алачак иде. Әмма табигать гайрәт биргәнгә акылны артык чумыруны кирәк тапмаган. Сәхия кара айгыр тикле җан иясен үрле-кырлы сикертә алуы белән бик бәхетле иде. Айгырның койрыгыннан йолкынган кылларны малайлар алдына салганда, ул үзен әкият батырыннан ким сизмәде.

— Кара айгыр кылы түгел бу,— диде малайлар ышанмыйча.

— Сиңа койрыгын йолкыттырып торса, нинди айгыр була ди ул! Әллә аны тешсез алаша дип белдеңме?

Сәхинең күзләреннән яшьләр атылып чыкты. Үзеңнең кылган эшеңне күрсәтү, кешеләр алдында раслау ул эшне эшләүгә караганда да

кыенрак иканен Сахия белми иде шул әле. «Теләсәм, мин кара айгырның колагын кисеп ала алам. Белдегезме?» — диде ул шик белдерүләренә бик рәнҗеп.

Малайлар тәгәри-тәгәри көлделәр. Көлеп туйгач, Хәйдәр исемле төптән чыккан малай:

— Әгәр дә мәгәр айгырның колагын кисә алсаң, мин сиңа көпә-көндез Хәбибулла абзыйларның кыярын урлап ашатам,— дип әйтеп салды.

Хәбибулла абзый кырыслыгы, катылыгы белән авылда бер кеше иде. Ел саен кыярын, помидорын, кишерен-шалканын күп итеп үстерә. Тик аның бакчасына беркем керә алмый: беренчедән, ихатасы бик нык — малайлар түгел, чебен дә очып үтә алмаслык. Икенчедән, Хәбибулла абзый кулына эләгүнең ни икәнен малайлар яхшы белә. Белмәгәннәр әнә Фатихтан сорый ала. Ул былтыр Хәбибулла абзыйның кыярын татып карады. Хәзер әнисенең яңа аерткан бал ягып биргән кыярын да ашамый ди. Югыйсә аны Хәбибулла абзый кайберәүләр кебек кыйнамаган, колагыннан сөйрәп, әнисенә дә алып бармаган. Фатихның кесәләренә, күлмәк изүләренә тутырган кыярларын алдына өеп куйган да: «Аша!» — дигән. Фатих ашамый икән. «Бәлки сиңа юып бирергәдер»,— дигән Хәбибулла абзый һәм ишегалдындагы комганнан су агызып, кыярларны әйбәтләп юып куйган. «Инде ашарсың бәлки»,— дигән. Фатих нишләсен инде, бер кыярны ашаган. Ә Хәбибулла абзый аның саен кыстый икән: «Аша-аша, тартынма. Урлап алганда кыенсынып тормагансың бит». Фатих яшенә төелә-төелә, тагын бер кыярны ашаган. Хәбибулла абзыйның кыставына каршы ул ишетелер-ишетелмәслек тавыш белән: «Бүтән ашый алмыйм, туйдым»,— дигән. «Юк инде,— дигән Хәбибулла абзый,— рас син аларны ашарга дип җыйгансың икән, берсен дә калдырмыйсың. Шунсыз сиңа моннан чыгу юк». Шулай дип, Хәбибулла абзый капкаларын эчтән бикләп куйган. Үзе исә утын кисәргә тотынган. Картлач берәр җиргә чыгып китсә, Фатих бу кыярлардан котылу чарасын тиз табар иде әлбәттә. Тик алдарсың Хәбибулла абзыйны! Аның күзләре тилгәннекеннән очлырак. Үзе ул бөтенләй сиңа карамаган төсле, ә үзе һәрбер хәрәкәтеңне күреп тора. Фатих әз генә кымшана башласа, балтасын бүкәнгә чабып, моңа карап куя икән.Фатих Хәбибулла абзыйның күңелен йомшартмакчы булып: «Өешимме?» — дип, утынга барып ябышкан икән: «Мин башта кешене туйганчы ашатам, аннары гына эшкә кушам»,— дип, утынны өйдермәгән. Фатих кыбырсып-кыбырсып куйган. Өйгә кайтасы, бозау карыйсы бар. Кайткач, тагын әнисеннән эләгәчәк.

Хәбибулла абзый моның каршысына килеп чүгәләгән дә: «Нәрсә, тамактан үтмимени? — дигән.— Үтмәс шул. Урланган әйбер тиз туйдыра. Ә син әнә туймастай кылангансың. Менә хәзер ашап бетер инде. Әгәр кыяр тотып ашарлык хәлең калмаган булса, үзем тотып ашатам»,— дигән. Һәм, сарыкка ипи каптырган кебек, Фатихка кыяр ашаткан. Тәки ашатып бетерткән бу. Шуннан соң капкасын ачып: «Инде кайт та әниләреңә әйт, Хәбибулла абзыйның фәлән хәтле кыярын ашадым, диген»,— дигән.

Хәйдәр менә шушы Хәбибуллаларның кыярына кермәкче. Җитмәсә көпә-көндез. Билгеле, ул Сәхиянең айгыр колагын кисә алмаячагына нык ышанганга әйтте бу сүзләрне. Карап карыйк, Сәхиянең моңарчы үз сүзен үтәми калганы юк иде әле.

Әтисенең бик каты хәтерен калдырачагын белде Сәхия, ләкин малайлар алдында да сынатасы килми иде. Һәм ул тәвәккәлләде: кесәсенә сарык йоны ала торган кайчы тыкты, аяк киемнәрен салып атты да абзарга кереп китте. Ә абзар өрлегенә менү аның өчен берни тормый иде. Ике сикереп, өч атлауга, ул инде өрлеккә менеп сузылып яткан иде. Кара айгыр бернидән шикләнми, керт-керт башак ашый. Сәхиянең утлы күзләре аның сыртын бораулый. Их, шушы елтырап торган сыртка төшең белән сузылып ятарга, хәер, юк, нярсез-нисез атланып, айгырны ак күбек-

кә батырганчы чабарга иде. Тик бу мөмкин эш түгел, этисе ул турыда ишетергә дә теләми.

Сәхия, өрлеккә ни өчен менгәнен онытып, шактый ятты. Айгырның һәр хәрәкәте сокландыргыч һәм килешле иде. Хәтта вакыт-вакыт башына кунган чебеннәрне куар өчен, колакларын селкетеп алуы да матур иде. Әйе, айгырның колагын киссәң, нәкъ менә шундый чакта гына кисә аласың. Чөнки колакларын шомрайтканда ул башын югары күтәрә, өрлеккә якыная. Һәм Сәхия югалып калмады, өрлектән түбәнгә үрелеп, айгырның колак очын кыртлатты да алды. Кара айгыр абзарны ишеп төшерердәй итеп кешнәп җибәрде, шашкын көч белән тибенде. Әгәр Сәхия курыкса яки башы әйләнеп өрлектән егылып төшсә, ул егылган урында бары тик юеш нокта гына калган булыр иде. Тик Сәхия егылмады, айгыр бераз тынычлана төшкәнче, өрлекне бөтен көченә кочаклаган килеш кымшанмыйча ятты.

Урамга малайлар янына чыккач кына үзендә бераз баш әйләнү сизде. «Барыгыз,— диде ул кипшергән иреннәрен ялап.— Айгырның колагын кереп карагыз». Малайлар ышанмыйча абзарга йөгерделәр. Ә абзардан чыккан чагында Хәйдәрнең борыны салынган иде. Малайлар аны үртәргә тотындылар:

— Кыярны кайчан ашыйбыз, Хәйдәр?

— Хәбибулла абзый — кыярларымны Хәйдәр җыеп чыкса ярар иде дип утыра ди анда.

— Коймадан керәсеңме, капкаданмы?

— Койма башына менәргә арты авыр, астан керергә корсагы сыймый.

— Ә капкадан керергә йөрәге җитми. Корсак зур булса да, йөрәкнең бәләкәен куйганнар сиңа.

Малайларның сүзенә үпкәләмәде Хәйдәр. Дөресен әйткәндә, аларны ишетми дә иде. Аның үз кайгысы кайгы. Авызың әйткәнне колагың ишетмәсә, шулай була ул. Ә Сәхиягә килгәндә, ул бик бәхетле иде. Хәбибулла абзыйларның кыярын ашамаса да, күңеле күкнең җиденче катында иде. Хәтта бу эше белән этисен бик каты рәнҗетәчәген дә онытты ул.

2

Әтисе тирәсеннән ераграк йөрергә тырышты Сәхия. Инде ул кызының үтлеген сизенгәндер, менә-менә күзеннән яшь чыгар дәрәҗәдә үпкәләр, кешеләргә күтәрелеп караудан читләшер, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр балтасыннан аерылмас дип көтте. Тик, ни хикмәттер, этисе соңгы вакытта үз тирәсендә кайнаган тормышны күрмәде. Сәхиянең урамда малайлар белән сугышуына да, киемен ертып кайтуына да әһәмият бирмәде. Әйе, ата кешенең үз борчуы борчу иде. Ул сугышка китәргә повестка алып кайтты. Инде сугыш бетүгә таба барганда, илебезнең әле бу шәһәрен, әле теге шәһәрен данлы армиябезнең азат итүе турында хәбәрләр ишетелеп торганда үзе кебек күзлекле кешегә мохтаҗлык беткәндер, дип уйлаган иде Локман. Сугышның нинди авыр чакларында ничәмә-ничә тапкыр кире борып кайтардылар бит югыйсә.

Сугышка китүенә болай пошынып идемени ул? Фронттагылар эшләгәнне эшләп, кешеләрнең күзләренә туры карап яшәүгә ни җитә? Болай да сугыш чыкканнан бирле Локман авылдашларының йөзенә күтәрелеп караудан тартына башлады. «Менә безнең ирләребез, улларыбыз яуда, ә син өрлектәй ир — монда йөрисең. Балта чабу да булдымы эш!» — дип әйтерләр кебек тоела иде аңа. Кызлары аннан башка нишләр? Шул борчый Локманны. Хәтта кесәсендә йөргән повестка турында әйтергә дә батырчылыгы җитми аның. Сәкинәсе бу хәбәрне ишетүгә мышык-мышык елый башлаячак. Ә Сәхиясе: «Әти, мин дә синең белән барыйм әле», — ди башлар. Әйтерсең, ул кунакка бара. Их, әнкәләренең гомере кыска

булды. Яннарында әнкәләре йөргәндә, каз бәбкәсенә дә тилгән ташланмый. Аның кызлары канат чыгармаган каз бәбкәләреннән артык түгел шул әле.

Күрше-тирәләргә әйтте инде Локман үзенең сугышка китәсен. «Бөтен ышаныч синдә, Зәйнәп әби,— диде үзләреннән ике өй аша яшәүче Зәйнәпкә.— Берүк күз-колак була күр».

Китәр көне җиткәч кенә Локман бу хәбәрне кызларына әйтә алды. Башта ул аларның икесен ике ягына утыртып сөйде. Аннары, күзлегем парланды дигән булып, күзен сөртеп алды, шуннан соң гына: «Мине сугышка алалар, мин китәм инде, балалар».— диде. Нәкъ Локман уйлаганча, Сәкинә мышык-мышык еларга тотынды, ә Сәхия әтисенең кочагыннан атылып чыгып: «Шәп булган, эти,— диде.— Әнә теге Габдулла абзый кебек орден апкайт. Синең орденнарыңны мин тагып чыгып малайларның күзен яндырырмын. Ату, бер нәрсә булса, синең этиеңнең буыны черек, җүнле кешеләр күптән инде сугышка киттеләр инде дип үртиләр. Ә хәзер үртәп кенә карасыннар!»

Сәхия әтисенә әйберләр тутырышты. Берара җай табып:

— Сугыш нәрсә ул, эти? — дип сорады.

— Сугыш... кешеләрнең акылсыз эше,— диде Локман озак уйлаганнан соң.

— Син сугышта нишләрсең икән, эти?

— Балта тота белгән кулны мылтык тотарга да өйрәтерләр, кызым.

— Берәр фашистны чәкү белән миңа яз, эти, яме?

— Миңа чәкетеп торсалар, язармын.

— Бер фрицне дә чәкемәгәч, барып та йөрмим мин анда.— Сәхиянең үз этисен бик герой итеп күрәсе килә иде. Авылдагы бүтән ирләр кебек я бригадир, я председатель, һич югы берәр атлы эштә эшләмәвенә дә эче поша, һәм, безнең эти кешеләргә кычкыра белми, шуңа андый җирләргә куймыйлардыр дип, үз-үзен юата иде.

Локман көз көне китте. Бакчада бәрәңгеләр алынып беткән, колхоз игеннәре бөтенләй диярлек урылган, көлтәләр зур-зур эскертләр итеп ындыр янына ташып куелган, инде кыш буе ат молотилкасында сугасы гына калган иде.

— Кыш ашарыгызга бәрәңгегез бар, шөкер,— диде Локман.— Сәкинә кызым, син укуыңны нишләтерсең икән инде? — Сәкинә авылда җиде классны тәмамлап, быел гына район мәктәбенә сигезенчегә йөри башлаган иде. Ул әтисенең соравына җавап бирмәде, бары тик җебегән борынын гына тартып куйды. Кызына биргән сорауга ата кеше үзе үк җавап кайтарды:

— Колхоз эшенә йөрергә туры килер сиңа, кызым. Тамак туйдырырга кирәк бит. Менә, алла бирсә, сугышларны бетереп кайткач укытырмын. Башың бар. Ә Сәхия әле яшьрәк, укуын ташламас.

Локман кызларының үзеннән башка яши алуларын һич күз алдына китерә алмады. Өйдә бер иплек он юк. Бригадада эшләп йөргәндә көненә өч йөз грамм булса да ипи алып кайта иде. Бөтен карап торган нәрсә бәрәңге. Ә өс-баш? Ә утын?

Ата кешенең күзләрен тагын яшь каплады. Халыкның җелеген төрле яктан суыручы сугышның һаман бетмәвенә эчендә ачу кайнады. Күпме ирләр сугышта ятып калды. Ә бит аларны еккан пулялар, снаряд ярчыклары монда тагын нич әмә-нич ә кешеләрне яралый. Күпме кешеләрнең йөрәге җәрәхәтле. Әгәр аңа ул-бу була калса, буыннары да ныгып җитмәгән кызлар нишләр? Аңа тигән пулядан кызлары егылмасмы?

Авыл башына чыгып җиткәнче шушы уйларыннан арына алмады Локман. Ике ягыннан атлап баручы ике кызына әллә нинди акыллы киңәшләр, файдалы сүзләр әйтеп калдырасы килде. Ләкин гомер буена җитәрлек акылны, үзгәрми торган киңәшне каян аласың?

Саубуллашканда, гадәттә, иң кирәкле сүзләр онытыла. Локман да: «Сәхия кызым, күлмәгеңнең төймәсе төшкән икән, кайту белән тагып куй»,— дигән сүзләрдән акыллырак сүз таба алмады.

— Ярар, эти, тагармын,— диде Сәхия, төймә тишегенә бармагын тыгып. Әтисенең күз алдында кызы мәңгелеккә шулай — төшкән төймә тишегенә бармагын тыккан килеш сакланып калды. Арбага менеп утырганнан соң Локман:

— Утынга нишләрсез икән инде, балалар? — дип кычкырды.

— И-и, эти, аптырама,— диде Сәхия күңелен төшермичә.— Бригатта иске арба, эрәмәдә чыбык бетмәс әле.

Әтисе бригадада балта остасы булып эшләгәч, алар моңарчы утынга кытлык күрмәделәр. Йомычкасын, иске арба тартәсен дисеңме — гел алып кайтып тордылар. Көннеке көнгә җитеп баргач, аларга күпләп утын әзерләүнең хаҗәте юк иде. Сәхия, әтисе киткәч тә тормыш шулай барыр, дип уйлый иде. Ләкин этиләре юклык бик тиз үзен сиздерә башлады.

Гадәттәгечә, Сәхия бригадага йомычкалар җыярга барган иде. Арбасына бер кочак нәрсә салырга өлгермәде, каяндыр Титак Габделхак килеп чыкты да Сәхия янына килеп басты. «Нәрсә, урлашырга килдеңме? — диде ул, ямьсез күзе белән Сәхияне ашардай булып.— Колхоз малын урлыйбызмы?»

— Мал түгел ул, йомычка,— диде Сәхия.

— Ә-ә, шулаймыни? Мал түгелмени? Бәлки әле син урлашмыйсыңдыр да, ә?

— Урлашмыйм шул.

Титак Габделхак Сәхиянең арбасындагы йомычкаларны җиргә сибереп төшерде. Аннары бераз вакыт арбага бәйләнгән каешка карап торды.

— Ә-ә, әле син колхозның аркалыгын да чәлдеңмени? — Ул каешны чишә башлады. Шул вакыт Сәхия чырылдап аның кулына барып ябышты һәм тешләрен Габделхакның кулына батырды. «Тотынма каешка, әтинең чалбар каешы ул»,— дип ысылдады үзе. Титак Габделхак кулы авыртуга түзә алмыйча каешны ычкындырып җибәрде. Аның кул аркасында Сәхиянең дүрт теш эзе ярылып калды.

Сәхияне ай күрде, кояш алды.

Әтисеннән сирәк кенә хатлар килгәләп тора иде. Әтисе исә кызын юатып: «Кызым, Габделхак абзаң алай начар кеше түгел, әле син аны аңламыйсың. Кешеләрнең күңелен менә бу ләгънәт сугыш тупасландыра. Ул бит сугышның беренче көненнән үк өч малаен ут эченә озатты. Җаны теткәләнгән чагына туры килгәнсеңдер. Берүк үч алам дип, берәр башсызлык эшли күрмә, кызым»,— дип язды.

Кара инде, әтисе Сәхиянең күңелендәгеп каян белгән диген. Ул бит чынлап та Титак Габделхактан ничек үч алырга икән дип баш ватып йөри иде. Башында бик шәп план да туган иде. Ә план мондый: Габделхак абзыйларның өйләре тыкрык янында, тыкрыкны көрт баса, шул көрт өстеннән генә боларның өй түбәләренә менәсең дә морҗаларына берәр чүпрәк тыгып куясың. Өйгә нишләп төтен чыга дип, тик баш ватсыннар. Ә син рәхәтләнеп көлеп йөрисең. Әйе, бер өйрәтсәң ярар иде. Тыкрыкларындагы таудан чана шудыртмый, ашала дип беләме?

Сәхия эченнән озак вакыт Титак Габделхакны сүгеп йөрде. Яңадан бригадага утынга дип бармады. Йомычкаңны башыңа бөркәнеп йокла, диде ул. Эрәмәдә тал белән каракаен бетмәгән. Ык каткан, кай төштән чыгасың килсә, шунда күпер. Тик менә бәләкәй чана диган нәрсә алай җиңел түгел икән. Эрәмәдә сиңа юл салып куймаганнар. Билдән карга чума-чума, башта куак төпләрен таптарга кирәк. Бер куактан бер кочак, икенче куактан бер кочак чыбык кисәсең, көрт ярып, аларны чана янына ташыйсың. Төяп, кайтырга чыккач кына каршы буран башлана. Ахылдап өйгә кайтып егыласың. Мичкә ягып җибәрерлек тә хәл калмый. Өстәвенә, нигә укырга йөрмисең дип, күргән саен укытучылар җанга тия. Сәкинәнең башы ындырдан кайтып керми. Ашлык сугалар. Шунда ичмасам кесәсенә әзрәк борчактыр, бодайдыр ише нәрсә дә салып кайта белми.

Малайлар белән бергә җыелган вакытта алар болай дип хыялланалар: «Патшаларның өстәлләре түгәрәк икән. Менә шул түгәрәк өстәл генә әйләнеп тора, ә патша әйләнеп килгәнен берсен сыпырып бара. Ә ул түгәрәк өстәлдә конфет-прәннекнең чуты-чамасы юк ди. Ашыйсың — бетми, ашыйсың — бетми.

— Бетмәгән нәрсә буламыни?

— Ялчылары өстәп торгач, бетмәс шул.

— Әгәр дә мәгәр мин патша булсам, туйганчы прәнник ашар идем дә урамда көн буе кикереп йөрер идем,— ди Хәйдәр.

— Синең патша булырга рәвешең килгән инде. Корсак шәп. Бер тәпән катык эһ тә итмичә сыя.

Сәхия гел малайлар белән генә уйный. Кызларның юк-бардан чырык-чырык көлүләре, әзрәк кагылсаң, җебеп төшеп, әнкәләренә әләкләргә йөгерүләре ошамый аңа. Малайлар белән ичмасам кара канга батканчы сугышырга, телеңә ни килә, шуны әйтеп үртәшергә, ә инде сугышып туйганнан соң элеккедән дә ныграк итеп дуслашырга була. Аннары шунысы бар: чебен тимәс чер итәр кызларны елатудан кызык юк. Ә йодрыклары мунча ташыдай каты, башлары өлгергән кабактай шома малайлар белән көч сынашу — үзе бер ләззәт. Сәхиянең иң яраткан уены малайларның бүреген салдырып, җылы бүрегенә кар тутырып, кире шуны хуҗасына кидерү. Чәче пәке белән кырып алынган җып-җылы башка карлы бүрекне кидерәсең дә, такырбаш аны-моны абайлап өлгергәнче, бүрек колакларын чәбәләндереп бәйләп куярга ашыгасың. Мондый чакта, әлбәттә, берәрсе сиңа ярдәм итешә: син бүрек колагын бәйләгәнче, малайның кулларын тотып торыша. Малай чәбәләнә, тибенә, хәтта тешләшә. Ул арада бүрек бәйләп тә куела. Бүрек хуҗасы колакчындагы бауларны өзеп атар иде, бүрек ертылып чыгуы бар — кайткач, әниләреннән эләгәчәк. Малай теше белән бүрек бавын чишкәнче, чәчсез башта кар эреп, җилкә чокыры буйлап аркага төшә башлый. Менә иң кызыгы шунда инде! Дөрес, Сәхиянең үзенә дә эләгеп тора: яка астындагы карны әз эретми ул, тукмакны да малайлардан ким алмый... Тик аның хәзер малайлардан бер өстен ягы бар: өйгә кайткач сүгүче юк. Юешләнеп кайткан киемнәреңне, кайтып керү белән, мич башына тондырасың. Кипсә — кипкән килеш, кипмәсә — юеш килеш алып киясең. Апасы өчен Сәхия әллә бар, әллә юк. Соңгы вакытларда ул әле үзе үзгәреп китте. Эштән кайтып кердеме — өстен-башын алышып, көзге каршына килеп утыра. Мичкә яккан чак булса, күмер өстендә бияләй энәсе кыздырып чәчен урый. Кызган энәгә уралган чәч көеп, сынып чыга... Тик бу Сәкинәне һич пошындырмый: чөнки сынган чәч барыбер бераз вакыт бөдрәләнеп йөри. Маңгай чәчләрен бөдрәләндереп яулык астыннан чыгарып салгач, үзенә ул бик чибәрләнеп киткәндәй тоеладыр.

Апасының бу кыланышларыннан Сәхия рәхәтләнеп көлә.

— Синең бу бөдрәләреңне күргәч, бөтен егет тәгәрәп үләр инде.

— Күп лыгырдама.

— Маңгай бөдрәләрең чабата мыекларың белән бик пар килгән.

Сәхия, бер үртәшә башласа, туктый белми. Бигрәк тә Рәмзи белән үртәргә ярата ул апасын.

Рәмзи — гармунчы егет. Сәхияләргә еш килә. Һәр кич үзенең өч бакалы тальянын шыңгырдатып боларның капка төбендә була.

Чәчең чылбыр, чәчең чылбыр,
Тартып өзәрлек түгел;
Чәчең чылбыр, үзең былбыл,
Күрми түзәрлек түгел,—

дип җырлый-җырлый, гармунын тартып җибәрсә, Сәкинә тизрәк ишеккә ташлана. Ә ишекне бер ачтыргач, утка җыелган күбәләкләрдәй, егетҗилән җыела. Урының гына җитсен. Гармун бар җирдә — егетләр, егет-

ләр бар жирдә кызлар булмый калмый. Аннары үзеннән-үзе мәзәк сүзләр ява, уен-көлке, жыр башлана. «Йөзек салышлы» уйныйлар. «Сөю хаты» дигән уен аеруча еш уйнала. Яшьләр сәкегә, эскәмияләргә утырышалар. Елгыррак, сүзгә остарак берәр егеткә уенны алып бару тапшырыла. Ул өчпочмаклап бөкләнгән дәфтәр битен берәр кызның кайнар учына китереп сала да болай жырлый:

Суда сусар үстердем,
Шуннан бүрек тектердем.
Сезкиләргә безкиләрдән
Сөю хаты китердем.

Кыз хатны укыган сыман итә һәм үзе дә жыр белән жавап кайтара:

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Бибигыйльми.
Коча белмәгән егеткә
Ярлар буласым килми.

Кызның төртмә жырыннан соң егет, батыраеп китеп, аны кочмакчы була, тик шулвакыт чүгәләп утырган берәр егет кинәт өскә калка һәм кыз әлеге егетнең кочагына керә. Өйнең түшәмен күтәрерлек көлеш китә.

Аулак өйнең иң кызган чагында Зәйнәп әби килеп керә. Ул кайбер хатыннар кебек яшьләрнең һәр кыланышына чәчрәнләп чыкмый, ипле генә итеп:

— Күңел ачабызмы? — ди.

— Әйе, әбекәй, әйдә түрдән уз.

— Утырган чак та булыр, ә хәзер таралырга вакыт. Кузгалыгыз, кузгал. Менә бу балаларның йоклыйсы бар. Сәкинәгә иртүк эшкә, Сәхиягә — укырга. Ул әле сабагын да укымагандыр...

Үзләре генә калгач, Зәйнәп әби Сәкинәләрне әрләп ала:

— Сез үзегезне бик алай басымчак иттермәгез. Аулак өйне көн дә ясамыйлар аны. Уеннан уймак чыкмасын.

Сәкинә каршы әйтми, Зәйнәп әби белән килешеп баш кагып тора. Ә күңелендә ризасызлык: «Йөрисең шунда эч пошырып». Рәмзи белән бер авыз сүз алышмый калуына ачулы ул. Сәхия исә аулак өйдә әллә ни кызык күрми иде. Моңардан үзенчә бер файда чыгарырга уйлады ул.

— Менә нәрсә,— диде ул апасына.— Бу бүлтерек тәкәләрне тиккә жыйганчы берәр файдаларын күрергә кирәк. Жылы өйдә бугаз киереп утырасылары килсә, тапсыннар утын. Кеше саен бер ярка алып килсәләр дә ярый ул. Эт сугарып йөреп, бөтен өйнең жылысын чыгарып бетерәләр.

— Ярар, ярар,— диде Сәкинә.— Бик алай шәп булгач, әйтерсең.

— Әйтермен шул. Әллә куркып торыр дип белдеңме?

Һәм, икенче көнне Рәмзинең гармун тавышы ишетелүгә, Сәхия ишек төбенә килеп басты.

— Кертмим. Утын алып килмәсәләр, эз бастырмыйм.

Болар турысына житүгә, гармун тавышы ныграк ишетелә башлады. Гармунга кушылып берсе:

Сары сандугач баласын
Сайратамын куенымда...—

дип жырлап жибәрде. Инде шушы урында ишек ачылып китәргә тиеш дип көттеләр. Ләкин Сәхия ишекнең бигенә тотынып: «Сары сандугач баласы кышкы буранда бик матур сайрый ди. Сайратыгыз шунда урамда»,— диде.

— Сәхия үскәнем! — диделәр тышкы яктан.— Апаң өйдә юкмыни? Ач әле.

— Ач булсаң, туеп кил.

Тышта тагын гармун уйнап жибәрделәр. Жыр тавышы да ишетелде. Рәмзи үзе жырлый иде бугай:

Агыйделгә төшеп юдым
Гарәбә ватыкларын.
Ялындырма, ялынмыймын —
Чәчәк күк вакытларым.

Бу җырдан соң Сәкинә ишекне ачарга омтылган иде. Сәхия аның кабыргасына бер генә төртте: «Тик кенә утыр ичмасам. Ачуымны китерсәң...»

— Я инде, ишегеңне ач. Юкса буран бабай куыра.

— Җылынасыгыз килсә, утын алып килегез. Сезнең өчен миңа гына чиләнергә димәгән.

— Күптән шулай диләр аны.

Мичне ул көнне бик кызу яктылар. Мич төбенә бәрәңге дә тәгәрәтеп ашагач, күңелләр күтәрелеп китте. Сәхия шундый шәп нәрсә уйлап табуына аеруча шат иде. Моннан соң ул башта тәрәзә аша егетләрнең утынын карый, аннан гына ишек келәсен күтәрә иде. Ә егетләрнең утынны кайдан табулары аны һич кызыксындырмады. Авылда: «Кемдер зират коймасын урлап яга икән»,— дигән сүзләр таралды. Бу сүзләр Зәйнәп әби колагына да килеп ирешкән иде, ул, пошынып, Сәхияләргә керде.

— Балалар,— диде ул.— Моңарчы авылның йөзен кызартырлык эш кылмадыгыз, рәхмәт. Инде менә яман сүзләр йөри башлады. Зират коймасын егетләр сезгә ташый диләр. Әгәр шушы сүз хак булса, бик-бик хурлык. Үзегез өчен генә түгел, сугыштагы әтиегез өчен, бөтен авыл өчен хурлык бу. Үлгәннәрнең рухын рәнҗетүдән дә зур гөнаһ юк. Тереләр үзләрен яклый алалар, ә үлгәннәр рәнҗи генә. Аларның рәнҗүе төшүдән куркыгыз, балалар.

Зәйнәп әбинең сүзләре Сәкинәгә бик нык тәэсир итте. Ул гөнаһтан бик курка. Әгәр берәр ярамаган эш эшләсә, озак газапланып йөри, күңеленнән андый эшне яңадан кабатламаска антлар итә, ләкин курка-курка, газаплана-газаплана, тагын икенче начарлык эшләп ташлый.

— Синең сүзеңә карап,— дип сукранды ул Сәхиягә. Сеңлесенең генә моңа һич исе китмәде.

— Алай бик гөнаһтан курыксаң, егетләреңә әйт, утынны өйләреннән алып килсеннәр,— ди Сәхия.

Бәхеткә күрә, көннәр язга якынлашып килә иде. Телдән-телгә күңелле хәбәрләр күчә торды. Кешеләр, менә-менә сугыш бетәргә тиеш дип сөйләнделәр. Тик нишләптер кызларның әтиләреннән хат килү тукталды. Бу хакта үзара сүз чыккан чакларда алар:

— Кайтадыр, шуңа язмыйдыр,— диештеләр. Зәйнәп әби дә: «Кайтыр, алла бирсә, кайтыр»,— дип, аларны юатып килә иде. Ләкин кызлар өчен иң авыр көннәр әле алда булган икән. Кайтыр дип көтеп торган әтиләренең «үлде» хәбәре килде.

Башта кызлар тәгәри-тәгәри еладылар. Дөньяда кинәт кызык бетте. Урамда гармун тавышы ишетелүгә ишеккә атылмый башладылар. Сәкинә болай да кешеләр белән рәтләп ачылып сөйләшми иде, бөтенләй йомылды. Сәхия исә үчне үзеннән көчсезрәк малайлардан алды. Мәктәпкә бармады. Үзләренең турысыннан сумка күтәреп үтүче берәр малай яки кыз күрсә, йөгереп, каршысына чыга иде дә тегенең сумкасын актарып, ипиен алып кала, ә инде ипие булмаса, китап-дәфтәрләрен таратып ташлый иде. Әтисенә дә ачулы иде Сәхия. Дан-шөһрәтсез үлеп калуы өчен ачулы иде. Башкаларга язган кебек: «Сезнең әтиегез фашист илбасарларга каршы көрәшкәндә, батырларча һәлак булды» — дип тә язмаганнар ичмасам.

Шундый уйлар әрнетте Сәхия күңелен. «Их, нигә мин малай булмадым икән? Яшем җитми дип тормас идем, качып китәр идем дә фашистларның көлен күккә очырып кайтыр идем. Автомат бирмәсәләр, рогатка белән маңгайларына таш чәпәр идем». Ә рогатка белән ата белә Сәхия. Немец генералларының окоптан баш калкытканнарын гына көтеп тора-

сың да агач башыннан шалт итеп тондырасың. Ике метрлы генералың маңгаен тотып тәгәрәп килеп төшә. Ул генералның тәгәрәгәнен күреп, бүтәннәре йөгереп чыга. Аларына дигән таш та кесәдә көтеп тора. Рогатканың керешен тартып кына өлгер! Иң эре генералларын кырып салгач, вак-төяк фашист нишләсен — билгеле, алары табан ялтырату ягын караячак. Иң кызыгы шунда: бернинди мылтык аткан тавыш юк, ә генераллар тәгәри тора. Бу урын җенле икән дип, яңадан ул тирәгә мәңге аяк басмаячак алар...

Бәлки әле фронтка качып китү уен тиз генә башыннан чыгармаган булыр иде Сәхия, сугыш бетеп куйды. Әй, ул көннең күңеллелекләре! Кемгә карама — иң матур киемнәрен кигән. Урамда сабан туе диярсең. Җырлыйлар, бииләр. Кайберәүләр бераз «төшереп» алырга да өлгергәннәр. Ә Кәлимулла абзый моңарчы малай-шалай күзеннән гел яшереп тоткан патефонын капка төпләрендәге эскәмиягә чыгарып куйган. «Я, кайсыгызның патефон уйнатасы килә? Курыкмагыз, курыкма. Менә моннан борыгыз»,— дип, малайларга үзе өйрәтеп тора. Туктаусыз әйләнеп утырган кара тәлинкәдән малайларга таныш булмаган телдә нииндидер җыр агыла. Ә Зәйнәп әби бер табак күкәй пешереп алып чыккан. Күкәй өелгән табак янында бала-чага кайнаша. Алар Зәйнәп әби күчтәнәчен маңгайларына бәреп ваталар да юеш туп белән уйнап, урамның барлык балчыгын җыйган кулларында әвәли-әвәли әрчиләр. Әрчеп бетергәндә, күкәй нәкъ малайларның куллары төсенә керә. Ләкин бу аларны куркытмый. Эрерәк балчык эләккәндә генә алар күкәйләрен чалбар төпләренә ышкып алгалыйлар. Шул рәвешле «чистарткannan» соң Зәйнәп әби күчтәнәче тишек кесәдәй төпсез авызга чума.

Зәйнәп әбинең табагын бушатуга, Әсма түтинең коймагы пешеп чыга. Авызлар майлана, куллар майлана. Майлы кулларын түшләренә ышкып малайлар башка җирләргә тамаша кылырга китәләр. Бүген һәркемнең тамагы тук, күңеле көр. Әти-әниләре эшкә кушмый. Телисең икән, урам пычрагына ятып түшең белән шуыш — бер сүз әйтмиләр. Сәхия белән Сәкинәнең күңелендә генә бөгәрләнеп кара кайгы ята. Аларның көтеп алыр әткәләре дә, бәйрәм күлмәге тегеп кидертер әнкәләре дә юк. Сәкинә бүген хәтта көзгегә-дә карамый. Кызарып беткән күзләрен кул аркасы белән уып, учак тирәсендә әвәрә килә. Сәхия үтмәс пәке белән чыбыркы сабы юына, ул әллә ничә тапны бозып атты инде, һаман теләгәнчә килеп чыкмый.

— Апа,— диде ул ахырдан чыбыркы сабын идәнгә ыргытып.— Беләсеңме, безгә нишләргә кирәк?

— Нишләргә?

— Баздан бәрәңге чыгарырга. Зәйнәп әби очраган саен шуны әйтә. Бәрәңгегезне баздан чыгарып, келәт идәненә таратыгыз, утыртыр вакыт җитә, шыта торсын ди.

— Базга син төш түлке,— диде Сәхия. Апасының бакалардан коты чыгып курыкканын белә Сәхия, башка вакыт булса: «Бака немец генералы түгел, аңардан куркасы юк»,— дип, бер төрттереп алыр иде, бүген шаярасы килмәде.

— Ярар, төшәрмен,— дип киенә башлады.

Эш кызларның күңелен күтәреп җибәрде. Бәрәңге шактый иде.

— Монда әле безнең байлык бар икән,— диде Сәхия.—Утырткannan соң калса, сатарбыз. Сиңа бер җилле генә күлмәк алып җибәрербез. Рәмзиеннең күзен яндырып...

— Әй кыланмасана.— Сәкинә бәрәңге белән Сәхиягә кундырды. Сәхия дә җавапсыз калмады. Алар эшләрен онытып бәргәләшеп алдылар. Уртәшү сүзләре яуды. Шул вакыт алар янына Зәйнәп әби килеп керде.

— Менәтерәк минем уңганнарым нишләп ята икән. Әйбәт, әйбәт, балалар. Бик вакытлы тотынгансыз. Үз җаегыз белән бакчагызны да казый торыгыз. Бәрәңгене җиргә кертkәнче генә кайгыртырга кирәк,

аннары ул үзе сезнең турыда кайгырта башлый. Аллага шөкер, бәрәңгегез житәрлек күренә. Бакчагыз бик әйбәт сезнең, ел саен бәрәңгегез котырып уңа. Әткәгез бакчагызны ат тиресе белән ашлап кына торды. Хәзер менә шушылай тату итеп эшләп йөргәнегезне күрсә, әткәгез илләә шатланыр иде...

Зәйнәп әби, кызларга күрсәтми генә, күгәрчен канатыдай яулык почмагы белән күзләрен сөртеп алды. Бәлки аның күңеленнән яуда ятып калган дүрт улы узгандыр. Бәлки кырда кышлаган язгы башак ашап агуланып үлгән кызлары исенә төшкәндер.

— Ярый, үскәннәрем, мин чыгыйм әле. Эшләгән кеше янында торганчы...— дип чыгып китте Зәйнәп әби.

Кызларның эше бетеп килә иде инде. Бәрәңгене чыгарып бетергәч, бер кызган килеш, базны чистартып ташладылар. Зәйнәп әбинең «үскәннәрем» дип мактавыннан күңелләре күтәрелгән иде аларның. Ипи белән бәрәңге кебек үк, кешегә җылы сүз дә кирәк шул.

Эшне түгәрәкләгәч, иң эре бәрәңгеләрне әрчемичә, ярып кына пешерделәр дә өстенә тоз сибеп ашадылар. Әтиләре бәрәңгенең өстенә шулай тоз сибеп ашарга ярата торган иде.

Сәкинә тулышып, матураеп килүче кыз хәзер. Юан итеп бер толымга үреп куелган чәч, өскә кигән телогрейка астыннан чыгып күзне үзенә тартып тора. Йөздә язгы җилләр яккан алсулыкка сирәк-мирәк сипкелләр кушылган. Текәлебрәк караган һәр караштан кабынып китә торган бит очлары. Беренче карашка аңарда кайбер кызлардагы кебек «кычкырып торган» матурлык юк төсле. Бәлки бу Сәкинәнең холкы басынкы, характеры юашлыктан киләдер, әмма күрә белгән кешегә Сәкинәдә матурлык җитәрлек. Яктылыкка, җылыга үрелеп үсүче гөл кебек яшьлек. Ул бит хәзер унҗиденче яшь белән бара.

Ә Сәхия бөтенләй апасына охшамаган. Табак биттә тырпаеп торучы яңак сөякләре. Кайсылай тарасаң да, тыңлауны белмәүче кара чәчләр. Сызылып киткән куе нәзек кашлардан тыш бүтән кеше кызыгырлык җире юк. Ни өчен ул кашлар шулай нәзек булгандыр, алла белсен. Сәкинә әнә кашларының чабатадай җәенке булуына пошынып йөри. Бирер иде Сәхия апасына үз кашларын. Пычагымамы аңа матурлык? Яшәр өчен матурлык түгел, көч кирәк, гайрәт кирәк. Син матур дип, бер кешенең дә әле, әлбә пешереп, кунакка чакырганы юк. Тормышта көч үзенең кирәклеген һәр көн, һәр сәгать сиздереп тора. Берәр эшне эшләргә бик теләп тә, көче яки сәләте җитмәгән чакларда Сәхия янә үзенең кыз булып тууы өчен әрни. Егет кешене дөньяда һичбер нәрсә рәнҗетә, кимсетә алмас кебек тоела аңа.

### 3

Бәрәңге бакчасының шактый өлеше казылып бетеп килә иде инде, шул вакыт кызлар сәер һәм күңелсез ачыш ясадылар: келәткә чыгарып куелган бәрәңге көннән-көн кими иде.

— Апа! — диде Сәхия кылдан үрелгән камчысын шарлатып.— Бәрәңгене безнең әллә җеннәр ташыймы икән? Менә бу почмакка сатарга дип, иң эре бәрәңгеләрне юри өеп куйган идем, өем бөтенләй беткән. Шыта торсын дип, идәнгә таратылганнарының да күбесе кимегән.

Сәкинә келәт идәнендә таралышып яткан бәрәңгегә карап елап җибәрде.

— И аллам, кемнең генә кулы барды икән? Тагын күлмәк ала алмыйм икән инде.

— Шыңшыма әле! Күлмәк сиңа, әле монда утыртырлык бәрәңге калмаган. Ә нәрсә ашарбыз?

Шушы сорау аларның башларына күсәк белән тондыргандай итте. Сәхия йөгереп кенә Зәйнәп әбине алып керде.

— Ятимнәр өлешенә тигән кешенең тамагына таш булып утырсын,— диде Зәйнәп әби ни әйтергә белмичә. Ул үз әйберен урлаткан кешедән дә ныграк борчыла иде. Бераз вакыт һушын җыя алмый торды.— Җир битләр,— диде ул үз-үзенә.— Кем өлешенә кул сузганнар бит. Әй алла, карак кеше гомер-гомергә көчсезне, яклаучысы юкны талый шул. Әгәр көчле кешеләрнең әйберенә нәфсең сузсаң, кулына бик каты итеп сугачакларын белә. Юк, юк! Болай калдырырга ярамый моны, балалар. Сәвиткә барып әйтергә кирәк. Килсеннәр, эзләсеннәр, тикшерсеннәр.

Бәрәңге урлану хәбәре тиз арада бөтен авылга таралды.

— Бичаралар, хәзер нишләрләр инде,— диештеләр кешеләр. Һәркемнең телендә бер сорау кабатланды:

— Кем эше икән?

Авылда караклыгы белән даны чыккан Зәйнулла исемле кеше бар иде. Инде менә Сәкинәләрнең бәрәңгесе урлану хәбәре ишетелгәч, кешеләрнең шиге аңа төште.

Авыл советында председатель булып фронттан бер кулын өздереп кайткан Зәкиев эшли иде. Хәлне аңлатуга, ул Сәкинәләргә төшеп китте.

— Алай бик борыннарыгызны салындырмагыз әле, табарбыз,— дип, кызларның күңелен күтәрергә тырышты Зәкиев.— Кайчанрак бәрәңгегезнең урланганын белдегез?

— Бүген генә.

— Келәтегез бикле идеме?

— Бикле дип... Келәсен тимерчыбык белән борып куйган идек. Менә шуның белән.

Зәкиев кызлар кулыннан тимерчыбыкны алып әйләндереп карады. Тик бу аңа берни сөйләмәде. Ул келәт тирәсендә йөренде, эзләргә күз салды, әмма шикләнерлек нәрсә тапмады. «Арба-мазар эзе күренми,— дип сөйләнде ул үзенә,— димәк, күтәреп ташыганнар. Капчыклап. Кызларның әйтүләренә караганда, бәрәңгеләре күп булган. Шушы тирә кешесе булырга тиеш. Белгән кеше. Тагын шул каһәр суккыры эшедер, мөгаен.

Сәкинәләр бакчаларының чирегенә генә бәрәңге утырта алдылар. Ачлык һәр почмактан упкындай авызын ачып карап тора башлады. Колхозда эшләгән өчен бирелгән әз-мәз икмәк көче телгә йогарлык кына иде.

— Сеңлем,— диде Сәкинәгә беркөнне авыл советы председателе Зәкиев.— Менә без сезнең хәлегезне җиңеләйтергә уйладык әле. Клубка мөдир итеп куярга исәп үзеңне. Я, ничегрәк уйлыйсың, булдыра алырсыңмы?

— Белмим шул, абый.

— Белемең бар,— дип дәвам итте Зәкиев.— Әз булса да акча керер. Белмәгәннәреңне ящереп торма, үзебезгә кил, ярдәм итәрбез. Эшне аны яңа тотынганда беркем дә белеп тотынмый. Менә мин дә мылтык тотып үскән кеше түгел идем, фронтка алып китеп, мылтык тоттыргач, атарга өйрәндем. Ә кайткач тагын өр-яңа эш бирделәр: председатель итеп куйдылар. Билгеле, авыр булды, әмма бирешергә исәп юк.

Шуның белән әңгәмә тәмамланды. Сәкинә яңа эштә эшли башлады. Клуб тикле клубка мөдир булып алгач, һич кимендә бер рәтле-башлы күлмәк кирәк иде. Яңа күлмәк табу турында Сәхия белән икәүләп озак баш ваттылар. Бу кыенлыктан чыгу юлын Сәхия эзләп тапты.

— Теге чаршаудан тектер,— диде ул.— Ни пычагыма безгә чаршау? Барыбер сандыкта әрәмгә ята.

Элегрәк бәйрәм көннәрендә, кунак-фәлән килгәндә, әниләре өйгә чаршау, кашагалар, әйләнмәләр элә торган иде. Андый чакларда һәр почмактан ниндидер күркәмлек, җылылык бөркелгән кебек була иде. Әнкәләре үлгәннән соң бу эшкә кул селтәделәр. Хәер, Сәкинә бервакыт

май бәйрәменә өйләрне юып чыгаргач, бөтен җирне элеккечә итеп бизәп караган иде. Әткәләре эштән кайтып керде дә әллә нишләп китте. Тамагына кайнар төер утырды, ә кич белән, гомердә эчмәгән кеше, эчеп-исереп кайтты.

— Әй, кызларым, үскәннәрем,— дип еларга ук тотынды ул.— ятим калдык бит без. Менә бу чаршауларны, кашагаларны әнкәгез үз куллары белән суккан иде. Без монда бәйрәм итәбез, шатланабыз, ә ул анда җир астында ята.— Әткәләре шулай кече якта шактый яшь түкте. Үзе дә, әнкәсез калган кызлары да җәл иде аңар. Аннары ул, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, урыныннан сикереп торды һәм чаршауларны, кашагаларны берәм-берәм тартып төшерә башлады.

— Шушы шайтан орган нәрсәләр житте аның башына. Дөньяның әле бер ертыгын, әле икенче тишеген ямап, монсын булдырыйм, тегесен житкерим дип яшәп харап булды. Их дөньясы...

Әйе,әнкәләре аларның бик-бик эшчән иде. Йокыдан торып, урамга карый да, берәсенең морҗасыннан төтен чыкканын күрсә, йөрәге «жу» итә: «Соңарганмын! Башкалар торып мичкә яга башлаган!» Һәм ул көнне аның ашы аш, эше эш булмый. Кулыннан әле бер нәрсә, әле икенче нәрсә төшеп аптырата. Авыл гомер-гомергә Мәгъдәниягә карап йокысыннан торырга, эш башларга күнеккән. Урак урганда, көлтә бәйләгәндә, Мәгъдәния артыннан житәм димә. Әгәр берәрсенең үзара якынлашып килүен күрсә, аның йөрәге ярылачак. Ә өйгә кайтуга аны өр-яңа эшләр көтеп тора. Сүс талку, киндер сугу, бәйләм бәйләү. Кышның эт эчәгесе кебек озын төннәрендә жиделе лампа астында шып-шып киндер сугып, күз нурларын әз түкмәде Мәгъдәния. Кияүгә чыгарга җыенучы кызлар, синең кулың жиңел, синнән әйбер алган киленнәр кире әйләнеп кайтмыйлар дип, ашъяулыгын, тастымалын аңардан алалар иде. «Синең кулың жиңел. Синең киндерләреңнең ниндидер нуры бар»,— дигән сүзләр Мәгъдәнияне чын-чынлап канатландыра, әйберен мактаган кешедән бәяне кимрәк алырга тырыша иде.

Хәер, без барыбыз да шуның өчен яшибез түгелме соң? Эшебезне башкалар яратсын, башкалар югары бәяләсен өчен тырышабыз. Әгәр сәләтеңне күрмиләр, бәяләмиләр икән — син юк. Һәркемнең җанында иҗат очкыны ята, шул очкынга сүнәргә ирек бирмәсәң, аны үстерә, дөрләтә килсәң — сине барыбер бервакыт таныячаклар. Танылу — шагыйрьләргә, әдипләргә генә түгел, һәркемгә кирәк. Кеше башта танылу, үз йөзен табу өчен тырышса, бер танылгач инде шул исемне аклар өчен бөтен көчен куя. Ә бу исә тырышлыкның тагы да зуррагын сорый, туктап калмауны таләп итә.

Язмышны кеше үзе яза диләр. Бу сүзләрдә, мөгаен, хаклык юк түгелдер. Әнә ич Мәгъдәния әҗәленә ничек ашкынды. Башта эрләгән җепләремне сугып бетерим дип тырышты. Ә сугып бетергәч, язгы бозлар киткәләгәнче бәкегә алып төшеп бәләкли-бәләкли юып калыйм, язгы кояшта агарып, язгы җилләрдә йомшап кипсен диде. Ә елгада бозлар кузгалырга торган чак иде. Бәке тишелгән бозның урыныннан кучканен, менә-менә яңадан кузгалачагын белеп керде Мәгъдәния. Ләкин үзенең өлгерләгенә ышанды. Әгәр боз киткәнче, киндерләрне юып өлгермәсәң, яңадан мондый форсат булмаячак. Елга үз ярларына кайтып, су буена басма салынганчы күпме гомер үтәчәк, көннәр югалачак иде. Шушы ашкыну алып китте Мәгъдәнияне... Аның гәүдәсен бик озак эзләделәр...

Локман, хатынын җирләп кайтканнан соң, ярты өйне биләп торучы киндер сугу станын балта белән тураклап ташлады, йомгак-йомгак җепләрне янган мичкә атты. «Тотынмагыз,— диде ул кызларына,— кул эше эшлим дип чекрәеп утырмагыз. Дөньяның тишек-тошыгын барыбер ямап бетереп булмый. Әнә үз гомерендә бер кием бияләй бәйләп кимәгән Мөгелсемнәр дә ачка үлми».

Йомшак холыклы Локман бу юлы сүзендә каты торды. Кызла-

рыннан кул эше эшләтмәде. Әнисе барында Сәкинә тегү эшенә бераз өйрәнә башлаган иде, тик, әнкәләре үлгәч, «Зингер» машинасын әткәләре сатып җибәрде. Бүген менә кулына әнкәләре суккан чаршауны тотып, авыл буйлап күлмәк тектерер кеше тапмыйча йөргән чакта Сәкинә беренче тапкыр этисенә рәнжеде. Ә бит кайчан гына әле башка кызлар бәйләм бәйләп, җеп эрләп яки берәр әйбер тегеп чекрәеп утырганда, әтисенең шундый әйбәт булуына сөенеп черт-черт көнбагыш яра иде. Эзли торгач күлмәк тегүче табылды. Күлмәк бик килешле чыкты.

— Түшең белән шуышып йөрсәң дә, бу сиңа бер биш елга җитә инде,— дип шаярып алды Сәхия.

Апасының клубта эшләве аны бик шатландырды. Хәзер инде ул теләсә нинди киногa бушлай керә ала. Сугыш турындагы киноларны бик ярата Сәхия, андый фильмнарны кабат-кабат карый. Малайлар каршында дәрәҗәсе бик үсте. Алар турысыннан сызгырмый узмыйлар. Сәхиянең үзен дә ике бармагын авызына кабып сызгырырга өйрәттеләр. Ә бит кайчан гына алар очындагы иң шәп сызгыручы Рамил болай сызгыру серен Сәхиядән яшереп маташкан иде. Хәзер исә үзе үк: «Әйдә, сызгырырга өйрәтәм»,— дип, Сәхияне чакырып чыгарды. Ә Хәйдәр үзенең абыйсыннан ялынып алган сигездән үрелгән камчысын бүләк итте.

## 4

Эшләр шулай әйбәт кенә көйләнеп барганда, Сәкинә әллә нишләде: иң беренче аның йөзеннән елмаю качты. Сәкинә хәзер башка чаклардагы кебек көзгегә карап утырмый, чыгып киткәндә яулык астыннан бөселеп торган чәчләрен әле маңгаена, әле колагына табарак тарап матурланмый. Гаебе бар кеше кебек түбәнгә карап йөри, хәтта күзләре дә кызаргандай күренә. Ә иң гаҗәбе: мунчага бара башласа, ничек тә сеңлесен ияртмәскә тырыша. Беркөн Сәхия шаярып: «Арканы әллә ләүкә астындагы җеннәрдән ышкытасыңмы?» — дигән иде, кызып китүне гомергә белми торган Сәкинә сеңлесенә әлләниләр әйтеп ташлады: «Синең миндә ни эшең бар, ләпек? Син шул малайлар белән кеше бакчасыннан шалкан урлаудан бүтәнне белмисең. Сиңа җиңел. Ә мин җиткән кыз кеше. Ә җиткән кызны...»

Сәкинә сүзен әйтеп бетермәде, яшенә капланды. Бәлки ул: «Җиткән кыз — кызарган алма, аңарга һәркем кызыга. Кызыгып кына калмый, үрелә, өзәргә тырыша. Өзеп алып, тешләп карауччылар да җитәрлек»,— дияргә теләгәндер.

Сәхия юату сүзләре белми, гомумән, елаган кешене аның җене сөйми иде, апасына җикеренде:

— Өшегән бәрәңге! Авызыннан сүз чыкканчы, күзеннән яшь коела башлар шушы җыбыткының. Җүнләп сөйли белмәс.

— Син нәрсә аңлыйсың соң...

— Мин аңгыра түгел, бөтенесен күреп торам: шул майлы күз Рәмзиеңнән алдангансыңдыр әле. Бер дә юкка корсагыңа тастымал урап йөрмисеңдер.

Сеңлесе авызыннан чыккан бу хакыйкатьне ишеткәч, Сәкинә агарып катты. Бите буйлап тәгәрәп төшеп килүче җитез тамчылар ияге һәм борын очларында эленеп калды. Кызның күңеленә коточкыч шом йөгерде. «Димәк, Сәхия барысын-барысын белә. Ул белгәнне башкалар белмәсме? Юк, бу хурлыкка түзәргә ярамый, китәргә кирәк авылдан, китәргә! Кадалсын клубы, чәнчелсен Рәмзие!»

Шулай уйлады Сәкинә, ләкин чыгып китәр өчен паспорт кирәк иде. Колхоз председателе, үлсәң дә, паспорт алырга белешмә бирмәячәк. Ул әнә районда көннән-көн ныграк шаулый барган нефть эшенә китүчеләрне дә кире борып алып кайткан диләр. Председатель Насыйбуллин-

нан бөтен кеше кан калтырап тора. «Без ни өчен сугышта кан койдык! — дип, өстәлгә бер генә китереп суга диләр аны.— Шушы җиребездә ипекәй үстерер өчен, кешечә яши белүебезне раслар өчен түгелмени? Колхоздан син качсаң, мин качсам — ипекәйне кем үстерер? Ә бит безнең бурычыбыз — бар кешене ипиле, бәрәңгеле итү генә түгел, безнең бурычыбыз — авылның йөзен үзгәртү...»

Председатель Насыйбуллинның бер мәзәк ягы бар иде: җыелышларда сүз сөйли башласа, ике сүзнең берендә өф-өф ди иде. Такташныкыдай озын сары чәчләре — Насыйбуллин: «Иптәшләр!» — дип әйтүгә, йөзенә килеп төшә һәм председатель аларны «өф-өф!» дип авыз турысыннан читкәрәк өреп җибәрергә мәҗбүр була. Сөйләгән сүз аның болайрак килеп чыга: «Иптәшләр, өф — бүген без — өф, гаять җитди — өф, сынау алдында торабыз — өф. Без — өф, гаять явыз — өф, гаять мәкерле — өф, фашистны дөмектереп — өф, тыныч тормыш яулап алдык — өф. Без — өф, ошбу авырлыкларны да — өф, совет кешеләренә генә хас — өф, фидакарьлек белән җиңеп чыгарбыз — өф-ф!»

Залда утыручылар аны елмаеп тыңлый. Шундый җитди сүз сөйләвендә, кешеләрнең мыек асларыннан көлеп утыруларына аптырый иде Насыйбуллин. Бервакыт бу турыда хатынына зарланып алды: «Безнең авылда кешеләр әллә нинди. Син аларга язгы чәчү яки игеннәрне вакытында җыеп алу турында сөйлисең, ә алар синең һәр сүзеңнән авыз ералар. Белмим, моның нинди кызыгы бардыр?!»

— Синең сөйләвеңнән көләләр алар,— диде хатыны.— Сүз саен «өф-өф» дисең бит. Белеп тор: син — «өф-өф Насыйбуллин».

Хатынының бу сүзләреннән соң Насыйбуллин «өф-өфен» ташлап карарга маташты, хәтта чәчен дә кыскарттырып карады, әмма гадәтен ташлый алмады. «Өф-өф»тән башка сөйләнгән доклад артык коры, сүзләр бер-берләре белән бәйләнеп җитми кебек тоелды аңа һәм ул, кеше үзенең сакаулыгына күнеккәндәй, моңа әһәмият бирми башлады.

Сәкинә килеп кергәндә председатель нидер язып утыра иде.

— Я, сеңел — өф,— диде ул башын калкытып.— Ни йомыш — өф?

— Мин, Насыйбуллин абый...— Сәкинәнең шуннан артыкка батырлыгы җитмәде, елап җибәрде.

Насыйбуллин урыныннан торды, кабинетында әрле-бирле йөрергә тотынды. Елап сөйләшүчеләрне җене сөйми иде аның. Алдында әгәр яшь кыз бала утырмаса: «Башта күзеңне, борыныңны корытып кер, һәркемнең яшен сөртеп, юатып утырырга минем вакытым юк»,— дип, кабинетыннан борып ук чыгарган булыр иде. Ләкин ятим балага каты кагылудан тыелып кала алды.

— Я, я, сөйлә, апаем.

— Миңа...— диде Сәкинә үксүен басарга тырышып,— миңа а-авылдан ки-итәргә-ә ки-ирәк, абый...

— Монысы нинди каприз тагын! — дип өстәлгә китереп сукты Насыйбуллин. Өстәлдәге кара савытлары сикерешеп куйды. Ә Сәкинә үзенә суккандай урындыгына сеңде, бөрешеп калды.— Мин сине җитдирәк сүз белән кергәнсеңдер дип тыңлап утырам тагын. Әллә син читтә майлы ботка пешереп көтеп торалар дип беләсеңме?

— Миңа майлы ботка кирәкми,— диде Сәкинә. Председательнең кызып китүеннән соң кызның яше кипте, күрәсең, үзенең эчендә дә нииндидер ярсу кузгалгандыр.— Мин авылда кала алмыйм, абый...

— Бәлки сәбәбен аңлатып сөйләрсең, кызый.

Сәкинә түбән карады. Оят эшне эшләү бер кыен, ә кешеләргә сөйләү икеләтә кыен. Ничек инде олы кешегә мин шундый-шундый дип әйтәсең. Әгәр Рәмзигә карата эчендә ачу кайнаса, аңардан үч аласы килсә, тагын бер хәл иде. Юк бит, Рәмзи аны кечләмәде, куркытмады. Йөри торган кызларын ташлап, гел үзе янында кайнашуына Сәкинә эчтән тантана итте. Сәкинәне бу эшкә әллә нинди курку катыш кызыксыну этәрде. Әгәр моны яшереп калдырырга мөмкин булса, бераз газапланып йөрер иде дә онытыр иде. Әмма моны яшерү хәзер янган

күмерне кесәдә йөртү белән бер. Кешеләр Сәкинәнең гайбәтен сата башлаячак. Ә кешеләр сүзеннән бик курка ул.

— Я? — диде Насыйбуллин кыза башлап.— Мин монда сезнең барыгызны көйләп утыра алмыйм.

Сәкинә тотлыга-тотлыга сөйләргә кереште. Сөйләгәндә җиң төймәләрен өзеп бетерде. Аны тыңлаганнан соң Насыйбуллин:

— Тә-әк! — дип, янә өстәлгә сукты.— Эшләгәндә эшләдек, хәзер авылдан качабыз дисеңме? Ә соң моңардан,— председатель аның бил турысына ымлады,— качып кына котылып булыр микән? Кара сакал бит ул гел арттан йөри. Юк, мин сиңа белешмә бирә алмыйм. Дөньяның рәхәте белән михнәте бергә йөри аның. Берсен татырга курыкмагансың, кешеләр йөзенә туры караудан да курыкма. Аннары синең бит әле үзеңнән кече апаең бар. Аны кемгә калдырмакчы буласың?

Сәкинә бу турыда уйламаган иде. Аптырап калды. Тик каушавын сиздерәсе килмәде.

— Ул миннән шәбрәк әле,— диде.

— Шәбрәкме, түгелме, бала әле ул.

Сәкинәнең хәлен аңлый һәм аны артык гаепләми иде Насыйбуллин. Нишлисең бит, ялгышкан. Адәм баласына ялгышу хас. Берәүләр ялгышларыннан сабак алалар, икенчеләре инде миңа барыбер дип, яңаларын ясыйлар. Әгәр хәзер бу бала авылдан китеп барса, мәңге чыга алмаслык ялгышларына кереп батмасмы?

Председатель Сәкинәгә соңгы кат ярдәм итмәкче булып:

— Менә нәрсә, апаем,— диде,— беркая китмисең. Телисең икән, Рәмзине, боргычлап алып, яныңа китереп куям.

Бер мизгелгә Сәкинәнең күңеленә сөенеч йөгереп алды: әйе, Насыйбуллин абый боргычлап китерсә, Рәмзиең кая барсын? Теләсә, Насыйбуллин абый Сәкинәне Рәмзинең муенына гармун итеп аса ала, йөрерсең авыл буйлап күтәреп.

Шундый уйлар эчендә күпмедер вакыт тантана итеп утырды Сәкинә. Тик бу мәсьәләдә сүз чыккач, Рәмзинең мыскыллы көлүе исенә төште: «Сез күбәү бит, матурым. Бөтенегез барыбер минем кочагыма сыймас»,— дигән иде ул.

— Юк, абый, кирәкми,— диде кыз, айнып киткәндәй. Председатель чарасыз иде.

Насыйбуллин кабинетыннан Сәкинә: «Барыбер китәм»,— дигән уй белән чыкты. Өенә кайту белән, ул Сәхиягә сиздерми генә әзерләнә башлады, әмма яшерерсең Сәхиядән! Эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук сизде.

— Нәрсә, качабызмы?

— Гомер буе авылда чиләнергә димәгән.

— Ә мин?— Сәхиянең күзләре бервакытта да булмаганча моңсу иде. Ул елап җибәрүдән чак тыелып калды. Берәрсе килеп, башыннан сыйпаса, юатса, яшьләре мөлдерәячәк иде. Ләкин юатучы булмады.— Бар, бар, кит,— диде ул бераздан ярсый башлап.— Урам пычрагы итеп маңгайга чәпи башлаганчы тай. Әнә, абзардан кәҗәне апкит. Менә бу чүпрәк-чапракларыңны да.— Сәхия кулына ни эләксә, шуны ыргытты. Кәҗә турында сүз чыгуга, Сәкинә дерт итте: аны сатарга уйлаганны каян белгән диген! Кеше түгелдер, җендер бу. Син уйлап өлгермисең, ул әйтеп сала.

— Кәҗәне сатмый, акча каян алыйм мин? — диде ул Сәхиягә.— Әллә анда миңа әзерләп куйганнар дисеңме?

— Әзерләмәгәч нигә качасың?

— Анда синең эшең юк.

— Авылдан чыгып киткәнгә генә әллә корсагың шиңәр дип беләсеңме? — диде Сәхия апасына, бәгыренә үтәрлек итеп. Сәкинәнең сүз көрәштерергә исәбе юк иде, дәшми-тынмый җыенуында булды.

Кәҗәне алучы табылды. Сәкинә сөенә-сөенә үзенең фаҗигасына таба юл тотты.

— Мин сиңа матур күлмәк, ак туфлиләр алып җибәрермен,— диде ул чыгып киткәндә.— Хәзер сиңа ундүрт тулды. Үз көнеңне үзең күрерлек булдың.

Матур күлмәкләр, ак туфлиләр алып җибәрәчәгенә нык ышанып әйтте Сәкинә, чөнки ул әле шәһәр тормышының, өскә ябынган кыска бишмәт кебек, башка тартсаң — аяклар ачыла, аякка япсаң — баш ачыла икәнен белми иде...



## 5

Сәкинә киткәч, Сәхия ачудан өйдәге барлык хатын-кыз киемнәрен утка якты: «Бөтен бәла шушы кыз булып туудан. Җитмәүчелек, үз-үзеңне яклый алмау — бөтенесе шуның аркасында. Әгәр Сәкинә егет кеше булса, үзен рәнҗеттерер идеме? Рәмзинең ләшпәйгән танавына берне генә менеп төшәр иде. Ә менә Сәхия үзе. Ундүрт яшьлек малайлар хәзер урман кисәргә йөриләр. Сыер җигеп тырма тырмалыйлар. Кеше алдында курыкмыйча тәмәке тарталар. Аларга беркем сүз әйтә алмый, чөнки алар эшләп кайткан. Бетте, моннан соң мәми авыз кыз булып йөрдек юк!»

Сәхия бар нәрсәне кырып салганнан соң сандыктан этисенең кешлеккә кия торган костюм-чалбарын тартып чыгарды: «Җитте сиңа. Күп яттың көя туйдырып. Файда күрсәтә башларга вакыт!»

Ул чалбарны киеп карады, чалбар шактый озын иде. Кире салып, балагын кисеп атарга туры килде. Зәңгәр чалбар балагын тегәрлек зәңгәр җеп юк иде, Сәхия аның өчен уфтанмады: «Урамга бер чыгып керүгә, акмы-зәңгәрме икәнлеге беленми башлаячак барыбер»,— дип фикер йөртте. Ныклабрак карасаң, балакның берсе озынрак, икенчесе кыскарак икәнен күрергә мөмкин булыр иде, әмма Сәхия андый вак-төякне исәпкә алмады. Балак озынрак тоелган якны ныклабрак күтәреп куйды да — шуның белән вәссәләм. Чалбарның төбе култык астына кадәр житеп торуы да куркытмады аны, каеш белән билне буып, күлмәк астында калдыргач, чуртым күрәме аны?! Ә күрсәләр соң! Күп кешедә мондый чалбар юк әле.

Урамга егет булып чыкты Сәхия. Тик менә башка кияргә кепка гына юк, кайчандыр этисе алып биргән кепкадан күптән инде җилләр искән иде. Этисенең эшләпәсен киеп карады — ошатмады. Беренчедән, артык зур, икенчедән, ярты сәгать эчендә малайлар үзенә «эшләпә» дигән кушамат тагачаклар. Бердәнбер чара — апасыннан калган киезләнеп беткән башлыкны кию иде.

Тирән кесәләренә көнбагыш тутырып, капка төбендә чырт-чырт көнбагыш яручы Сәхиягә авылның олысы-кечесе карап үтте. Тиз арада аның янына малайлар җыелды. Чалбарны тотып-тотып карадылар. Алар тоткан җирдә уймак-уймак эзләр калды. Сәхиянең моңа исе китмәде. Чалбар никадәр тизрәк каралса, шуның кадәр яхшырак иде.

— Атасының чалбары белән мактанырга чыккан,— дип төрттерепалды арадан берсе.

— Булса син дә мактаныр идең, синең атаңның чалбары юк,— диде Сәхия.

— Булмас!

— Булса нигә кими? Киндер ыштан төбе белән урам себереп йөри.— Сәхиянең бу сүзләреннән малайлар шаркылдашырга тотындылар. Сәхияне үртәгән малай башкалар артынарак посты. Ә Сәхия, үз сүзләренең

шундый тәэсирле чыгуын күреп, тагын һөҗүмгә күчте: — Беркөннәре урамнан трактор бүрәнә өстерәп килә дисәм, синең атаңның ыштан балагы өстерәлеп тузан туздырып бара икән.

Бусы инде теге малайның сабыр савытына тамган соңгы тамчы иде. Сәхиягә ул: «Беләсең килсә, сине детдомга озаталар»,— диде. Бу сүз яңакка чабудан авыррак иде. Сәхия агарып китте, ләкин бик тиз үзен кулга алып өлгерде һәм малайның якасына барып ябышты: «Дуңгызның борын тишегеннән чыккан нәрсә! Кем әйтте сиңа алай дип, ә?»

— Кем әйтәсе юк, бөтен авыл сөйли,— диде малай гыжылдап.— Анда әнә калач кына ашаталар ди...

Малай сүзен әйтеп бетерә алмады, Сәхия үзенең таштай башы белән аның эченә дөкеде. Малай бермәлгә тынсыз калды. Тик озакка түгел, үпкәсенә һава тулып өлгерүгә, йодрыкларын эшкә җикте. Тәпәләш китте. Күпмедер вакыт эчендә малайның өзелгән җиңе, Сәхиянең якасы җирдә аунап ята иде инде. Һәр икесенең борын юешләнде, һәр икесенең күзләре янды. Сугышып арыганнан соң әйткәләшү, кемнең ныграк кундырганын ачыклау китте.

Шушы көннән Сәхиянең исеме бер хәрефкә кыскарды, Сәхигә әйләнде. Малайлар аны тиз арада үз иттеләр. Көчен аямыйча сугыша белүе, күпме тукмалса да, шыңшымавы өчен яраттылар. Тик Сәхине бу җиңү сөендермәде, аның күңеленә шом һәм шик оялады.

«Чынлап та балалар йортына җибәрсәләр? Юк, үлсәм үләрмен, бармам! Әгәр инде милиция белән озаталар икән — качам! Качам да урманда бер үзем яши башлыйм. Чәнчелеп китсеннәр».

Ул үзен Робинзон Крузо кебегрәк бер кеше итеп күз алдына китерде. Дөрес, Робинзон Крузо турындагы китапны укыганы юк аның, малайлар сөйләвенә караганда, Робинзон Крузо куркусыз кеше булган. Кыргый җәнлекләр аулаган. Ни өчен Сәхи Робинзон Крузодан ким булырга тиеш? Ояга качкан куяннарны Сәхи койрыкларыннан өстерәп чыгарачак. Их, куян ите тәмледер ул! Куянның бәлеше шәп була диләр. Куяны әләгүен әләксә, бәлешсез дә тамакка төртелеп калмас иде лә анысы. Туйганчы куян боты кимергәч, имән төбенә сузылып ятып йоклыйсың. Их!

Шулай хыялланып ятканда, Сәхиләргә авыл Советы председателе Зәкиев килеп керде. Зәкиевне күрүгә үк Сәхинең колаклары сагайды, йөрәге ешрак тибә башлады. Зәкиев нигәдер сүз башларга ашыкмады: өйнең эчен карап чыкты, чөйдәге кием-салымнарга күз салды, аннары гына сәкегә утырып сүз башлады:

— Я, ничек яшибез? — Сәхи сүзсез генә җилкәсен сикертеп куйды.— Бик кыен түгелме? — Бу сорауга да җавап ишетелмәде, чөнки Сәхи сагаеп сүзнең төп темага күчүен көтте. Һәм, ниһаять, Зәкиев дипломатлыкны бер читкә куеп, Сәхигә болай диде:

— Менә нәрсә, үскәнем. Без сине балалар йортына җибәрергә булдык...

Сәхи сикереп торды, битенә кайнарлык йөгерде.

— Юк! — диде ул.— Барасың килсә, үзең бар, ә мин...

— Туктале, тукта, кызмый гына сөйләшик. Син бит бәби түгел, аңла.

— Бәби түгел шул. Әнә бәбиләрне җибәрегез детдомга. Ә мин аннан барыбер качачакмын.

— Анда синең өстең бөтен, тамагың тук булыр, укырсың. Ә берничә елдан «туп» итеп кайтып төшәрсең. Анда әйбәт...

— Миңа әйбәт кирәкми.

— Киреләнмә әле, үскәнем. Монда бит, үзең күреп торасың, тормыш авыр. Ләгънәт төшкән сугыш бөтен тормышыбызны җимерде. Сугыш җимерекләрен төзәтеп, ныклап аякка басканчы, шактый еллар үтәр. Ә хәзергә синең кебекләргә генә түгел, өлкәнрәкләргә, буын ныгыткан кешеләргә дә таманга туры килә.

Зәкиев озак сөйләде, тик Сәхия күңеленнән аның сүзләрен ниндидер

гарьлек белән кире кага барды. Каршы әйтмәгәч, Зәкиев аны үзе белән килешүе дип аңлап: — Шулай, апаем. Әзерләнебрәк тор, урын булуга, илтеп куярбыз,— диде.

— Барыбер мин анда бармыйм, бармыйм!— диде Сәхия елар чиккә житеп.— Эшкә йөрим мин. Берәр атлы эш бирегез миңа.

— Атлы эш ул — атаң жиккән атка утырып йөрү түгел. Ат белән урман ташыйлар, жир сөрәләр, урак уралар. Синең менә шуларның кайсына көчең житә?

— Бәрәңге ашап көч булмый.

— Менә ипекәй ашасын дип, балалар йортына жибәрәбез бит инде.

— Минем ипи ашасым килми.

— И-и, киребеткән нәрсә! Кеше аңа яхшылык тели, ә аның үз киресе — кире.— Зәкиев ишекне шарт итеп ябып чыгып китте.

Сәхия сәкегә тәгәрәп еларга тотынды. Үзен кызгану, тормышны нәгъләтләү хисләре кайнар дулкын булып күкрәккә бәрде. Тиктомалдан сулыш кысылды, тын алганда, эчтән ыңгырашу авазлары бәреп чыкты. Шулай үксеп ята торган бермәлне ул йоклап китте. Һәм бик матур төш күрә башлады. Менә аның әнисе яшь-яшь, матур. Сәхиянең башыннан сыйпап: «Балам, син кешеләргә рәнжемә,— ди.— Яшәү беркемгә дә жиңел түгел. Авыр дип, эчеңә ачу жыйма. Ачулы кеше — көчсез кеше». «Юк, әни, ачулы кеше — көчле кеше. Бик каты ачуым чыкканда, мин үземнән көчле малайларны жиңәм». Әнисе Сәхия белән килешми, йомшак, ягымлы тавышы белән әкрен генә сөйли. Үзе һаман кызының чәчләреннән сыйпый: «Чәчләреңне малайларныкы кебек итеп кискәнсең икән». «Әйе шул, лакандагы суга карадым да кисеп аттым. Минем жебегән кызлар буласым килми». Әнисе әкрен генә көрсенеп куя: «Әй бала, бала!»

...Шул урында төш өзелә. Күзләрен ачып жибәрсә — Сәхия янында Зәйнәп әби утыра. Үзе нәкъ Сәхиянең төштәге әнисе кебек тирән итеп көрсенә. Сәхиянең уянганын күргәч тә шул халәтендә озак утырды ул. Бераздан гына: «Гариф бабаң кичә тегермәнгә барганые, менә бу шишара белән чәй эчеп жибәрик әле»,— дип, ашъяулыкка төрелгән кисәкне өстәлгә куйды. Ипи яңа пешкән иде, тәмле исе борынга килеп бәрелде. Ипи исе Сәхиянең бөтен кайгысын оныттырды, ул сикереп урыныннан торды:

— Хәзер самавыр куеп жиппәрәбез.— Сәхия күз иярмәс хәрәкәтләр белән самавырның көлен какты, су салды. Күмере юк иде, күмер урынына коры-сары тутырды.— Безнең самавыр тиз кайный ул,— диде үзе. Зәйнәп әби ни өчендер урыныннан кузгалгач. Күрәсең, чыгып китәр дип курыккандыр. Сәхиянең бу минутта бер дә ялгыз каласы килми иде.

Самавыр чынлап та тиз кайнады. Зәйнәп әбинең ашъяулык почмагында ниндидер үләннәр булган икән, башта Сәхия моңар игътибар итмәгән иде, шул үләннәрне чәйнеккә салып чәй иттеләр. Ипиен олы-олы кабып эчкәч, шикәр юклык сизелмәде. Сәхиянең күптәннән болай тәмле чәй эчкәне юк иде, маңгаеннан тирләр бәреп чыкты.

Тамак туйдыргач, Зәйнәп әби читләп-читләп кенә сүз башлады: «Быел да көтүне Ибрай бабаң ала икән. Ул алса, безнең жан тыныч инде. Тик менә үземә берәр шәп памушник кирәгие дип әйтә ди».

Сәхия Зәйнәп әбинең тел төбен аңлап житмәде.

— Табар, беткәнмени кеше. Ипиле эшкә бөтен кеше атлыгып тора.

— Әйе, әйе. Шулай, балам. Нинди елларда да көтүченең тамагы тук була.

Бераз вакытка сүз өзелеп торды. Чыгып китәргә жыенып, Зәйнәп әби, ашъяулыгын төреп, кулына тотты. Ишеккә житкәч кенә әйтте: «Әллә, мин әйтәм, Ибрай бабаңа памушниклыкка син барасыңмы дим. Балалар йортына жибәрәбез дип тә бәйләнмәсләр иде үзеңә. Уйлап карамыйсыңмы?»

Бу сүзне башка кеше әйтсә, Сәхия аңа тозлап-борычлап жавабын бирер иде, әмма Зәйнәп әбигә каршы әйтә алмады. Жыен булмаган кеше

көтүгә керә дип уйлый иде ул. Дөрес, көтүченең тамагы сыйлы. Ул ягы әйбәт. Көн саен ипи ашасаң, беләкләргә көч керер иде керүен.

Уйлана торгач Сәхия көтүчелеккә кереп карасаң да ярый дип тапты. Зәйнәп әби әйтмешли, детдомга җибәрәбез дип аптыратмаслар. Тик менә таң тишегеннән йокыдан тору белән килешәсе килмәде аның. Ятып житмисең, торырга кирәк. Йокылы башны мендәрдән кубарудан да авыррак нәрсә юк сыман. Беркөнне ул Ибрай бабайга мондый тәкъдим әйтте: «Әйдә болай итәбез, Ибрай бабай. Син көтүне иртәнге якта көт, төштән соң мин көтәрмен». Ибрай карт аның тәкъдимен ишеткәч: «Без бит авылны йокыдан уятучылар. Иртән торып, чыбыркыңны бер шартлатуга, хатыннар сикерешеп торып, сыер саварга тотыналар. Ә син: «Ашыгыгыз»,— дип, тагын бер шартлатасың. Кемне шулай, таңнан торып, бөтен авыл озата? Көтүчене! Кемне бар эшен ташлап, бөтен авыл каршы ала? Көтүчене! Мондый пачут губернаторларга гына тисә тигәндер. Ә син шушындый пачуттан үзеңне мәхрүм итмәкче буласың»,— диде. Ибрай бабай Сәхиянең күңелендә бу эшкә мәхәббәт уятырга уйлый иде, күрәсең. Тик Сәхиянең бик ашкынып торганы сизелми. Балалыгыннан аерыла алмый. Көтүдәге тәкәләргә атланып, җаннарын ала. Борылып-борылып үскән мөгезле бер сарык тәкәсен аяктан ега инде. Бу минем мотоцикл дип, авылны чыгуга, шуңа атлана. Теге мескен, Сәхияне чөеп ыргытмакчы булып, ничекләр генә сикерми. Әмма төшерерсең Сәхияне! Тәкәнең сыртына тигәнәктән ким ябышмый ул.

Көтүдән качарга яратучы сыерларга да көн күрсәтми Сәхия: авызыннан күбекләр килгәнче чыбыркылап йөри. «Синнән җүнле көтүче чыкмас,— ди Ибрай бабай.— Малларны җәлли белмисең».

Бер җәй йөргәч, бу эшне ташлады Сәхия. Кышкылыкка ашарына житәрлек иде. Укытучылар өенә килеп ялынса, мәктәпкә баргалады. Җиденче класста бер ел укыган иде инде ул, күчмәде генә. «Сыер койрыгын борырга белем кирәкми, барыбер шуннан ерак китәсем юк»,— дип, бөтенләй туктады. Укуын ташлавын белгәч, бригадир аны рәхәтләнеп эшкә җигә башлады. Ашлык сугу машинасыннан салам тарттырырга, тирес түгәргә, хәтта олылар белән урман кисәргә җибәрде. Сәхия эшне ярата иде, карышмады. Бик арыган чакларда бригадирдан җайлы гына котылу чарасын тапты ул. Ә хәйлә бик гади: алдавыч йозакны өйалды тактасының бер ярыгыннан кул тыгып тышкы якка элеп куясың да, вәссәлам! Бригадир, бу өйдә юк икән дип, борылып китә. Сәхиягә кызык. Бригадирны төп башына утырта алу рәхәтлегеннән тәгәри-тәгәри көлә ул. Бу хәйләсе бәлки озакка барган булыр иде, ләкин Сәхия үзен-үзе тоттырды: ишегән тышкы яктан бикләп, беркөнне бәрәңге пешерергә тотынды. Ә төтенне яшерә алмыйсың. Юкка гына мич турында: «Аның ашаганын бөтен авыл күреп тора»,— дип мәкаль чыгармаганнардыр.

Кыш шулай төрле эшкә чабып узды. Ә язга чыккач, Сәхиягә өр-яңа эш таптылар. Тракторларга су ташырга куйдылар аны. Яз життеме, колхозга МТСтан берничә трактор килеп төшә. Колхоз МТСтан килгән тракторчыларга аш пешерүче, су ташучы билгели. Су ташучыларга ат бирә. Тракторлар сөрә торган кырның һәр ике башына олы-олы су савытлары утыртыла. Су ташучы шушы савытларны һәрвакыт тулы тотарга тиеш. Чөнки тракторлар, бераз эшләүгә, кыза башлый, радиаторда су кайный. Кайнаган суны өзлексез алыштырып торырга кирәк. Шулар өстенә тракторчыларның үзләренә эчәргә, аш пешерергә, чәй кайнатырга, савыт-саба юарга гел су кирәк булып тора.

Сәхия бик яратты бу эшне. Атның гына артык өшәнгәне эләкте. Сыртын — ыңгырчак, муенын камыт кырып бетергән. Кырыена килеп, чыбыркы шартлатсаң да, ике колагының берсен селкетми. Коргаксыган мичкәне кыршаулары гына тотып торган кебек, сөякләре таралып китүдән тиресе генә саклап тора мескенне. Атның бердәнбер ошаган җире — колаклары булды. Җирән атта — ике ак колак. Сәхия үзенең ак колаклы

жирән биясен Аккош дип атады. Юк, аккошка охшаганга түгел, дөресен әйткәндә, аккошны күргәне юк иде аның, бу исем матур яңгыраганга шулай йөртә башлады ул атын. Сәхия дилбегәләрне кагып:

— Очтыкмы, Аккошым? — диюгә, жирән бия йокымсырап торган жиреннән сыңар күзен ачып карый. Сәхия чыбыркысы белән кабыргаларына берне менеп төшкәч, селкенеп куя, ә инде чыбыркы икенче тапкыр чыжлап узгач әкрен генә кузгала башлый.— Шулай, артык ашыкма,— дигән була Сәхия.— Җәй бар, кыш бар — ашыгып, ни эш бар, ди бит Гариф бабай.

Җирән биясенә сөйләнә-сөйләнә Ык буена барып туктый Сәхия. Яр кырыендагы чирәмлеккә атын тугарып җибәрә: «Ашый тор, Аккошым, әле мин бу мичкәгә чиләкләп су тутырганчы, ике тапкыр туеп өлгерерсең. Тик кара аны, Аккош булдым дип, очып китә күрмә. Син очып китсәң, мине бу эштән очырырлар. Безгә хәзер бик нык тырышырга кирәк. Өф-өфнең күзе дүрт булсын».

Тракторчыларга да ошады Сәхия: «О-о, безгә Сәхи балык шулпасы алып килгән!» — дип каршы алдылар аны беркөнне. Сәхия башта ни өчен болай диюләрен аңламый торды, баксаң — ул алып килгән суда әллә никадәрле вак маймычлар йөзеп йөри икән. Тракторчыларның төрлечә шаяру-көлүләренә ул күнегеп килә инде. «Үсеп буламы, егет!» — дип, шалт итеп җилкәгә сугуларына да исе китми. Дөнья аны әз суктымыни! Зәйнәп эби әйтмешли, бусы хәере генә. Сәхия инде туктаусыз кыйналып торган ат төсле, тормыш чыбыркысы тагын кайсы яктан килеп төшәр икән дип, гел сагаеп йөри. Ә көтеп-көтеп тә, чыбыркы төшмәсә, хәтта бераз пошына, тынычлыгын югалта башлый.

Биредә күңелле иде аңа, ә иң шәп ягы шул: тракторчыларга пешкән әйбәт токмачлы ашны сыйганчы ашарга була. Өстәвенә, һәр көн саен өч йөз грамм ипи бирәләр. Дөрес, ул ипи күп вакыт борчак оныннан пешә, ә борчак ипие әз генә искерә башладымы, сындырганда сузыла, гүя аның эченә чуалган җепләр тутырып куйганнар да ипинең кайсы башын сындырма, шуннан чуалган җеп очлары эләгеп чыга. Тик Сәхия моңарга шаккатмый, аның ашказаны тимерне эшкәртерлек, бугаздан гына үтсен. Аш пешерүче Тәлига апа: «Менә Сәхидән үрнәк алыгыз»,— дип, тәлинкәсенә салынган ашны ашап бетермәүчеләргә аны үрнәк итеп куя. Тәлига — Сәхия өчен генә апа, тракторчылар өчен ул яшь, житкән кыз. Тракторчылар кайвакыт майлы кулларын сузып: «Бер генә кочаклыйм әле үзеңне. Кулларым майлы булса да, кочагым җайлы минем»,— дип Тәлигага таба якынлаша башлый. Тәлига чырылдап кычкырып җибәрә. Өстенә ул гел кара итәк белән ак кофта кия. «Кофтамны пычратасың, якын килмә»,— дип чырылдаган саен, тракторчылар аны ныграк кысрыклый. Кайвакыт Сәхия Тәлига кофтасының күкрәк турысында бармак эзләре күрә. Имам исемлесе бигрәк тынгылык бирми Тәлигага. Будкада Тәлиганың ялгыз калганын күрсә, мәче шикелле тып-тын гына басып, кызны кочаклап алырга тырыша. Тәлига кармакка эләккән балыктай тыпырчына, тик колхоз ипие ашап тазарган Имамнан алай гына ычкынырмын димә. «Шул үгезнең маңгаена нигә чүмечең белән тондырмыйсың?» — ди Сәхия андый чакларда. «Син, үскәнем, бик яшь әле»,— ди Тәлига. Ә Имам Сәхиягә каш астыннан сөзеп карый: «У-ух, сабака! Пәрисең шунда кирәкмәгән җиргә юеш танавыңны тыгып». «Хатының килсә, кирәгеңне бирдерермен әле,— ди Сәхия тантана белән. Имамның хатыны барын-югын белмәсә дә.— Ул синең таш маңгаеңа нәрсә белән кундырырга белер».

Чынлап та, кайвакыт тракторчыларның хатыннары килеп чыккалый, кайберләре исә будкада кунып ук киткали иде. Сәхиянең бу сүзләреннән соң Имам, калҗата юлыгып та эләктерә алмаган ач маэмайдай, Тәлигага комсыз караш ташлый, ләкин күпмедер вакытка кулына ирек бирергә батырчылыгы җитми йөри. Әмма мондый хәл озакка бармый, бораү күзләр тагын Тәлиганы әзәрлекли. Әй, Тәлигасын әйтер идем:

үзе чыр-чыр килә, үзе шуңарга ныклап берне кундырмый. Әйтерсең, ач бүрене юри котыртып йөргән куян — гел шул маңгайсыз Имам тирәсендә чуала. Кешенеке төсле кыяфәте булсын иде ичмасам. Бармак киңлегендә маңгае юк. Кабактай башка ике тишек тишкәннәр дә, ни яшел, ни зәңгәр түгел ике күз чәпәгәннәр. Борынын әйт тагын: туу белән песи ашаган. Төбе генә калган. Табак хәтле биттә ул борын бәлеш уртасындагы шулпа тишегенә куелган камыр бөке кебек тора. Аның каравы, авыз мул. Күрәсең ходай: «Сиңа бүтән нәрсәнең рәтлесе тимәде, ичмасам авызың бөтен кешенекеннән артык булсын»,— дигәндер инде. Ашый башласа, кеше кадәр өч сыпыра. Ул туймас тамакка Тәлига итнең иң зур кисәген сала. Шушы булдымы кеше. Тфү!

Сәхиянең исәпләвенчә, Имамның кеше яратырлык җире юк иде. Ләкин ул аның хатынын күргәч шаккатты: шундый чибәр, мин сиңа әйтим, карап кына торырлык. Өстенә кигән киемнәре ялык-йолык итеп тора. Районда сатучы булып эшли икән. Хатыны килгәч, Имамның күзләре Тәлиганы бораулармый башлады. Әйтерсең, Тәлига бөтенләй юк: «Гөлзәрия, Гөлзәрия»,— дип, гел хатыны тирәсендә бөтерелә, әмма хатыны алай бик тиз эреп төшәргә охшамаган. Чебен кугандай, иренең сүзләренә кул гына селти. Аның Тәлигадан нидер сорашасы килгәнлеге күренеп тора. «Бар, бар, эшеңдә бул, без монда хатын-кызлар әзрәк үзара сөйләшеп алабыз»,— дип, ирен үз янынннан куып җибәрергә ашыга. Ирләр эшкә таралгач Тәлигага:

— Матурым, эшләреңне беразга куеп тор әле,— дип, йомшак кына итеп эндәште. Сәхинең болай матур итеп эндәшкән-сөйләшкән кеше күргәне юк иде.— Я, ничегрәк соң, ир-ат арасында эшләү бик кыен түгелме?

— Юк, кыен түгел,— диде Тәлига кулын сөртә-сөртә.

— Бик матур чагың, тулышкан чагың.— Гөлзәрия Тәлиганың күкрәкләрен, бил тирәләрен сыпырып куйды. Тәлига кыенсынып читкәрәк тайпылды.— Син, матурым, миннән оялма, әнә тегеләрдән оял.— Ул җир сөреп йөргән тракторчыларга таба ымлады.— Мөгаен, бәйләнәләрдер әле үзеңә, әйеме? Безнекенең кулы тик тора торган түгел.

Сәхия шул вакыт: «Әйе шул, ул тар маңгай Тәлига апаны интектереп бетерә»,— диярга уйлаган иде, Тәлиганың ничектер бөрешебрәк, тартыныбрак калганын күреп, дәшмәде. Ә Гөлзәрия иреннән болайрак итеп Тәлиганы кысрыклавында булды:

— Яшермә, матурым, яшермә. Безнеке кеше бакчасындагы алмага кызыккан бала кебек ул.— Тәлига Гөлзәриядән котылырга теләп, будкадагы урын-җирне рәтләргә тотынды, тик Гөлзәрия: — Тукта инде, матурым, кунак килгәч, өй җыештырмыйлар,— дип, кире аны үз янына утыртты.— Бәйләнәме? Хатыным юк диме? Я, я, тартынма, сөйлә. Синең кебек кызларга кызыкмаган ирләрнең эчендә җаны булмас. Әллә безнеке үзеңне куркытып куйдымы? Әйтсәң, дөнья йөзендә яшәтмим дидеме?

— Юк, юк, мин үзем...— диде Тәлига һәм, телен тешләп, ярты сүздә туктап калды. Ләкин Гөлзәриягә шушы сүз бик җиткән иде.

— Ах син, җир бит,— диде ул, секунд эчендә үзгәреп.— Әле син монда безнең ирләрне аздырып ятасыңмыни? Кәнтәй, тирес корты, ирләрне генә аздырмасаң, синең кебек кәнтәйгә нинди егет карасын? Менә авылыгызга кайтып әйтим әле...— Хатын бик озак тузынды. Тәлиганың ботларын — кул белән, җанын тел белән кап-кара иткәч кенә ире янына китте. Имам янында нинди пәри туе буласын күз алдына китерү кыен түгел иде.

— Нәрсәгә шул кабыксыз бәрәңгедән (Сәхия Гөлзәриягә ни өчендер кабыксыз бәрәңге дип исем такты, бәлки күлмәге ак булгангадыр) үзеңне талатып торасың? — диде.

— Син, үскәнем, берни аңламыйсың әле.

— Нәрсә, әллә мин аңгырамы? — диде Сәхия.

— Аңгыра дип әйтүем түгел, үскәнем,— диде Тәлига аны кочып,— башың яшь әле. Вакыты җиткәч аңларсың.— Ә хәзер бар...— Тәлига

үзе шулай диде, үзе Сәхиянең иңенә башын куеп елап жибәрде.— Юк, китмә. Мин моны барыбер кемгә булса да сөйләргә тиеш.

Һәм Тәлига үзенең яраткан егетенә тормышка чыгып, бер генә атна торып калуын, ичмасам бер тупылдатып сөярлек баласы булмавын ачынып сөйләде.

— Әй, сезнең барыгызны да бер чыбыктан куалаганнар,— диде Сәхия ачуланып. Аның күз алдына апасы килеп басты. Апасы турында нинди генә сүзләр йөрми хәзер. Имеш, баласын больнистан алмаган. Имеш, врачларга, бала бик кирәк булса, үзегезгә алып кайтыгыз, дигән. Сәхия апасына эчендә үпкә саклый: хат язармын, матур күлмәк салырмын, бераз рәтләнүгә, үз яныма алдырырмын дигән булды, юха. Сәхия аның күлмәк салмасын белеп торды, тик хат язып салырга ярты бит кәгазь таба алмыймыни?! Янына атылып килеп житәрләр дип куркадыр. Исе киткән ди Сәхиянең. Сезнең кебекләрнең поты бер тиен аңа.

Егетләр аны хәзер үз итәләр. Сабан туенда ат башына утырттылар. Егетләр-кызлар төялгән тройка кадәр тройканың дилбегәсен тоту бәхете кемгә эләгә? Бик тәти егетләргә дә мондый бәхет тәтеми. Чын егеткә әверелеп килә Сәхи. Борын астындагы бала йоннарын әтисеннән калган бритва белән кырып йөри. Еш кырсаң, мыек чыга диләр бит. Әйдә, егет икән, егет булырга! Мәчедән курыккан тычкан кебек ничу куркып йөрергә. Әнә, кызлар курыксын. Әле ул тракторга да өйрәнәчәк. Миша абый аны өйрәтергә буш куллап риза. Тик менә Миша абый — татарча, Сәхия русча белми. Мәктәптә укыганнары өченче көн ашаган бәрәңге күк әллә кайчан чыгып беткән.

— Өйрәнергә кирәк русча,— ди Миша абый аңарга.— Русча белмәгән кеше — телсез кеше кебек бит. Син моны авылыңнан чыгып китү белән аңлаячаксың.

Кирәк икәнен Сәхия үзе дә яхшы белә. Әмма русча сүзләргә теле һич бөкләнми шул. Беркөн, Миша абыйның тракторы ватылгач, Сәхиягә авылга тимерчелеккә кайтырга туры килде: «Быстренько скачи-ка в деревню. Привези мне подковый гвоздь»,— диде аңа Миша абый. Атына атлануын атланды Сәхия, әмма «подковый гвоздь»нең ни икәнен генә аңламады. Миша абый аңа ботинка астындагы дагасын күрсәтте. Янәсе, менә бу дага була, шуны кага торган кадак кирәк. Сәхия, төшенгәнлеген белдереп, баш какты, ә тимерчелеккә килгәч:

— Миша абыйның тракторы ватылды, ботинка кадагы кирәгие,— диде.

— Ботинка кадагы? — дип тимерче бик гажәпләнде.

— Әйе.

— Ватылган тракторга нигә кирәк булды икән ул ботинка кадагы? Бәлки Миша абыеңның ботинка табаны төшкәндер, ә? — Тимерче шулай сорашты. Ә Сәхия үз сүзендә нык торды:

— Урысчаны аның хәтле генә беләм инде мин. Миша абый «патковый гвоз» диде. Ызначит ботинка кадагы була.

Тимерче абзый Сәхиягә сиздерми генә көлеп куйды. Аннары Сәхиянең учына дүрткырлы берничә кадак салып: «Миша абзаң сиңа дага кадагы алып килергә кушкан. Мә, кесәң тишек булып, төшереп калдыра күрмә»,— диде.

Миша абый аның кадакларын күргәч бик сөенде.

— Менә бит булдыргансың, молодец,— дип мактады.— Ә хәзер бергәләп тракторны төзәтик инде.— Тракторчы, сүтеп ташлаган детальләрне пычрагыннан чистартып, кире үз урыннарына куйды. Тракторның ниндидер валы ычкынган икән, валның башындагы тишеккә Сәхия алып килгән дага кадагы кереп ипләнде.

— Хәзер беркая чыгып китә алмый инде бу.

Миша абый янында кайнашу Сәхиягә бик кызык иде. Ул инде хәзер нинди гайкага нинди ачкыч кирәген, тракторның кайсы рычагын

тарткач, кай якка борылуын, кая баскач кузгалып китүен, нишләткәч туктавын белә. Рөхсәт итсәләр,гөрләтеп йөртә алыр кебек. Рөхсәт кенә итмиләр. Тик Сәхия өметен өзми әле.

Кайвакыт Сәхиягә, запчастьләр алырга, районга барырга туры килә. Районга дисәләр, гел атлыгып тора ул. Районда станция, аннан поездлар уза. МТС тимер юлдан ерак түгел, синең белән килгән тракторчы әле бер җирдән, әле икенче җирдән кул куйдырып, тиешле запчастьны алганчы, Сәхия ыжгырып узган поездларга карап рәхәтләнә. «Боларны да кеше йөртә микән? — дип уйлый ул.— Мондый әкәмәтне йөртер өчен биш баш кирәктер. Трактор түгел ул сиңа. Моны йөрткән кешенең йөрәге дию пәриенеке кебектер. Куллары тимердер. Менә Имам белән көрәштерәсе иде поезд шуферын. Сыңар кулы белән сыртына салыр иде ул Имамны. Ату, әйдә көрәшәбез, әйдә көрәшәбез дип, теләсә кемгә бәйләнеп йөри. Маңгайсыз тәре».

Бигрәк яратмый Сәхия шул Имамны. Районга аның белән бергә барачагын белгәч, төрлечә хәйләләп карады:

— Минем тәгәрмәч таралырга тора. Район юлы — таш юл. Калтыр-колтыр бара-бара, берни калмас.

— Синең тәгәрмәчең күптәннән таралырга тора инде,— диделәр аңа.— Әйдә, җыен, ватылса, районда рәтләп бирерләр.

Карышуның файдасы тимәде, барырга туры килде.

Имам запчастьларны арбага чыгарып салгач: «Мин әле берәр көнгә монда калам. Мунча кереп, Гөлзәрия апаңның әзрәк күңелен күрәсе бар. Әнә бит ничек чәпчеп килеп җиткән,— диде.— Син үзең генә кайт»,— Имам серле итеп күз кысып куйды. Сәхия Имамның үзе белән кайтмавын белгәч, чак биеп җибәрмәде. Юлда ялгыз йөрергә ярата иде ул. Зәңгәрле-яшелле тавышың белән җырлый-җырлый кайтасың. Көлүче юк.

Ат Сәхияне җырыннан ук аңлый. Әгәр Сәхия сандугач сүзе белән башланып киткән җырлар җырласа, димәк, үз җаеңа кайтырга була. Сыртка чыбыркы төшмәячәк. Сандугач белән башланган җырлары әллә ничә Сәхиянең. Менә бусын аеруча еш җырлый ул:

> Сандугачның балаларын
> Тота алмаслар әле.
> Чәйнәсеннәр, сөйләсеннәр —
> Йота алмаслар әле.

Бүген дә Сәхия районның соңгы йортын узуга, шушы җырны башлады. Аккош адымнарын бераз әкренәйтте. Йөк җиңел, юл такыр иде. Егерме өч чакрым җирне кайтып җиткәнче, «сандугач» дип башланган бик күп җырлар җырланачак иде әле. Тик нәрсә бу, юлда бер чәчбикә кул күтәрә түгелме соң? Аккошның хуҗасы утыртыр микәнни шушы чәчбикәне. Юк, утыртмас, яратмый ич ул аларны. Ә алайса нигә дилбегәне тарта? Әйе шул, туктарга боера. Аккош — һәр боерыкка буйсынырга күнеккән зат. Нишлисең бит, туктарга кала.

— Чава? — диде Сәхия кыз янында туктап.

— Довези пожалуйста, парень, до Урала.— Барганда да, кайтканда да Урал дигән авыл аша үтәргә туры килә. Зур авыл ул, бер башыннан икенче башына чыга-чыга күзең күгәрә. Житмәсә, бу авылда малайлар усал. Өерләре белән арбага төялергә генә торалар. Каеш чыбыркыңны туктаусыз уйнатмасаң, башыңа менеп атланырга да күп сорамаслар.

— Ызначить син Уралский? — диде Сәхия кызны утыртып кузгалып киткәч.

— Да.— Кызның сөйләшергә дәрте күренми иде. Хәер, Сәхия дә аның белән сөйләшергә дип җан атып тормый әле. Белмәгән урысчаң белән тел арытканчы, җырлап кайтуга ни җитә.

> Ындырда ашлык сугалар,
> Машина килә ду-ду.

Синең ише ярлар белән
Заниматься не буду.

Сәхиянең бу җырыннан соң арбадагы кыз түзә алмады, пырхылдап көлеп җибәрде. Татар кызы икән кыланчык. Урысча сөйләндереп, кешене җәфалый. Бик ачуны китерсәң, төшердем калдырдым булыр. Сәхиянең талканы коры.

— Нәрсә дип ипи савытыңны кыйгайтасың? — диде Сәхия үпкә белән. Кыз аның сүзләрен аңлап җитмәде бугай, аптыраулы караш ташлады.— Шушы ак чырайлар кешечә сөйләгәнне аңламаслар инде. Нигә авыз ерасың дип әйтәм мин сиңа.

— Бигрәк кызык җырлыйсың бит. Безнең авыл егетләре мондый кызык җырлар җырламыйлар.

— Ә безнең авыл егетләре җырлыйлар.— Сәхия үзен егеткә санауларына сөенеп куйды. Соңгы вакытта ул ничектер буйга тартылып, чандырланып китте. Борын астындагы бала йоннарын кырып йөрүнең файдасы тияр кебек күренә. Ә тавыш ягына килгәндә — ансы аңарда аллага шөкер.

Сәхиянең бу кыз белән егетләрчә сөйләшәсе килеп китте. Ничек сөйләшәләр икән соң егетләр шул чыркылдыклар белән? Кызның сер капчыгын чиштерергә иде.

Шактый баш ватып барды Сәхия, аннары кызга хикмәтлерәк берәр җыр җырлап карарга булды, ләкин иң кирәк чагында алары каядыр качты, каһәре. Эһе, менә берсе тел очына килеп төште әле:

Алмаларны ашар идем
Басып ботакларына.
Серләремне сөйләр идем
Ятып кочакларыңа.

Кызга карады, кыз көлми иде. Тагын берне җырлады:

Алмачылар алма ашый,
Алманың ни туклыгы?
Яшь йөзләремне саргайта
Җан сөйгәннең юклыгы.

— Кызык егет син,— диде кыз.— Син гел шулай җырлап йөрисеңме?

— Юк, синең кебек кызлар күргәндә генә.

— Мин нинди соң? — Сәхия кызга текәлебрәк карады. Чибәр нәрсә чукынчык! Түштәге ике калкулык алъяпкыч атламаларын әнә ничек кабартып тора.

Сәхиянең бу кызны чырылдатасы килеп китте. Ул тыныч кына барган атына берне сыдырды: кыз да, Сәхия үзе дә артка чөйлектеләр. Шул чөйлегүдән файдаланып Сәхия үзенең тузган башын кызның алдына салды.

— Беләсеңме син нинди?

— Нинди?

— Бозау төсле.

— Бозау төсле? — Кыз үпкәләп икенче яккарак борылып утырды. Сәхия аның үпкәләвен чынга алмады. Аның өчен яшь бозаудан матуррак нәрсә юк кебек. Сәхиянең әле хәтерендә: әниләре исән чакта алар сыер асрыйлар иде. Сыерның бозаулаганын кыш буе көтеп йөрисең. Менә бервакыт әтиләре, бөтен тәненнән пар бөркеп торган юеш бозауны күтәреп, өйгә алып керә. Һәркемнең йокысы ачыла. Өйне суыта дип тормыйлар, сыерны да өйгә кертәләр. Сыер үзенең бәбкәчен ялап корыта. Бозауга бераз хәл керә, ул торып юанмакчы була, тик аяклары идәннән шуа да дүрт тәпи дүрт якка аерыла. Бозауны корсагыннан күтәреп торгызышасың. Бозау әнкәсенең имчәгенә борынын төртә, сыерның күзләре шатлыктан мөлдерәмә. Ә берничә көннән күрше-тирәне угыз ашына җыясың. Карчыкларның сәкедә тезелешеп утырып, тәмле угыз ашы

ашаганнарын почмактан бозау карап тора. Минем аркада сыйланганыгызны онытмагыз, янәсе. Юк, карчыклар шатлыкның төп сәбәпчесе ул икәнен онытмыйлар. Бозауга да, сыерга да озын гомер тели-тели дога кылына. Өйнең почмагында кашытырга муенын сузып торган яшь бозау булганда, өй бәйрәм төсен ала.

Сәхиянең күз алдыннан шундый күренеш узды. Ул күзен кыса төшеп кызга карады.

— И ускәнем,— диде кыз бозау турында бөтенләй онытып.— Бигрәк яшь шул әле син.— Үзе шулай диде, үзе Сәхияне этеп җибәрмәде. Киресенчә Сәхиянең кепка астыннан бүселеп чыккан чәчләрен бармагына урап, уйнап бара башлады.

— Ә син кайда эшлисең? — диде Сәхия.

— Мин әле эшләмим. Быел менә район мәктәбендә унны бетердем. Районга эш эзләп барганыем.

— Таптыңмы соң?

— Юк!

— Безнең колхозга кил. Тракторчыларга аш пешерүче итеп алам үзеңне.

— Аш пешерер өчен унны бетермәдем мин. Колхозда чиләнеп йөрмәсен дип укытты мине әти-әнием.

— Ә-ә,— диде Сәхия кызның алдыннан торып. Кызның үз укуы белән һавалануын ул үзе кебек наданнарга төрттерү дип кабул итте.

— Нәрсә, әллә син колхозда шыр наданнар гына эшли дип беләсеңме?

— Мин алай димәдем. Әүдересен генә әйтсәк, менә синең тракторчыларыңа аш пешерер өчен ун ел уку кирәкме? Юк! Сыер савуны алыйк, сыер имчәгенең кайда икәнен белү өчен дә ун класс кирәкми.

Кыз берничә һөнәрне санап чыкты. Сәхиянең аңа каршы куярлык дәлилләре юк иде, әмма барыбер күңеленнән кыз белән бәхәсләшеп барды, хәтта үзенең дәлилләре юклыкка, бер сүз белән кызның авызын томалый алмавына үртәлеп куйды.

— Син районда укыгач, урысчаны шәп сукалыйсыңдыр алайса,— дип, кызны бу яклап сынамакчы булды. Русчаны шәп белгән кешеләргә аның ихтирамы зур иде.

— Әлбәттә. Минем произношением буенча татар икәнлегемне дә белмиләр.

Сәхия «произношение»нең ни икәнен белми иде. Тик аптырап калмады.

— Алайса әйт әле: урысча тәртә ничек була? — диде ул.

— Оглобли.

— Ә ыңгырчак?

— Нәрсә соң ул ыңгырчак? Мин бит аның татарчасын да белмим.

— Әнә теге ат сыртындагы әйбер.— Кыз җилкәсен сикертеп куйды. Бу тәкәбберенең борынына чиертә алуына бик сөенде Сәхия, ул яңаданяңа сораулар яудырды:

— Чөелдерекне беләсеңме?

— Син миннән әллә нинди юк-бар нәрсәләр сорыйсың.

— Ничек инде юк-бар булсын? Ыңгырчактан, чөелдеректән башка ат җигеп кара син.

— Мин бит ат караучылыкка укымадым.

— Ә-ә, шулаймыни? — Сәхия эчтән тантана итте.— Алайса төш арбадан. Чөелдерек белән ыңгырчакны да белмәгәч, ничу атка утырып йөрергә!

Кыз, чынлап әйтәме бу дип, Сәхиягә күтәрелеп карады. Ул инде чибәрлеге, укымышлылыгы белән бу егет аламасын тәмам сихерләдем дип уйлаган иде.

— Я, я, төш!

Кыз арбадан сикереп төште. Бик хәтәре калды аның. Тәнендәге бөтен күзәнәкләре белән үзенең матурлыгын тоеп торган кызны аттан төшереп калдырсыннар әле. Бу бит синең матурлыгыңны танымау дигән сүз. Чибәр кыз өчен моннан авыр ни бар тагын?

Кыз юл чатында басып калды. Ул озак кына бу хәлнең чынлыгына ышана алмады. Менә теге егет аламасы артына борылып, менә ялына-ялына утырырга кыстар, синең кебек кызны утыртып йөрү үзе зур бәхет дияр кебек тоелды. Сәхия борылып килсә, бераз ялындырмакчы иде, ә тегесе борылып та карамады. Киресенчә, Аккошка берне сыдырып кызулап китте. Җебегән кызлар алдында үзенең өстенлеген тою тантанасы аның күңелен кузгаткан иде.



## 6

Сәхия бу эштә берничә ел эшләде. Шушы еллар эчендә үсте, ныгыды, матурайды. Кызлар аңа астан-астан күз салып киткәли башладылар. Әллә соң бу исәр баш чынлап та егет кеше микән? Әнә ич борын астында кап-кара мыек үсеп килә. Йөреше, тавышы нәкъ егетләрнеке. Ул көче тагын. Ирләр төшерә алмаган сулы мичкәне арбасыннан өереп төшерә. Дөрес, монда ул көчкә караганда хәйләгә ныграк таяна. Әкрен-әкрен атын бора, ат борылган саен, арбаның алгы тәгәрмәче аскарак кереп, арбаны бер якка янтайта бара. Ә Сәхия суы түгелмәсен өчен мичкәнең авызын һаман өскә табарак калкыта. Билгеле, сыер корсагыдай мичкәне кул белән генә борып булмый. Монда тракторчылардан алган юка башлы лом ярдәм итә. Суны түкмичә мичкәне җиргә төшерергә өйрәнгәнче күп тапкырлар телне аркылы тешләргә туры килде аңа. Кайчагында ат кинәтрәк борылып китеп мичкәне йөзтүбән капландырып та куйгалады. Җәһәннәм тишегеннән барып алган чишмә суың (эчәр өчен хәзер ул бары тик чишмә суы гына алып килә иде),оясына качкан елан кебек, минут эчендә юкка чыкса, теленне генә түгел, терсәгеңне тешләрсең. Әмма Нужа бабай ярдәмчел бит ул. Булышты, ярдәмләште. Сәхиядән менә дигән егет ясады.

Авыр физик эш үзенекен итте: хатын-кызларда гына була торган нәфислек аңарда яралган хәлендә килеш үк җан бирде. Түш өстенә ояларга тиешле ике ак күгәрчен үзләре урынына борыннарын гына кадап калдырдылар. Аның каравы беләк мускуллары кабарды. Әгәр авырып, Сәхиягә укол кадарга туры килсә, медсестралар аның тәненә энә кертә алмыйча җәфаланырлар, мөгаен.

Сәхия хәзер тракторны да җиңел йөртә. Кайвакыт тракторчылар: «Әллә бер-ике урыйсыңмы?» — дип, аңа үзләре үк тракторларын бирәләр. Сәхия карышмый: бер дә урый, ике дә. Кайвакыт яртышар көн трактордан аерылмаган чаклары була. Ә тракторчы күләгәдә йокы симертә. Кичен кызлар озатырга көч җыя. Тик Сәхиянең үзенең эшен эшләүче генә юк. Сусап килгәндә эчәрләренә теш сындырырлык салкын су булмаса — мыгырданалар. Гел генә ул суны ничек салкын тотаргадыр?

Печән өсләрендә Сәхиянең дәрәҗәсе бик күтәрелеп китә. Нигә дисәң — Сәхиядә ат бар. Аның Аккошы хәзер элеккечә тире белән сөяктән генә тормый. Кабырга араларына ит кунды, камыт кырган, ыңгырчак баскан урыннары төзәлде. Теләсә нинди йөкне рәхәтләнеп тарта. Артык кумасыннар гына. Нәрсә-нәрсә — кызу йөрүне яратмый Аккош.

— И акыллым, бер генә йөк печәнем барые, атыңны биреп тормассың микән? — дип гозерләнеп килүчеләргә күп вакыт атын биреп тора ул.

— Түлке артык куалама, — дип кисәтә биргәндә.

Ләкин кеше дигәнең, синең яныңда чагында гел син кушканча гына эшләр кебек тоелса да, капкаңны чыгуга, үзенчә эшли. Ат кулга эләккәндә, күбрәк төяргә, күбрәк юлларга тырыша. Бер йөк дигән печән

ике-өч йөк булып чыга. Аккош арый, йончый. Арыган ат белән көне буе эшләргә кирәк була. Атын ял иттерергә җибәрсә, Сәхияне сүгәргә тотыналар. Нигәдер менә нәкъ ат арыган көнне районга яки берәр колхозга барырга туры килә. Мондый чакларда: «Бүтән беркемгә атны бирдем юк!» — ди ул ярсып. Һәм озак вакыт бирми йөри. Хәтта тәкәббер Рәмзине дә кырт кисеп, борып чыгарды. Тегесе үз-үзенә бик ышанган хәлдә:

— Кайнеш, Аккошың белән очып кына эрәмәгә барып кайтыйм әле,— дигән иде, Сәхия аңа:

— Алай бик очасың килсә, әнә ала каргага атлан,— дип,— тал башында утыручы каргага күрсәтте. Рәмзинең җен ачулары чыкты, тик ачуын бугазына утырган төере белән йотарга булды, чөнки әле ул Сәхиянең күңелен йомшатып, атны алырмын дип өмет итә иде.

— Я, я,— диде Рәмзи,— мин шаярдым гына. Әйдәле, утырып берне тартыйк.— Рәмзи, кесәсеннән папирос чыгарып, Сәхигә сузды.

— Мин ташладым,— диде Сәхия. Чынында исә аның бик тартасы килә иде. Малайлар белән мунча себеркесе яфрагы тартудан башлан-ган нәрсә хәзер гадәткә керде.

— Кара инде, үз аты кебек кылана.

— Миңа бирелгән — минеке! Мин бит синең гармуныңны барып сорамыйм.

Рәмзи күп ялынырга өйрәнмәгән иде, күрәсең, сүгенмичә түзә алмады. Әмма сүгенеп кенә Сәхиянең күңелен яралап булмасын аңлый иде ул, шунлыктан үтемлерәк итеп сугарга уйлады.— Апаң юмартрак иде...— Рәмзинең мыскыллы елмайган авызына Сәхиянең тәмәке һәм дегет исләре аңкытып торган йодрыгы килеп төште. Бу йодрык гүя бергә йомарлан-ган биш бармак кына түгел, ә чуалып-уралып үскән агач тамыры иде. Йодрыкның авырлыгын, ныклыгын Рәмзинең авызы бик тиз сизде. Рәмзи буйга озын һәм яшькә Сәхиядән өлкән булса да шактый йомшак буынлы иде, шуңамы — көрәшне дәвам иттерүне кирәк дип тапмады. Авызын-дагы канлы төкереген Сәхиянең битенә чәпәп, тизрәк чыгып китү ягын карады.

— Күрсәтермен әле мин сиңа, сөләгәй!

Мондый янаулар Сәхия өчен әллә бар, әллә юк. Клубка чыккач, Рәмзи аны егетләрдән тукматмакчыдыр, мөгаен. Әй, исең киткән икән, бер мәртәбә артык тукмалудан ни була? Тән генә ныгый.

Сәхиянең бүген кичке уенга чыгарга исәбе юк иде, шөлләттем дип уйламасын әле дип, чыгарга булды. Клубта гадәттәгечә вечер бара. Озын эскәмияләрне як-якка тезеп, уртада биер өчен мәйдан ачканнар. Үсмерләр көнбагыш яра. Кызлар-егетләр берәм-берәм уртага чыгып биеләр. Сәхия керү белән гармунчыга күз салды: гармунчы — Рәмзи түгел, әле күптән түгел ГДРда хезмәт итеп, аннан бик матур кызыл аккор-деон алып кайткан Фуат иде. Сәхия җиңел сулап куйды: тукмакны соңрак алуың хәерле.

Кәефе әйбәтрәк чакларда Сәхия уеннарга теләп катнаша. Әгәр матрос биюен биеп җибәрсә, бөтенесе, авыз ачып, аңа карый. Ә бер тотындымы, гармунчыны арытмыйча туктамый инде ул. Узган атнада яңа ботинка киеп килгәч тә тоташ бер сәгать биеде.

Бүген дә аны биергә чакырдылар, ләкин Сәхия чыкмады. Аның әле күңелендә һаман Рәмзи белән көрәш бара иде. Клубта уеннардан ямь тапмый, өйгә кайтып китәргә дигәндә генә почмакта домино сугучылар өстәле янында бер ялгызы басып торучы ят егетне күреп алды ул. Егетнең өстендә ак костюм, башында авыл егетләренеке кебек кепка-фәлән дә юк — яланбаш. Ул ак самавыр төсле әллә каян аерылып тора. Мөгаен, районда нефте эшендә эшләүчедер. Нефтьчеләр шулай авыл яшьләрен шаккаттырыр өчен фырт киенергә яраталар. Бусы — барысын-нан да уздырган: ак костюм киеп килгәннәре юк иде әле. Бәлки берәр начальник-фәләндер. Алай дисәң, бик яшь. Йөзендә дә кәпраю-мазар

сизелми. Киресенчә, аның йөзе үзенә бер яктылык, җылылык сибә сыман. Кызлар астан-астан гына аңа күз ташлыйлар, әмма егет аларның карашларын сизми. Ул мавыгып уеннарны күзәтә. Вакыт-вакыт кырыенда басып торучы егетләргә нидер әйтеп куя.

Бу егетне күрүгә, Сәхиянең йөрәген нәрсәдер чеметеп алгандай булды. Чыгып китәргә дип атлаган аяклары бусагага ябышты. Күңеленең кайсыдыр почмагында ят бер аваз: «Янына бар, якынрак бар»,— дип пышылдады. Ләкин Сәхия урыныннан кузгала алмады. Хәтта үз тирәсендә кайнашкан яшьләрне дә күрмәде. Ул озак вакыт караңгыда торып, яктыга чыккан кеше төсле иде.

Бу халәт бәлки озак дәвам итәр иде, ләкин тәмәке тартырга чыгучы бер төркем яшьләр аны үзләренә ияртте. Ул, магнитка ябышкан тимер кисәгедәй, тегеләр төркеменә кушылды.

Клуб ишегалдына чыккач кына үзен ияртеп төркемнән аерылды. Аның әз генә вакытка булса да ялгыз каласы, уйларын тәртипкә китерәсе килде. Җитмәсә төне нинди! Күктән чекерәеп йолдызлар карый, әйтерсең, подноска өелгән чәкчәк. Җил, ирка песи баласыдай, сиздерми генә, йомшак кына итеп куенга керә, битләргә койрыгы белән кагылып китә. Күңел түреннән нинди чишмә тибәргә маташканын төшенмичәише алдында шактый йөрде ул. Эчендә нәрсәдер кайнады. Өелеп торган утыннарны таратып ташлыйсы, әллә ниләр җимерәсе, үзгәртәсе, яңадан корасы, һич югында бер үксеп елыйсы килде.

Үзенә урын таба алмыйча ул кире клубка керде. Клубта уен кызган иде. Авылның иң чибәр кызы Гөләндәм ялтыравыклы башмакларын шапы-шопы китереп биеп ята. Бөтен егетләрнең күзе аңарда. Кунак егетен әйткән дә юк: ул, гаҗәеп чәчәк күргән бала кебек балкып, онытылып, яратып, сокланып, Гөләндәмне күзәтә. Гөләндәм кызылга ак ромашкалар төшкән ситсы күлмәгенең итәген чеметеп тоткан да кунак егете янында бөтерчектәй әйләнә. Бүтән чакта ялындырып маташа иде, бүген Гөләндәмгә әллә ни булган. Гүя күренми торган канатлары бар: очып-очып бии. Менә ул кунак егете алдына килеп шыпылдатып басты да баш иде. Янәсе, әйдә, безнең белән ярышып кара. Тик кунак егет очып чыгарга ашыкмый, шап-шып басып, үзен чакыручыга карап, тик тора. Егетләр аны эткәлиләр: бар инде, биергә чакыра бит, диләр. Кунак егете җилкәләрен җыера, бии белмим дигәнне аңлатмакчы була. Әмма Гөләндәмнең бирешергә исәбе күренми. Без синең ишеләрне генә түгел, кыяны да баш идерәбез дигән сыман горур, тәкәббер, таләпчән, назлы кыяфәт белән һаман саен ярсыбрак бии. Кунак егетнең Гөләндәмгә каршы очып чыкмавына Сәхия күңеленнән рәхмәтләр укый: «Чыкма, егет бул! Матур кызлар алдында бар кешегә дә эреп төшергә димәгән». Әмма егетнең озак каршы тора алмаячагы күренеп тора. Ул: «Синең янында бер бөтерелү үзе зур бәхеттер»,— дигәндәй, мөлдерәп, Гөләндәмгә карый. Һәм кызның, үз турысына житкәч горур башын янә бер түбән иеп, ымсындырып дәшүенә түзә алмый, тыңламас аякларын сөйрәп тыпырдый башлый. Ялындырып маташса да, бию дигән нәрсәдән бөтенләй мәхрүм түгел икән. Әле бөтерелеп, әле аягын тукылдаткалап рәвешен китерә. Шунысы да бар: матур кыз янында син никадәр шәп биемә, барыбер күләгәдә калачаксың. Синә түгел, аңа караячаклар, аны күрәчәкләр. Хәер, алай дип кистереп әйтергә ашыкмыйк. Әнә ич, Сәхиянең күзләре гел кунак егетендә. Егетнең Гөләндәмгә ошарга тырышып, әле уң ягына чыгып, әле сул ягына чыгып йөрүләрен ошатмыйча тешләрен кысып тора. Гөләндәмне түгәрәк уртасыннан тартып алып, кунак егете каршысына үзе барып басасы килә. Менә ичмасам биеп күрсәтер иде. Башка вакытта күңелендә нинди дер теләк туса һич икеләнеп калу белмәгән Сәхияне бүген нидер тотты, нидер тыйды. Ят кешегә карагандай, үзенең өс-башына күз салды һәм гарьләнүгә, кимсенүгә якын хисләр кичерде. Гомерендә беренче тапкыр башындагы кепкасын, өстендәге пинжәк-чалбарларын йолкып атып, аяк астына салып таптыйсы,

Гөләндәмнеке кебек җиңел ситсы күлмәк киеп җибәрәсе килде.
Эчтән кайнап чыккан ярсу бугазга олы төер булып утырды. Яка муенны буды, суларга комачаулады. Ул: «Их»,— дип, изү төймәсен тартып өздe дә урамга чыкты.

Озак йөрде ул урамда. Кычыткaнлы тар тыкрыкларга керде. Өреп калган этләргә таш атты.

Кара урманның өстеннән
Килә болыт күкерәп.
Эчем тулы утлар яна,
Ничек чыдыйм күкерәк,—

дип җырлап алды. Әнә шулай ялгыз башын кая куярга белми йөргәндә, өерелешеп сугышып яткан егетләр төркеменә тап булды. Башта ул аларны читләтеп үтәргә уйлаган иде, тик нәрсәдәндер сагаеп, алар янына барасы итте. Егетләр теге кунак егетен тәпәлиләр икән. «Безнең кызларга борыныңны сузма»,— дип очып-очып куналар. Кунак егете исә караңгыда төрле яктан килеп төшкән тукмакларга җавап бирә алмыйча ике кулы белән башын тоткан. Авылга килгән кунак егетләрен кайчак «сыйлап» җибәрү күптәннән килгән гадәт булганга, Сәхиянең моңа исе китмәде. Тик шуны беләсе килә иде: кемне озаткан икән бу егет?

«Гөләндәмне! — дигән уй кинәт миен ярып үтте.— Әлбәттә, Гөләндәмне. Кызның бер алдына, бер артына чыгып, ничек бөтерелде бит»

Сәхия бермәлгә ниндидер канәгатьләнү тойгандай сизде. Минем якка күтәрелеп карамаган идең, матурларга күз атсаң, шулай була ул, янәсе. Тик бу хис, атылган йолдыздай, күз ачып йомганчы юкка чыкты. Шундук аны икенче нәрсә — чит-ят җирдә яклаучысыз калган егетне тегеләр кулыннан йолу теләге биләп алды.

— Нәрсә сез бер кешегә унау ябырылдыгыз? — дип кычкырды ул. Аның яшелле-зәңгәрле тавышы тегеләрне сискәндереп җибәрде. Кем икәнлеген танычач: «Ат аягын дагалаганда бака ботын кыстырган. Йөрмә монда буталып»,— дип читкәрәк эттеләр. Ләкин Сәхия кыза башлаган иде инде, тәпәләшкән кешеләрнең уртасына барып керде. Егеткә эләгәсе тукмакның яртысы аңа төште. Сәхия дә тегеләрне өлешсез калдырмады: кемнең кулын тешләде, кемнең чәчен йолыкты. Егетләр тешләнгән кулларын уа-уа, «убыр», «мунча пәрие» кебек сүзләр белән Сәхиягә ябырылдылар. Кунак егете шуннан файдаланып, каядыр юкка чыкты.

Сәхиянең эчендәге гарьлек, кимсенү, язмышка булган ачу, тау астыннан бәреп чыккан чишмәдәй, бүген кинәт өскә калыкты. Шуңа күрә үлгәнен-калганын белмәде ул. «Сыер дуласа аттан яман»,— дип, егетләр сукраныштылар. Егетләр таралышкач, шунда капка төбендәге ташка утырып, күз яшьләренә ирек бирде. Кыен, бик кыен иде. Ул хәтта теге кунак егетенең үз янына килеп басуын да сизмәде. «Авыртамы, брат?» — дип, егет аның җилкәсенә кулын салгач кына башын калкытып карады. Шул вакыт егетнең җилкәсенә куйган кулына башын салып, өр-яңадан үксисе килде. Гомерендә бер генә тапкыр булса да юатуга, яклауга, назлауга хакы бардыр бит Сәхиянең? Ләкин егет аны юатырга ашыкмады. Кесәсеннән папирос алып, Сәхиягә сузды: «Тартып җибәрик, дускай. Яшь чакта кызлар өчен кыйналмаган егет юк. Ә яклашуың өчен рәхмәт. Чын егет икәнсең. Шәп сугыштың».

Башка чак булса, мондый сүзләр күңелне канатландырып җибәрер иде, бүген аның бөтен күзәнәкләре: «Мин кыз кеше, мин кыз кеше!» — дип кычкыралар иде. Егетнең саубуллашырга сузган кулын озак җибәрәсе килмәде. Әгәр шул вакыт күңеленең мөлдерәмә савытына иплэп кенә кагылсаң, һич югы җылы сүз әйтеп, башыннан сыйпасаң, эчкә җыелган ачы су ташып түгеләчәк, җанын ачып бирәчәк иде ул. Ләкин баштан сыйпаучы булмады.

«Җитте! Бүгеннән салып атарга бу карачкы киемнәрне. Кай җире

кешенекеннән ким аның? Куллары катымы? Гөләндәм кебек әтисе-әнисе алып кайтканны ашап үсмәде шул ул. Буе зифа түгелме? Ә кем белә, бәлки зифадыр. Билләрен өзеп торган күлмәк киеп җибәрсәме? Чиертәчәк әле ул Гөләндәмнәрнең борынына. Кунак егетләре Гөләндәм өчен түгел, Сәхия өчен сугышырлар». Ул үзен билләп тегелгән күлмәк, ап-ак туфлиләр кигән итеп күз алдына китерде. Кашларны, керфекләрне бүтән кызлар кебек каралтасы юк — алары шәп. Чәчләрен әйбәтләп юып тарыйсы гына, эре дулкыннар кабарып китәргә генә тора. Ә эш ягына килгәндә — кызлар белән эшли торган җиңелрәк эш беткәнмени? Бүтәннәр кебек инәнә бизәкле тырмалар салып болынга печән җыярга барыр, алар белән бергә-бергә су керер, уеннарда катнашыр. Исемен Сәхи дип түгел, Сәхия дип әйтергә кушар. Әйе, бүгеннән яңадан Сәхия булачак ул.

Уйларына бирелеп, ничек өенә кайтып җиткәнен дә сизмәде Сәхия. Ишегалдына килеп кергәч кенә айнып китте, чөнки ишегалдында һәрвакыт керт-керт үлән ашап каршы алучы Аккош юк иде. «Сасы көзән — Рәмзи! Бары тик шул гына!» — диде Сәхия һәм тозлап-борычлап сүгенеп куйды. Ишегалдында ат кына түгел, арба да юк иде. Димәк, Рәмзи аңардан менә ничек итеп үч алырга уйлаган. Ничава, әллә кая китә алмассың.

Сәхия өенә кереп тормады, туры Рәмзиләргә юнәлде. Аның әле башында нинди дә булса ачык планы юк иде. «Кара канга батканчы сугышырга, Рәмзине яңадан кеше әйберенә сузылмаслык итәргә»,— дигән ярсу ашыктырды аны. Кызлар күлмәге киеп, яңача яши башларга дигән уйлары җил тараткан төтендәй юкка чыкты. Күкрәгендә дию пәриләрен җиңәрдәй көч барлыкка янә шатланды. «Ничава, без алай чебен тигәнгә чер итмәбез, әллә кемнәргә әләкләшеп тә йөрмәбез. Үзебез өчен үчне үзебез алырбыз». Ул кесәсенә берничә таш салып куйды. Кирәге чыгуы бар.

Төн якты, айлы иде. Тик бераздан ай, гашыйкларны озатып бетердем, инде әз-мәз черем итеп алсам да ярыйдыр, дигәндәй, болытларга төренеп йокларга ятты. Рәмзиләр турына килеп җиткәндә, караңгылык, салкында тоткан дегет кебек, куерды. Саклык кирәген бөтенләй онытып, капканы тибеп ачты Сәхия. Аның исәбенчә Рәмзиләр печәннән кайтып, нәкъ менә хәзер бушатып ятарга тиешләр иде.

Сәхия үз күзләренә генә ышанырга теләмичә ишегалдын урап чыкты, бакча артларына күз салды. Һичбер җирдә бушатылган печән күренмәде: «Минем вакыт җитәрлек, көтәрбез». Ул капка төбенә чыгып утырды, тәмәке кабызды. Әмма йөрәк ярсуын тәмәке генә басмады: «Нәрсә эшләп яталар инде? Тизрәк кайтсыннар иде, тизрәк».

Эчендә вулканнар кайнады, таулар тетрәде. Бу ташкын көчне күкрәккә генә сыйдырып бетереп булмый, ул тамырлар буйлап килеп, йодрыкларны йомарлата, аяк табаннарына төшеп китә, беләк мускулларына йөгерә иде. Үзе өчен генә түгел, Сәкинә апасы өчен дә үч аласы бар. Сыер башы хәтле гармунын өстерәп, көн саен Сәкинәләргә килеп, кеше күңелен җилкендерде. Ә хәзер әллә каян чит авылдан кыз алып кайтты. Кич җитсә, җитәкләшеп клубка чыгалар. Рәмзие гармун тарта, хатыны бу авылда белмәгән-күрмәгән уеннар оештырып йөргән була. Клуб мөдире иттеләр дигәч тә. Сәкинә аның кадәр генә уеннар оештыра алмас идеме? Кырыенда апасы булса, бәлки Сәхиягә җиңелгәрәк төшәр иде. Авыр тормыш аларның әнисен гүргә кертте. Сугыш әтисез калдырды. Әтисенең сугышка китәр алдыннан сәкегә утырып: «Дөньясына утлар капкан, безгә тия ялкыны»,— дип моңаеп җырлаганы Сәхиянең күз алдыннан озак китми йөрде. Ләкин үлгәннәрне кире кайтарып булмаганны белгәнгәме, әти-әниләре якты бер хатирә, татлы сагыш булып кына калды, ә менә апасы еш кына искә төшә дә йөрәкне чеметеп-чеметеп ала. Әллә нинди сагыну белән сагына ул апасын. Бер карасаң, эт итеп сүгәсе, икенче карасаң, бәләкәй вакытта әнкәсенең алдына яткан кебек алдына ятып иркәләнәсе, шаяра-шаяра әүмәкләшәсе, үртәп чәчләрен

тартасы, «тоталмыйсың», «тоталмыйсың» дип куышып йөгерәсе, йоклаганда бөгәрләнеп куенына кереп ятасы килә.

Янында әпасы булса, дөнья бу кадәр үк шыксыз тоелмас иде. Хәзер инде Сәхия аны яклый белер иде. Ах, дөньяның бу усалларын!

Сәхия дөньяның астын өскә әйләндерердәй булып сикереп торды. Инде таң да атарга маташа. Төнге караңгылыкны ераккарак куалап, салкын җил исә. Әллә салкынлыктан, әллә эчке киеренкелектән, тәнгә калтырау төште. Артык күтәргә мөмкин түгел, ә үч алмыйча да кайтып китәргә ярамый иде. Ул кесәсендәге ташларын Рәмзиләрнең тәрәзәләренә тондырырга тотынды. «Бусы Сәкинә өчен, бусы ат өчен». Әтәч кычкырган тавышларны басып, зыңгылдап тәрәзәләр ватылды. Эчтә ут кабыздылар, шау-шу, ыгы-зыгы купты. Сәхия караңгылыкка кереп эреде. Аның эчендә тантана иде. Ә тынычланган башта акыллы планнар туа, матур фикерләр килә. Сәхия дә: «Хәзер кайтып өскә калынрак киям дә, сасы көзәннәргә бригадирны алып киләм. Менә шунда ничек боргаланырсың икән»,— дип бик акыллы уйлар уйлап кайтты. Ә кайтып керсә...

Кайтып керсә, ишегалдында арбасы-ние белән аты тора иде. Кемдер төне буе Аккошны эшләткән. Аккошның тәне дер-дер килә, муен тирәләре, корсак аслары лычма су. Аккош: «Нигә мине шундый комсыз, усал кешеләрдән җәберләттерәсең? Мин бит сиңа турылыклы хезмәт итәм. Хаксызга сыртыма чыбыркы төшерсәң дә рәнҗемим. Ә син якламыйсың»,— дигән кебек хуҗасына мөлдерәп карап тора. Хәтта алдына салган үләнне ашарлык та хәле калмаган. Сәхия, атын кочаклап, үкси башлады: «Их, Аккошкаем. Аңламыйм мин кешеләрне. Нигә кешеләр шул тиклем каты бәгырьле? Нигә гел көчсезләрне, яклаучысызларны рәнҗетәләр? Нигә, нигә?..»

Беркемгә бирмәгән сорауларны Аккошка бирде Сәхия. Аккош салкын, юеш танавын хуҗасының муенына, битенә төртеп, үзенчә сүзсез генә җавап кайтарып торды.

Аларның икесенә дә бик кыен иде.

## 7

Аккошның инде яше шактый иде, төне-төне җигелүгә түзә алмады, берничә көн тамактан калып ятканнан соң Сәхиянең кулына башын салып җан бирде. Сәхия Аккошның ачылып калган дымлы күзләрен әрекмән белән ябып куйды. «Чебеннәр утырмасын!»

Инде нишләргә икән? дигән сорау туарга өлгергәнче, Сәхияне идарәгә чакырттылар. Өф-өф Насыйбуллинның бик ярсыган чагы иде, ахрысы. Сәхия бусаганы атлап җитмәстән үкереп җибәрде: «Син нәрсә, суккин сын, колхоз атын әллә үзеңнең Сарбаең дип белдеңме? Теләсә кемгә биреп...»

— Кемгә биргән? — Сәхия, председательнең сүзен бүлеп, һөҗүмгә ташланды.— Кешегә акырырга оста сез, төне буе урлашып печән ташучыларны күрмисез.

— Анысы синең эшең түгел. Син миңа шуны әйт: ат бәясен түлисеңме, әллә судка бириммe?

— Судка бир. Алып китсеннәр, утыртсыннар. Минем өчен барыбер.

— Ипекәй ашап, тамагың туйдымыни?

— Ашаса, мин эшләп ашыйм. Урлап түгел.

— Ә кем урлап ашый, кем? — Насыйбуллин Сәхиянең күзенә керердәй булып каршысына килеп басты.— Без сине җәлләп этлекләреңә күз йомабыз. Ә син понимаешь...

— Җәлләп ашка чакырганыгыз юк әле.

— Ах... ишшү телләшеп тора. Бу килеш котылып калырмын дип уйлама. Өеңне сатып түләрсең.

— Төрмәгә утыртам дисең бит. Төрмәдә өй кирәкми.

Сәхиянең бу сүзләре Насыйбуллинны чыгырыннан чыгарды. «Уф-уф, өф-өф»,— ди-ди, ул төймәләрен чишеп җибәрде. Аннары аяк тибеп: «Вон!»— дип кычкырды. Дөресен әйткәндә, Аккошның үлемендә Сәхия гаеп-ле түгел икәнен белә, бары тик моннан ары уяурак бул, йоклап йөрмә, кешеләрнең төрлесе бар дип кисәтмәкче генә иде. Әллә ничек кызыбрак китте. Җитмәсә талашып тора. Молокосос. Районда да җитәрлек кычкыралар Насыйбуллинга.

Сәхия өенә ярсып, кызып кайтып керде. Бер тибеп җибәрүгә, бәләкәй капка очып төште, икенче тибүгә, ишек канатланды. «Ярар, кадерне белмәдегез, инде үзегезгә үпкәләгез. Миңа гына колхозда чиләнергә димәгән. Артымнан елап килсәгез дә, ике аягымның берсен атламам. Әнә, ерак китәсе юк, басуда гына буровойлар үкереп эшләп утыра. Бардым кердем».

Язмышын шулай хәл итте Сәхия. Кешеләргә, тормышка үпкәсе зур иде. Җаны тиз генә эремәде. Үз-үзен ышандырыр өчен нефть эшенең уңай якларын күңеленнән санады.

Паспорт өчен борчылмады ул, чөнки кулында инде күптән председатель мөһере сугылган кәгазь бар иде. Ул аның кулына болай төште: беркөнне идарәдә төнге дежур торучы апа кунакка китте, үзе урынына кызы Рәҗибә калды. Рәҗибә, берүзем кунарга куркам дип, иптәш кызын ияртте. Ә ике кыз булган җиргә егетләр килми каламы? Бераздан идарәдә кечкенә аулак өй иде инде. Шунда егетләр ничектер председательнең өстәл тартмасын ачып карыйсы иттеләр.

— О-о, егетләр,— диде берсе,— монда председательнең пичәте калган. Кайсыгызның маңгаена сугабыз, ә?

Маңгаена пичәт суктыручы табылмады. Ләкин егетнең кулга мондый нәрсә эләккәндә бераз председатель ролендә уйнап аласы килә иде.

— Өф-өф, иптәшләр, өф,— диде ул, нәкъ Насыйбуллин төсле итеп.— Бүгенге көндә — өф, безнең алда — өф, гаять тә ки катлаулы бурычлар тора — өф. Нинди бурычлар дисезме — өф? Бурычларыбыз шул ки — өф: амбарлардагы икмәкләрне кая куярга белмибез — өф. Иптәш Төхфәтуллин үзенә тиешле биш тонна икмәген һаман килеп алмый — өф, колхоз амбарында тота — өф.— Кызлар, егетләр пырхылдашып алды.— Инде — өф, Рәҗибә Сибгатуллинага тукталыйк — өф. Ни өчен үзегезгә тиешле — өф, өч центнер бодаегызны — өф, һаман килеп алмыйсыз?

«Председатель» һаман артистларча кылануын дәвам итте: Кулындагы пичәтен карага манып әле бер нәрсәгә, әле икенче нәрсәгә сукты. «Менә мине өф-өф Насыйбуллин урынына сайласагыз, тамакларыгызны бик тиз туйдырырмын,— диде ул.— Ә хәзер килегез, сорагыз. Юмарт председательнең нинди икәнен күрсәтәм мин сезгә. Давай, давай курыкмагыз. Бурычка түгел, бөтенләйгә бирәм. Колхоз үзебезнеке бит».

— Миңа берәр центнер бодай кирәгие,— дигән булды берсе.

— Ә нигә бер центнер гына, мә сиңа бер тонна! Рәхәтләнсен тавыкларың.— Пичәтле егет, өстәлдәге газетаны ертып, сораучыга пичәт сугып бирде.— Тагын кемгә нәрсә?

— Миңа — өй түбәсен ябарга салам.

— Мә, рәхәтен күр. Ун йөк салам сиңа. Тик минем монда җыенлебашлы кәгазь беткән икән әле, Рәҗибә, синең җырлар дәфтәреңдә буш битләр юкмы? — Рәҗибәнең дәфтәрендә буш битләр бар икән, председатель булып уйнаучы берничә буш биткә шалт-шолт пичәт сугып чыкты.— Сәхи, сиңа матчалык бүрәнә кирәк иде бугай, мә. Урманнан иң озын агачны алып кайтырга рөхсәт итәм. Кызлар, ә сезгә ни бирим икән?

— Берәр тәпән бал бир. Самавыр куеп, чәйгә чакырырбыз үзеңне.

— Мәслихәт эш. Мәгез ике тәпән балга язу.

«Председатель» кәгазен егетләр-кызлар, рәхмәт әйтеп, кесәләренә салып куйдылар. Пичәт белән уйнауны туктатып, башка уеннарга күчтеләр. Ә таралышып урамга чыккач, председатель булып уйнаган егет, Сәхия янына килеп, болай дип пышылдады:

— Кәгазеңне ташламадыңмы?

— Син нәрсә? — диде Сәхия,— әллә моның белән чынлап урманнан агач алырга кушасыңмы?

— Кибәк баш,— диде егет,— бу кәгазьнең бәясе бер матчалык кына түгел. Беләсең килсә, моның белән паспорт алырга була. Тик шауламаска гына кирәк. Аңгыралар, әйдә, пичәтле кәгазьләренә тәмәке төреп тартсыннар. Без иплән кенә колхоздан таярбыз. Күп чиләндек, җитәр.

— Монда бит бер нәрсә язылмаган,— диде беркатлы Сәхия.

— Язылмавы әйбәт аның. Язылмаган кәгазьгә теләсә нәрсә язып була.

Сәхиянең ул чагында колхоздан китәргә исәбе юк иде. Шулай да кәгазен ташламады, иске квитанцияләр белән бергә сандык төбенә салды. Ә теге егет исә озакламый районга барып паспорт алды да нефтькә эшкә керде. Кесәсе тулы акча. Клубта кинога керергә акчасы юк малайларны җыя да: «Сезнең,егетләр, кинога керәсегез килә инде, әйеме?» — ди. «Әйе». «Ә маңгаегызга ун тапкыр чиерттерәсегез киләме соң?» Малайлар эндәшмиләр. «Маңгаегызга чиерттерсәгез, билет алып бирәм үзегезгә». Малайларга маңгай җәл түгел. Тезелешеп, чиратка басалар. Малайларга кино кызык, ә егеткә үзенең шулай юмарт, киң күңелле булуын күрсәтү кирәк. Үз гомерендә бер тапкыр да кесәсендә акча кыштырдавын ишетмәгән кешегә бу уен гаҗәеп рәхәтлек бирә, аны акчасыз ертык чалбарлы авыл малайлары алдында бик нык югары күтәрә иде. Гомумән, хәзер, авылда торып, нефтьтә эшләп йөрүчеләр күбәйгәннән-күбәя бара. Районнан авылга вахта машиналары йөри. Алар иртән эшчеләрне төяп алып китәләр, кич белән китереп куялар. Нефтьчеләрнең башлары кадерле.

Ә менә Сәхия ни өчендер аларга кызыкмады. Трактор тирәсендә кайнашу күңеллерәк иде аңа. Акчасы юклыгы гына бик яман. МТСтан килгән тракторчыларга йөкләп-йөкләп икмәген, кесә тутырып акчасын бирәләр, шулар белән үк эшләп йөргән сиңа — коры хезмәт көне. Бәлки әле Аккошның үлүе дә вакытлы булгандыр, юкса бөтенесен берьюлы кырт кисә алмас иде.

Сәхия районнан эш эзли башлады. Әмма ул заманда хәзерге кебек почмак саен фәлән-фәлән җиргә эшчеләр кирәк дигән игъланнар эленеп тормый иде. Бик күп конторaларга кереп йөри торгач, шоферлар әзерли торган мәктәпкә юлыкты ул. Монда аны кире бормадылар, алдылар. Тракторлар белән электән танышлык ярдәм итте ме, техникага үзенең кулы ята идеме — җайлы һәм җиңел өйрәнде бу һөнәргә. Ә инде алты ай укып, кулга таныклык алган көн зур бәйрәмгә әйләнде.

Бер автохуҗалыкка эшкә урнашып, машинага утыргач, тормыш ярыйсы ук көйләнде. Кесәгә акча керә башлады. Иң рәхәте — үзеңне зур, көчле кеше итеп тоясың. Машина синең һәр хәрәкәтеңә буйсына: акселераторга бассаң, ажгырып, алга ыргыла; тормозга басуга, шып итеп туктый.

Ничек рөхсәт бирәләрдер, Сәхия машинасын төнгелеккә гел үзләренә алып кайтып куя. Ә капка төбендә машинаң торгач, йокыңны бераз иртәрәк ачарга була. Кирәк җиреңә рәхәтләнеп чабасың. Кешеләр сине буш итмиләр: җиләккә баручылар җиләк бирә. Алмасаң, үпкәлиләр. Ә берәрсенә утын яки печән алып кайтырга туры килсә, өйгә чакырып сыйлыйлар. Акчалы кешеләр күбәеп килә, кемдер бура ала, кемдер түбәлек шифер кайтарта. Кай көнне Сәхиягә мендәргә борын төртеп алырга да туры килми: әле берсе кереп аягына егыла, әле икенчесе. Беркөнне Сәхия үзенә дә берничә нарат бүрәнә китереп ташлады. «Матчаларны алыштырам, өф-өф Насыйбуллинга ялынып эш чыкмады»,— диде ул. Авылда балта осталары күп иде. Эшне аңлатып биргәч, осталар: «Эш матчада гына түгел әле, парин, түшәм башларың да черегән,— диештеләр.— Без — иң яхшысы — болай итик: өеңә ике матча куйыйк. Матчалыкларың бар. Түшәмнең черек башларын кисеп ташларбыз.

Җитмәгән җиренә сәке такталары ярар. Хәзер сәкене кешеләр болай да чыгарып аталар. Тик минә түбәне сүтми булмас».

Әниләре үләр алдыннан Сәхиягә бер төш кереп йөдәтте. Имеш, аларның матчалары сынган да түшәмнәре җимерелгән. Җимерелгән түшәмнең бер кадәре Сәкинә өстенә, бер өлеше Сәхия өстенә төшкән. Сәхия аларны алып ташларга тели, ләкин түшәмнәр авыр, кымшанган саен, ыграк басалар. Бу төшен әнисенә сөйләгәч, әнисе: «Төшкә ни кермәс»,— дип кенә куйган иде. Менә бит ничек килеп чыкты: әнкәләре үлде, тормыш авырлыгы боларга төште.

Искегә тисәң, исең китәр дип, юкка гына әйтмәгәннәр шул. Эшли башлагач, өйнең әле бер җире, әле икенче җире бүселде. Тәрәзә асларындагы ниргәләргә төртсәң, кул кереп китә иде. Шулай да, маташтыра торгач, өй яшәрлек хәлгә килде.

Әмма тормыш җайга төшә барган саен, җанында ниндидер борчу арта барды аның. Буш вакытларында үзенә урын таба алмады. Элек мендәргә баш тиюгә, йоклап китә иде, хәзер исә әле тегеләй борылды, әле болай әйләнде. Я урыны каты тоелды, я авыртмаган җире авыртырга тотынды. Кайвакыт, йоклый алмый яткан чакларда, теге кунак егете кинәт кенә күз алдына килеп баса да болай да телгәләнергә торган бәгырьне парә-парә кискәли башлый. Ул күз алдына килеп басу белән, Сәхия гүзәл бер кызга әйләнә: өстендәге барлык алам-соламнар шуып төшә, тел үзе белгән иң матур сүзләрне кабатлый, куллар аккош канатына әверелеп, аны биеккә күтәрә, йөрәк икелэтә-өчләтә катырак тибәргә тотына.

Моңарчы Сәхиянең ир-егетләр күзенә күтәрелеп караганы юк, аның өчен ир-ат һәммәсе бер төсле булып күренә иде, хәзер урамнан егетләр төркеме үтеп китсә, сагаеп кала. Шулар арасында теге егет булыр кебек. Исемен генә дә сорамады бит. Авыл егетләре аның исемен, каян килүен беләләрдер белүен, ләкин алардан ничек сорыйсың. Шундук ыржая башлаячаклар.

Сәхия, аны районда очратырга өметләнеп, кай көннәрдә озак кына урамда йөри, яшьләр күңел ача торган бакчаларга сугыла, клуб тирәләрендә туктала. Күзенә ак костюмлы кеше чалынса, «шул» дип, йөрәге сулкылдап куя. Ә бервакыт кыен хәлгә дә калды: ак костюмлы берәүне әлеге кунак егетенә охшатып, артыннан китте. Сәхия адымнарын шәбәйткән саен, ак костюмлы кеше дә кызулый барды. Бара-бара алар йөгерә үк башладылар. Кычкырырга, туктатырга, ике авыз сүз алышырга иде, юк шул, исемен белмәгәч, ни дип кычкырасың. Ә ул әнә һаман Сәхиядән ераклаша. Ләкин Сәхиянең кайчаннан бирле эзләгән кешесен бер авыз сүз дә алышмаган, һич югы йөзенә күтәрелеп карамаган килеш яңадан югалтасы килми иде. Әмма ак костюмлы кибеткә халык арасына кереп югалды. Сәхия чат башында аның чыкканын сагалап торды. Тик ишшләптер күрми калды, теге, кибеттән чыгып, шактый ара үткәч кенә яңадан күреп артыннан йөгерде. Ак костюмлының артыннан менә җитәм, менә җитәм дигәндә, каршыларына бер милиционер килеп чыкты. Ак костюмлы Сәхиягә төртеп күрсәтә-күрсәтә нидер сөйли башлады. Алар сөйләшкән арада Сәхия болар янына килеп җитте. Һәм ак костюмлының йөзенә күтәрелеп карау белән, үзенең ялгышканлыгын аңлады. Ул борылып китмәкче булган иде, милиционер туктатты: «Граждани, сезнең документыгыз? Нәрсәгә бу иптәшне эзәрлеклисез?»

Сәхия аптырап калды:

— Эзәрлеклим? Ничек эзәрлеклим?

Сүзгә ак костюмлы кеше кушылды.

— Һы, хәзер фәрештә булып кылана. Кайчаннан бирле куалый инде ул мине. Бандит икәнлеге әллә каян күренеп тора, иптәш милиционер. Мөгаен, кесәсендә пычагы бардыр. Тентергә кирәк.

— Нишләргә кирәген үзебез белербез,— диде милиционер кырыс кына һәм боларның икесен дә үзе белән алып китте.

Милиция бүлегеннән чыккач, Сәхия, кая барырга белми, озак йөрде. Милиционерның, аңа ышанмыйча, җыен тузга язмаган сораулар бирүенә түгел, алдануына җаны әрнеде, кешеләрнең һәрнәрсәдән начарлык эзләүләренә рәнҗеде.

Күңеле бераз утыра төшкәч, кибеткә керәсе итте. Кибет эчен бер әйләнеп чыкканнан соң хатын-кыз күлмәкләре эленеп торган җиргә килде. Күлмәкләрнең нинди генә юк монда: күз явын алырлык чәчәкләләре дисеңме, кисәң, тәнгә сыланырдай тарлары дисеңме, бөтерелгәндә, парашюттай кабара торганнары дисеңме — бар да бар. Сәхиянең күзе акка буй-буй кара сызылган күлмәккә төште. Бусы бүтәннәр янында артык «кычкырып» тормый, буе да таман күренә. Сатучы кыз Сәхиянең бу күлмәк янында бөтерелгәнен күреп:

— Нәрсә, кәләшкә күлмәк сайлыйбызмы? — диде. Кибетче кызның бу сүзләреннән соң Сәхия үз буена үлчәп торган күлмәкне прилавка өстенә куярга ашыкты:

— Төреп бирегез!

Кайту белән, күлмәкне киеп карарга булды ул. Менә алып кайткан күлмәген ниндидер бер битарафлык белән кулында әйләндергәли. Әлбәттә, күлмәкне киярга кирәк. Болай ярамый. Юкса тупас кием күңелне тупасландыра. Күрәсең, кеше, нинди кабыкка төренсә, шундыйга әвереләдер. Ә Сәхиянең үз асылына кайтасы килә.

Күлмәк бер ыргытыла, бер яңадан алына.

Киярга дигәч — киярга! Ничу сузарга. Әле яшьлек узмаган.


Ниһаять, өстән бөтен кием-салым салынып ташланды. Үзенең шәрәлегеннән оялгандай, ул тиз-тиз күлмәген киеп куйды. Саргаеп беткән, урта-тирәсеннән карасаң, бер төсле, почмактанрак карасаң, икенче төрле итеп күрсәтә торган рамлы көзгедән үзен озак кына күзәтте. Менә бит, бер дигән кыз булды түгелме соң? Җилкәләр бераз тырпаебрак тора икән, торса соң! Икенче тапкыр иңсәлерәк күлмәк алыр. Ә билләр ярамаслык түгел. Путасын да буып җибәргәч — хәтәр генә. Күңел үзеннән-үзе канатланды, хыял еракка алып китте. Менә ул аклы күлмәген киде дә, хыял канатларында очып, урамга чыкты. Урамда Зәйнәп әби очрады: «Сөбханалла, сөбханалла! Синме соң бу, Сәхия кызым?» «Мин бу, Зәйнәп әби, мин! Мин бүген үткәннәрем белән хушлашырга чыктым. Бүгеннән яңача яши башлыйм». «Бик хуп, Сәхия кызым, күптән шулай кирәк иде. Юкса синең турыда кешеләр әллә нәрсә сөйли». «Мин кеше сүзеннән курыкмыйм, Зәйнәп әби». «Алай димә, Сәхия кызым. Кешеләр алдында матур булу — үз алдыңда матур булу ул». «Ә мин бүген матурмы соң, Зәйнәп әби?» «Син һәрвакыт матур, балам. Тик кайчак үзеңне үзең ямьсезлисең». «Тормыш мәҗбүр итә бит, Зәйнәп әби». «Тормыш барыбыз өчен дә бер, балам». «Ярый, Зәйнәп әби, мин клубка киттем. Матурлыгымны бөтен кеше күрсен әле». «Бар, балам, бар».

Хыял канатлары Сәхияне клуб эченә очырып алып кереп китте. Клубта яшьләр бүтән вакыттагыга караганда күбрәк җыелган. Биилар, уйныйлар. Биючеләр биюеннән, уйнаучылар уйнавыннан туктап, Сәхиягә карыйлар: «Кем бу, нинди фәрештә очып төште безнең клубка?»

Егетләр арасында теге кунак егете дә бар. Аның күзләре Сәхиядә генә. Сәхия гармунчы янына килеп: «Уйнап җибәр әле без яраткан көйләрне»,— ди. Гармунчы матрос биюен уйный башлый. Ләкин Сәхия аны туктата: «Юк, бүген син миңа кызлар бии торганны уйна, күрмисеңмени каршыңда иң гүзәл кыз басып тора». Гармунчы беркөн Гөләндәм биегән көйне уйнап җибәрә. Сәхия аккоштай йөзеп кенә биеп китә. Куллар канат кебек кагынып-кагынып куя, аяклар оркестрдагы барабан таяклары төсле әле көчәеп, әле салмакланып бер тактка тыпырдыйлар. Менә Сәхия тыпыр-тыпыр басып кунак егете каршысына килә. Кунак егете беркөн Гөләндәмгә ялындырган кебек ялындырмый, Сәхия каршысына очып чыга.

Боларның биюләрен бөтен клуб сокланып күзәтә.

Сәхия, уйларына бирелеп, күрше хатынының кергәнен дә сизми калды.



А. Тимергалина рәсеме.

«Хи-хи-хи, ха-ха-ха» — дип көлгән тавышка сискәнеп китте. Әйтерсең, яман эш эшләп тотылды, битләре кызышты, тәннәре куырылды. Матур уйларын бүлдергән өчен аның бу хатынга җен ачулары чыкты.

— Нәрсә кирәк сиңа монда, вон! — дип кычкырды ул.

— Әбәү, әбәү,— диде күрше хатыны.— Харап икән. Күлмәк киеп кенә кеше рәвешенә кермәкче булгансыңдыр. Күлмәк кенә түгел, алтынга манчылсаң да, сиңа егетләр әйләнеп карамаячак. Иржәнкә! — Хатын шап итеп ишекне ябып чыгып китте. Сәхия өстеннән күлмәген йолкып атты. Күлмәкнең кайсыдыр җире шытырдады, нәрсәседер өзелде.

«Кем өчен тырышам соң мин? Хәзер хатын-кыз карарлык егетләр бармыни? Кайсына карама, синең җилеңнән аварга тора. Җыенысы малай-шалай. Юньлеләре сугышта кырылып беткән. Исән калганнары артыйорты. Алары да биш-ун хатын-кызга берәү туры киләдер. Әнә, авылда күпме кызлар кияү тапмый йөри. Бетте, бүтән бу күлмәкне кулга алдым юк. Кеше көлдереп йөргәнче!»

Күлмәк, тормышка ашмаган хыял булып, сандык төбенә чумды. Сәхия күптән түгел «Ашыгыч ярдәм» машинасына күчкән иде. Монда эш җиңел. Ә иң шәбе шул: тизлекне арттырасың дип, инспекторлар бәйләнми. Кирәк җиреңә сиренаңны улатып оч кына. Районның баш врачы хатын-кыз, ә хатын-кызның эше бетәме соң? Әле бер җиргә чабасың, әле икенче җиргә. Җәй көне бөтен больница халкын урманнан дару үләннәре җыйдыртып җанын ала баш врач. Сәхиянең урманга бик исе китми. Алар урманнан ерак яшәделәр. Матурлыкка сокланып үсәргә туры килмәде аңар. Кайбер врачларның яки сестраларның: «Ай, нинди матур, нинди гүзәллек!» — дип чәчәкле аланга һушлары китеп карап торуларын күрсә, эченнән мыгырдап куя: «Гүзәллек пычагым. Печәнлек дисәң ярар иде ичмасам».

Баштарак врачлар аңа үләннәрнең кайсылары даруга яраклы икәнен аңлатып маташканнар иде, тик үзләре сөйләгәндә, Сәхиянең агач башындагы карга оясына карап торганын күргәч, бу эшнең файдасыз икәнлеген төшенделәр: «Ярый инде, ул бит шофер кеше».

Сәхиягә шул гына кирәк тә. Врачлар китеп бару белән, берәр куләгәгә баш төртергә ашыга ул. Яшел чирәм өстендә чалкан ятып болытлар агышын күзәтү кызык. Кем куалап йөртә икән аларны? Кая ашыгалар алар? Дөньяның нинди зурлыкта икәнен болытлар гына беләләрдер, мөгаен. Әй, гизәсе иде дөньяны шулар кебек. Сәхиянең әле Бөгелмәдән башка шәһәр күргәне юк. Кайвакыт каядыр еракка чыгып китәсе килә, әмма куркыта. Белмәгән-күрмәгән җирләрдә ни булмас. Ә шулай да дөнья күрү зыян итмәс иде. Кем белә, бәлки аның бәхете нәкъ менә читтәдер. Монда тормышның кызыгы кимегәннән-кими бара. Беркем аның эштән кайтуын ашкынып көтми, беркем аны күреп сөенми. Сәхиянең машина белән пыр-пыр урам ураганын күреп, күршеләр сукраналар, уйсыз-гамьсез дип сүгәләр. Эченә җыелган уйларын, җанын талкыган борчуларын таратыр өчен чабадыр бу бала дип башына китерүче кеше юк.

Кызык, кеше ни өчен яши икән дөньяда? Ни өчен Сәхия бот буе чагыннан ук таңнан торып эшкә чапты? Ни өчен ачлыкның «менә йотам» дип ачылган авызына кереп китмәскә теләп тартышты? Ни өчен баш өстендә уйнаган язмыш кусәгенә барып ябышты? Ни өчен?..

Сәхия күңелендә җавабы табылмаган сораулар артканнан арта. Бәлки яшәү ул әнә шул сорауларга җавап эзләүдер?

Уйлары белән дөньяны урап чыккач, ул җиләк җыярга тотына.

Район больницасы белән күршедәге балалар бакчасында бер малай бар. Әнисе аны тапкач, алмый калдырып чыккан. Хәзер инде бу балага ике яшь ярым, өч яшь тирәсе. Бу бала ике телдә дә бик матур итеп сөйләшә. Барлык хатын-кызга «әни», ир-атка «әти» ди ул. Күпләр аны кулга алып сөя. Ул, «әни» дип, няняларның муенына сарылганда, күпләрнең күзеннән яшь саркып чыга. Ә Сәхия аның өчен урманнан сабаклы җиләк җыя. Җыйган җиләкләрен ул кабинасының тәрәзәсенә элеп куя.

Сабагыннан кысып бәйләнгән кып-кызыл җиләкләр көн буе машинада чайкалып-тирбәлеп йөри.

Сәхиянең машинасы больница ишегалдына килеп кергәч, теге бала йөгереп чыга. Сәхия аны күтәреп машинасына менгерә.

— Җиләк ашап җибәрәбезме, матурым?

Бала башта букет итеп бәйләнгән кып-кызыл җиләкләргә сокланып карап тора, җиләк бәйләмен әле бер кулына, әле икенче кулына күчерә. Карап туйгач кына ашый башлый. Аның бармаклары, иреннәре кызара. Сәхия машинасының көзгесен алып: «Бер матур малай күрәсең киләме?» — дип, көзгене бала алдына куя. Бала үзенең җиләккә буялган битләрен сөртмәкче була, ләкин тагы да ныграк буяла гына.

— Ярый, ярый,— дип тынычландыра аны Сәхия.— Болай матурак та әле.— Бала бәхетле елмая. Калган җиләкләрен сабагыннан берәмберәм өзеп, Сәхиягә каптыра башлый. Кайвакыт Сәхиянең бу баланы тупылдатып сөясе, җиләкле битләреннән үбәсе килә, әмма батырчылыгы җитми, гел нидер тыеп кала.

Ә балага машина кабинасында кызык. Рульне борып, «ту-ту» килә, рычагларны тарткалаган була.

— Син баланы артык иркәләп бозып җибәрмә,— диләр аңа.— Анныры беребезне дә тыңламый башлар. Бала — уенчык түгел: бер кешегә бик нык ияләшмәве яхшы. Соңыннан кыенга туры килә ул аңа.

Сәхия моның шулай икәнлеген аңлый, ләкин машина күргәч утырырга тырпылдап торган малайны нәүмиз итәсе килми, тагын күтәреп ала.

— Үскәч мин шуфил булам,— ди малай.— Ту-ту, выж-выж...

Шушы малай янында кайнашудан Сәхия сөенеч таба, хәтта ул күңелен байтактан җилкендереп йөргән кунак егете турында да онытты бугай. Һәрхәлдә «оныттым» дип үзен ышандырырга тырышты. Ләкин язмышка аларны яңадан очраштырырга кирәк булган икән әле.

Сәхия үзенең машинасында җилдереп каядыр бара иде, күпер янында туктап калган бер «Победа» күреп, тизлеген әкренәйтте. Әнә, «Победа» хуҗасы үзе дә шунда икән. Ул, майланган кулларын яшел үлән белән сөртә-сөртә, Сәхиягә туктарга ымлады.

— Нәрсә, егет, әллә «очкынын» югалттыңмы? — Тракторчылар янында эшли башлаганда, Сәхия бер абыйның нәрсәдер эзләгәнен күреп, ни эзлисең, абый, дип сораган иде. Менә очкынын югалттым, шуны эзлим, дигән иде тракторчы абый. Әй эзләште, әй эзләште Сәхия аңа югалган очкынны. Чөнки ул һәр яңа кешедән тракторчыларның шулай көлүләрен белми иде әле. Хәзер менә аптыраган шофердан Сәхия үзе көлмәкче булды. Әмма каршында басып торган кешенең кайчандыр үзләренә килгән ак костюмлы егет икәнен танагач, кинәт кенә теле аңкавына ябышты. Егет Сәхияне танымады, хәер, каян танысын — ул аны караңгыда гына күргән иде бит.

— Томаулаган сарык кебек төчкереп барды-барды да сүнде,— диде егет Сәхиягә ялварулы карап.

Сәхия үзенең каушап, югалып калуын сиздермәскә тырышса да, ниндидер эчке калтыравын баса алмый азапланды. Ярый әле егет үзе сүзчән булып чыкты, машинасы тирәсендә бөтерелеп, һаман теленә салышты: «Шәп бахбай бу, моңарчы әле алай кәҗәләп күрсәткәне юк иде,— диде ул капотын сыйпагандай итеп.— Эти машинасы. Әле мин үзем белән таныштырмадым бугай. Таныш булыйк: Адонис Саматов.— Ул Сәхиягә кулын сузды.— Саматов фамилиясе сезгә таныштыр дип уйлыйм».

Әйе, Сәхиянең атаклы нефтьче Саматов турында ишеткәне бар иде. Аңа герой исеме бирелгәч, бөтен газеталар язды, радиолар сөйләде. Димәк Адонис — шул атаклы нефтьченең малае. Исеме әллә нинди ят исем. Шул ук вакытта серле дә. Сәхия уйлавынча, бу егетнең исеме шулай башкаларныкына охшамаган булырга тиеш иде дә.

Егеткә аның әтисен генә түгел, үзен дә белгәнлеген, клубта күрү белән, йөрәгенең иң тирән катламнары актарылуын, шуннан бирле җанын-

да күрәш барганлыгын сөйлисе килде Сәхиянең. Үзе «Победа»ның моторында казынды, үзе янәшәсендә басып, туктаусыз сөйләнүче егетнең иңенә кагылып китүдән ниндидер рәхәтлек алып, эченнән сөенеч кичерде. Машинаның кай җире төзек түгеллеген ул шундук аңлады: карбюраторга бензин килми икән, насос белән өрдереп җибәрсәң, сәгать кебек эшләп китәчәк. Әмма Сәхия бу бәхетле мизгелдән озаграк ләззәтләнергә теләде. Шул ук вакытта үзен булдыксыз итеп тә күрсәтәсе килми иде.

— Нәрсә, булмыймы? — диде Адонис, аның янына иелеп. Егетнең чәчләре Сәхиянең муенына тиде, сулышы битен иркәләде.

— Була,— диде Сәхия әллә нинди ят тавыш белән.— Кая, насосың бармы? Карбюраторны өрдерергә кирәк.

Егет җәһәт кенә багажниктан насос алып килде. Үзе Сәхиянең өлгер кулларына сокланып карап тора башлады.

Карбюраторга бензин килә торган юлларны чистарткач, машинаны кабызып карадылар. Ачкычны бер боруга, машина гөрләп эшләп китте. «Ну егет икәнсең,— дип, Адонис Сәхиянең җилкәсенә сукты.— Син булмасаң, бахбайны тарттырып кайтырга туры килә иде. Бу бахбай бүген әле мине бер асылъяр янына алып барырга тиеш.— Адонис «менә шулай безнең эшләр» дигәндәй, күз кысып куйды.— Моның белән асылъярның капка төбенә килеп туктасаң, дәрәҗәң икеләтә арта, дустым. Борыны иң югарысының да кикриге шиңә. Синең алдыңда бөтерелеп йөри башлыйлар».

Егет күбрәк сөйләнгән саен, Сәхиянең йөзе караңгылана барды, ләкин Адонис аны күрмәде, һаман тел тегермәнендә көрпә очыруында булды: «Ә бервакыт бахбаема утыртып, бер асылъярын алып киттем урманга. Ну, малай, шәп нәрсә иде. «Җиләк җыябызмы, Адонисчик?» — ди бу. «Җыярбыз,— дим,— ләкин минем башта синең җиләктән авыз итеп карыйсы килә иде». Әй ялындыра бу: тегеләй боргалана, болай боргалана. Кычкырмакчы, ычкынмакчы була. Һы, ычкынырсың минем кулдан! Андыйларны гына күргән бар. Кул белән ега алмаганын без аның тел белән егабыз, үзләре үк, елый-елый, кочакка керәләр аннары. Әй, малай, шәп бит кызларның ул җиләкләре! Ух!»— Адонис тагын бер тозсыз сүз әйтә башлаган иде, Сәхия, гайка бора торган ачкыч күтәреп, аңа ташланды.

— Җитте! Кызлар турында тагын бер генә пычрак сүз әйтсәң, авызыңны мәңге ыржайтмаслык итәм.

— Син нәрсә! — диде Адонис артка чигенә-чигенә.— Әллә ачкыч бездә юк дип беләсеңме?..

Адонис машинасын кабызып китеп баргач, Сәхия яшел чирәмгә тәгәрәде. Йөрәген әрнү кимерде, күзләрдән яшь бәреп чыкты. Үзенең кешеләрдә еш алдануына, күпме алданса да, һаман акыл кермәвенә, һаман ышануына ачуы чыкты. «Юк,— диде ул үз-үзенә.— Китәргә кирәк моннан. Ераккарак китәргә. Онытырга кирәк бөтенесен. Кызларның иң кадерле нәрсәсен җиләк кебек өзеп йөрүче Адонислардан, авыр балачагыңны, кимсенүле яшьлегеңне адым саен искә төшереп торучы бу төбәкләрдән ераккарак китәргә. Ят җирләрдә тормышны икенче якка борып җибәрү, мөгаен, җиңелрәктер».

## 8

Сәхия Себер якларына китеп барды, ә киткәндә, саубуллашырга дип, Зәйнәп әби янына керде. Зәйнәп әби авырып ята икән: Сәхияне күргәч, урыныннан калкынып куйды. «Соңгы вакытларда сезгә кергәләп булмады, ничек соң, бәбкәм, бик кыен түгелме?»

Зәйнәп әбинең «бәбкәм» дип яратып әйткән сүзеннән Сәхиянең күңеле тулды. Ул, Зәйнәп әбинең күкрәгенә башын салып, үксергә тотынды. Зәйнәп әби кытыршы куллары белән йомшак итеп башыннан сыйпады: «Җыла, бәбкәм, җыла, җиңеләймәсме? Сиңа бигрәк авырга

туры килде шул. Кыз баланы ходай дөнья йөгэн җигелеп тартырга яратмаган да бит, нишлисең инде».

Зәйнәп әби әкрен генә сөйләнде. Сәхия елауның болай ләззәтле икәнен белми иде, рәхәтләнеп бушанды. Бераз җиңеләйгәч тә Зәйнәп әбинең самавырын куеп җибәрде.

— Рәхәтләнеп бер чәй эчик әле, Зәйнәп әби. Мин менә әзрәк тәмтом алып кергән идем.

— Мәшәкатьләнмәскә иде, балам, мин бит ураза.

— Ураза? — Сәхия аптырап калды.— Юк, юк,— диде ул аннары.— Сиңа ураза тотарга ярамый. Сугыш елларында бөтен гомергә җитәрлек итеп тоттык инде без аны. Ә хәзер ашарга кирәк. Ашамыйча терелеп буламыни? Эчәбез әле чәйне, Зәйнәп әби, теге вакытта бездә эчкән кебек тәмләп эчәбез. Гөнаһысын миңа язарлар.

Сәхия сумкасыннан конфеттыр, җимештер ише нәрсәләр чыгарып, өстәлгә тезде.

— Ә менә болары, Зәйнәп әби, сиңа яулык белән исле сабын.— Сәхия яулыкны Зәйнәп әбинең өстенә салды: — Минем төсем итеп бәйләрсең, Зәйнәп әби. Мин китәм инде.

Сәхия үзенең ниятен сөйләп бирде.

— Анысы шулай,— диде Зәйнәп әби, аның сүзен тыңлагач,— тик, балам, бәхет дигән нәрсә кайда да бер бит ул. Күңелеңә авыр алмасаң, мин сиңа бер сүз әйтер идем...

— Әйт, Зәйнәп әби.

— Салып ташла син үзеңне ямьсезләп торган шушы киемнәреңне. Син бит алай тупас түгел, күңелең матур синең. Яшермә үзеңнең матурлыгыңны. Йомшаклыктан курыкма, йомшаклык ул, балам, көчсезлек түгел. Хатын-кызга ул кирәк. Мәрхүм Гариф бабаң миңа, синең күңелең йомшак, шуңа яратам мин сине ди торганые. Беләм, сиңа бирешмәскә кирәк иде. Тырыштың, тырмаштың, бирешмәдең. Ул ягына сүз әйтә алмыйм. Хәзер ул заманнар үтте бит инде. Аллага шөкер, дөнья әйбәтләнде.

Зәйнәп әби белән Сәхия ул көнне туйганчы сөйләштеләр. Икесенең дә күңелләре бушап, җиңеләеп калды. Чыгып киткәндә, Зәйнәп әби болай диде: «Дөньяга ачу саклама, балам. Кешеләргә бәхет тигез бирелмәгән. Үзеңнән бәхетлеләрне күрсәң — аларның бәхетен күпсенмә. Үзеңне дә беткәнгә санап йөрмә. Ходай сиңа тазалыкны биргән, калганы бәндәнең үз кулында. Насыйбы табылыр. Ә инде чит җирләрдә бик кыенга туры килсә, озак уйланма, кайт. Туган туфрак беркемне дә кире какмый. Туган якның туфрагы да җиңел дип, картайгач, үләр өчен тикмәгә генә кешеләр туган-үскән җирләренә кайтмыйлар».

Сәхиянең китканче тагын бер җиргә — больницага кереп чыгасы бар иде. Зәйнәп әбидән соң өйләренә сугылып, кесәсенә чикләвекләр салды да туп-туры шунда китте. Теге кечкенә малай — Алмаз ничек икән анда? Нишләп мине машинаң белән йөртмисең дип, Сәхиягә үпкәләмәгәнме? Әллә соң үзен алып кына китәргәме? Ә нигә, әти-әнисенә кирәкми... Сәхия аны беркемнән кактырмас-суктырмас иде.

Шундый ниятләр белән килде Сәхия больницага. Тик Алмазны моннан ике көн элек икенче балалар йортына озаткан булып чыктылар.

Яңа җиргә килеп төшү белән, Зәйнәп әбинең киңәшен тотып, ир-ат киемен салып атты. Эшнең хатын-кызлар эшли торганрагын эзләде. Шоферлыктан кала башка һөнәре юк иде, бер төзелешкә кара эшче булып керде. Шул ук көнне аны тулай торакка урнаштырдылар. Бер бүлмәдә алар дүрт кыз яшәделәр. Сәхиядән кала башкалар шактый яшь иделәр. Эштән кайтып керүгә, кайсы танцыга, кайсы киного дип таралышып бетәләр иде. Баштарак алар Сәхияне дә кыстап карадылар, ләкин Сәхия андый җирләрдә ямь тапмады. Күңеле каядыр ашкынды, нидер эзләнде. Күрше бүлмәдәге Оксана исемле бер кыз белән дуслашып алгач кына җаны бераз басыла төшкәндәй итте. Оксана яшькә Сәхия

белән бер чамадарак, төскә-биткә әллә ни мактанырлыгы юк, ләкин чибәрләр турында сүз чыкса, ул үзен иң чибәрләр рәтенә куя иде. Сәхия бервакыт аңа үзенең балачагын, ир-ат киеме киенеп, авыр эшләрдә эшләп тупасланып бетүен сөйләп ташлады. Оксана Сәхиянең үткәннәре белән танышкач:

— Бер дә кайгырма, миңа таян,— диде.— Мин сине хатын-кызларның бөтен серләренә төшендерермен.— Һәм шул көннән ул Сәхиянең һәр хәрәкәтен, һәр эшен бик нык лап күзәтә башлады. Бүлмәдә икәү генә калган чакларда вак-вак атлап йөрергә, ашаганда кайсы кулга кашык, кайсына чәнечке тотарга, йоклаганда ирләр кебек гырылдамас өчен ничегрәк ятарга — һәммәсен-һәммәсен өйрәтте ул.

Болар бүлмәсенә еш кына Женя исемле инде олыгаеп килүче бер буйдак егет кереп утыра иде. Оксана аны үзенә игътибар игтерер өчен әллә ниләр эшләп карады: я күлмәгенне юып бирәм дип, егетне чишенергә кыстады, я бәйрәм бүләге дип, нәрсә дә булса сатып алды, я табынга төрледән-төрле ризыклар куеп, кунакка чакырды, әмма Женя ни өчендер Оксананың бу кайгыртуларын бөтенләй күрмәде. Аңарга Сәхия белән сөйләшеп утыру кызыграк иде. Дөрес, ул Сәхиягә дә баш әйләндергеч мәхәббәт сүзләре әйтмәде, бары тик үз тормышы турында гына сөйләде. Күңелен бушатасы килгән кешегә тыңлаучы кирәк, моңарчы Женяга тыңлаучыга караганда сөйләүчеләр күбрәк очрады. Ә Сәхия тыңлый белә, киресенчә, сөйли белми иде. Шушы капма-каршылык аларны көннән-көн якынайта барды. Моны алар үзләре аңлап өлгергәнче, Оксана күреп алды.

— Ах, астыртын, ах, ирдәүкә,— дип сукранды ул.— Кая үрелә бит. Женясын әйтер идем. Шул кабык түшнең кай җиренә кызыгадыр?

Һәм көнләшүдән күзе томаланган Оксана Женяның үзен генә туры китереп болай диде:

— Сезнең гыйшык-мыйшык эшләрегез тирәнгә кереп бара бугай.

— Барса соң.

— Ә син үзеңнең гыйшкыңның кем икәнлеген беләсеңме соң?

— Вакыты җиткәч белермен, сездән килеп сорамам.

Оксана, егет күңеленә болай ачкыч таба алмагач, икенчерәк юл сайларга булды.

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде ул.— Һәркемнең үз башы үзендә. Син акыллы егет, бөтенесен нык лап уйлагансыңдыр. Ләкин мин сине артык якын иткәнгә күрә, Женя, бер нәрсәне әйтми калдыра алмыйм. Синең ул Сәхияң — ирдәүкә! Вәт шул.

— Ирдәүкә? Моны ничек аңларга кушасың, Оксана?

Оксана Женяга үтергеч караш ташлады.

— Ирдәүкәнең кем икәнен белмисеңмени? Ни егет түгел, ни кыз түгел, вәт шул. Миңа Сәхия үзе сөйләде. Беләсең килсә, аны авылларында Сәхи генә дип йөрткәннәр. Авыл үз баласының кызмы, малаймы икәнен генә беләдер.

Женя Оксанага күтәрелеп карамыйча бүлмәдән чыгып китте. Шуннан соң ул аларга аяк басмады. Сәхия белән кара-каршы очрашырга туры килсә, читкәрәк кararга тырышты. Сәхия аңардагы үзгәрешне һич аңламады.

— Женяга нәрсә булган, нигә миннән гел кача икән ул? — дип Оксанадан сорады.

— И-и, дускаем,— дип тезеп китте Оксана.— Беткән баш бит ул Женя. Миңа сер итеп кызлар сөйләде: өйләнергә ярамый икән аңа.— Оксана як-ягына каранып кет-кет көлеп куйды.— Югыйсә шушы яшькә кадәр йөрер идемени?!

Сәхиянең күңеленә, Женя белән берәр вакыт тормыш корып җибәрербез, дигән уйның килеп караганы да булмады. Аңа Женя белән кызык иде. Кеше җанының һәркөн яңа катламнарын ача бару, анда башкалар күрмәгән кояшлы аланнар күрү, шул аланнарга керергә нәкъ менә үзенә

хокук бирелү белән бәхетле иде Сәхия. Моңарчы аңа болай ачылган кеше юк иде. Женяның үзеннән читләшергә тырышуын бик авыр кичерде. Беркатлылыгы белән ул Оксананың сүзләренә тулысынча ышанды. Һәм Женяга якынаер өчен күп мәртәбәләр омтылып карады. Женяны чын күңеленнән жәлләп йөрде. Ә инде Женя, нигә минем артымнан чабасың, сиңа миннән ни кирәк дип, сүгеп ташлагач, рәнжеп,беркем белән сөйләшмәс булды.

Мондагы эше дә ошамый иде. Житмәсә теләсә кем сиңа кычкыра, теләсә кем сүгә. Машина маена буялып йөрүләре үк күңелле, бензин һәм майларның исе үк тәмле иде.

Озакламады, китте Сәхия бу эшеннән. Йөри торгач, Якутия якларына ук барып чыкты. Үзенең яраткан эшенә — машинасына утырды. Дөрес, башта аны, монда хатын-кыз түгел, тимер дә түзми, кышкы салкыннарда комташтай уала башлый дип, шоферлыкка алмый маташканнар иде, әмма кеше кирәклек һәм Сәхиянең көн саен конторага килеп йөрүләре үзенекен итте — аны сынау шарты белән эшкә алдылар. Ә Сәхиянең моңарчы сынатканы юк иде, монда да беренче көннән үк жен кебек эшли башлады. Машинаның зурысын, куәтлесен бирделәр, руда чыгара торган карьер ерак түгел, көненә әллә ничә урарга була.

Күңеле күтәренке чакларда Сәхия әлек үзенең Аккошына жырлаган жырларын сузып жибәрә. Кайвакыт берәр ир-ат шофер аны якын итеп эч серләрен сөйли башласа, андыйлар белән яңадан очрашмаскарак тырыша, якынаеп китүдән курка. Бер якын иткән кешесен һич оныта алмый ул. Әле һаман, ятты исә, күз алдына ак костюмлы Адонис килеп баса. Бәлки кызлар турында ул шапырынгандыр гына. Ярата бит егетләр бер-берсенә шулай мактанышырга. Адонис Сәхияне кыз кеше дип белмәде ләбаса. Бәлки шунда аңа ачылырга кирәк булгандыр. Мөгаен, Адонис аны аңлар иде. Хәер, аңламас иде. Ул герой әтисенең даны белән һаваланып йөрүчегә охшаган. Танышканда ук әтисенең исеменнән башлады ич. Балда-майда йөзеп, ата-ана назында иркәләнеп үскән кеше сине аңлыймы соң? Иң күбе — ул сине кызганыр, ә Сәхиягә кызганучы кирәкми. Менә Женя акыллы, бөтенесен аңлар төсле иде, ләкин кинәт әллә нишләде. Юк инде, Зәйнәп әби әйтмешли, бәхет бөтен кешегә дә тимидер.

Зәйнәп әби исенә төшкәч, Сәхиянең күңеленә якты нур бөркелгәндәй булды. «Берәр күчтәнәч салырга кирәк үзенә,— дип уйлады. Зәйнәп әбинең, үзе авылдан чыгып китүгә, дөнья куйганлыгын белми иде әле ул.— Ни салырга икән? Конфет ише нәрсәләр юлда ук искереп бетәчәк. Кием-салымга әлек тә бик исе китми иде, картайгач, бөтенләй кирәксенмидер. Әһә, сәйлүн чәе жибәрергә кирәк. Әйбәт чәйләр авылга сирәк кайта, рәхәтләнсен».

Уйлаган уен икенче көнгә калдырырга яратмаган Сәхия тиз арада посылкасын әмәлләп жибәрде.

Ел артыннан еллар ага торды. Һәр елны Сәхия чираттагы ялында авылга кайтырга жыенды, ләкин гел берәр тоткарлык килеп чыгып, аның планнарын жимерде. Аннары авылга кайтырга бераз курка иде бугай. Нәрсәдән курка иде соң ул? Үзен кызгануларыннанмы? Бәхетсез булып күренүдәнме? Алай дисәң, ялгызлар әзме дөньяда?

Ә авыл торган саен ешрак искә төшә, сагындыра. Кайчандыр үзе жигеп йөргән Аккошның кешнәве колагында чыңлап киткәндәй була, күзләрен йорт казларының урам тутырып каңгылдашып очарга маташулары күз алдына килә, салам түбә кыегына оялаган чыпчыклар, өянке башларындагы карга оялары — һәммәсе шундый якын, шундый кадерле. Әйтерсең, Сәхиянең авылдагы гомере бәхеттә, рәхәтлектә үткән. Бәлки бәхетнең ни икәнен аңлар өчен дә вакыт узу кирәктер. Сагыну һәм юксыну өчен «һәркемнең дә үзенә якын туган-үскән жирләре» дип жырлар өчен ул жирләрдән аерылып тору кирәктер.

Әгәр юлда машинасы ватылып, машина астында озак ятудан салкын

тиеп, күзләре начарланып китмәсә, Сәхия һаман авылын эчтән генә сагынып читтә яшәп ятар иде. Чираттагы комиссиядә врачлар, сиңа машинада эшләргә ярамый, дигән язу биреп чыгаргач, әллә нишләп китте ул. Бәрелде-сугылды, хаксыз икәнен белсә дә, врачларга үпкәләде. «Гомер шулай үтеп тә китте микәнни?» — дигән уй җанын өшетеп алды. Хәтта беразга авылны сагынулары онытылып торды. Куллар ирексездән озак еллар кесәдә йөреп искереп беткән һәм инде менә киреәксезгә чыккан шоферлык таныклыгы белән әле яңа гына алынган пенсия кенәгәсен капшадылар. Беренчесе аның җаныдай кадерле, сине гомер буе яклашкан дустыдай газиз, икенчесе яңа кием кебек иләәшелмәгән, күнегелмәгән иде.

Кеше, гадәттә — я бәхете ташып торганда, я күтәрә алмаслык кайгы килгәндә, я юлын югалтканда — туган якларына кайта. Бәхетле кешенең үз бәхете белән бераз мактанасы, кайгылының кайгысын таратасы, юлын җуйганнарның юл табасы килә.

Сәхия менә шундый көннәрдә — алга алып баручы юлының өзелгән көннәрендә авылга кайтып төште.

Ул, күнегелгән гадәт буенча, һәркөн таң белән торып утырды, ишегалларын урады. Колхозның механика мастерское тирәләренә барып чыкты, моторлар гүләвенә колак салды. Әгәр берәр машинаның тигезсез эшләвен күрсә: «И пешмәгән нәрсә, рәзе машинаны шулай йөртергә ярый»,— дип, эчтән генә шоферга сукранды.

Авылдашлары, Сәхиянең балтасы суга төшкән кешедәй йөрүен күреп, төрлечә сөйләделәр.

— Тормыш моны да җиңгән икән. Машинасы белән җен шикелле чаба торганые.

— Күзе начарланган диләр бит, машинага утырырга ярамый икән.

— Һәй, ахирәт, әйттең сүз. Теләсә, ул сукыр килеш тә шайтанның үзен узачак. Кеше таптатырмын, бәрелеп үләрмен, дип курка белә торган нәрсәмени ул.

— Ансы шулай инде, әле дә ул башка килмәстәй нәрсәләр уйлап йөридер. Ул бит безнең кебек эчендәгеп кеше саен чәчми. Менә мин әйтте диярсез: шаккаттырачак әле ул авылны.

Һәм Сәхия, авылдашларының сүзен расларга теләгәндәй, кулын кесәгә тыгып йөрүдән туктады. Әллә кемнең иске мотоциклын алып кайтты. Аны башта кирәксез сәгатьне сүткәндәй сүтеп ташлады, аннары җыя башлады. Малай-шалайның күзе койма ярыгында булды: моннан ни чыгар? Әгәр бу тимер өеменә җан кертә алса, Сәхиянең дәрәҗәсе алар алдында бермә-бер үсәчәк иде.

Көннәрдән бер көнне мотоцикл... койрыгы капкага кысылган кәҗәләрне көнләштерерлек тавыш белән эшләп китте. Зәңгәр төтен ишегалдына гына сыймыйча урамга чыкты һәм малайларның борыннарына ислемай булып керде. Шушы көннән Сәхия тагын элекке хәленә кайтты. Авылның бер очыннан икенче очына тыр-тыр чапты. Авылда күп кешедә машина, мотоцикл булуга карамастан, күзләр Сәхиягә текәлде. Чөнки моның мотоциклы кебек төтенле, тавышлы, калтыравык мотоцикл авылда юк иде.

— Теге «җен калтырчасы» чыккан инде,— дип сукранып калалар иде карчыклар.

Сәхия үз алдына ниндидер максат куйган иде, күрәсең, кайчакларда «җен калтырчасы» белән ераккарак, район тирәсенәрәк китеп югалгалады. Таныклыксыз йөрисең дип, инспекторлар тотып алудан курыкмады.

Менә беркөнне Сәхияләрнең капка төпләренә кирпеч төялгән зур-зур машиналар килеп туктады. Ишегалдына машина керерлек түгел иде — капка төбенә бушаттылар. Өй каршында ап-ак кирпеч өелеп калды. Нигез өчен тимер-бетон свай башлары кайтартылды.

— Өй салырга җыена,— диде кешеләр.— Зурдан кубарга уйлый бугай.

— Аныкы кешечә генә булмас.

Иске өйне сүтми торып, яңа өй салырга урын юк иде. Чөнки

хужа үзе ничә еллар читтә йөргәндә, һәр ике як күршесе аны кысрыклаган булып чыкты. Сәхия ике уйлап тормады, бульдозер китертеп, өйне бәрәңге бакчасына таба сөздерде дә куйды. Хәтта эчендәге карават ише нәрсәләрен дә чыгарып маташмады. Бер-ике сәгатьтән инде өй урыны кунак табынындай такырайган иде. Өй салырга ул, каяндыр табып, бик оста әрмәннәр яллады. Нигез чокырын казырга экскаватор китерде.

— Коры тотынды. Читтә йөргән чакларын кире кайтармакчы ахры.

— Өй генә түгел, клуб салдырырга уйлый бугай бу исәр баш.

Күзләргә кергәләгәнче, өйгә соңгы кадак кагылды. Район кибетеннән матур-матур җиһазлар алып кайтып, өйне бизәп җибәрделәр. Осталар белән исәп-хисапны өзәргә торганда, Сәхия аларга тагын бер эше калганлыгын әйтте: ишегалдына таган ясап куярга кушты.

Таганга бик кызыга иде ул. Әтиләре, сугышка киткәнче балта остасы булып эшләсә дә, кызларына андый нәрсәләр ясап, аларны иркәләмәде. Ул турыда бервакыт Сәхия сүз кузгаткач: «Атынасы килгән кешегә тал ботагы беткәнме?!» — дип кенә куйды. Гомумән, өй өчен тырыша торган кеше түгел иде әтиләре.

Ә менә алардан бер тыкрык аша гына яшәүче Гаяз абзый үз кызлары өчен ни генә ясамады. Койма аша ишегалларына күз салсаң, аерылып булмый иде. Гаяз абзыйның ап-ак күлмәкле кызлары итәкләрен җилфердәтә-җилфердәтә, атынчыкта атынып ятканда, Сәхиянең йөрәге әллә нишләп китә иде. Яшьле күзләрен җиңе белән сөртә-сөртә, койма ярыгыннан бик озак карап тора, тик керергә кыюлыгы җитми, чөнки Гаяз абзый ишегалларына чит балалар җыелганны яратмый иде. Сәхиягә Гаяз абзый кызларыннан да бәхетле кеше юктыр кебек тоела иде.

Ә бервакыт, инде колхозда су ташучы булып эшли башлагач, төнлә, курка-курка, Гаяз абзыйлар ишегалдына керде ул. Моның өчен аңа шактый көннәр Гаяз абзыйларның этен үзенә бирелгән ипи белән сыйларга туры килде.

Ләкин аңа таганда атынырга насыйп булмады. Караңгыда кармаланып барганда, ул ниндидер буш чиләккә абынды. Чиләк коточкыч тавышлар чыгарып тәгәрәп китте. Чиләк тәгәрәгән тавышка эт өрергә тотынды. Сәхия этнең башыннан сыйпап: «Бу мин, Актырнак, өрмә,— дип сөйләнде.— Бер генә тапкыр шунда атынып карарга рөхсәт ит. Мин сине тагын үземә тиешле борчак ипие белән сыйлармын».

Сәхия Актырнакны тынычландырды, ләкин хуҗа эт өргән тавышка уянып өлгергән иде шул инде. Ул: «Кем бар анда?» — дип йөгереп килеп чыкты. Сәхия өянке төбенә сеңде, тик Гаяз абзыйның фонареннән төшкән яктылык аны бик тиз эзләп тапты.

— Ә-ә, менә кем икән минем кыярларны әкрен генә сыпырып ятучы! — Гаяз абзый Сәхиянең кулларыннан эләктереп алды. Сәхия аңа берни әйтә алмады. Атынчыгында атынып карарга гына кергән идем, дигәнгә, Гаяз абзый барыбер ышанмаячак. Изүен ачып дыңгычлыйдыңгычлый кычыткан тутырганда да, кычытканыңны тиз генә ташлыйсы булма дип, өр-яңадан төймәләрен каптырганда да, ул авырту сизмәде кебек. Бары үзе артыннан капка ябылгач кына яңаклары буйлап ике кайнар тамчы тәгәрәп төшүен тойды.

Шул көннән башлап таган аның тормышка ашмаган хыялы булып калды. Яңа өй каршына таган ясатып куйгач, авыл халкы янә бер гаҗәпләнде: «Бусы нәрсәгә икән тагын?»

Ә таган, малай-шалайларның күзен яндырып, җил искәндә,әкрен генә тирбәлә иде. Сәхия үзләре тирәсенә малайлар җыелганны күрсә, пинжәген иңнәренә элеп, капка төбенә чыга һәм көчләп диярлек малайларны ишегалдына кертә: «Атыныгыз. Курыкмагыз, бавы өзелерлек түгел».

Малайлар башта бу ят ападан кыенсыналар иде. Килгән саен капкасы ачык булгач, иялаштеләр. Бигрәк тә этисез малайлар якын итте аны. Теге «җен калтырчасын» бörгалап кабызып карау дисеңме, ишег-

алдында аунап яткан кирпечләрдән «өй»ләр салу дисеңме — һәммәсе кызык иде. Малайларга иске мотоциклның тәтенәнә хәтле кадерле. Алар, кыюланып китеп, аны сөткәләп тә карыйлар. Сәхия, болдыр баскычына утырып, аларның мәж килеп уйнауларын күзәтә. Вакыт-вакыт йөзендә бәхетле елмаю чагылып китә.

## 9

Инде тормышын көйләп куйгач, күңеле басылыр, дип уйлаганнар иде, ә ул һич көтмәгәндә юкка чыкты. Хәтта өен дә бикләмәгән иде, күршеләре генә ишегенә йозак салып куйдылар.

— Кая китте икән бу? — дип аптырады күрше-тирәсе.— Әллә сугамазар төшеп үлде микән? Су буенда йөрергә бик ярата иде.

— Тырышып-тырмашып өй бетерде, мескенкәй. Рәхәтен күрә алмый китеп барды микәнни?

— Исәндер әле, исәндер. Менә мин әйтте диярсез, таш арасыннан чыккан үлән кебек, көтмәгән-уйламаган җирдән калкып чыгар.

Әйе, Сәхия исән һәм аның нияте зурдан иде. Ул апасы Сәкинәне эзләп китте. «Дөнья без бәләкәй чакта гына артыгын зур тоелган, табармын. Илне ике урасам урармын, барыбер эзенә төшми туктамам»,— дип үҗәтләнеп тотынды ул. Һәм тапты. Апасы, ул уйлаганча, җәһәннәм астында булмаган, шушында борын төбендә — Өфе каласында гына яшәп яткан икән.

Сәхия, Сәкинәне табу белән, эченә ничә еллар буе җыелып килгән барлык рәнҗүләрен, үпкәләрен, ачуларын берьюлы түгеп салырмын дип уйлаган иде. Тегү машинасына кадалып, шалтыр-шолтыр нидер тегеп утыручы апасын күргәч, катты да калды. Бу хәлендә Сәкинә нәкъ әниләренә охшаган иде.

Ата-ана — кешегә үскәч тә кирәк икән. Кеше җылыныр өчен кулларын учакка сузган кебек, гел ана назына тартыла, һич югы, шул назны күңелендә яңартып юана. Сәхиянең күңеленнән гомеренең бер кисәге яктырып үткәндәй булды, бөтен үпкәләре онытылды.

— Сәкинә! Апа!

Сәкинә сагаеп башын калкытты. Күрешергә дип кулларын сузып, үзенә таба килүченең Сәхия икәнлегенә ышанырга теләмичә чылт-чылт күзләрен йомды. «Мин инде бу, мин — Сәхия, — диде таныш түгел кеше.— Тәки таптым үзеңне. Менә кая качкансың икән».

Алар кочаклашып күрештеләр. Сәкинә түшенә кадаган энәсен нишләтергә белмичә әле тартып алды, әле яңадан кадады. Аннары ул электр чәйнегенә чәй куеп җибәрде. Аны белән әле ул һаман Сәхиянең үзеннән бик бәләкәй калган сеңлесе икәнлегенә ышанып җитә алмый иде. Күрешү ыгы-зыгысыннан айный төшкәч, яулык почмагына күзләрен сөртеп мышкылдарга тотынды.

— Һаман шул җыбыткы икәнсең,— диде Сәхия. Ләкин аның үзенең дә күңеле менә тулам, менә түгеләм дип тора иде.

— Сүк әйдә, сүк,— диде Сәкинә,— синең шулай сукранып йөрүләреңне сагындым.

— Сагынгач кайталар аны. Сине авылдан көлле пумала белән куып җибәрмәделәр ич.

— Кешеләр кумаса, оятым куды. Шул нәрсә мине гомерем буе эзәрлекләде. Бер шәһәрдән икенчесенә качарга мәҗбүр итте. Юкса мин әллә кайчан төпләнеп, менә дигән фатирларда яшәргә тиеш кеше идем.

Сәхия — апасының бүлмәсенә күз төшереп чыкты. Әйе, мактанырлыгы юк шул. Күрәсең, тормышы җиңелдән булмагандыр. Тик, ни хикмәттер, апасын кызганмады ул, киресенчә, аңа ачуы гына чыкты.

— Алайояттан бик курыккач, нигә соң ятимнәр үрчетеп йөрисең? — диде ул рәнҗеп.— Үзебез ятим үскән җитмәгәнме?

Сәхиянең йөзенә бәреп әйткән әлеге сүзләреннән Сәкинә куырылып калды. Әйтерсең, аны шәп-шәрә килеш кычыткан арасына кертеп җибәрделәр, тәнендә бүртмәч-бүртмәч тимгелләр барлыкка килде, тамырлары тартышты.

— Син аларын да беләсеңмени? — диде ул көч-хәл белән.

Сәхия бу сүзләрне авылда ишеткән имеш-мимешләргә генә таянып әйткән иде күрәсең, гайбәт дигәннәре хактыр. Әнә ич апасы ничек кызарынды. Чыраеннан учак кабызырлык булды.

— Авылның йөз күзе бар. Аннан берни яшерә алмыйсың,— диде ул апасының күңелендә өмет калдырмыйча.

Бүлмәдә беразга авыр тынлык урнашты. Һәр икесе үз тормышын күз алдыннан уздырды. Соңыннан Сәхия ике кулы белән тезләренә сугып, урыныннан сикереп торды.

— Ярар, булган эш булган инде,— диде,— мин сине авылга апкайтырга дип килдем. Әйдә, балаларыңны эзләп табабыз да...

— Юк, юк,— диде Сәкинә коты очып.— Нинди кайту ди ул? Мин инде хәзер өзелгән яфрак. Ә өзелгән яфракны агачына кире элеп куеп булмый. Син миңа, ни өчен ятимнәр үрчетеп йөрисең, дисең. Кеше ул бер хатасын төзәтәм дип, икенчесен эшли, аннан өченчесен. Соңыннан бөтенесенә кул селти. Мин беренче баламнан җайлы гына котылсам, өр-яңадан тормыш корып җибәрермен дип уйладым. Кешесе дә чыгып тора иде. Тик булмады. Иртә уңмаган кич уңмый диләр бит. Китте. Бала буласын белгәч, башын алып качты. Минем дә ачуым килде: «Нигә әле ул баланы мин генә карарга тиеш? Миңа гомер ике бирелгәнмени? Яшәп калырга кирәк»,— дидем.

Үземне шулай тынычландыргач, җиңеләеп киттем. Минем турыда яман сүзләр куера башласа, фанер чемоданымны күтәрдем дә башка җиргә сыпырттым. Миңа ул шәһәр тормышының тагын бер җайлы ягы. Корган нигезем кала дип уфтанасы юк. Һәммәсе җиңел хәл ителә. Шулай озак вакытлар үземне иркә кош санап йөрдем. Баксаң-күрсәң, мин иркә кош түгел, бая әйткәнемчә, җил кая иссә — шунда очып йөрүче өзелгән яфрак булганмын икән. Әйе, өзелгән яфрак. Авыл — мәңге яшел агач. Мин инде хәзер күпме генә тырышсам да, ул яшел агачның яфрагы була алмыйм.

— Мин авылга өй салдым. Үзебезнең нигезгә,— диде Сәхия.— Өй зур, барыбыз да сыярбыз. Алып кайт балаларыңны. Ничә балаң бар?

— Син нәрсә? — Сәкинә чын-чынлап гаҗәпләнде.— Ул балалар бит инде тормыш корып, үзләре бала үстереп яталар.

Сәхия ничектер бу турыда уйламаган иде. Кара инде бу гомерне? Чыбыркы шартлату кебек кенә икән. Кайтавазы урман арасына керә дә югала. Аннары эзләп кара син ул кайтавазны! Ә бит Сәкинә матуррак итеп яши ала иде. Бала тапкансың икән, нигә аларны әллә кайларда калдырып китәргә? Әзме авылда алтышар-җидешәр баланы ялгыз үстергән толлар? Аларны бәхетсез дип кем әйтә ала?

Сәхия ишекле-түрле йөрергә тотынды. Апасының үткән тормышы белән ныграк танышкан саен, йөрәгендә әрнү арта барды. Үзенең бәхетсезлегенә күнеккән иде инде ул. Аннары аның тормышында бик-бик якты көннәр булды. Кеп-кечкенә килеш зурлар кулыннан килмәстәй эшләрне ут өереп эшләгәндә, бала-чагаларны машинасына төяп урам әйләнгәндә, авыл кешеләренең утынын-печәнен кайтарып, мең-мең рәхмәтләр ишеткәндә, бәхетле түгел идемени ул?

Ләкин кеше үткәннәр белән генә яши алмый. Аңа киләчәк кирәк, өмет кирәк. Ә Сәкинә белән Сәхиянең киләчәге кая?

Апа һәм сеңел әле елашып, әле яшь аралаш көлешеп, үткән көннәрен күңелдән уздырдылар.

— Зур булсалар да, син аларны эзләп тап,— диде Сәхия ниһаять ныклы карарга килеп.— Бала ата-анасының туган җирен белергә тиеш. Кайтсыннар, күрсеннәр, бәлки төпләнеп калырлар. Берга-бергә яшәрсез.

Кем әйтмешли, бәхет өчен беркайчан да соң түгел. Минем балаларым булсамы?!

— Их! — диде Сәкинә ачынып.— Алар мине әнкәләре дип танымыйлар бит. Олылары турында әйтмим инде мин. Аларын үзем дә бала итәргә уйламадым. Язмышларын читләр кулына тапшырдым. Алары кыз балалар иде, ә кыз балаларны без ата-ана йортыннан барыбер очарга тиешле кош дип саныйбыз. Минем ишетүемчә, кызларым матур гына тормыш корганнар. Ә менә өченчесе...

— Өченчесе...

— Әйе. Анысын мин аның табам дип тапмадым. Олыгаеп килә идем. Котылырга мөмкинлек булмады. Үзенең артык кеше икәнен белгән кебек, бик киребеткән малай булып чыкты.

— Малай?

— Әйе, малай.

— Хәзер аңа ничә яшьләр инде?

— Уналты тулып килә.

— Син аның кайда икәнен беләсеңме?

— Беләм. Баргалап йөрим. Квартира якларын җайлагач, үз яныма алырмын дип уйлаган идем, җүнсез малай, качып китте.

— Кайда ул?

— Шушында, балалар йортында. Нишләптер мине бер дә яратмый. Мин килгәнне күрсә — кача.

— Әйдә киттек. Алып кайтыйк без аны. Авылга алып кайтыйк. Малай кешегә төпләнер урын кирәк. Ныклы нигез кирәк.

Сәхия, апасының бу малае турында ишеткәч, җанланып китте. Күңелендә өмет чаткылары дөрли башлады. Яшьлеккә кире кайткандай, тамырларына кайнарлык, җиңеллек, дәрт йөгерде. Ләкин апасы аның ашкынуын уртаклашырга ашыкмады.

— Син аны күрсәң, бик тиз сүрелерсең,— диде ул.— Балалар йортында аннан зарланмаган кеше юк. Дөньядагы бөтен этлекне ул уйлап таба диләр.

Сәхиянең җаны түзмәде, апасын ашыктыра башлады. Сережаны (малайның исеме Сережа иде) бер күрүдә яратырмын кебек тоелды. Апасының сөйләвенә караганда, холкы белән ул Сәхиянең кечкенә чагына охшаган булырга тиеш. Сәхия аз сугыштымы? Бу бит аның тормыш кыерсытуларына җавабы иде. Малай кеше бит әле ул. Малай башы белән тормыш җәберләренә нигә буйсынып яшәсен! Сәхия аны бик яхшы аңлый. Кеше, читтән таяныч тапмаганда, һәрвакыт шулай тормыш каршылыкларына үзенең киреләген куя. Көрәшә, үзен сытарга теләүче яманлыкны тар-мар итәсе килә аның.

Кешегә гел таяныч кирәк. Кеше җылылыкка һәрвакыт мохтаҗ. Тауның биегенәрәк менгән саен җил-давыллар көчәйгән кебек, гомер үренә менгәндә дә давыллар каршылыгы арта. Тормыш юллары төрлечә булган төсле, кешеләрнең мохтаҗлыклары да төрлечә. Бераүләргә каткан күңелләрен йомшартыр өчен — наз, икенчеләргә зарларын сөйләгәндә — тыңлаучы, өченчеләргә — көченә-гайрәтенә сокланучы, дүртенчеләргә тагын әллә нәрсәләр кирәк. Ә Сергей кебек уналты яшьлек чагында мондый кирәкләр санап бетергесез була. Менә шуны тою ашыктырды Сәхияне.

Барышлый алар, кибеткә кереп, күчтәнәчләр алдылар. Сәхия, сумкасын дыңгычлап тутырганнан соң, кибеткә яңадан кереп, бер бөтен ипи күтәреп чыкты. Аның күз алдына мичтә яңа пешкән шишара тоткан Зәйнәп әби килеп басты. Нинди тәмле булган иде Зәйнәп әбинең ул шишарасы! Әтисе фронтка китеп һәлак булганнан, апасы бердәнбер кәҗәдән яздырып чыгып тайганнан соң үзен дөньяда иң артык, иң кирәксез җан итеп тойган чагында күтәреп кергән иде Зәйнәп әби кайнар ипекәен. Шул ипинең тәме әле һаман онытылмый. Ипидә кешеләрне бер-берләре белән туганлаштыра торган көч бардыр, күрәсең.

Әле кибеттән алып чыккан ипи дә теге чактагы кебек җылы иде.

— Син нәрсә? — диде Сәкинә,— әллә аларны анда ач тоталар дисеңме?

— Юк, ач тоталардыр димим. Көчтәнәч тәмле була бит ул.

— Алар безнең чор балалары түгел, ипигә шаккатмыйлар.

Сәхия Зәйнәп әби алып кергән ипи турында апасына сөйләп тормады.

Беразга алар сүзсез бардылар. Балалар йортына килеп җитәрәк Сәкинә туктап калды.

— Бар, үзең генә кер, бәлки синең белән сөйләшер. Син бит аңа чит кеше. Мине күргә, җене котыра башлый. Тәрбиячеләре дә, син килеп киткәч, отыры усаллана диләр.

Сәхиянең кем икәнлеген һәм нинди ният белән йөргәнлеген сорашкач, Сергейны чакырып китерделәр. Сәхия аны таза гәүдәле башкисәр егет итеп күз алдына китергән иде. Сережа тәбәнәк буйлы кеп-кечкенә малай икән. Тышкы кыяфәтенә караганда, аңа һич уналтыны бирерлек түгел.

— Я, үсеп буламы? — диде Сәхия беренче сүз итеп.

— Үсеп булмаса, әллә синдә даруы бармы? — диде Сережа дорфа гына.

— Бар шул,— диде Сәхия бик ышанычлы итеп һәм сумкасындагы күчтәнәчләрне Сережа алдына өеп куйды.— Менә боларны ашасаң, шундук бер башка үсәрсең. Ипиен генә кара әле, авыздан суларны китерә. Тик бер шарты бар: иптәшләрең белән бүлешеп ашыйсың. Качып-посып ашаган кеше үсә алмый.

Сережага әнисе берәр әйбер алып килсә: кешегә өләшмә, шушында гына аша ди иде. Ә бу түти бөтенләй киресен сөйли. Шулай да Сережа күчтәнәчләргә үрелергә ашыкмады: олылар корган тозак булмагае. Алдыңны-артыңны карап эш итү яхшырак.

— Син кем соң?

— Мин синең тутаң булам.

— Тутам? — Сережа шарык-шырык көләргә тотынды.— Менә тагын берәү табылды. Мин үсеп җитүгә «газиз» эткәем һәм әбекәй-бабакайларым табыла башлар әле.

— Бик мөмкин. Кеше үзенең хаталарын тора-тора аңлый. Аңлагач, ялгышларын төзәтәселәре килә.

— Юк инде, мин аларга мондый мөмкинлек бирмәячәкмен.

— Нигә ул тиклем усаллык?

— Алар да җәзасын күрсеннәр.

— Ә беләсеңме, синең әниеңне тормыш болай да аз җәзаламады.

— Белмим һәм белергә дә теләмим. Минем әнием юк. Мин бит җилдән туган малай. Җилдән туганнарның әтисе-әнисе булмый.

Сережа үз сүзләреннән канәгать иде, тагын ямьсез итеп көләргә тотынды. Сәхия аны бөтенләй ишетмәгән шикелле малайның мыскыллы ыржаюдан туктавын көтте.

— Менә нәрсә, үскәнем,— диде ул аннан сабырлыгын җуймаска тырышып.— Кеше үзенең тууына җаваплы түгел, әмма яшәвенә җаваплы. Әгәр синең эчеңдә ачу гына булса, сиңа яшәү кыенга киләчәк. Син бернигә дә ирешә алмаячаксың. Ә бит синең, мөгаен, көчле, батыр буласың киләдер.

— Килсә соң!

— Менә-менә, барыбызның да көчле буласыбыз килә. Тик көчлелекнең нинди икәнлеген генә белеп бетермибез.

— Һы, әллә мин аңгырамы? Шуны белмәскә! Көчле кешедән бар да курка. Ә көчле кеше үзе беркемнән курыкмый. Теләсә кемне салып кына ега.

Сәхия малайның беркатлылыгыннан елмаеп куйды. Кайчандыр ул үзе дә шулай уйлый иде бит. Көчлелекнең урамда сугышып башкалардан өскә чыгу гына түгел икәнлеген аңлатырга кирәк иде. Ул Зәйнәп әбине мисал итеп алды.

— Менә тыңла,— дип башлады ул сүзен.— Кайчандыр синең кебек бар дөньяга үчле бераү яшәгән. Аны тормыш бик кыерсыткан: әтисен-әнисен тартып алган. Бер туйганчы ашар өчен ул көннәр буе чапкан. Бөтен яклап кысрыклаучы тормышка бик-бик рәнҗегән ул. Йодрыкларын һаман ныграк йомарлый барган. Үзе яшендәгеләрне генә түгел, үзеннән зурракларны да шактый кыерсыткан. Бүтәннәрне күбрәк елаткан саен, үзенең өстенлегенә ышана барган. Ә боларның күршесендә бетәшеп беткән бер әби яши икән. Көннәрдән бер көнне шул әби әлеге көчле малайларга җып-җылы ипи күтәреп кергән. «Мә, бәбкәм, аша»,— дигән ул. Ә малай белә: бу әбиләрнең дә ашарларына юк. Чөнки заманасы шундый — сугыш заманасы. Әби моңа ипине үз авызыннан өзеп керткән. Менә синең бик нык ачыгып караганың бармы?

— Бар. Качып киткәч, туры килде.

— Шулай ачка үләрдәй булып йөргәндә, синең кулыңа бер телем ипи килеп керде ди. Син шул ипине үзеңнән ачрак икенче бераүгә бирә алыр идеңме?

— Нигә бирим ди мин аны? Ул үзе тапсын.

— Шул-шул. Ә теге әби бирә алган. Үз кулындагы ипине бүтәннәргә сузу өчен, урамдагы малайлар белән сугышуга караганда күбрәк көч кирәк булгандыр аңа, мөгаен.

Сәхия үзенчә көчлелеккә төрле мисаллар китерде. Аның мисаллары шундый аңлаешлы, гади иде. Сережа хәтта каршылык күрсәтә алмый торды. Бу таныш түгел түти аңа кай ягы беләндер серле булып тоелды. Әнә ич: «Теләсәң, мин сине бик көчле кеше итә алам»,— ди. Үзе мөгаен Сережаның җиленнән аварга торадыр әле.

Һәм Сережа, бу беркатлы түтине төп башына утыртырга уйлап, ачык ишектән тиз генә шылмакчы булды. Әмма теге түти әллә нинди гайрәт белән аны шундый итеп эләктереп алды, әйтерсең Сережаның беләге авыр ишеккә кысылып калды.

— Без бит синең белән качышлы уйнарга сөйләшмәдек,— диде ул малайның кулын җибәрмичә.— Син әле мине тыңлап бетермәдең. Мин сине алып китәргә дип килдем.

— Ә минем китәсем килмәсә?

— Килер. Син әле үзеңнең ни теләгәнеңне белеп бетермисең.

— Син беләсеңме?

— Беләм. Чөнки мин синең яшьтә булып карадым.

— Алайса әйтеп кара: миңа ни кирәк?

— Сиңа, үскәнем, иң элек таяныр кеше кирәк. Аннары тамыр җәяр өчен туган җир, үзеңне ныклы сизәр өчен нигез кирәк. Бу түти акыл сата дип уйлама, мин моны үземнән чыгып әйтәм. Мин үземә ни кирәген артык соң аңладым. Ә менә сиңа әлегә соң түгел. Вәт шулай, үскәнем. Җыенып тор. Мин сине алып китәчәкмен. Ә хәзер, бар, күчтәнәчләреңне дусларың белән бергәләп аша. Әгәр үзеңнең көчлеме-түгелме икәнлегеңне беләсең килсә, үзеңә бик кадерле нәрсәңне башкаларга биреп кара.

Сәхия шулай диде дә малайның җилкәсеннән кагып чыгып китте. Ул инде Сергейны үзе белән кайтырга күндердем дип уйлаган иде, иртәгесен малайдагы үзгәрешне күреп шаккатты. Сережа бүген аның белән сөйләшергә бөтенләй теләмәде, ә Сәхия ныграк төпченә башлагач: «Ни кирәк сезгә миннән, нигә килдегез?» — дип кычкырынырга тотынды. Сәхия аның сүрелә төшкәнен көтте.

— Тынычрак сөйләшик әле,— диде ул.— Ни кирәкме? Дөресен генә әйткәндә, ни кирәген үзем дә белмим әле, ләкин кирәк. Синең менә бер ялгызың яшәп караганың бармы? Юк. Син үзеңне бик бәхетсезгә, кешеләр тарафыннан рәнҗетелгәнгә саныйсың. Ә бит синең янында үзең кебек иптәшләрең, кирәк чакта барып сыенырга акыллы тәрбиячеләрең, уйныйм дисәң, бөтен төрле уенчыкларың бар. Син бер мәртәбә дә мичена ягылмаган салкын өйләрдә ятып йокламагансың, тәннәрең дер-дер калтырап уянмагансың, күңелеңдәге хыялларыңны сөйләр кеше тапмыйча интекмә-

гәнсен. Синең, башкалар умырып ипи ашаганны күреп, авызыннан сулар килмәгән. Дөрес, синең дә ялгыз гына яшәренеп елаган, әниеңнең тезләренә башың салып иркәләнәсе килгән көннәрең булгандыр. Син инде, хәзер мин үстем, андый чакларым артта калды, миңа беркем кирәкми дип уйлыйсыңдыр. Юк, үскәнем, кешеләр һәрвакыт бер-берләренә кирәк.

Ул көнне алар сүзсез генә аерылыштылар. Сергей инде бу тути янадан килмәс дип уйлаган иде, ялгышкан булып чыкты. Сәхия иртәгесен дә янадан килде.

— Миннән туймадыгызмы әле? — дип каршылады аны Сережа.

— Син бит майлы ботка түгел, майлы боткадан тына туялар,— диде Сәхия.

— Юк, миннән дә бик тиз туялар,— диде Сергей.— Миңа әни тиешле кеше бер килсә, ике-өч атна күренми йөри.

Әйе, Сәхия үзе дә апасын аңлап бетерми. Сөйләвен тыңлап торсаң, Сережа өчен җанын ярып бирер төсле. Хәтта күзеннән яшь агызмый сөйли алмый. Ә эшкә килгәндә — бөтенләй киресе. Нича сумлык күчтәнәч алып барганына кадәр чутлап бара. Аннары кешеләргә шуны тотып селки: имеш, менә мин аның өчен күпме тырышам, ә ул кадерне белми.

Сәкинә үз гомерендә бер тапкыр да кешеләргә яхшылык эшләү бәхетен татып карамаган, күрәсең. Юкса һәр нәрсәне исәп-хисапка гына кормас иде. Сергей әнисе янына кайтырга ризалашса да, аңа җиңел булмаячак.

Шушы нәрсәне аңлаганга күрә, Сәхия хәзергә апасын авылга кайтырга артык кыстамады, басымны күбрәк Сережага ясады. Әйдә, Сережа бераз бүтән тормышка, чын тормышка күнегә торсын. Үзе турында кайгырту сизеп, җаны эри төшсен.

## 10

Сәхия авылга үзенең бәләкәй чагындагы кебек ут күзле, йомры башлы малай җитәкләп кайткач, авыл гөж килде.

— Менә кемгә дип салган икән гүрнәчадәй өйне.

— Әйттем бит мин сезгә, таш арасыннан чыккан үлән кебек, уйламаган җирдән кайтып керер дип.

Ә Сәхия авылдашларының үзенә текәлгән күзләрен күрмәде. Ул Сережага ишегалларын, өйләрен күрсәтеп йөрде. Үзе югында утыргычын малайлар шомартып бетергән атынчык янына алып килде. Көчли-көчли анда Сережаны утыртып атындырып алды.

Сережага яңа урында иң ошаган нәрсә — абзар почмагында сөялеп торучы иске мотоцикл булды. Ул ап-ак кирпечтән салынган йортка да, бүлмә саен куелган ялтыравыклы җиһазларга да исе китмичә әлеге «җен калтырчасына» барып тотынды.

Сахия мотоциклны тибеп кабызды. Күрше тавыкларының котын алырлык тавыш яңгырады. Малайның авызы ерылды. Беренчедән, бу түтинең тылсымчы кебек бер тибүдә мотоциклны кабыза алуына сокланса, икенчедән, теләгәндә йөрерсең, үзенә булыр, дигән сүзләре йөрәгенә май булып ятты.

«Качарга туры килсә, матайны йөртергә ныклап өйрәнергә кирәк»,— дип күңеленә салып куйды. Ул әле үзенең бу якларга, тышкы яктан кырыс күренгән Сәхия тутасына көннән-көн ныграк ияләшәчәген, Сәхия тутасы сөйләгән тамыр җибәрер туфракны шушында табачагын белми иде.

Сәхия өр-яңадан яшьләгенә кайткандай очынып йөри башлады. Аның күңелендә моңарчы бер тапкыр да татып карамаган бәхет тертеп килә иде. Бу бәхет — кеше язмышы өчен борчылу, кемгәдер таянычы икәнеңне аңлау бәхете иде.

## Ренат Харис

# ТУЗГА ЯЗГАННАРДАН

### Шагыйрь

Дөреслекнең теле булыйм!
Тормыш гөрзиләре
сандалларга салып тапаса да,
Дөреслекнең теле булыйм!

Чәчәк, күбәләкләр турында дөресен җырлау гына —
батырлык түгел,
ә батырлыксыз шагыйрь була алмый!

Дөреслек — кеше йөрәгенә кергән һәр нәрсәдә...
Йөрәктән ерак нәрсә турында дөресен әйтү — җиңел.
Сәясәт, абруй, тәхет, шәхес, бәхет
турында дөресен әйтү —
барлык гасырларда да
ут үбүгә бәрабәр булган,
шагыйрь гомере буе
тәмуг аша шигырь юлы булып сузылган
кылдан йөргән!
Дөреслекнең теле булыйм —
телсез Дөреслек — телле ялган колы...

### Баскыч

Баскыч һәрвакыт биеклек белән тәбәнәклекне,
түбәнлек белән бөеклекне тоташтыра.

Тугач ук, тәпи баскач ук
аягыңа синең баскыч кагыла:
беренче басмаң — әниең тезе,
аннары — өстәл,
аннары — койма башы,
аннары — өй кыегы,
аннары — иң биек агач очы...

Егылгалап төшкәлисең...
Борының каный,
кулың чатный,
тешең сына..

Торгызалар, яраларың бәйлиләр,
кеше булырга ярдәм итәләр,
чөнки син
адәмлектән түбәнрәк төшеп китмәгәнсең.

... Мәтәлгәләп киткәлисең һәм кинәт:
«Мөгезеннән тотыгыз, койрыгыннан күтәрегез,
чыбыркылагыз, бәлки торып китәр!..»
Димәк,
син адәмлектән шактый түбәнрәк...
Һәм бу очракта
сиңа бернинди баскыч та ярдәм итмәс.
Кеше гомере буе юлда түгел,
кеше гомере буе баскыч басмасында.
Аны бөеклек өскә тарта,
түбәнлек аска өстери.

Син бел:
баскычның ике очы да — җирдән китү:
берсе — манара дәвамы,
икенчесе — коеныкы...

## Тезләнүче

Баш тезләнә алмый —
аның тезләре юк.

Башның сер тулы диңгезләре,
яктылык тизлегеннән тиз канатлары,
космосны йота алырлык упкыннары,
гасырларны сыйдырырлык гүзәл үзәннәре,
урманнары, таулары,
җанлы һәм җансыз барлык нәрсә белән
аңлашырлык аңы бар!
Шуңа башның тезләнерлек тезләре юк!

Ә син тезләнә алсаң — тезлән...
Башның тезләнерлек тезләре юк!
Ә син тезләнә алсаң — тезлән:
муен югарылыгында кылыч оча.

Тезләнүченең күзенә
күксез җир тула
һәм ул,
чиксез иркенлек ләззәтен тоймыйча ук,
җир була, гүр була...

Әгәр онныкларың канына да
тезләнү гадәте күчсен дисәң — тезлән.
Ләкин белеп тор: алар
сине иска төшереп сызланырлар!
Әнә җил исте — тезлән...
Әнә төтен чыкты — тезлән...
Чит бер радиодулкын төкрек чәчә — тезлән...
Бер исәр
йолдызлар сугышы белән яный — тезлән...

Муен югарылыгында кылыч оча...
Маңгай югарылыгында бәхет оча...
Башым горур,
күзләремнең аскы яртысына
барлык гүзәллеге белән җир тула,
өске яртысына —
иреккә, биеккә, чиксезлеккә омтылышлар чишмәсе — күк!

## Каргыш

Һәр каргыш җинаятькә төбәлгән була...
Иң олы җинаять иң беренче булып каргала...
Яманлыкның
кешегә һәм кешелеккә,
тамчы суга һәм чиксез океанга,
ком бөртегенә һәм Җир шарына
чаткыга һәм туй учагына,
сулышка һәм атмосферага кагылганы —
җинаять!
Ә җинаятьне бары кеше генә эшли.
Ә каргышка барлык нәрсә сәләтле!

Әгәр дә син — белепме, белмичәме —
берәр җинаять эшләсәң —
тамыр җимешкә агулы сут сузар,
җимеш тамыр өстенә төшеп черер
һәм черетер үз тамырын,
кылыч безе булып көнгә төн керер,
су уттан балага узар —
тәмуг туар...
Әгәр дә син
атом кнопкасына
бармак орсаң —
шул бармагың утлы табага салган
атланмайдай чыжлап эресен —
атом кнопкасы басым көчен сизмәс булсын!
«Каргыш — буш сүз!..» — димә!
Каргыш — чиктән ашкан теләк!

Каргыш яралудан курык —
каргыш атом шартлавыннан да көчлерәк!

## Юмартлык

Үз аңыңны һәрбер башка,
үз күңелеңне һәр кешегә,
үз хыялыңны һәр күңелгә,
үз сүзеңне һәрбер телгә,
үз илеңне барлык илгә
күчерергә телисең икән,
димәк,
синңа иңгән аксакаллар өмете,
яңадан кайткан сабыйлар тәвәккәллеге;
син үзеңне аңлагансың,
аңлагансың илеңнең асылын,
гүзәллегенә соклануың
яңгыр болытына әверелгән,

киләчәгенә ышанычың —
юмартлыгың чишмәсенә!
Улым!
Шушы теләк белән типкән
йөрәгең синең талмасын!
Тик
Мәҗнүн булып калма син —
кешеләрдән, төрле киртәләрдән
куркып, чүлгә качып китеп,
үз теләгеңнән үзең генә кабынып,
тычкан уты булып янма син!

## Төтен

Төтен күреп, син ни дисең?
Нәрсәгә юрыйсың?

Төтен — яктылык, җылылык кебек үк,
яну билгесе:
төтенне яшереп булмый.

Йөрәк яна — төтене нәрсә?
Хыял яна — төтене кая?
Ышаныч яна...

Төтен — учак эчендә туган бөек хәбәр.
Учак һәр нәрсәдә:
телдә, сәясәттә, нияттә,
әхлакта, йөрәктә, аңда, хәрәкәттә...
Төтен күрдеңме — белергә тырыш:
нәрсә көлгә әйләнә, нәрсә үчә,
нәрсә җансыз кала —
төтен мәгънәле,
аны аңлый белсәң,
ул сиңа акыллы киңәшләр бирер!

Тыңла халык сүзен — Җир төтенен,
һәм кемлегеңне белерсең...

## Хатыннар

Алар ирләрдән азрак булырга тиеш...
Сугышлар, төрле афәтләр аларны күбрәк итә —
ирләр китә, кайтмый...

Алар азрак булырга тиеш —
аларны без күбрәк яратсын өчен.
Азрак нәрсә һәрвакыт кадерлерәк!

Аларны сөю — илне, Җирне, яшәүне сөю.
Һәрберсенә илаһи наз,
түгәрәк бәхет тисен өчен
алар азрак,

бераз гына азрак булырга тиеш.
Хатыннар бәхетле булса — Җир бәхетле!

Сындырылган ботак,
тешләп ташланган алма,
тапталган чәчәк кебек язмышлар
кимрәк булсын өчен
алар азрак булырга тиеш.

Алар — безнең күкләргә чөелгән идеалыбыз,
безне ымсындырып,
төшләргә кереп чакырып, илһамландырып,
өндә батырлыклар кылдырып,
ир-егет иткән хыялыбыз!
Алар ирләрдән һәрчак күбрәк!
Үзләренең кадерләрен киметеп булса да,
горурлыкларының башын идереп булса да —
алар күбрәк!

Җирдә бәхетсезләр азрак булсын өчен —
алар күбрәк!

Ирләр,
ирләрдән күреп — илләр,
илләрдән күреп планеталар сугышмасын өчен —
алар күбрәк!

## Бизәкләр

Күзләреңдә матурлыкка мәхәббәт булсын,
колагыңда — гүзәл авазларга, тыныч тынлыкка!

Җирнең тәнен сылу тәне белән чагыштырма —
сылу — чишенгәч, Җир киенгәч гүзәл!

Йөрәгеңдә бизәкләргә мәхәббәт булсын —
һәм шунда гына син
күмерләрнең елаганын,
көлнең, канның сыкранганын ишетерсең...
һәм кулларың чүкеч сорар,
йортлар төзер, гармунга үрелер,
алмагачның ярасын бәйләр.

Аңыңда бизәкләргә мәхәббәт булсын —
шәһәр-авылларның,
һәр сукмакның, аэропортның,
һәр паркның, багананың
Җир күлмәгендә асылташ икәнлеген күрерсең!

һәм үзең үк сизәрсең:
кальбеңне җәберсетеп торткан
җимерү, вату, юк итү теләгенең
тамыры корый башлар.
Аны урыныннан куптарып,
башка теләк туар —
һәм ул Җирдә иң бөек бизәк булыр!..

## Пакьләнү

Кулны-битне су белән юып була...
Ә күңелне — туфрак белән дә...

Туфрак сабан төрәнен чиста тота,
ә төрән җирне генә түгел,
күңелне дә сөрә,
җирне генә түгел,
күңелне дә яңа чәчүләргә әзерли...

Туфрак кагылган барлык нәрсә пакь:
ашлык, һәрбер агач,
йорт нигезе, аяк табаны, гөл тамыры...
Була кайчак — күңел пычрана,
кан тончыга,
җанга сулыш алу кыенлаша...
Һәм шулчак кеше ак мендәрләргә түгел,
сөйгәненең җылы күкрәгенә түгел,
хәтта әнисенең рәхимле кочагына да түгел,
ә туфракка капланып елый,
үзен-үзе битәрли,
каргый, тәүбә итә —
пакьләнә!..

«Кардай ак, сөттәй пакь...» — дибез.
Бәлки
«Сөттәй ак, туфрактай пакь...» — дип әйтсәк,
дөресрәк булыр?..

# УЛ — АВГУСТ ЙОЛДЫЗЛАРЫННАН

(БӨЕК ИСПАН ШАГЫЙРЕ Ф. Г. ЛОРКАНЫҢ ҺӘЛАК БУЛУЫНА 50 ЕЛ)

Август. Кемгә ничектер, бу ай минем күңелгә ел саен моңсу сагыш алып килә. Ничәмәничә еллар инде шушы тойгыдан арынып булмый... Август — сагыш...

...Август. 1936 елның 19 августы. Франко палачлары — фалангистлар испан шагыйре Федерико Гарсиа Лорканы атып үтерәләр. Шагыйрьгә нибары 38 яшь...

...Август. 1943 елның 8 августы. Немец фашист палачлары чех язучысы Юлиус Фучикны җәзалап үтерәләр. Язучыга нибары 40 яшь...

...Август. 1944 елның 25 августы. Немец фашист палачлары татар шагыйре Муса Җәлилнең башын кисәләр. Шагыйрьгә нибары 38 яшь...

...Август. 1945 елның августы. Хиросима белән Нагасаки һәлакәте...

Быелгы августта прогрессив кешелек дөньясы бөек испан шагыйре Федерико Гарсиа Лорканың һәлак булуына 50 ел тулу көнен билгеләп уза.

Әле 1921 елда ук үзенең бер шигырендә Гарсиа Лорка аңлашылмас бер алдан күрүчәнлек-әүлиялек белән болай дип яза: «Алтын пычак йөзе. Август. Егерме алтысы...» Шагыйрь берничә көнгә генә ялгышкан: аны атаклы Гранададан сигез чакрымдагы Виснар авылы тирәсендә 19 августта атып үтерәләр. Лорка белән бергә тагын өч кеше атыла. Аларны Айнадамар чишмәсе янындагы карт зәйтүн агачы төбенә җирлиләр. Шагыйрьнең «Кистеләр өч агачны» шигыре хәтердә янара:

Өчәү үсә иде.
(Балталы кон килде.)
Икәү генә калды.
(Агач канатлары күләгәне ярды.)
Калды берәү бары...
Берсе дә калмады.
(Шәрә чишмә яры.)

«Иң хәсрәтле шатлык — шагыйрь булу» — моны бары Лорка гына әйтә алган.

Лорка әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителмәгән диярлек. Шагыйрьнең образлар системасы, шигъри күзаллавы гаҗәеп үзенчәлекле, гаҗәп катлаулы. Лорка — тәрҗемәгә «буйсынмый» торган шагыйрьләрдән.

1929 елның җәендә Гарсиа Лорка Америка Кушма Штатларына бара. Бу сәяхәт көтелмәгәндә генә була. Ул шагыйрьнең һәм рухи, һәм иҗади кризис кичергән вакытына туры килә. Америкада Лорка 1930 елның мартына кадәр яши. Ләкин ул Американы кабул итә алмый.

Җырларның нәфис сабагы
шәфкатьсез киселгән монда,
агачларның тере суты
үле каучукка әйләнгән.

«Негрлар сәнгатен исәпкә алмаганда, Кушма Штатларда механика белән автоматизмнан башка бер нәрсә дә юк», — дип яза ул. Лорка Америкадан Кубага китә, тик анда да җанына урын таба алмый, янадан Испаниягә әйләнеп кайта.

Әлеге сәяхәт нәтиҗәсендә Гарсиа Лорка ике пьеса һәм «Шагыйрь Нью-Йоркта» дигән шигырьләр китабы яза. Бу җыентыгын ул бик тәфсилләп, кайта-кайта эшли, төрле кичәләрдә укый. 1935 елның августында (янә август!) Лорка бу китабын бастырып чыгарырга әзерли. Әмма китап чыкмый кала. Ул бары тик 1940 елда гына Мексикада басылып чыга.

Укучыларыбызга шул китаптан бер шигырьне татар теленә тәрҗемәдә тәкъдим итәбез.

# Федерико Гарсиа Лорка,

испан шагыйре.

## Үлем биюе

*Өрәк! Карагызчы — өрәк!*
*Өрәк оча Африка ярларыннан*
*Нью-Йорк кварталларына!*

* * *

Нәни ак фосфор бөреле
борыч агачлары кайда?
Арган гәүдәле дөяләр,
аккош томшыклары тишкән
якты нур — дулкыннар кайда?

Карагыз, һәр нәрсә кипкән:
башаклар сукыр, җанварлар
изелеп-сытылып беткән,
күпер тимерләре тутык,
тирә-юньдә җансыз тынлык.

Карагыз, үле җанварлар
бары бергә җыелганнар —
гиппопотам аяк сузган,
тояклары күренә көлдән,

кыр кәҗәсе авызында
кычыткан ефәге үскән —
мескеннәрнең барысын да
үткен көн яктысы тишкән.

Ташландык, сулган тынлыкта
сытылган өрәкләр бии.
Артта — ярты дөнья комы,
алда — калган ярты дөнья,
кургашын дөнья, кояшсыз,
каннар ага теркөмештәй.

*Өрәк! Карагызчы — өрәк!*
*Чүлләр комы*
*крокодилның иләмсез авыз-упкыны*
*йотудан куркынган өрәк,*
*курку оча Нью-Йорк өсләрендә!*

* * *

Буш, җансыз күкне акшарлап,
известька катырган тынлык,
плантация кырларында
үлгән коллар тавышы тик,
битараф, буш, чип-чиста күк,
чәчәкләр эреп җуелган
аның еракларында.

Җырларның нәфис сабагы
шәфкатьсез киселгән монда,
агачларның тере суты
үле каучукка әйләнгән,

яктылыкның көзгеләрен
чәлпәрәмә вата-вата,
соңгы тыныч йолдызларны
җил себерә койрык болгап.

Салкын диварлар буенда
ялангачлар елаганда,
банк директоры үзе,
телсез-өнсез тиен-сумның
үлчәп миһербансызлыгын,
манометрга бакканда,
өрәк инде Уолл-стритка.

Үзенә биергә урын —
соры күзле крематорий
сайлап алган икән үлем —
моның бер дә гаҗәбе юк.
Сфинкс, я тимер сейф
ач сабыйларның йөрәген
бер төсле өшетә ала.

Машина энергиясе
табигать энергиясен
миһербансыз таптый монда,
һәр икесе яралганны
кояш нурыннан гына тик —
бөтенләй белми дә үзе.

Әгәр дә көпчәк онытса
механизм икәнлеген,
ат тояклары янында
рәхәтләнеп җырлар иде;
әгәр ялкын эретә алса
проектларның салкын бозын,
тәрәзләрнең җанлы-тере,
нурлы, матур балкышыннан
качып китәр иде буш Күк.

Ышандырып әйтә алам,
үзенә биер урынны
үлем яхшы сайлап алган.
Өрәк биер ургып аккан
кан ташкыны уртасында,
алтын бураннар эчендә,
саннар сафы арасында,
айсыз төннәрдә илергән
эшкезләр ыңгырашында.

Кыргый, явыз Америка,
карлы чикләргә җәелгән
оятсыз Америка син!

*Өрәк! Карагызчы — өрәк!*
*Пычрак сазлык дулкыннары*
*шуыша Нью-Йорк өстендә!*

* * *

Мин балконда басып торам,
Ай белән сугышам үзем.
Төн йөзенә теш батыра
көтү-көтү тәрәзәләр.

Бозау-болытлар күземнең
нурларын суырып эчә.
Бродвейның кан каплаган
пыяла витриналарын
озын ишкәкле җил кыйный.
Айның коры ботагында
сулган алма чәчәгедәй
кан тамчысы кибеп каткан,
көтүчеләр үзәннәрдән
җилләр куып китергәннәр,
изелгән медуза булып,
калтыранып үлә җилләр.

Үлем биюен биюче,
юк, мәетләр түгел һич тә.
Юк, ышанмыйм. Алар ята
тырнак кимереп, тыныч кына.
Үлем-өрәк уйный торган
скрипканың тавышына
бии монда гел башкалар.
Ул башкалар — салкын затлар,
көмештән исергән алар,
шәрә аяк кисешеннән
һәм чәнечкеле утлардан
үсеп чыккан затлар алар,
баскыч панорамасыннан
корт чүпләүче затлар алар,
үлгән кызларның күз яшен
банкаларда эчә алар,
алтын ватып, ватыкларын
почмакларда ашый алар.

Җитте, Папа, биемә син!
Җитте, Король, биемә син!
Җитте дим, биемәгез сез,
зәңгәр теш — миллионерлар,
чиркәү чаңнарына басып,
биемәсен балерина,
асылташлар җыючылар,
акылсызлар, гаугачылар,
җитте дим, биемәгез сез!

Сезнең белән бии бары,
бии бары карт бер өрәк,
канланган, сәләмә өрәк,
бары, бары, бары өрәк!

Белеп калыгыз әмма сез,
котсыз небоскребларның
иң соңгы этажларында
кобра еланнар ысылдар,
урамнарда, балконнарда
шайтан таяклары үсәр,
кычыткannар тирбәлерләр,
мүк капланган таш өеме
булып калыр сезнең биржа,
мылтык утына уралып,
лианалар үрмәләрләр,
үрелеп-урап буар алар
бик тиздән, әйе, бел, тиздән —
о, Уолл-стрит!

*Өрәк! Карагызчы — өрәк!*
*Агулы үлән агуын түкерә ул*
*Нью-Йоркның йөзенә!*
*Шәһәрнең котсыз йөзенә!*

**Марс ШАБАЕВ** кереш сүзе һәм тәрҗемәсе.

## Салисә Гәрәева

# УРАЛ ҖИЛЕ

### Полетаево станциясен узганда

...Поезд чаба Чиләбегә.
Тирә-якта яшел урман.
— Полетаево кайда соң —
Шагыйребез төшә торган?

...Җилә поезд. Тукай бара
Уйлар уйлап, оеп кына.
Авыру шагыйрь. Гамьле гомер...
Йөзе, күзе боек кына...

Селкетә дә тирбәтә юл
Поезд барган бер уңайга...
Хәтер китә еракларга —
Пугач, Канкай һәм Юлайга.

Таныш Җаек далалары
Хәтеренә килеп керә.
Ике корыч елан кебек
Юл йөгерә, юл йөгерә...

Арыган һәм томаннарда,
Яңгырларда туңган тәне —
Урын сорый, йокы сорый
Тәненең һәр күзәнәге...

Оеп китә Габдуллабыз,
Сизми поезд туктаганны.
Кемнең кемдә ни эше бар? —
Уятмыйлар йоклаганны.

Тора поезд Полетайда,
Пассажирлар йөгерешә...
— Тукай юк! — ди аны көткән.—
Юк бит Тукай, бу ни эш, ә?!

Берничәсе вагоннарга
Кереп китә, гаҗиз булып.
Бер вагонда Габдуллабыз
Черем итә онытылып.

Җилкәсенә башын салган.
Ике кулы — җиңнәрендә:
Җылы эзли үги бала
Газиз туган илләрендә...

Уяталар мосафирны,
Эндәшәләр әкрен генә:
— Сез ошыйсыз Тукаевка —
Олы шагыйрь әфәндегә?..

Рәхим итеп, тарантаска
Утырыгыз, чыгып, әйдә:
Йомшак печән салган арба —
Атлар көтә безне, бәйдә...

Күрешәләр ике куллап,
Кыенсынып, сабыр гына.
...Җылы җилләр кагылгандай
Була халык шагыйренә...

Юлга чыга Троицкига
Авыру шагыйрь һәм дуслары.
Каршы ала Габдулланы
Кояш, Җил һәм май кошлары...

Келтер - келтер җилә атлар.
Алда — дала, алда — кымыз.
Сихәтләнер шагыйребез —
Әйдә, атлар, юыртыгыз!..

Саф һавалы дала җиле
Җылы тынын ягып ала.
Ат хуҗасы атын куа —
Дилбегәсен кагып ала...

Алда дала. Бияләрнең
Яшь үләнне кырган җире.
Дус мулланың Тукай өчен
Киез тирмә корган җире...

---

**...ЛИСӘ ГӘРӘЕВА** — *«Уралым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Чиләбедә яши.*

Озаймасмы бераз гомер,
Жылынмасмы туңган жаны...
Ашыгырга кирәк аңа —
Күпме эшләр көтә аны!..

Дала, дала! Урал җиле!
Шифалы бул җырчыбызга!
Таң чыкларын, кояш нурын
Кош моңнарын куш кымызга!..

## Таш палатка

*Магнитогорскида, шәһәргә һәм металлургия комбинатына нигез салган беренче төзүчеләргә һәйкәл итеп, таш палатка куелган. Итәгенә Урал шагыйре Борис Ручьев шигырьләреташтан уелган.*

Башым иеп ялгыз басып торам,
Таш палатка, синең алдыңда.
Магнитканың утлы шәүләсеннән
Горизонтлар кичен ал монда.

Гүя сулый шәһәр минем алда:
Мартеннардан төтен, пар чыга.
Урам почмагыннан Борис Ручьев
Килеп чыгар кебек каршыга...

Таш урамнан бүген аермачык
Тойдым кичтә шагыйрь килгәнен;
Һәм ишеттем чибәр Любаваның[1]
Чая Любаваның көлгәнен...

Металл пешә мартен мичләрендә.
Күккә ашкан горур станнар.
Алар минем халкым җанына да
Горурлык һәм ялкын кушканнар.

Таш палатка тора Магниткада,
Канат җәеп дала җилендә.
Эшләп, янып, гөрләп без яшибез
Борынгы, чал Урал җирендә!..

*

Очрашулар,
Сөйләшүләр монда үзгә:
Сүзен әйтә кеше
Туры карап күзгә.
Кыса кулны
Сөялләнгән учы белән —
Кавышкандай
Иң яраткан дусы белән.
Кыерсытмас
Юкка сине җирдә беркем,
Үз эченә алса әгәр эшче төркем.
Шулай була,
Сынасалар сине эштә —
Ихлас булсаң
Эш һәм сүз сыналган төштә.—
Шунда гына
Була сиңа иң зур бәя
(Уйлама, дип:
Бөтен Урал кочак җәя!)...

Монда халык
Мактауга һәм сүзгә саран,
Тик шушында
Төзәлде күп күңел ярам...
Учыма куй
Сөялләнгән учларыңны,—
Урал гизеп,
Эштә сына дусларыңны!..

---

[1] Любава — шагыйрьнең шул исемдәге поэмасының төп героинясы.

## Балам

Үзем туганчы ук, сабый булганчы ук
йөрәгемдә, җылы тәнемдә
кан тамчысы булып яшәгән ул —
тамырларга килеп бәрелгән...

Нур сеңгесе булып керфегемнән
зур дөньяга карап көлгән ул.
Вакыт җиткәч, пешкән алма кебек,
җиргә киләчәген белгән ул.

Моңнарымны, кайгы-хәсрәтемне,
шатлыгымны эчкән туйганчы...
Йөрәгемнең бөтен мәхәббәтен
алган, минем кулга кунганчы.

Нәселемнең бөтен билгеләрен,
тамгаларын җыйган үзенә.
Инде туган, үскән. Тере бәхет
булып карый минем күземә.

Кабатлый ул минем көнелемне...
Тик бәхетле булсын язмышы:
афәтләргә, канлы сугышларга
юлыкмасын гомер агышы!..

## Сулар ага

Сулар ага, тансык сулар ага,—
болганчыгы ага, тонызы...
Сокландыра чишмәләрнең моңы,
урман, күлләренең тынлыгы...

Тылсым тулы таллы ярга басып,
тыңладым мин сүзсез елганы:
Ул аңлады минем сагышымны,
тыңлап ләззәтләндем мин аны...

Нигә сүзләр?! Олы табигатьнең
балалары сөйли бер телдә!
Без — елганың, елга безнең җанны
аңламый дип әйтмәс беркем дә!..

Кайда да су ага чылтыр-чылтыр,
үз мохите, җыры, яры бар.
Һәм кайда да күзләр агымсуга
йөрәк моңын кушып карыйлар...

Үткән гомер, түгелгән яшь, хәтер,
үкенүләр моңы, уйлану...
Ни сәбәпле йөгерек агымсулар
уйлануга охшаш булган ул?!

Яр башында торам: сулар ага...
бөтерелеп, уйнап су ага.
Моңга серләр, сагышка җыр ялгап,
карый кеше агымсуларга...

●

Кызыл таллык суга кулын тыккан,
зәңгәр шәлен юа тын гына.
Җил уйнамый яшел яфракларда —
яшьлегемнән килгән моң гына...

Елга, елга, син эчкерсез, гади,
бормалысын юлның сайлыйсың,
Ач син миңа болын иркенлеген,
сукмакларның якты, айлысын.

Язмышымнан яңа үрләр көтәм,—
күкрәгемә ургып һаман кер!
Синең кебек миңа юлдаш булсын,
сердәш булсын газиз туган җир!

Алып китим киртләч сукмакларга
тынычлыкны синең, көчеңне!
Һәм дусым бул: илт син киләчәккә
минем җырны, минем исемне!..

## Мәгъсум Хуҗин

# ТӨП НИГЕЗ

хикәя

*— Төп нигезне бетерәбезмени, улым?*



Мирза ишекне тартып карады, ябылып беткән икән. Әмма аның таптанып торуын сизмәделәр ахрысы, тавыш бирүче булмады. «Өйдә юклармы әллә»,— дип уйлады Мирза. Парланган күзлеген сөртеп киде. Өйдәләр икән. Шәйдулла агасы түрне иңләгән сәкегә түшәкне тәгәрәтеп кенә җибәргән дә шуңа чумып ята әнә. Мирза тамак кырды.

— Ә-ә, синмени,— диде Шәйдулла, борылып карамыйча гына.

— Мин әле.

— Җиңгәң дип торам. Шуңа күрә йоклаган булып ята идем. Хатын-кыз белән туймый да соң. Чыгып киткәненә кайчан, һаман кайтмый, онытты дөньясын. Белем дигәндә, картаеп беткәч тә аруны белми хатын-кыз.

— Җегәрендә чакта йөрсен. Башкаларның хәлен белешә бит ул.

— Шулаймы? Анысы бар, хәер.

— Күз бәйләнер чак житкәнче, сезгә тагын кереп карыйм әле дидем.— Мирза тунын салып, чөйгә элде.

— Бүтән эшең юк ахры синең, Мирзаҗан, безгә ничә тапкыр кергәнеңне санамасаң. Хәер, хисапка күнеккән кеше бит әле син. Әмма ки сиңа ишек тәүлек буена ачык. Хәл белергә керүеңдер ич...

— Бу юлы үз хәлемне белдерергә әле.

— Ул-бу юктыр ич? — Шәйдулла урыныннан ашыгып торды.

— Юк та, бар да дигәндәй.— Мирза, аякларын ишек катындагы паластан алмыйча гына, мич буендагы эскәмиягә утырды.

— Монда уз. — Шәйдулла сәке йөзлеге буйлап җәелгән бизәкле киезгә күрсәтте.

— Итекне салып тормаска иде.

— Һе, әйтерсең, моңарчы сала идең инде! Салма, кем салырга куша сиңа. Янгыр явып, тышта җир лыжырдамагандыр ич.

— Яуган ди, сезгә кереп житкәнче дә салкын битне чеметеп алды.

— Анысы булыр. Безнең җыерчыклы битләр чеметергә үтә дә җайлы бит аннары, Мирзаҗан күрше.— Шәйдулла кече якта газ плитәсенә чәй кайнатырга куйды.— Чәй дигән кодрәт иясе хәзер җылытып җибәрер үзеңне.

— Чәй генә җылыта алмастыр.

Шәйдулла күршесенә сынап карады.

— Ни булды соң сиңа? Иртәнчәк язгы кояш сыман елмаеп тора идең, шул арада сөмсерең коелган.

— Шәйдулла ага, ни...— Мирзаҗан капылт тукталды.

— Әйт соң.

— Картайдым мин...

— Күрегезче, Мирзаҗан картайган, вәйт экәмәт! — дип кәткелдәде Шәйдулла.— Минем күрше Мирзаҗан картайган, экәмәт

— Исемне матур итеп тутырып әйтәсең син, Шәйдулла ага.
— Миңа ни сан ди син үзеңне картка исәп кылгач? Шуны уйла башта. Сиңа ничә яшь әле?
— Житмеш сигезенче.
— Унсигезенче диген. Шулай дисәң, ышанырмын.
— Анысына инде алтмыш ел узган. Кимендә.
— Яшь кимләп-артыклап саналмый. Бик белеп тор син моны, энем. Тукай әйткәндәй.
Мирза алга шуышкан күзлеген этәрде, болай да сыланып яткан ак чәчләрен сыпырды.
— Картлык басты.
— Һаман иске авыздан яңа сүз. Житәрме соң бер үк нәрсәне тәкелдәргә! Балалар кебек, ачуым да килмәгәе!
— Иртәнге якта сездән чыккач, мин дә синең кебек түшәккә таянып торган идем,— дип тезде Мирза.— Черемгә китеп алганмын. Шунда төш күрдем. Газизә чакыра икән. Кил, ди...
Газизә Мирзаның хатыны иде, былтыр көз жирләде ул аны. Каты һәм озак авырды Газизәсе, коры сөяккә калды, кызы Факиһәнең беләгеннән чытырдатып кыскан килеш өзелде. Факиһә әнисенең өчесен һәм жидесен уздыргач кына китте. Шәһәрдә тора ул, үз гаиләсе ишле. Мирза япа-ялгыз хәзер. Кызы-кияве атна саен алмашлап кайталар, оныклары — олы малай һәм тагын ике игезәк малай кышкы каникуллары буена монда булдылар, әмма Мирзага ялгызлыгын оныттырырга болар гына житми шул. Һәм ул күрше Шәйдуллаларга еш керергә гадәтләнде. Ике карт бер-берсен аңлыйлар, хәер, алар электән үк уртак тел табалар иде.
Шәйдулла тугызынчы дистәсен тутыра, хәйран нык әлегә, каралтыкурасын үзе карап тота, мал-туарны бетерми, печән-утын әзерләгәндә, бәрәңге утыртканда-казыганда, оныклары һәм оныкларының балалары булыша. Бүтән эшләрне карчыгы белән майтара торалар, хастага төшеп, урын өстенә калмауларына сөенәләр.

...Мирзага Шәйдулла тагын озаклап карап торды. Күршесенең хәле мөшкеллеген күрде ул — олыгайгач тиз авыша кеше, әмма моны үзенә сиздерергә ярамый — өлкән кешенең күңеле тиз кителүчән.
— Син, Мирзаҗан, дәһри кеше ләбаса, ә үзең ырым-шырымга ышанасың икән. Укымышлы зат ич син, инде мин, гыйлемсез адәм, төш юрасам, бераз килешер дә иде.— Шәйдулланың ачулануына кул селтәде Мирза, ләкин аның бу киреләнүен күршесе ошатмады.— Картайган имеш! Мин картаймыйммы? Барыннан да битәр, чирләп китмә син. Менә шул. Әйдә, чәй кайнады. Син яраткан сәйлүн чәе пешердем. Җиңгәңне көтмәбез. Алданмыйдыр әле ул, замана карчыгы, үзе дә бик тәмләп чәй эчәдер. Салып торма аягыңнан, кирәк газап дисең ич. Зарлануны белми торган идең, ярты көндә үзгәрдең дә куйдың, ходайның хикмәте.
— Мин хәзер дә зарланмыйм. Шулай да искәртмичә ярамый.
— Искәртерлек ни булган?
— Булмаган. Буласы. Белеп торам.
Чәйнең тәме югалды, берәр касә эчкәч, Шәйдулла табын ризыгын тастымал белән каплады. Мирзаның тирән уйга чумуы аны хафаланырга мәжбүр итте. Күңел күзе дөм сукыр булмаган кешегә Мирзаның көзге кырау төшкән чәчәктәй тиз сулуын күрмичә мөмкин түгел иде.
— Явыз чир эләккән дисәм дә инде...— дип аптырашта калуын яшермәде Шәйдулла.— Ни арада эзләп тапсын ди инде ул сине, әле күптән түгел генә язгы кояш булып балкыган кешене...
— Хәзер дә балкыйм! — диде Мирза, көчәнеп елмаеп.— Сиңа үтенечләрем бар...
— Әйт соң.
— Мунча ягыйк әле. Беренче үтенечем шул. Бүтәннәрен соңрак әйтермен, әлегә вакыты килеп үк җитмәгән.
— Тышта зәмһәрир салкыны, дисең үзең. Мунчага тиз генә жылы төшәрме икән соң мондый көндә? Аннары, Мирзаҗан, минем олы малай-

лар берсәкөнгә яга, җиңгәң дә шунда булышып йөри, бүгеннән үк җылы бирмәкчеләр. Түз бер көнгә. Беренче кызуына керерсең. Урам аша гына, еракка йөрисе түгел. Теләсәң, арканны чабармын.

— Рәхмәт. Тик мин,— дип каршы төште Мирза бу тәкъдимгә,— үз мунчабызда чабынасы иттем. Бергә керербез, анысы. Ялгызым гына шикләндерә. Хәл бетеп китмәгәе.

— Алла бәндәсе, ягабыз соң! Ниткән сүз булырга мөмкин ди! — Шәйдулла өстенә үк киенә башлады.— Хәзер үк җылы бирик.

Мирза, тунын төймәләп, эскәмиядән тире бияләйләрен алып киде. Шәйдулланың әзер булуын көтте. Күршесенең ярдәм итәргә тиз ризалашуына аның күңеле булды.

— Илткән утын җитәрлек, су ташырга бәләкәй чанага бидон бәйләдем. Ягыйк әле мич тимерләре кызарып чыкканчы! Караңгы төшкәнче суын да ташып өлгерербез шәт, Шәйдулла ага, әйеме.

— Өлгерербез! Ярдәмгә берәр оныкны да алып чыгармын, барыбер олы малайга кермичә булмый, җиңгәңә әйтергә кирәк, кая качкан бу картлач, дип борчуга төшмәгәе.

— Балаларның сабак әзерлиселәре бар, аларга дәшеп тормыйк, суны икәүләп кенә ташыйк. Аннары... аннары мунчага су да кертмәслек үк хәлсез түгел әле мин...

Мунчага җылы биргәндә, алар, дөрләп янган мич авызы каршына утырып, тагын әңгәмә кордылар. Мирзаның Шәйдулланы үз яныннан җибәрәсе килми иде. Мичне томалагач, күршесен өенә чакырды ул. Саклана килгән сый-нигъмәтләр белән өстәлне тутырды хуҗа. Алар, чәй эчкәч, диванга таянып ял иттеләр, чәй яңарттылар, тагын диванга күчкәнче Мирза, кием шкафы эчендәге кечкенә чемоданны актарып, калын дәфтәр алды.

— Аягыңнан өеңдә дә салмыйсың син, Мирзаҗан. Салып җибәр, аякларың рәхәтләнеп китәр.

— Иртән киенгән килеш йөрим инде шулай,— диде Мирза, итек башларын бер-берсенә каккалап.— Сызлыйлар, салкынгамы шунда, алай дисәм, көне дә сындырды инде бераз. Мунча кергәч, тәннең сызлавы басыла минем. Шуңа исәп тотып якмакчы булдым мунчаны. Хәер, парланыпчабынып кына бетмәс тә инде бетүен сызлавы. Бу юлы, дип әйтәм.— Ул, иелеп, уң аяк йөзенең уртасыннан бармагы белән сызып күрсәтте.— Монысын шушы төшеннән өздe, ә сул аякның бармакларын гына кыеп алды. Сугыш дигәнең артык күрде минем аяк башларын...

— Алай... Үзеңә бикләнгән кешe дә түгелсең, нигә соң аны моңарчы яшердең?

— Гариплекне качырып торып буламы соң?! Ни яшерергә тырышсам да, атлаган саен алга иелеп куюдан барыбер сизелгәндер...

Шәйдулла Мирзаның аяк очларын тоткалап карады, анда тән булмавын тойса да, ышанып бетмичә:

— Исән кебек ләбаса болар,— дип куйды.

— Мамык тутырып үстерәм мин аякларны. Протез көйли алмадылар.

— Мирзаҗан, ә ничек бии идең соң... гарип аякларың белән? — дип, тагын гаҗәпләнде Шәйдулла.— Мөгаллим булып килгән елны сабан туенда иллә дә егетләрчә биегән идең!

— Шатлык зур иде ул чакта, Шәйдулла ага! Шул басты авырту әрнүләрне.— Мирза, аягүрә торып, аякларын алмашлап селкеткәләде.— Менә хәзер биеп булмый. Сәбәбе картлыкта гына түгел.— Ул, баскан саен алга иелеп атлап, мич каршына барды, учактагы күмерләрне кыскыч белән өйгәләде дә төтен юлын кысты.— Шатлыгыбыз зур иде безнең Газизә белән ул чакта! Шатланмыйча соң, үзең уйлап кара, гомерең буена оя кормас кошлар кебек йөре-йөре дә менә шушында, кешеләре әйбәт авылга килеп урнаш әле син! Туган җиребезгә кайтып төпләнгән кебек булдык бит без. Кызыбыз Фәкыйһә дә шул сөенечкә сөенеч өстәп үсә иде. Их, Шәйдулла ага, тормышның катлаулылыгын сиңа аңлатып торасы юк ләбаса, үзең миннән күбрәк яшәгән

— Яшәвен яшәгән, әмма ни дөнья күргән соң мин? Бар белгәнем — туган авылымда тәгәрәп үсү дә, гражданнар сугышында ат атланып чабулар, соңгы сугыш михнәтләре- шулар белән бетте дә китте.

— Авыл тормышы да мең катлам. Менә син, гади генә итеп, авыл дисең, сугыш дисең. Төшләреңә бер дә кермиме шул сугыш, шул михнәт чигүләр?

— Кермәгән кая! Сугыш аждаһа булып буарга җыенганда, саташып кычкырып уянган төннәрем күп. Әллә гомер буена да онытылмаячак инде бу газаплар...

— Безнең гомер кыйссабыз онытылмаячак. Анысы хак.— Мирза, кулларына таянып, Шәйдуллага борыла төште.— Күр әле, сабан туенда минем биегәнне хәтерлисең икән, ә?

— Хәтерләмичә соң! Хәтер капчыгы тишекле-тошыклы түгел лә минем!

— Җырлаган идем дә әле мин шул сабан туенда, туган җирем итеп күргән авылга кайтып урнашу шатлыгыннан җырлаган идем...

— Җырың уртасында,— дип бүлдерде Шәйдулла Мирзаны көйләргә җыенуыннан,— каршыңа төз адымнары белән Газизәң килеп басты да парлап җырлап бетердегез.

— Газизә белән мин генә белгән җыр иде ул. Шуны берәү дә ишләптер отып алмады. Ә отуларын теләгән идек без. Әллә безнең җырга ваемсыз булды кешеләр, әллә сабан туенда яңгыраган бүтән җырлардан аермасын сизмәделәр шунда. Хәер, чит-ят кешеләр, әле генә килгән кешеләр җырлаган җырның йөрәк түренә үк үтмәве дә мөмкин, һәр йөрәкнең үз җыры, дигәндәй. Инде менә бөтенләйгә алып китәм Газизә белән икебезнең җырны...

— Тагын кирле-мырлы сөйләшә башладың бит, Мирзаҗан! Җитәрме сиңа, юкмы, телеңне чатнама суыкта корт чаккыры!

— Ачуланма, Шәйдулла ага. Газраил якаңа ябышкач, әйтәсе сүзләр күбәя икән. Шулай. Гәүдәмне югач, сабан туенда биеп-җырлап алган сөлгегә сөртә күр, яме. Тотылмаган ул.

— Менә син, ә, тыңламас җан булдың, тәмамысы! Иш соң, әйдә, иш тавыңны. Әллә бераз тамак чылаттыңмы соң син, Мирзаҗан күрше?

— Шулай дигән бул. Ачулан. Үпкәләмим. Синең урыныңда мин дә күңел күтәрергә, дәртләндерергә, хушлашуны белгесез вакытка кичектерергә тырышыр идем. Ләкин барыбер кешенең соңгы гозерләрен тыңламыйча ярамый. Үзеңә авырлык алып булса да, тыңларга кирәк.

— Тыңлыйм ич инде, Мирзаҗан. Тик тавышны артык ургылдырып ишмә. Үзең беләсең, биек таудан тәгәрәп төшкән кырлы ташны тотып, туктатырга минем дә көч җитмәве ихтимал. Менә бит, ә, иртән якты дөньяга изге теләк белән уянасың, кечкә тормыш дигәнең үзенчә хәл кылып куя. Тыңлыйм, Мирзаҗан, тыңлыйм.

Мирза диван башындагы дәфтәрне алды, күзлеген маңгаена күтәреп, дәфтәрне битләп актарды, кайбер төшләрендә бармагын йөртеп, ашыкмыйча гына эчтән укыды. Шәйдулла тын гына утырды, кирәксез сүз әйтеп, Мирзаның күңелендә җәелгән яраны зурайтып җибәрүдән сакланды.

— Шулай,— диде Мирза, дәфтәрен ябып.— Шулай,— дип кабатлады тагын.— Тормышка ашмаган бер теләгем кала...

— Нинди? — дип акрын гына искәртте бераздан Шәйдулла. Хәзер Шәйдулла гадәтенчә житез сөйләшми, тавышы базыкланган иде.— Ярдәмем тиярлек түгелме?

— Хикәя язмакчы идем мин.

— Әкият димәкче буласыңмы?

— Түгел! — дип җанланып китте Мирза.— Әкият уйлап чыгарылган җан нәләре турында була бит ул. Ә бу — хикәя! Дөньяда булган хәлләр турында.

— Язасың калган соң! Син укымышлы кеше, заманында мөгаллим-

нәрнең үзләренә дә мөгаллим булгансың. Әйбәт укытучы килде, дип, бала-чага тәмамысы мөкиббән булды үзенә.— Мактау сүзләре Мирзаның күңелен күтәреп җибәргәндәй тоелды Шәйдуллага.— Язасың калган! Язарга кирәк тә иде. Күпне күргән Мирзаҗан лабаса син.

— Белем бар да, тик мин математик шул, балаларга исәп-хисап өйрәттем, әдәбият гыйлеме түгел.

— Кызың Факиһәгә әйтеп торып яздырасы иден. Язу дигәндә аңарга куш инде, аның язган хатларын без дә тыңлап рәхәтләнәбез. Газизә мәрхүмә дә, Факиһәдән хат алуга, шуны безгә кереп укыр иде. Факиһә кызың булдыра андый шөгыльне. Яза торган бармакларына былбыл кунган диярсең.

— Факиһә?!.— дип сискәнде Мирза, йокысыннан җилтерәтеп уятылган кешедәй.— Факиһә... Юк, Факиһәгә әйтеп яздырырга ярамый, аңа бигрәк тә сөйләп торып яздырып булмый.

— Минем оныкларның берәрсеннән яздыр соң, кайсы да карышмас. Үзең нигә язмаска ди тагын, кулың каләм тота, күзең аера, фикерең җете, гыйлемең җитеп ашкан. Минем генә мәдрәсә сабагы ярты юлда өзелеп калды, ары укып булмады.

Мирза дәфтәрне тагын кулына алды, алгы битен ачты.

— Яза алмауның сәбәбе бүтән. Кушу-алу җөмлә төзүгә караганда күп җиңел минем өчен. Ә язып булмый. Булмады язып. Теләкне, үти алмадым. Көчемнән килмәде.

— Бу кадәресен үзең беләсең, хәер. Сиңа ярдәмем тиярдәй түгел язу шөгылендә. Киңәшләрем исә әйткәннәремнән узмый.

— Шәйдулла ага, беләсеңме, һәркемнең тормышы турында кемендә бер хикәя язылырга тиеш бит. Бу хикәяне ул үзе кәгазьгә төшермәсә, аның хакында башка берәү язарга бурычлы.

— Әкәмәт икән,— диде Шәйдулла, уенга алырга исәпләп.— Минем тормыш кына бернинди хикәялек тормый алайса. Яза калсалар да, кызыклы чыкмас ул, килер буыннарга риваять булып калмас. Туксан ел буе авыл сукмагы таптауның хикмәтен кем табар икән. Йөзгә җиткәч, авыз тутырып әйтерлек бер хикәят булыр иде, бәлки.

— Синең йөрүең гел авыл сукмагыннан гына түгел. Гражданнар сугышы, фин сугышы, соңгысы.

— Әй, шул өч сугышка туксан еллык гомернең җиде елы күп түгел нич инде. Аннары бу сугышларда искитмәле батырлык кылмаган ла мин. Качып та йөрмәдем, монысы да хак. Тагын ки шунысы, Мирзаҗан энем, сугыш газаплары бер минем башка гына түгел, бөтен ил өстенә афәт булып төште бит. Димәк ки, кинолык тормый минем тормыш. Йөзнең теге ягына чыгып бассам гына инде! Һәм шуңарчы нәкъ менә минем тормышымда бер-бер галәмәт хәл булса гына инде! Тик кая инде ул миңа йөзгә җитүләр!

— Җитәсең йөзгә, Шәйдулла ага!

— Амин сүзеңә. Мәгәр яз хикәяңне. Синнән матур риваять калсын.

— Мин аны язып карадым, ләкин төзек чыкмады. Укып күрсәтимме? Кайбер төшләрен генә. Югыйсә, озынга китте лә ул, сузылды, дәфтәр тулды.

— Укып җибәр, әйдә. Кеше укыганны тыңларга яратканымны беләсең. Укы.

...Кояш офыктан аерылды. Салмак күтәрелә ул. Күтәрелгән саен көләчләнә, күккә ашу сөенеченнән игелек нурларын һаман мулрак чәчә.

Идел төнге томаннан ачыла бара. Су өстен сабый җил сыпырып уза да бөке-калкавыч шадра дулкыннарда алпан-тилпән чайкалырга тотына.

Ярда бер малай белән бер кыз шул тәтәлкәне балык батыруын көтеп утыралар. Алар бер-берсенә елышкан, киемнәре юка, икесе дә яланаяк. Кыз аякларын күлмәк итәге белән капламакчы була, тик туңудан күгәргән тәпиләре барыбер күренеп кала. Малай чебиләгән аякларын

бөкләгән. Беләүләнгән бушлат астына икесе бергә сыйганнар, әмма бушлатның, зур булса да, төймәләргә изүе җитми. Туңалар, кояш аларны җылытып җиткермәгән әле.

— Тизрәк кояш кыздырсын иде,— ди кыз.

— Туңма инде,— дип юата малай, бушлатны кызга шудырып. Үзенең уң җилкәсе бөтенләй ачык кала. Хәер, малайга, балык чиртсә, кармак сабына үрелергә болай җайлырак та бит.— Кояш көйдерер дә әле ул, балык чиртсен иде, диген син.

— Әнә, чиртә!

— Балык түгел, дулкын уйната тәтәлкәне. Тегәрҗебе юанрак булды, шуны күреп капмый балыклар. Кармак ясарга да нечкәрәк тимер чыбыкка бара алмадым. Бүген барам да, табам да мин аны! Шәһәр артындагы чүплектә дөнья андый чыбыклар! Кичә барырга вакыт кына тимәде.

— Балыкны тоткач ничек пешерербез?

— Һи, эләксен генә, анысын гына белербез! Учак сүнмәгән, чыбык-чабык өстибез дә ыслап кына алабыз.

— Тамак ачты...

— Хәзер икебез дә ашап туярлык балык эләгә, зурысы. Түз, бәбәй булма.

— Мин учакка ягарга чыбыклар җыя торам, яме.

Кыз, яр буйлап йөгерә-йөгерә, чыбыклар җыйды. Җылынды ул. Инде кояш та хәйран кыздыра башлаган иде. Хәзер аларга зур балык эләгәчәк, икесенең дә тамагы туярлык...

Мирза шушы урында кинәт туктады, тавыш-тын бирмичә тыңлап утыручы Шәйдуллага карады, хикәясенең эчтәлеге өлкән күршесенә аңлашылып җиту-җитмәвен белергә теләде.

— Алай,— диде Шәйдулла, сузып кына. Сырлы кара түбәтәе өстеннән генә башын кашып алды. Аның шул хәрәкәтеннән һәм бер сүзеннән абайлады Мирза — вакыйганы төшенә, димәк, Шәйдулла агасы.

— Шулай.

Алар, күп еллар якын күршеләр буларак аралашып, берсен-берсе шушы сүзләрдән дә аңлашалар иде.

— Ятимнәр икән болар. Ләкин ки малай белән кызның исемнәрен атамагансың.

— Ул чакта исемнәре белән эндәшмиләр әле аларга, кушамат белән генә йөртәләр аларны. Революция кузгалганчы ук булган хәл бу. Исемнәрне аларга соңрак кушалар. Дөресендә, малай кызга, кыз малайга исем куша.

— Алай... Бу заманнар сиңа да эләгеп калган шул. Тагын укы.

Мирза дәфтәренең бернечә битен актарып кына узды.

— Малай белән кыз, үзләре хәреф танымасалар да, гәзит сатып йөриләр, эшләп ашыйлар ягъни,— дип, укылачак вакыйгага кереш ясауны кирәк тапты Мирза.— Инде революция булган, ә тартышу-көрәшүнең каты кызган көннәре.

...Малай белән кыз, култыкларына төргәкләр кыстырып, уң кулларында газеталар җилфердәтеп, олы урам буйлап йөгерәләр.

— Яңа сан чыкты! Гәҗитнең яңа саны! — дип кычкыра малай.

— Яңа гәҗит! — дип кушыла кыз.

— Хөрриятне саклыйк!

— Хөррият...— дип кабатлый да тукталып кала кыз.— Ә хөррият нәрсә?

— Шуны да белмисең! Кешенең үзен иркен тотуы, бәхете, байларга хезмәт итмәве дигәнне аңлата хөррият. Хөрриятне сак...

Пуля сызгыруы малайның сүзен бүлә. Кыз, аптырап, малайга карый. Малай күзләрен йомган, эчен тоткан, бармак араларыннан кан ага. Ул, бөгәрләнеп, җиргә егыла, авыртуга чыдый алмыйча ыңгыраша, урам ташын тырный.

Малайны лазаретка салалар. Кыз да аның белән керә. Бүтән якын

кешесе булмавын әйткәч, аңа малайны карауда булышырга рөхсәт итәләр. Пуля малайның, йөрәгеннән астарак күкрәгеннән кереп, эчке әгъзаларын артык имгәтмичә, арка кабыргасына терәлеп калган була. Кыз малай эченнән пуляны алган докторга гомере буе рәхмәт укып яши, аның белән беренче сөйләшүен кат-кат исенә төшерә.

— Исеме ничек аның, малайның?

— Карурман...

— Исеме ничек дим мин.

— Карурман.

— Ә синең исемең?

— Әллүки.

— Кызык икән сез! Аңа ничә яшь?

— Яшь? Белмим...

— Ә син ничә яшьтә? Үз яшеңне беләсеңдер ич.

— Яшь? Белмим дим ич. Без аның белән Иделдә балык тоттык җәй көне.

— Аннары ниләр эшләдегез?

— Эшли идек, гәҗит сата идек. Хөрриятне — кешеләрнең бәхетен явызлардан саклый идек.

— Абыйлы-сеңелле дисәң инде, охшашлык чалымнарыгыз юк, яшьләрегез дә бер чамадыр, унбер-унике яшьләр тирәседер. Яки тугызундыр да. Шулай да кемең соң бу малай?

— Белмим лә. Ә без үсеп җиткәч, ул минем ирем була. Абый, дим, Карурман тиз терелерме?

Доктор, кызның бу сүзләреннән соң башын бик озак чайкап утырган да:

— Савыгыр, ләкин тиз түгел,— дип кызның башыннан сөйгән.— Савыктырырбыз...

— Алай,— дип сузды тагын Шәйдулла, Мирза укуыннан туктагач.— Алай. Бу малай белән кызның тормышы китап язарлык риваять итеп калдырылган икән шул. Революция карынында яралган булып чыга болар икесе дә. Аннары ниләр булган инде?

— Аннары... Үсеп җиткәч, чыннан да өйләнешәләр. Белем алалар, сугышта булалар. Урта Азиягә барып эшлиләр дә, туган якларына кайтып, рәхәт гомер итәләр. Балалары була... балалары... оныкларын сөеп үстерәләр.

Мирза караватка мендәр салды. Чалкан ятып, күкрәген уды, Шәйдулла китергән касәдән чәй йотты.

— Хәл китеп алды,— диде ул, тирән сулап.— Зыянсыз, узар әле. Шәйдулла эндәшмәде.

— Васыятемне дәфтәрнең соңгы битенә яздым.— Факиһәнең олы малае быел институт бетерә, агроном булып чыга. Ул монда кайтып яшәр. Төп нигезне бетерергә ярамый, шуны ныклап әйткән идем үзләренә. Газизә белән бергәләп әйткән идек. Риза булдылар. Яшьләрне ярдәмеңнән ташлама. Хәер, нигә монысын искәртеп торам соң әле? Ышанам мин сиңа, Шәйдулла ага, ышанам...

Мирзалар кырык сигезенче елда килделәр авылга. Урта Азиядә институтта укыткан булганнар, тик гел авыл җирен сагынып яшәгәннәр. Баштарак безнең телгә чит сүзләр дә катнаштырып сөйлиләр иде, тиз оныттылар тагын аларны. Йорт-җир җиткерергә, төпләнергә ниятләгәч, аларга урынны Шәйдулланың зур бакчасы башыннан кисеп бирделәр, арткы бер яклы урамны ике яклы итеп сала башлаганнар иде инде ул чакта. Мирза моңа Шәйдулланың үзеннән рөхсәт сорады, карышу-үпкәләү булмады, яңа күршесе йорт җиткергәндә, Шәйдулла үзе дә башыннан ахырынача булышты. Тату, ярдәмчел күршеләр булып утыз биш ел гомер иттеләр.

...Бу кичтә Шәйдулла Мирза янында утырды. Карчыгы белән олы малае да иптәшкә монда керделәр.

Тышта аяз. Төн уза.

Инде моржа башларыннан төтеннәр күтәрелә. Ә Мирза мунчасы жылы биргән килеш калды, юыныр-чабыныр өчен таңнан торып ягылмады.

Мирзаның гәүдәсен Шәйдулла юды.

...Күрәсен күргән икән бу тән, хәтта артыгын да, дип уйлады Шәйдулла, Мирзаның күкрәгендәге һәм аркасындагы яра җөйләрен сыпыргалады. Карурман... Син «Кара урман»ны, Газизәң «Әллүки»не базар чатларында җырлап тамак туйдырган җаннар булгансыз икән сез... Беренче кушылган исемең ничек иде икән синең, мәрхүмкәй. Яшең күпме булды икән?

Туган җиреңне дә белмәгәнсең икән син, ятим. Ә соңгы көнеңәчә зарланмадың, язгы кояш сыман елмаеп туймый идең. Исемеңне тутырып эндәшкәнне яраттың, яшеңне үзгәртмәдең. Кичә яшең турында да сәер сүзләр әйткән идең. Лазарет докторы биргән яшь белән йөргәнсездер сез, мөгаен генә. Шулайдыр. Бәлки, пенсиягә алданрак та китә алгансыңдыр. Ә үзең пенсиягә бөтенләй чыкмадың.

Төп нигезеңне авылыбызда кордың. Авылыбызны туган җирең итеп күрдең...

Син кичергән хәлләрне бер генә дәфтәргә язып сыйдырырлык түгел икән шул. Синең гомереңнең кай сәгате дә кыйссалык торган икән...

Моннан соң сине дә төшләремдә күрергә язсын. Керерсең төшләремә, боерган булса... Синең гомерең кыйссасын белергә тиеш ич инде мин. Ярый ла син аны дәфтәреңә тулырак язган булсаң. Һе, әллә синең өчен мин язып бетерергә тиеш буламмы?.. Алай... Анысы, язмышларда охшашлык бар инде, ил өстенә килгән авырлыкларны үз җилкәбезгә алып салу кадәресендә охшашлык бар... Кыйсса язарга миңа васыятең итеп... укыдың алайса дәфтәреңне, Мирзаҗан, васыятең итеп...

Иртә киттең, Мирзаҗан, иртә... Җырыңны отып кала алмадык. Отып кала белмәдек Газизә белән синең җырны... Җырыгыз сүзләрен кичә сорарга акыл җитмәде, ә. Дәфтәреңә язган булсаң, бәхет кенә дә бит. Менә син, ә, кичә сине җырлаткан булсам соң мин?! Җырлыйсың килгәндер дә, мин үтенгәнне көттеңме икән? Әллә, Газизәңнән башка — Әллүкиеңнән башка, ялгызың гына җырламас идеңме?..

# Мөхәррәм Каюмов

## Канатлар

Кыр казлары!.. Тегермәнче кисә,
Очып китмәсен дип, канатларын.
Ак канатлар — киемнәре кебек
Яуда әсир төшкән солдатларның.
Канатсыз каз — читлектәге киек,
Кешеләрнең азмы канатсызы?!
Өметләре сүнгән шәм шикелле,
Еллар озын алда, гомер озын...
Кыр казларын зәңгәр күк чакыра.
Август күге әнә нинди биек!
Канатлары, бәлки, күк читенә
Алыр иде әле тиеп-тиеп.
Каңгылдаша казлар, канатсыз да
Күтәрелеп очып китәр кебек.
Күкрәк белән күкне ярыр өчен
Бер омтылыш бары житәр кебек...
Ә канатлар җирдә яңа юнган
Йомычкадай ята кочак-кочак...
Ничек ташка әверелми куллар,
Ничек кулдан төшеп сынмый пычак?

*

Бабамнар ул алда... Һаман юлда —
Ишетелә аяк тавышы.
Алар байрак йөрткән кайнар еллар
Гасырларга таба авышты...

Әткәмнәр ул алда... Утка керә.
Ишетелә йөрәк кагышы.
Үлемсезлек алган елларының
Киләчәккә таба агышы...

...Ә бездән соң дөнья нинди булыр?
Үзгәрмәсме җирдә шатлык, моң?
Арттан килүчеләр ишетерме
Шулай безнең аяк тавышын?..

Шулай безнең йөрәк кагышын?

---

МӨХӘРРӘМ КАЮМОВ (1941) — *яшь шагыйрь, шигырьләре журналда берничә тапкыр дөнья күрде. Казанда яши.*

## Йөк

Сынды күчәр. Сынды. Дүрт тәгәрмәч
Сазга бата — авыр үгезгә.
Печән йөге җиргә сеңә бара
Кораб баткан кебек диңгездә.
Булса булыр унбиш адым гына,—
Ләкин менә ничек үтәргә?
Әткәм йөкне Алып батыр сыман
Көчле иңе белән күтәрә.
Чүкте кинәт. Солдат, яраланса,
Бөгәрләнә шулай — кинода...
Борыныннан, күрәм, кан ага...
Шунда миңа чынлап әйттеме ул,
Әллә инде ялгыш ишеттем:
— Улым, улым! Дөнья сиңа кала,
Кулларымнан минем эш китте...

Куасы юк — киерелеп тарта.
Күкрәк белән. Вакыт — үгезем.
Йолдызлыклар буйлап Җир-арбада,
Әйтерсең лә барам бер үзем.
Тәгәрмәчләр тигез тәгәрәми,
Юлы такыр түгел заманның.
Сазлыклары аша бер уздырса,
Бер йоттыра кайнар тузанын...
Шул арбада миллион язмыш җебе
Бер төенгә бергә төйнәлгән.
Ләкин аңа яшел печән түгел,
Мичкә-мичкә дары төялгән.
Барган саен, йөгем авырая,
Афәт җитә соңгы сызыкка.
Очмасмы соң Җирем-яшел арбам
Чиксезлеккә — төпсез сазлыкка?
...Әй кешелек! Бөек Тылсым көчең
Күрсәт әле, күрсәт әйдә бер:
Шушы дарыларның һәр бөртеген
Шатлык орлыгына әйләндер?! —
Һәрберсеннән чәчәк шытып чыксын...

## Саннар

Саннар төрле-төрле бит ул,
Җөпләре бар, таклары бар.
Зурлары бар, ваклары бар,
Ялганнары, хаклары бар.
Бакчадагы чәчәкләрдәй
Саннар әллә ничә төстә:
Каралары — күпме язмыш
Дахауларда янган мичтә.
Кызыллары — Ил-ананың
Туган елы, туган көне.
Шул заманның ялкыннары
Яктырта бит бүгенгене...
Съезд документларын мин
Ләззәтләнеп укыйм кат-кат.

Саннар, саннар! Миллионнарның
Өметедәй якты, ап-ак.
Ул саннарда — Сәйдәш моңы,
Сабыйларның шат авазы.
Җир яшьлеге, ил яшьлеге,
Кешелекнең яңа язы.
Саннар гади, саннар гадел,
Бар булмаган алар юктан.
Партиянең йөрәгеннән,
Зиһененнән кайнап чыккан.
Анда — безнең омтылышлар,
Ышаныч һәм ныклы терәк.
Илләр таңы имин булыр,—
Фәкать шундый саннар кирәк!..

## Иске тегермән

Шаулап акмый елга элеккечә,
Сәер кебек шуңа, ят сыман.
Яр башында торган тегермән — бер
Эшкә яраксыз карт ат сыман...
Замананың авыр чакларында
Кайнаштылар монда атлылар.
«Уфалла»лы толлар кайгыларын
Шушы тегермәндә тарттылар.
Мөшкәләрдән ап-ак шатлык акты,
Күз яшьләре эчкә йотылды.
Тою белән яңа икмәк исен,
Дөнья авырлыгы онытылды.
Яр астында күпме учак янды,
Чиләкләрдә умач кайнады.
Кайнар умач шундый тәмле иде,—
Үзебез туйдык — күзләр туймады...
Ә тегермән уйга баткан төсле,
Нидер эзли кебек сулардан.
Әйтерсең лә аның матур чагы
Менә шунда төшеп югалган.

❁

Чатта торам... Өч тар сукмак алда.
Нигә кинәт җанда көч сүнде?
Өч тар сукмак... Гүя йөрәгемә
Төзәгәннәр шулай өч сөңге.
Сиңа барам көмеш сөңге буйлап,
Үткән еллар тарта чабудан.
Баскан саен, сөңгем тирбәлә дә,
Ирексездән кинәт абынам.
Сөнге буйлап барам... Циркач шулай
Аренага чыга канатта.
Бергә үттек гомер мизгелен без
Канат буйлап түгел, пар атта.
Тынмаган җиз кыңгыраулар чыңы,—
(Менә шуны тыңлап киләмен.)
Ак бураннар һаман элеккечә
Җәя алда ап-ак келәмен...

Сиңа барам көмеш сөңге буйлап,
Сезнең якта шундый җылылык!
Мәхәббәтең саклый алган булсаң,
Мин бу юлда калмам егылып...

.................

*КПССның XXVII съезды карарларын — тормышка!*

## Марсель Зарипов

# МӘҢГЕ ЯШЕЛ АГАЧ ҖИМЕШЕ

Тормышта һәрнәрсә үзара бәйләнештә. Бабалары утыртып калдырган бакчаны уллар, оныклар үстереп җиткерәләр. Башлап җибәрүчеләрнең хыялын алдагы буыннар тормышка ашыра.

Бина каршында кечкенә генә бакча. Анда — Сергей Миронович Киров һәйкәле. С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институты. Бормалы коридоры буйлап барсаң, синтетик каучук кафедрасына килеп чыгасың... Тукта, сүзне ниндидер бәйләнешләрдән башлаган идек бит, монда нинди бәйләнеш бар дисезме? Бар шул. Революциягә кадәр бу бинага урнашкан реаль училищеда Уржум шәһәреннән килгән үсмер Сережа Костриков укыган. Соңрак Ленинград коммунистлары җитәкчесе булып өлгергән Сергей Миронович Киров шул үзе инде. Костриков-Киров тропиклар иркәсе — каучукны Россия кебек кырыс табигатьле илдә дә, гомумән, җир шарының теләсә кайсы почмагында да ясарга мөмкин икәнлеген һәм бу шөгыльнең искиткеч әһәмиятен аңлаган, шул өлкәдә эзләнүче галимнәргә җитди ярдәм күрсәткән.

Социализм төзүче совет халкы гаҗәеп кыюлык белән элекке Россия хыяллана да алмаган эшкә тотынды. Заводлар корылды, җимерелгән промыселларга, шахталарга яңадан җан керде, геологлар руда, күмер, минерал ятмалары эзләүне дәвам иттерделәр. Ихтыяҗлар күп иде, акча гына җитенкерәмәде. Дөресен әйтергә кирәк, шул акча җитмәү сәбәпле кайбер эзләнүләр инде тәмамланыр алдыннан туктатылып тордылар. Бәхет кошы инде кулда дигәндә генә... Унөч мең — хәзерге заман өчен бик аз, ә ул чорда бик зур байлык. Дөньякүләм әһәмияткә ия булган ачышның язмышы шуңа бәйле булган. Һәм ул акча Кировның шәхси күрсәтмәсе буенча бирелгән. Инде харап булды дигәндә, эш яңа көч, яңа дәрт белән дәвам ителеп, егерменче гасырның иң зур фәнни-техник уңышларыннан берсе белән тәмамланган. 1932 елда Ярославльдә дөньяда беренче синтетик каучук заводы эшли башлады. Бер елдан Ефремов шәһәрендә конвейер сафка басты, соңрак Воронеж, Казан заводлары эшкә тотындылар. Илебезнең материаль хәле бик авыр заман өчен зур фидакарьлек иде бу.

Казан химия-технология институтының синтетик каучук кафедрасы — беренче заводларның яшьтәше. Алга куелган бурыч ул вакытта ук ачык иде — ясалма каучук җитештерү өчен белгечләр хәзерләү, эшне фәнни яктан тәэмин итү.

Хәзер инде синтетик каучукның күп төрләре бар. Бу өлкәдә тагын нәрсә эзлиләр? Нигә хаҗәт? дигән сораулар да бик табигый кебек.

Казан химия-технология институты ректоры, СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты Петр Анатольевич Кирпичников һәм кафедраның профессоры, химия фәннәре докторы Александр Григорьевич Лиакумович белән әңгәмә нәкъ шундый сораудан башланды да. «Нигә кирәк?»

Ачыш никадәр әһәмиятле, яңа тәгълимат никадәр ышанычлы булса, аңа карата ихтыяҗ да күбрәк. Атом-төш физикасы барлыкка килүгә сәбәп булган, беренче тапкыр Беккерель күзәткән радиоактив нур, Петровның эретеп ябыштыруга нигез салган электр дугасы органик химиянең күп тармакларына башлангыч булган Бутлеров теориясе белән дә нәкъ шундый хәл. Мәңге яшел фән агачының каучук дип аталган ботагында инде йөзләрчә яңа үрентеләр бар. Көн саен башка бөреләр ачыла тора. Табигый каучук бер генә төрле, ә ясалма каучукка төрледән-төрле сыйфатлар

---

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ (1931) — *рус телендә язучы прозаик, очеркист. «Ордер на квартиру», «Чужой медовой месяц», «Мәңгелек шәһәр» кебек повесть һәм очерк китаплары авторы. Татарстанның атказанган культура работнигы, Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты. «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе. Казанда яши.*

иңдерергә була. Кайбер төр каучукларга нефть тә сыланмый, иң көчле кислоталар да тәэсир итми, температураның бик нык үзгәрүенә дә түзәләр. Мисал итеп шуны алыйк. Самолет очкан биеклектә салкынлык 40 градус чамасы, җиргә төшкәндә, аның резина көпчәкләре дүрт йөз градуска кадәр кызалар. Һәр үзенчәлекне алдан планлаштырып куярга туры килә, кайбер кушылмаларның бик аз микъдары гына да бер үк материалга капма-каршы сыйфатлар бирергә мөмкин.

— Моңа ничек ирешергә соң?

— Табигать белән идарә итүнең бөтен кыенлыгы да шунда инде. Безгә таш кебек каты каучуклар да кирәк, пәрәвез җепләре кебек сузылучан сыйфатлысы да. Бу мәсьәләләр белән зур институтлар шөгыльләнәләр. С. В. Лебедев исемендәге Бөтенсоюз синтетик каучук институты эзләнүләренең төп юнәлеше — катализаторлар һәм эреткечләр булса, Ярославль синтезкаучук мономерлары институтында исә яңа төр чимал табуны максат итеп куйдылар. Шин ясаучыларның, машина төзүчеләрнең, кибернетикларның, физикларның да үз бурычлары бар: табигатьтә әзер хәлдә булмаган яңа материаллар ачарга тырышалар. Фән һәм техниканың, медицина һәм биологиянең, авыл хуҗалыгының үсеше бездән шуны таләп итә.

— Каучук — каучукның көндәше булып чыгамы?

— Хезмәттәше дисәк, дөресрәк булыр, кеше табигатькә ярдәм итә бит. Мәсьәлә гаять катлаулы, күпьеллык хезмәт нәтиҗәсе булган һәр ачыш үзе яңа бурычлар тудыра. Табигать — чиксез.

Синтетик каучук кафедрасы галимнәренең фәнни хезмәт мәйданы — яңа каучуклар. Күп ачышлар ясалган, әмма хәл итәсе эшләр арта гына бара.

Институт ректоры, кафедра мөдире Петр Анатольевич Кирпичников каучуклар белән, беренче дүрт завод эшли башлагач, кызыксынучан акыл ияләре өчен бәхетле чорда мавыгып киткән. Институтны тәмамлаганнан соң заводка эшкә килгән. Башта — мастер, соңрак цех начальнигы булып эшләгән. Шул ук чорда, төп хезмәте белән бергә институтта ассистент вазифаларын да алып барган. Әйтүе кыен, кайсы омтылыш өстенлек алган булыр иде икән. Инженерлыкмы, әллә фәнни хезмәтме. Сугыш аның бөтен планнарын үзгәртә. Кирпичников кандидатлык диссертациясен диплом алганнан соң егерме ел узгач, 1956 елда гына яклый. Аннары — докторлык диссертациясе, член-корреспондент итеп сайлану. Сугышчан Кызыл Йолдыз орденына тыныч хезмәт өчен бирелгән Ленин ордены өстәлә. Үзенчәлекле, шул ук вакытта күпләргә хас биография.

1956 елда СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Алексей Андреевич Коротков җитәкчелек иткән лабораториядә халык хуҗалыгына бик күп күләмдә кирәкле изопрен каучук уйлап табылды. Инде лабораториядәге ачышны завод конвейерына күчерү мәсьәләсе туды. Галимнәр хезмәте завод конвейерларына барып җиткәч кенә чын ачыш булып санала башлый. Гомер гомергә акыл ияләренә мәдхия җырлыйлар, ә рәхмәт эшне башкарган оста куллыларга әйтелә. Күпме ачышлар завод конвейерларына барып җитә алмыйча онытылалар бит.

Лиакумовичның тормыш юлы башкачарак. 1962 елда ул башкала институтында лаборатория мөдире урынын калдырып, Урал ягына, Башкортстандагы Стәрлетамак шәһәренә китә, тәҗрибә заводында яңа процесс оештыра. Бу яңа эш аның гомерлек хезмәте булыр дигән уй башына да килмәгәндер. Сәгатенә бары тик бик аз гына каучук эшләп чыгаручы кечкенә генә заводның төп максаты — сынаулар үткәрү. Сыналган технология исә теләгән җирдә кулланылырлык булырга тиеш.

Төзүчеләр Стәрлетамакта, Тольяттида, Түбән Камада зур заводлар сала башлый. Заманча технология элеккечә спиртка түгел, нефть куллануга җайлана.

Фән белән шөгыльләнү кайда уңайлырак — башкаладамы, әллә төбәкләрдәме? Галим үзенең бәхет кошын кайда тизрәк тота ала? Бу турыда бәхәсләр инде бик күптәннән бара. Иң әһәмиятлесе кайда тотуда түгел бит, ничек тотуда. Казанышлар белән мактанып кына яшәргә була, шул ук вакытта әлегә кадәр тормышка ашырылмаган эшләр турында уйлап, борчылып йөрергә дә була.

Тормыш һәм фән, фән һәм тормыш — кеше эшчәнлегенең бер ягы кайда тәмамланып, икенчесе кайдан башлануын төгәл әйтеп бирү кыен. Өченче юл дөресрәктер: җитештерү өлкәсендә кыю, колачлы фәнни фикер йөртү, детальләрне гомумиләштерә белү мөһим булса, галимгә ачышының мөмкин кадәр тизрәк җимеш бирүенә ирешү кирәк.

КПССның XXVII съезды карарларында да моңа басым ясап: «Төп бурыч — фән һәм производствоның үзара бәйләнешен ныгыту, фән, техника һәм производствоны интеграцияләүнең, фәнни идеяләрнең тиз арада тормышка кулланылуын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган оештыру формаларын булдыру»,— диелгән.

Лиакумович Урал якларында алты ел эчендә фән кандидаты булуга ирешә, докторлык диссертациясен яклый. Соңрак ул дистәләгән химия заводлары булган

Татарстанга, әллә ничә төрле продукция житештерүче нефть химиясе гиганты шәһәре — Түбән Камага килә. Башта институтның Түбән Камадагы кичке факультетында эшли, аннары Казан химия-технология институты кафедрасына профессор булып күчә. Шул ук вакытта ул Түбән Кама химикларының фәнни консультанты вазифасын үтәвен дәвам итә. Синтетик каучукларның изопренлылары уйлап табылганнан соң узган чирек гасыр дәвамында профессор Лиакумович ирешкән иҗади уңышларга күз салыйк: аның житәкчелегендә ясалган йөз сиксән ачыш илгә илле миллион сум табыш китергән. Галим-миллионер! Намуслы хезмәт, мактауга лаеклы нәтиҗә!

Гомерендә бер мәртәбә яңа төр роза үстерүгә ирешкән, жирдән иген уңышы ала алган яки Арктиканың боз чүлләре аша бер тапкыр узган кешеләр бу төр мавыгуларын ташлый алмыйлар. Ә инде, атом һәм молекулалар дөньясыңа үтеп кереп, материянең күзгә күренмәс кисәкләрен үз теләгенә буйсындырган галимнең, яңа ачыш хакына башка нәрсәләрдән ваз кичүе һич гажәп түгел.

Синтетик каучук кафедрасы — институтның илле тугыз «күзәнәгенең» берсе. Анда иңгә-иң торып бер член-корреспондент, өч фәннәр докторы, утыздан артык кандидат һәм әле фәнни дәрәжә алырга өлгермәгән хезмәткәрләр, аспирантлар эшлиләр. Нинди зур акыл һәм белем байлыгы тупланган монда! Алар укыту, фәнни тикшеренүләр алып бару белән бергә мәсьәләләрне практик яктан тормышка ашыру белән дә якыннан торып кызыксыналар.

Профессор Л. А. Аверко-Антонович группасы тиокол каучуклар белән шөгыльләнә. Бу материаллар герметик булулары ягыннан кыйммәтле. Алар йортлар һәм күперләр салганда, автомобильләр, уенчыклар ясаганда, хәтта җәрәхәтләрне дәвалаганда да кулланыла.

Тикшерүләрнең икенче бер юнәлешен доцент Л. А. Зенитова җитәкли. Механик тәэсирләргә каршы тора алуы буенча цементтан, бетоннан, металлдан ныграк полиуретаннар бар. Алардан ышкылу көченә каршы торырга кирәкле башка материаллар чыдамаган очракларда файдаланалар.

Ут һәм нефть ярдәмендә дөньяга килгән синтетик каучук вакытны бик «авыр» кичерә. Һәрвакыт йомшак булсын өчен аны «картаюдан» сакларга кирәк. Профессор Н. А. Мукменова группасы, Стәрлетамак тәҗрибә заводында эшләүчеләр белән бергә, махсус стабилизатор ачкан. Аның ярдәмендә каучукны һәрвакыт яшь килеш сакларга мөмкин.

Унберенче бишьеллыкта галимнәр йөздән артык ачыш ясадылар. Производствода куллана башлау турында акт язылганнан соң гына авторлык таныклыгына лаек дип табылганнары да аз түгел.

Табигать серләрен үзләштерү юлында аерым этап булырдай ачышлар ясаган Сергей Васильевич Лебедев: «Каучук — чиксез төрлелек чыганагы ул...» — дигән иде. Бу сүзләр бүген каучук серләрен ачуда беренче юл салучыларның киләчәк буыннарга васыяте кебек яңгырыйлар.

* * *

1970 елда Түбән Камада беренче изопрен каучук заводы эшли башлады. Яңа завод дистәләрчә миллион сумга төште. Соңгы унбиш елда заводның куәте дүрт тапкырга артты.

Могҗизалар химиядә дә була алмый, тормыштагы һәр вакыйганы аңлаткан кебек үк монда да гаҗәпләнерлек урын юк. Бергә өчне кушкач, һәрвакыт дүрт була. Инде эшли башлаган завод янына тагын берсе артыннан берсен салып куясың да — җиңү турында рапорт бирергә мөмкин!

— Монысы — арифметика. Идарә итү өлкәсендә югары математика отышлырак,— дип аңлата Түбән Кама нефтехимикларының баш инженеры Алексей Павлович Ворожейкин. Ул елына миллиард сумлыктан артыграк продукция чыгаручы, заманча техника белән коралландырылган берничә зур завод белән идарә итә.

Беренче изопрен каучук заводында, беренче карашка, үзгәрешләр юк та кебек. Чынында исә, эшләүчеләр саны азайган. Җитештерелгән продукциянең күләме дүрт тапкыр дип әйтерлек арткан. Болар барысы да галимнәрнең пыяла савытларыннан килеп чыккан бит!

Мин аңлатып бирүләрен үтенәм:

— Ничек, заводларны пыяла савытларда эшләп буламы?

— Химиядә мөмкин,— диде Ворожейкин.— Химиклар табигать ялгышларын төзәтә алалар икән, нигә әле кеше мөмкинлекләрен дә арттыра алмаска тиешләр?

Беренче заводны сафка бастыру дистәләрчә миллион сумга төшкән иде. Хәзер шул производствоның гомуми куәтен дүрт тапкырга арттыру өчен, яңа заводлар салуга карагында, дүрт тапкыр кимрәк акча тотылган. Моңа ничек ирешелгән дисезме?

Станокта да, машинада да кайбер детальләр ышанычлырак, кайберләре «йомшаграк» булалар. Заводларда, гомумән, халык хуҗалыгының һәр тармагында да үсешне тоткарлаучы шундый урыннар бар. Берәүләр өчен, конвейер эшли башлау — җиңү турында рапорт бирергә сәбәп, башкалар моны яңа эзләнүләр башларга этәргеч итеп күрәләр. 1970 елда шинчылар Түбән Кама каучугыннан техника өчен «башмаклар» кия башладылар. Унбиш ай үтүгә, ягъни билгеләнгән сроктан ике тапкыр тизрәк, завод бөтен көченә эшли иде инде. Алдан исәпләнгәннәр барысы да расланды. Уңыш, җиңү, казаныш — бөтен бәяләр дөрес, төгәл!

Түбән Камадагы гаять зур нефтехимия комплексының изопрен каучук заводы илебездә беренчеләрдән иде. Аны салганда җитешсезлекләр, ялгышлар да булмады түгел. Тормыш үзе дә планнарга төзәтмәләр кертә тора. Уңыш бит ул үзе дә — һәрвакыт яңага, камилләштерүгә юл эзләү, галимнәрнең яңа ачышларын күзәтеп бара белү һәм тәвәккәлләү нәтиҗәсе. Үзгәрешләр ясамыйча, көн дә бер үк эшне кабатлап, тыныч яшәү, әлбәттә, җиңелрәк, тик барыбыз да башкаларга гына ышыкланып торсак, отышлы яңалыкларга кем юл ярыр?

Шул ук мәйданда акчаны дүрт мәртәбә кимрәк тотып, яңа продукция җитештерә башлау — агымдагы камилләштерүләр нәтиҗәсе, илебездә генә түгел, дөньякүләм әһәмиятле кырык ачыш җимеше.

Каучукның чималы йөзләрчә-меңнәрчә үзгәрешләргә дучар ителә. Иң әүвәл нефтькә ияреп чыгучы катлаулы газдан этан-пропанны аерып алалар. Аннары чималны изобутан һәм гади бутанга таркаталар. Янәшәдәге реакторда аппаратчылар изопентан һәм нормаль пентан белән маташалар. Пентан молекуласында бер углерод атомы «адашып йөри», аны кирәкле ноктасына урнаштырырга кирәк. Шушы эшне башкарып чыкканда гына безгә кирәкле изопентан барлыкка килә. Анысыннан изопрен-мономер алачакбыз. Аннан инде төп максат — каучукка да ерак калмый...

Бер җайланмада ялкын котырына, икенче бер урында колонналар кар кызы кебек акка төренгәннәр. Шушы ут, су, пар, катализатор һәм эреткечләр мәхшәре аша узганда матдәләрнең күзгә күренмәс кисәкчәләре — атомнар парлашалар, чылбыр, күпкырлыклар рәвешендә тоташалар яки, кеше ихтыярына буйсынып, таркалалар. Конвейердан агылып торган каучук брикетлары, әзер шиннар — әнә шул катлаулы хезмәт җимеше.

Әмма полимерлашу процессында аппаратлар арасындагы тоташтыргыч җайланмалар томалана. Менә бәла! Гадәттә нефтехимиклар, бу бәладән котылу өчен, җайланманы туктатып торалар, корым утырган торбаларны кыралар.

Түбән Камада исә аппаратларны эштән туктамыйча гына чистарталар, бу эшне махсус ингибаторлар башкара. Ингибаторларны С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институты галимнәре уйлап таптылар, ә нефтехимиклар эштә сынап карадылар. Җаваплылыктан курыкмыйча, тәвәккәлләп куллана башлаган иделәр, хәзер шул кыюлыкларының рәхәтен күрәләр. Отыш — биш миллион сум, тик хикмәт акчада гына да түгел. Хезмәтнең, үз көчеңнең, табигать каршылыгын буйсындыра алуның аерым бер ләззәте дә бар бит әле.

Унберенче бишьеллык Түбән Кама нефтехимиклары җитмештән артык ачышны эшкә җиктеләр. Экономия — йөз миллион сум чамасы. Уйлап табулар заман кагыйдәсе буенча сайлап алына: яңа фикер әлегә кадәр бер җирдә дә ишетелмәгән булырга тиеш. Бу шартның таләбе бик аңлашыла, мәсьәлә никадәр җитди, каршылыклы булса, осталыгыңны, гражданлык батырлыгыңны күрсәтү өчен мөмкинлекләр шулкадәр күбрәк.

Дивинил заводында окисьлаштыра торган дегидридлау кулланыла башлады. Аның идеясен Ярославль синтетик каучук мономерлары фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләре тәкъдим иттеләр, монтажчылар, аппаратчылар, инженерлар тормышка ашырдылар. Атамасы бик катлаулы, тик фән нәфис сүзләргә караганда фикер төгәллеген кулайрак күрә, ә эшнең асылы гади.

Дегидридлау — аерып алу процессы. Арадаш продукт бутилен дивинилга әверелсен өчен, аның молекуласыннан ике водород атомын аерып алырга кирәк, шуннан соң кирәкле ярымфабрикат-дивинил барлыкка килә. Дивинилдан каучукка кадәр ара бик якын, тик ничек үтәргә?!

Водород — гаять зур энергия чыганагы. Эш процессында аны һавага, атмосферага гына очыралар. Янәшәдә генә һавадан азот аерып алучы аппаратлардан күккә кислород чыгып тора. Водороды — ягулык, кислород ут өчен җан кебек кадерле нәрсә! Нигә бу көчтән нефтехимиядә дә файдаланмаска?!

Артык кислородны, аерып алынган водород белән кушып, күптонналы реакторның энергия чыганагына әверелдерәләр. Бу эшне тормышка ашыручыларның югары дәрәҗәдә һәм техник, һәм фәнни яктан белемле булулары кирәк. Түбән Кама нефтехимикларының үз араларында дистә ярымлап фән кандидаты бар, диссертация якларга әзерләнүчеләре дә җитәрлек. Шулай да нәтиҗәләрне әйтеп үтәргә кирәк.

Колонналарга кислород җибәрү җылылык файдалануны киметергә генә түгел, реакцияләрне тизләтергә дә мөмкинлек бирде, җайланмаларның куәте егерме процентка артты. Еллык файда — биш миллион сум. Тагын бер өстәмә аппарат көйләсәләр, кислород әле башка җайланмаларга да хезмәт күрсәтәчәк.

Менә шулай, Түбән Камада берсе артыннан берсен агрегатларны, тулы бер технология җайланмаларын яңадан үзгәртеп җыялар, яңа фәнни ачышларны озакка сузмыйча куллана башлыйлар. Нәтиҗәдә яңа заводлар салгандагыдай байлык туа.

Кешеләр тропик урман каучугына артык баш ими башлаганга ярты гасыр вакыт узды. Әмма ниндиен кулланырга дигәндә, һәрвакыт табигый каучукка өстенлек бирелә. Чит ил фирмалары да, шин ясаганда, катнашманың өчтән бер өлешенә табигый каучук кушалар.

Түбән Кама химиклары эшләп чыгарган каучукта почетлы сыйфат билгесе. Аппаратлар проектта күрсәтелгән график буенча эшли башлаган көннәрдә Түбән Камага куанычлы хәбәр килде: Ленинград галимнәре катализаторны түбән температурада әзерләргә тәкъдим итәләр. Утка каршы — салкынлык! Төп фикернең хуҗасы С. А. Будер ярты гомерен Түбән Камада уздыра, яңа ачышны практикада файдалануны оештыра.

Лабораториядәге эзләнү нәтиҗәләренең конвейерда расланмаган очраклары да аз түгел. Әгәр барып чыкмаса? Алдын-артын күп уйлаучылар көтәләр һәм оттыралар, азагы уңышлы булуына ышанучылар тәвәккәллиләр һәм оталар. Түбәнкамалылар институттан яңа процесс серләрен иң беренче булып соратып алдылар. Һәм ике елдан рәхәтләнеп яңа катализатор кулланып эшлиләр иде инде. Чыгымнар булмады түгел, булды, әмма эш тә җайга салынды, Түбән Кама нефтехимиясенең профессиональ горурлыгы артты.

К. Маркс: «экономик чорлар берсе икенчесеннән нәрсә җитештерелүе белән түгел, ә ничек, нинди хезмәт чаралары кулланып җитештерү белән аерылып торалар» — дип язган иде. Түбән Кама заводлары тозелә башлаган елларда компьютерлар куллану кагыйдәгә әверелмәгән иде әле. Идарә итү тулысынча автоматларга нигезләнде. Автомат тиз башкара, әмма компьютер тагын да тизрәк һәм төгәлрәк эшли.

Молекуланың бер генә бәйләнешкә керә алучан биш атомы өч төрле вариантта кушылырга мөмкин. Әгәр аларны боҗралар, өчпочмаклар, ромблар рәвешендә тоташтырсаң, вариантлар арта. Алты атом биш төрле тоташа ала, ун атом — җитмеш биш, унөчесе — сигез йөз төрле. Кыскасы, төрлечә эшләп карауның исәбе-хисабы юк, тик кыенлыклар да арта бара. Арадан иң отышлы нәтиҗәне табарга кирәк.

Иҗади дәрт белән, һәвәсләнеп эшләүче рәссам киндергә әкияттәгедәй сихри төсләр төшерә, скрипкачы үзе уйнаган музыканың һәр тавышын үзе сайлап уйный ала, сүзләр, иҗекләр сайлый-сайлый шагыйрь шигыренең камиллегенә ирешә.

Матдәнең күз белән күреп, кул белән тотып булмый торган кисәкчекләре кирәкле тәртиптә кушылсын өчен реактор янында үз вазифаларын үтәүче аппаратчылардан нинди төгәллек, осталык таләп ителә?! Кеше үзенең сиземләү көченә, зирәклегенә, осталыгына гына таянса, бу эшне башкарып чыга алмас иде.

Түбән Кама нефтехимия берләшмәсенең кибернетик үзәгендә егерме биш электрон хисаплау машинасы бар. Системаның техник өлешен академик Константинов исемендәге Ленинград атом-төш физикасы институты, СССР Фәннәр академиясенең аналитик приборлар төзү институты, Ленин орденлы шин промышленносте фәнни-тикшеренү институты галимнәре башкардылар, технология программаларын завод кибернетиклары төзеделәр.

Икенче изопрен каучук заводында мин баш инженер Равил Шияповтан дисплейны эшләтеп каравын үтендем. Экранда кызыл тамгалар, исем-фамилияләр йөгереп үтте. Биш секунд эчендә машина һәркемгә «гадел бәя» биреп чыкты. Программаларның берсе каучукка өстәлә торган кыйммәтле стабилизаторны «күзәтә». Тәүлетасма, барлык мәгълүматларны тиз генә тикшереп, заводта иң оста, иң сакчыл сменаның Валерий Назаров җитәкләгән смена булуы турында хәбәр итте:

— Чын хуҗаларча эшлиләр! — дип мактады Шияпов.— Башка сменаларда стабилизатор бер тонна продукциягә ике килограммга артыграк тотыла, болар янга калдыралар!

Түбән Кама нефтехимиклары тугызынчы бишьеллыкта продукция җитештерүне ун тапкырга арттырдылар, унынчы бишьеллык та күрсәткечләр тагын өч тапкырга артты, унберенче бишьеллыкта, алдагы биш елдагы белән чагыштырганда, бер миллиард сумлык продукция артыграк җитештерелде.

Коллектив байрагында илебезнең иң югары бүләге — Ленин ордены балкый. Бу зур хөрмәт — фидакарь хезмәт, иң мөһиме — нәтиҗәле хезмәт белән яулап алынды.

— Һәрнәрсәнең чиге булырга тиеш. Һәр производствоның да үсеш мөмкинлекләре билгеле бер вакытта файдаланылып бетә. Ул чакта нишләрсез?

— Ул көннәр турында уйларга иртәрәк әле,— дип җавап бирде минем сорауга Ворожейкин.— Мөмкин булганның барысын да эшләдек кебек, ә һәр яңа көн моңа кадәр башка да кермәгән яңа мөмкинлекләр алып килә. Тамгалы изотоплар җибәргән идек, беләсезме, ниләр ачыкланды?

— Ниләр?— Мин Ворожейкинның яңа могҗизалар турында сөйләвен көттем.

— Чынбарлыкта колонналарның өчтән бер өлешендә генә без теләгән процесслар бара икән, калган өчтән ике өлеше эшкә җигелмәгән булып чыга. Нишләргә? Сораулар бик күп, җаваплар азрак. Әмма төгәл куелган сорауларга җавап эзләү җиңелрәк. Кеше никадәр күп эш башкарса, шулкадәр күп мөмкинлекләр туа тора.

Николай Васильевич Гогольнең үлемсез әсәре буенча эшләнгән — «Үле җаннар» фильмын Үзәк телевидение күп мәртәбәләр күрсәтте. Анда шундый эпизод бар. Россиядәге губерна шәһәрләренең берсе. Алпавытлардан үле җаннар сатып алучы Павел Иванович Чичиков рессорлы арбада кунакханә ишегалдына кереп бара.

— Бу вакыйга шәһәрдә бернинди тавыш-гауга чыгармады,— дип башлый Гоголь әсәрен.— Ике мужик кына бер нәрсәгә игътибар иттеләр.

— Кара әле,— диде берсе,— нинди көпчәкләр, ә!

— Син ничек уйлыйсың, бу тәгәрмәчләр Мәскәүгә барып җиткәнче чыдарлар иде микән?

— Чыдарлар,— ди икенчесе.

— Минемчә, Казанга кадәр чыдамаслар кебек.

— Казанга кадәр чыдамаслар,— ди икенчесе.

Тарантаслар, арбалар авылларда гына калды. Бөтен кеше автобусларда, тиз йөрешле «Волга», «Запорожец», «Нива» һәм «Жигули»ларда йөри. ВАЗ конвейерында көн саен ике мең ярым җиңел машина җыялар. Бер тәүлек эчендә ике мең ярым җиңел машина! Тагын бер тәүлек — тагын ике мең ярым! Әмма машиналарга көпчәкләр дә кирәк. Запастагысы белән биш данә. Автомобиль гомеренә бер генә комплект җитми әле, ул аларны биш кат туздыра. Димәк, һәр машинага егерме биш камера, егерме биш покрышка кирәк. Тольятти автомобильләр заводы ел саен эшләп чыгарган җиде йөз мең машинаны егерме биш көпчәккә тапкырласак, егерме миллион килеп чыга. «Жигули» һәм «Нива»лар өчен генә шулкадәр «аяк киеме» кирәк. Әле бит «Запорожец»лар, «Москвич»лар, «Волга»лар, «УАЗ»лар да бар.

Илебездә ел саен бер миллион өч йөз мең җиңел машина эшләп чыгарыла, алга таба бу сан тагын да артачак. Машинаның байлык хикмәте генә түгел, хәрәкәтләр чарасы, файдалы, кирәк әйбер икәнен дә истә тотыйк. Һәр автомобиль ике дистә көпчәк туздырса, шулкадәр машинага «аяк киеме» ничек җиткермәк кирәк? Шиннар ясау өчен өч йөз миллион тонна чимал гына кирәк булачак, күпме көч, энергия, башка ресурслар сарыф ителәчәк. Ә нигә көпчәкләрне автомобиль гомеренә чыдарлык итеп ясамаска? Мәшәкать тә кимрәк булыр иде, дәүләт өчен дә файда?!

Мин шушы җитди сорауга җавап эзләп, Түбән Кама нефтехимиклары янына барган көннәрдә Ленин орденлы шин промышленносте фәнни-тикшеренү институтының каучуклар лабораториясе мөдире Людмила Владимировна Мәсәгутова да анда иде.

Түбән Кама нефтехимия комплексының баштагы вариантында шин заводлары төзү күздә тотылмаган иде, чимал буларак Татарстан нефть байлыкларын файдалануга исәпләнгән тиңдәшсез производствоның технологиясе каучуклар җитештерү белән тәмамланачак иде. Әмма вакыт үзе төзәтмәләр кертте. 1968 елда Түбән Камада промышленность мәйданының биш йөз гектарын беренче шин заводы төзелешенә бүлеп бирделәр. Алты елдан соң монда миллионынчы камера эшләнде. Бу нәтиҗә киләчәк хезмәт җиңүләренең беренче карлыгачы иде. Коллектив унберенче бишьеллыкны менә нинди уңыш белән тәмамлый: автомобиль, трактор һәм башка техника өчен миллионнарча көпчәк. Башка бер генә чит ил фирмасының да, илебездәге предприятиеләрнең дә мондый нәтиҗәгә ирешкәне юк иде әле. Киләчәктә илебездә эшләнгән шиннарның байтагы Түбән Каманыкы булачак.

Борын-борыннан ничә гасырлар буе җир эшкәртү, терлек үрчетү, бакча үстерү, урман кисү, җәнлек аулау, балык тоту белән генә шөгыльләнгән кешеләребез хәзер самолетлар һәм вертолетлар ясарга, сәгатьләр һәм электрон-хисаплау машиналары җыярга, җир куеныннан нефть чыгарырга һәм аннан кирәкле әйберләр эшләргә өйрәнде. Инде хәзер яңа һөнәр үзләштерде — шиннар ясый.

Вакыт ашыктыра, һәркемнең — Түбән Камада эшләүчеләрнең дә, алар белән элемтәдә торучы партнерларның да үз мәшәкатьләре бар. Түбән Камага Мәскәү, Ленинград, Казан, Ярославль, Киев, Баку, Куйбышев, Уфа кебек фән үзәкләреннән галимнәр килә.

Фәнни яктан тәэмин итүдә алтмышка якын фәнни-тикшеренү институты гына түгел, академик үзәкләр, Югары һәм махсус урта уку йортлары министрлыгы да катнаша. Бер көн эчендә без Түбән Камада СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы председателе, член-корреспондент Петр Анатольевич Кирпичников һәм Бе-

тенсоюз каучук институты директоры Алексей Павлович Никандров белән очраштык. Үз эшләре белән бу якларга Казан химия-технология институты профессоры Александр Григорьевич Лиакумович та килеп чыккан. С. В. Лебедев исемендәге Бөтенсоюз ясалма каучук институты өлкән фәнни хезмәткәре С. А. Будер химиклар шәһәрендә чираттагы бәхет кошын тоту уе белән йөри. 1983 елда химиклар Будерның бер ачышын кулланып дүрт миллион сум экономия ясаганнар. Саллы бит! Будерның Түбән Камада елга ничә көн булуын санап чыгардык — нәкъ алты ай җыела.

— Нормаль хәл,— ди Будер.— Кама буенда эшләүнең Нева проспектында эшләүдән берниндн аермасы юк. Институтта чәчкәннең уңышын монда килеп җыябыз.

Машина гомеренә чыдарлык көпчәк турында минем соравыма шин коючылар һәм Бөтенсоюз институты хезмәткәре Людмила Владимировна Мәсәгутова менә ничек җавап бирделәр.

— Иң элек машина йөртүчеләрне тынычландырыйк: җиңел машина көпчәкләре һәм Казанга, һәм Мәскәүгә, һәм Владивостокка кадәр барып җиткәнче түзәчәк, экватор буйлап әйләнергә дә җитәр. Нефть каучугыннан ясалган шиннар өч мең чакрымга чыдагач, ничек куануыбызны искә төшерик. Хәзергә шиннар кырык-илле мең километр юл узалар, тик безне бу да канәгатьләндерми.

Чыннан да, кичәгә рекорд бүген нормага, гомуми кагыйдәгә әверелә, көн узган саен казанышларыбыз да үсә, димәк, максатларыбыз да югарырак булырга тиеш.

Нигездә, мәңгелек көпчәк ясау кыен эш түгел, бүгенге көндә андый мөмкинлекләр бар. Әгәр шинны полиуретан каучуктан эшләсәң, машина тузып беткәч тә, көпчәк яңа кебек калачак. Тик эш шунда ки, мондый шин киертелгән машина беренче борылышта ук мәтәләчәк, гомумән, урыныннан кузгала алмаячак, чөнки полиуретанның башка өслекләргә ябышу үзенчәлеге бик түбән. Мәсьәләнең шул ягын хәл итәсе бар.

Шин кытлыгын бетерүнең беренче юлы — аны мул иттереп җитештерү яхшы бара, ә менә чыдамлыгын арттыру мәсьәләсе авыррак. Автомобиль шины — металл дискка киертелгән резина кисәге генә түгел, шактый катлаулы нәрсә ул, сыгылмалы көпчәктә бөек Менделеев таблицасының шактый өлеше тупланган. Көпчәк озак вакыт хезмәт итсен өчен аның бөтен детальләре дөрес хәл ителгән булырга тиеш. Өстәвенә, эксплуатация шартларын, һава хәлен, эшнең зурлыгын да истә тотарга кирәк. Тиз оча торган самолет көпчәкләренә тәэсир итүче көч белән вертолет көпчәкләренә туры килгән көч арасында аерма бик зур. Яки Арктика белән субтропик тирәлекләрне алыйк. Төньяк салкынында бер төрле резина пыяла кебек уалырга мөмкин. Көньякта — эрүе ихтимал. Шуңа күрә каучук, резина катнашмаларына махсус өстәмәләр кертәләр, шиннарның кояш, җил, яңгыр тәэсиренә каршы тору сыйфатын үзгәртәләр.

КПССның XXVII съездында расланган «1986—1990 елларга һәм 2000 елга кадәрге чорга СССРның экономик үсешенең төп юнәлешләре»ндә дә бу турыда: «Металл җепләр куллануга нигезләнгән радиаль конструкцияле шиннар, зур һәм үтә зур габаритлы шиннар эшләп чыгаруны киңәйтергә»,— диелә.

Мондый шиннар элеккеләр белән чагыштырганда бер ярым тапкыр артык юл уза алачаклар.

Әмма шин гомерен озайтуның иң ышанычлы алымы материалның, беренче чиратта, каучукның сыйфатын яхшыртуга бәйле. Шинчылар химиклардан кыйммәтле сыйфатларга ия булган каучук көтәләр. Кыскасы, алда — катлаулы, кызыклы эш.

Хәзергә кадәр эталон буларак табигый каучук алына, чит илләрдә эшләнгән шиннарда ул утыз-кырык процент тәшкил итә. Безнең халык хуҗалыгыбыз мондый «бәхет» турында хыяллана алмый, тропиклар «күчтәнәче» өчен алтын белән түләргә кирәк, шуңа күрә партиябезнең XXVII съезды химия промышленносте алдына яңа бурычлар куйды: «1990 елда... синтетик каучуклар эшләп чыгаруны 2,7—2,9 миллион тоннага җиткерергә... Заманча конструкцион пластик массалар һәм полимер материаллар җитештерүне тизләтеп үстерергә...»

Химикларга теләкләр күп әле: шинчыларга әлегә махсус реагентлар аз килә, аларны чит илләрдән сатып алалар. Эшләнәсе эшләр, хәл ителәсе мәсьәләләр күп әле, әмма «мәңгелек башмакка» заказ кабул ителгән. Бүген без элеккегә караганда зуррак өмет белән, фән булдыра алмаган эш юк дип әйтә алабыз. Кешенең үзе куйган сорауга дөрес җавапны кайчан табуы гына ачык түгел.

* * *

Полимерлар, пластмассалар, гомумән, табигать байлыкларын үзләштерү, җир астыннан чыккан чималны кирәкле әйбергә әйләндерү шактый кыйммәткә төшә. Каучукны эшкәртеп, эластик резина ясау ысулын ачкан, тик җитештерүне оештыра

алмаган, бурычка батып, хәерчелектә үлгән американ Чарлз Гудьир турында: «Әгәр сез өстенә резина плащ, башына резина эшләпә, аягына резина башмаклар кигән, кулына резина зонтик тоткан, резина янчыгында бер бакыр акчасы да булмаган кеше очратсагыз, белегез: бу, һичшиксез, Чарлз Гудьир булыр»,— дип көлгәннәр. Табигый каучук плантацияләренә ярдәмгә килгән күп санлы заводлар эшли башлауга карамастан, халыкара базарда каучукның тоннасы хәзерге көндә мең доллар тора һәм бу бәя, экономик шартларның нинди булуына да карамастан, артык үзгәрми.

Түбән Кама изопрен каучукларының абруе югары, аларны дөньяның күп илләрендә бик теләп сатып алалар. Чимал, энергия һәм кеше хезмәтенең аз сарыф ителүе нәтиҗәсендә, продукциянең бәясе дә арзан. Чирек гасыр дәвамында Ленин орденлы «Нижнекамскнефтехим» берләшмәсе заводларына ике ярым миллиард сум дәүләт акчасы тотылган.

«Заводлар» дип әйтү генә Кама буендагы үзгәрешләрнең күләмен, характерын ачып бирә алмастыр. Түбән Кама нефть химиясе комплексы — экономик һәм социаль мәсьәләләрне уңай хәл итү үрнәге, илебез Түбән Кама халык хуҗалыгы комплексына биргән өч миллиард сум акчаның бер миллиарды шәһәр төзелешенә, монда эшләүче кешеләрнең тормыш-көнкүрешен бар яклап тәэмин итүгә тотылган.

Хәзергә көндә яшь шәһәр Түбән Камада йөз җитмеш мең кеше яши. Бер ел дәвамында шәһәрдә җитештерелгән продукция — синтетик каучук, шиннар, монда гына эшләнә торган башка әйберләр, күп катлы йортлар — ике миллиард сумлык. Ел саен күбрәк, ел саен яхшырак эшләү — шәһәр кешеләренең төп кагыйдәсенә әйләнгән.

Егерме алтынчы съезддан соңгы биш елда гына да промышленность предприятиеләре төзелешенә, культура-көнкүреш объектлары челтәрен үстерүгә бер миллиард сум акча тотылган. Төзүчеләр ике йөзгә якын күп катлы йорт салганнар. Биш урта мәктәп, балалар өчен егерме ике комбинат, пионерлар йорты, балалар культура сарае, «Ана һәм бала» санаторие да — төзүчеләрнең тырыш хезмәтләре нәтиҗәсе. Шәһәрдә төзелгән яңа объектлар арасында химик юл белән чистарту һәм буяу фабрикасы, санаторий-профилакторий, стадион, автовокзал, «Балалар дөньясы» кибете, «Олимпия» спорт сарае, «Татар ашлары йорты» да бар. Кайбер ниятләр уникенче бишьеллыкта тормышка ашачаклар, башкалары ике меңенче елга кадәр исәпләнгән, озак еллар программасына кертелгән.

Менә алдан исәпләнгән берничә сан. Ике меңенче елга шәһәрдә яшәүчеләр саны өч йөз меңгә җитәчәк. Җитди сан бу, проблемалар күп, мәшәкатьләр тау кадәр. Якындагы елларда промышленность мәйданында дистә ярым эре производство сафка басарга тиеш, халык куллануы товарлары җитештерүне ике тапкырга арттырырга кирәк. Торак мәйданы бүгенгегә караганда ике тапкыр артыграк булачак. Аның гомуми мәйданы биш миллион квадрат метрдан артып китәчәк. Шәһәрнең баш заказчысы, ягъни нефть һәм химия промышленносте, уникенче бишьеллыкта Түбән Кама үсешенә 180 миллион сумнан артыграк акча бирә. Бу суммага яңа заводлар, алты йөз мең квадрат метр торак мәйданы, егерме балалар бакчасы, биш урта мәктәп, больницалар, ике кинотеатр төзеләчәк.

Чыгымнар шактый, тик алар файда бирәчәк, төгәл экономик фикер йөртүгә, алдан күрә белүгә нигезләнгән чыгымнар. Шушы еллар дәвамында «Нижнекамскнефтехим» берләшмәсе заводлары гына да ике ярым миллиард сум саф табыш алыр. Шин заводлары табышы миллионнарча сум тәшкил итәчәк. Бу инде гаҗәеп зур нефтехимия комплексы аңа сарыф ителгән бөтен акчаны дәүләткә кайтарып биргән, киләчәктә ел саен дәүләт бюджетына миллионнарча сум саф табыш керәчәк дигән сүз. Яхшы саннар!

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Түбән Кама аппаратлары, реакторлары нефтьнең иң җиңел бүленмәсен — углеводородлар эшкәртәләр. Әле күптән түгел генә алар, күзгә дә күренмичә, цистерналардан, резервуарлардан һавага оча иделәр, күчереп йөрткәндә дә югалтулар күп булды, факел итеп яндырырга да туры килде. Димәк, заводлар да, шәһәр дә һавадан алынган булып чыга.

Экиятләрдә, риваятьләрдә генә булган сихри сарайлар, шәһәрләр чынбарлыкка әверелә. Тик алар тылсым белән түгел, кешеләрнең ихтыяр көче, хезмәте, ныклыгы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр.

Любовь Уманская

# ҖИҢҮЧЕГӘ — ЧӘЧӘК БӘЙЛӘМЕ

Партия, әле XXVII съездга хәзерлек барган көннәрдә үк, һәр эштә, һәр коллективта социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерүгә, аның тагын да зуррак нәтиҗәләр бирерлек иттереп оештырылуына игътибар юнәлтте. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Михаил Сергеевич Горбачев стахановчылык хәрәкәте ветераннары белән очрашуы вакытында: «Илнең экономикасын интенсификацияләү юлына бастырганда, иң беренче башлап Ленин тарафыннан күтәрелгән социалистик ярышны оештыру мәсьәләсе безнең алга яңача килеп баса,— диде.— Безнең үзебезгә дә бу мөһим чараның күп якларына бөтенләй яңа күзлектән карарга кирәк».

Тәҗрибә күрсәткәнчә, социалистик ярышка кагылышлы эшләр барлык мәсьәләне бербөтен итеп кабул иткәндә һәм барын да дөрес чишкәндә генә яхшы нәтиҗәгә китерәләр. Моңа хезмәтне дөрес оештыру да, фәнни-техник прогрессны тизләтү дә, идарә итү ысулларының камиллеге дә керә. Шул җәһәттән бу урында авыр йөк автомобильләре чыгара торган Кама берләшмәсендәге тәҗрибәгә тукталасы килә. Билгеле булганча, КамАЗ коллективы үзенә тиң башка коллективлар арасында социалистик ярышны дөрес һәм шактый отышлы иттереп оештыручыдан санала.

Аз гына узганга күз салып, КамАЗ төзүче комсомол яшьләр арасында башланган «Кызыл канәфер» ярышына игътибар итик. Бу ярыш ВЛКСМ Үзәк Комитеты органы булган «Молодой коммунист» журналы тарафыннан оештырылды. Ярышның төп максаты бердәм коллектив туплау иде. Башлыча мөстәкыйль тормышка беренче адымнарын ясаучы яшь-җилкенчәкләрдән торган төзелеш өчен алга мондый бурыч куюның сере ачык. Беренче авырлыклардан ук гайрәте чигеп, эш ташларга, икенче бригадага, җиңелрәк хезмәткә күчәргә ашыгучыларга иң кулай киртә иде бу. Әлеге ярыш шартларында һәр бригада үз коллективына кертелгән төзүчене саклап калырга тырыша, чөнки ярышның иң беренче таләбе — тотрыклылыкны тәэмин итү. Моңа ирешү исә бары тик барың бер җан кебек бердәм омтылыш белән рухланып эшләгәндә генә мөмкин. Бу хакыйкать үзеннән-үзе яшьләрдә югары аңлылык, белемлелек, кешелеклелек, башкалар өчен корбанга әзер тору кебек сыйфатлар тәрбияли башлады. Кеше күңеленең иң тирәндә яткан серләренә кагылганлыктан, моңарчы ачылмаган рухи хәзинәләрен айкап чыгарганлыктан, «Кызыл канәфер» тиз арада иң популяр ярышка әйләнде. Ул яшьләрнең заманга лаек булып формалашуына көчле этәргеч тә иде.

Ә ни өчен бу ярышка шундый исем бирелде? Ярышта җиңүчегә бирелгән бүләк нинди иде соң? Укучыбыз күңеленә, мөгаен, шундый сораулар да килгәндер. Аңлатып үтик. Канәфер чәчәге электән үк «Молодой коммунист» журналының символы иде. Журнал тышына Җир шарының схемасы сызыла һәм аңа кызыл белән СССР мәйданы ясала. Шушы кызыл сурәт нәкъ канәфер чәчәгенә охшаш килеп чыга иде. КамАЗда социалистик ярыш оештырылгач, җиңеп чыгучыларга бирелә торган көмеш бүләк журналның рәссамы И. П. Леонов эскизы буенча ясалды. Төзүче кулында измә сала торган калак. Шул калак фонында кызыл канәфер чәчәге рәвешенә кертеп җир шары ясалган. Бу бүләкнең беренчесен, ягъни КамАЗны салучы төзүчеләргә дигәнен Мәскәүдә ясап китерделәр. Ярыш автомобильчеләр арасында да оештырылып, тагын бер бүләк кирәк булгач, «Кызыл канәфер»не КамАЗ осталары коеп бирде.

Ярыш нәтиҗәләре өч айга бер мәртәбә тикшерелеп, җиңеп чыккан коллективка шушы күчмә бүләк тапшырыла башлады. Ярыш шартлары моннан гыйбарәт: план үтәү күрсәткечләре; коллектив членнарының осталыгын һәм белемен күтәрү дәрәҗәсе; коллективка яңа кешеләр алу, ГПТУдан килгән яшьләрне кабул итү һәм аларны тәрбияләү; кадрларның эш ташлау-ташламавы; җәмәгать эшләренә катнашу; фәнни-техник иҗатка мөнәсәбәт. Әйтергә кирәк: ярыш шартлары хезмәт коллективларында бик кирәкле якларны эченә алган. Бу удар төзелешкә дә, заводларга да Кама буенда эшләргә теләүче йөзләрчә кешеләр агылып торды. Күбесе яшьләр. Алар арасында Совет Армиясе сафларыннан кайтучылар да, училище тәмамлап килүчеләр дә, ерактагы башка төзелешләрдән күчүчеләр дә җитәрлек иде. Яңа коллектив алдына зур бурыч — шушы чуар төрлелектән бер сулыш белән яшәүче өр-яңа хезмәт гаиләсе оештыру бурычы килеп басты. Моңа ирешмичә торып КамАЗны да, яңа каланы да вакытында сафка кертү һич мөмкин булмаячак иде. «Кызыл канәфер» ярышы шул мөһим бурычны чишүгә турыдан-туры хезмәт итте.

Ярышка катнашучылар хезмәтне камилләштерү, йөкләмәләрне арттырып үтәү, һәр адымда шәхси җаваплылык тою кебек ифрат кирәкле сыйфатлар булдырдылар. Ярышның нәтиҗәсен күрсәтә торган берничә мисалны гына китерик. «Кызыл канәфер» бүләгенә лаек бригадалардагы комсомол яшьләр хезмәт планнарын 102 проценттан алып 317 процентка кадәр арттырып үтәделәр. Ярыш барышында берсеннән-берсе куанычлырак тәкъдимнәр кертелде. Уңганлыкларының даны бөтен илгә таныш Вазыйх Мәүликов бригадасы: «Әтиләр күтәреп чыккан данлы байрак астында — хезмәттәге яңа җиңүләргә!», «Хезмәт планнарының һәр көнне һәм һәр җирдә үтәлешен һәркемнең шәхси җаваплылыгына тапшырыйк!» кебек яңадан-яңа өндәмәләр белән чыктылар. Сүзләрен эшләрендәге матур күрсәткечләр белән раслап та күрсәттеләр. Бу башлангычка Ш. Хөснетдинов, Г. Павлов, Р. Хәйбуллин җитәкләгән бригадалар да кушылдылар.

«Кызыл канәфер» ярышына катнашучылар арасында тәртип күзгә күренеп яхшырды. Бу бригадаларда эшкә соңга калу, тапшырылган бурычны үтәми калдыру, хезмәттәге тәртипне бозу күренешләре бөтенләй очрамый башлады. Алар булган белемнәрен арттыруны алга максат итеп куйдылар. Урта белеме булмаганнар кичке мәктәпләргә, техникум яки училищеларга йөри башладылар. Кайберәүләр, институтка кереп, югары белем алдылар. Шуңа ук өстәп, яшьләрнең һөнәрләрен камилләштереп, икенче-өченче һөнәрләргә өйрәнүләрен дә әйтергә кирәк.

Ярыш ачучылар коллективка килгән яшьләрне, һөнәрсезләрне тәрбияләргә алындылар. Чөнки «Кызыл канәфер»нең төп шартларының берсе иде бу. Комсомол яшьләр мәктәпләрдә, пионер дружиналарында, һөнәр училищеларында, автомеханиклар техникумында китеп алынган кунаклар иде. 2 нче мәктәптә тәрбияче-вожатый булып йөргән «Кызыл канәфер» лауреаты Галина Ермакованы әле дә сагынып сөйлиләр.

Югарыда телгә алынган уңышлы якларына игътибар итеп, «Кызыл канәфер» бүләгенә багышланган социалистик ярышны КамАЗ автомобильчеләре дә үзләштерделәр. Төзүчеләр исә алар белән үз тәҗрибәләрен бик теләп уртаклаштылар. «Кызыл канәфер» гигант берләшмәдә дә үзенең бик файдалы вазифасын тулысынча башкарып чыкты. Вакытында «Кызыл канәфер» лауреаты булган бригадалар соңыннан оештырылган төрле ярышларда да яңа казанышларга ирештеләр.

Хәзер КамАЗның двигательләрен һәм хәрәкәтләндерү өлешен тамырдан үзгәртү көн тәртибенә килеп басты. Бу үзгәреш ике күчәрле, 10 тонна йөк тартырлык яңа төр автомобиль чыгара башларга этәргеч булачак. Мондый сыйфатка ия машиналарны чит ил базарларында да теләп алалар. Бу юнәлештә хәл ителергә тиешле тагын бер мәсьәлә бар әле — ягулыкны мөмкин кадәр азрак сарыф итү мәсьәләсе. Киләчәктә 60—70 мең км узган һәр йөк машинасы 10—14 тонна дизель ягулыгына экономия ясаячак дип күздә тотыла.

Әлбәттә, алга куелган мондый яңалыклар берләшмә коллективының һәр кешесеннән эшкә иҗади мөнәсәбәт, фидакарьлек таләп итә. Шунлыктан социалистик ярыш тагын да мөһимрәк роль уйный бара. Двигательләр заводы алдынгылары, мәсәлән, бригадалардагы кадрларның даимилеге өчен ярыш башлап җибәргәннәр иде, хәзер аңа ике меңнән артык бригада кушылды. Шул ук вакытта ярышның индивидуаль төре дә әһәмиятен җуймый. Чөнки һәр уңышта аерым эшченең үз өлеше исәпкә алына. Шунлыктан социалистик ярыш аерым бригадаларның гына түгел, һәр эшченең дә үсүенә китерә. Эшчеләр укырга, техник һәм экономик белемнәрне күтәрергә тиеш булалар. Аларның бу ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен коммунистик хезмәт мәктәпләре ачылды. Бригадирлар, мастерлар өчен мәктәпләрнең башка төрләре — конкрет экономика, экономик семинар кебекләре дә бар.

Социалистик ярышның иң мөһим нәтиҗәсе шунда, ул һәр кешедә хезмәткә иҗади караш тәрбияли, шәхеснең камилләштерүенә китерә. КамАЗдагы ярыш хәтта Брежнев шәһәренең гомуми тормышы матурлануга да тәэсир итте.

«Кызыл канәфер»нең күркәм шытымнары КамАЗда шундый киң мәйданга таралган икән, нигә аны республикабыздагы башка төзелешләрдә дә оештырмаска?! Соңгы елларда гына Алабуга, Түбән Кама, Брежнев төзү коллективлары яңа зур эшләр башлады. Хәзер минераль ашламалар заводы, трактор заводы, атом электр станциясе төзелешләрендә вакытында «Кызыл канәфер» ярышы күтәргән мәсьәләләр кабаттан калкып чыкты.

Бу төзелешләргә ерак-ераклардан, төрледән-төрле язмышлы кешеләр килә. Мондый шартларда социалистик ярыш бердәм коллектив булдыру, максатларны уртак итү өчен дөрес бер юнәлеш билгеләргә тиеш. Бөтен ил бер булып КПССның XXVII съезды карарларын тормышка ашыру өчен тырышканда, тагын да матуррак күрсәткечләргә ирешүдә моның, һичшиксез, файдасы тиз сизелер. Шул җәһәттән чыгып караганда, үз вакытында КамАЗда, Брежнев шәһәрендә оештырылган һәм зур җиңүгә китергән «Кызыл канәфер» үрнәгеннән файдалану бик урынлы булыр иде.



**Ф. С. Сибагатуллин,**
КПССның Мамадыш райкомы беренче секретаре

# ҮРГӘ КҮТӘРЕЛГӘНДӘ

Моннан 200 еллар элек расланган Мамадыш шәһәре гербында яшел иген кыры, алтын бодай көлтәсе һәм ике көмеш урак сурәтләнгән. Елъязмаларда әйтелгәнчә, гербта әлеге якның бар нәрсәгә дә бай булуы тасвирланган. Ул чорларда безнең якларда игенчелек, сәүдә, һөнәрчелек киң таралган булган. Пәнҗешәмбе көннәрендә шәһәрдә һәм авылларда базарлар эшләгән, елга бер тапкыр — 7 июль көнне — зур ярминкә үткәрелгән. Анда крестьяннар һәм һөнәрчеләр үз хуҗалыкларында җитештерелгән продуктлар белән сату иткәнләр.

Октябрь революциясенә кадәр Мамадыш әнә шулай башкалардан берние белән дә аерылмаган сәүдәгәрләр шәһәре була. Сату-алуда иң зур урынны икмәк алып тора. Кайбер мәгълүматлар күрсәткәнчә, Мамадыш пристане аша бер миллион потка кадәр икмәк озатыла. Әмма шушы икмәкне үстерүче крестьяннарның өстәлендә ул сирәк күренә. 1895 елда Петербургка җибәргән бер хәбәрендә Казан губернаторы болай яза: «Мамадыш тирәсендәге авылларда яшәүче дәүләт крестьяннары, бигрәк тә татарлар, соңгы корылыклы елларда гаять зур бөлгенлеккә төштеләр. Алар үз гаиләләрен туендыра алмыйлар, басулар чәчелми, балалар хәер эстәп көн күрә».

Статистика күрсәткәнчә, бу елларны бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 2-4 центнер уңыш алына.

Әмма Мамадыш ягы крестьяннары халыкның җелеген суыручы сәүдәгәрләр, руханилар, байлар, динчеләр каршында баш иеп, бил бөгеп кенә яшәмиләр. Пугачев гаскәрләре безнең якларга килеп чыккач, мамадышлылар «крестьян патшасы»н, чаң сугып, ипитоз белән каршы алалар. Кирмән, Җөри, Комаровка һәм башка авыл крестьяннарыннан бер төркем Бәхтияр Канкаев отрядына кушыла һәм Казан янындагы сугышларда катнаша.

Мамадышлылар танылган революционерка Вера Фигнер истәлеген хөрмәтләп саклыйлар. Аның яшьлек еллары безнең якларда үткән. Ә хәзер иң матур урамнарның берсе аның исемен йөртә. Иске Мултан эше буенча бездә язучы В. Г. Короленко була. Әсәрләре өчен М. Е. Салтыков-Щедрин безнең якларда шактый бай материал туплый. 1900 елда әнисе һәм өлкән апасы белән В. И. Ленин утырган пароход Омар һәм Соколка пристаньнарында туктала. 1919 елда бортында Н. К. Крупская булган «Красная звезда» агитпароходы Соколкада тукталыш ясый.

Гражданнар сугышы елларында Мамадыш янында канлы бәрелешләр була. Шәһәрне аклардан азат итүдә Ленинградның йөзләгән эшчесе һәм латыш укчылары башларын салалар. Хәзер алар истәлегенә Пузанка тавында мәһабәт һәйкәл бар.

Гражданнар сугышы герое В. М. Азин һәм 19 яшьлек полк командиры В. И. Чуйков (соңыннан Советлар Союзы Маршалы) кызылгвардиячеләре ротасы, ут астында Вятка елгасын кичеп, төбәгебезне Колчак гаскәрләреннән чистарталар. 1918 елның 20 сентябрендә шәһәрдә яңадан һәм бөтенләйгә Совет власте урнаштырыла.

Яңа эраны ачкан легендар «Аврора»ның залпы яңгыраган көннәрдә аның бортында өч якташыбыз хезмәт итә. Албай авылы егете С. В. Домолазов гражданнар сугышы тарихына «Албай Чапаев» дигән исем белән кереп кала. Кыска гына вакыт эчендә ул 600 коммунисттан торган «Мамадыш коммунистик батальоны» төзи һәм акларга каршы көрәштә өч мәртәбә сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1921 елда, Татарстан республикасы хөкүмәте үтенече буенча, Домолазов Татарстанның хәрби комиссары итеп билгеләнә. Дивизия начальнигы Домолазов Идел буе һәм Дон хәрби округларының кавалерия инспекторы булып эшли.

1917 елның ноябрендә Мамадышка беренче Бөтендөнья сугышы окопларыннан коммунист А. В. Давыдов кайта. Ул, шушы як кешесе буларак, халыкне тиз аңлый, властьны

үз кулларына алган эсерларга һәм аларның иярченнәренә каршы кискен көрәш җәелдерә, күнгә берничә мәртәбә халык алдында чыгышлар ясый, эшчеләр белән очраша. РСДРП-ның Казан губерна комитеты белән тыгыз элемтә урнаштыра. Мамадышта чыга торган «Безнең көннәр» газетасында ул кул куйган өндәмә басыла. А. Давыдов эшчеләрне һәм крестьяннарны большевиклар партиясенә язылырга чакыра. Әнә шулай итеп өяздә беренче большевиклар оешмасына нигез салына.

Район коммунистлары халык хуҗалыгын күтәрү, илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, культура революциясе, Бөек Ватан сугышы елларында да үз-үзләрен аямыйлар. Районның беренче стахановчыларыннан тракторчы, коммунист Гаян Миңлекаев хезмәттәге батырлыклары өчен Ленин ордены белән бүләкләнә. 1939 елда башкалабыз Мәскәүдә ачылган беренче Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең Почет китабына районыбызның берничә хуҗалыгы һәм производство алдынгыларыннан 38 кеше кертелде.

Бөек Ватан сугышына мамадышлылар үз араларыннан 13 меңнән артык якташларын озаталар. Аларның һәр дүртенчесе яу кырында ятып кала, 1,5 мең кеше туган якларга инвалид булып кайта. 7 меңнән артык фронтовик орден-медальләр белән бүләкләнә, дүрт якташыбыз — Г. Я. Нигъматуллин, И. Т. Максимов, М. К. Москвин, М. А. Просвирнин Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар. Тылдагылар «Барысы да фронт өчен! Барысы да җиңү өчен!» дигән теләк белән хезмәт итәләр. «Мамадыш колхозчысы» дигән сугышчан самолетлар төзү өчен генә дә алар 2 миллион сумнан артык акча җыеп тапшыралар, «Татарстан колхозчысы» дигән танк колоннасы төзүдә актив катнашалар, фронт өчен җылы киемнәр җыеп озаталар, фашист илбасарлардан азат ителгән шәһәр һәм авылларны торгызуга зур өлеш кертәләр.

Райондашларның тиңдәшсез хезмәте нәтиҗәсендә биш ел эчендә авыл хуҗалыгы һәм промышленность сугышка кадәрге дәрәҗә белән тигезләнә.

Унберенче бишьеллыкта районда ПМК-2, ПМК-761, механикалаштырылган колхозара күчмә колонна көче һәм хуҗалык ысулы белән 2937 урынга исәпләнгән мәктәпләр, 1 800 урынлы культура йортлары һәм клублар, балалар бакчалары һәм яслеләр, больницалар һәм поликлиникалар файдалануга тапшырылды, 25 мең квадрат метр торак салынды, капиталь төзелешләр өчен 77 миллион сум акча тотылды.

Мамадыш һәм Кама урман хуҗалыклары, май-сыр комбинаты, автотранспорт предприятиесе,«Сельхозтехника»ның һәм «Сельхозхимия»нең район берләшмәсе, Түбән Кама сал агызу рейды, колхоз-совхозлар үз көчләре белән зур төзү эшләре алып баралар, колхозчылар белән иңгә-иң торып авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеген тагын да күтәрергә тырышалар.

Авылларны социаль үзгәртеп кору буенча зур эшләр башкарылды. 1985 елда мәктәпләр, клублар һәм торак йортлар төзү һәм аларны файдалануга тапшыру буенча планнар 120—130 процентка үтәлде. «Пятилетка» совхозында, «Яңалык» колхозында урта мәктәп бинагы файдалануга тапшырылды. Аларда бик яхшы спорт заллары бар. «Таң» колхозында да урта мәктәп салына. «Пятилетка» совхозында башлангыч мәктәпнең уку кабинетлары белән бергә балалар комбинаты — ясле бинасы файдаланыла башлады.

Районда 27 спорт залы бар. Аларның егерме бере — мәктәпләрдә, спорт залы да булган культура йортлары да арта. Милли һәм иркен көрәш буенча балалар — яшүсмерләр спорт мәктәбе уңышлы эшләп килә. Бирелә кыска вакыт эчендә биш РСФСРның спорт мастеры, бер СССРның спорт мастерлыгына кандидат, беренче разрядлы 22, төрле разрядтагы 158 спортчы әзерләнде. «Татэнергострой» төзү идарәсенең икенче механикалаштырылган күчмә колоннасында спорт залы, бассейны, душы, ләүкәле мунчасы, ял итү бүлмәсе, профилакторие булган зур спорт комплексы төзелә.

Төзүчеләребез уникенче бишьеллыкта тагын да зуррак эшләр башкарырга алындылар.

Районның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында кызыксынганда һәр тарафта уңай үзгәрешләр күзгә ташлана. Әле моннан унбиш-егерме еллар гына элек һәр сыердан елга 1600—1950 килограмм сөт саву рекорд саналса, хәзер без район буенча өч мең килограмм савуны максат итеп. «Мамадыш» совхозының Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, коммунист, КПСС райкомы члены Софья Васильевна Гарифуллина һәр сыердан биш мең килограммнан артык сөт сауды. Шулай ук Г. Мостафина, А. Мальцева, Л. Сәләхиева, Г. Галиева, Н. Нәдершина, Л. Тупаева һәм башка дистәләгән савымчыларыбыз да биш мең чиген уздылар.

Сигезенче бишьеллыкта Социалистик Хезмәт Герое исемен алган «Мамадыш» совхозы дуңгыз карауччысы Миңнури Хәйруллина ирешкән күрсәткечләр дә безнең бүген чик түгел инде. Нәселләрне яхшырту, кул хезмәтен механикалаштыру, абзарларны төзекләндерү, азык базасын ныгыту, терлекчелекне укымышлы кадрлар белән тәэмин итү әлеге тармакны отышлы итәргә мөмкинлек бирде.

Терлекчелектә «Дружба», «Спартак» колхозлары, «Мамадыш», «Берсут», «Омар», «Яке» совхозлары аеруча яхшы күрсәткечләргә ирештеләр.

Куйбышев исемендәге, «Таң», «Чулпан», «Алга», Ленин исемендәге, XXII партсъезд исемендәге, «Уңыш», «Маяк» колхозлары савымчылары көче белән район буенча дәүләткә сөт сату планын вакытыннан алда үтәргә мөмкинлек арта.

Терлекчелектә ике сменалы эшкә күчтек. Шунысы куанычлы: терлекчеләр әлеге прогрессив алымны производствога тизрәк кертүне житәкчеләрдән үзләре үк таләп иттеләр. «Кызыл флаг» колхозында шулай булды, терлекчеләр катгый карарга килделәр: «Житәр, күп сөйләндек. Су язып май төшмәс. Тиз арада мәсьәләне хәл итәргә кирәк!» — диделәр. Бу фермада ике сменалы эш шуннан оешып та китте.

Районыбыз терлекчеләренең башкалар белән уртаклашырлык тәҗрибәләре дә шактый. КПСС райкомы, урыннардагы башлангыч партия оешмалары алар арасында социалистик ярышны җәелдерү дә житәкчелек итәләр.

Ферма коллективларына агитаторлар беркетелде, депутат посты һәм халык контроле постлары эшли. Терлекчеләрнең нәтиҗәле хезмәтен оештыру һәм культуралы ялын тәэмин итү йөзеннән кызыл почмаклар җиһазландырылды, ашау-эчү бүлмәләре көйләнде, эш урынында медицина, сәүдә, культура-көнкүреш хезмәте күрсәтү җайга салынды.

Безнең якларны табигать үзенең җир-су, урман-болыннары белән артык кыерсытмаган. Тик ул республикада иң төньяк районнарның берсеннән санала. Җиребезнең көлсу, көрән туфрагын тәрбияләп, ашламалар белән сыйлап тормасаң, орлыкның иң әйбәтен чәчмәсәң, туфрак эшкәртү һәм игеннәрне тәрбияләү технологиясен төгәл сакламасаң, уңыш алырмын димә. Бу исә авыл хуҗалыгы эшчәннәренә, тармак белгечләренә аеруча зур җаваплылык өсти.

Әлегә кадәр игенчелеккә караш салкынрак иде. Дөрес, җир буш калмый, сөреле, чәчелә, җыеп алына. Кышын кар мулдан яуса, җәен яңгырлар тоткарланмаса, уңышы да чагыштырмача начар түгел. Тик аның чуарлыгы — исең китәрлек. Мисал өчен экономик яктан иң нык хуҗалыкларның берсе — «Кызыл флаг» колхозын алыйк. Унынчы бишьеллык. 1976 елда хуҗалык игенчеләре бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 21,4 центнер уңыш җыйдылар. 1977 елда — 9,9 центнер, 1978 дә — 18,8, 1979 да — 15,2, 1980 дә — 16,2 центнер. Район буенча да шул ук хәл. Унберенче бишьеллыкның беренче елларында да уңыш язмышын табигать үзгәрешләре йогынтысыннан чыгару турында кайгыртучанлык җитәрлек булмады. КПССның XXVI съезды материалларында һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары карарларында исә бу мәсьәләләргә нык игътибар таләп ителә иде.

Шулардан чыгып, без игенчелектә зур борылыш ясарга булдык. Хәзер барлык хуҗалыкларда сабан культураларын игүдә интенсив технология кулланыла. 1986 елда 27 000 гектар мәйданда бөртекле культуралар шушы ысул нигезендә үстерелде. 2,5 мең гектар борчакка индустриаль технология нигезендә игелде. Туңга сөрелгән җирләрдә буразналар сызып калдыру, оячыклар ясау, культивацияләү, каралган күләмдә сөрү катламын тирәнәйтү кебек саклау алымнары үткәрелә, сөргәндә «Мальцев корпуслы» сабаннар кертелә. Минераль һәм органик ашламаларны да күбрәк куллана башладык. Моңа кадәр без абзар тирәсендәге салам катыш тиресне басуларга ташу белән чикләнә идек. Черемәгән тирес белән басуларга чүп үләне орлыклары чыгарылды, игеннәрне чүп басты. Хәзер бездә тиресне бары тик компост хәлендә генә файдалану кагыйдә итеп санала.

Минераль ашламалар белән дә шул ук хәл. Күп көч куеп йөзләрчә километрдан кайтартылган кыйммәтле ашламаның җил-яңгыр астында кыя ташка әйләнеп каткан чаклары аз булмады. Мондый хәлдән котылу өчен, беренче чиратта, һәр хуҗалыкта ашлама складлары төзедек, җаваплы кешеләр билгеләнде.

Агулы химикатлардан теләсә ничек файдалану әйләнә-тирә мохиткә аеруча зыян китерә. Самолеттан ашланган басу тирәсендә яфраклары саргаеп кипкән урман кишлекләрен күреп, кемнең генә йөрәге сыкранмый икән? Без самолет ярдәменнән баш тарттык. Минераль ашлама туфракка культивация үткәргәндә һәм чәчкәндә, игеннәрне карап үстергәндә кертелә. Игеннәрне тәрбияләү махсус калдырылган эзләрдән алып барыла. Шулай итеп, без ашламаның тулысынча туфракка керүенә ирешәбез, сулыкларны, урманнарны пычратмыйбыз. 1985 елда без бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 18 центнер уңыш җыеп алдык, дәүләткә 35 мең тоннадан артык Мамадыш икмәге озатылды, ашлык сатуның еллык һәм бишьеллык планнары арттырып үтәлде. Бу безнең шартларда да тотрыклы уңыш алырга мөмкин икәнен тагын бер кат раслады, игенче күңелендә психологик борылыш булды. Бүген без «Дружба», «Кызыл флаг», «Таң», «Чулпан», «Родина», Куйбышев исемендәге, «Спартак» колхозлары, «Мамадыш», «Пятилетка» совхозлары кебек алдынгы хуҗалыклар мисалыннан чыгып, шуны әйтә алабыз: фәнни нигезләнгән һәм практикада расланган прогрессив технологияне кулланып, гектарның көчен елдан-ел күтәрә барырга мөмкин. Моның өчен безнең РСФСРның атказанган механизаторы, 40 нчы өлкә партия конференциясе делегаты, коммунист И. Әүхәдиев (Ямашев исемендәге колхоз), Татарстанның атказанган механизаторы Д. Миңлеәхмәтов («Таң» колхозы), С. Мозаффаров, Х. Вәлиев («Дружба»), А. Минкашов («Мамадыш» совхозы) кебек йөзләгән

тәҗрибәле игенчеләребез, ышанычлы техникабыз, чәчү һәм туфрак эшкәртү машиналарыбыз, сортлы орлыкларыбыз җитәрлек. Киләчәктә бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 20-25 центнер һәм аннан да артыграк уңыш җыярбыз дип ышанабыз.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, авыл хуҗалыгы производствосының нәтиҗәлелеген күтәрүдә партоешмаларның, хуҗалык җитәкчеләренең һәм белгечләрнең кадрларны сайлап алу һәм урнаштыру турында тирәнтен кайгыртулары да әһәмиятле. Аларны алдынгылар үрнәгендә тәрбияләү, эш һәм ял өчен тиешле шартлар тудыру, мораль һәм материаль кызыксындыру чараларын белеп куллану — партоешмаларның мөһим бурычы.

Райондашларның намуслы, тырыш хезмәте нәтиҗәсе аларның тормыш һәм көнкүреш хәленең һаман яхшыра баруында ачык чагыла. 1934 елда районыбыз газетасы бер колхозчы гаиләсенең патефон сатып алуы турында шатлыклы хәбәр бастырган. Ә бүгенге колхозчыларның ниләр сатып алганын саный китсәң, газета бите генә җитмәс кебек. Мамадышның урамнарына асфальт җәелде. Бишәр катлы, барлык уңайлыклары булган йортлар калкып чыкты. Җәен тиз йөрешле суднолар район үзәгеннән дистәләгән шәһәрләргә китеп торалар. Казан-Брежнев трассасы автобус маршрутларының санын арттырырга мөмкинлек бирде. Унберенче бишьеллыкта юллар салырга гына 6 миллион сумнан артык акча тотыла. Без алга шундый бурыч куйдык: һәр бригада колхоз үзәгенә, һәр колхоз район үзәгенә ныклы юлдан теләсә кайсы вакытта килеп-китеп йөрерлек булсын! Куптәнге бу хыял уникенче бишьеллык башында тулысы белән тормышка ашачак.

Соңгы елларда безнең авыл хуҗалыгы һәм промышленностьта гына түгел, культурабыз үсешендә һәм көнкүрешебездә дә күркәм яңалыклар булды. Район үзәгендәге спорт мәктәбе биш ел эчендә бер мастерлыкка кандидат, утызлап беренче разрядлы спортчы тәрбияләде. РСФСР чемпионы Ф. Фатыйхов, Н. Хәбибуллин — шулай ук шушы мәктәптә үскән көрәшчеләр. Мәктәптә 4 тренер җитәкчелегендә 300 ләп яшүсмер шөгыльләнә. Мамадыш командасы татарча көрәш буенча герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге зур приз өчен барган ярышларда республикада беренче урынны яулады.

Хәзер кайбер авылларда кышын да сабан туе үткәрелә. Аларда һәр хуҗалыктан йөзләгән спортчы катнаша. Һәр культура йортында һәм клубларда спорт буенча төрле түгәрәкләр эшли. Кырда сынатмаган егетләр келәмдә дә бил бирмәскә өйрәнәләр, чыныгалар, тәҗрибә туплыйлар.

Унберенче бишьеллык нәтиҗәләре тагын бер вакыйга белән истәлекле. Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Кама урман хуҗалыгы директоры Иван Захарович Ивановка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Билгеле, бу барлык район коммунистлары, барлык хезмәт ияләре өчен зур шатлык. Уникенче бишьеллыкта геройлар сафын ишәйтерлек батырлыкларга ирешү теләге белән яшибез һәм эшлибез.

Безнең төбәк табигате, данлы тарихы, хезмәт уңганнары белән генә түгел, матурлыкка, хезмәткә мәдхия җырлаучы талантлары белән дә күренекле.

Сөн суында коенып үскән, зәңгәр чишмәләрдән, бихисап урман-болыннарыннан илһам алган композиторлар — Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннары белән горурлана бу яклар. Туган җирне мактап җырлаучы Миңгол Галиев тә — төбәгебезнең зур шатлыгы. Татарстан әдипләре арасындагы якташларыбыздан Шәйхи Маннур, Зиннур Мансуров, Әхмет Гадел, Ринат Мөхәммәдиев мамадышлыларның горурлыгы санала.

Республикага танылган «Нөкърәт» вокаль-инструменталь ансамбле безнең районда канат ныгытты. Мәскәүдә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә чыгыш ясаган «Нөкърәт бизәкләре» балалар ансамбле — аның бүгенге дәвамы.

Район газетасы редакциясе каршында «Агымсу» әдәби-иҗат берләшмәсе эшли. Ул үзенең 20 еллык юбилеен билгеләргә җыена. Бүген «Агымсу» үз тирәсенә дистәләрчә кешеләрне туплый. Алар арасында төрле яшьтәгеләр, төрле һөнәр ияләре бар. Иҗат көчләренең мәктәп яшендәгеләре район пионерлары һәм мәктәп балалары йорты каршында оешкан «Карлыгачлар» берләшмәсенә йөри.

Мамадыш — авыл хуҗалыгы районы. Әмма сөт елгалары белән генә түгел, нефть фонтаннары белән дә танылыр көннәре җитә аның. Районда табылган нефть ятмалары шул хакта сөйли.

Мамадыш — авыл хуҗалыгы районы. Дәүләткә тапшырыла торган миллион пот икмәге белән генә түгел, җитештерә торган өй җиһазлары, агач материаллары белән дә тирәяк өлкәләргә танылды ул.

Мамадыш — авыл хуҗалыгы районы. Әмма бездә тегелгән аяк һәм өс киемнәрен, тукылган тукымаларны республикабызда теләп алалар. Бөек Октябрьга кадәр спирт заводыннан башка бернинди промышленносте дә булмаган Мамадышта дистәләгән предприятиеләр эшли, меңнәрчә кешеләр материаль байлык тудыра, машина рулен кулына ала, укучыларга дәрес аңлата, авыруларны дәвалый...

...Районның киләчәге тагын да куанычлы. Мамадыш районы хезмәтчәннәре менә шул якын киләчәкне тизрәк күрү өчен тырышалар, яңа үрләр яулыйлар.

## Миргазиян Юныс

# ИСӘННӘРНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛ...

*Биш ел буе чут төймәсе тарттым*
*(Төп эштән соң яздым шигырьләр).*
*Журналист та булып уң ел чаптым*
*(Төп эштән соң яздым шигырьләр).*

*«Эш»,— диделәр, эшне сорадылар.*
*Беркем сорамады тегесен.*
*Эштән арып кайткач, ялны урлап.*
*Эшләнелгән минем төп эшем.*

Шагыйрь Шәүкәт Галиев чыннан да Олы Бакырчы (кайчандыр бу авылда бакырчылар — чеканщиклар яшәгәндер дип уйлыйм мин) авылында хисапчы булган. Газетага күчкәнче, район үзәге Кайбычта да шул эшне башкарган. Хисапчылык Шәүкәтнең табигатендә дә бар: ул беркайчан, беркемгә әҗәтле булырга яратмый (дебет-кредит шаукымы) һәм әйткән сүзен, биргән вәгъдәсен төгәлләп, җентекләп, вакытында түләргә ярата. Ләкин хисапчыллык үзе генә кешенең начармы, яхшымы икәнлеген билгели алмый әле. Бу сыйфатны начар кеше начарлык, яхшы кеше яхшылык эшләү өчен куллана. Кайбер богемалар арасында гына бухгалтер — коры, вакчыл тип итеп, шигъри табигатьле кешенең антонимы дип санала, ә Европада, киресенчә, андый кешене ихтирам итәләр.

Башка төбәкләрдә, бәлки, бу гадәт бүгенге көнгә кадәр сакланмагандыр да, әмма безнең якта хисапчы («чутават») итеп авылның иң зирәк, гадел, абруйлы кешесен куялар иде. Председательләр ел саен алышынып торганда, халыкның ышанычы «чутават»ларда булды. Безнең «Урал» колхозы хисапчылары, мәсәлән, Сафуан абый, Разия апа, шул эшкә яшьли керешеп, картайганчы эшләделәр.

Борынгылар да логика төгәллегенә тик хисап, математика гыйлеме аша гына ирешеп булганны яхшы аңлаганнар. Шәрыкта математика фәне — философия, поэтика, риторика һәм дин гыйлеме белән бергә өйрәнелгән. Мәсәлән, Гомәр Хәйямне һәм Заһретдин Бабурны хисап яраткан өчен тәнкыйтьләп буламы икән? Минемчә, татар әдәбиятындагы кимчелекләрнең күбесе хисап белмәүдән. Сәгатенә өч йөз километр тизлек белән очучы бомбардировщикның алты йөз километр тизлек белән йөрүче истребительне куып җитеп, таран ясый алмавы турында мин бер тапкыр язган идем инде. Тагын авиациягә багышланган бер китапны укыганда, кулыма навигация линейкасы алып, хисаплап карадым: чутласаң, әсәрдәге бер генә очкыч та һавага күтәрелергә һәм кире үз аэродромына әйләнеп кайтырга тиеш түгел иде... КамАЗ турында зур-зур романнар язылды. Әгәр шул романнарда чагылган экономиканы, андагы техник хисапларны компьютерга тапшырсаң, әсәрдәге геройларның барысын диярлек растрата ясаган өчен җәзага тартып булыр иде.

Хисап эше кешене кырыс тәртипкә өйрәтә. Хисапчылар арасында «мин бухгалтер!» — дип күкрәк киереп йөрүче очрамый. Бу эш, бәлки, тыйнаклыкка да өйрәтә торгандыр? Без, кызганычка каршы, шигъри табигатьле кешене мохит аңламый, андый кеше үзенә тиң дуслар, лаеклы ярлар таба алмый дигән хорафатка ышанабыз. Шагыйрьләрнең семья тормышында бәхетле була алмаулары турында сүз чыккач, Шәүкәт: «Без ялгыш өйләнүебез өчен дә җавап бирергә тиешбез. Гадәттә, мәхәббәтне күңел ачуга кейләгән, семья тормышына җавапсыз караган кеше бәхетсез була»,— ди.

Үзенең гаилә коруы турында исә шагыйрь болай яза: «Бер авылда үстек... Бер мәктәптә, бер класста бергә укыдык... Мәхәббәтне сиздермичә генә бер партада бергә утырдык. Яшьлек бергә үтте... Беләм: шуннан аерылдылар диеп көтәсез? Бер шәһәрдә бер үк квартирда яшибез без — гафу итәсез!» Әйе, семья тормышы — безнең яшәешнең фундаменты ул. Ә иҗат исә океанда йөзгән айсбергның су өстеннән күренеп торган өлеше генә. Аста — безнең холык, дөньяны күзаллау, вөҗдан, кешеләргә һәм җәмгыятькә булган мөнәсәбәтләребез. Укучы шул күзгә күренмәгән күләмне, аның сыйфатларын тоя. Иҗади уңышта айсбергның су астында калган сыйфатының өлеше гаять

зур. Шуңа күрә иҗат кешесенең шәхси тормышыннан читкә борылып, күрмәмешкә салышып китәргә безнең хакыбыз юк. Шәүкәт яза: «Әби әйтә: «Кыр казларын күргәч, җирдән бер уч салам алсаң, тезелешеп үсә бәбкәләре, казның оясына салсаң...» Шуңа ышанып ул чак, салам алып, чаптык икәү без өйләргә; тезелешеп үсә дүрт балабыз, шуннан ары ни сөйләргә?»

Балалары тезелешеп үскән чакта, Шәүкәт исә, эштән кайткач, китап кочаклап, кичке мәктәпкә йөгерә... Бу еллар аның «Чаян»да эшләгән чагына туры килә. Иҗатының актив чоры. Сатирик журнал бимазасын кичке мәктәпкә йөрү, бала тәрбияләү һәм иҗат эше белән бергә уңышлы алып бару өчен зур түземлек кирәк.

Белмим, бәлки моңа да бухгалтерлык өйрәткәндер. Шәүкәт эшне гаҗәп пөхтә, көмешчеләр төгәллеге белән башкара белә. Мин үзем кирәк кәгазьне эзли башласам, өйнең астын өскә әйләндерәм. Хәлдән таеп туктыйм. Икенче көнне карасам, эзләгән кәгазем янәшәдә генә аунап ята... Таркаулыкның трагедиягә әйләнгән чаклары да бар. «Биектә калу»ның соңгы вариантын эшләп бетергәч, караламаны иллюминатор аша диңгезгә томырдым да, тынычланып йокларга яттым. Иртән торып карасам, диңгезгә очкан каралама... өстәлемдә ята. Нинди могҗиза бу? Мистика, сихер? Тикшерә башласам, каралама урынына диңгезгә редакциягә җибәрәсе соңгы вариантны ыргыткванмын... Шәүкәт исә, кулын гына суза — кирәк кәгазь аның алдында. Ул җыеп барган материаллар, жанрына һәм темасына карап, җентекләп сайланган, пөхтә итеп теркәп куелган. Һәр эшендә — тәртип, система, оптималь сыйфат һәм файдалы эш коэффициенты. Четерекле авыр эшләрне бергә алып баруның сере менә кайда!

...Шәүкәт Галиев белән Переделкино тирәсендәге кырларда, урманнарда йөреп кайттык. Мин билгә чаклы пычракка батканмын. Юлдашымның тик олтаны гына пычранган. Мине юатыр өчен ул тыйнак кына аңлата: «Син бит, дус кеше, сүзгә мавыгып, гел пычракка кереп йөрдең». Юлдагы пычраклардан саклануы әллә ни түгел, ә менә сатирик журналның әхлакый пычракларга каршы көрәшендә? Нәшрият эшенең тынгысыз мәшәкатендә?.. Тормыштагы төгәллек кешедә әчке, рухи төгәллек тәрбияли, күрәсең.

Шәхес ул — тоташ бер феномен. Гадәтләр — эшкә, хезмәт фидакарьлеге — рухи сыйфатларга, рухи байлык иҗатка килеп тоташкан. Һәр шагыйрьнең иҗат юлын яктыртып торган бер бөек идеясе була. Ул — сәяхәтче кулындагы компаска охшап, шагыйрьгә кыйбла күрсәтеп тора. Шәүкәт Галиевнең иҗатындагы кыйбла күрсәтүче идея:

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел.

Шагыйрьнең беренче адымнарыннан башлап шушы тезис аның иҗат офыгын яктыртып, исәннәрне гаделлеккә, Ватанга тугрылыкка, фидакарьлеккә өндәп килә. Исәннәрнең кадерен белү — икейөзлелеккә, комсызлыкка, кеше хакына керүгә каршы аяусыз көрәш. «Теңкәбезгә тиеп торалар, онытлырмый үзен юньсезләр; Күз алдыңда синең гел шулар, шулар тирәсендә гел сүзләр. Истән чыга яхшы кешеләр, игътибардан алар мәхрүмнәр, соңга калган җылы сүзләрне ишетә алмый китә мәрхүмнәр»,— ди шагыйрь, шушы тезисына кат-кат әйләнеп кайтып. Үлгәннәрнең васыятьләрен үтәргә кирәклек шагыйрьнең иҗатында лейтмотив булып яңгырый. «Күңелемдә күп кешеләр тере, ни кылсам да читтә калмыйлар; сугышялкыннары арасыннан мөлдерәтеп күзгә карыйлар. Сүзсез өнсез димә син аларны, күңеленә кагып дәшәрләр! Алар хыялынча яшәсәң син, синең белән мәңге яшәрләр». Шушы тезисны шагыйрь эш планы дәрәҗәсендә куллана, программасын һаман киңәйтә, тирәнәйтә һәм чор куйган яңа таләпләрдән чыгып конкретлаштыра. «Алар хыялынча» яшәүнең аяусыз дошманы — комсызлык, ялкаулык, умырткасызлык һәм татлы гөнаһлар. «Алар хыялы» белән яшәргә тырышучыларга киртәләр очрап тора. «Шома юллар яңалыкка илтми,— дип аңлата шагыйрь,— үз юлыңны кирәк салырга; каршылыклар, кыенлыклар үтеп, егыла-егыла алга барырга. Бер йодрыктай йомарлану кирәк, ихтыярны төпкә җигәргә. Иң кыены шулдыр — бертуктаусыз үз-үзеңне кирәк җиңәргә...»

Адәм баласы әллә нинди авырлыкларны җиңә ала. Иң авыры — үз-үзеңне җиңү. Андыйлар безнең арада шактый сирәк очрый. Дошманга каршы көрәшкәндә гайрәт һәм батырлык кирәк булса, үз-үзеңне җиңәр өчен шушы сыйфатлардан тыш ихтыяр көче, тәртип, фидакарьлек, бөек идеал, иман һәм тагын әллә нинди сыйфатлар кирәк. Шәүкәт Галиевнең лирик герое бөек идеалга тугры яши. Аның даими идеалы — тугрылык һәм хакыйкать:

Туры сүзне кисеп әйткән чакта
Кая хәтер саклап торышлар.
Бер-беребезгә бигрәк мәрхәмәтсез,
Каты бәгырьле без тормышта...

Сискәндерә мине шундый уйлар
Берәр иптәш китсә арадан...
Ә тереклек үзенекен итә,
Шул ук принцип яши яңадан.

Һәр кешегә ярап, мыштым гына
Йөри алырмын дип уйлама.

Яшәүдән һәм үлемнәрдән көчле
Хакыйкать бар әле дөньяда

Хакыйкатькә тугрылык саклау лирик геройны көндәлек тормыш кешесенә якынайта. Ул тыйнак, ипле, гади; ясалма пафосны, купшы сүзне өнәми. «Сиңа әйтер сүзем бар» дигән шигырьдә егет сөйгән кызына тормышны тулысынча үзгәртә торган хәлиткеч сүз әйтергә тиеш. Бу очракта күп шагыйрьләр лирик геройны әллә нинди ялкынлы мәхәббәт сүзләре әйтергә, аллы-гөлле вәгъдәләр бирергә мәҗбүр итәләр. Шәүкәт Галиевнең герое хәтта шушы очракта да тыйнаклык саклый. Ул өйләнешкәннән соң кызны таңнан торып мичкә ягу, сыер саву, эшкә йөрү, бала үстерү шикелле мәшәкатьләр көткәнен белә һәм зәңгәрсу хыяллар белән сөйгән ярының башын әйләндерүдән тыела. «...Әллә инде таң да ата, мичләр тәмәке тарта? Киленнәр таңнан тора, тәрәзәләр яктырта. Бездә ут алынмаган, мичкә дә ягылмаган... Карт шул инде әни дә, йә, сузасың син нигә? Көтмик лә, көтмик көзне, узма бу юлы безне... Керик, инде ай да юк, болай йөреп файда юк...» Борынгы гадәтләрне саклап әйтелгән гади, тыйнак тәкъдимдә кызны дулкынландырырлык җитдилек һәм тирән ышаныч бар.

Тыйнаклык — Шәүкәт Галиев иҗатының даими бер сыйфаты. Аны тасвирлау алымнары укучыны хәйран калдыруга көйләнмәгән. Метафоралар төгәл, ритм тыныч; салмак шигырь тигез болыннар аша узган дәрья шикелле, ашыкмыйча, тойгы җылылыгына төренеп, әкрен генә ага бирә. Хисләр тышка бәреп чыкмый. Шагыйрь аларны, тирәнгәрәк яшереп, озак суынмаслык итеп сакларга тырыша. Укучының хисләрен тиз генә кабызып, аны әсәрләндерергә, шушы юл белән шигъри максатка ирешергә Шәүкәт Галиев яратмый. Тыйнаклык — аның шигъриятенең канында, һәр күзәнәгендә һәм сулышында. Бу алымны мин борынгы җырларда, дастаннарда очратам. Дуамаллык, кинәт кабынып китү соңрак, тарихи тетрәнүләрдән соң туган булса кирәк. Борынгыларның «сабырлыклар — сары алтын» дигән искиткеч тирән әйтемнәре бар. Сабырлык безне фаҗигале чорларда өмет өзүдән, төшенкелеккә бирелүдән саклап калган. Шушы алым Шәүкәт Галиев иҗатын халыкчанлаштыра, фольклорга якынайта. Шагыйрьнең халык иҗаты чыганакларына мөрәҗәгать итүе, шул үрнәктә эшләве очраклы хәл түгел. Ул чыганак Кол Гали чорыннан алып шушы көнгә кадәр шагыйрьләргә шифалы сулышын өреп тора.

Яшәү мәйданында кешене дөрес юлдан яздыручы бәлаләр шактый күп. Җәмгыятьтә начарлыкларга каршы көрәш бара. Ул көрәш беркайчан да туктамый. Дөнья яралганнан бирле яшәп килгән начарлыкның берсе — яңалыктан өркү, күнегелгән кануннарга, торгынлыкка ябышып яшәү. Торгынлыкны, үзенең өркүен җиңмичә, кеше шәхеслеккә ирешә алмый.

Шагыйрь иҗатында лейтмотив булып яңгыраган «исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен» белеп, ихтирам җылылыгында, татулыкта һәм башкаларның бәхетле булуларына куанып яшәргә өндәү һаман көчәя, киңәя һәм конкретлаша барып, Туган ил, Ватан зурлыгына ирешә:

Яшисең ил гамен кайгыртып —
Үткәнен, бүгенен, киләчәген.
Чиләнеп бетәсең чишкәндә
Мең төрле чуалчык төенен.
Гомернең буеннан-буена
Гел шундый борчылу озатты;
Шул минем гомерне кыскартты,
Шул минем гомерне озайтты.

Ил гамен кайгырту гына «исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен» ихтирам итүгә ирештерә ала. Шушы фикер лирик геройның төп теләгенә һәм максатына әверелә. Шәүкәт Галиев иҗатын бары тик шушы позициядән өйрәнгәндә генә тулысынча аңлап була. Матбугатта исә, шагыйрьнең иҗатын өчкә бүлеп өйрәнү гадәткә кереп киткән. Шәүкәт Галиев — лирик, Шәүкәт Галиев — юморист, Шәүкәт Галиев — балалар шагыйре. Бер иҗатны вак кисәкләргә бүлеп өйрәнү эклектик караш тудыра. Иҗат шәхесе, әгәр ул «шәхес» мәгънәсен акларлык булса, һәр очракта — вакыйга. Башкача кабатланмый, башка вакыйгалар белән чагыштырып булмаслык хәлдә уникаль күренеш. Шәүкәтнең балалар әдәбиятына керткән өлешен ачыклар өчен, мин рус һәм дөнья әдәбиятыннан охшашлыклар эзләп карадым. Корней Чуковский? Самуил Маршак? Джанни Родари? Джозеф Редьярд Киплинг? Юк, боларның берсе дә шагыйрьнең иҗатын ачыкларга ярдәм итә алмый. Аның иҗади диапазоны философик лирикадан башлап, җырлар, сатира, юмор аша балалар поэзиясенә кадәр булган киңлекне биләп тора. Һәм шушы киңлектәге иҗади кредо шул ук «исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен» ихтирамлауга багышланган.

Яшәү тукталмый. Ул катлаулы. Ул тоташ. Яшәүне бу дөньядан киткәннәрнең васыятьләрен онытмау, аны тормышка ашыру тоташ итеп тора. Киткән буыннарның васыятьләре бүгенге көн яшәешен тарихка һәм киләчәккә тоташтырган. Тарих тирәнлегенә тамыр җәеп, ботакларын киләчәк иркенлегенә суза алмаган халыкны чорлар давылы үскән җиреннән суырып ала. Тамырын тарихка, яфракларын киләчәк һавасына сузып үскән мәһабәт агач та әле афәтләрдән тулысынча азат түгел. Аның яфракларын корт кимерә, тамырларына сукыр тычканнар һөҗүм итеп тора. Империалистик чынбарлыктан килгән агулы һава, әхлакый браконьерлар сулышы — боларның барысы да агачның үсүенә, аның иминлегенә комачаулык китереп торалар. Шушы хәлне күреп яшәгән шагыйрь чәчәнлек җаваплылыгын тойган очракта, беркайчан да мохиткә битараф кала алмый.

Социализм төзүгә аяк чалучылар, коммунистик тәрбиягә зыян китерүчеләр җәмгыятьтә очрап торганда, шагыйрь тыныч кына яши алмый. Бу кулга сатира, юмор коралын алырга мәҗбүр итә. Иҗат аренасыннан тәнкыйтьне сыпырып ташларга, әдәбиятны һәм шигъриятне тулысынча мәдхиягә көйләп, алсу гамьсезлек атмосферасында яшәргә өндәүчеләр әле һаман кала киләләр. Һәр тәнкыйтьне чынбарлыкка кул күтәрү итеп күрсәтергә теләүчеләр дә юк түгел. «Чаян» мәктәбендә тәрбияләнгән Шәүкәт Галиев сатира һәм юморны снайперларча куллана белә.

Сатира белән юмор арасындагы ызанны эзлим. Сатира турыдан-туры маңгайга бәреп әйтү. Анда нәфрәт көчле һәм тупасрак. Әллә шунлыктан, ачу басылу белән, сатира көчен югалта башлый, тәэсире кими. Сатираның гомере кыска. Юмор башкарак юл белән тәнкыйтьли. Ул тәнкыйтьләү инициативасын күбрәк укучының үзенә бирә. Юмор озын гомерле, ләкин аны тудыру өчен талант көче, композиция нечкәлекләре, махсус ситуация тудыра белү осталыклары кирәк. Шушы атрибутларны Шәүкәт Галиев тормышның үзеннән таба. Аның төп алымы — вакыйганың, персонажның хәйлә һәм күз буяудан торган комуфляжын ачып, укучыга аның чын йөзен күрсәтү, асылда эчтәлекнең бөтенләй икенче икәнлеген фаш итү. Көлке — эчтәлекнең тышкы рәвешкә туры килмәвеннән туа, шунлыктан ул — авыз ерып ихахайлау түгел, җирәнгеч тойгы, нәфрәт тудыра торган көлке.

Шәүкәт Галиев вөҗдан таптап, җәмгыятьнең әхлакый атмосферасын пычратучылардан тулы бер галерея җыеп, аларның гөнаһлы эшләреннән энциклопедия төзегән. Кемнәр генә юк монда, нинди генә күз буяулар, пычраклык эшләүләр юк! «Җитмәде бер балл» дип, институтка керүче абитуриентның әтисеннән бер тәпән бал китертүче ришвәтче... «Лично үзем» дип, хезмәтне һәм тәртип саклауны кабинет һәм персональ машина тәрәзәсеннән генә күзәтеп йөрүче бюрократ начальник... «Өйгә кайткач, өйгә кайткач» дип кенә алкоголикларны, хулиганнарны, хатынына кул күтәрүче кыргыйларны яныннан уздырып торучы формалист милиционер... Хатын-кызларны «Вокзал кебек йөрәге» аша үткәреп, тойгы белән сәүдә итүче азгын ир... Җыелышка кадәр һәм җыелыштан соң тәнкыйть куертып, социалистик чынбарлыкның ышанычлы коралын гайбәткә әйләндереп йөрүче «кыю Галләм»... Колхозга «борылыш ясарга килеп», «алты күкәй әзерләшеп, алтмышны ашап киткән» соры корт вәкил... Семьяда «берсе — тимер, берсе — игәү» булып яшәүче ир белән хатын... Шагыйрьнең көлке тозагыннан әхлаксызларның берсе дә ычкына алмаган диярлек. «Шалт Мөхәммәтҗан», «Әмин белән Дәмин», «Мөстәкыйль Мөстәкыйм», «Аннан-моннан»нар халыкның сөйләм теленә кереп, әйтемнәргә әйләнеп беттеләр.

Җир йөзендә яшәгән шагыйрьләрне санап чыгу өчен бөтендөнья әдәбиятын аерым күзәтергә, аннан соң гасырларга бүлеп бик озак санарга туры килер иде. Шагыйрьләр күп, бик күп. Бу фикер бәхәссез. Ләкин, ни сәбәптер, чын балалар шагыйре әдәбиятта чиктән тыш сирәк очрый. Дөрес, балалар өчен махсус язылган шигырьләр аз түгел. Тик балалар поэзиясендә эшләүче шагыйрьләр аз. Бөтендөнья әдәбиятында бары тик балалар өчен генә язган шагыйрьләрдән Джанни Родаридан башканы табу кыен. Эзләгәндә хәтта энциклопедия дә миңа ярдәм итә алмады.

Шәүкәт Галиевнең балалар өчен язган шигырьләрен укыйм. Тик «укыйм» сүзе бу процессны тулысынча аңлата алмый. Мин балачак рәхәтлегенә, андагы әкияти чынбарлыкка кире кайтам. Мин бәхетле. Нинди рәхәт икән ул тоташ керсезлек, ихласлык тою. Шигырьләрнең үзенчәлеге дөньяга сабыйларча керсез, риясыз карый алудан туган. Без, зурлар, өлкәнәю дәверендә, чынбарлыкка «кирәкчә, тиешлечә» карарга өйрәнәбез. Балалар исә, урынына карап, җайлаштырып фикер йөртә һәм сөйләшә белмиләр. Аларның карашы риясызлыктан туа.

Сабыйларның үзләрен ничек тотуын күзәтегез әле! Бозылып өлгермәгән чын балада тәкәбберлек тә, ялагайлык та юк. Аның кыланышларында табигый, куанычлы юморга сугарылган гадилек. Шәүкәт Галиевнең иҗатындагы уңышлыклар менә шушы мәсьәләнең асылын аңлаудан килә. Аның балаларга багышланган шигырьләрендә «исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел»ергә чакыру тагын да көчлерәк, тагын да җитдирәк яңгырый. Чакыру авазларында үгет-нәсихәт юк. Ышандырырга тырышып, хәйлә һәм трюкләр куллану да очрамый бу шигырьләрдә. Шагыйрь балаларча ихлас мавыгып эзләнә башлый һәм сизмәстән хакыйкать дөньясына килеп керә. Кызыктыргыч үеннар, елмаепкөлүләр — боларның барысы да дөрес юнәлештә башкарыла. Шушы мавыктыргыч сәяхәттән сабыйлар рухи яктан баеп, үзенчә бер бәхеткә ирешеп кайталар.

Ватан сугышы чорындагы тарихи вакыйгаларны, ул чордагы геройлыкларны балаларга җиткерү — һәр шагыйрьнең патриотик бурычы. Тик сугыш турында язылган балалар китабында мин даими бер җитешсезлек күрәм. Сугышны без балаларга туп атулар, ур-ра кычкырып атакага барулар аша гына күрсәтергә тырышабыз. Бала шушы эпизодларны укыганнан соң, китапта күрсәтелгән геройлыкларны үзенең сугыш уеныңдагы геройлыклары белән бутый башлый. Шунлыктан ул «безнеке»ләрнең җиңәсен, фашистларның җиңеләсен алдан белеп тора. Шушы алдан белү мавыгуны юкка чыгара. Ә менә Шәүкәтнең «Солдат әби» дигән шигырен алыйк. Бала әби кешене батырлык күрсәтү өчен яралмаган дип уйлый. Карчыклар, гадәттә, сабыйларның үзләренә тиң. Алар йомшак, көчсез һәм вак-төяк йомыш кына башкара алучылар. Реаль әбинең сугыш вакытында самолеттан бомба ташлап йөрүче штурман булуы бала күңелендә көчле парадокс тудыра. Бала тетрәнә һәм шушы көтелмәгән хәл онытылмаслык булып сабый күңелендә саклanып кала. «Солдат әби» уйлап чыгарылган хәл түгел. Сугыш елларында Советлар Союзы

Герое Мәгубә Сыртланова җиңел бомбардировщикларда штурман булып очкан. Шагыйрь шушы факттан уңышлы файдалана алган.

Шәһәрләшү елдан-ел көчәя барганда, балаларны табигатькә якынрак тоту, аларны матурлык тоярга, сокланырга, җир йөзендәге тереклек һәм үсемлек дөньясын сакларга өйрәтү — безнең иң житди гражданлык бурычыбыз. Шәүкәт Галиевнең лирик герое — күп вакыт табигать кочагында. Балалар өчен шигырьләр бала тоя һәм аңлый торган сабыйлык дулкынында язылган. Кысла үз кыскычына эләккән бармакның авыртуын тоя. Тәгәрмәч эчендә йөгерүгә дучар ителгән тиен азатлыкны, урман иркенлеген сагына. «Аучылардан качып котылу өчен чыныгырга кирәк»,— дип уйлый куян һәм һәркөн физзарядка ясый. Керәшәләр һава бозылуы турында үзара борчылып сөйләшәләр (искиткеч көчле һәм тирән мәгънәле символ). Шагыйрьне туган төбәк табигате, анда яшәүче тереклекләр генә канәгатьләндерми. Ул балалар белән бергә сәяхәт кылып, аларга көнгерәләр, тәвә кошлары, зәңгәр зебрлар күрсәтеп йөри. Аның иҗатында күбәләк бер тәүлек эчендә дөньяның бөтен матурлыгын күреп, татып калырга өлгерә. Балалар, шигырь тыңлаганда, салкын чишмәләрнең чылтырап акканын, ак каеннарның язгы җилдә тирбәлүен, усак яфраклары сөйләшүен ишетеп, тоеп торалар. Шәүкәт Галиев иҗаты балаларга шатлык бүләк итә. Шундый мул, юмарт кул белән бирелгән шатлык сабыйларны бәхеткә ирештерә.

Халкыбызның ничә мең еллар бөртекләп җыйган, шушы көнгә кадәр күз нурыдай саклаган тел байлыгын балалар аша киләчәк буыннарга тапшыру да безнең гражданлык бурычыбыз. Халык телендә күп буыннарның яшәү тәҗрибәсе, ата-бабаларыбызның рухи казанышлары, халыктагы мөнәсәбәтләр җылылыгы, күңел моңы һәм башка искиткеч кыйммәтле хәзинәләр сакланып калган. Шушы байлыкларны балаларга тапшыру буенча да Шәүкәт Галиев күп еллар буе уңышлы эшләп килә. Ул нәниләр белән бергәләп туган тел стихиясенә керә, андагы төрле нечкәлекләрне, тылсымнарны күрсәтеп йөри. Татар әдәбиятында балалар этимологиясен беренче булып уңышлы рәвештә куллана башлаучы да Шәүкәт Галиевтер дип уйлыйм мин. Бу — үзе бер зур тема. Сарык йоны алырга көйләнгән «сарыкмахерская», суга чумуда беренчелекне алган «чумпион», көз житкәч «өзелә-өзелә» җәйне сагынучы алмалар, шапырынырга яратучы «Шапырҗан». Нинди генә тылсымнар юк шагыйрь иҗатында!

Иҗат процессында яңа сүз табу, аны уңышлы кулланып, укучыга җиткерү — әдәбиятта шактый сирәк очрый торган куанычлы хәл. Шәүкәтнең моңа да көче җитә. Шагыйрь тапкан неологизмнар шуклыкка, тапкырлыкка һәм эмоциональ җылылыкка сугарылганнар. Бәлки аларның шушы сыйфатлары онытылмаслык булып хәтердә калуга ярдәм итә торгандыр? Шагыйрьнең фантазиясе мөстәкыйль яши башлаган поэтик образлар тудыра алды. Оптимист Шәвәли, хәким Котбетдин, ялкау Камырша образлары тере кешегә әверелеп, безнең балаларыбыз арасында, алар белән уйнап, мәктәпкә йөри башладылар.

Шәүкәт Галиевнең әле җиң сызганып эшләгән чагы. Шат, тынгы белми торган оптимист талант һаман эзләнүдә. Аның иҗаты чор китергән үзгәрешләрдән артта калмыйча, алга бара. Үлгәннәрнең васыятен исәннәргә тапшырып, бер-беребезнең кадерен белергә өндәгән шагыйрьләр безгә бүген аеруча кадерле.

Мәскәү.

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**Журналыбызның быелгы 2 санында Р. Сафаров һәм Л. Леронов хатлары буенча тәрҗемә турында сөйләшү башланып киткән иде. Аннан соң сөйләшүне М. Рафиков, Р. Кукушкин, Н. Арсланов, Р. Юсупов, Ә. Баянов, Л. Хәмидуллин, Ә. Исхак, Р. Гатауллиннар дәвам итте.**

**Бу санда сүзне прозаик һәм драматург Фоат Садриев белән шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин ала.**

## Фоат Садриев:

— Иң мөһим нәрсәдән башлыйсы килә: кайсы язучыны, нинди әсәрне тәрҗемә итәргә? Бу процесс аерым шәхесләрнең иҗади инициативасына гына бәйлеме, әллә аңа билгеле дәрәҗәдә юнәлеш бирелергә, ул оештырылырга тиешме? Сүз дә юк, тәрҗемәче әсәрне бер телдән икенчесенә әйләндереп салучы машина түгел. Ул — билгеле культурага һәм әдәби зәвыкка ия булган иҗади шәхес. Тәрҗемә процессының уңышын, әлбәттә, ул тәшкил итә. Шуңа да карамастан, теге яки бу язучыны, әсәрне башка милләт халкына тәкъдим итү мотивлары тирәндәрәк ята. Аларны әлеге халыкларның иҗтимагый-политик тормышыннан, рухи омтылышларыннан һәм культура дәрәҗәләреннән эзләргә кирәктер. Фикеремне үземә танышрак әдәби фактларга таянып дәлиллисем килә.

Миңа революциягә кадәрге татар әдәбиятында М. Ю. Лермонтов әсәрләренең тәрҗемәләрен барларга һәм өйрәнергә туры килгән иде. Шул чакта бик кызыклы бер күренешкә тап булдым: Лермонтов поэзиясе бездә башлыча 1907—1910 елларда гына тәрҗемә ителә. 1907 елга кадәр аның нибары ике әсәре — «Ашик-Кериб» хикәясе (1897 елда) һәм «К деве небесной» (1906) шигыре татар телендә дөнья күрә. Ә инде 1907—1908 елларда «Бэла» һәм егермегә якын шигыре тәрҗемә ителә. Алар арасында «Парус», «Смерть поэта», «Выхожу один я на дорогу» кебек поэзиянең югары үрнәкләре бар. Габдулла Тукай да аның 12 шигырен тәрҗемә итте.

Хикмәт нәрсәдә? Ни өчен 1907—1910 елларда рус шагыйре безнең өчен «уң ягы белән торган» соң?

Билгеле булганча, зур күкрәүләр белән башланган 1905 ел революциясе бастырылгач, татар хезмәт ияләренең якты хыялын реакция сөреме каплады. Азатлык идеяләре үлмәсә дә, хыял тормыштан аерылды, халык өметләре реакция чынбарлыгы белән капма-каршы килде, аңа протест рәвешендә гәүдәләнде. Татар иҗтимагый фикерендәге шушы киеренкелек әдәбиятта *романтизм агымын* тудырды. Әлбәттә, аңа кадәр дә аерым романтик әсәрләр булган. Әлеге агым тарафдарлары — С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Н. Думави, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич һ. б. шәхес азатлыгы өчен көрәш ачтылар, изүгә протест белдерделәр, якты идеаллар эзләп билгесезлеккә ашкынучы бунтарь образын тудырдылар.

Яңа идея яңа форма да таләп итте. Ул чордагы мәгърифәтчелек рационализмы һәм дидактикасы романтик идеяне гәүдәләндерерлек форма түгел иде. Үзләренең идея-эстетик ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен татар язучылары XIX йөз рус әдәбиятына һәм Европа романтикларына мөрәҗәгать иттеләр. Пушкин, Жуковский, Плещеев, Гейне, Шиллер, В. Гюго әсәрләре тәрҗемә ителде. Әмма рус романтизмының күренекле вәкиле М. Ю. Лермонтов поэзиясен өйрәнү һәм тәрҗемә итү аеруча көчәйде. Бу һич тә очраклы хәл түгел иде. Лермонтовка, башка рус романтикларыннан аермалы буларак, Николай реакциясенең аеруча котырынган вакытында иҗат итәргә туры килде. Аның поэзиясендә әлеге эпохага хас булган ялгызлык һәм сагыш, протест һәм котылу чарасын эзләү мотивлары искиткеч дәреслек белән гәүдәләнде. Татар халкының да шундый караңгы дәвер кичерүе, шундый идеяләр белән януы Лермонтовны татар чынбарлыгына якынайтты. Аның поэзиясе үзенең идеяләре белән дә, художество чаралары белән дә татар милләтенә һәм яңа эпохага хезмәт итә башлады. Мин бер төрле эпохада бер иш язучылар гына, икенче эпохаларда икенче иш язучылар гына тәрҗемә ителә, реалист язучылар реалистларга гына, романтик метод вәкилләре романтик әсәрләргә генә мөрә-

җәгать итәләр дип расларга җыенмыйм. Реалистик әдәбият беркайчан да дөньяны танып белү, эстетик-тәрбия кыйммәтен югалтмый. Монда теге яки бу сәбәпләр аркасында милли әдәбиятларның үзара якынаюының аеруча көчәюе яисә йомшавы турында гына сүз бара.

Тәфсилләп сөйләвем юкка түгел. Хәзерге шартларда, идеология эшенең әһәмияте туктаусыз арта барганда, тәрҗемә фронты аның бик мөһим участогын тәшкил итә. Тәрҗемә, әдәбиятның барлык башка тәрләреннән аермалы буларак, *конкрет юнәлеш бирүне, махсус оештыруны сорый.* Әсәрне русчага тәрҗемә итү ул — татар әдәбиятын барлык совет халкына (аның аша бөтен дөньяга) тәкъдим итү булып тора. Бу — бик җаваплы эш. Чәчүлек орлыкны чүпчардан чистарткан, калибрлаган кебек, иң элек әсәр җентекләп *сайланырга* тиеш. Мин бу сайлауның механизмын белмим, анысына белүчеләр тукталыр. Һәрхәлдә, русча чыккан китапларны күргәч, бу эш тәрҗемә ителергә теләүче язучының күбрәк үз тырышлыгына бәйле түгел микән дигән уй туа.

Ә кем сайларга тиеш? Бәлкем, тәрҗемә секцияседер? Бәлкем Язучылар союзы һәм нәшрият каршында абруйлы бер комиссия кирәктер? Ләкин бер нәрсә бәхәссез: бу специфик тармак, әдәбиятның башка сфераларыннан аермалы буларак, әдәби агымны көчле фильтр аша уздыруны сорый. Миңа калса, бүгенге көндә бездә рус һәм дөнья прозасына ихтыяҗ зур. Ә менә бүгенге поэзия һәм драматургия өлкәсендә без үз «товарыбызны» дөнья базарына тәкъдим итә алабыз. Мәсәлән, былтыр Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»енең үзәк телевидение аша күрсәтелүе безнең өчен дә, барлык совет тамашачылары өчен дә вакыйга булмадымыни? Совет халкының рухи хәзинәсе татар милләте тарафыннан баетылуы түгелмени бу?! Фильтрдан әнә шундый хәзинә булырлык әсәрләр генә үтәргә тиеш.

Ярый, әсәр сайланды. Аны тәрҗемә итүдә иң мөһиме нәрсә? Журнал куйган сораулар арасында мондые бар: иң мөһиме эчтәлекне тулы килеш саклаумы, милли колоритны бирүме, метафораларны төгәл тапшырумы? Бу сорау кояшның нуры кирәгрәкме, җылылыгымы, яктылыгымы дигән кебегрәк тәэсир калдыра. Формадан башка эчтәлек юк һәм киресенчә. Киңәйтелгән бер метафора рәвешендә язылган әсәрләр аз түгел. Аларның идея-эчтәлеге дә, милли колориты да, тел-сурәтләү чаралары да шул метафора эчендә эрегән бит. Сорауны башкачарак куярга кирәктер: тәрҗемәдә эчтәлекне, милли колоритны, сурәтләү чараларын бертигез дәрәҗәдә төгәл биреп буламы? Аларның бердәмлегенә ирешү нәрсәгә бәйле? Минемчә, тәрҗемәченең интеллектына, әдәби зәвыгына һәм осталыгына бәйле. Ул үзе тәрҗемә итә торган язучының иҗат манерасын, әсәрен, әгәр шулай әйтергә ярасa, эстетларча нечкәлек белән тоярга, әсәрнең идея-проблематикасын, художество көчен һәм үзенчәлекләрен әдәбият галимнәре дәрәҗәсендә аңларга тиеш.

Тәнкыйтьне әдәбиятның намусы диләр. Тәрҗемәчедә әдәбиятның намусы белән фидакарьлегә берләшмиме икән? Язучыны, аның әсәрен башка телдә яңгырату өчен йөрәк кайнарлыгын сарыф итү, тау-тау сүз катламнары актару һәркемнең дә кулыннан килми. Аның хезмәте игенченеке кебек үк — иҗат җимешеннән барлык кешеләр авыз итә, ә кем көче кергәнне белүче сирәк.

Иң элек идеаль вариантны алыйк. Шигырьне — шагыйрь, прозаны — прозаик, драма әсәрен драматург тәрҗемә итә. Инде бу эш подстрочниксыз да башкарылса, ягъни тәрҗемәче ике телнең дә хасиятен белсә — бал өстенә май. Минемчә, идеаль вариантта да объектив югалтулар белән килешергә туры килә, алар котылгысыз.

Тәрҗемә — катлаулы процесс. Әйтик, Һ. Такташны А. Миних һәм күренекле рус шагыйре Е. Винокуров тәрҗемәсендә укыган бар. Берсе 1939 елда чыккан, икенчесе 1971 елда. Аларның аермасы — җир белән күк арасы. Е. Винокуровта инде Такташ бар. Ләкин ул әле һаман да гел үк «татарча» Такташ түгел. Рус телендә Тукай да тиешле яңгыраш ала алмады. Миңа калса, төп гаеп әлеге дә баягы подстрочник аша эшләүдәдер.

Тукайның «Пар ат»ын хәтерегезгә төшерегез:

Җиктереп пар ат,
Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер,
суккалап та тарткалап.

Бу ике юл — әсәрнең увертюрасы. Без тыпыр-тыпыр атлар чапканын ишетәбез, лирик геройның шул атлардай йөрәк ярсуы безне дә чолгап ала... А. Ахматова тәрҗемәсендә ул болай яңгырый:

Лошадей в упряжке пара,
на Казань летит мой путь;
И готов рукою крепкой
вожжи натянуть.

Атлар чапканын ишетәсезме? Юк, әлбәттә. Увертюра югалды, шуның белән бер

гә шигырьнең төп дулкыны — билгесезлеккә ашкыну тойгысы да югала. Лирик геройны бит пар ат түгел, ә язмыш арбасы билгесезлеккә алып чаба. Ул сагышлана да, курка да, нәрсәгәдер өметләнә де. «Пар ат» бик оста, белеп, ихлас күңелдән тәрҗемә ителгән, ләкин тәрҗемәче әсәрнең поэтик дулкынына, йөрәк музыкасына тулысынча кереп, көйләнеп бетә алмаган.

Бу кимчелек бүгенге шагыйрьләрне тәрҗемә итүдә дә күзгә бәрелә.

Поэтик әсәрне тәрҗемә иткәндә, минемчә, сүздән башламаска кирәктер. Әсәрнең поэтик дулкынын, шагыйрьнең *текст астында яткан күңел ярсуын* табу эшнең тәүге баскычын тәшкил итми микән? Шигырьнең беренчел элементы булган ритм шул чакта гына дөрес табыла, үзенә тел-сурәтләү чараларын «суыра». Шул күзлектән карaганда, Г. Тукайның «Пар ат»ы, рус теленә 8—7 иҗек үлчәме белән тәрҗемә иткәндә, ничегрәк яңгырар иде икән? Тукай димәктән, бөек шагыйребезнең тәрҗемә практикасын җентеклəбрәк өйрәнергә вакыт. Ул ирекле тәрҗемә итте. Ләкин Тукай үзе тәрҗемә иткән шагыйрь алдында беркайчан да бурычлы булып калмады. Ул шагыйрьнең күңел утын, аның кайнарлыгын укучыга илтеп җиткерү өчен оригиналдагы тел-сурәтләү чараларын көчәйтүдән, тыгызлаудан курыкмады, шигырь агышына бәйле рәвештә үзгәртте.

Текстка ябышып тәрҗемә итүнең нинди зур югалтуларга, төгәлсезлекләргә китерүен без яхшы беләбез. Алайса, бәлки ирекле тәрҗемәгә яшел урам ачаргадыр? Һич тә! Тәрҗемә эшенең магистраль юлы һәм эчтәлектә, һәм формада төгәллеккә, таңгаллеккә ирешү аша гына үтә ала. Ләкин хәзерге этапта ирекле тәрҗемәне дә арбадан ыргытып бәрергә ярамый. Ул башка мөмкинлек булмаганда кулланылырга тиеш. Ә нинди очрак соң ул? Аны билгеләүче критерийлар нәрсәдән гыйбарәт? Төп критерий — тәрҗемәнең оригинал рухын төгәл саклаган хәлдә художество ягыннан көчле тәэсир итүендә булса кирәк. «Пар ат»ның уникe сүздән торган беренче ике юлын татар кешесе бер укып чыга да мәңгегә-исендә калдыра. Ул аңардан котыла алмый, ул аның канына, җанына тарала. Ә менә җырлап торучы шушы ике юлны рус укучысына ничек итеп шундый ук куәтендә җиткерергә? Монда ирекле тәрҗемә ярдәмче була алмас идеме икән? Бәлкем аны дүртәр юллы ике строфа белән тәрҗемә итеп карарга-дыр? Ә бәлкем, гел башкачадыр...

## Гарифҗан Мөхәммәтшин:

— Тәрҗемә ул — бай әдәбиятыбызны ил мәйданына чыгару, бөек рус теле аша илебезнең башка тугандаш халыкларына җиткерү, дөнья күләмендә яңгырату (ә бит әдәбиятыбыз ул дәрәҗәгә лаек!) дигән сүз. Илебезнең төрле почмакларына таралып яшәүче үзебезнең татар халкының яңа буыны да еш кына туган әдәбиятын шул тәрҗемәләр аша бәяли.

Хәер, тәрҗемәнең әһәмиятен барыбыз да аңлыйбыз. Һәм барыбыз да зарланабыз. Хәтта тәрҗемә эшендә нәрсә яхшы, нәрсә начар, алай итсәң дөрес буламы, әллә болай итсәңме дип, искитмәле интеллектуаль югарылыкта акыллы бәхәсләр дә алып барабыз. Әмма нәкъ шушы рухта, шушы эчтәлектә барган бәхәсне мин инде әдәбиятны укый башлаганнан бирле беләм. Шушы ук рухта, шушы ук эчтәлектә. Димәк, ул зарланулар, ул сөйләшүләр тәрҗемәнең «тәрҗемәи хәлен» үзгәртмәгән. Ни өчен?

Тәрҗемә турында аңгәмәгә кушылган иптәшләрнең дә күбесенең фикере борчый мине. Хәтере калган сабыйны хәтерләтәләр. Имеш, әллә кайдагы дәү абруйлы тәрҗемә осталары (хәтта аларның исемнәре дә атала) татар әдипләрен тәрҗемә итмиләр. Ә бит шул ук Я. Смеляков, А. Солоухин, Я. Козловский, Л. Мартынов, Н. Гребнев, В. Чивилихин һ. б. безнең күп әсәрләребезне рус теленә менә дигән итеп яңгыраттылар. Димәк, безнең «тауларыбыз» бар.

Бу мәсьәләгә кагылган һәр язмада диярлек — моңа кадәр кылынган тәрҗемәләр тиешле яңгыраш тапмады, аларның сыйфаты түбән булды, дигән зар ишетелә. Узган съездда Гариф Ахунов үз докладында да шушы фикерне әйтте: «Такташны Л. Мартынов тәрҗемә итте. Әмма ул Такташның трибунлыгын бирә алды, ә моңын яңгырата алмады». Шундый мөһер сугып торганда «таулар» безнең янга бик килеп тормаслар шул.

Әйтәсе килгәнем шул — безгә абруйлы, зур тәрҗемәчеләрнең килгәнен көтеп торырга түгел, аларны табарга, алар белән иҗади дуслыкны ныгытырга, ярдәм итәргә, аларга карата миһербанлырак булырга кирәктер. Һәрхәлдә тәрҗемәченең эшендә җитмәгән якларны гына табып тору эшне уңайга алып бара алмый. Шундый чагыштыру урынлы булыр — рус телен менә дигән итеп белсәләр дә, әдипләребезнең бик азы гына рус әдәбиятын татар теленә тәрҗемә итүдә катнаша. Ә менә татар телен бөтенләй белмәгән рус әдибенең татар әдә-

биятын тәрҗемә итү эшенә алынуын ничек бәяләргә? Бу иҗади батырлыктыр. Һәм андый кеше милли колоритны колачлауда да, тел стихиясенә һәм нечкәлекләренә үтеп керүдә дә, безне бик борчыган моңны үзләштерүдә дә безнең иң эшлекле, дусларча ярдәмебезгә лаек. Һәм мохтаҗ, билгеле.

Моң дигәннән, бездә аны татар әдәбиятына гына хас булган, башка телдә аңлатып булмый торган серле-сихри нәрсә итеп күзаллау гадәткә кергән. Ә бит шундый тирән, үзәк өзгеч моң рус әдәбиятында да, башка әдәбиятларда да җәйрәп ята. С. Есенинны гына алыйк. Аның шигырьләрен укыганда, еш кына Һ. Такташ, Х. Туфан яки башка үз милли шагыйрьләребез алып кергән моң дәрьясына кереп чумганыңны сизми дә каласың.

Мин Чыңгыз Айтматов әсәрләре белән рус телендә таныштым. Бу бөек әдипнең һәр әсәрендә чайкалып-мөлдерәп торган моң шулкадәр тирән, шулкадәр нечкә һәм тәэсирле, әсәрне беренче генә түгел, кабат-кабат укыганда да җанны пара-пара китереп уйга сала.

Уйланыйк әле, тәрҗемә мәсьәләләренә кагылган чыгышларның күбесендә тәрҗемә уңышлы булуның иң әһәмиятле шарты итеп: тәрҗемәченең авторга хас кешелек һәм иҗади сыйфатларын, аның эстетик дөньясын, иҗат кредосын һәм лабораториясен һ. б. бик күпне белүе атала. Аннан соң бит әле тәрҗемә ителәсе әсәрнең тәрҗемәче өчен авторның үзенә булган кебек үк якын, үз булуы, тәрҗемәченең иҗади зәвыгына туры килүе кирәк.

Тәрҗемәләребездәге уңышсызлыкларның иң зур сәбәбе, билгеле, аларның күпчелек очракта татар телен, татар культурасын, татар дөньясын белмәүчеләр кулы белән башкарылуында. Мондый тәрҗемәче үз алдына нинди генә зур максат куймасын, нинди генә зур сәләткә ия булмасын — уңай нәтиҗәгә ирешә алмый. Чөнки ул әсәрнең үзе белән түгел, аннан эшләнгән ярымфабрикат-подстрочник белән эш итә. Дөресен әйткәндә, ул телнең нечкәлекләрен, образлы гүзәл бормаларны, милли бизәкләрне һәм башка бик күпне сиземли дә алмый. Әсәрнең рухына, җанына үтеп керү турында сүз дә була алмый. Әнә бит, Л. Мартынов булып ул да ирешә алмаган моңа.

Болардан гади генә нәтиҗә чыга — әгәр дә үз милли әсәрләребезнең рус телендә тулы җегәрендә яңгыравына ирешергә теләсәк, аларны үзебезнең татар әдипләре тәрҗемә итү кирәк. Бәлки моннан 30—40 ел элек мондый таләпне кую урынлы да булмагандыр. Ә бүгенге көн әдипләребезнең күбесе рус телен туган теле дәрәҗәсендә белә, су кебек эчә. Эшкә алыну гына кирәк.

Бездә еш кына зур шагыйрь яки язучы булу оста тәрҗемәче булу түгел әле ул, диләр. Килешеп булмый бу фикер белән. Әнә бит, үз әсәрләребезне русның иң зур әдипләре тәрҗемә итүен таләп итәбез. Нигә соң үзебезгә дә таләпнең шундый зурын куймаска?

Үз фикеребезне раслау өчен без еш кына халык акылына мөрәҗәгать итәбез. Ә тәрҗемә мәсьәләсендә халыкның фикере катгый һәм икеләнүгә урын калдырмый. «Татарга тылмач кирәкми!» — дигән халык.

Бездә тәрҗемәче хезмәтенең тиешенчә бәяләнмәве, аңа үзе иҗат итә алмаучылар эше итеп, кимсетеп карау да, бәлки, күпмедер сәбәптер? Ә бит «Мокамайны» чын Такташча рус телендә яңгырату нинди дер уртакул яңа әсәр иҗат итүдән түбән эш түгел! Шундый гына мисал китерим — газета һәм журналларда язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең тормышы һәм иҗаты турында еш кына языла. Ә минә нинди дер зур тәрҗемәчебез турында мин андый язманы укыганымны хәтерләмим. Мәҗит ага Рафиков чыгышын укыгач («Казан утлары», № 3, 1986 ел), мин таң калдым. Менә нинди зур талант, хезмәт, күңел байлыгы, җан олылыгы кирәк икән тәрҗемәче булу өчен. Ул чыннан да иң олы иҗатчы икән. Димәк, хөрмәте дә шулкадәр үк булырга тиеш.

Халкыбызга рухи байлык итеп үз иҗатын калдырып, күпме олы әдипләребез дөньядан киткән. Алар инде үз иҗатларын башка халыкларга җиткерү турында кайгырта алмыйлар. Бу — исәннәрнең изге бурычы. Әдәбиятка яңа буыннар, яңа талантлар килә. Аларның күпме гүзәл әсәрләре татар дөньясыннан чыга алмый ята. Тәрҗемә өлкәсендә эшлиселәребез кими түгел, арта гына икән. Үзебездә тәрҗемәчеләрнең ышанычлы корпусын булдыру — көн таләбе. Әдәбиятыбызның штабы булган Язучылар союзы идарәсенә бу мәсьәләгә җиң сызганып алынырга һәм тәрҗемәнең «тәрҗемәи хәленә» яңа, яктырак сәхифәләр язу юлларын табарга кирәк. Бүген үк, иртәгә калдырмыйча!

# ШАГЫЙРЬЛЕКНЕҢ ИКЕ КАНАТЫ

Чор, шәхес һәм шагыйрь... Шушы өч төшенчә торган саен ешрак уйландыра аны. «Хикмәт шушы бәйләнештә,— дип яза ул.— Шуңа карап, шагыйрьнең олылыгы, кешелеклеге, батырлыгы, гражданлыгы беленә. Тумыштан талантлы кешеләр байтак. Шигырьгә дә сәләтле яшьләр, шөкер, килеп тора. Яхшы гына башлыйлар. Еллар үтә. Карыйсың, әйе, шомарган, чарланган, оста яза, ә әдәбиятта үз йөзе, үз эзе юк. Бу нидән? Баксаң, аның чорга, яшәешкә кеше буларак үз ачык мөнәсәбәте, үз иҗади платформасы юк икән, язганында үз шәхесе, үз гражданин «мин»е юк икән».

Шигърият һәм шәхес турындагы бу уйлануларның авторы шагыйрь Равил Фәйзуллинның соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән яңа китаплары[1] хакындагы сүзне шул рәвешле үзенә мөрәҗәгать итүдән башлау урынлы тоелды. Чөнки иҗади шәхеснең чор турында һәм шул чорга лаек җырлар язу хакындагы принципиаль уйланулары аның үз иҗатына тәнкыйди мөнәсәбәтнең дә критерийларын билгеләргә ярдәм итә.

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның иseме матбугат битләрендә күренә башлап, аның һәр яңа адымы әдәби тәнкыйтьтә җанлану һәм фикер каршылыклары уята килгән көннәргә инде ике дистә чамасы ел узып бара икән. Вакыт мәрхәмәтсез, ул үзенекен итә, аның үз законнары... Әмма шуңарга да карамастан, Р. Фәйзуллин исеме һәм иҗаты бүген дә гомум игътибар үзәгендә. Фикер каршылыклары һәм бәхәсләр дә һаман дәвам итә. Хәтта, «яшь шагыйрьләр» дигәндә, бу исемлекне янә аңардан — Р. Фәйзуллиннан башлап китәсе килгән чаклар була, әздән тыелып каласың. Һәм бу табигый да, чөнки шагыйрь үзенең яшьлеккә генә хас беренчел сыйфатларын — өзлексез эзләнүләрен, форма яңалыгы һәм фикри кыюлыкка, шигырьдәге һәр сүзгә мөмкин кадәр күбрәк җегәр салырга омтылып иҗат итү кебек үзенчәлекләрен югалтмады, саклап калды. Мисал өчен, «Кавказ күренеше» дип исемләнгән шигырьне китерик:

Каршымда, күз алдымда —
итәгендә ак болытлар
утлап йөргән мәгърур таулар.

Күңелемдә —
Туган якның яшел үрендәге
оя-оя ап-ак казлар...

Беренче кат укыганда, ничектер, тел көрмәкләнеп алгандай була, сагайта төшә бу юллар. Кайчандыр, моннан дистә еллар элек, шагыйрьнең «Нюанслар иле»н укыгач туган халәт искә төшә. Ул елларда Р. Фәйзуллинның байтак кына нюансларын телдән төшерми, шагыйрьне «аңлаешсызлыкта», шигырь исеме белән уйнап, экспериментлар ясауда гаепләүләр байтак булды. Һәм ул тәнкыйть фикерләрен бөтенләй урынсыз иде дип бәяләү мөмкин түгел. Шулай да бер нәрсә ачык — шагыйрь эзләнә, шигъри сүзнең идея-эстетик җегәрлегенә ирешү юлында кыю адымнар ясый иде.

Шул чорда аңлаешсызлык үрнәге буларак еш кына мисалга китерелгән бер шигъри «нюанс»ны хәтергә төшерик:

ТУЛАЙ ТОРАКТА

Кызлар күптән йоклый.
Кефир шешәсендә гөлләр
таңны көтә.

Кемгә ничек, әмма бүгенгәчә күңелдән чыкмый хәтердә сакланып килгән бу юллар. Һәм аларны һич кенә дә бушлыкта яисә башка бер житешсезлектә гаепләргә мөмкин түгел. Игътибар итик, нибарысы өч юл, сигез сүз. Рифмасын китереп такмаклый-такмаклый, дилбегә буе язылган шигъри язма-

---

[1] Р. Фәйзуллин. Җырларда — ил гаме. Әдәби-публицистик мәкаләләр һәм юльязмалар. Татарстан китап нәшрияты, 1984; Р. Фәйзуллин. Яктылык. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты, 1985.

лар янәшәсендә бу — «чүп» кенә. Яшеренбатырын түгел ич, шигырьгә кытлык юк соңгы арада. Әмма җанны кузгатып, акылны, рухны үзенә иртәргә сәләтле шигъри сүзгә ихтыяҗ зур.

Дөрес, «Тулай торакта»— колачлы проблема яисә ярсу хисләр өермәсе алып килгән шигырь түгел. Шулай ук эч пошканнан сырлап куелган такмак та түгел ул. Аның үз формасы, җилкәсенә таман күтәргән үз йөге бар. Иң элек, аның шундук җанлы бер картина, этюдны хәтерләтүен инкяр итеп булмый. Ә бу исә, инде үзе генә дә, шигырь эстетик җәгаргә ия дигән нәтиҗәгә нигез бирә. Икенчедән, хис, тойгы һәм рухи халәттән өлешсез калган дип тә әйтү мөмкин түгел ул юлларга карап. Кызлар йокысы, кефир шешәсендә бөреләнгән гөлләр, яз рухы һәм якынлашып килгән таң... Болар, янәшә килеп, күз алдында тагын бер сурәт тудырып гына калмыйлар, ә күңел кылларына кагылып узалар. Туачак таң белән бергә кефир шешәсендәге гөлләр генә түгел, буй җиткергән яшь кызлар да уяначак. Шул мизгелне керфек тә какмый көткән егет образы да төсмерләнә сыман... Кыскасы, ул юллардагы детальләр күңелендә шигъри рух йөрткән укучы өчен байтак зур тәэссорат җирлеге булып тора.

Инде шагыйрьнең яңа әсәре — «Кавказ күренеше»нә кайтсак, анда да без шигъри сүзгә соң дәрәҗәдә талымлылык белән очрашырбыз. Чит җирләрдә туган якны сагыну хакында аз язылмаган, әмма, миңа калса, Р. Фәйзуллинның бу шигырендә нибарысы бер деталь белән күңелне кузгатырлык картина тудырылган. Кавказ итәгендә утлап йөргән ак болытлар һәм туган авылы каршындагы тау битендә оя-оя казлар... Шушы ике күренешне янәшә куеп, укучы алдында иксез-чиксез ассоциацияләр өчен җирлек тудыра шагыйрь.

Әйе, «җирлек тудыра»! Р. Фәйзуллин укучыга «чәйнәп каптыру» юлын һичкайчан тотмады. Аның карашынча, яңа шигъри әсәр белән очрашкан һәр укучы үзе үк иҗат процессына килеп кушылырга тиеш. Иҗади фикер йөртергә, шагыйрь билгеләп үткән нокталарны үз пунктирлары белән тоташтырырга сәләтле укучыга йөз тота ул. Аерым алганда, әлеге фикерне Р. Фәйзуллин тәнкыйтьче И. Нуруллин белән үткәргән әңгәмәсендә дә язып чыкты.

Бездә вакыт-вакыт Р. Фәйзуллинны татар поэзиясенең күп гасырлык традицияләре белән хисаплашмыйча, үзенчә бер мактәп тудырырга омтылган, каш ясыйм дип, күз чыгарган дигән сыманрак бәяләүләр дә булгалады. Миңа калса, бу — нигездән хата фикер. Борынгы төрки-болгар традицияләреннән, Йосыф Баласагунлы һәм Кол Галиләрдән, Тукай һәм Дәрдмәндләрдән килүче шигъриятебезне лаеклы дәвам итүчеләрнең берсе бит ул асылда. Һем шагыйрь үзенең шушы магистраль юнәлешнең дәвамы булуы белән горурлана да ала.

Шагыйрь исеме һичкайчан шигырь язучы дигәнне генә аңлатмаган. Гәрчә бездә шулай уйлап хаталанучылар да байтак! Шагыйрь, инде югарыда билгеләп үтелгәнчә, ул — гражданин һәм шәхес дигән сүз. Заман һәм халкың алдында җаваплылык дигән сүз. Шуңа күрә дә чын шагыйрьнең иҗаты бик сирәк очракларда гына шигырь кысаларына сыешырга мөмкин. Әдәбиятыбыз тарихын барласак, без шундый хакыйкать белән очрашырбыз: аерым бер этап барлыкка китергән олы шагыйрьләр бер үк вакытта ялкынлы публицист, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе һәм туры сүзле тәнкыйтьче дә булганнар. Тукай, Такташ, Җәлил мираслары бу җәһәттән дә гыйбрәтле үрнәк булып тора. Бүгенге совет поэзиясенең авангардын тәшкил иткән Е. Евтушенко, Е. Исаев, Р. Гамзатов, М. Кәрим, С. Хәкимнәрнең күп тармаклы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге дә шуны раслап килә. Чор, халык, әдәбият язмышына һәм проблемаларына битараф калып, әкәм-төкәм кебек, үз кабыгына кереп бикләнгән шигырь чыгаручы шагыйрь буламы икән?!

Бу хакта, замандашлары һәм каләмдәшләре өчен дә җаваплылык тоеп, еш кына уйлануларга бирелә шагыйрь Р. Фәйзуллин. «Без үзебез кемнәр соң? Бүгенге тормышта тоткан урыныбыз һәм яңа җәмгыять төзелешенә керткән өлешебез ниндирәк? Үзебезгә үзебез куйган таләп, бәя, чыннан да, объектив, дөресме?.. «Шагыйрь» дигән төшенчә үз замандашыбыз уенда, дөресен әйтик, төрле тойгылар уята, шул исәптән, ул тойгыларда, ихтирам белән бергә, берникадәр көлемсерәү төсмере дә юк түгелле-ген онытмыйк. Нигә алай соң?»

Сүз дә юк, сораулар — урынлы, борчылулар да... Димәк, әдәбият алдында, һәр шагыйрьнең генә түгел, һәр шигъри сүзнең дә урынын фактларга туры карап бәяли бару ихтыяҗы туган. Р. Фәйзуллин үзе үк билгеләп үткәнчә, «Шагыйрь урта кул була алмый. Шагыйрь бар яисә ул юк». Әдәби җәмәгатьчелеккә һәм тәнкыйтькә бу кырыс хакыйкатьне инде тирәнтен аңларга вакыт икәнлекне искәртә әлеге уйланулар.

Р. Фәйзуллин үзенең шигъриятта очраклы шәхес түгеллеген «Җырларда — ил гаме» дигән әдәби тәнкыйть һәм публицистик ма-

каләләр җыентыгы белән янә бер кат исбатлый. Әйе, аңлашылса кирәк, тәнкыйть эшчәнлеген һәм публицистиканы мин шагыйрьнең шагыйрьлеген билгеләгән, аның гражданлык йөзен күрсәткән төп критерийларның берсе дип саныйм. Юк, очраклы исемнәр, бүген укылып та, иртәгәсен онытылачак әсәрләр тирәсендә әйләнми шагыйрьнең тәнкыйть сүзе. Тукай поэзиясенең халык язмышындагы урыны һәм аны пропагандалау юнәлешендәге кичектергесез проблемалар борчый, Җәлилнең иҗат һәм шәхси каһарманлык үрнәге сокландыра, Г. Кутуй, Х. Туфаннарның әдәбиятыбыз барышындагы кабатланмас урыны уйландыра аны. Шулай ук бүгенге татар шигъриятенең алгы сафында баручы С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Афзаллар иҗатына багышланган махсус хезмәтләр яза, чордашлары, замандашлары Ш. Галиев, С. Сөләйманова, И. Юзеев, М. Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Харис, Г. Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов һәм Зөлфәтләр иҗатына үз мөнәсәбәтен белдерә шагыйрь. Шигъри хәрәкәт хакындагы фикерләр проза, драматургия язмышы, әдәби тәнкыйть алдында торган проблемалар хакында уйланулар белән алышына. Сәнгатьнең башка төрләре, республикабызда, Туган илебездә һәм дөньяда барган киеренке вакыйгалар — болар һәммәсе шагыйрь публицистикасы һәм шагыйрь тәнкыйте үзәгендә.

Миңа Р. Фәйзуллинның прозаик һәм драматург Ш. Хөсәенов иҗаты хакындагы сүзе аеруча гыйбрәтле тоелды. Бер уйласаң, ифрат дәрәҗәдә аз яза торган бу әдип иҗатының игътибарга алынуы очраклы саналырга хаклы. Әмма ашыгып нәтиҗә ясамыйк, сүз «Мәхәббәт сагышы» повесте, «Профессор кияве», «Зөбәйдә — адәм баласы» һәм «Әни килде» кебек, һәркайсы әдәбиятыбыз барышында игътибарга лаек вакыйга сыман кабул ителгән әсәрләр авторы хакында бара икән ич. Әдәбиятта исә эшләнгән эшне сан белән түгел, сыйфат белән бәяләр вакыт житкән. Хәер, бу элек-электән шулай. Кызганыч, вакыт-вакыт без бу хакта оныткалап куябыз.

Шагыйрьнең «Җырларда — ил гаме» һәм «Яктылык» китапларын янәшә куеп фикер йөрткән тәнкыйтьчегә кемдер сорау бирергә мөмкин: Р. Фәйзуллин үзенең публицистикасында Ватан һәм халык алдындагы бурыч хакында зурдан сүз йөртеп тә, шигъриятенә килгәндә, бу хакта, ни өчендер, бик аз уйлана түгелме? Урынлы сорау. Чынлап та, элгәрерәк елларда Р. Фәйзуллин бу җитди темаларга ешрак мөрәҗәгать итә иде. Аның «Гадиләргә гимн» һәм «Көрәшчеләр» поэмалары да турыдан-туры моңарга дәлил булып килә ала. Ә «Яктылык»та исә, беренче карашка, «зурдан сүз йөртү» бөтенләй күзгә дә ташланмый кебек. Һәм, гомумән, шагыйрь соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрендә тематик киңлеккә һәм күзгә ташланып торган гражданлыкка омтылмый да башлады түгелме? Әмма бу шикләнүләрнең урынсыз икәнлеген шундук билгеләргә кирәк. Чөнки шагыйрь әлеге изге төшенчәләр хакында турыдан-туры сөйләмәсә дә, үзенең фәлсәфи һәм лирик күзәтүләргә корылган әсәрләрендә кеше булу, Җирдә яшәү һәм сөя-сөелә белүнең гүзәллеге хакында яза.

Бу җырлар — бәгырьнең
кылына тиюем.
Бу җырлар — гомерем,
нәфрәтем, сөюем.
Тормышны мин шулай
аңлыймын диюем.

Ихластан әйтелгән юллар. Һәм шагыйрьнең «бәгырь кылы»ннан ишетелгән моң, нәфрәт һәм сөю авазы укучыны битараф калдыра алмый — уйландыра, бәхәсләшергә этәрә, күңелдә матур тойгылар уята. Мисал өчен, нибарысы берничә шигъри табыш — этюдлар китереп узыйк:

Унбер яшьләр булыр, бер кыз килә,
кәрҗин асып.
Иелеп-иелеп,
кабырчыклар чүпләп ала.
Ярда йөргән акчарлакмыни!

(«Әдрән диңгез яры. Иртә таң»)

Табигатьнең бөек яңарышка
әзерлеге тоела һәркайда.
Хәтта очкан кара каргаларның
күләгәсе зәңгәр бу айда.

(«Март ахыры»)

Шундый тынлык! Ишетелә кебек
үрмәкүчнең җәтмә үргәне!..

(«Тансык тынлык»)

Әлбәттә, Р. Фәйзуллин тудырган мондый шигъри этюдларны кабул итү һәм аларга салынган эстетик җегәрнең рухына күчүен тою өчен күңелнең, җанның билгеле бер шигъри дулкынга, акылның образлы актив фикерләүгә көйләнгән мизгеле булырга тиештер. Хәер, теләсә нинди сәнгать әсәре, шул исәптән иң камил шигъри әсәрләр дә, тиешле рухи халәт тудырылмый икән, игътибардан читтә калырга мөмкин. Шулай да, чын шигырь һәм шигъри образ битарафлык-

ны җиңү һәм оныттыру юнәлешендәге тәүге адымны үзе ясый. Шагыйрьнең «Яктылык» китабындагы байтак әсәрләрнең шул рәвешле актив җәлеп итү сәләтенә ия булуына ышанасы килә.

Шулай да шагыйрьнең яңа җыентыгындагы рухи яктылыкны рәссамнарга хас осталык белән тудырылган гүзәл картина, этюдлар белән генә чикләргә ярамастыр. Монда дөньядагы вакыйгаларга, илдәге үзгәрешләргә актив мөнәсәбәт тә һәр даим сизелеп тора, кеше күңелен тагы да баерак, тирәнрәк итеп күрүгә омтылыш, мәхәббәт хисенең олылыгын раслау да күз уңында. Халык язмышы, үткәнгә һәм киләчәккә мөнәсәбәт тә үзенчәлекле шигъри детальләрдә чагылыш таба. Мисалга, күләм җәһәтеннән зур булмавың искә алып, «Теплоходта узып барышлый» дип исемләнгән шигырьне китереп узасы килә:

Ярлардагы сыр-сыр катламнар —
ерак гасырларның эзләре.
«Үткәннәр гел өнсез түгел!» —
дигән кебек
атылып чыкты ярдан карлыгач!

Тарих проблемаларына актив мөнәсәбәттә булган замандашны сискәндереп куярга сәләтле шигырь. Ярдагы оясыннан очып чыккан карлыгач бу очракта, әйтерсең лә, тарихтан килгән гыйбрәт сыман кинәт бәгырьгә килеп кадала, битарафлыкны оныттырып, күңел күзен актуаль заман проблемаларына юнәлтә.

Әмма шул ук шигырьне икенче берәүнең бөтенләй башкача кабул итүе дә ихтимал. Инде югарыда искәртелгәнчә, Р. Фәйзуллин шигырьләре билгеле бер актив рухи халәткә, иҗади дулкынга көйләнгән булуны таләп итә. һәм шул очракта гына укучы үзе өчен эстетик матурлык һәм идея тирәнлегенә ия яңа образлар дөньясы ачылуын тоя. Гомумән, бу иҗатны йокымсыраган халәттә кабул итеп булмый. Актив поэзия укучыдан да актив мөнәсәбәт таләп итә.

Татар әдәбиятын ил киңлекләренә һәм аннан дөньяга шигъриятебез алып чыккан. Бүген Туган илебезнең теләсә кайсы төбәгенә генә түгел, ерак дәүләтләргә барып чыкканда да, конкрет исемнәр атап, татар поэзиясе хакында олыдан сүз әйтергә мөмкин. һәм сине аңлаячаклар! Чөнки Тукай исеме, Җәлил исеме күпләргә мәгълүм. һәркайда хөрмәт, соклану белән искә алына. Ниһаять, мәшһүр Кол Галинең рус телендә күркәм китабы булдырылды (тәрҗемәчесе Сергей Иванов). Әмма, кызганычка каршы, һ. Такташ, Х. Туфан һәм Ф. Кәримнәр иҗаты бүгенгәчә үз хәзинәбез генә булып кала. һәм бу хәл әдәби җәмәгатьчелекне борчып кына калмаска тиеш, кичектергесез чаралар күрергә дә вакыт. Р. Фәйзуллин урынлы билгеләп үткәнчә, «рухи байлыгың бар икән, аны бүтәннәр белән бүлешү гаеп түгел ич!»

Бүгенге замандашларыбыздан шигъриятебез аксакалы С. Хәким иҗатының рус телендә лаеклы яңгыраш алуы да гомум әдәбият казанышы саналырга хаклы. С. Хәким шигырьләре рус теле аша күп кенә тугандаш телләргә дә тәрҗемә ителде. Соңгы елларды татар балалар әдәбиятында уникаль күренеш саналган Ш. Галиев әсәрләре дә, ниһаять, үз тәрҗемәчеләрен тапты. Аның әсәрләре дөньякүләм танылу юлында.

Күп дисталәгән шагыйрьләребез бар дибез... Тагын кемнәр? Тагын нинди әсәрләр күпмиллӛтле совет әдәбиятының уртак казанышына әверелү юлында соң? Рус телендә лаеклы яңгыраш алган Р. Харис иҗаты һәм, әлбәттә, Р. Фәйзуллин... Юк, ихлас һәм эчкерсез моңнары белән туган телебездә гүзәл яңгыраш тапкан күп кенә талантлы шагыйрьләребез иҗатын санга сукмау булып аңлашылмасын. Чын шагыйрьләр бездә байтак. Ә менә шуларның ике-өч меңле тираждан артмый чыккан китапларын күрү җиңел түгел. Нигә киңрәк масштабта яңгырамый соң әле алар?!. «Үз өеңдә «мин!» дип күкрәк кагу — бер хәл, ә дөнья күләмендә үзеңнең барлыгыңны горур белгертә алу — үзе бер дәрәҗә». Р. Фәйзуллинның гомум милли культурабызга карата әйтелгән бу сүзләре бүгенге поэзиябез турында сөйләшкәндә дә урынлы яңгырый булса кирәк.

«Яктылык» китабына килсәк, анда чын мәгънәсендә шигърилеккә ия байтак кызыклы яңа әсәрләр урын алган. һәм алар, шулай ук, тиз арада үз тәрҗемәчеләрен табып, тагы да киңрәк шигъри бәйгегә чыгарлар дип ышанасы килә. Шулай да бу уңайдан бер нәрсәгә игътибарсыз киту мөмкин түгел: соңгы арада Р. Фәйзуллин үзенең әсәрләренә исем биргәндә алынма сүзләргә урынлы-урынсыз мөрәҗәгать итү белән мавыга шикелле. Әйтик, «Мираж (ностальгия)», «Элегия», тагы бер тапкыр «Ностальгия», «Сентенция», «Метаморфоза», «Си минор», «Затонда». Әлбәттә, бүгенге татар укучысына чит төшенчәләр диним аларны, киреңсә, сүзлекләр дә кул астында гына. Шулай да туган телебездә иҗат ителгән шигырьләр өчен башка исемнәр дә табу мөмкин булыр иде кебек. Бу кадәресе урынсыз мавыгу тәсләрәк кабул ителә.

Шагыйрьнең яңа җыентыгында лирик ки-

черешләр һәм хисләргә дә мул урын бирелгән. Нечкә зәвык белән иҗат ителгән эчкерсез мәхәббәт лирикасыннан да матур үрнәкләр байтак. Күңелнең тулышкан, хисләрнең ургыган мизгел-халәтен укучыга җиткерүдә Р. Фәйзуллин каләме аерым көчкә ия. Шундый үрнәкләрнең берсен укучы хөкеменә тәкъдим итми узу кыен:

«Ничекләр киләсе булдың
өмет тә итмәгәндә?
Килдең менә, үрелергә
инде кул җитмәгәндә...

Син! диеп янган идем бер
яшьлектә, көтмәгәндә...
Шуннан соң егерме еллап,
әйтерсең, үтмәгән дә!
...Ничекләр киләсе булдың
өмет тә итмәгәндә?!»
Ничекләр китәсе булыр! —
яшьләрем кипмәгән лә...

Мәхәббәт лирикасында шагыйрьнең сүзләре канатлана төшә, бер карашка җиңеләя дә сыман. Әмма шигъри сүз һәм строфаларның киеренкелеге бу очракта да югалмый, аларның һәркайсында аерым бер эчке җегәр сиземләнә.

Әдәбиятыбызда Тукайлар чорыннан килгән бер матур традиция бар — балалар өчен әсәрләр иҗат итүне намус эше санау. Балалар әдәбияты — аерым фидакарьлек һәм гражданлык хисе таләп итә торган өлкә. Әлеге сыйфатлар аңарда ныграк та сынала. Анализлана торган һәр ике китапта балалар әдәбиятына аерым урын бирелгән. Публицист һәм тәнкыйтьче буларак үзен чын мәгънәсендә борчыган бу проблемага Р. Фәйзуллин шагыйрь буларак та даими игътибар юнәлтеп килә, һәм аның балалар өчен язган әсәрләре, миңа калса, шулай ук җитди игътибарга лаек. Шагыйрьнең нәни укучылар белән баласытып түгел, ә фикердәше сыман үз итеп, үзенә тиң итеп сөйләшүгә корылган шигырьләре күпкә кызыклырак.

Чор, шәхес һәм шагыйрь төшенчәләре, аларның үзара бәйләнеше һәм аерылгысыз бөтенлеге хакындагы уйланулардан башланган иде бу язма. Инде аны тәмамлаганда, янә шушы бергәлеккә кайтасы килә, чөнки шагыйрь, публицист һәм тәнкыйтьче буларак, Р. Фәйзуллинның соңгы еллардагы иҗат эшчәнлеген барыннан да элек шушы үзенчәлек характерлый. Шәхес һәм шагыйрь буларак бүгенге чорның каршылыкларын һәм кичектергесез проблемаларын аңлый алган һәм шуларны замандашларының күзенә туры карап ачып бирү сәләтенә ия каләмдәшкә иҗат уңышлары, фидакарьлек һәм яңа биеклекләргә күтәрелүен генә телисе кала.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.**

*Конкурска*

# КЕМНӘР АЛАР — «ҺӘМ БАШКАЛАР»?

Балалар-яшүсмерләр прозасы яшь буынны героик рухта тәрбияләү, аларны батырлыкка әзерләү кебек мөһим темага игътибарын беркайчан да киметмәде. Бары әлеге теманы яктырту, аны киң катлам укучылар күңеленә якынайта төшү ысуллары гына үзгәрә төште.

Бер проблеманың берничә чишелеше булган кебек, балалар-яшүсмерләр прозасында да бу теманы яктыртуда ике юнәлешнең булуы үзен сиздерә. Г. Гобәй, М. Әмир, Ф. Яруллин һәм башкаларның әсәрләре, нигездә, тыныч тормышта да батырлыкка урын бар дигән принципка таянып иҗат ителгән. Әлеге язучыларыбыз батырлыкның әхлакый нигезен яшәешнең тирән катламнарыннан эзләп, чор герое образын көндәлек тормышыбыздан тапканнар. Г. Бакиров, А. Әхмәт, Г. Әпсәләмов, Ә. Давыдов, Ш. Рәкыйпов кебек язучылар иҗатында исә батырлыкның тирән тамырлары героик дәверләргә, илебез язмышы хәл ителгән елларга, аның рухи җегәре һәм матди куәтле сыналган дәһшәтле көннәргә барып тоташа.

Ә менә иҗатын тулаемы белән балалар-яшүсмерләргә багышлаган Ләбибә Ихсанова повестьларында әлеге ике принцип тигез дәрәҗәдә яши кебек. Язучы батырлык төшенчәсенең асыл билгеләрен революция елларыннан да таба, бүгенге заманның тыныч көннәреннән дә эзли. Нәтиҗәдә, ул иҗат иткән геройлар язмышы аша кырыс көрәш

романтикасы чагыла, чор гаме белән янып яшәүче шәхес сыйфатлары сизелмәнә.

Шушы уңайдан Татарстан китап нәшриятында чыккан «Наил, Фаил һәм башкалар» китабыннан «Гөлләр кояшка карый» дигән повестька тукталасы килә. Анда революция алды еллары, Казанда Совет власте урнаштыру көннәре, фетнә күтәргән милләтчеләргә һәм дин әһелләренә каршы аяусыз көрәш вакыты тасвирлана. Шушы вакыйгалар эчендә кайнаган балаларның «кояшка караган гөлләр кебек яктыга, белемгә үрелүләрен», аларның матур хыялларын күрсәтү максат итеп куелган.

Иске дөнья җимерелә башлаган көннәрне Л. Ихсанова балалар күңеле аша тасвирлый. Кайвакыт олылар да асылына төшенеп җитә алмаган вакыйгаларга балалар күзе белән карый. Аларның рухи кичерешләрен җентекләп анализлый, психологик үзенчәлекләрен нечкәләп сурәтли. Повесть геройлары табигый кабул ителә. Менә шуның бер мисалы. Балалар башта революцияне зурлар да мавыгып киткән галәмәт кызык бер уен дип уйлыйлар. Шул «уенга» үзләре дә катнашып китәләр. Чөнки ишегалдында бай сәүдәгәр булып уйнау аларны күптән туйдырып бетергән. Ә революция исә яңа, кызыклы, серле «уен». Өлкәннәр кебек митингларга йөрү, солдат чыгышларын тыңлау аларда ифрат зур соклану уята. Әмма социаль көрәш «уен» түгел икән. Балалар моңа эшче егет Әсәдулланың һәлак булуын күргәч төшенәләр. Шулай итеп, алар әлегә хәтле чын булып күренмәгән хакыйкатьне аңлыйлар. Социалистик революция тормышка яңалык алып килә, балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне дә тамырдан үзгәртеп куя. Мавыктыргыч уен, революция эшенә әверелеп, балаларның зиһенен ача, күңелләрен үстереп җибәрә. Балалар өлкәннәрнең яңа тормыш төзү өчен алып барган көрәшенә булыша башлыйлар, гомерләрен куркыныч астына куеп, кызылгвардиячеләргә хәрби пакет илтәләр. Бу җаваплы бурычны үтәгәндә, бер кыз бала авыр яралана. Фетнәчеләрнең хәрби берләшмәсе — тимер дружинаны эчтән таркатуда да алар зурларга ярдәм итәләр.

Җәмгыять тормышын яңабаштан үзгәртеп кору турындагы фәлсәфи-эстетик күзаллавын Л. Ихсанова әлеге образларда гына туплап калмый, революциянең чын мәгънәсендә балалар психологиясен яңарткан шифалы асылына да игътибар итә. Бу мәсьәләләрне чишкәндә, язучы тарихилык принцибына нык таяна. Ләкин аны бераз тирәнәйтәсе бар әле. Балаларга үрнәк күрсәткән революционер образлары эпизодларда гына чагылып китәләр. Аннары Казанның татар бистәләре урнашкан өлешендә Болак арты республикасы дигән нәрсә әвәләгән буржуаз милләтчеләргә каршы көрәш тә өстәнрәк тасвирланган. Гади халыкны алдау юлы белән Совет властена каршы коралны чыгыш оештырган Гыйльметдин бай, кибетче Хәнәфи, офицер Йосыф ише Печән базары исе аңкыган фетнәчеләр белән көрәш җиңел булмаган, билгеле. Үз вакытында бу «курчак дәүләт»нең төзелүе бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинны да бик борчыган, һәм ул Казан большевикларына ярдәмгә кораллы көчләр җибәргән. Шулар ярдәме белән генә Казанда Совет властен саклап калу мөмкин булган.

Язучы бу көрәшнең кискенләгән оста табылган әдәби деталь — солдат улы Мәтәли белән мулла малае Сәетҗанның үзара әләгешеп алуы аша күрсәтә. Олылар арасында барган сыйнфый көрәшне яшь геройлар дөньясында да күрү, бер яктан, балаларның наивлыгын чагылдырса, икенче яктан, ул революция язмышын кайгыртучыларның җитди буыны үсеп килүенә дә ишарә ясый. Дәлил рәвешендә, повестьтан бер өзек китерик:

«— Сөнгать абый, бүген без дә Сәетҗаннарны тукмадык әле,— диде Мәтәли эчке бер горурлык белән.

— Сәетҗан кем соң ул?

— Ул да контр инде, Зәңгәр мәчет мулласының малае...»

Күрүебезчә, Л. Ихсанова балалар психологиясен нечкә сизелләп кенә калмый, алар күңелен белеп алган яңарышка гади бер урам «вакыйга»сы аша да үтеп керә белә. Яшь геройларның кылган гамәлләре аша дәвер героикасын тудыра алу сәләте язучыны Гайдар традицияләренә якынайта. Моны әсәрнең бөтен сюжетында, төзек композициясендә һәм тасвир чараларында да күрергә мөмкин. Бер-бер артлы чиратлашып торган вакыйгалар тезмәсе әсәргә эзлекле юнәлеш бирә, сюжетны мавыктыргыч итә. Повестьның пафосын көчәйтеп җибәргән динамик куәт белән драматик киеренкелекне язучы геройларның характер үзенчәлекләрен ачу максатына буйсындырган. Автор бу чара белән тышкы эффект артыннан кумый. Реализм кануннары «рөхсәт иткән» кадәр романтик буяулар кулланып, үсеп килүче буынны революцион традицияләр рухында тәрбияләү өчен матур бер өлге тәкъдим итә.

Китапка кергән икенче әсәр — «Авылдашларым» повестенда да героик чор — Бөек Ватан сугышы еллары үзәккә алынган. Әмма бирдәге геройлар, кулларына корал тотып, яу кырында көрәшмиләр. Алар — унҗиде-унсигез яшьлек кызлар — әти-абыйлары урынына калганнар. Фашист яулары белән авыр көрәш алып барган Ватан солдатларын азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итеп торалар. Шуны сугышчан бурычлары дип аңлап, фронт өчен бар көчләренә тырышалар.

Язучы яшь кызларның героик хезмәтен аларның бай эчке дөньясына бәйләп бирә. Бигрәк тә повестьның төп герое Нәзифә образы тулы ачыла. Ул колхоз комсомол

оешмасын җитәкли һәм авыл яшьләрен оештырып йөри. Сабыр табигатьле уңган кыздан яшьлек яме бөркелеп тора. Нәзифә мондый авыр көннәрдә дә күңел күрлеген югалтмый. Ә аны саклау җиңел түгел. Фронт еракта булса да, аның дәһшәте һәр адымда сизелә. Сугышның кәфенгә төренгән салкын шәүләсе, кара мөһер сугылган хатлар рәвешендә кереп, күп өйдә булырга өлгерә. Гарип солдатлар кайта башлый, хәбәрсез югалганнарның исемнәре телгә керә... Авылдашларының боек күңелләрен күтәрү, якыннарын югалтканнарның әрнү-яраларын берazга булса да оныттырып тору максатыннан, Нәзифәләр спектакль һәм концертлар куялар. Әнә шулай, ил кайгы йоткан көннәрдә михнәт-газаплардан сыгылмаган, сынмаган яшь кызларның рухи гүзәллеген фронт сугышчыларының хәрби батырлыгына тиңләп булыр иде.

Ә бүгенге көндә якты классларда белем алган балалар батырлык күрсәтү һәм илгә файдалы булып үсү кебек олы төшенчәләрнең тирән мәгънәсен ничек аңлыйлар соң? Моңа турыдан-туры җавап бирү «Наил һәм Фаил» повестенда үзмаксат итеп куелмаса да, әсәр геройлары белән очрашып, алар холкында очраган кайбер нюансларны күзәткәч, күпмедер «аванс» белән уңай фикергә килергә була. Җиденче класс укучыларына багышланган повестенда Л. Ихсанова үзенчәлекле алым сайлаган: ул балалар тормышындагы кимчелекләрне гыйбрәтле мисаллар җирлегендә раслау күзлегеннән чыгып бәяләү юлыннан киткән. Әлбәттә, мондый алымның үз өстенлекләре бар. Әйтик, повесть геройларында күзәтелгән кимчелекле яклар белән күзгә-күз очрашкач, укучы аны кире кагып кына калмый, тәнкыйть иләге аша да үткәреп карый, тормышта сабак булырлык гыйбрәтле мисал күрә. Шул хасияте белән үк повесть билгеле дәрәҗәдә тәрбияви көчкә ия була ала.

Исеменнән үк күренгәнчә, повестьның төп герое икәү — Фаил һәм Наил атлы укучылар. Фаил — уртача укучы, чая, тере, кыланчык табигатьле малай. Шуңадыр да ул еш кына мәзәк хәлләр һәм кызганыч ситуацияләргә дә юлыга. Л. Ихсанова бик үк тәртипле булмаган бу малайның эчке дөньясына игътибар итә. Рухи яктан җитлегү чорында Фаил ясаган хаталарга җаны әрни. Аның зур борчулар, җан тынычсызлыклары аша үтеп сафлана баруын күреп сөенә, ялгышлардан арыну өчен күңел хезмәтенең дә кирәклегенә басым ясый.

Повестьның икенче герое Наил исә, четерекле хәлләр каһарманы Фаилдән аермалы буларак, яхшы укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, шахмат түгәрәгенә йөри. Кыскасы, ул бар яктан да килгән, булдыклы пионер, үрнәк булырлык әйбәт малай. Ләкин повесть белән танышып чыккач, күңелдә нигәдер андый фикер уянмый. Кайбер сәер гамәлләре белән Фаил образы бераз истә калса да, уңай сыйфатлары күбрәк булган Наил образы тойгыларыбызны тулысынча биләп бетерә алмый. Моның сәбәбе нидә соң?

Уебызча, моның сәбәбе Фаил белән Наил образларында күңел көткән геройларның кайбер йөз чалымнары гына чагылып калуында бугай. Чөнки повестьта аларның әхлакый сыйфатлары ачылып китү өчен тиешле шартлар тудырылмый. Фаил язмышы юри катлауландырылып алына һәм әсәр ахырында уңай якка хәл ителә. Наил алдындагы киртәләр дә тиз алып ташлана. Образларның эчке үсешен болай ясалма рәвештә туктату тормыш һәм сәнгать дөреслеге белән җитди каршылыкка керә шикелле. Кызганычка каршы, Наил белән Фаилнең эш-гамәлләрендә кайчандыр Мәтәлиләргә көч биргән революция ялкынының бүгенге көндәге «дәвамы», безнең чордагы рухы җитенкерәми.

Психологик кичерешләр динамикасын йомшарту исәбенә, сюжет киеренкелеген хулиган белән сугышу, фатир басу кебек ситуацияләр ярдәмендә көчәйтергә тырышу да күзгә бәрелеп тора. Шулай булса да, Л. Ихсанова урамның яшүсмер күңеленә йогынты ясавын күрми үтмәгән. Ул урамның яшүсмерне кызыктыру, үзенә тарту белән бергә, аның күңелсез хәлләргә куя торган ягы барлыгын да онытмый. Сүз бүгенге көндә актуальләшеп киткән мөһим бер проблема — яшүсмерләр арасында еш очрый торган тәртип бозу күренеше турында. Бу хәлнең сәбәпләре төрле һәм катлаулы булса да, аның бер канаты балалар-яшүсмерләр прозасына да тиеп уза. Чөнки соңгы вакытта яшүсмер күңелен әсир итәрлек уңай герой образы күренми башлады. Балаларга юлланган әдәби әсәрләргә күз салсак, андагы геройларның да бертөслерәк булуын күрербез. Әгәр без ул геройларны ничәмә буын сокланган Корчагин, Тимур кебек героик образлар янына куеп карасак, күңел юатырлык нәрсә сизмәбез.

Сүз дә юк, бүгенге шәһәр балалары тормышы, мәктәп хәлләре турында әдәби әсәр язу җиңел эш түгел. Уку программалары катлауланган, яшүсмерләрнең мәгълүмат алу чыганаклары көннән-көн зурая барган чорда бигрәк тә. Өстәвенә, тук тормыш тудырган эленке-салынкылык, ата-ана җилкәсенә салыну, җиңел яшәргә омтылу кебек тискәре күренешләр дә яшүсмерләргә йогынты ясый әле. Болар барысы бергә тәрбиягә авыр бирелүчән үсмер, тискәре холыклы бала кебек төшенчәләрне тудыралар.

Бу күренешләр безне борчып кына калмый, тәрбия эшен яхшырту юлларын да эзләргә чакыра. Шуңа күрә дә инде, повесть, әлеге кимчелекләр хакында да искәртеп,

бар көченә чаң суга. Чөнки үсеп утырган агачларга үткен пәкеләр белән «Мәдинә — Илдус» дигән сүзләр уеп йөргән һәм, өлкәннәрдән качып, подъезд төпләрендә тәмәке көйрәтүне зур батырлыкка санаган үсмерләр ишәя бара. Шул сәбәпле, аларның киләчәк язмышына без битараф була алмыйбыз. Тик без аларны Наил белән Фаил кебек үзәкләре ныгып җитмәгән геройлар мисалында әдәпкә өндәсәк, итагатьле, инсафлы булырга чакырсак, бу — сабагын начар үзләштергән укучыга, ниндидер ташлама ясап, яхшы билге кую кебек сәер килеп чыкмасмы соң?

Әлбәттә, бүгенге көн яшүсмерләре сугыш чоры яшьтәшләреннән шактый үзгәләр. Аларның теләк-омтылышларын, матди байлыклар белән рухи кыйммәтләрне үзләренчә бәяләүләрен безгә бәлки тулысынча аңлау җиңел түгелдер. Шуңа күрә дә, «Ана көндәлеге» повестеның герое Рөстәмнең эчке кичерешләре башта сәеррәк тоела. Ләкин бу тойгы озакка бармый. Зур тормышка аяк атлаган яшүсмернең катлаулы күңел дөньясы бездә теләктәшлек хисе уята. Рухы ниндидер бер урталык, билгесезлек, нәрсәдер көтү халәтендә тапанган мәлдә аңа ярдәм кулы сузасы килә. Рөстәм кайбер гаделсезлекләргә һәм зурлар ясаган хаталарга карата кискенрәк мөнәсәбәттә тора, үзе аңлап бетермәгән катлаулы күренешләргә бәйле характер һәм язмышларны аңларга омтылганда, яшьлек максимализмына хас кайнарлык, ашыгучанлык күрсәтә. Шул сәбәпле, үзе дә ялгышлар җибәрә. Беренче мәхәббәте кире кагылгач, Рөстәм өчен яшәү яме югалгандай тоела. Кешеләргә һәм үз-үзенә ышанычы кимеп барганда, укытучы Хәсән абыйсы йөзендә хәленә керүче һәм җанын аңлаучы дустын очрата. Акыллы һәм төпле киңәшләре белән ул Рөстәмнең язмышын уңай якка борып җибәрә.

Укытучы Хәсән образы шул ягы белән кызыклы: ул мәктәпкә, укыту-тәрбия эшенә яңача карашны гәүдәләндерә. Ул педагог-тәрбиячеНең бурычы һәм вазифасы итеп иң элек укучы җанын аңлый алу, аның күңел тирбәлешләрен дөрес сизә белү сыйфатын саный. Укучыга зур эшләр башкарырга сәләтле шәхес итеп карый. Хәсән образында без яңа тип педагогны күрәбез. Ләкин яңа принциплар, яңа карашлар тамыр җәю өчен, аның җиңүе кирәк әле. Повестьта без шул карашларның бәрелешен күрәбез.

Укыту-тәрбия эшендә үз фикерен уздырырга тырышкан Ләлә Мәхмүтовна башта эшчән, тырыш укытучы кебек күренсә дә, төптәнрәк фикер йөрткәндә, без аның зур сыйфатлар артына яшерелгән башка йөзен дә таныйбыз. Аның укучы яхшы билге алу хакында гына уйларга тиеш дигән фикерләре, бердән, яшь буынның гармоник үсешен чикли, икенчедән, аның мөстәкыйль шәхес булып җитлегүен тоткарлый. Бу карашларның ялгышлыгын раслаучы мисалны повестьның үзеннән үк табабыз. Ләлә Мәхмүтовнаның яраткан укучысы отличница Света каты бәгырьле, матурлык хисләрен аңламаучы циник табигатьле кеше булып үсеп килә. Әнә шулай, Светаның тупас гамәле аша Ләлә Мәхмүтовна «теориясе»нең зыянлы асылы ачыла.

Повестьта яшүсмер һәм тирәлек, тирәлекнең яшүсмергә йогынтысы һәм яшүсмер өчен уңай мохит тудыруда олыларның роле кебек гаять әһәмиятле бурычларны хәл итүнең матур үрнәге бирелә.

Менә без Ләбибә Ихсанованың дүрт повестен үз эченә алган шактый күләмле китабы белән танышып чыктык. Язучының озак елларга сузылган иҗади эзләнүләре, балалар әдәбияты өлкәсендәге фидакарь хезмәте берьюлы күз алдына килде. Без геройларның кызыклы һәм мавыктыргыч тормышы белән очраштык, аларны борчыган куркыныч проблемаларны йөрәгебез аша кичердек. Болар барысы да — без белгән, без яшәгән тормышның үзе, безне тирән борчыган проблемалар. Язучы мохит, әйләнә-тирә (гаилә — урам — мәктәп һ. б. лар) белән балалар һәм аларның үзләре арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне җентекләп тикшерә. Хәтта «Наил, Фаил һәм башкалар» дип әйтүдә дә шуңа ишарә бар сыман. Кемнәр алар — «һәм башкалар»? Без язучының «Гөлләр кояшка карый» кебек укучыларга тиз арада танылган повестенда бу сорауны җентеклерәк, җитдирәк өйрәнү, анализлау мисалын күрдек. Бу — бик катлаулы бурыч. Аңа ирешә алмаган очраклар да була. Әлеге четерекле проблема һаман игътибар үзәгендә кала һәм язучы моны истән чыгара алмый. Катлаулы заманда үсүче яшь кешенең ил-көнгә файдалы шәхес булып формалашу үзенчәлекләрен өйрәнү, уңай мохитне тудыруда лаеклы өлеш кертү — әдәбият алдына партиябезнең XXVII съезды куйган иң зур бурычларның берсе.

Балалар өчен язу кебек изге эшкә тугрылыклы әдип Ләбибә Ихсанова менә шушы бурычны тирәнтен аңлап иҗат итә. Әдәбият алдында — тормышның яңа катламнарына тирәнрәк үтеп керү, хәзер урамда туп тибеп йөрүче Наилләребез, Фаилләребез күңеленә тагын да ныграк якынаю бурычы тора.

**Әхмәт САХАПОВ.**

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

## Гаделлек һәм бурлык

Булган бер кеше. Мәскәүдәме, Петербурдамы, Казандамы,— анысын белмәдем, бергә йөрмәдем. Аның булган өч улы. Бу кеше үлеп киткән. Уллары аталарының байлыгын бүлешергә керешкәннәр. Бүлешә торгач, аның ат башыдай алтыны килеп чыккан. Алай иткәннәр егетләр, болай иткәннәр, бу алтынны бүлә алмаганнар. Аны бүлмәскә, сакларга булганнар. Биек таскакъ[1] ясап, алтынны югары күтәреп саклый башлаганнар. Бер атна берсе, икенче атнада икенчесе, өченче атнада иң кечесе сакларга барган. Бервакыт кече егет йөгереп кайткан да:

— Безнең алтынны урлаганнар,— дигән.

Болар бик аптырашта калганнар, бергәләшеп киңәшкәннәр. Сөйләшә торгач:

— Безнең алтынны, мөгаен, бик озын буйлы кеше алгандыр, таскакъка тик андый кешенең генә буе житә, исеме Муса, үзе сакал-мыегын кырып йөри торган матур кеше булырга тиеш,— дигәннәр.

Егетләр алтынны эзләп юлга чыкканнар. Бара торгач, аларга бик озын буйлы, сакал-мыегын кырган бер кеше очраган. Исемен сораганнар.

— Исемем Муса,— дигән теге.

— Әһә-ә, безнең алтынны син урлагансың икән, кая яшердең, китереп бир! — дип, болар бу кешегә бәйләнә башлаганнар.

— Алтыныгызны мин алмадым, күрмәдем, бу якларга беренче килүем, нәрсә югалтканыгызны белмим,— дигән юлчы.

Шулай да егетләр аны жибәрмәгәннәр, үзләре белән бергә алып киткәннәр. Болар каршысына бер карт килеп чыккан. Ул карт әлеге юлчылардан:

— Сезгә юлда бер хатын очрамадымы? — дип сораган.

— Очрады,— дигән егетләр,— ул хатын дөя өстендә иде, дөясенең сул як күзе зәгыйфь, алгы теше ерык иде, дөянең бер ягына бал аскан булырга кирәк, икенче ягына серкә асканга охшый,— дип сөйләгәннәр әлеге картка.

Бу сүзләргә тәмам ышанган карт үзенең хатыны артыннан бармаска булган.

— Минем хатын турында болар белеп сөйлиләр, аны талап үтергәннәрдер, хәзер хатыным артыннан баруның кирәге юк,— дигән һәм, кире борылып, егетләр белән бергә китеп барган.

Болар бергәләшеп патша сараена керергә булганнар.

— Безне патша үзе шәригатьчә хөкем итсен,— дигәннәр.

Патша бу юлчыларга үз жиренә керергә рөхсәт итеп, хезмәтчеләренә аларны ашатырга кушкан.

Патша хезмәтчеләре аш китергәч, егетләрнең олысы:

— Йолдызы сирәк икән,— дигән. Аңа уртанчысы кушылып:

— Ае ярты гына икән,— дигән. Ә кече энеләре:

— Сезнең борыныгыз сизәме, бу аштан эт исе килә,— дигән. Ә олы егет ашка карап-карап утырган да:

— Бер дә гажәп түгел, патша үзе дә бер карагол малае икән, зур заттан түгел икән,— дип өстәп куйган.

Юлчыларга аш биргән ялчылардан патша:

— Нәрсә ишеттегез, нәрсә сөйләделәр? — дип сораган.

---

[1] Вышка, манара.

Ялчылар егетләрнең нәрсә сөйләгәннәрен әйтеп биргәч, патша уйга калган:

— Болар аштан ашны аера белә торган кешеләр икән, шәригатьчә хөкем итүе читен, монда баш кирәк,— дип үзенең хөкемен картны сөйләтүдән башлаган.

— Минем хатын юлга миннән алда чыгып киткән иде, аны бу дүрт егет юлда үтереп ташлаган,— дигән карт.

— Без аны тотмадык, аңа тимәдек, үтермәдек,— дигәннәр егетләр.

— Алайса сез ул хатынны ничек беләсез? — дигән патша.

— Дөя өстендә барган кешенең хатын икәнен белүе читен түгел, ул дөясеннән төшкән җирдә үлән аз гына изелеп калган. Сул күзе зәгыйфь дөя уң ягын ашап бара, алгы теше ерык дөя ашаганда үләннең уртасы утырып кала — тешенә эләкми. Дөянең уң ягында бал булганын, юлга бал төшеп, кортлар җыелганнан, ә сул ягында серкә булуын бер ягы кибеп, корып барганнан белеп була,— дигәннәр егетләр.— Без боларны юлга карау белән, ул хатынны күрмәсәк тә әйтә алабыз,— дип өстәгәннәр.

— Синең хатыныңны болар тотмаганнар, үтермәгәннәр, үзләре шулай күпне белә торган кешеләр, бар, хатыныңны теләсә кайдан эзләп тап! — дип, патша бу картны сарайдан чыгарып җибәргән.

Инде эшнең төбе дүрт егеткә калган. Патша бу егетләрдән:

— Алтыныгызны Муса алганын ничек белдегез,— дип сорагач, алар:

— Муса биек кеше, анда Мусадан башка кешенең буе җитәрлек түгел, алтынны ул гына алган,— дигәннәр.

— Алтыныгызны мин күрмәдем, алмадым, кайда икәнен дә белгәнем юк,— дигән Муса. Патша:

«Бу егетләр бик күпне беләләр, инде аларны ничек хөкем итәргә»,— дип уйлап утырганда, янына кызы килеп:

— Әти, син рөхсәт итсәң, мин аларга юмак[1] сөйләп бирер идем,— дигән.

Әтисе рөхсәт иткәч, патша кызы аларга юмак сөйләргә керешкән: «Бер зифа кыз белән егет бер-берсенә гашыйк булганнар. Егет — алырга, кыз — барырга сүз куешканнар. Ә кыз үсеп җиткәч, әти-әнисе аны башка егеткә кияүгә биргән. Кода-кодагыйлар җыелган. Музыкантлар килгән. Бик зур туй ясаганнар. Туйлар уйналып, үз вакыты җиткәч, кияүне кыз куенына керткәннәр. Шул вакыт кыз йомарланып елый башлаган, кияүне үз янына китермәгән, кочаклатмаган. Кияү бик аптыраган:

— Нигә болай елыйсың, нигә йомарланасың? Мин сине сөям, син нигә мине сөймисең? Сөймәгәч, миңа килергә ник риза булдың? — дигән.

— Әйтсәм әйтим, минем бер шартым бар,— дигән кыз.

— Нинди шартың бар, сөйлә! — дигән егет.

Кыз үзенең шарты турында сөйләп биргән:

— Кече яшьтән бер егет белән бер-беребезгә гашыйк булган идек. Ул мине алырга, ә мин аңар барырга сүз куешкан идек. Әгәр башка кешегә кияүгә барсам, әүвәл шушы егеттән рөхсәт алырга булган идем. Күңәме ул, юкмы, анысында эшем юк, ләкин ул егетне күреп вәгъдәмне үтәргә тиешмен,— дигән.

— Алайса, бар да беренче егетең белән шартыңны үтәп кил! — дигән кияү егет.

Кыз чыгып киткән. Бара торгач, моның каршысына бурлар очраган. Алар моның матурлыгына кызыкканнар, үзен кочакларга, әйберләрен алып калырга уйлаганнар. Сөйләшә торгач, бу өч бур куркып калган:

— Моны кочаклап, эшне бозарбыз, киемнәрен саткан вакытта тотсалар, тагын да хур булырбыз! — дип, кызны үз юлына җибәргәннәр.

Бурлардан котылып киткәч, кыз беренче егете яшәгән өйгә килгән дә ишеген дөбердәтеп:

— Ишегеңне ач, мин синең яныңа шартымны үтәргә килдем,— дигән.

Ә беренче егете:

— Син хәзер миңа кирәкмисең, барган кешең белән бул, мин инде риза! — дигән һәм кызны хәтта өенә дә кертмичә кайтарып җибәргән.

Кыз, өенә кайтып, нәрсә булганын сөйләп биргән дә кияве кочагына кергән».

Юмагын сөйләп бетергәч, патша кызы уйланып торган да шәригатьчә хөкем итүне сораган егетләргә өч сорау биргән.

Беренчесе: кочагына кертмәгән никахлы хатынын яшьлек шартын үтәтте-

---

[1] Әкият.

рергә жибәргән кияү, сезнеңчә, гадел егетме? Әллә изәр[1] булганмы?

Икенчесе: яшьтән сүз куешкан әүвәлге егетенә баргач, кызны ризалык белән өенә кайтарып жибәргән яшь кеше гаделме, әллә изәрме?

Өченчесе: зифа кызны күргәч, әйберләрен алырга уйлап, соңыннан бер дә тимичә аны үз юлына жибәргән бурлар гадел бурлармы, әллә изәрләрме?

Ике олы егет бу сорауларга:

— Никахлы егет тә, сүз куешып, сөйгәненә өйләнми калган егет тә гаделлек күрсәткәннәр, кызның юлына чыккан бурлар да гадел бурлар булганнар,— дип җавап биргәннәр.

Ә егетләрнең иң кечесе:

— Хатынын егете янына жибәргән яшь кияү дә, яраткан кызына ишек ачмаган, аны бер үпмичә өенә кайтарып жибәргән егет тә изәр кешеләр, кызга тимәгән, әйберләрен алмаган бурлар да изәр бурлар,— дип әйткән.

Патша кызы боларның җавапларын тыңлаган һәм Мусаны сарайдан үз юлына чыгартып жибәрткән. Аннан әтисе янына барып:

— Каракны тоттым, инде үзең хөкем ит,— дигән.

Патша егетләрне үз янына чакыртып:

— Алтыныгызны Муса алмаган, кече энегез алган, кайтыгыз да алтыныгызны табып бүлешегез! — дигән.

Болар кайтып киткәннәр. Алтынны бүлешкәннәрме, юкмы — анысын белмәдем, алар белән йөрмәдем, үзләрен күрмәдем. Ләкин патша аны бүлешергә кушкан.

*Омск өлкәсенең Тары районы, Кип-Куллар авылында 1940 елның 15 июнендә Юма Әбдрәшитовтан* **Мөхәммәт Садри** *язып алды.*

## Хәйяр белән Мәкер

Хәйяр белән Мәкер турында ишеткәнегез бармы? Булмаса, сөйлим. Борын заманда Хәйяр белән Мәкер кушаматлы ике кеше булган. Һөнәрләре хәйләкәрлек һәм мәкерлек булган. Алар икесе бер хатын белән яшәгән. Бер хатын белән торганлыкларын үзләре дә белмәгән. Бервакыт базарда алдап-йолдап йөргәндә, боларның мәкерлеге һәм хәйярлыгы сизелә башлаган. Шуннан Мәкер йөгереп өенә кайткан да:

— Әй, хатын, минем мәкерлек сизелә башлады, миңа көн булмас, инде нишләргә? — дип сораган.

Ә хатын аңа:

— Әй, чынлап та күңелсез хәлдә калгансың, син инде бер як читкә качып кит! — дигән.

Хатын моның юлына азык әзерләгән: пешкән казның уртасыннан икегә ярып, ярты казны, бер бөтен ипинең яртысын биргән. Мәкер азыгын төйнәгән дә юлга чыгып киткән.

Озакламый Хәйяр да йөгереп кайткан һәм:

— Әй, хатын, минем хәйярлыкны сизделәр, инде нишләргә? — дип киңәш сораган.

— Эшең күңелле түгел икән, сиңа бер як читкә китеп югалып торырга кирәк! — дигән һәм юлына Мәкердән калган ярты каз белән ярты ипине төреп биргән.

Шулай итеп, Мәкер артыннан Хәйяр да юлга чыккан. Болар кая барганлыкларын үзләре дә белмәгәннәр. Бара торгач, Хәйяр Мәкер артыннан куып җиткән. Хәлләре беткәч, икесе бер урында ашарга утырганнар. Шул чакта берберенең ашамлыкларын күреп гаҗәпкә калалар. Чөнки боларның яртышар казын берektерсәң, яртышар ипиен бергә кушсаң, икесе дә бер кулдан чыкканга охшыйлар. Мәкер Хәйярдән сорый:

— Син, юлдаш, кай җирдә торасың?

— Каралты урамында торам,— ди Хәйяр.

---

[1] Гакылга загыйфь, исәр.

— Анда кай төштә торасың?

— Зариф байлар рәтендә,— ди Хәйяр.

— Ә хатыныңның исеме ничек? — дип сорый Мәкер.

— Хатынымның исеме Балдахчы,— дип җавап бирә Хәйяр.

— Хи-хи-хи,— ди Мәкер,— нигә юкны сөйлисең, ул — минем хатын, ә ул йорт — минем йортым.

— Минә иске авыздан яңа сүз, нишләп ул синең хатын булсын, ул минем хатын, минем йортым! — ди Хәйяр.

Бәхәсләшә торгач, болар сугыша башлыйлар. Бит-башлары тырналып, авыз-борыннары канап, хәлдән тайгач:

— Монда безгә сугышып бәхәс бетмәс, әйдә, аның кем хатыны икәнен үзеннән сорыйк,— дип, борылып өйләренә кайталар. Өйдә:

— Син Мәкер хатынымы, әллә Хәйяр хатынымы? — дип сорыйлар болар. Ә хатын:

— Бүгенгәчә икегезгә дә хатын идем, инде кайсыгызның һөнәре артык булса, шуның хатыны булырмын,— дип җавап бирә.

— Алай булса, әйдә, миңа ияр,— ди Мәкер Хәйяргә.— Башта һөнәремне мин күрсәтәм!

Болар базар янындагы бер кибеткә керәләр. Кибеткә керү белән Мәкер кибетченең кесәсенә тыгылып, акчалы янчыгын ала. Ачып караса, эчендә йөз сум акчасы бар икән. Мәкер үзенең исеме язылган балдагын да салып, янчыкны тиз генә кибетченең кесәсенә кире төшерә дә:

— Каравыл, каравыл! Кибетче минем янчыгымны урлады! — дип кычкыра башлый.

Болар янына тиз генә килеп җиткән стражник, Мәкерне көчкә туктатып, нәрсә булганын ачыграк сөйләргә куша. Мәкер:

— Минә бу кибетче янымдагы акчалы янчыгымны әләктерде,— дип тагын акыра башлый.

— Бу хәшәрәтне мин беренче күрәм, монда юкка бәйләнеп тормасын,— ди кибетче.

— Алдалый ул, алдалый,— ди Мәкер,— ышанмасагыз, янчыгын карагыз, янымда йөз сум акчам белән исемем язылган балдагым бар иде!

Кибетче ачуланып:

— Менә карагыз, стражник әфәнде, үз акчам, үз янчыгым,— дип кесәсеннән янчыкны алып бирә. Стражник янчыкны ачып караса, акча чынлап та йөз сум икән, исеме язылган балдак та Мәкернеке икән. Шулай итеп, кибетчене көлкегә калдырып, Мәкер йөз сум акчалы була.

Инде Хәйяргә чират җитә. Шул көнне эңгер-меңгерләрдә, кешеләр йокларга ята башлагач, Хәйяр Мәкерне ияртеп, патша сарае янына юнәлә. Сарай янына җиткәч, башта Хәйяр, аның артыннан Мәкер койма аша сикереп төшәләр дә каз абзарына керәләр. Хәйяр ике казны тиз генә ботарлый да ашханәгә кереп, аларны пешереп ашый башлый. Мәкерне дә ашарга чакыра. Мәкернең коты ботына җиткән була: «Юк,— ди ул,— әйдә, моннан китик, патшаның берәр каравылчысы уянса, харап булырбыз, безне үтерерләр»,— ди. «Курыкма,— ди Хәйяр,— монда куркыныч түгел, әлек тамакны туйдырыйк, патшаның үзе янына керәбез әле».

Төн уртасы авышып, сарайдагылар йокыга талгач, Хәйяр: «Әйдә, патшаның үз бүлмәсенә керергә вакыт җитте»,— ди. Кирәк була калса дип, болар сарай пешекчеләренең киемнәрен киенеп, саклык белән һәм тиз-тиз генә патша бүлмәсенә килеп керәләр. Патша тәмле йокыга талган. Ул йоклаган вакытта нәкъ нәни бала шикелле үзен бишектә тирбәттереп йокларга ярата икән. Аны бер гүзәл кыз тирбәтә икән. Тирбәткән вакытта йоклап китмәсен өчен патша кыздан сагыз чәйнәттерә икән. Кыз, патшаны тирбәтә-тирбәтә күзен йомган арада, Хәйяр сиздермәстән генә бишек астына яшеренә. Иплән кенә кызның авызына кыл тыга һәм шул кылга ябыштырып кыз авызындагы сагызны тартып ала. Кыз баскан килеш йокыга китә. Катырак йокласын өчен Хәйяр аңар хушын җибәрә торган дару иснәтә. Кыз, идәнгә ятып, рәхәт йокыга тала. Хәйяр инде патшаны үзе тирбәтә башлый. Ә Мәкер коты алынып бер почмакта тора һәм: «Әйдә киттек, хатын синеке булыр, зинһар китик моннан»,— дип ялына. Хәйяр аңар дәшми, патшаны тирбәтә бирә. Бераз тирбәткәннән соң Хәйяр нечкәрәк бер тавыш белән:

— Падишаһым, сезгә бер сорау биримме? — ди.

— Сора, сора,— ди патша.

— Сезнең алтын-көмешегез кайда?

— И, син аларның кайдалыгын беләсең ич, күрше бүлмәдә генә...

— Аларның барысын да алыйммы, әллә үзегезгә дә калдырыйммы? — ди Хәйяр.

— Барысын да ал, барысын да! — дип җавап бирә патша йокы аралаш.

— Китик инде зинһар,— ди Мәкер калтыранып.— Хатын синеке булыр, бер нәрсә дә алмыйк!

— Юк,— ди Хәйяр,— алтын-көмеш белән кайтмасак, Балдахчы безгә ышанмас.

Патша күрсәткән бүлмәгә кереп, болар алтынны күтәрә алганын бер, көмешне икенче капчыкка салып, сарайдан чыгып китәләр дә өйләренә кайталар.

— Я, инде кем хатыны буласың? — диләр Хәйяр белән Мәкер, күргән-белгәннәре, эшләгән эшләре турында сөйләп.

— Синең хатының булам,— ди Балдахчы Хәйярга.

Таң атып, кояш шактый күтәрелгәч, патша үзенең бишегендә уянып күзен уып ятканда, янына курка-курка гына кереп, аңар кемнеңдер ике казны бугазлап, пешереп ашап киткәнен, казларның мамыклары гына тузгып калганын хәбәр итәләр. Патша гаҗәпләнеп:

— Каз абзарына керергә кемнең дә батырчылык иткәне юк иде, анда кем керә алган икән? — дип, бишегеннән сикереп тора.— Болай булгач, кассаны да карарга кирәк!

Кассаны карасалар, анда алтын да, көмеш тә юк — бернәрсә дә калмаган икән. Патша тиз генә вәзирләрен җыеп алып гакыллаша:

— Әйтегез, сарайга кем кергән, алтын-көмешләрне кайдан эзләп табабыз? — ди.

Вәзирләр арасыннан бер кыюрагы: «Төнлә каз абзарына керергә, сарайдан алтын-көмешләрне алып чыгарга кем батырчылык иткән, шул кеше үзен белдерсен, патша хәзрәтләренә килеп күренсен, ул кеше бертөрле җәзага да тартылмас, алтын-көмешнең яртысы үзенә бирелер», — дип, белдерү язып ябыштырырга киңәш иткән.

Бу белдерүне, билгеле, Хәйяр да укый һәм хатыны белән гакыллашып: «Нәрсә эшлибез?» — дип сорый. Хатыны: «Барма, алтын-көмешләребезне дә алыр, үзеңнең дә башыңны чаптырып харап итәр»,— ди. Хәйяр уйлап-уйлап тора да, ни булса да булыр, башымны чаптырса чаптырыр, ди, китә бу патша сараена.

— Падишаһым-солтаным, туздырып чабата олтанын, сараеңда мин йөрдем, ике казыңны мин ашадым, бүлмәңә кердем, алтын-көмешләреңне мин алдым, инде тиешле җәзаңны бир! — ди Хәйяр.

— Бу эшкә сине кем мәҗбүр итте? — ди патша.

— Хатын,— ди Хәйяр,— без Мәкер белән икебез бер хатын белән яшәгәнбез. Бәхәсләштек. Хатын безгә кайсыгызның һөнәре артык булса, шуныкы булам, диде. Һөнәремне күрсәтәсем килде. Аннары синең, тәмле йокысын качырып, үсмер кызны аяк өсте бастырып тирбәттерүеңә дә ачуым килде. Инде хөкем ит, падишаһ, хатын минекеме, әллә Мәкернекеме? Алтын-көмеш миндә каламы, сиңа кайтамы?

— Хатын сиңа булсын, ә алтын миңа кайта,— дип, патша алтынны бирмәгән, алдаган. Аннары, бишектә йоклап өйрәнгәнгә, оятыннан гади караватта йоклый башлагач, сырхауга сабышкан да үлгән. Ә Хәйяр үз хатыны белән әлегәчә бергә дус булып рәхәтләнеп торалар икән. Мәкер исә әле дә курка-курка гына мәкерлек итеп йөри ди.

*Омск өлкәсенең Дзержинский районы, Үләнкүл авылында 1940 елның 6 июнендә Баки Хөсәеновтан* **Мөхәммәт Садри** *язып алып эшләде.*

# БЕРГӘ ГОМЕРГӘ

1963 елның матур җәй ае. Казандагы дусты Талияләргә кунакка килә Исламия. Бергәләп башкаланың истәлекле урыннарын карап йөриләр. Кремль белән дә танышлар. Кинәт «Татар дәүләт республика күчмә театры» дигән язуны күреп, сискәнеп китә кунак кызы. Тукта, бу театр артистларының Әлки якларына да килгәне, Исламиянең аларны мөкиббән китеп, шаккатып караганы бар лабаса... Сабый чактан ук җанына тынгы бирмәүче хыялы, артистка булу теләге, бөтен батырлыгын җыеп, театр бусагасын атлап керергә көч бирә аңа. Юлы уң була. Шул керүендә үк «имтихан» тота кыз. Ярсып-ярсып, Һ. Такташның «Алсу»ын сөйли, Ф. Әхмәдиевнең Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган, ул вакытта бик тә популяр булган «Кама буе туган як» җырын башкара, М. Фәйзинең «Галиябану»ыннан авыл сәхнәсендә үзе уйнаган өзекне күрсәтә.

— Ә хәзер Галиябануны болайрак уйнап карагыз,— ди аның һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтүче Равил Тумашев.

Исламия режиссер әйткәнчә уйнарга тырыша. Галиябану булып җырлый. Табигый моңы, тавышка хис сала белүе, эчке музыкальлеге белән тыңлаучыларда өмет уята һәм... театрда эшкә кала.

Көненә кадәр хәтерли Исламия: 18 апрель, 1964 ел. Беренче мәртәбә олы сәхнәгә чыга ул. А. Гыйләҗевның «Кара күзле кызлар» әсәрендә Гөлләр образын башкара. Тәүге адым, кыюсыз хәрәкәтләр. Беренче иҗат газаплары, иҗат шатлыгы!..

— Гүя нәни кош баласы мин,— дип искә ала әлеге көнне Исламия.— Әйтерсең яңа гына канат чыгарганмын да, бераз гына каушап, бераз гына куркып, зур очыш алдында торам, очар өчен зәңгәр офыкларны күзәтәм, җирнең күк белән тоташкан урынын эзлим. Ә офык ерак. Анда барып җитү өчен кавырсынны ныгытырга, канатларны чыныктырырга кирәк икән әле...

«...Ул (Исламия) саран гына адымнар белән дә Гөлләрнең иң нечкә хисләрен шактый ачык чагылдыра алды. Сәхнәгә яңа аяк баскан яшь көч өчен бу уңышлы һәм өметле башлангыч»,— дип язылды «Социалистик Татарстан» газетасында «Кара күзле кызлар» турындагы рецензиядә. «Беренче талпынуда ук рольгә кереп китә алуы, бушлык калдырмыйча уйнавы белән барыбызны да шатландырды»,— ди Ирек Баһманов, Исламия Мотыйгуллина-Мәхмутова белән бергә эшләгән көннәрен искә алып.

Халыкны ышандырырлык һәм сокландырырлык образ тудыру өчен, беренче чиратта, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгага артист үзе



*Италия язучысы Карло Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе» әсәрендә: Исламия Мәхмутова — Беатриче, Хәлил Мәхмутов — Флориндо ролендә.*

ышанырга, үзен шул вакыйга герое итеп тоярга тиеш. Бу хакыйкатьне яшь артисткага театрның баш режиссеры Кәшифә Тумашева тәкрарлап тора. Бәхеткә каршы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабыздагы беренче хатын-кыз режиссер Кәшифә ханым белән байтак кына бергә эшләргә туры килә аңа. Беренче рольне дә ул бирә. Сәнгатьнең сикәлтәле авыр юлыннан сыкранмыйча барырга кирәклеген өйрәтә, әйткән сүзләре белән генә түгел, үзүзен тотышы, яшәү рәвеше белән дә яшьләргә үрнәк булып тора.

— Кәшифә Җамалетдиновнаның һәрбер репетициясе — үзе бер сәнгать дәресе. Аның ихлас күңел белән дөньяны, терек-

лекне, табигатьтәге һәр хәрәкәтне яратуын күрү үзе бер хозурлык иде,— ди Исламия, остазын хөрмәтләп искә алганда. Шулай итеп, берсеннән-берсе талантлы сәнгать кешеләре арасына килеп керә ул, Люция Фарсина, Сания Исмәгыйлева, Фәридүн Юнысов, Фирдинанд Фарсин кебек сәхнә осталары арасында эшли башлый.

— Якты йолдызлыкка килеп эләккәндәй хис иттем үземне. Алар минем өчен укытучылар, остазлар гына түгел, алар минем өчен илаһи бер җан ияләре иде,— ди Исламия Мәхмүтова үзенең коллективташлары турында. Бәлки нәкъ әнә шуңа күрә, театрны изге урын, андагы кешеләрне әллә нинди могҗизалар турында да сәләтле затлар итеп таныганга күрә, бөтен күңеле белән яратып, җаны-тәне белән бирелеп, онытылып башкарадыр ул үзенә тапшырылган рольләрне.

Югарыда телгә алган остазлары белән берлектә уйнаган спектакльләреннән Зәйни Шаһиморатовның «Әй, әшнәләр, әшнәләр» исемле комедия-водевилен алыйк. Гаять тә каршылыклы, катлаулы Галимә ролен уйнарга туры килә Исламиягә бу спектакльдә. Галимә — эш сөючән, акыллы кыз. Ул әтиәнисен хөрмәт итә. Төрле хәлләр кичерсә дә, тормышта гадел булып, мәхәббәткә тугрылыклы булып кала. Эчке дөньясын җыр белән ача. «Ник син, кояш, мине күрмисең?» — ди ул йөрәктән килгән әрнү катыш моң белән. Бераздан: «Мин тагын җил белән сөйләштем»,— дип өзгәләнә. Исламиянең моңы, йөзенә чыккан эчке кичерешләре Галимә образының музыкаль монологы булып яңгырый. Алай гына да түгел, башкаручының йөрәге халык йөрәге белән бербөтенгә әверелә.

— Җырлы рольләр гомумән дә килешә Исламиягә. Андый вакытта аеруча эмоциональ, аеруча нечкә һәм сизгер күңелле булып туа аның геройлары,— ди Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Тумашев.

Исламия Мәхмүтова — чынлап та, шагыйрәнә күңелле хатын-кыз. Үзенә генә хас нечкә драматизм, лирик йомшаклык бар анда, геройларның эчке психологиясен ачу осталыгы бар. Исламия иҗаты өчен вакыйганың эчендә кайнап, кечкенә генә хәрәкәтне дә үзенең җанына сеңдереп, һәр күренешне дәлилли белеп гәүдәләндерү хас. Бәлки нәкъ шушы хасият — Исламиянең актерлыгындагы иң калку сыйфаттыр. «Нәкъ шул байлыгы ул иҗат иткән геройларны үзе кебек «сөйкемле сөякле» итәдер...

Бу уңайдан Ю. Әминовның «Умырзая чәчәкләре» исемле эпик драмасы буенча куелган спектакльне искә төшерик. Исламия анда, егерме пот арышка алыштырылып, авыл мулласына кияүгә бирелгән, рәнҗетелгән Фирүзә ролен башкара. Әмма кыз югалып калмый. Октябрь революциясе Фирүзәнең аңын яктырта, күңелен уята, һәм ул иренең йортын ташлап китә, революция эшенә кушыла. Дөреслек өчен, хакыйкать өчен көрәшә һәм шул юлда һәлак та була. Фирүзә образы халык күңелендә чисталык һәм батырлык символы булып җанлана, кешелеклеге, мөлаемлеге белән тамашачыны әсир итә. Хәтта тормыштан киткәндә дә эчке дөньясының сафлыгын, күңеленең дөрес булуын күрсәтеп китә.

А. Гыйләҗевның «Сары чәчәк ата көнбагыш...» драмасында да гражданнар сугышы чоры фаҗигасе сурәтләнә. Бу әсәрдә Исламиягә яшь монашка Анна ролен башкарырга туры килә. Ул — «алла колы». Монастырьның калын таш стенасы аша үтеп кереп күзләренә кояш нуры төшмәсә дә, йөрәгендә өмет яктысы бар. Аның гыйбрәтле язмышы үз бәхетен, үз мәхәббәтен көтә. Ул большевик Хәлил (Х. Мәхмүтов) белән очраша. Ачык йөзле сылу кыз белән кайнар йөрәкле, яхшы күңелле егетнең көтмәгәндә очрашулары уртак мәхәббәт хисләре уята.

Сүз уңаеннан әйтеп киткәндә, Исламия Мәхмүтованың күп уены Хәлил Мәхмүтов белән бара. Табигый һәм тормышчан була аларның бергә башкарган эпизодлары, чөнки берсенең уенын икенчесе тулыландырып, камиллеккә омтылып эшлиләр.

— Сәхнәдә мәхәббәт уйный-уйный, берберсен тапты Мәхмүтовлар. Хәзер исә гел дә бергә,— дип искәртә алар турында иптәшләре шатланып.

— Бергә гомергә! — дип елмая Исламия, бәхетле итеп. Зәңгәр күзләрендә генә түгел, һәр күзәнәгендә шатлык кайный кебек. Гүя шул шатлык аның һәрбер хәрәкәтенә җиңеллек өсти, күз карашыннан нур булып тарала. Тарала да: «И, кешеләр, һәркем үз бәхете өчен үзе көрәшергә, өлешенә тигән көмеше белән гомергә бергә булырга тиеш!» — ди шикелле.

Менә зәвык белән җыештырылган якты, чиста бүлмә. Шунда бер-берсенең кадерен белеп яшәүче биш җан: кайнана, ике бала, ир белән хатын. Кайнанасының йомшак тавыш белән «кызым» дип эндәшүе, балаларының «әнием» дип киңәш соравы, иренең ихтирам белән «Исламия» дип сүз катуы — һәммәсе дә бер хакыйкать турында — өйдәге тыныч, тату мөгамәлә, үзәктә торучы киң күңелле, ачык йөзле, уйнаклап торган Исламия турында сөйлиләр кебек...

«Туктагыз әле, Исламия әллә тормышта да артистка булып яшиме?» — дип сорар бәлки кайберәүләр. Юк, Исламия — әни булып, Исламия — килен булып, Исламия — сөя һәм сөйдерә белүче акыллы хатын булып яши. Шәхси тормышында спектакль уйнамый ул. Киресенчә, сәхнәдә тормыштагыча чын итеп, дәртле итеп, ашкынулы итеп яши. Бәлки шуңа күрә, сәхнәдә табигый итеп яши белгәнгә күрә, ул иҗат ит-

кән образлар тере һәм тормышчан булып туалардыр да. Бәлки шуңа күрә, кеше күңеленең иң нечкә кылларына кагылып, тамашачыны каләм алырга мәҗбүр итәләрдер...

«Исәнмесез, минем яраткан артисткам Исламия! Мин Сезне «Үзебез сайлаган язмыш» спектаклен караганнан бирле күңелемдә йөртәм. Телевизордан уйнаганыгызны күрсәм — авыруларым онытыла. Әгәр Зәй-Каратайга килсәгез, безгә керегез. Мин йөри алмыйм. Ә Сезне якыннан күрәсем килә. Бик тә күрәсем килә.

Кәтибә Гыйльметдинова.
Лениногорск районы».

«Сеңелем, гафу ит. Якын иткәнгә «син» дип эндәшәбез. Беренче мәртәбә 1969 елда Ямаш авылы клубында күрешкән идек. Шул вакыттан бирле йөрәкләрдә якты образ итеп саклыйбыз сине. Сагынып искә алабыз. Бигрәк тә «Кыр казлары артыннан» спектаклендә уйнавың күз алдында тора. Андагы җырны бары тик синең йомшак, ягымлы тавышың гына җиренә җиткереп, үзәккә үткәреп башкара ала кебек. Рәхмәт сиңа, сеңелем!

Балык Бистәсе районы, Юлсубино
мәктәбе укытучылары исеменнән:
Әминә Сәлахова, Наилә Әмирова».

Димәк, артистканың сәхнә аша җиткерергә алынган фикерен, уй-хисен тамашачы кабул иткән, димәк, халык аңа ышанган, үзенә рухи азык алган. Ә бу — иҗатчы өчен бәхет түгелмени?!

— Бервакыт шулай авылларда «Кыр казлары артыннан» спектакле белән йөрибез,— дип сөйли Исламия.— Чираттагы тамашадан соң, билгеләнгән йортка ял итәргә кайттык. Хуҗа хатын: «Наныем, синең тавышыңны магнитофонга яздырып калу өчен улым бүген йөргән кызын озатырга бармады. Шул «Кыр казлары артыннан» җырын бик яратабыз инде без. Җырламассың микән?» — ди. «Җырлыйм, апа,— мин әйтәм,— Рәхим итеп язып алыгыз!..»

Кыр казлары артыннан
биеклеккә тартылам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан...

Җырлап бетерүгә Хәлил коры гына:

— Туктале, карчык. Нәрсә дип бәйрәм көнне мондый җыр җырлыйсың? — димәсенме.

— Мин башка җыр белмим ич,— дим мескен тавыш белән.

— Белмәсәң дә мондый җыр җырлама! — ди ул тагы да кырысрак итеп.

Шулчак хуҗа кеше куркынып:

— Тукта әле, туган. Ул бит, соң... ни... без сораган өчен генә... Кызма әле, туган. Без гаепле, без сорадык бит җырлавын,— дип Хәлилне тынычландыра башлый. Бактың исә, хуҗабыз, эштән соң кайту сәбәпле, безнең уенны карый алмаган икән. Әлеге әңгәмәнең спектакльдән бер өзек икәнен белмичә, әнә шулай каушап, югалып калды ул.

— Кайчакта менә шулай да була,— дип рәхәтләнеп көлә Исламия.

Зәңгәр күзләрендә бәхет очкыннары кабына. Юк, күзләрендә генә түгел, һәр адымына, һәр кул хәрәкәтенә күчә. Берсе пианинода уйнап, берсе җырлап утырган кызлары янына килеп, башларыннан сыйпый. Әле Лилиясенә, әле Ләйсәненә кушылып, күңелле балалар җырын башкара.

Кайвакыт Исламиядән: «Кызларыгызны музыкага кайчан өйрәтә башладыгыз?» — дип сорыйлар. Ул исә күренекле венгр композиторы Золтан Ходаи сүзләре белән җавап бирә: «Туганчы тугыз ай алдан!..» Хәер, Исламиянең үз күңеленә дә туганчы тугыз ай алдан кереп оялмадымы икән ул музыка дигән серле сәнгать. Чөнки әтисе Һидиятулла, әнисе Мәрвияне Түбән Әлкидә генә түгел, бөтен тирә-юньдә җырчы Мотыйгуллиннар дип беләләр. Заманында аларны хәтта башкалага да чакырып карыйлар. Ләкин Һидиятулла абыйның сүзе нык була. «Кулымда егәрем, күкрәгемдә йөрәгем булганда, балаларыма үзем үстергән ипекәйне ашатачакмын!» — ди. Һәм дөрес әйтә. Балаларында гына түгел, оныкларында да авыл кешесенә, туган җиргә карата мәхәббәт хисе тәрбияли.

Туган җиргә мәхәббәт дигәннән, ниндидер сәбәпләр аркасында читтә оя типкән кешеләр белән очрашырга туры килә Исламиягә. 1981 елда Татар дәүләт драма һәм комедия театры өч сәхнә әсәре: Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», М. Гафуриның «Кара йөзләр», И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан» спектакльләре белән Ленинградта гастрольләрдә була. Спектакльләрне карарга Финляндиядә яшәүче татарлар да килә. Күрешеп, сөйләшеп утыралар. Менә шул чакта туган җиреннән аерылган кешенең җирсүенә, туган илен сагынуына, Тукаебыз әйтмешли, әткәсе-әнкәсе телен тансыклавына шакката Исламия. Сагынып саргаю әнә ничек була икән дип уйлый ул. Туган илендә туган халкың белән бергә яшәүнең олы бәхет икәненә инана. Шушы очрашулардан соң Исламиянең иҗат фантазиясенә тагын бер яңа төсмер өстәлә. Илең, җирең, сөйгәнең белән бергә булуның олы бәхет икәненә тагын да ныграк басым ясау теләге уяна. «Бергә гомергә...»

Әнә шулай туктаусыз эзләнә Исламия. Олы сәнгать осталарының иҗатын өйрәнә. Казанга килгән бер генә гастрольне дә, коллегалары уйнаган бер генә спектакльне дә карамыйча калмый. Эшлисен эшләдем дип, кул кушырып, канәгатьләнеп утырмый, ирешкән уңышлары белән бервакытта да

һаваланып сөйләшми. Яңадан-яңа образлар — тормышка, халыкка якын геройлар иҗат итү өстендә эшли.

Исәпләп карасаң, ел әйләнәсенә сигезтугыз ай вакытын халык арасында яши Исламия. Икмәк үстерүчеләр, терлек караучылар, Азык-төлек программасын тормышка ашыручылар арасында. Кышкы суыкларда туңып, җәйге чилләләрдә сусап, алҗып та, талчыгып та алган чаклары була аларның. Әмма барыбер ярата, барыбер үз итә ул авылны, аның кешеләрен. Кайтып, шәһәрдә бераз яшәүгә, күңеле юлга чакыра башлый. Саф йөрәкле, дөрес күңелле авыл кешеләре белән очрашу үзе бер гомер булып тоела аңа. Кешеләрне шатландыру, алар өчен күпмедер вакытка рәхәтлек тудыру аның кодрәтендә икән — нигә әле кулыннан килгән шул яхшылыкны эшләмәскә?! Елмайсыннар, көлсеннәр, күңелләре күтәрелсен кешеләрнең дип уйлый артистка. Күңел күтәренке вакытта әллә ни гомер кул бармый яткан эшләрне эшлисең, әллә нинди авырлыкларны да җиңәсең бит ул...

— Беләсеңме? — Исламиянең зәңгәр күзләреннән нур көлтәсе тарала.— Андый вакытта үзем дә карыш ярымга үсеп китәм мин. Буем түгел, билгеле, күңелем үсә, сулыш иркенәя, дөнья яктыра...

Балачагыннан белә Исламия: артистларның авылга килүе — көтеп алынган бәйрәм. Ә бәйрәмнең бөтенлеге, матурлыгы артистларның намуслы хезмәтенә бәйләнгән. Залда берьюлы йөзләгән күз, йөзләгән йөрәк күзәтә аларны. Йөзләгән акыл йөз төрле фикер йөртә. Әнә шул вакытта килде-китте уйнап кара син! Зәвык югары, ихтыяҗ зур халыкта. Халык бер вакытта да яхшыны — начар, начарны — яхшы димәс. Үзен борчыган гаделсезлекне күзеңә карап әйтер. Турыдан ярып, Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәрендәге укытучы Нурия шикеллерәк.

Нурия образы Исламияне кабат яшьлегенә алып кайта. Чөнки ул театрга килгәнче бер ел булса да пионервожатый булып эшли. Дөрес, ул эшләгән мәктәптә спектакльдәге кебек конфликт булмый. Биредә балалар язмышына бармак аша карап, гаделсез хөкем йөртмиләр. Нурия образын иҗат иткәндә олы йөрәкле, киң күңелле, туры сүзле аксакал педагогларның якты сыйфатлары өлге булып тора аңа. Нәтиҗәдә менә дигән, тормышчан укытучы образы туа.

Һәр артистның иҗатында аеруча истә калырлык образлар була. Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» әсәрендәге Ясминә роле — Исламия өчен шундый образларның берсе. Беркемне дә кабатламыйча, зур осталык белән, мавыгып, үзенең геройняларын тирән аңлап уйнавы Исламия Мәхмүтованы күпкырлы талант итеп танытты. Бактың исә, нечкә хисле, киң күңелле, сабыр холыклы хатын-кызларны гына түгел, әйтик Риза Ишморатның «Кайту» әсәрендә сурәтләнгән аяусыз, усал, зәһәрен чәчеп торучы пырдымсыз Мәхмүзәләрне дә бик шәп уйный икән әле ул. Авыр сугыш елларында илдә икмәк өчен көрәш бара. Ил йөген төпкә җигелеп тартучы фидакарь хатынкызлар янында гайбәтче, башкалар исәбенә яшәргә омтылучы Мәхмүзәләр дә яши. Гыйбрәтле хәл. Әмма иртәме-соңмы, Пытымыр Мәхмүзә үз сыныгын, үз өлешен тир түгеп, хезмәт куеп табу юлына баса.

Исламия башкарган рольләрне саный китсәң, алар бүген илледән артык. Ул — үз тамашачысын инде күптән тапкан, меңләгән йөрәкләрне сөендергән, шатландырган сәхнә остасы. Татарстанның халык артисткасы!

Колхозчы гаиләсендә туып, алты бала арасында тәрбияләнгән гади авыл кызына — халык артисткасына кадәр үсү өчен күпме тырышлык кирәк булган. Хезмәт юлын бутафорчы кассир булып башлаган унсигез яшьлек кызга әлеге үрне яулау өчен күпме вакыт кирәк булган. Ике дистә елдан артык! Азмы, күпме бу вакыт? Егерме өч ел рәттән түгел, ә нибары бер җәен, бер язын балаларыннан башка каршылаган, нибары бер кышта бурап яуган кар көртләрен ерып юл йөргән, нибары бер көздә үзәкләргә үтеп искән әче җилләргә каршы атлаган кеше әйтсен. Азмы, күпме ул егерме өч ел буе тоташ юл йөрү?!.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.**

# ҖӘҮҺӘРЛӘРГӘ ТУЗАН КУНМАСЫН

Татарстанда СССР Сәнгать академиясе, Бөтенсоюз декоратив-кул эшләре һәм халык сәнгате музее, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, ТАССР Художниклар һәм Язучылар союзлары катнашы белән оештырылган комплекслы гыйльми экспедиция эшләде. Бу экспедиция алдына куелган практик максат халык һөнәрчеләре эшләгән эшләрне җыеп, Бөтенсоюз музеенда Татарстан коллекциясен туплау һәм Татарстан китап нәшрияты чыгарасы альбом өчен материал әзерләү булса, фәнни максат милли культурабызның үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү, халык һөнәрчеләрен барлау, хәзерге авылның ничегрәк бизәлүен күздән кичерү булды. Өйрәнү-эзләнүләрдә сәнгать фәннәре докторы Н. Воронов, сәнгать фәннәре кандидаты Д. Вәлиева, РСФСРның атказанган рәссамы Ә. Тумашев, ТАССРның халык рәссамы Т. Хаҗиәхмәтов, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре К. Миңлебаев, тарихчы Җ. Мөхәммәтшин, сәнгать белгече Г. Павелковская катнашты.

Экспедициянең җитәкчесе — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре кандидаты С. Червоннаядан шушы өйрәнү вакытында республикабызның төрле районнарыннан җыелган материаллар, халык сәнгатенең бүгенгесе һәм киләчәге турында тупланган фикер һәм уйлանулары белән уртаклашуын үтендек.

## 1. Чишмә

Чишмәсе лә чишмәсе! Тешне сындырырлык салкын саф су бер киртләчтән икенче киртләчкә челтер-челтер ага да ага. Чишмәнең көмештәй челтерәве Кукмара районындагы «Россия» колхозы басуында комбайннар гүләвенә шигъри ямь өстидер, кичке эңгергә талган Сәрдекбаш поселогының тынлыгына бертөрле моңсулык бирәдер сыман. Ә чишмә өстендә бизәкләпуеп эшләнгән, әкияттәгедәй матур, бәләкәй генә бер өй нурланып-балкып утыра. Өйчекнең кыегына «алтын» әтәч менеп кунган. Гүя ул — Пушкин әкиятеннән Тукай шигърияте аркылы егерменче йөз башында ук татар поэзиясендә урын алган әтәч: менә-менә салават күпередәй койрыгын чөеп, канатларын җилпеп, кычкырып җибәрер шикелле...

Бу бәләкәй өйне дә, әтәчне дә агачтан эшләгән кеше — Мөхәрләм Ихсанов, колхозның партоешма секретаре Г. Низамов сүзләре белән әйткәндә, алтын куллы кеше. Юк, һич тә мактап әйтүе түгел партком секретаренең, гаделлек шуны таләп итә: бу авыл остасының барлык һөнәрен саный китсәң — ул механизатор да, төзүче-коручы да, архитектор да, үзе үк гидротехник та һәм, әлбәттә, балта остасы да икән. Казан артындагы районның исеме нәкъ әнә Мөхәрләм шикелле һөнәр ияләренең гаҗәеп зур осталыгына соклanудан килә дә инде: Балтач авылы, Балтач районы.

Татарстанда эшләгән комплекслы гыйльми экспедиция алдына куелган төп максат Арча, Балтач, Кукмара, Саба районнарында яшәүче һөнәр ияләренең иҗатын өйрәнүдән гыйбарәт иде. Аннары без, Питрәч районы аша Казанга сугылып, Каманың аргы ягына — Куйбышев, Алексеевск, Әлки районнарына барып чыктык. Экспедициябезнең «комплекслы» дип аталуы аның берничә оешманы эченә алуыннан яки төрле профессия әһелләре (борынгы һәм бүгенге сәнгатьне өйрәнүчеләр, музей хезмәткәрләре, язучы һәм рәссамнар) катнашканнан гына түгел, ә бәлки безне кызыксындырган мәсьәләләрнең күп төрле булуыннан да килеп чыга: борынгыдан калган сәнгать әйберләренең саклануын, бүгенге авылның эстетик йөзен, художество һөнәрчеләренең киләчәген, үзешчән осталарның иҗатын, авыл җирендә төзелгән музейларның ни белән шөгыльләнүен, халыкның милли художество культурасын үстерүгә хезмәт итәрлек нинди резервлар барлыгын анықлау, күрү һәм өйрәнү иде ниятебез.

Әйтүе ансат та бит, моннан йөз ел чамасы элек тукылган-чигелгән көнкүреш әйберләрен табуы алай ук җиңел түгел: берданн, алар бүгенге көндә кулланудан чыгып беткән; икенчедән, мондый үрнәкләрнең күбесе югалган, таушалган-тузган яки бөтенләй ташланган. Ә бит безгә әле бүген дә кыйммәтен җуймаган әйберләр кирәк. Без шу-

ларны кыска вакыт эчендә эзләп табарга, җае чыкса, музей өчен сатып алырга, анда да әле һәркайсының кайчан һәм кем тарафыннан эшләнгән булуын анықлап, кәгазьгә теркәргә тиешбез. Музейда һәммә нәрсәнең дә исеме тәгаенләнгән булса гына кызыклы. Югыйсә аның кыйммәте әллә ни зур булмый. Останың исеме югалырга тиеш түгел.

Татар халкы киң күңелле бит ул. Еш кына әти-әнисенең, әби-бабасының төсе итеп сакланган кыйммәтле нәрсә өчен акча алмый, ул аны үз кулы белән музейга бүләк итә:

— Һич тә малга кызыгып бирүем түгел, мин аны гомердә дә сатмас идем, әйдә, бүләк булсын...

— Сугыш елларында да сатмадык, хәзер аны сатарга калмаган, тормышыбыз әйбәтләнде. Музейга кирәк булганга гына бирүем...

— Әнием төсе итеп саклый идем. Мин үлсәм, яшьләр аның кадерен белмәс. Ичмаса, музейда саклансын...

Кайбер авылның яки төбәкнең исталекле әйберләрен (сәнгать әсәре буларак кыйммәткә ия булырдайларын) фотога төшерәбез, рәссамнарыбыз сурәтен ясап ала. Әйтик, Әтнә, Күпербаш, Балтач, Шеңшеңәр авылларында матурлап-бизәп эшләнгән өйләр, Казиле, Кәчимир, Яңа Үргәгар авылларында агачтан яки таштан салынган һәм беркем беркайчан язып чыкмаган мәчетләр, иске зиратларда сакланган матур каллиграфияле борынгы кабер ташлары (бу өлкәдә безгә Болгар дәүләт тарих-архитектура заповедникы директоры Җәмил Мөхәммәтшин зур ярдәм күрсәтә)... Болгарда һәм Биләрдә археологлар казып яткан чокырларның бормалы юлларын өйрәнәбез. X—XII гасырларда Бөек Болгар осталары ясаган керамика әйберләрен профессор А. Халиков кулыннан музей өчен кабул итеп алабыз. Татарстанда борынгы традицияләрне дәвам иттерүче тармаклар яки бөтенләй яңа художество промыселлары белән танышабыз, җирле промышленность чыгара торган продукциягә карата сокланубызны белдерәбез, кимчелекләрен әйтәбез, ул предприятиеләрдә эшләүче оста куллар белән әңгәмә алып барабыз, җитәкчеләргә киңәшләр бирәбез, авыл Советлары, мәктәп, клуб, музейларда халык сәнгатен барлау, җыю һәм саклый белеп саклау кагыйдәләрен өйрәтергә тырышабыз.

Һәммә җирдә безне ачык чырай белән каршы алалар, ярдәм кулы сузарга әзер торалар. Югыйсә без бер айдан ким вакыт эчендә сигез районда, кырыклап авылда яки поселокта булып, музей өчен 60-70 күркәм әйбер тапмас идек, йөздән артык исталекле урынны күреп, авыл халкының өйләрендә, һөнәр ияләренең остаханәләрендә, сәнгать промыселлары предприятиеләрендә булып, меңнәрчә сәнгать әсәрен күреп өлгерә алмаган булыр идек. Ә бит без күргәннәр арасында ничаклы әйберләр — күнгә төшерелгән бизәк, тукыма, чигү, ювелир үрнәкләре, рәсемле яки матур язулы шамаилләр һ. б. бик күп сокланырлык нәрсәләр дә бар.

Халыкның көнкүреше белән кызыксынабыз. Авыл культурасын тудыручы һәм аның өчен үзләрен җаваплы санаучы осталарны күреп сөйләшәбез. Предприятиедә яки өйдә эшләүче күпме кешенең, кайвакыт еллык план, айлык план үтим дия-дия, ата-бабадан килгән гүзәл традицияләрне онытырга, җиңел кулдан продукция җитештерү юлына басарга мәҗбүр ителүен күреп көенәбез. Авыл клублары, мәктәп музейлары, картина галереяларында сакланган җиһазларны күреп сөенәбез.

Арча районындагы Казиле авылында гаҗәеп бер корылмага — авыл җирендә сирәк очрый торган таш мәчеткә юлыктык. Татар халкының архитектурасы тарихына кагылышлы фәнни хезмәтләрдә бу корылма турында әле моңарчы берәүнең дә язганы юк. Бары тик авыл халкының буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән хикәяте мәчетнең салыну тарихын онытмаска ярдәм иткән. Безгә аны шул авылда гомер кичергән Солтан абзый Гыйлфанов сөйләде.

Казиле мәчете XIX гасырның азагы һәм XX гасыр башында корылган; архитектурасында Казан осталарының кулы сизелә (шуннан алда гына — 1890 елда — Әҗем мәчете җиткерелгән була); кирпечне дә губерна каласыннан ташыйлар, витражлар өчен төрле төстәге пыяланы да шуннан китерәләр; авыл җирендә агач мәчетләр җиткерү стилен дә читләтеп үтмиләр — иркен зал булдырып, манараны төньяктагы очына ук чыгарып утырталар; осталарны мишәр якларыннан да, Балтач белән Чүтидән дә чакырталар. Әллә ни бизәп тә эшләнмәгән инде югыйсә, шулай да мәчет гаҗәеп мәһабәт күренә. Аның кирпечтән сырлап салынган диварлары да, михраб ягында төрле төстәге пыяладан корылган витражтәрәзәсе дә бер күркәмлек биреп тора. Мәчет бинасы яхшы сакланган, һәм анда хәзер авылның культура йорты урнашкан. Бары тик 1978 елгы җил-давыл гына мәчет манарасының очындагы айны очыртып төшергән, һәм хәзер ул (бакырдан өреп тутырылган ай үзе бер сәнгать әсәре!) мәчет каршындагы бер өйдә саклана. Казиле мәчете үзенең оригинальлеге белән дәүләт тарафыннан саклана торган тарихи биналар исемлегенә кертелергә, шулай ук Татарстанга багышланган альбомнарда һәм архитектура басмаларында һичшиксез урын алырга лаеклы.

Халык иҗатының традицияләре зур биналар, әйтик, агач мәчет кору эшендә дә нык чагыла. Әмма аларның күбесен хәтта әле сәнгать белгечләре дә юньләп белми. Шул ук вакытта әлеге корылмаларга җәмәгатьчелекнең игътибары артуын, респуб-

ликада аларны тәзекләндерү эшенең җайга салынуын, дәүләт күләмендә кайгыртучанлык күрсәтелүен әйтеп үтәргә кирәк.

Кукмара районының Уразай авылында узган гасырда ук салынган агач мәчет реставрацияләнеп беткән диярлек — түбәсен дә яңадан ябканнар, мәһабәт манарасын да сипләгәннәр. Шундый зур эшләр тәгәлләнгәннән соң, ул бинада туган якны өйрәнү буенча мәктәп балалары җыйган музей экспонатлары коллекциясе бик әйбәт сакланачак. Шул ук районның Кәчимир авылындагы агач мәчетне дә элекке хәленә кайтару мәсьәләсе хәл ителгән. Архитектура массаларының бер-берсенә ятышып торуы, пропорцияләренең төңгәл килүе гүзәл сәнгать әсәре тудыра: аның бер-беренә беректереп, өч буйдан салынган бинасы бер түбә астына сыенган; сигез почмаклы биек манарасы катлы-катлы итеп эшләнгән, урта бер җирендәге балкон балюстрада-баганалар белән түгәрәкләп уратып алынган; өскә таба очлайган манара зәңгәр күккә төбәлгән.

Кайсыбер мәчетләрдә бүгенге көнгәчә кыйммәтле эчке җиһазлар сакланган. Халык архитектурасының андый үрнәген без Әлки районындагы Яңа Үргәгар авылында күрәбез. Анда, Шәрык илләреннән китерелгән паласлар белән бизәлгән, шул авылның оста чигүчеләре тамбурлап, чәчәк бизәкләре төшереп чиккән затлы нәрсәләр, бизәкләр уеп төшерелгән сокланггыч мөнбәр, шулай ук мондагы шәмаилнең каллиграфияле язуы һәм төсләре дә уңмыйча саклануы аеруча ямь бирә. Ә инде биредә ювелир сәнгатенең төрле өлгеләре һәм борынгыдан калган китапларның да булуы мәчетне музейга охшата.

Сәнгать тарихы өчен фәкать мәчетләр генә түгел, матурлап-бизәп эшләнгән өйләр дә зур кызыксыну уята. Мәсәлән, Әтнәдә колонналап-сырлап салынган ике катлы йорт үзе генә дә ни тора. Андый сәнгать әсәрләрен эстетик яктан дөрес бәяләү аларның яхшы саклануына игътибарны тагы да арттырыр иде.

Ә шулай да иң зур игътибарны борынгы татар зиратларындагы кабер ташларына юнәлдерү зарур. Тарихчылар һ. Йосыпов, Ф. Хәкимҗанов, Җ. Мөхәммәтшин һ. б. галимнәр тарафыннан болгар-татар эпиграфикасын өйрәнүгә күркәм өлеш кертелде: күп кенә кабер ташларындагы язмалар билгеле бер фәнни системага салынды, тарихи яктан тәгаен ачыкланды; эстетик яктан чыгып, һәркайсына лаеклы бәя бирелде. Болгардагы тарих-архитектура заповедингында җыелган кабер ташлары экспозициясе үзе бер музей ташкил итә. Татарстан АССР Берләштерелгән дәүләт музеенда да гаҗәеп зур кыйммәткә ия кабер ташлары коллекциясе тупланган. Ләкин, гомумән алганда, эпиграфика сәнгате әсәрләренә игътибар җитешми: алар шул иске зиратлар урынында ташландык хәлдә мүкләнеп ята бирәләр... Әйтик, Арча районының Олы Мәңгәр авылы артындагы борынгы зират әнә шулай ташландык хәлендә. Ә бит анда дөнья бәясе торырлык сәнгать әсәрләре — XVI йөзнең беренче яртысы — «Казан ренессансы»на караган кабер ташлары ачык һавада, юл буенда ауган-түнгән килеш яталар! Ул ташларда, уйлап карасаң, архитектура, пластика, графика, шигърият, сүзләрнең матур язылышы — һәммәсе бергә килеп кушылган. Әлеге кыйммәтле сәнгать әсәрләрен җимертми-нитми саклау — бөтенебезнең дә изге бурычыдыр.

Хәер, язулы кабер ташларының кыйммәте аларның борынгылыгыннан гына да килми. Әйтик, Балтач районы, Түнтәр авылы зиратында сакланган кабер ташларындагы язуларга карап, әлеге милли сәнгатьнең үзгәрү рәвешен һәм XVIII йөздә нинди булганын аермачык күзалларга мөмкин. Күлле-Киме зиратындагы кабер ташларына матурлап язылган язулар бу төр халык сәнгатенең әле бүген дә яшәвен раслый. Бу хәл үзе генә дә ташка язу сәнгатен монументаль-декоратив пластикага җайлы гына кертеп җибәрү мөмкинлеген ача.

Бөтенроссия музеена Арча районының Казиле авылында яшәүче колхоз пенсионеры Фатих абзый Закиров, Балтач районының Шөнщеңәр авылы колхозчысы Мөнәвәрә апа Хәйруллина өйләрендәге шәмаилләрне бүләк итеп бирделәр. Куйбышев районының Ямбакты авылында яшәүче Бибисара Хәйруллина өендә дә без милли орнамент төшереп язылган шәмаил күрдек. Татар авылларында ишек янсә тәрәзә башына элеп куела торган шәмаилләрнең, әлбәттә, һәркайсы да сәнгать әсәре була алмый. Әмма Коръән аятен ничек җитте алай гына күчереп язган, бернинди бизәк-рәсем төшермәгән урта кул әйберләр арасында зур осталык белән язылган, рәсем яки орнаментбизәкләр төшерелгәннәре дә очраштыргалый. Андыйлары, һичшиксез, татар халык сәнгатендә лаеклы урын алырга тиеш. Әйтик, Әлки районының Иске Үргәгар авылында пенсионерка Минҗиһан апа Кәшшафова музейга бүләк итеп биргән шәмаилнең тексты типографиядә басылган. Ул каллиграфия остасы Исмәгыйль Нәҗметдин улы Шәмсетдинов (Әйшә авылыннан) язганнан соң, рәссам А. Кокаревның Казандагы типо-хромо-литографиясендә 1902 елны басылган булып чыкты.

Кызганычка каршы, республика музейларында шәмаилләр аз җыелган, әле анда да фондта гына сакланып, экспозициягә бик сирәк очракларда куела. Ә бит бу чынчынлап халык сәнгате! Рус халкы борынгыдан калган икона-сурәтләргә сак караган кебек, татар халкы да сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән (матур каллиграфия белән бергәттән, милли орнаментны да эченә алган) шәмаилләрне кадерләргә хак-

лы. Игътибарга шунысы лаек: халыктан чыккан осталар дин сүзләре урынына еш кына тапкыр-зирәк мәкаль-әйтем яки бәет сүзләрен, яисә Тукай шигырен, ә менә революциядән соң — Совет хөкүмәтенең лозунгларын язып куя торган булганнар.

## 2. Халык осталары

Казан татарлары арасында көмешчеләр һәм бүтән төрле осталар борын-борыннан ук яшәп килгән. Әмма бу өлкәдә эшләргә омтылучыларның саны торган саен кими бара. Әйтик, Саба районының Тенеки авылында халыктан чыккан Хәбибрахман Ганиев үз кулы белән күпме беләзек, йөзек, алка, чулпы житештергән — һәр нәрсәне дә күңел биреп эшли-эшли, күпме кешене сөендергән! Ата-бабадан килгән һөнәренә үзенең улын да өйрәткән. Әмма улының инде көмешче булып калырга исәбе юк: бигрәк мәшәкатьле мондый эш белән бүгенге көндә «тамагыңны туйдыра» алмыйсың.

Бу авылда янә дә бер көмешче — Фәттахетдин абзый Хисамиев моннан ике-өч ел гына элек дөнья куйган. Без аның кулы белән эшләнгән зиннәтле әйберләрне музей өчен останың хәләл җефете Өммекамал апа белән кызларыннан алдык. Әмма кайчандыр үзенең көмешчеләре белән дан тоткан төбәктә без бүтән бер генә останы да таба алмадык...

Партиянең Саба район комитетында борчылып әйткән сүзләребезгә, әлбәттә, колак салдылар, киләчәктә ничек кенә булса да бу төбәктәге һөнәр изләренә игътибар күрсәтергә булдылар. Татар халкының ювелир сәнгатенә бөтенләй юк сүнәргә ирек бирмәс өчен, бүгенге көндә ниләр эшләргә кирәк соң? Безнең карашыбызча, иң әүвәл, халык арасыннан чыккан рәссамнарны, осталарны һәр төбәктә, һәр районда исәпкә алырга кирәк; аннары бу һөнәрчеләргә азмы-күпме кулы ятырдай яшьләрне беркетергә мөмкин булыр иде; шуннан соң инде аларны, Татарстан Культура министрлыгы белән сөйләшеп, иҗади производство комбинаты аркылы махсус заказлар белән тәэмин итү ягын кайгырту зарур. Әнә шулай дәүләт эше дип караган очракта сирәк һөнәрләр белән шөгыльләнүчеләр саны да артыр, һәм алар башкарган затлы әйберләр дә бүгенге халык сәнгате өлгеләре сыйфатында музейларда лаеклы урын алыр иде. Казан татарларының гасырлар буе яшәп килгән ювелир сәнгатен бетерергә — Россия Федерациясенең культура картасыннан сызып ташларга безнең хакыбыз юк! Республикада бу эшләрне киң күләмдә җәелдереп җибәрү мөмкинлекләре аз түгел.

Халык осталарының үз эшләрен профессиональ сәнгатькә якынлаштырырга омтылуыннан да бигрәк, аларның нәкъ шушы төбәктә элек-электән килгән милли традицияләрне дәвам итүләре кыйммәт. Әйтик, без экспедиция вакытында Балтач районы Шеңшеңәр авылында яшәүче балтачы — өй кыекларын, тәрәзә яңакларын, койма һәм капкаларны төрлечә бизәп, үз авылына да, тирә-яктагы башка авылларга да ямь өстәүче Рәшит Гариповның хезмәт җимешләрен күреп сокландык. Шул ук районның Исмәгыйль авылында халык остасы Мөхәммәтнәби Шәяхмәтовның тал чыбыгыннан гаҗәеп бер эстетик зәвык белән үргән өстәл, диван, карават, кресло-урындыкларын күрү бәхетенә ирештек. Хәер, аның хатыны Зәкия апа да туку-чигү эшләре белән һич тә аннан калышмый икән. Арча районының Әтнә, Маңгәр авылларында кул осталарының хезмәтенә бүгенге көнне дә яшьләрнең игътибарлы килүен, аларның хезмәтенә хөрмәт белән каравын һәм әби-әниләренең һөнәрен дәвам итүен күреп сөендек. Сөенмәслек тә түгел бит: димәк, бу якларда милли сәнгатькә сүнәргә юл куймаячаклар!

Кызганычка каршы, татар халкы сәнгатенең бүгенге көндә нинди хәлдә икәнлеге тиешенчә чагылмый, аның гүзәл казанышларын Татарстан сынлы сәнгать музеенда да, Зеленодольскидагы махсус халык иҗатын һәм этнографияне пропагандалаучы музейда да очрата алмыйсың. Шулай ук сәнгать белгечләре дә үзләренең фәнни хезмәтләрендә бүгенге һөнәр иязләрен читләтеп үтү ягын карыйлар... Ә бит бу төр сәнгать автономияле республиканың социалистик культурасына турыдан-туры бәйләнә, һәм аның казанышлары игътибарлы булуны, халык һөнәрчеләренең бүгенге хезмәтенә дәүләт күзлегеннән чыгып карауны, кыйммәтен-кадерен белүне сорый.

## 3. Үзешчән рәссамнар хезмәте

Авылдагы үзешчән сынлы сәнгатькә аерым тукталмыйча ярамый. Экспедиция вакытында без төрле авылларда энтузиастлар ясаган эшләрне очраттык. Арада акварель яки майлы буяу белән язылган табигать күренешләре дә, натюрмортлар да, чүкеп яки чокып ясаганнары да бар. Балтач районы башкарма комитеты культура бүлегендә без әле генә республика Халык иҗаты йортында үткәрелгән смотрдан әйләнеп кайткан «шүрәлеләр»не, «су аналары»н күрдек.

Үзешчән рәссамнарның хезмәтен бәяләүгә төрлечә килергә туры килә. Әгәр андый рәссам, табигатьтән килгән сәләтен йомып калдырмыйча, үзенең туган авылын матурлауга, бизәүгә юнәлдерә икән, бу, әлбәттә, мактауга лаек. Колхоз бюджетына һич зарар китерми генә башкарылган мондый хезмәт еш кына хәйран уңышлы чыга. Аның кыйммәте — үзенчәлекле булуында

башкалардан аерылып торуында, беркемне кабатламавында. Ә инде үзешчән рәссам халык арасында популярлык казанган һәйкәл яисә картинага охшатып ясарга маташа башласа — адәм мәсхәрәсе килә дә чыга. Республика авылларында, кызганычка каршы, андый хәлләр дә очрый.

Олы Мәңгәрнең киң урамына кыйммәтле металлдан (титан) Казанның Культура һәм ял паркы алдындагы һәйкәлгә охшатырга тырышып «обелиск» әмәлләп куйганнар. Еш кына мондый «заказ»ларны үтәгән өчен колхоздан яки совхоздан шактый гына каералар. Ә бит шул ук суммага худфондтан намуслы профессионалларны да чакырырга мөмкин булыр иде.

## 4. Сәнгать промыселлары

«...Күпчелек предприятиеләрдә иҗади процессны оештыру әле һаман ныклы системага салынмаган. Киң массаларга чыгарыла торган продукциянең художество дәрәҗәсе һәрвакытта да югары булмый. Кабатланмау хас булган иҗади кул хезмәте бик аз керә. Билгеле, һәр промыселда үзәк фигура — халыктан чыккан оста, художник. Ләкин аның индивидуаль осталыгына еш кына тиешле бәя бирелми, иҗади зарурлыкка кирәгенчә игътибар ителми...»

«Правда» газетасының 1984 ел, 26 августында басылып чыккан баш мәкаләсендә әйтелгән бу фикерләр Арча милли аяк киемнәре производство берләшмәсендәге хәлләргә бигрәк тәңгәл килде.

Берләшмәнең баш художнигы Илдус Гайнетдинов белән без шактый озак сөйләшеп утырдык. Мәскәүдә җиңел промышленность институтын тәмамлап кайтканнан соң Арчада әле өченче елын гына эшли. Татар халкының борын-борыннан килгән читек чигү, күнгә бизәкләр төшерүнең эстетик төмен-бәясен яхшы белә. Әмма производство берләшмәсендә катгый планлы эш барышында яшь белгеч ниләр генә майтара алыр икән? Берләшмә хәзер елына бер миллион пар чамасы аяк киеме чыгарса, киләчәктә ул күләмне икеләтү күздә тотыла.

Казан күн берләшмәсеннән килә торган хромы да бит әле сыйфат ягыннан ташка үлчим! Бар син аңа катлаулы бизәкләр төшереп кара! Әле бит аның төрле экспериментлар үткәрү өчен лабораториясе дә, осталар группасы да юк. Баш рәссам көннең көнендә иҗади булмаган эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Шунсыз планы да үтәлми бит әле...

Арчаның үзендә яки берләшмәнең унҗиде филиалында яисә өйдә утырып эшләүчеләр тәшкил иткән чигү цехларындагы хатын-кызларның зәвыгы да гомумпродукциянең эстетик кыйммәтен күтәрүдә азмыкүпме файда китерә ала. Шул берләшмәдә эшләүче Фазилә Гайнетдинова белән Гөлнадия Галиәхмәтова чиккән читекләр юкка гына 1980 елны Лейпциг ярминкәсендә Алтын медальгә лаек табылмагандыр лабаса. Әмма андый сәнгать әсәрен житештерү өчен бит әле аның күне дә йомшак булырга тиеш, төс ягыннан да затлы булуы зарур, бизәген дә сайлый белергә кирәк, чигүчеләрне дә план үтәгәндәгечә куаларга ярамый...

Татарстандагы иң яшь художество мәктәбе Арчада ачылган. Аның директоры Габделбәр Бәхтияров, мәктәп программасыннан тыш, балаларда әле тагын ничек кенә булса да күн производствосына мәхәббәт уятырга, өстәмә белем бирергә, киләчәктә берләшмә өчен кадрлар әзерләргә хыяллана.

Хәер, ни генә димә, әлеге берләшмәдә күпме кеше янып-көеп эшли, үзләре эшләп чыгарган аяк киемнәре белән һәркайсыбызны сөендерә, киләчәкне уйлый, кайгырта. Ә менә Питрәч керамика участогы бөтенләй сүнгән, сүрелгән, киләчәккә дә өмете өзелгән. Егерменче елларда «Татарстан» артелендә гөрләтеп эшләп яткан осталар таралган: кайсы кочегар, кайсы каравылчы булып эшли... Керамика производствосының элеккеге данын кайтару өчен аны өр-яңадан торгызасы, борынгы халык сәнгатенә якынайтасы, заманча мичләр, кип тергечләр булдырасы һ. б., һ. б. кирәк булса, бүгенге көндә ипле генә эшләп килгән Карадуган мебель фабрикасының Чепья цехына бераз гына игътибарны арттыру да бик житкән. Анда Исмәгыйль осталарының традициясенә таянып, иң гади кәрзинне дә, өстәл-урындыкны да хәйран гына матур итеп, челтәрләп үрәләр. Һич югы, күргәзмә яки музей өчен продукция әзерләгәндә генә булса да, чуар төсләрдәге полиэтилен чыбыкларны тал чыбыгы белән алмаштырган һәм ассортиментны яңабаштан карап чыккан — татар халкының милли традицияләренә якынайткан очракта, һичшиксез, бу фабриканы гаҗәеп үзенчәлекле художество промыселы дәрәҗәсенә күтәрү мөмкин булыр иде. Моның өчен Балтач районында бөтен мөмкинлекләр дә бар!

Игенче белән терлекчегә генә түгел, рәссамнарга да, реставраторларга да, музей хезмәткәрләренә дә, сәнгать тарихын өйрәнүчеләргә дә, укытучыларга да, культураның башка төрле өлкәләрендә эшләүчеләргә дә — һәммәбезгә дә авыл җирендә эш җитәрлек.

**Светлана ЧЕРВОННАЯ**,
сәнгать фәннәре кандидаты,
Татарстанның атказанган
сәнгать эшлеклесе

# МӘГЪРИФӘТ ЙОРТЫ

Моннан 80 ел элек мәдәни тормышыбызда күренекле вакыйга була: Казанда «Китапханәи исламия» исеме белән рәсми рәвештә танылган беренче татар китапханәсе ачыла. Аның беренче мөдире һәм башлап оештыручысы — «Йолдыз» газетасының редакторы Әхмәтһади Максуди. Мөдирлек вазифасын ул Октябрь революциясеннән соң да 1922 елга кадәр үти.

Бу китапханә турында татар укымышлылары озак еллар хыялланып яшәделәр! Казанда хәзерге В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе 1865 елдан бирле эшли. Ләкин монда татар телендә китаплар булмый. Татарлар китапханәне тоту өчен налог түләсәләр дә, аннан тиешенчә файдалана алмыйлар.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте киң җәелгән XX йөз башында татар халкы өчен үз ана телендә китапханә кирәклеге зарури булып көн тәртибенә килеп баса. Җәмәгатьчелекнең бу таләбен Һ. Максуди берничә мәртәбә шәһәр думасы алдына куя. Ниһаять, 1905 елның 8 февралендә үтенеч канәгатьләндерелә. Кирәк-ярак сатып алу өчен 590 сум акча, октябрь аенда китапханә өчен «Болгар» кунакханәсенең өченче катыннан кечерәк кенә ике бүлмә бирелә. Һ. Максуди үзе янына Закир Сәедов исемле бер хезмәткәр ала. Фонд туплау өчен дума биргән акча гына, әлбәттә, җитми. Һ. Максуди 100 китап, бертуган Кәримовлар 488 китап бүләк итә. Китапханәнең беренче эше әнә шул бүләк китаплар белән башлана. Китапханә шәһәр үзәк библиотекасының (хәзерге В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе) шөгъбәсе (филиалы) буларак, 1906 елның 2 гыйнварында рәсми рәвештә ачыла. Бу көн газета-журнал битләрендә күренекле вакыйга итеп билгеләп үтелә.

1916 елның 2 гыйнварында «Китапханәи исламия»нең 10 еллык юбилее үткәрелә. Тантанада рус галимнәре дә катнаша. Һ. Максуди җыелган халык алдында ун еллык эшкә хисап ясый. Бу вакытта инде «Китапханәи исламия» хәзерге Тукай белән Париж Коммунасы урамнары кисешкән чатта (3 нче номерлы тегү фабрикасы конторасы, 20 йорт) Кәримовлар йортының беренче катында чагыштырмача киң һәм якты бинада эшли иде. Әдәбият исемлеге дә 3 мең 500 данәгә җитә, фонд аерым кешеләр бүләк иткән китаплар хисабына да байый. Гарәп, фарсы, төрек әдәбияты туплана. «Әлгасрел-җәдит», «Шура», «Чүкеч», «Яшен», «Ялт-йолт», «Мелла Насретдин» журналлары, «Урал», «Йолдыз», «Вакыт», «Бәянел-хак», «Кояш», «Әхбар», «Азат», «Азат халык», «Казан мөхбире», «Нур», «Таң йолдызы», «Идел», «Тәрҗеман», «Шәркый рус» газеталары алына.

«Кояш» газетасының 1913 елгы 14 гыйнвар санында басылган «Казан китапханәи исламиясе» исемле мәкаләдә укучыларның Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинев, рус язучыларыннан Толстой, Пушкин, Тургенев, Гоголь, Лермонтов, Островский, Достоевский, Горький, Л. Андреев, Көнбатыш Европа язучыларыннан Байрон, Шекспир әсәрләрен яратып укулары әйтелә. Һәрхәлдә, «Китапханәи исламия» милли чикләнгәнлек юлыннан бармый, киштәсендә егерме исемдә рус газетасы һәм журналы тора. «Русские ведомости», «Камско-Волжская речь», «Новое время», «Русское слово» газеталарына сорау бигрәк тә зур була. Китапханә укучыларын фән һәм культураның төрле тармаклары белән таныштыруны максат итеп куя. Китаплар күрсәткечендә философия, хокук, социология, технология, авыл хуҗалыгы, математика, табигать, медицина, рус тарихы буенча әдәбият исемлеге бирелгән.

Китапханәнең беренче һәм төп укучылары — Казанның «Мөхәммәдия», «Халидия», «Касимия» һ. б. мәдрәсә шәкертләре, гимназия яшьләре. Яшьләр монда имтиханга хәзерләнгәннәр, үзләрен кызыксындырган әдәбият белән танышканнар. Бу мәгърифәт йортына халык торган саен күбрәк тартылган. 1906 елда аңа 13 мең кеше керсә, 1915 елда ул 22 мең 373 кешегә хезмәт күрсәтә. Китаплар өйгә бирелми, һәркөнне уку залына 150 кеше кереп утырып, үзенең белемен күтәрә. Кайбер көннәрдә урын көтеп, чират тезелүе турында газета битләрендә мәгълүматлар бар.

1905 елда утыз татар хатын-кызы, Казан шәһәр үзәк китапханәсенә керү өчен рөхсәт сорап, губернаторга гариза бирә. Гариза сигез ел хәрәкәтсез ята. «Китапханәи исламия» ачылгач кына татар хатын-кызларының үтенече канәгатьләндерелә. Аларга 1913 елдан башлап якшәмбе көннәрне көндезге сәгать уникедән дүрткә кадәр уку залына керү хокукы бирелә. Бу вакыйга шулай ук, татар хатын-кызларының белемгә, иҗтимагый тормышка омтылышын чагылдырган зур яңалык итеп, газета битләрендә билгеләп үтелә.

Юбилей көннәрендә китапларны өйгә бирү таләбе дә күтәрелә. Ләкин бу мәсьәлә Совет власте елларында гына хәл ителә. Китапханәнең эшчәнлеге тагын да киңәя, фонды арта. Аңа Суфия Таһирова, Зәйнәп Хәбибуллина кебек яшь хезмәткәрләр килә. 1922 елның маеннан китапханә Мулланур Вахитов исемендәге Шәрык китапханәсе дип йөртелә башлый. Китапханәдә белешмә-библиографик бүлек булдыруга омтылышлар ясала. Гыйльми эш

белән шөгыльләнүчеләр өчен аерым бүлмә булдырыла. Авыл китапханәләре өчен хезмәткәрләр хәзерләү курслары оештырыла. Габдулла Тукай исемендәге балалар бүлеге ачыла. Бу бүлектә 1923 елның сентябреннән 1924 елның июненә кадәр танылган драматург М. Фәйзи эшли. Ул үзенең көндәлекләрендә бу китапханәне җылы хисләр белән искә ала. М. Фәйзи кечкенә укучылардан әдәбият түгәрәге төзи, әдәби кичәләр үткәрә, китап



күргәзмәләре оештыра. «Коммунага» дигән пьесасын да шушында эшләгәндә яза. Пьесаны 1924 елның мартында балалар көче белән сәхнәгә куя.

Җыеп әйткәндә, Казанда рәсми рәвештә ачылган беренче татар китапханәсе — милли культурабыз тарихында якты бер сәхифә. Халкыбызның белем һәм иҗтимагый аңы үсешендә билгеле бер урын тота. Милли әдәбиятыбызның бай фонды Октябрьга кадәр нәкъ менә шушында тупланa.

1929 елда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карары белән китапханәнең татар фонды шәһәр библиотекасына кушыла, ягъни бу очракта үзәкләштерү күздә тотыла. Шул җирлектә шәһәр үзәк китапханәсендә татар бүлеге оеша һәм ул Шәрык китапханәсе тәҗрибәләренә таянып үсеп китә. Гарәп шрифты белән язылган әдәбият Казан университетының фәнни китапханәсенә тапшырыла. Бу әдәбияттан инде ничә буын галимнәр һәм студентлар файдалана. Мулланур Вахитов исемендәге 1 нче номерлы шәһәр библиотекасы да (Киров урамы, 57 йорт) үзенең башлангычы итеп Шәрык китапханәсен исәпли.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

## Ике Фәйзи

Әхмәт Фәйзи белән Җәүдәт Фәйзи якын дуслар иде. Берсе Мәскәүдә, икенчесе Казанда яшәсә дә болар еш кына очрашалар. Шулай бервакыт, шактый гына гәпләшеп утырганнан соң, боларның бик ашыйсылары килә. Җәүдәт Фәйзи:

— «Сүз бозау имезә»,— диләр,— ди ул.— Сүз боткасы белән тамак туймый, минем бит бик ашыйсым килә. Әллә мин әйтәм, йомырка пешереп, тамак ялгап алабызмы?

— Була ул, йомырка пешерүе бик җиңел, китер давай,— ди Әхмәт Фәйзи.

Җәүдәт Фәйзи:

— Йомыркаларны сәгатькә карап пешерергә кирәк,— дигәч, Әхмәт Фәйзи бер кулына йомыркалар икенче кулына сәгатен тота. Су кайнап чыгуга... йомыркалар урынына кайнар суга сәгатен тондыра...

Җәүдәт Фәйзи:

— Я инде, тизрәк бул, шактый вакыт узды, аны ике генә минут пешерергә кирәк,— ди. Әхмәт Фәйзи исә, тирләп-пешеп, су эченнән нәрсәнедер тартып чыгарырга маташа. Үзе:

— Йомырка... йомырка нәрсә ул, минем сәгатем кайнар суда пешеп ята,— дип сөйләнә...

*Журналист Рауза Газизова китерде.*

## Ничарадан бичара

Шулай бервакыт Шәрык клубы сәхнәсендә Г. Камалның «Беренче театр»ы куела. Хәмзә бай ролен Габдулла Кариев башкара. Биби ролен башкаручы артистка, бу рольдә күп мәртәбәләр уйнаган булса да, гадәттәгечә тотлыга, чөнки сүзләрне рәтләп ятламаган була. Кыскасы, аенны ул суфлерсыз ерып чыга алмаячак. Ә суфлер вазифасын үтәүче Исмәгыйль Рәми, будкада, дөньясын онытып, тамашага карап утыра. Әйтерсең, беренче тапкыр карый! Бу «тәртипсезлеккә» ачуы чыккан Кариевка, уен барышында суфлер будкасы яныннан үткәндә, «әшлексез» И. Рәминең борын шәрифенә тибеп китүдән башка чара калмый.

Суфлер үзенең будкасын ташлап китүенә карамастан, Г. Кариев аенны уңышлы башкарып чыга.

## Мөхәррирләр карасы

Самара (хәзерге Куйбышев) шәһәрендә татар телендә чыга торган «Икътисад» (Экономика) журналы үзенең 1911 елгы бер санында Казанда «Ай» исемле яңа ширкәт оештырылу хакында хәбәр итә. Хәбәрдән мәгълүм булганча, яңа ширкәт төрле төсләрдәге язу каралары, канцелярия җилеме, аяк киемнәре өчен крем һ. б. әйберләр житештерү белән шөгыльләнә. Эшләре рәтләнеп китсә, мөхәррирләр, ягъни язучылар, журналистлар өчен махсус «мөхәррирләр карасы» эшләп чыгару да күздә тотылачак, имеш. Кара савытларының «тышлыгындагы кәгазьләрендә — Каюм Насыйри, Риза казый (Р. Фәхретдинев), Гаспринский, Тукаев, Рәмиев, ...Г. Камал, Кәримов, Максудов, З. Бәшири кебек мәшһүр мөхәррир вә шагыйрьләрнең рәсемнәрен дә куячаклардыр»,— дип билгеләп үтә хәбәрнең авторы ...Зариф Бәшири.

*Җәүдәт Миңнуллин әзерләде.*

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ТУКАЙНЫҢ ЙӨЗ ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНАЛАР

11 июньдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы юбилей бәйрәме булды.

Президиумда — КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, ВЦСПС секретаре В. Н. Мокеев, Г. Тукай юбилеена әзерләнү һәм аны үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе члennары, тугандаш әдәбиятлар вәкилләре, иҗат союзлары җитәкчеләре, республикабызның хезмәт коллективлары, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре. Кунаклар арасында — РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Николай Доризо, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе һәм СССР, РСФСР, БАССРның Дәүләт премияләре лауреаты, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, «Правда» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге редакторы урынбасары, РСФСРның атказанган культура работнигы С. П. Кошечкин, Үзбәкстан ССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Үзбәкстан ССРның Дәүләт һәм комсомол премияләре лауреаты шагыйрь Абдулла Арипов, шагыйрь, тәрҗемәче, филология фәннәре докторы, Ленинград университеты профессоры С. Н. Иванов, Каракалпак АССРның халык шагыйре Байнияз Каипназаров, Чувашия АССР язучылар союзы идарәсе председателе П. В. Афанасьев, Мари АССР язучылар союзы идарәсе председателе Н. Ф. Рыбаков, РСФСР һәм БАССР Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Нажар Нәҗми, «Литературная газета» редколлегиясе члены А. Х. Хәкимов, СССР Язучылар союзы идарәсе партоешма секретаре, художестволы тәрҗемә советы җаваплы секретаре В. Х. Ганиев, Казахстан шагыйре Токэн Абдрахманов, Молдавиядән шагыйрь һәм прозаик Н. И. Бобогла, Астрахань язучылар оешмасы җаваплы секретаре А. И. Шадрин, «Советский писатель» нәшрияты редакторы Я. М. Мостафин, РСФСРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй Рәхим һәм башкалар.

Кичәне КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев ачты.

Докладны Г. Тукай юбилеена әзерләнү һәм аны үткәрү буенча республика комиссиясе председателе ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ясады.

РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Николай Доризо, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим, КПССның Арча райкомы беренче секретаре Д. К. Каюмов, ТАССР язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин, «Правда» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге редакторы урынбасары С. П. Кошечкин, Социалистик Хезмәт Герое, «Органик синтез» берләшмәсе аппаратчысы Л. Е. Смирнова, Үзбәкстан ССР язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Абдулла Арипов, Тукай районының «Ильбухтино» совхозы сыер савучысы В. С. Вәлиева, казах шагыйре Токэн Абдрахманов, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенткасы М. Айтуганова Г. Тукайның үлемсезлеге, шагыйрь иҗатының дөньякүләм әһәмияте турында сөйләделәр.

Кичә Татарстан сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

11 июньдә Казанда, Габдулла Тукай исемендәге мәйданда татар халкының бөек шагыйре музее ачылуга багышланган митинг булды. Бу тантанага йөзләрчә казанлылар, республика башкаласына Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган олы тантанага илебезнең төрле почмакларыннан килгән кунаклар җыелды.

Митингны Халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Идиятуллин ачты.

Татар халкының күренекле улы Г. Тукайның кыска, әмма сокландыргыч тормыш юлы, үлемсез шигърияте турында Казан дәүләт университеты доценты А. Г. Әхмәдуллин, «Литературная газета»ның бүлек мөдире А. Х. Хәкимов, Казан «Мединструмент» фәнни-производствосы берләшмәсе слесарь-инструментальщигы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты В. Н. Черепанов, Казан шәһәренең 80 нче мәктәп директоры, РСФСРның атказанган укытучысы Р. Г. Кагирова сөйләде.

Г. Тукай музеена керү юлындагы символик тасманы СССР Дәүләт премиясе лауреаты язучы Г. Б. Бәширов кисте.

Тукай урамындагы 63 нче йорт. Монда демократик карашлы яшьләр — Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиев катнашында «Әльислах» газетасын чыгарганнар. Редакциягә һәр көнне Габдулла Тукай килгән, көндәлек почтаны караган, хатлар укыган, аларга җаваплар язган. Буш вакытларында редакция урнашкан йортның ишегалдына малайлар күп җыелса,

урамга ук чыгып, алар белән рәхәтләнеп күзна уйнаган.

Ерак та түгел. «Шәрык» клубы, «Көфер почмагы», «Печән базары» һәм шагыйрьгә илһам биргән башка урыннар. Хөсәен Ямашев туган йорт. «Ялт-йолт» редакциясе. Хәзер бирелә «Тукай» кинотеатры урнашкан. Аның каршындагы мәйданны элек Юнусовлар мәйданы, мәйдан бакчасы, соңрак Тукай почмагы дип йөрткәннәр.

Бик иртә гомере өзелгән баласын озатырга җыелган халык урамнарга сыймаган. Шушы мәйданнан аны соңгы юлга — үлемсезлеккә озаталар.

Бу мәйдан, Казан шәһәр Советы башкарма комитетының ТАССР Министрлар Советы раслаган карары нигезендә, **Тукай мәйданы** дип йөртеләчәк.

12 июньдә Кырлайда меңләгән кеше катнашында шигырь бәйрәме башланды. Үзешчән сәхнә осталары гына да — алар район авылларыннан һәм Арчаның үзеннән килгәннәр — йөзәрләп. Үзешчәннәр иртәдән үк бәйрәмчә бизәлгән Г. Тукай мемориалының үзәк мәйданына җәелгән сәхнәдә осталык күрсәтәләр. Татар, рус, мари җырлары яңгырады, дәртле биюләр бер-берсен алмаштырып торды.

Кунаклар Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр салдылар һәм шагыйрь музеен зур кызыксыну белән карадылар.

Шигырь бәйрәмен ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Р. Фәйзуллин ачып җибәрде һәм алып барды.

Шигырь бәйрәмендә РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты рус шагыйре Н. Доризо, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты башкорт шагыйре Н. Нәҗми, каракалпак шагыйре Б. Каипназаров, чуваш шагыйре В. Эндип, Тукай шигырьләрен тәрҗемә иткән Р. Моран, Мәскәү шагыйрьләре М. Акчурин, В. Вәлиева, Р. Бохараев, гагауз шагыйре Н. Бобоглу, мари шагыйре Н. Рыбаков, башкорт шагыйрьләре Р. Сафин, Р. Бикбаев һәм К. Аралбаев һәм татар шагыйрьләренең шигырьләрен зур алкышлар белән каршыладылар.

РСФСРның атказанган артисткасы җырчы Фәридә Кудашева Тукай бәйрәмен җыр белән сәламләде.

Ахырдан Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты драматург Т. Миңнуллин бу олы бәйрәмне үткәрү өчен зур тырышлык куйган кырлайлыларга, арчалыларга, төзүчеләргә тирән рәхмәт хисләрен белдерде. Соңыннан Татарстан җыр һәм бию ансамбле зур концерт бирде.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты һәм Татарстан язучылар союзы Г. Тукайның туууына 100 ел тулуга багышлап Бөтенсоюз фәнни конференциясе уздырды.

Конференцияне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы, профессор М. Х. Хәсәнов ачты. «Габдулла Тукай — милли классик стильне иҗат итүче» дигән темага доклад белән филология фәннәре докторы Г. М. Халитов чыгыш ясады.

«Г. Тукайның иҗади үсешендә рус әдәбиятының роле» дигән докладны В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетыннан филология фәннәре докторы Т. С. Карлова сөйләде.

Тарих фәннәре докторы, профессор Р. И. Нәфиговның «Шагыйрьнең политик карашлары формалашуга карата: эшчеләр һәм социал-демократлар белән бәйләнеш», Ленинград дәүләт университетыннан филология фәннәре докторы С. Н. Ивановның «Тукайның рус теленә тәрҗемәләре», «Азәрбәйҗан ССР Фәннәр академиясенең Низами исемендәге Әдәбият институтыннан филология фәннәре кандидаты В. М. Кулиевның «Г. Тукай һәм XX йөз башында азәрбәйҗан-татар әдәби бәйләнешләре» дигән темаларга докладлары конференциягә килүчеләрдә зур кызыксыну уятты.

Көннең икенче яртысында Бөтенсоюз конференциясе үзенең эшен секциягә бүленеп дәвам итте. Анда Мәскәү, Үзбәкстан, Каракалпак АССР, Чувашия, Мари АССР, Дагыстан, Мордовия АССР, шулай ук Татарстан галимнәре катнашты.

Г. Тукай юбилеена килгән һәм Бөтенсоюз конференциясендә чыгып сөйләгән Хельсинки университеты профессоры, Финляндиядәге Тукай исемендәге культура җәмгыяте башлыгы Гомәр Таһирның чыгышын һәркем зур кызыксыну белән тыңлады.

Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое Мостай Кәрим, Ленин премиясе лауреаты академик К. Ә. Вәлиев конференциянең почетлы кунаклары булдылар.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган «Тукай укулары» булды.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре оештырган бу укуларда институт галимнәре белән бергә Казан дәүләт университеты, Казан һәм Алабуга педагогия институтлары, Казан культура институты, РСФСР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Казан филиалы галимнәре, Татарстан Культура министрлыгы хезмәткәрләре, язучылар, композиторлар, рәссамнар катнашты. Барлыгы 40 лап доклад тыңланды.

Татарстан сәнгать музее, татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулуга туры китереп, халык һәм хәзерге заман декоратив-гамәли сәнгате буенча фәнни-практик конференция уздырды.

Конференциядә сәнгатьнең шушы төренә кагылышлы теория мәсьәләләре, проблема һәм тикшеренүләр буенча, музей коллекцияләрен комплектлау һәм аларның тарихы турында ике дистәгә якын доклад һәм белдерү-

ләр тыңланды. Фәнни чара эшендә Татарстан белгечләре белән беррәттән, Чувашия, Удмуртия, Калмык АССР, Мари АССР һәм Пермь галимнәре, СССР халыкларының декоратив-гамәли сәнгате дәүләт музее вәкилләре катнашты.

Конференциягә килгән белгечләр Зеленодольскидагы халык сәнгать музеенда, Зөя шәһәрендәге музей-заповедникта булдылар, фольклор ансамбле чыгышын карадылар.

Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулган көннәрдә Уральск өлкә тарих-крайны өйрәнү музееның әдәбият филиалында экспозиция ачылды.

Уральск һәм Казан галимнәре, крайны өйрәнүчеләр туплаган документлар һәм материаллар шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйли. Алар арасында Тукайның, беренче рус революциясендә актив катнашучы буларак, халыкның самодержавиегә каршы көрәше турында шигырьләре аерым урын алып тора.

БАССРның Стәрлетамак шәһәрендә Г. Тукайның 100 еллыгы киң билгеләп үтелде. Шәһәрнең китап сөючеләр җәмгыяте «Габдулла Тукай һәм Анна Ахматова» дигән тематик кичә уздырды. Шулай ук Химиклар культура сараенда, культура-агарту училищесында, «Сода» производство берләшмәсендә шагыйрь иҗатына багышланган юбилей кичәләре узды. Аларда Стәрлетамак язучылар оешмасы секретаре шагыйрь Р. Нигъмәтуллин, педагогия институты доценты И. Вәлитов, культура-агарту училищесы укытучысы Г. Әпсәләмов һ. б. Тукай иҗаты турында сөйләделәр, шагыйрьнең иҗатына багышланган концертлар булды.

Куйбышев шәһәрендә В. И. Ленин исемендәге металлургия заводының культура сарае каршындагы «Ялкынлы яшьлек» җыр һәм бию ансамбле сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган яңа программасын күрсәтте. Аның белән иң беренче «Юбилейный» культура йортында Тольятти шәһәре хезмәт ияләре таныштылар.

Концерт инструменталь группа башкаруында «Туган тел» көе белән башланып китте. Бу концертның беренче бүлегендә тамашачы игътибарына Г. Тукайга багышланган әдәби-музыкаль хореографик композиция тәкъдим ителде.

Концертта ансамбльнең барлык группалары да катнашкан иде. Гыйниятуллина җитәкчелегендәге хор сөекле шагыйребезнең «Туган тел», «Туган авыл», «Бәйрәм бүген» дигән җырларын башкарды. Инструменталь группа «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» көйләрен уйнады. Ансамбльнең балетмейстеры Р. Гыйззәтуллин тарафыннан «Шүрәле» поэмасы нигезендә куелган «Шүрәлеләр», «Утынчылар» биюләре композицияне тагын да төрлеләндерде. Г. Тукай әсәрләрен һәм тугандаш халыклар шагыйрьләренең бөек әдәбиятыбызга багышланган шигырьләрен кичәне алып баручы инженерлар И. Колючев, Р. Фәхретдинов, Г. Әхмәтҗанова укыдылар.

Прозаиклар Р. Кәрами, М. Насыйбуллин һәм яшь шагыйрь Г. Моратов 5 — 8 майда Устинов шәһәрендә булып кайттылар. Алар шәһәрнең хезмәт коллективларында удмурт әдипләре белән бергәләп Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби кичәләр үткәрделәр.

Румыниядә Тукай исеме инде шактый күптәннән бирле телгә алынып килә. 1916 елда бастырган «Ике Себер» дигән китабында румын язучысы Еужен Гога, мәсәлән, бөек татар шагыйренең вафат булуын белдереп, аның иҗатын Шиллерныкы белән тиңләгән иде. Тукай шигырьләре румын татарлары өчен чыгарылган 1 — 8 класс дәреслекләренә дә кертелде. Монда алар латин хәрефенә күчерелде һәм җирле сөйләш вәкилләре җиңел аңларлык хәлгә китерелде. Клуж (1967) һәм Тимишоара (1979) опера-балет театрлары сәхнәсендә «Шүрәле» спектакленең куелуы, аннары бу труппаларның татар балетын барлык өлкә үзәкләрендә гастрольгә алып баруы нәтиҗәсендә, Тукай иҗаты Румыниянең меңләгән тамашачыларына тагын да киңрәк танытылды.

Шагыйрьгә 100 яшь тулу уңаеннан Румыния җәмәгатьчелегенең Тукай иҗатына игътибар итүе яңа югарылыкка күтәрелде — 9 мартта илнең башкаласы Бухарестта махсус гыйльми утырыш уздырылды. Жорже Кэлинеску исемендәге Әдәбият тарихы һәм теориясе институты оештырган бу мәҗлесне институтның директор урынбасары профессор Ион Кицимия ачып җибәрде. Ул «Г. Тукай һәм А. Мицкевич» дигән кереш сүз сөйләде. Аннары филология фәннәре докторы Надрәт Мәмүт «Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты»-на багышланган докладын укыды. «Г. Тукай һәм балалар дөньясы» темасын институтның гыйльми хезмәткәре Лилиана Ботез яктыртты. Филология фәннәре докторы Әнвәр Мәмүт үзенең чыгышында «Г. Тукай һәм дөнья әдәбияты» темасын ачты.

Норвегиянең башкаласы Осло шәһәрендә чыга торган «Арбайдербладет» (рабочая газета) газетасының 1986 ел 14 апрель санында Г. Тукай турында мәкалә дөнья күрде. Һелена Краг тарафыннан язылган бу мәкаләдә татар әдәбияты классигының тормыш һәм иҗат юлына күзәтү ясалган һәм Тукайның фоторәсеме урнаштырылган.

# АВГУСТ, ИКМӘК...

Натюрморт... Татарстан сынлы сәнгатенең сугыштан соңгы чорында, сюжетлы-тематик картина, портрет һәм пейзаж белән беррәттән, әлеге жанр аеруча көчле үсеш алды. Туган як табигатенең бәяләп бетергесез гүзәллеге мондый әсәрләрнең төп аһәңен билгеле. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Евгений Зуев натюрмортларында, мәсәлән, җиребезнең бәрәкәт һәм матурлык чыганагы булуы бигрәк тә ачык гәүдәләндерелә. Автор тирә-яктагы гадәти әйберләрдә дә сәнгать сөючеләрне тәэсирләндерерлек шигърият күрә, озак еллар шәһәрдә яшәвенә карамастан, Идел буе киңлекләренә мәхәббәтен киметми, туган туфракның хезмәт кешесенә юмарт булуын әсәрдән-әсәргә калкурак күрсәтергә омтыла.

«Урман бүләкләре», «Җир җимешләре»... Әсәрләренең исемнәреннән үк күренгәнчә, Е. Зуев урман-кырларның үзенчәлекле портретын тудыра. Аларда рәссамның идея-эстетик карашлары да ачык чагыла. Натюрмортларда ватанчылык башлангычына зур әһәмият бирелә. Полотноларда без бөтен халыкка аңлаешлы гадәти предметларны күрәбез. Җитмешенче еллар башында иҗат ителгән натюрмортлар сериясен генә алыйк. Елның унике аена багышланган әлеге җыелмада рәссам аерым фасылларның кабатланмас эчтәлеген образлы-символик тоем ярдәмендә тирәнтен ачуга ирешкән («Июль, җиләкләр», «Октябрь, кәбестә» һ. б.). Шулар арасында «Август, икмәк» исемлесе күңелгә аеруча якын булуы белән аерылып тора.

Авылча чигелгән пөхтә эскәтер өстендә — ипи (карасы да, агы да), суган, кисеп ясалган тоз савыты, пычак, тар муенлы чүлмәк, агач кашык... һәркемгә үз әйберләр. Әлеге әсәр чын мәгънәсендә күңелне кузгата. Үзеңне авыл өендә итеп сизә башлыйсың. Әле генә мичтән чыккан ипи исе килә төсле. Тәрәзәләрдән август аеның алтынсу нурлары бөркелә. Август икмәге, яңа уңыштан пешерелгән ипи... Яшәү символын гәүдәләндергән әлеге икмәктә без игенченең фидакарь хезмәт нәтиҗәсен дә, халкыбызның кунакчыллыгы образын да күрәбез, фронтовик-рәссамның игенче һөнәре өчен тыныч аяз күкнең мөһим шарт булуы турында искәртүен дә сизәбез.

**Юрий ГОРШУНОВ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
өлкән фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенчә битендә:** күренекле әдип, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фатих Хөсни.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1987 ЕЛДА

Татар совет әдәбиятының күренекле әсәрләре укучыларга иң элек «Казан утлары» журналы аша барып ирешә.

Редакция портфелендә язучыларыбызның күләмле проза әсәрләре байтак. Менә аларның кайберләре:

Нурихан Фәттах. «Сызгыра торган уклар» романының икенче китабы.

Мәдинә Маликова. «Басып сайрар талы бар». Роман.

Гариф Ахунов. «Идел кызы» романының икенче китабы.

Нәби Дәүли. «Без дөньяга килдек» повестеның икенче китабы.

Рафаил Төхфәтуллин. «Чатта тукталу». Повесть.

Миргазиян Юныс. «Таңда Босфор аша». Повесть.

Вакыйф Нуруллин. «Җавап бир...» Повесть.

Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов, Мәгъсүм Насыйбуллин һ. б. журнал өчен яңа әсәрләрен төгәлләп киләләр.

«Казан утлары» поэзия һәм драматургия әсәрләренә, тугандаш халыклар әдипләренә, яшь язучылар иҗатына, бүгенге көн проблемаларын күтәргән очерклар һәм публицистик мәкаләләргә, әдәби хәрәкәт, тарих, сәнгать мәсьәләләренә киң урын бирә. Иҗат серләре турында яңа язмалар, әдәби мирас үрнәкләре, истәлекләр, хатлар укучыларыбызда шулай ук кызыксыну уятыр.

Журнал сәхифәләре сезгә киләсе елда да рухи канәгатьлек, яңа очрашулар шатлыгы алып килер дип уйлыйбыз.

«Казан утлары»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

РЕДКОЛЛЕГИЯ.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)